Академия наук Республики Татарстан
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МИЛЛИ ЯҢАРЫШЫ

ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ

2018 ел, 6–7 сентябрь. Казан шәһәре

# ГАЯЗ ИСХАКИ И НАЦИОНАЛЬНОЕ ВОЗРОЖДЕНИЕ ТАТАР В НАЧАЛЕ XX ВЕКА

МАТЕРИАЛЫ МЕЖДУНАРОДНОЙ КОНФЕРЕНЦИИ

6–7 сентября 2018 года, город Казань

# GHAYAZ ISHAKI AND NATIONAL RENAISSANCE OF THE TATARS AT THE BEGINNING OF THE 20th CENTURY

PROCEEDINGS OF THE INTERNATIONAL SCIENTIFIC CONFERENCE

6–7 September, 2018, Kazan

КАЗАНЬ
2018

УДК 821.512.145
ББК 83,3(2Рос=Тат)
Г 30

*Печатается решением Ученого совета
Института языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ*

**Составители:**

***Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина***

**Г 30 Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века:** материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ, 2018. – 450 с.
ISBN 978-5-93091-253-1

В сборнике представлены материалы международной научно-практической конференции «Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века», посвященной 140-летию со дня рождения классика татарской литературы Г. Исхаки.

В статьях сборника творчество Гаяза Исхаки освещается в контексте тюрко-татарской и мировой литературы, а также раскрываются социально-философские, общественно-политические, эстетические и языковые аспекты художественного, публицистического и эпистолярного наследия писателя.

Издание адресовано преподавателям, аспирантам и студентам, а также всем, кто интересуется данной темой.

Материалы публикуются в авторской редакции. За содержание ответственны авторы публикаций.

**ISBN 978-5-93091-253-1**

© Оформление. Институт языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2018

**Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләховның «Гаяз Исхакый һәм ХХ йөз башы татар милли яңарышы» халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучыларга**
**СӘЛАМЛӘҮ СҮЗЕ**

Хөрмәтле коллегалар, кадерле кунаклар!

Танылган язучы, драматург, җәмәгать эшлеклесе, публицист, тәнкыйтьче һәм журналист Гаяз Исхакый – татар халкының милли-мәдәни тормышында гаять зур урын алып торган шәхесләрнең берсе. ХХ йөз башы татар әдәбиятын һәм сәнгатен аның бай иҗатыннан башка күз алдына да китереп булмый. Талантлы әдип татар яңарышы дулкынында иҗат мәйданына килә. Аның язу стиле чор рухы белән тыгыз бәйләнештә формалаша һәм ул яңа татар реалистик әдәбиятын тудыручыларның иң күренеклесе булып таныла.

Г. Исхакый татар әдәбиятына яңа тема-мотивлар алып керә, милләт язмышын чагылдырган, милли яшәү рәвешен, милли геройларны тасвирлаган әсәрләрне киң әдәби мәйданга чыгара. Ул күтәргән тема һәм проблемалар төрки һәм Идел-Урал халыклары өчен дә гаять әһәмиятле булып, алар арасында да киң яңгыраш ала. Әсәрләрендә алгы планга куелган гомумкешелек кыйммәтләре бүгенге укучыга да якын.

Россия тарихында ХХ йөз башы сәяси, социаль-мәдәни үзгәрешләр белән характерлана. Шул шартларда татар халкы милли һәм социаль тигезлекне яклау хәрәкәтенә кушыла. Г. Исхакый әдәби әсәрләре белән генә түгел, бәлки сәяси, публицистик эшчәнлеге белән дә бу хәрәкәтнең алгы сафында була, татар халкының хокукларын яклап көрәшкә чыга. Ул 18 тапкыр кулга алына, төрмә михнәтләре кичерә.

Г. Исхакый яңа совет хакимиятен, пролетариат диктатурасына нигезләнгән системаны кабул итми һәм 1918 елны эмиграциягә китә. Аңа Кытай, Япония, Германия, Польша, Төркия кебек илләрдә яшәргә туры килә. Әмма ул һәркайда татар милләтен кайгыртып иҗат итә, көрәш алып бара.

Әдип бай мирас калдыра: арада утызга якын проза, егермедән артык пьеса, публицистик һәм тарихи, аналитик язмалар, тәрҗемәләр, истәлекләр бар.

ХХ гасырның ахырыннан олы шәхеснең тормышын, иҗатын, хезмәтләрен өйрәнү, аңлату буенча җитди эш алып барыла. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әзерләп чыгарган 15 томлык «Сайланма әсәрләр» әлеге эшчәнлекнең матур һәм уңышлы нәтиҗәсе булып тора.

Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция олы әдип иҗатын татар милли яңарышы һәм тугандаш төрки әдәбиятлар белән тыгыз бәйләнештә бәяләүне максат итә. Аның эшендә Төркия, Казахстан, Азәрбәйҗан кебек илләрдән, Мәскәү, Уфа, Чебоксар, Чаллы, Әлмәт һ.б. шәһәрләрдән күпсанлы кунаклар катнашу – әдип иҗаты белән кызыксынуның зур булуын күрсәтә. Конференциядә җитди һәм актуаль мәсьәләләр буенча бәхәсләр, фикер алышулар булыр, фәнни нәтиҗәләр ясалыр дип ышанам. Конференция эшендә катнашучыларга уңышлар телим.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ: ХАЛЫККА КАЙТУ ЮЛЫ

***К.М. Миңнуллин** (Казан)*

В статье рассматривается процесс возвращения литературного наследия классика татарской литературы Гаяза Исхаки на родину. Определяются знаковые события, указывается вклад Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ и отдельных ученых-гуманитариев Татарстана в дело изучения, введения в научный оборот, популяризации личности, деятельности и творчества Исхаки. Говорится о некоторых задачах, стоящих перед гуманитариями республики по изучению и пропаганде наследия Исхаки.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, татарская литература, Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, возвращение источников, изучение наследия.

The paper considers the process of bringing the literal heritage of Gayaz Iskhaki back to his homeland. Authors define the significant events and the role the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Science of the Republic of Tatarstan and individual scholars have played in the process of study, promotion and returning into the research area of the G. Iskhaki's work. The paper also identifies the main problems on the promotion and study of G. Iskhaki's heritage that have to be considered by the humanitarian community of the Republic of Tatarstan.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, Tatar literature, Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Science of the Republic of Tatarstan, bringing back the sources, heritage study.

Гаяз Исхакый исеме татар халкы арасында XX гасырның беренче елларында ук танылу ала. Беренче өйрәнчек әсәрләре – «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) хикәясе, «Кәләпүшче кыз» (1900), «Бай угълы» (1903) повестьлары, «Өч хатын берлән тормыш» пьесасы (1900) басылып чыгуга, Татар укытучылар мәктәбендә белем алучы сәләтле яшь егет хакында сүз тарала. Әлеге әсәрләрне укыган Й. Акчура татарларда ике зур әдип күтәрелеп килүен, шуның берсе – хисле, сизгер, ялкынлы «милләтпәрвәр, идеалист вә романтик Гаяз» [1: 32] икәнлекне хәбәр итә. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) повесте татар дөньясында көчле каләм иясе пәйда булуны гомумбилгеле фактка әйләндерә. Хәтта каләмдәшләре иҗатын мактауга саран Г. Ибраһимов та аны «бөтен матбугатымызда иң югары торган бер әсәр» [6: 102] дип атый.

Шушы вакыттан ул татар әдәбияты тарихында «беренче классик язучы-прозаик» урынын ала. Әсәрләре күпмеңле тиражлар белән басыла, күптомлыклары әзерләнә, пьесалары сәхнәгә куела. М. Токтамышевның 1914 елда «шушы кешегә милли җирлектә туган яңа татар әдәбиятының башында тору роле насыйп була» [17: 183] дигән сүзләре аның иҗатына лаек бәя булып яңгырый һәм бүгенге көнгә кадәр татар әдәбият белеме фәне Исхакый иҗатын шушы югарылыкта тикшерә.

1905 елгы демократик үзгәрешләр дулкынында Гаяз Исхакый татар милли-сәяси хәрәкәтенең авангардына баса, татар халкының яңарыш хәрәкәтен җитәкли, аның барыр юлын билгеләүче әйдаманына әйләнә. Халык аны үзенең сәяси, иҗтимагый эшлеклесе, лидеры, «сәяси юлбашчысы» [2: 130] дип таный.

Россиядәге инкыйлаби үзгәрешләр нәтиҗәсендә Исхакый 1919 елда чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр була. 1954 елда йөрәге тибүдән туктаганчы алып барган тынгысыз һәм гаять нәтиҗәле иҗтимагый, сәяси эшчәнлеге тарихи өермәләр вакытында үз милләтен саклау һәм яклауга юнәлтелгән булып, ул татарның иң абруйлы, фикерле, эшлекле мөһаҗире булып танылa. Башта – Харбинда, аннары Франциядә, Германиядә, Польшада, Төркиядә яши, дөнья буйлап милләттәшләре яшәгән җирләргә сәяхәт итә, татар мөһаҗирләрен берләштерергә

омтыла. Кайда гына төпләнмәсен, татар оешмалары төзи, газеталар чыгаруны юлга сала, чыгышлар ясый, милләтенең кайчан да булса ирекә чыгасына өметен җуймый. «Гомумән алганда, мөһаҗир Г. Исхакый 1917 елдан соң татар әдәбияты өчен яңа бер тарихи әһәмиятле миссия башкарды. Әдәбиятыбызның үткәндәге милли асылына һәм максатчанлыгына тугрылыклы булып калып, ул совет илендә мөмкин булмаганны эшләде, ягъни милләт яшәеше һәм язмышының мөһим мәсьәләләрен яктыртуын дәвам итте, моның белән Октябрь инкыйлабыннан соңгы әдәбиятыбызны милли-мәгънәви яктан тулыландырды, баетты. Болар барсы Г. Исхакыйның XX йөз татар әдәбияты тарихындагы феноменаль урынын билгели» [11: 104].

Әмма үз илендә Г. Исхакый исеме онытылуга дучар ителә. Инде 1922–1924 елларда ук, иңгә-иң торган көрәштәшләре дә аңа яла ягудан тайчынмый (кара: Г. Ибраһимовның «Безнең заманның Әбүҗәһелләре, Ишмиләре, Пуришкевичлары»; «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» китаплары һ.б. [7]). Сталин репрессияләренә эләккән татар зыялыларын аның белән бәйләнеш тотуда гаеплиләр, совет хөкүмәте тарафыннан Исхакый иң куркыныч фигураларның берсе дип игълан ителә. Хәтта 1949 елның апрелендә аны Бөтенсоюз җинаятьчеләр исемлегенә кертәләр.

Мондый шартларда Исхакыйның мирасын өйрәнү түгел, хәтта телгә алу турында да сүз бара алмый. Әмма татар зыялылары, татар халкы хәтерендә Исхакый исеме, бик тирәнгә яшерелгән булса да, сакланып кила. Үзгәртеп кору хәрәкәте башлануга, 1987 елда күренекле язучы Әмирхан Еники язучылар алдында Исхакый исемен аклау, аның мирасын халыкка кайтару мәсьәләсен күтәрә. Аның белән бер үк вакытта диярлек, «Советская Татария» газетасының 1987 елгы 26 июль санында Р. Мостафин «Подъем затонувших сокровищ» мәкаләсендә язучы исеменә һәм әсәрләренә салынган «ярамый» богавын алып ташларга чакыра.

Әмма идеология үзгәргән заманда да әдип исемен аклау җиңел генә бармый. К.Ф. Фәсиев шул ук «Советская Татария» газетасының 1987 елгы 23 август санында Р. Мостафинга җавап биреп, «Не все то золото» мәкаләсендә Исхакыйны милләтче һәм контрреволюционер дип атый. «Агитатор сүзе» журналының 1987 елгы 13 санында М. Абдуллинның «Тарихның чүп-чар өемендә», «Советская Татария» газетасының 1989 елгы 20 май санында У. Беляловның «Гаяз Исхаки. Он же Шольц» кебек язмалары тәкъдим ителә, аларда Исхакыйның фашистлар белән хезмәттәшлеге турында сүз алып барыла. Аларга җавап төсендә Сәгадәт Чагатай «Минем әтием Германия сәясәтчеләре белән аралашмады» дигән мәкалә яза, тик ул илдә билгесез кала: «Шәһри Казан» газетасында 1993 елда гына басылып чыга. 1988 елны исә Ибраһим Нуруллинның «Вечерняя Казань» газетасының 17 октябрь санында «Возвращение Гаяза Исхаки» язмасы дөнья күрә, галим Исхакыйны «үз халык тарихының аерылгысыз өлеше», «яңа татар әдәбиятына, тәнкыйди реализмга нигез салучы» [13: 308–309] дип атый, XX йөз башы татар әдәбияты тарихын Исхакый иҗатыннан башка өйрәнү дөрес түгеллекне ассызыклый.

1989 елны «Дружба народов» журналының 8 санында И. Нуруллинның «Во имя научной объективности» мәкаләсе басыла, анда галим, Мәскәү югарылыгыннан торып, «Исхакый мирасын югалту – халык тарихыннан, аның яшәү рәвешеннән, гореф-гадәтләреннән, гасырлар буе камилләшкән әхлакый кыйммәтләрдән мәхрүм булып яшәү» дип белдерә [14: 326].

Шушы вакыттан Г. Исхакыйның исеме, иҗаты халыкка кайту процессы башлана: бер томлык әсәрләрен басмага әзерләү эшенә керешелә, газета-журналларда аерым әсәрләре басыла. Бу эшне галимнәр җитәкли. Алар

арасында Исхакый исемен телгә алырга ярамаган елларда аның турында материалларны бөртекләп җыя башлаган шәхесләр – Һәнүз Мәхмүтов, Ибраһим Нуруллин, Рашат Гайнанов, Лена Гайнанова, Альберт Фәтхи, Рашат Әмирханов, Мөхәммәт Мәһдиев, Зөфәр Рәмиев – исемнәрен аерып күрсәтергә кирәк. Күп кенә документлар, фотографияләр Төркиядән, андагы милләттәшләребез ярдәме белән кайтарыла.

Шунысын да әйтергә кирәк: татар халкы, үз тормышын куркыныч астына куеп, яшереп булса да, Исхакый китапларын кара елларда да саклап килә, укырга алар иң ышанычлы кулларга гына бирелә. Исемен аклау эше башлангач, Казанда, Татарстанда әдипнең гарәп язулы шактый китаплары табыла.

1991 елда Г. Исхакый әсәрләреннән төзелгән беренче җыентык – «Зиндан» зур тираж белән басылып чыга. Китапка текст һәм искәрмәләрне Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре Лена Гайнанова әзерли, Исхакый тормышы, эшчәнлеге, мирасы хакында язмаларның авторлары – И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов. Җыентыкта әдипнең 12 проза, 5 драма әсәре тәкъдим ителә. Монда урнаштырылган «Кәҗүл читек» белән «Сөннәтче бабай» шунда ук мәктәп һәм югары уку йорты дәреслекләренә кертелә. Исхакый мирасын кайтаруның торышын һәм алда торган эшләрне барлап, китапта И. Нуруллин болай дип яза: «Г. Исхакый иҗаты, бигрәк тә аның эмиграциядәге елларына караган өлеше, әле җитди өйрәнүне таләп итә. Әмма бу юнәлештә моңарчы башкарылган эшләр дә Гаяз Исхакый XX йөз башы татар мәдәниятендә үзәк фигура һәм бу чор татар әдәбиятына нигез салучыларның иң күренеклесе иде дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә» [15: 18].

1993 елның апрель аенда Татарстан хөкүмәте Г. Исхакый әсәрләрен 15 том итеп бастырып чыгарырга дигән карар кабул итә, бу эш Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына йөкләнә. Фәнни мөхәррир итеп Татарстан Фәннәр академиясенең президенты Мансур Хәсән улы Хәсәнов билгеләнә (аннары бу исемлекне М.В. Гайнетдинов, Ф.М. Мусин, З.З. Рәмиев тулыландыра). Унбиш томлык «Әсәрләр»не әзерләп нәшер итү – Г. Исхакый мирасының төп өлешен илгә кайтарып, халыкка җиткерү була.

Әлеге зур проект Г. Исхакыйның әдәби, публицистик әсәрләрен, шәхси хатларын, автобиографик язмаларын, тормышына һәм иҗатына караган документларны, аның турында истәлекләрне бергә туплый. Аны әзерләүчеләр Исхакый мирасына академик фән югарылыгыннан якын киләләр: һәр текстның язылу тарихына, чор һәм кешеләр белән бәйле фактларга, эчтәлегенә комментарийлар эшләнә, аңлатмалар языла, Исхакый һәм, гомумән, татар мәдәнияте белән бәйле бик күп вакыйгалар, персоналийлар, мәдәни күренешләр ачыклана, шәрехләнә. Шуңа күрә унбиштомлыкның һәр томы чын мәгънәсендә заман фәне югарылыгында әзерләнгән басма булып чыга.

1–4 нче томнарда әдипнең 1917 елга кадәрге мирасы: проза һәм драма әсәрләре бирелә. Программ әсәрләреннән «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Зиндан» повестьлары, «Зөләйха», «Мөгаллимә» драмалары урын алган. 5 нче том язучының мөһаҗирлектә иҗат ителгән проза һәм драма әсәрләрен үз эченә ала. «Көз», «Өйгә таба», «Локман Хәким», «Җан Баевич» кебек әсәрләре татар укучысына шушы томда ирештерелә. Әлеге томнарны басмага әдәбиятчы-текстолог Л. Гайнанова әзерли.

6–7 нче томнарга Исхакыйның публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыйнала. Бигрәк тә 1902–1914, 1915–1916 елларда «Тәрҗеман», «Таң йолдызы», «Казан мөхбире», «Бәян әл-хак», «Ил», «Сүз» газеталарында, «Әл-гасыр әл-җәдид» журналында басылган язмалары күпләп кертелә.

8 нче томда Исхакый тормышы һәм иҗаты хакында замандашлары язган мәкаләләр, рецензияләр, Казан губерна жандарм идарәсе документлары (1898–1917) китерелә. Әлеге томнар басмага әдәбиятчы-текстологлар Ф. Ибраһимова, З. Рәмиев, Э. Галимҗановалар катнашында әзерләнә.

9–13 нче томнар Исхакыйның Февраль инкыйлабы һәм аннан соңгы чорларда газета-журналлар битләрендә дөнья күргән мәкаләләреннән гыйбарәт. Аларны басмага әзерләүдә, аңлатма һәм искәрмәләр язуда әдәбиятчы-текстологлар З. Рәмиев, Э. Галимҗанова, Г. Хөснетдинова, З. Мөхәммәтшин, Г. Ханнанова һәм Ф. Кадыйровалар хезмәт куя.

Әдипнең төрле архивларда, музейларда, шәхси кулларда сакланып калган хатлары һәм автобиографик язмалары (1902–1954) 14 нче томга туплап бирелә. Аларны басмага Ф. Фәйзуллина әзерли. 1923–1990 елларда СССР һәм чит илләрдә Г. Исхакыйга бәйле басылган мәкаләләр, истәлекләр Г. Ханнанова һәм Р. Кадыйров әзерләгән 15 нче томда урын ала.

Гаяз Исхакыйның 15 томлык «Әсәрләр»е басылып чыгу татар әдәбияты, мәдәнияте, тарихы өчен гаять зур әһәмиятле вакыйгага әйләнә. Мирасның шулай зурдан, 15 том булып басылуы әдипкә кагылышлы материалларны академик югарылыктагы чыганаклар рәвешендә укучыга җиткерергә һәм системага салырга мөмкинлек бирә. Татар әдәбияты классигының мирасын халыкка кайтаруы һәм фәнни әйләнешкә кертүе өчен бу басма Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге иң югары бүләгенә – Дәүләт премиясенә лаек була. Әлеге бүләк томнарны әзерләүгә иң зур көч куйган галимнәр төркеменә – Зөфәр Рәмиев, Лена Гайнанова, Фатыйма Ибраһимова һәм Зөфәр Мөхәммәтшинга тапшырыла.

15 томлык «Әсәрләр» Исхакыйның шәхесен, аның язучы, матбагачы, публицист, сәясәтче буларак эшчәнлеген тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Әмма Исхакый белән бүгенге укучыны бер гасыр вакыт аерып тора. Моннан тыш, бер гасыр эчендә татар әдәбиятын, мәдәниятен өйрәнү Г. Исхакый мирасыннан башка алып барылган. Шуңа күрә дә әлеге мирасны кайтару аны халыкка җиткерүдә тиңе булмаган гамәлләрдә санала. Бу кыйммәтле мирас галимнәр, белгечләр өчен генә азык булып калмасын өчен, ул заман фәне югарылыгыннан бәяләнергә, аңлатылырга тиеш. Бу очракта без әдипнең аерым әсәрләрен анализлап, әдәби барышка урнаштыруны да, аларны сайлап, мәктәпләргә, югары уку йортларына җиткерүне дә, Гаяз Исхакыйның тормышын һәм эшчәнлеген гомумиләштереп бәяләүне дә, ул калдырган фикри һәм әдәби байлыкны популярлаштыруны да күздә тотабыз.

Татарстан галимнәре Исхакый мирасына шушы яссылыкта якын киләләр. Әдипнең әсәрләре кирилл хәрефләренә күчерелеп басыла башлауга, Татарстан Фәннәр академиясенең президенты М.Х. Хәсәнов аның иҗаты буенча кандидатлык диссертацияләре әзерләү мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әдип иҗатының мөһим чорларына яки аерым мәсьәләләренә караган тикшеренүләр гаять киң колач белән башланып китә. Исхакыйның 1917 елга кадәрге әдәби иҗатын этапларга бүлеп, Институтта 3 диссертация [19] яклана. Х.С. Шагбанова хезмәте – 1897–1910 еллар (1998), Р.А. Яруллина – 1897–1906 еллар (1998), С.Г. Сәмитова 1914–1917 еллар (2002) әдәби иҗатын колачлый. Бу хезмәтләрдә Исхакыйның илдә язылган әсәрләренә гомуми бәя бирелә, һәр әсәргә җентекле анализ ясала.

Болар белән янәшә, филология фәннәре докторы Ф.М. Мусин Г. Исхакый тормышы һәм эшчәнлеген өйрәнүне үзенең төп темасы итеп ала, 1998 елда, әдипнең тууына 120 ел тулуга багышлап, монографиясен бастырып

чыгара. М.Х. Хәсәнов фәнни редакторлыгында дөнья күргән бу китапта Г. Исхакыйның тормышы һәм эшчәнлеге, иҗаты ике этапка бүлеп тикшерелә: «Туган илдә» һәм «Мөһаҗирлектә», моннан тыш, җыентыкка Г. Исхакый турында әдәбият күрсәткече урнаштырылып, анда 1988 елдан безнең матбугатта дөнья күргән материаллар хакында да мәгълүмат бирелә [12].

Г. Исхакыйның тормышын һәм иҗатын өйрәнүне чорларга бүлеп, аларга хас үзенчәлекләрне билгеләп системалаштыру эшен Р.К. Ганиева башлый. 1998 елда галимә «Гаяз Исхакый иҗаты» дип исемләнгән махсус курс программасын булдыра, ул шунда ук мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен төп ярдәмлеккә әйләнә.

Шул ук 1998 елда М.Җ. Сәхапов «Гаяз Исхакый иҗаты һәм XX гасыр татар әдәбияты» дигән темага докторлык диссертациясе яклый, бер-бер артлы язучы эшчәнлегенең төрле якларын татар мәдәниятенең гомуми агымында чагылдырган монографияләр [16] бастыра, шул исәптән, Гаяз Исхакый исемен рус һәм инглиз телләрендә дә яңгырата.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты галимнәрне аеруча кызыксындыра. 2002 елда Г.И. Зәйнуллина тарафыннан шушы темага кандидатлык диссертациясе яклана [5]. 2005 елда, Башкортстаннан килеп, И.С. Мансуров Гаяз Исхакый иҗатын татар мөһаҗирият әдәбияты контекстында тикшергән хезмәтен яклый [9]. Филология фәннәре докторы Х.Й. Миңнегулов татар мөһаҗирият әдәбияты хакында берничә зур хезмәт язып бастыра [10].

Болардан тыш, Исхакый иҗатына бәйле аерым мәсьәләләр А.А. Кәримова (2000), Р.Ф. Харрасова (2002), Ф.И. Габидуллина (2004), Д.М. Хәйруллина (2005), Г.Х. Якупова (2006), А.О. Кадырова (2007), Т.А. Абдулбариева (2010), Л.М. Гайнанова (2010) һ.б.ның диссертацияләрендә [8] тикшерелә.

Гаяз Исхакый тормышы, иҗаты буенча барлыгы 2 докторлык, 18 кандидатлык диссертациясе якланып, шуларның 1 се –тарихи мәсьәләләргә, 3 се – текстларның теленә, 1 се публицистик мирасына кагыла, калганнары әдәби иҗатын үзәккә куя. Барлык диссертацияләр дә диярлек, үз чиратында, махсус фәнни монографияләр булып дөнья күрә. Алай гына да түгел, татар галимнәре Исхакый мирасы белән бәйле ачыла башлаган, моңа кадәр мәгълүм булмаган материалларны әйләнешкә керткән фәнни хезмәтләр язалар: Х.Й. Миңнегуловның «Гаяз Исхакый: Ислам мәмләкәтләрендә» (2003), З.Г. Мөхәммәтшинның «Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай» (2006) һ.б. китаплар шундыйлардан.

Фәнни тикшеренүләр белән бергә, даими нигездә Г. Исхакыйның юбилейларына багышлап фәнни конференцияләр оештырыла, аларның материаллары дөнья күрә. 2000 елда Казанда әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара конференция үткәрелә, аның материаллары басылып чыга [3], 2008 елда Казанда Исхакыйның 130 еллык юбилеена мөнәсәбәтле чара да зур галимнәр, чит ил кунаклары катнашында уза [4]. 2008 елда Уфада да Гаяз Исхакыйның 130 еллыгына багышлап «Идел–Урал регионында туган тел һәм әдәбиятларның яшәеше» дигән бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырыла, аның материаллары нәшер ителә.

1991 елда Чистай районының Яуширмә авылында Гаяз Исхакый музее ачылу әдип мирасын өйрәнү һәм популярлаштыруны аның туган төбәге белән тагын да тыгызрак бәйләү мөмкинлеге бирә. Шул ук елда Татарстан Язучылар берлеге тырышлыгы белән әдип исемендәге әдәби премия булдырыла.

Г. Исхакыйның мирасын кайтару белән бәйле оештырылган чараларны гомумиләштереп күзәтү күп кешеләр тырышлыгы, көче, инициативасы белән 30 ел эчендә бик зур, масштаблы эшләр алып барылуы турында сөйли.

Шуның белән бергә, Гаяз Исхакыйның – гомерен милләткә, халкын үстерүгә багышлаган шәхеснең эшчәнлеген пропагандалау, иҗат мирасын халыкка тагын да якынайту юлында алда торган эшләребез дә байтак әле. XX гасыр башы зыялылары да, бүгенге галимнәр дә Исхакыйның әдәбият тарихындагы урынын Г. Тукай белән янәшә күзаллый. Г. Тукай үзе дә аңа: «И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа! / И мосаувир! Кемгә биргән пакъ вә чын сүз кибриа»[18: 288] (барысын күрә торган «яшен күз»ле, пакь вә чын сүз»ле бөек язучы-рәссам) дип эндәшкән!

Әмма бүген Г. Исхакый халкыбызга, аның олысына-кечесенә Тукай дәрәҗәсендә билгеле дип булмый әле. Аның иҗатын уку-укыту процессының төрле баскычларында тәкъдим итү, бигрәк тә кече яшьтән, балалар бакчасыннан ук Исхакый әсәрләре хакында мәгълүмат бирү юлларын табасы бар! Рус телле укучыга да Исхакый әсәрләре җитәрлек күләмдә тәкъдим ителә дип булмый. Исхакый әсәрләренең әдәби-эстетик үзенчәлекләрен, аларда тәкъдим ителгән тема һәм мотивларны татар әдәбияты һәм дөнья әдәбияты фонында өйрәнү дә үз тикшеренүчеләрен көтә.

Фәнни яктан алда торган эшләребезне күзалласак, 15 томлык басылып чыкканнан соң да Татарстанга Исхакыйга бәйле шактый күп мәгълүматлар, материаллар кайтты. Аларны академик дәрәҗәдә әзерләп, бергә туплап халыкка тәкъдим итү хакында да уйланасыбыз бар. Татарлар чит җирләрдә чыгарып килгән журналларны (әйтик, Исхакый 11 ел дәвамында «Милли юл»ның 136 санын чыгарган) чыганаклар буларак фәнни әйләнешкә кертү дә – алда торган бурычлардан. Гомумән алганда, Исхакыйның публицистик, иҗтимагый-сәяси эчтәлекле хезмәтләрен тикшерү, шәрехләү, аңлату да башланып кына килә әле.

Әлбәттә, шәхеснең мирасын пропагандалау аның исемен популярлаштырудан башлана. Гаяз Исхакый исеме белән бәйле биналарга истәлек такталары урнаштыру, Казанда һәм Чистайда аңа һәйкәлләр кую, музейларын ачу сорала. Яуширмә музеенда ел саен уздырыла торган Исхакый укуларын башлап җибәрү дә бу бөек шәхескә ихтирам һәм игътибарны арттырыр кебек. Музейның үзен исә республикага килгән туристлар маршрутларына урнаштыру зарур.

Гомумән алганда, алда торган эшләр турында бергәләп киңәшләшү һәм аларны бергәләр башкару мәслихәт. Гаяз Исхакыйның бай мирасы халыкның хәзинәсе булып яшәргә, ерак гасырларга тапшырылырга лаек.

ӘДӘБИЯТ

1. Акчура Й. Гаяз әфәнде // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т. 8: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары (1898–1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 31–36.

2. Акыш Г. Гаяз Исхакый – Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т.15. Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында истәлекләр һәм мәкаләләр (1923–1990). Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 129–145.

3. Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: Әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2000. 296 б.

4. Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 11 дек., 2008). Казан, 2008. 376 б.

5. Зайнуллина Г. И. Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции: дис. … канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2002.

6. Ибраһимов Г. Әдәбият агымы // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т. 8: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары (1898–1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 101–103.

7. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 9 томда.Т. 9: Хатлар һәм документлар. Казан: Фикер, 2000. Б. 106–109.

8. Каримова А.А. Идейно-эстетическая эволюция проблемы феминизма в творчестве Гаяза Исхаки: дис. … канд. филол. наук / КГУ. Казань, 2000; Харрасова Р.Ф. Ранняя проза Гаяза

Исхаки в контексте литературных взаимосвязей (1894–1905): дис. … канд. филол. наук / КГУ. Казань, 2002; Габидуллина Ф.И. Гаяз Исхаки – романист (проблематика и ее художественное воплощение): дис. … канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2004; Абдулбариева Т.А. Традиции классицизма в драматургии Гаяза Исхаки: к проблеме мотивов государственности: дис. ... канд. филол. наук / КГУ. Казань, 2010; Гайнанова Л.М. Художественное пространство и время в прозе Гаяза Исхаки: дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2010. и т.д.

9. Мансуров И.С. Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции: дис. … канд. филол. наук / ГОУВПО «Башкирский государственный университет». Казань, 2005; Мансуров И.С. Татар мөһаҗирияте. Стәрлетамак, 2003. 162 б.

10. Миңнегулов Х. Исхакый мөһаҗирлектә. Казан: Таң-Заря, 1999. 84 б.; Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.; Миңнегулов Х. Чит илләрдәге татар әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2007. 399 б.

11. Мусин Ф. Милләт сагында // Казан утлары. 2008. № 2. Б. 95–104.

12. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

13. Нуруллин И. Возвращение Гаяза Исхаки // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т. 15. Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында истәлекләр һәм мәкаләләр (1923–1990). Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 308–309.

14. Нуруллин И. Во имя научной объективности // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т.15. Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында истәлекләр һәм мәкаләләр (1923–1990). Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 323–326.

15. Нуруллин И. Гаяз Исхакый (әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача бер күзәтү) // Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 5–18.

16. Сәхапов М. Исхакый иҗаты: монография. Казан: Мирас, 1997. 368 б.; Сәхапов М. XX гасыр башы татар әдәбияты һәм Гаяз Исхакый иҗаты: монография. Казан: Таң-Заря, 1998. 105 б.; Сәхапов М. Яңарыш хәбәрчесе. Казан: Мәгариф, 2003. 368 б.; Сәхапов М. Бердәм агым. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 399 б.; Сахапов М. Творчество Гаяза Исхаки и татарская литература XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1998. 60 с.; Сахапов М. Исхаки и золотая эпоха татарского ренессанса. Казань: Логос, 2002. 528 с.; Сахапов М. Гаяз Исхаки: начальный этап творчества. Казань: Мастер Лайн, 2003. 84 с.; h.б.

17. Токтамышев М. Татар әдәбияты һәм Исхаков // Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. Т. 8: Гаяз Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары (1898–1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 183–186.

18. Тукай Г. Мөхәрриргә // Габдулла Тукай. Әсәрләр: томда. Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.

19. Шагбанова Х.С. Становление творчества Гаяза Исхаки (1897–1910 гг.): дис. … канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 1998; Яруллина Р.А. Идейно-эстетическое своеобразие творчества Г. Исхаки (1897–1906): дис. … канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 1998; Самитова С.Г. Идейно-эстетическая эволюция творчества Гаяза Исхаки (1914–1917 гг.): дис. … канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2002.

# Г. ИСХАКЫЙНЫҢ ӘДӘБИ ИҖАТЫ: МИЛЛӘТНЕ ҮСТЕРҮ-ҮЗГӘРТҮ ЮЛЫН ЭЗЛӘҮ

***Д.Ф. Заһидуллина*** *(Казан)*

В статье рассматривается художественное творчество Гаяза Исхаки с точки зрения присутствия в нем различных кодов, регулирующих создание текста. Кроме общелитературного кода, пробуждающего читателя прочитать текст как художественное произведение, в творчестве писателя обнаруживается публицистический код (просветительской или общественно-политической направленности), условно-символический код, национально-философский код. На материале анализа произведений Г. Исхаки определяются точки трансформации в его творчестве, произведения, которые стали знаковыми в эволюционном пути художественного поиска.

**Ключевые фразы:** татарская литература, Гаяз Исхаки, публицистический код, условно-символический код, национально-философский код, идейно-эстетическое своеобразие.

In the article art creativity of Gayaz Iskhakiy from the point of view of presence at him various codes regulating creation of the text is considered. Except the common-literary code awakening the reader to read the text as the work of art, in works of the writer the publicistic (of educational or social and political orientation), conditional and symbolical, national and philosophical codes are found. On material of the review of G. Iskhakiy's works transformation points in his creativity, works which became sign in an evolutionary way of art search are defined.
**Key phrases:** Tatar literature, Gayaz Iskhakiy, publicistic code, conditional and symbolical code, national and philosophical code, ideological and esthetic originality.

Г. Исхакый бай әдәби иҗат мирасы калдыра: бу мираста гомумиләштереп санаганда 3 роман, 30 лап повесть һәм хикәяләр, ике дистәгә якын драма әсәрләре бар. Алар бүгенге укучы күзлегеннән дә актуальлекләрен җуймаганнар, укылалар – заман фәне сүзләре белән әйтсәк, аларда шушы укылышны тәэмин итә торган «гомумәдәби код» беренче урында тора[1].

Әмма Г. Исхакыйның әдәби иҗаты шушы билге – «гомумәдәби код» чикләрендә генә кала алмый: аның һәр әсәре «башка кодлар» калку күренеп торырлык итеп язылган. Чөнки ул – иң беренче чиратта, бер милләтнең тормыш-яшәешен үзгәртергә алынган, тотынган кеше! Аның өчен әдәбият та – шушы юлда үтемле корал, кешеләрнең аң-акылына үтеп керү чарасы, фикер белдерү чыганагы. Шушы яктан якын килгәндә, Г. Исхакый әсәрләренең уртак сыйфаты – халыкны, милләтне үстерү-үзгәртү юлын эзләү икәнлеге ачык.

Г. Исхакый әдәби әсәрләренә әдәбият үлчәмнәре белән генә якын килү мөмкин түгеллеккә аның иҗатын бәяләүчеләр үз заманында ук игътибар итәләр. Бигрәк тә Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926) хезмәтендә иҗатын, язучының фикри юлы үзгәрү нигезендә чорларга бүлү омтылышы ясала: җәдидчелек чоры; «социализмга охшаш бер ис аңкый торган Гаяз»; милләт язучысына әверелү чоры [10]. Хәзерге татар әдәбият белемендә бу фикерләрне Р.К. Ганиева хезмәтләре гомумиләштерә. Ул Г. Исхакый иҗатын дүрт этапка аера: «мәгърифәтчелек» (1897–1904); «таңчылык» (1905–1910); «милләтчелек» (1910–1918) һәм «мөһаҗирлек» (1919–1954) чорлары [3: 7–8].

1898 елда Татар укытучылар мәктәбендә укый башлаган 20 яшьлек Гаязның беренче иҗат җимешләре «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1899) хикәясе, «Кәләпүшче кыз» (1900), «Бай угълы» (1903) повестьлары, «Өч хатын берлән тормыш» пьесасы (1900) – өйрәнчек әсәрләр, әмма алар татар әдәби барышында зур бер күренеш кебек кабул ителәләр. Бер яктан, әлеге әсәрләрдә әле «гомумәдәби кодның» тиешле югарылыкка куелмаганын искәртергә: ягъни әсәрләрнең әдәби-эстетик сыйфаты түбән булуга игътибар итәргә кирәк. Моның урынына аларда мәгърифәтчелек, үгет-нәсихәтчелек, мораль уку алга чыга: мәгърифәтчел эчтәлекле публицистик код калку. Бу – гомумән XIX–XX гасырлар чиге татар әдәби барышына хас сыйфат. Әмма сюжет төзи белү, образ-геройларның җанлы килеп чыгуы, язучының каләмгә үз милләттәшләренең аңын үзгәртү чарасы итеп каравы инде әсәрләрнең укылышын тәэмин итә. Бу урында Җ. Вәлидинең сүзләрен мисалга китерергә мөмкин: «Булар – никадәр саф диланә вә никадәр әхлакчы. Буларда әле сәнгать бик азны күргән. Типлар юк, сурәтләр дә гаять юка булып, алар артында яшеренгән вәгазь иң гади күзгә күренеп тора. <...> Шулай да булса, ул шул вакытта ук үзенең истигъдадын, табигатен, хөласан, Гаязлыгын күрсәтә. Аның язганнарында башкаларда күрелмәгән бер хөлус вә җитдият күрелә. Ул чагында

[1] Бу очракта без француз галиме Р. Бартның һәм һолландияле Д. Фоккеманың әдәби текстта төрле ассоциатив катламнар, кодлар булу хакындагы нәзарияләренә таянабыз.

ук милләтнең чын авыруларын карый, зур яраларын күрсәтә, күп сырланмый, фәлсәфә сатмый» [2: 123].

«Кәләпүшче кыз» повестеның кереш сүзендә Исхакый «Камәр кеби булуның ахыры ни булачагын күрсәтеп, милләтемнең туташларын шул кара бәхетләрдән коткарыр өчен» [6: 51] каләмгә тотынуын белдерә. «Өч хатын берлән тормыш»ның керешендә язучы үзенең күп хатын алуны кире кагу һәм Риза мисалында бер хатын белән торуның уңай күренеш икәнен күрсәтү максаты куюын әйтә. «Бай угълы»ның 1903 елгы басмасына кереш сүзендә фикер тагын да төгәлләшә төшә: «Минем бу эшем, милләттәшләрем арасында бик күп вакыйгъ була торган мөдһиш бер хәлне язып мәйданга куюым, башка кешеләргә үз гаебемезне белдерер өчен түгелдер. Кирәк бер кешенең булсын, кирәк бар милләтнең булсын, бер гаебене юк итеп күрсәтү яки яшерергә тырышу хәер хаһлык түгелдер. Чөнки бу эш шул кешене яки шул милләтне шул начар хәлендә дәвам итүене теләү буладыр. Билгакес, гаебене күрсәтеп, шуннан котылыр өчен юл күрсәтү хәер хаһлыктыр. Милләтемездә шул мәсьәләне ислах фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем. Җәнабе хак һәрберемезгә хак фикерләр биреп, хәмияте миллиямезне уяндырып, ватаныбыз, милләтемезнең файдасына тырышырга насыйп итсен!» [6: 113–114].

Бу сүзләр Исхакыйның ни өчен әдәбиятка килү сәбәпләрен ачып бирә. Әсәрләр халык тормышындагы кимчелекле якларны аның үзенә күрсәтү, кавемдәшләрен шулардан арынырга чакыру максаты белән иҗат ителгән: шуңа да аларда мәгърифәтчел эчтәлекле публицистик код беренче урында тора. Язучы халкын үсү-үзгәрүдән тоткарлый торган күренешләрне барлый, аларны тәнкыйтьли, халыкның үзенә күрсәтә һәм алардан арынырга чакыра!

Алга таба Г. Исхакый әсәрләренең пафосы, мәгънәви һәм форма ягы зур үзгәрешләр кичерә. Әмма мәгърифәтчел-публицистик код, төп позициядән чигенсә дә, югалмый: ул соңгы әсәрләренә кадәр башка кодлар белән янәшә мөһим урынын саклап кала. Шуңа бәйле бу иҗатта әсәрләрне җыеп торучы үзәк – һәрвакытта да автор аңы, язучы фикере-идеясе дия алабыз.

Г. Исхакыйның беренче әсәрләреннән соңгы иҗади эзләнүләре, әдәбиятта үз юлын табарга омтылуы үзгә характердагы әсәрләр язуында ачык күренә. Без тәрҗемә ителеп, татар проблематикасына якынайтып тәкъдим ителгән «Ике гашыйк» (1901–1903) пьесасын шушы яссылыкта карыйбыз. 1903 елда яшь геройлары яшәешендә мәхәббәт, гаилә һәм бурыч мәсьәләләренә романтикларча, лирик-сентименталь дулкында якын килгән әсәр – «Очрашу, яки Гөлгыйзар» повесте языла. Монда пароходта очрашкан Габдулла белән Гөлгыйзарның мөнәсәбәтләре шәхси-психологик яссылыкта сурәтләнә. Әсәрдә гомумәдәби код беренче урынга чыга: ул романтик-сентименталь характерлы. Әмма сөю хисе татар җәмгыятендә яшәгән гадәтләр корбанына әверелә: адәм балалары өчен табигый кичерешләрнең иске карашлар белән каршылыгын үкенеч, сызлану озата бара. Бу очракта да язучының мәгърифәтчел максаты күренә. Сызлану – тәнкыйть, мөнәсәбәт белдерү белән сугарылган.

Повестьта «сынап каралган» психологизм алымнары, бигрәк тә уй-кичерешләрне герой затыннан өзмичә күзәтә бару, кеше хисләрен табигать белән янәшәлектә тергезү, символларга мөрәҗәгать итү татар әдәбиятын, татар дөньясын үзгәрткән әсәр – «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) повестенда гаять мөһим сыйфат үзгәрешләренә китерә.

Повестька җентекле анализ ясаган Г. Гобәйдуллин аның концепциясенең америкалы Эдвард Белламиның «Йөз ел соңра» (1888) социаль-утопик романы йогынтысында формалашуын әйтә [4: 81]. Роман Американың йөз елдан соң нинди зур алгарышка ирешүен күрсәтү максат итеп куйса, Г. Исхакый

әсәрендә ике йөз елдан соң татар халкының милли фаҗига кичерүен, инкыйразын-бетүен чагылдыру үзәк урын ала: ул «төрки-татар әдәбиятлары тарихында беренче антиутопия» [3: 11] булып чыга.

Повестьта публицистик код Исхакыйның милләт үсешен тоткарлый һәм аны һәлакәткә китерә торган сәбәпләр хакында уйлануы төсен ала. Татарда тормыш тоткасы иске карашлы руханиларда булу; мәктәп-мәдрәсәләрнең азлыгы, булганнарында да укытыла торган фәннәрнең тормышта яраксызлыгы; милләткә хезмәт итүче зыялыларның, бик ярлы сыйныфтан чыгып, көчләрен күбрәк тамак туйдыруга сарыф итүләре; яшьләрне рус мәктәпләрендә укытуга каршы килү; эшне башлап та ахырына җиткерә белмәү – шундыйлардан. Исхакый аларның халыкны фаҗигагә китерәчәген дәлилли. Милләтнең буш эшләр белән йөрүен, татар руханиларының юк-бар сораулар тирәсендә гауга куптарып бәхәсләшүләрен, яңача һәм искечә укыту тартышларын, русча укытуга кагылышлы бәхәсләрне, шушы «эшләрнең» мәгънәсезлеген шәрехли, аларны җәмгыятьнең чире дип бәяли. Бу авыруга «дәва» – яшьләргә аң-белем бирү, мәгариф системасын яңарту, балаларны рус уку йортларында укыту, хатын-кызларга аң-белем һәм тәрбия бирү.

Әмма публицистик код мәгърифәтчелек чикләреннән чыгып, иҗтимагый-сәяси эчтәлек ала. Әсәр үзе милләт язмышын тасвирлауга өстенлек биргән программа характерындагы текстка әверелә.

Татарның инкыйразга баруын укучыга мөмкин кадәр тәэсирлерәк күрсәтү өчен, Исхакый махсус алымнарга мөрәҗәгать итә: чиктән тыш арттыра – «татарның өстенә мең төрле бәлаләрне берьюлы китереп аудара» [2: 127], фантастика ярдәмендә болгар дигән милләтне юкка чыгу чигенә китереп җиткерә. XXII гасырда җир йөзендә нибары ике болгар кешесе: әдип һәм тарихчы Җәгъфәр һәм аның хатыны Сөембикә генә торып калу, үле бала табудан терелә алмаган Сөембикәнең вафатыннан соң изге Болгар җиренә юл тоткан ирнең дә, давыл аударган багана астында калып, һәлак булуы символик мәгънәле. Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә – милләт анасы, халыкның терелачәгенә, нәсел чылбыры дәвам итәчәккә соңгы өмет. Сөембикә үлеме белән бу өмет сүнә: язучы Казандагы Сөембикә манарасының да авуын телгә ала – хәтта хәтер югала. Повестьта шартлы-символик код (гомумәдәби код) беренче урынга чыга. Язучы үз уй-фикерләрен халыкка тизрәк һәм тәэсирлерәк итеп җиткерү өчен, үгет-нәсихәтчелектән китеп, психологик, романтик-сентименталь, экзистенциаль, символик сурәтлелеккә өстенлек бирә.

Мондый үзгәрешләр милли әдәбиятыбызда да идея-эстетик борылыш китереп чыгара. Исхакыйның «Теләнче кыз» (1901–1908) романында психологизм тагын да тирәнәя, язучы татар кызының рухи үсешен, иҗтимагый көрәшкә килү юлын аның уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен өзлексез күзәтеп барып һәм милләт язмышы белән бәйлелектә тасвирлый. Әсәр үзәгенә язучының иҗтимагый-сәяси концепциясе салынса да, романда романтик-символик характерлы гомумәдәби код алга чыга. Язучы татар хатын-кызының тормышын, этапларга бүлеп (авылдагы матур балачак, шәһәрдә теләнче кызга әйләнү, сатлык хатын-кыз, бай хатыны, беренче тапкыр театрга бару һәм башка тормышка омтылыш тою, белем алу, мохтаҗларга ярдәм итүдән тәм табу, халыкка хезмәткә омтылыш уяну), милләт мәнфәгате белән яши башлауга килү тарихына әйләндерә. Исхакый героинясын психологик анализ ярдәмендә – аның уйларын, төшләрен, эчке монологларын, курку һәм саташуларын тергезеп, символлар һәм табигать сурәте мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итеп, рухи хәрәкәттә күрсәтә. Шушы туктаусыз эмоциональ хәрәкәт янәшәсендә табигать белән сөйләшүләр, киная һәм символлаштыру, лирик чигенешләр, кеше халәтенә тәңгәл

күпсанлы детальләр эчтәлекне гаять тирәнәйтә. Болар теләнче кыздан милләт хадимәсенә, милләт анасына кадәр юл үткән Сәгадәт үрнәгендә татар җәмгыятенең, татар милләтенең дә, белем алып һәм камилләшеп, тормыш төбеннән күтәреләчәгенә ышаныч булып яңгырый.

«Теләнче кыз»да үзен эстетик, психологик сурәтләү остасы итеп таныткан Г. Исхакый публицистик характердагы әдәбияттан да баш тартмый. Шуның характерлы мисалы – Чистай төрмәсендә утырганда язылган «Зиндан» повесте (1907). Жанры ягыннан төрмә хроникасы рәвешендәге бу повесть Г. Исхакыйның төрмәдә күргән-кичергәннәренә нигезләнә, тоткын герой автор белән тәңгәлләшә һәм аның шул чордагы иҗтимагый-сәяси карашларын ача, автобиографик әсәрдә публицистик код иҗтимагый-сәяси эчтәлекле.

Г. Исхакыйның көрәш еллары рухы белән сугарылган «Мөгаллим» (1906), «Тартышу» (1908) драмалары, «Алдым-бирдем» (1907), «Кыямәт» (1909–1910) һәм «Җәмгыять» (1909–1910) комедияләрендә татар җәмгыятендә милләт үсешенә каршы торучы көчләрне фаш итү үзәктә тора. Мондый көчләр рәвешендә иске карашлы кешеләр, бигрәк тә дин әһелләре күрсәтелә. Драматург аларның тормышта табигый яңарышка агымына каршы торырга тырышуларының мәгънәсезлеген күрсәтә, бер үк вакытта, кире кагылган иске тормыш моделе белән янәшә, милләтне үсешкә, яктыга алып чыгачак юл да, яңалыкка йөз тоткан иҗтимагый үсеш моделе дә билгеләп куела. Әсәрләрдәге иҗтимагый-сәяси эчтәлекле публицистик код татар укучысын, тамашачысын милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып көрәшкә чакыру, өндәү төсендә кала.

1909 елдан язучының каләме, язу рәвеше кабат үзгәреш кичерә: публицистик код, мәгърифәтчел һәм иҗтимагый-сәяси катламнар текстлар тукымасында тагын да арткарак чигенәләр, романтик характерлы милли-фәлсәфи кодка урын бирәләр. Чөнки ул лозунг-чакырулардан, җәмгыятьтәге күзгә күренеп яткан тискәре якларны тәнкыйтьләүдән баш тартып, милләт тормышындагы бик тирән яшеренгән, тамырлары ерактан килә торган традицияләрне анализларга алына. Истанбулда «Тормышмы бу?» (1909) повесте иҗат ителә. Бер шәкертнең хатирәләре, көндәлекләре рәвешендә хикәяләү шәхеснең үсеш-үзгәрешен аның үз-үзен танып белүе рәвешендә күзәтеп бара. Эчке монолог, аң агышы герой хис-кичерешләрен мөмкин кадәр тулырак яктыртырга мөмкинлек ача. Бер үк вакытта аерым күренешләр татар җәмгыяте, тирәлек кешегә көчләп таккан сыйфатлар кебек тәкъдим ителә.

Геройның татар дөньясы өчен типик булуына, күп татар яшьләренең изге-матур хыяллар белән яши башлавына, әмма ахырдан сынып-сыгылып калуына игътибар юнәлтеп, әсәргә җентекле анализ ясаган рецензиясендә Г. Гобәйдуллин болай ди: «Ләкин безне дә шул ук каһарманны баскан мәдрәсә куркаклыгы кысып, бертөрле генә, бер яктан гына карый торган вөҗданымыз тыйгандыр да кире чигенгәндермез, яисә: “Яхшы түгел!” фикере илә бу эшләрдән суыткандыр. Ләкин заман үтүе, җисмани тормышымызның тәрәккъые – һәммәсе безне бу вөҗданның куәтләрен җиңәргә азаплагандыр. Һәм без дә, каһарман шикелле, “йитәр, әле бик күп форсат югалттым!” дип әйтергә мәҗбүр булганмыздыр... Әүвәлге вөҗданнарымыз ватылгандыр да, каһарман шикелле, Кабан күле бозларыны үтәргә мәҗбүр булганмыздыр...» [5: 71].

Повестьның башыннан ахырына кадәр шәкерт үткән юлны Р.К. Ганиева түбәндәгечә билгели: «1) яшь, матур, китап укырга һәвәс малай; 2) гарәп һәм фарсы телләрен, ислам фәлсәфәсен, аның схоластик логикасын әйбәт үзләштергән мөнәзарачы шәкертнең хәлфә, мулла, пәйгамбәр кебек яхшы кеше булу идеалы; 3) И. Гаспралының «Тәрҗеман» газетасын, «Дар әр-рәхәт мөселманнары» исемле утопиясен, рус әдәбиятын һәм төрекчәгә тәрҗемәдә француз ро-

маннарын укып, ислахчы, мәгърифәтче, җәдитче, ауропалашу тарафдары булып китү, милли тәрәккыять идеаллары белән янып яшәү; 4) мәгърифәтчелек идеалларының татар тормышын үзгәртү, яңартудагы көчсезлеген танып, ярым өметле, ярым өметсез егеткә әверелү; 5) халыкка хезмәт итү идеалларын югалткан, вөҗдан газапларына дучар булган авыл мулласына әйләнү» [3: 16–17].

Ни өчен юлның шулай төгәлләнүен язучы иҗтимагый-сәяси баскычтан торып, милли тирәлек хәле белән бәйләп аңлата: «Буның шулай калуында үзе генә гаепләме? Нигә көлеп торасыз?! Буның шулай, бер элгәрге игътикадыны бозып, яңа игътикадсыз калуында сез дә, аны чолгап алган бөтен татар тормышыңыз да гаепле түгелме?» [7: 89]. Шул рәвешле, язучы шәхес трагедиясен – 1905 ел инкыйлабы үзгәрешләр алып киләчәгенә чын күңелдән ышанган татар яшьләре буыны фаҗигасенә, уянып үз тормышына бәя биргән, ләкин аны үзгәртергә көче җитмәгән милләт трагедиясенә әйләндерә [1: 292–293]. Бер үк вакытта нәкъ менә шушы – ачык фикерле, чиста-матур омтылышлы, милләт-халык хакына гомерен дә корбан итәргә әзер татар яшьләре – тормышны үзгәртерлек көч-куәт дип билгеләнә. Бу фикер нәкъ менә Г. Исхакый иҗатында формалаша, яңгыратыла, киң мәйданга чыгарыла.

Шушы табылган язу рәвеше язучы иҗатында аның иң соңгы әсәрләренә кадәр саклана. Г. Исхакый милләт яшәешендәге тирән яшерен (яки яшерелгән) катламнарга, тарихи-сәяси вакыйгалар яки милли гадәт-традицияләр тәэсирендә барлыкка килгән ситуацияләргә үтеп керә, бер үк вакытта ул милләтне үзгәртү юлын белем үзләштерүдә, башка халыклардан үрнәк алуда түгел, бәлки үз эчке көчендә, тарихи үзенчәлекләрендә, фикри һәм менталь потенциалында таба.

1910 елның язында Г. Исхакый Петербургтан яшерен рәвештә Финляндиягә чыга һәм анда җәй аен уздыра. Кыска гына вакыт эчендә «Мулла бабай» романы, «Фамилия сәгадәте» исемле хикәяләр циклы языла. Г. Исхакыйның иң күләмле әсәрләреннән булган «Мулла бабай»да авыл малаеның, мәдрәсә баскычын үтеп, туган авылында мулла булу тарихы күрсәтелә. Әсәрнең үзәк герое Хәлим, күбрәк белем алу ниятендә, шәһәр мәдрәсәсенә китә, анда ачлы-туклы ун ел укып пишкадәм була, аннары үз авылларында зур кыенлыклар белән мулла итеп сайлана. Герой шәһәрдә алган белемнәре белән туган авылы кешеләренә хезмәт итү турында уйлый һәм әсәр ахырында шушы теләген тормышка ашыра. Роман төгәлләнмәгән булса да, текст ахырына Хәлим ислам дине белгече, халык әхлагын саклаучы абруйлы мулла булып җитешә. Шушы герой, аның максаты-омтылышы – татар дөньясын үзгәртер көч, тарих тәгәрмәчен әйләндерер куласа, ди автор.

Романда революциягә кадәрге авылның патриархаль яшәеше һәм мәдрәсәләр тормышы киң колачлап һәм төгәл күренешләрдә чагылдырыла. Мисал өчен, авылда мулла сайлау, килен ярәшү, туй үткәрү, мәдрәсәдә укыту тәртипләре, шәкертләрнең ял кичәләре, табигатькә чыгу, җыр-биюләр, шамакайлану һәм театр күрсәтүләр һ.б. бөртекләп күз алдына бастырыла. Татар әдәбиятында XX йөз башы татар руханилары тормышын халык яшәеше белән бербөтен итеп һәм яратып, җентекле-матур күрсәткән башка әсәр табуы кыен.

1910 елның көзендә Истанбулга килгән Г. Исхакый «Сөннәтче бабай», «Кияү», «Шәкерт абый» хикәяләрен яза. Аларда татар тормышының гаять матур йола-гадәтләре этнографик төгәллек белән сурәтләнә, саф татар типлары тудырыла, шуның белән янәшә, кешеләр фаҗигасе хакында сызлану урын ала. Әйтик, «Кияү» (1914) хикәясе, бер яктан, татар гаиләләрендәге кунакчыллык, өйләнү-кыз бирү традицияләре хакында матурлык эстетикасы теле белән сөйли. Шул ук вакытта дан-шөһрәткә омтылышның, кеше җилкәсендә яшәүнең тискәре, чиктән тыш арттырылган мисалын тасвирлый.

«Сөннәтче бабай» (1911) да татар тормышының традицион билгеләре – чисталык-пөхтәлек, сабырлык, кунакчыллык, үз һөнәреңне яратып башкару, тәртип ярату Корбангали карт һәм Гөлйөзем карчык образларына салынган. Г. Исхакый бу геройларын, аларга хас сыйфатларны милләтне яшәтүче, үстерүче, үзгәртүче билгеләр буларак тәкъдим итә. Охшаш яңгырашлы «Остазбикә» дә (1910) укымышлы, дөньяга җитди карашлы кызның – милләт анасы Сәгыйдәгә әйләнү тарихын сөйли, аны идеаллаштырып, татар хатын-кызларының милләтне, нәселне яшәтүен, саклау һәм үзгәртү көчен ассызыклый.

Г. Исхакыйның Истанбулда иҗат ителгән «Зөләйха» трагедиясе татар тарихындагы иң аяныч вакыйгаларга – чукындыруга мөрәҗәгать итә. Татар анасы Зөләйха бу очракта киң идея-фәлсәфи мәгънә йөкләнгән символга әйләнә, аны чукындыру бөтен милләтне диненнән ваз кичтерергә тырышу мәгънәсен ала. Язучы дини-мифологик образларга, ислам тарихына һәм фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә, психологизм алымнарыннан, саташу, төш күрү, Аллага сыгыну мотивлары ярдәмендә эчтәлекне катлауландыра. Әсәрдә ислам диненең татарлар өчен милли рух һәм әхлакны, иманны саклаучы булуы хакындагы фикер үткәрелә. Шартлы-символик код беренче урынга чыга.

Язучының «Ул икеләнә иде» (1914) һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) повестьлары шушы сөйләшүне XX гасыр башына күчерә. Алар руслашуны – катнаш гаиләләр проблемасы аша ача: әсәрләрдә чит милли мохиткa эләгүнең татар кешесен үзеннән-үзе милли җирлектән һәм яшәү рәвешеннән аеруы һәм аның нәсел тамырлары корытуга китерәчәге күрсәтелә. Әдип бу хәлнең, ахыр чиктә, милләт язмышына кире тәэсир итәчәгенә ишарә ясый. Сызлану милли-фәлсәфи кодның эчтәлеген билгели башлый.

Г. Исхакый язмышында Октябрь инкыйлабы кискен борылыш тудыра: илдә урнаштырыла башлаган яңа тәртипләр, бигрәк тә большевикларның милли сәясәте белән килешә алмыйча, ул туган илен ташлап китәргә мәҗбүр була. Мөһаҗирлектәге тормышы сәясәтче буларак милләт яшәеше һәм язмышы турында кайгыртуга буйсындырыла. Әмма ул әдәби иҗатны да ташламый.

Иң көчле әсәрләреннән булган, сызлану фәлсәфәсе белән сугарылган «Көз» (1923) повестенда әдип руслашу күренешенең сәбәпләрен барлый, аны мохит белән бәйләп куя. Мирза кызы Гөлсем үзенең тормышы турында болай ди: «Бик тиз мине укыта башладылар, ләкин урысча укыта башладылар. Минем беренче танылган китабым урыс китабы булды. Беренче укыганым урыс тормышы булды. Шуннан мәктәпкә кердем. Тирә-юнемдә һәммәсе урыс иде, өйдә дә урысча сөйлиләр иде. Килгәннәр урыс була, барганнарымыз урыс була иде, бәйрәмнәр булганда гына мин үземнең әллә нинди икенче төрле урыс икәнемезне, рождество ясамаенча, корбан бәйрәмен гает ясый торган урыс икәнемезне хис итә идем. Иптәшләрем арасында шул чынлап урыс булмавымыздан хурлана да идем» [9: 115]. Сәүдәгәр гаиләсендә туып, мөселманча аң-белем һәм тәрбия алган Нәфисә мисалында әдип, балаларны милли рухлы итеп үстерү өчен, аларны милли мохитта яшәтергә кирәк, дигән фикер уздыра.

Примечательно, что в последнем номере этого издания предлагается вниманию читателя статья-рецензия Г. Исхаки на книгу, напечатанную издательством «Сабах» в 1907 г., неизвестного автора (некто «А» эфенди) «Русия тарихы» («История России»). Здесь перед нами открываются новые грани творчества Г. Исхаки. Как можно заключить, основным мотивом, побудившим автора написать эту статью, послужило понимание чрезвычайной важности исторической науки в целом и необходимости пропаганды среди татар знания истории России в частности. По мнению исследователя Ф.Н. Шакурова, автор книги «Русия тарихы» принадлежал к левому лагерю, «возможно, среде татарских эсеров» [23: 84]. Рецензент Г. Исхаки, отмечая достоинства и недостатки (җитешкән вә җитешмәгән яклары) и признавая значимость нового труда, в заключение подчеркивает, что это «книга, которую должен прочитать, знать каждый» [21].

Таким образом, в период становления национальной прессы начала XX столетия Г. Исхаки проявил себя как талантливый организатор печатного органа татарских социалистов-революционеров (таңчылар), пламенный публицист, исследователь. Исхаки обыскивали, арестовывали, привлекали «к переписке», но он оставался верным своим идеалам. В одном из номеров газеты «Таң йолдызы» он написал: «Уважаемые читатели! Я снова вышел на белый свет, я снова, вдыхая свежий воздух, вернулся в мир своих товарищей, друзей, близких, знакомых. Я снова, сломав поставленное на мне клеймо (печать), начинаю речь <…> Хоть я вынужден пока оставить Казань и своих любимых читателей, обещаю не покидать страницы “Таң <…>”» [20].

24 октября 1907 г. Гаяз Исхаки был выслан из Казани этапным порядком в Архангельскую губернию под гласный надзор полиции на три года «за принадлежность к партии социал[истов]-революционеров и преступную агитацию среди крестьян» [11: 108]. Его Путь продолжался.

## ЛИТЕРАТУРА


1. Амирханов Р.У. Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). М.: Наука, 1988. 188 с.

2. Амирханов Р.У. Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток-Запад» (на примере развития русской культуры). Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 239 с.

3. Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 152 с.

4. Загидуллин И.К., Хамитбаева Н.С. «Татарские социалисты» в петиционной кампании мусульман России 1905 года // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2015. № 5. С. 72–95.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Т. 7: Тарихи хезмәтләр (1911–1927). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 539 б.

6. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 6: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 446, [1] б.

7. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 1. Оп. 4. Д. 1694.

8. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 1. Оп. 4. Д. 1698.

9. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 1. Оп. 4. Д. 1984.

10. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 199. Оп. 1. Д. 234.

11. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 199. Оп. 1. Д. 538.

12. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 199. Оп. 1. Д. 543.

13. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 420. Оп. 1. Д. 57.
14. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 420. Оп. 1. Д. 87.
15. Таң йолдызы. 1906. 22 май.
16. Таң йолдызы. 1906. 29 май.
17. Таң йолдызы. 1906. 5 август.
18. Таң йолдызы. 1906. 15 август.
19. Таң йолдызы. 1906. 9 сентябрь.
20. Таң йолдызы. 1906. 5 ноябрь.
21. Таң мәҗмугасы. 1907. 1 июнь.
22. Тукай Г. Избранное: Стихотворения; Поэмы; Сказки; Стихотворения для детей: пер. с тат. / сост. Р. Бухараев; вступ. статья С. Хакима. М.: Худож. лит., 1986. 239 с.
23. Шакуров Ф.Н. Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 127 с.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «ОСТАЗБИКӘ» ПОВЕСТЕНЫҢ ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***К.Г. Бадиков*** *(Казан)*

Классик татарской литературы, пламенный публицист, видный общественный деятель Гаяз Исхаки воплотив в себе лучшие, передовые традиции татарской, русской и Европейской литературы создал замечательные произведения прозы, драматургии, публицистики. Особое место в его творчестве занимает повесть «Остазбикә» («Наставница»), где автор по-новому раскрывает глубокие душевные переживания главных героев Сагиды и Вахида. Повесть «Остазбикә» является не только ярким примером, образцом татарской национальной литературы, отражающая лучшие черты религиозных деятелей того времени в разрешении острых семейных конфликтных ситуаций, но и умелого использования неисчерпаемых возможностей лексических, изобразительно-выразительных средств национального языка. Наиболее ярко проявляются эти богатства в использовании общеупотребительных слов, религиозно-культовой терминологии, фразеологии, эпитетов, сравнений и т.д. В данной работе автор, не претендуя на полноту их интерпретаций, приводит лишь отдельные, наиболее яркие примеры их использования.
**Ключевые слова:** Исхаки, писатель, повесть, «Остазбикә», язык, стиль, лексика, тропы.

A classic of Tatar literature, a fiery publicist, prominent public figure Gayaz Iskhaki, embodying the best, advanced traditions of Tatar, Russian and European literature, he created remarkable works of prose, drama, and journalism. A special place in his work is the story «Ostazbike» («Mentor»), where the author in a new way reveals the deep emotional experiences of the main characters of Sagida and Vahid. The story «Ostazbike» is not only a vivid example, a model of Tatar national literature, reflecting the best features of religious figures of that time in resolving family conflict situations, but also skilfully using the inexhaustible capabilities of the lexical, expressive means of the national language. The most vividly manifested these riches in the use of common words, religious and cult terminology, phraseology, epithets, comparisons, etc. In this paper, the author does not pretend to the fullness of their interpretations, the results are only individual, the most vivid examples of their use.
**Key words:** Ishaki, writer, story, «Ostazbiks», language, Steele b, vocabulary, trails.

Гаяз Исхакый XX гасыр башында милли әдәбият, әдәби тел, матбугат, иҗтимагый фикер-аң үсешенә гаять зур йогынты ясаган мәшһүр әдипләребезнең берсе, аның игелекле тәэсире әле бүген дә дәвам итә. Талантлы каләм иясе, ялкынлы милләтпәрвәрнең халкыбызны олылап, аның киләчәген кайгыртып язган алты йөзгә якын әдәби, публицистик, фәнни хезмәте, әдипнең шул киң колачлы иҗаты турында язылган ике меңнән артык төрле күләм-жанрдагы мәкалә, язмалар һәм әле соңгы вакытта гына «Шәхесләребез» сериясенең Гаяз Исхакыйга багышланган китабы – шуның ачык мисалы.Әлеге хезмәттән

күренгәнчә, күп булмаса да, язучы иҗатының тел-стиль үзенчәлеген өйрәнүгә багышланаган хезмәтләр һәм мәкаләләр дә байтак. Г. Исхакыйның тел-стиль үзенчәлеген әйрәнүгә Г. Сәгъди, И. Бәширова, Г. Зиннәтуллина (Гобәйдуллина), Ф. Сафиуллина үзләреннән шактый зур өлеш керткәннәр. Гомумән алганда, бу бик аз, әлбәттә. Әдәби әсәрнең беренчел һәм төп элементы сүз булуын кабат искә төшерсәк, уйланырга урын бар монда. Бу – бер яктан аңлашыла да: әдәби әсәргә төрле яклап бәя биргәндә, башлыча тарих, фәлсәфә, әдәбият белеменә нигезләнеп, шактый ирекле, мөстәкыйль фикерләр әйтеп булса, ә менә әдәби әсәр теленә анализ ясау фәннилекне, төгәллекне, конкретлыкны, мисаллар китереп, дәлилләп бирүне таләп итә. Моңа, беренчедән, күп вакыт сарыф ителә, икенчедән, әдәбият белеме дә, тел белеме дә кирәк була. Шуңа күрә әдәби әсәргә тел-стиль анализы ясау – аеруча катлаулы күренеш һәм аның шулай икәнлеге күп кенә галимнәр тарафыннан да раслана.

Г. Исхакыйның күренекле язучы, мөхәррир, җәмәгать эшлеклесе булып формалашуына шул чор, тормыш, әйләнә-тирә мохитнең йогынтысы шактый көчле була. Гыйләҗетдин хәзрәт белән Камәрия абыстай гаиләсендә дөньяга килгән Мөхәммәтгаяз исемле зиһенле бала биш яшеннән укырга өйрәнә, тиз арада башлангыч мәктәп программасын үзләштергәннән соң, башта Чистай, аннан соң Казанның «Күл буе» һәм Әмирхановлар мәдрәсәсендә, ата-анасы мулла булырга тиешле баласының руслар белән аралашуына бик нык каршы килсә дә, Х. Ямашев, Г. Коләхмәтовлар белән бергә Татар укытучылар мәктәбендә (Татарская учительская школа), белем һәм тәрбия алып, җор телгә, сүзгә-бәхәскә осталыгы белән башкалардан шактый аерылып торган Гаяз шәкерт «Күл буе» мәдрәсәсендә үзе дә хәлфә буларак җәдитчә, ягъни яңача – аваз методы белән укытуны гамәлгә кертә, төрек, рус, Көнбатыш Европа язучыларының әсәрләрен, төрки телдә чыккан бердәнбер «Тәрҗеман» газетасын даими укып бара. Шулар йогынтысында 17 яшьлек егетнең үзендә дә иҗат дәрте кузгала һәм ул бер-бер артлы «Тәгаллемдә сәгадәт яки Гыйлем өйрәнүдә рәхәт гомер» (1899 елда басылып чыга), «Кәләпүшче кыз» (1900) хикәяләр һәм «Өч хатын белән тормыш» (1900) исемле драма язып бастыра һәм тиз арада талантлы, оста язучы буларак танылa. Шушы беренче әсәрләрендә үк ул уку, белем алуга омтылу туры юлга, бәхет-шатлыкка илтә, наданлык, бозыклык, әхлаксызлык юлдан язуга, бәхетсезлеккә китерә дигән мәгърифәтчелек реализмы белән сугарылган алдынгы фикерне алга сөрә. Ул дөнья әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен уку белән бергә, күңеленә хуш килгән А. Пушкинның «Капитан кызы» повестен һәм Н. Гогольнең «Борынгы алпавытлар» әсәрен татар теленә тәрҗемә итә. Аның турында матбугатта беренче сүз дә шул уңайдан әйтелә һәм ул уңай бәяләнә. 1902 елда Г. Исхакый Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә мөгаллим итеп чакырыла, табигать фәннәре һәм рус теле укытучысы буларак, анда да яңача укытуны тормышка ашырырга тели, әмма аның бу омтылышлары мәдрәсә тотучы миллионер Хөсәеновларга ошамый һәм ул бер елдан соң аннан китәргә мәҗбүр була.

Г. Исхакый 1905 елгы беренче рус революциясен шатланып каршылый, язучылык һәм журналистик эшчәнлеге белән бергә, эсерлар фиркасендә катнашып, революцион көрәш юлына кереп китә. Шул уңайдан кулга алынып, ике ай Чистай төрмәсендә утырып чыга, 1907 елда «социалист-революционерлар партиясендә торуда һәм крестьяннар арасында җинаятьчел агитация ясауда» гаепләнеп, Архангель губернасына өч елга сөргенгә сөрелә. Шул авыр шартларда да ул «Зиндан» (Чистай төрмәсендә), «Солдат» повестьларын, «Теләнче кызы» романының ике кисәген, «Алдым-бирдем» (Казан төрмәсендә), «Тартышу», «Мөгаллим» пьесаларын яза, шулар аша, Г. Ибраһимов язганча, татар әдәбиятына реализмны алып керә.

Сөргеннән качып, 1908–1911 елларда Төркиядә яши, шул чорда «Мулла бабай, «Томышмы бу» романнарын, «Сөннәтче бабай», «Кияү» повестьларын, «Фамилия сәгадәте» исеме белән чыккан «Татар гакылы», «Мәдрәсә җимеше», «Башкорт бәхете», «Көтелгән бикәч» дигән һәркайсы үрнәк булырлык дүрт хикәя иҗат итә. 1911 елда Петербургка кайтып, бүтән кеше паспорты белән качып яшәгәндә кулга алына һәм кабат шунда сөргенгә озатыла. 1913 елда сөргеннән азат ителеп, бераз вакыт Казанда яшәгәч, Петербургка китә һәм анда «Ил» исемле газета чыгара башлый. Күп вакытын, көчен матбугат һәм публицистикага багышласа да, ул әдәби иҗатын да дәвам итә. Әлеге кыскача күзәтүләр аның «Остазбикә» повестен нинди катлаулы, зур тормыш һәм иҗат мәктәбе аша узып, нинди хәзерлек белән язарга алынуын барларга мөмкинлек бирә.

Г. Исхакый татар тормышын төрле яклап, тирәнтен белеп, зур осталык белән тасвирлап-сурәтләп яза. Бу җәһәттән караганда аның 1914–1915 елларда язылган «Остазбикә» повесте гадәти булмаган, яңача сюжеты, төп геройлары – остазбикә Сәгыйдә белән указлы яшь мулла Вахидның гаилә корып, унике ел дәвамында бәхет эчендә рәхәт, тыныч яшәүләреннән соң, балалары булмау сәбәпле, гаять киеренке, тирән эчке кичерешләре, тел-стиленең камиллеге, сурәтләү-тасвирлау чараларының байлыгы белән татар әдәбиятының казанышын гәүдәләндергән әсәр буларак аеруча югары бәяләнә. Гәрчә ул хакта сүз булмаса да, әсәрнең тел-стиль ягыннан камиллеге, сынландыру-җанландыру чараларының байлыгы белән дә игътибарны җәлеп итүенә аерым тукталырга кирәк.

Төрек журналында нәшер итү өчен дип фараз ителгән, ярым төрекчә, ярым татар телендә язылган «Тәрҗемәи хәлем» һәм иске китап, гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләрнең күплеге, аңлап укырга кыенлыгы белән аерылып торган «Тәгаллемдә сәгадәт яки Гыйлем өйрәнүдә рәхәт гомер», «Кәләпүшче кыз» хикәяләреннән үзгә буларак, «Остазбикә» әсәре хәзерге әдәби телгә якын, аңлаешлы телдә язылган. Дөрес, әсәрдә шул чорга хас булган һәм тулысынча мулла-абыстайлар томышын тасвирлауга багышланганга: *игътикад итү* (ышану), *мәсъүлиятле* (җаваплы), *фидия* (сәдака, мал), *мөяссәр* (җайлы), *лива* (байрак), *кыйраәт* (уку, Коръәнне яттан кычкырып уку), *фи сабил* (юлда, олы юлда), *кабзыятьләнү* (каушау), *истикамәт* (тугрылык, намуслылык), *мәкруһ* (начар), *мөрәккәб* (барлыкка килгән,кушылган), *мәд* (аваз), *мәдәд* (ярдәм), *ингыйкас* (чагылу), *татбикат* (яраштыру, килештерү), *сахиб* (хуҗа, ия), *гыйддәт* (ирсез калган хатынның икенче иргә бармый торырга тиешле вакыты), *тәхәллел* (аерылышу), *ләфзаи морад* (тел генә әйткән теләк), *хотбә* (нотык, вәгазь), *нәшьәле* (дәртләндерерлек, күңелгә ятышлы), *хисса* (өлеш), *гасабәләр* (ата ягыннан булган туганнар), *мөддәт* (вакыт, ара), *хашия* (китап бите читтендәге язма-искәрмәләр), *фәукыйльгадә* (гадәттән тыш), *дәргяһ* (мәрхәмәт), *газамәт* (олылык), *динадар бүрек* (цилиндр формасындагы каракүл бүрек), *ягъмур* (яңгыр), *зобани* (җәһәннәмдә гөнаһлыларны җәзалаучы), *грифтар* (дучар, тоткын) кебек алынма, иске, дини сүзләр еш очрый. Шулай да бу повестьта алда әйтелгән ике хикәядәге: *әлвидаг* (аерылышу, саубуллашу), *ашык* (күз сөяге), *тәхсил* (гыйлем алу), *изаг* (рөхсәт бирү, кул кую), *рәһим* (закладка салу), *бәни* (мине), *тиреслек* (кирелек), *җәпы* (исеме), *тәшәккер* (яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү), *сара* (аваз, тавыш), *гариб* (фәкыйрь), *бәдәл* (бәя, хак), *дәкыйк* (төгәл), *сәнәви* (еллык), *вәсилә* (сәбәп), *заигъ* (әрәм, файдасыз), *айлау* (кызгану), *зира* (чөнки), *нан* (ипи), *фасикъ* (бозык), *сәрмия* (кыйммәт), *мөбтәл* (дучар булу), *зикер* (искә алу) кебек сирәк кулланыштагы сүзләр яңа мәгънәләр белән алыштырылган яки алар сирәк очрый.

Шуның белән бергә, Г. Исхакыйның рус телен яхшы белүе нәтиҗәсе булса кирәк, әсәргә шул тел сүзләре дә килеп кергән: *повозка, повозкалы* атлар (йөк

арбасы, арба), *мужик* (күп тапкырлар кабатлана: ир, ир кеше, авыл кешесе, абзый, агай), *собрание* (җыелыш), *приказчик* (кибет хуҗасына ялланып, төрле әйберләр сатучы хезмәткәр), *дублы мужик туны* (иләнгән тиредән тегелгән, тышсыз, кайры тун), *программа* (киләчәк эшләрнең планы), *доктор* (табиб), *простой* (гади, җиңел, ансат), *приговор* (карар, фикер, хөкем) һ.б.

Муллалар тормышын тасвирлаганга, билгеле, повестьта дини-терминологик сүзләр шактый урын алып тора. Аларны урынлы куллануы язучының шул тормышны тирәнтен, тәфсилләп белүе турында сөйли. Шул сүзләр аша гына да әсәрдә сүзнең кем, нәрсә турында баруын шактый төгәл чамаларга мөмкин: *хәзрәт, мулла, абыстай, тәкъдир, шәкерт, мөәззин, мәхәллә, лявазим, гарәфә, фидия, дога, муафикъ, вәгазь-нәсихәт, мөяссәр, ястү, дамелла, мәрхүм, «Дөррәтелнасыйххин», «Мөхәммәдия», зикер, мәчет, намаз, мәхдүм, хәлифә, әстәгъфирулла, тәһарәт, бисмилла, гөнаһ, әфәлем, раббем, ходаем, хәзрәти, әлхәмделиллаһ, михраб, грифтар, гошер, ясин, «Әлхәмде» сүрәсе, мәдрәсә, Коръән, әссәламе галәйкем, вагаләйкем әссаләм, сабак, фәрештә, мөнҗия, сәдака, рәҗәб, шәгъбан, руза, ырым, татбикат, иттифак, хаҗи, мөдәррис, сахиб, вәгазъ, кадер киче, «Бисмиллаһи әлләзи», талак, никях, суфи, тәхәллел, мәчет манарасы, мәдәд, нәфел, рәкәгать, колһуалла, бәхил, разилуллаһе ганһе, лива, ләфзаи морад, тәхият, әл-мәсҗед, хотбә, фарыз, фатиха сүрәсе, гасәбә, бәгни-л-гыйлләтләр, бәни-л-әгъяннар, зәвие әл-Хамнар, мөддәт, биниһайә, догачы, пәйгамбәр, яучы, вәсвәсә, фәүкыльгадә, зәмһәрир, бәхетсәгадәт, метрика дәфтәре, жария, кәнизәк.*

Әлбәттә, әсәрнең чын йөзен төрле лексик катлам сүзләреннән бигрәк, гомумхалык сүзләренең һәм сурәтләү-тасвирлау чараларының кулланылышы билгели. Бу яктан алганда Г. Исхакыйның әдәби телне дә, халыкның җанлы сөйләм телен дә яхшы белүе, сәнгатьле сурәтләү чараларын да мулдан һәм урынлы куллануы игътибарны җәлеп итә.

Вакыйга, күренеш, һәм кешеләрне тасвирлаганда, Г. Исхакый сыйфатлау – эпитетларны аеруча киң куллана. Аларның барысына да махсус тукталып, шактый зур күләмле аерым бер хезмәт язарга булыр иде. Бу очракта шуларның кайберләренә генә игътибар итү дә, язучының сүзгә осталыгын күзалларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, мәчетне, мөәзиннең намаз укуын ул болай тасвирлый: «Иртә белән Шакир мөәззин иртә намазга керде. *Кечкен әгенә* тәрәзәле, *караңгы гына* мәчет үзенең *сәләмә* намазлыклары белән *фәкыйрь төсле* күренсә дә, яшь мулланың сузып кына, яхшы гына кыйраәт белән имам булуы шактый күңелгә тулды». *Кечкенә генә, караңгы гына, сәләмә, фәкыйрь төсле* эпитетлары аша мәчетнең нинди булуын шактый ачык итеп күз алдына китереп була.

Сәгыйдәнең булачак каенанасын беренче мәртәбә күрүе сискәнгеч тә, көлкеле дә итеп, эпитетлар, чагыштырулар аша, буяуларны мулдан, ачык, җете итеп кулланып тасвирлана. Монда авторның гаять дәрәҗәдә күзәтүчәнлеге дә, юморга осталыгы да, тормыш-көнкүрешне бик нечкәләп белүе дә, хатын-кызның бизәнүгә чама хисен югалтып бирелүе дә калку итеп гәүдәләнә. «Түрдә *киң генә битле, урта яшьләрдәге* бер хатын утырган. Чынаякны алганда аның алдына таба *зур, озын яка чылбырлары* берсенә берсе бәреләбәреләә *алга таба бөгеләләр*. Күкрәгенә кушып кигән, *ике кул иңле ука тезелгән хәситәдә төрле зурлыктагы тәңкәләре шылтырашып акаеп торалар.* Колакларындагы *хәзерге заманның чулпысы кебек колак алкалары болай да зур колакларын* басып, сәлендереп торалар. Ул бер-бер әйбер алу өчен селкендеме, аның артындагы *озын чәч такмасы*, аларга тагылган *зур чулпылар*, *кыңгыраулы тайлар җыелган кебек*, шылдырау тавышлары чыгаралар. *Кулларының саргайган тиреләре* өстендә *берсеннән-берсе киң, әллә ничәшәр беләзекләр* аның

кулларын *сынганнан калайланган чәйнек борыны кебек* иттереп күрсәтәләр. *Юан-юан бармакларда зур ахаклар, фирәзәләр, простой кызыл ташлардан ясалган кашлы, төрле төстәге, алды-артлы киелгән өчәр-дүртәр йөзекләр* аның бармакларына кырык тартмачыдагы сатар өчен *төрле төстәге, төрле буяудагы* йөзекләр утырткан агач төсен бирәләр. Шул бизәнү генә аз кебек күренгән булырга кирәк, кодагый *ап-ак иттереп* акшар белән битенә кершән яккан. Инлек белән бит урталарын кызартып, аны *буяган чиләк төбенә охшаткан. Тешләренең аклыгы шул матур йөзгә*, шул кием-салымга килешеп бетмәс дип уйлаган булырга кирәк, ул *атныкы кебек тешләрен* карага буяган! Тутасының ясаган чәен авызына алмыйча, ул һаман шуңарга карады. Хикәяләрдә сөйләнә торган *убыр карчыгына охшаган* куркыныч каенананың ничек сөйләшүен ишетер өчен, торып китмәде, китә алмады. Шуны ишетәсе килүе, шуны беләсе килүе аның бөтен йөрәгендә кайный торган күз яшен буып тотты. Менә ул авызын ачты, аның кара тешләре ыржайды, аның өстләренә элгән төрле тәңкәләре, челтәрләре, төймәләре хәрәкәткә килеп, *йәшел-йәшел тавышлар* чыгарды; Сәгыйдә үзенең колагы белән каенанасының тавышын ишетте. Ул тавышны ни дип әйтергә?.. Ул аны аңлатырга әле дә сүз таба алмый. Ул, Сәгыйдәнең моңынча күргән һичбер кешенең тавышына охшамаган кебек, Сәгыйдәнең һичбер төрле кош-корттан да ишеткән тавышына да туры килми. Ул карт урысның *йомшак иттереп, матур татар хатыны булып* сөйләргә теләгән кыланышына гына аз гына охшый». Әлеге өзектә язучының сыйфатлауларга һәм чагыштыруларга аеруча зур осталыгы күренә. Укучыга яхшы таныш булган әйбер, күренеш, хәрәкәт, тавыш, төсләрне янәшә куеп тасвирлау-чагыштыру аша ул персонажларның килеш-килбәтләрен генә түгел, рухи дөньяларын, холык-фигыльләрен, кичерешләрен дә төгәл итеп гәүдәләндерә.Әлеге әсәрдә язучы телнең фразеологик байлыгын да киң кулана. Мәсәлән: *үз сүзендә торды* (сүздә тору), *чит күрделәр* (чит күрү), *күздән үткәрде* (күздән үткәрү), *башлары күккә тиеп чыктылар* (баш күккә тию), *катып калды, хәйран калды, ачуы килде, рәхмәт укыды* (рәхмәт уку) һ.б. сөйләмне халыкчан итеп, җанландырып җибәрә.

Г. Исхакый әсәрләренә хас булганча, Сәгыйдә яучылап, димләп, көчләп, күзе белән күрмәгән-белмәгән, теләмәгән ниндидер муллага киягә чыгуга бөтен тырышлыгы белән каршы торып карый. «Сәгыйдәнең күзенә яшь килергә өлгермәде, *зур абыстай* килеп: “Әйдә, тәһарәтең бармы? Каенанаңа күрендерергә”, – дип, *җилтерәтеп алып китте.* Сәгыйдә тын алырга, хәл җыярга өлгермәде, бисмилла дип бер ягыннан олугъ тутасы, бер ягыннан карт җиңгәсе тотып, аны кодагыйларның чәй мәҗлесенә китереп бастырдылар вә бисмиллалар, салаватлар белән: “Кодагый абыстай, килеңеңез!” – диделәр. Ул элгәре тавышсыз еласа да, ахырга таба теле ачылып: “Ни генә гөнаһым булды икән лә, раббым! Нигә генә бу бәлагә грифтар булдым икән лә!” – дип көйләргә тотынды. Бераздан соң: “Нигә соң ул кадәр миңа дошман булдыңыз, әй әтием, әй әнием, нигә соң мине урамга гына чыгарып ыргытмадыңыз, нигә генә соң мине үстердеңез?” – дип ыңранырга, сыкранырга кереште. “Сабыр ит, Сәгыйдә, алла теләсә, бөтенләй уйламаганча чыгар”, – дип димли-димли башын әйләндергәч кенә Сәгыйдә, күңеленнән ышанмаса да: “Беткән баш беткән!” дип, туйны туктатмасыннар дидертте».

Әлеге уңайдан шунысын да әйтергә кирәк: өзектә кулланылган *булдыңыз, ыргытмадыңыз, үстердеңез* кебек сүзләрдәге *-ыңыз, -еңез* һәм әсәрдәге *-ымыз, -емез, -мыз, -мез, -ңыз, -ңез* грамматик формалары сөйләү теле нормасы булмаган, госманлы төрекләре теленә хас китап телендәге борынгы формалар ул вакытларда мулла гаиләләре сөйләмендә киң кулланылган һәм алар язучы ижа-

тында да файдаланылган. Язучы кулланган *дидертте, иттерде* кебек грамматик формалар да хәзерге телдә үзгәргән яки пассивлашкан.

Билгеле, ихтыярына каршы килеп, димләп кияүгә бирү күренеше Сәгыйдә тормышындагы каршылыкның башы гына. Ахырдан ул моның белән бик рәхәтләнеп килешә, хәтта Вахид муллага чынлап торып гашыйк та була һәм алар бик бәхетле, рәхәт яшиләр. Әмма балалары, варис булмау аларның икесен дә зур сынауларга, каршылыкларга дучар итә. Тик Сәгыйдә шул сынауларны сынатмыйча, киеренке эчке каршылыкларны сабырлык, акыл белән җиңеп чыга һәм чишелеше мөмкин булмаган кебек күренгән шул хәлнең чишелешен таба: Вахидне үзе яучылап, үзе укыткан Хәйрулла хәзрәт белән Зөлфия абыстай кызы Галимәгә өйләндерә. Йорт-җирләре бала белән тула. Автор бу хакта әсәрне болай дип язып тәмамлый: «Бала тәрбиясе, бала мәшәкате хәзрәтнең дә, Сәгыйдәнең дә бөтен тормышын тутырды. Алланың биргән бер елында Галимә абыстай йә бер кыз, йә бер угыл багышлап торса да, хәзрәт үз кулы белән метрикә дәфтәренә исемен "атасы Вахид, анасы Галимә" дип язып торса да, ул үзен-үзе һаман да бер хатынлы иттереп хис итте; бер хатынлы дип уйлады; бер хатынлы иттереп торды. Галимә һәрвакыт бергә булса да, Галимә хәзрәткә дә, Сәгыйдәгә дә матур балалар багышласа да, әллә ничек, ул хәзрәткә хатын булып, бала анасы булып күренмәде. Ул шунда жарияме, кәнизәкме?.. Әллә... әллә нәрсә генәме булды да калды».

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Исхакыйның «Остазбикә» әсәре эчтәлеге белән генә түгел, халыкчан, бай әдәби телнең мөмкинллекләрен тулы көчкә файдаланып иҗат ителгәнгә күрә, укучы аны үз заманында да, хәзер дә зур кызыксыну белән укый. Язылуына бер гасырдан артык вакыт узып китсә дә, ул бүген дә осталык үрнәге булып саналырга лаеклы әсәр.

## ЯЗЫКОВЫЕ ОСОБЕННОСТИ ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ ГАЯЗА ИСХАКИ

***Ф.С. Баязитова*** *(Казань)*

Языковые особенности художественных произведений Г. Исхаки вызывают большой интерес у исследователей. В своем творчестве он активно использовал живой народно-разговорный язык своего родного края. Своеобразие и неповторимость речи родного края проявляются в разнообразных фонетических, грамматических и лексических формах, «малая родина» включает в себя еще уклад и традиции, живущих в ней.
**Ключевые слова:** литературный язык, фонетические диалектизмы, речь персонажей, лексика народных традиций.

The language features of G. Iskhaki's works of literature evoke great interest among researchers. In his literary works he has actively referred tothe vivid popular language of his people. The originality and uniqueness of the speech of the native land are manifested in various phonetic, grammatical and lexical forms; the "small homeland" reflects the way of life and traditions of its inhabitants.
**Key words:** literary language, phonetic dialectisms, speech of characters, vocabulary of folk traditions.

Понятия «литературный язык» и «язык художественного произведения» не тождественны, хотя в то же время не могут быть резко противопоставлены друг другу. Язык художественного произведения по своим рамкам значительно шире литературного языка: в нем, кроме слов, ставших литературной нормой, употребляются просторечные, диалектные и другие слова.

Диалектизмы, как известно, вводятся в язык художественных произведений с различными целями: с целью обогащения литературного языка недостающими в нем для выражения того или иного понятия словами; иногда диалектное слово может быть более выразительным, более точно передавать мысль автора, быть экспрессивно окрашенным и т.д.; диалектные слова могут употребляться для придания местного колорита, часто служат для локализации изображаемых событий, используются для речевой характеристики персонажей и т.д. [9: 27].

Под термином «диалектизм» здесь следует понимать слово или словосочетание, попавшее из того или иного диалекта в литературную речь или в текст художественного произведения.

Очень важную роль в понимании смысла диалектизма играет контекст, т.е. словесная обстановка, словесное окружение. Даже если из состава слова нам не очень ясно его значение, место слова в предложении общий смысл всего высказывания делают понятным и диалектизм.

Изучение и выявление диалектных слов и выражений из произведений писателей помогает сознательному использованию их в литературном языке, дает богатый материал для диалектологических исследований, поскольку каждый писатель в какой-то мере (вольно или невольно) отражает в своем творчестве тот диалект (говор), носителем которого является он сам. Кроме того, изучение диалектной лексики произведений писателей необходимо и для выявления чрезвычайно интересных закономерностей и фактов, важных для лексикологических исследований и истории литературного языка.

Писатели в своем творчестве стремятся использовать все доступное им лексическое богатство родного языка: и слова, кодифицированные нормами литературного языка, и слова из диалектов (говоров), в первую очередь, носителями которых они являются сами.

В формировании литературного языка важную роль играют диалекты. После сформирования его начинается новый этап во взаимодействии с ними. Литературный язык начинает оказывать свое нормализующее влияние на диалекты, способствует нивелировке их, а диалекты становятся неисчерпаемым источником обогащения литературного языка.

Изучение диалектной лексики в составе языка художественной литературы – это также и изучение процесса продвижения диалектных слов в литературный язык. Произведения писателей, пользующихся в своих произведениях диалектной лексикой, особенно писателей-носителей говора, отчасти служат как бы проводником диалектной лексики в литературный язык.

В данном случае нас интересует употребление диалектизмов и просторечных слов в языке художественных произведений писателя-прозаика, классика татарской литературы Г. Исхаки.

Гаяз Исхаки (1878–1954) – один из самых выдающихся татарских писателей XX века. Он родился и вырос в д. Яуширма (Кутлушкино) Чистопольского уезда Казанской губернии, т.е. нынешнего Чистопольского района Татарстана.

Проделав долгий творческий путь, писатель оставил нам бесценное богатое наследие: рассказы, повести и романы, комедии, драмы и трагедии, публицистические и научной статьи.

Г. Исхаки творил свои произведения в сложный период формирования татарского литературного языка – в начале XX века на близком к народу, литературном языке своего времени [6: 120]. Поэтому языковые особенности его произведений вызывают большой интерес у исследователей. Он старался использовать живой, народно-разговорный язык своего родного края.

Своеобразие и неповторимость речи родного края проявляются в его творчестве в разнообразных фонетических, грамматических и лексических формах, «малая родина» включает в себя еще уклад и традиции, живущих в ней. Как носитель чистопольского говора, он представил характерную для этого говора диалектную лексику во всех формах речи: в прямой, несобственно прямой, даже в авторских словах.

Творчество Г. Исхаки богато лексическими (собственно лексическими, семантическими) диалектизмами – словами, выражающими названия предметов, признаков, явлений и т.д.

В данной работе мы рассматриваем наиболее характерные диалектизмы, встречающиеся в сборнике «Зиндан», в который вошли избранные прозаические и драматические произведения писателя [8:670].

В первую очередь рассмотрим **фонетические диалектизмы** – слова с частичным различием в фонемном составе, чем в литературном языке, но с одинаковым значением. Это по существу фонетические варианты литературных слов. Они употребляются автором в речи персонажей и частично в несобственно-прямой речи. Рассмотрим некоторые из них.

Одной из основных особенностей мишарского диалекта является употребление *й* вместо литературного *җ*. Они наблюдаются в следующих словах:

*йил* – җил ‘ветер’, *йир* – җир ‘земля’, *йылы* – җылы ‘теплый’, *йиңел* – *җиңел* ‘легкий’, *йиде* – җиде ‘семь’, *йимеш* – җимеш ‘фрукт’, *йимерде* – җимерде ‘разрушил’ и др.

В то же время в творчестве Г. Исхаки наблюдается и җоканье. Возможно, это результат влияния литературного языка и общение с представителями среднего диалекта:

*җыр* ‘песня’, *җиләк* ‘ягода’, *җиңел* ‘легкий’ и др.

Вместо дифтонгов *-ий/-ей* (графич. и) литературного языка употреблены дифтонги *-ай/-әй*: *Озак үтмәй* (үтми) *печәнгә төшәргә* («Тормышмы бу»). *Кешеләргә гакыл да бирмәй* (бирми) *торган кеше* («Ул икеләнә иде»). Такое явление является активным и в соседнем мензелинском говоре среднего диалекта.

Характерные особенности в соответствии согласных.

*т~ч: чәй түбе*–чәй чүбе ‘чаинка’.

*тишә* – чишә ‘развязывает’.

*к~т: келәү* – теләү ‘моление’; ‘желание’.

*р~п: шурпа – шулпа* ‘суп’; ‘бульон’.

*п~ф: керпек* – керфек ‘ресница’.

*т~д: тулкын* – дулкын ‘волна’.

*м~н:җилем* – җилен ‘вымя’.

*г~к: тегәп* – текәп ‘направляя’.

**Морфологические диалектизмы. Имя действия.** Наряду с литературной формой на *-у/-ү* активно употребляется и отглагольное имя на *-ыш/-еш: Бер мәртәбә ул бүлмәдә чигеш чигеп торган Галимәне күрсәтер өчен...* («Остазбикә»). *Укышларын сорашырга кереште* («Ул икеләнә иде»).

Имя действия на *-ыш/-еш* встречается во всех трех диалектах татарского языка, но особенно активно оно в говорах среднего диалекта, например, в нукратском, глазовском, параньгинском, заказанском, нурлато-кайбицком говорах. В мишарском диалекте оно выступает в таких говорах, которые формировались в контакте со средним диалектом, например, в чистопольском.

**Вопросительная частица *-мы/-ме.*** В современном татарском литературном языке вопросительная частица обычно присоединяется к концу глагольного сказуемого, после аффикса сказуемости *(аласыңмы? хәтерлисеңме?).*

В произведениях Г. Исхаки часто используется диалектная форма, где вопросительная частица ставится перед аффиксом сказуемости: *Исән торамсың, Садыйк?* («Кияү»).

*Шигырьне яратамсыз?* («Ул икеләнә иде»).

**Причастные формы.** Вместо причастных форм на *-ган/-гән, -кан/кән* часто употреблены древние архаичные формы на *-дык/-дек:*

*зәһәрләндекләре* – зәһәрләнгәннәре

*идеке* – икәне

*хәзерләндеге*– хәзерләнгәне.

**Лексические диалектизмы.** Как принято считать, закономерность употребления диалектизмов в художественной литературе заключается в том, что они вводятся обычно в речь персонажей и выполняют различные функции. Особенностью творчества Г. Исхаки является то, что здесь диалектная лексика встречается не только в речи персонажей, но и в авторской, причем в последней даже чаще.

*Кан'атым*– ласковое обращение к молодым. В говорах мишарского диалекта это слово употребляется еще в вариантах: *кан'аткә, акыллы канәт, канатыми* др. [1: 124].

*Абыстай* – почтительное обращение к женщинам старше себя. Такое употребление этого слова характерно для говоров среднего и мишарского диалектов: *«Яшьләргә канатым дип, картларга абыстай дип эндәшә иде»* («Теләнче кызы», 11).

Использованы термины родства, слова-обращения характерные для чистопольского говора мишарского диалекта: *бикәч* – яшь килен 'молодуха'; *тудык җиңги* 'обращение к жене старшего брата'; *чибәр абыстай* 'обращение к младшей сестре своего мужа' и др.

*Алъяпма* – литер. алъяпкыч 'передник, фартук': *Ул да каенатадай хәзрәткә чабатадан, билдә алъяпма булган кыяфәттә очрап оялды* («Остазбикә», 281). *Ул шул көнне алъяпма яба, башына ак эшләпә кия иде* («Теләнче кызы», 57). *Алъяпмалык* – литер. алъяпкычлык, т.е. ситец, материя, предназначенная для шитья фартука, передника: *«Җыелган икмәкне сатып карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк, ыштан...»* («Сөннәтче бабай», 211). Слово *алйапма/ алҗапма*в таком же значении употребляется и в мензелинском говоре среднего диалекта, оно зафиксировано в чистопольском, дрожжановском, мелекесском говорах мишарского диалекта татарского языка [3: 278].

*Кагау* – литер. тилгән 'коршун'. Слово *кагау* в таком же значении зафиксировано в сергачском и хвалынском говорах мишарского диалекта: *Тагы Сәгадәткә үзенең балалыклары, инештә: «Күшә, кагау (тилгән), күшә. Бер аягыңа яфрак, бер аягыңа тимер! Аны алмаенча гел тилмер!» дип, кызлар белән каз бәпкәләре саклаудан алып...үткән эшләрне уеннан кичерде* («Теләнче кызы», 31).

*Кыйты* – литер. начар 'плохой'. Это слово употребляется и в заказанских говорах среднего диалекта. «*Яхшы ананың баласы яхшы, кыйты ананың баласы әшәке булуында һич кемнең шөбһәсе юктыр* («Ике йөз елдан соң инкыйраз», 180). *Тирес* – литер. кире, үзсүзле 'упрямый, своенравный'. В таком же значении это слово употребляется во всех говорах мишарского диалекта. *«Иреңне сөйсәң дә үз гакылың үзеңдә булсын дип тәрбия кылыр идең, ирең үзсүзле, тирес булса, нишләрсең*?» («Татар гакылы», 150).

*Айбагар* – литер. көнбагыш 'подсолнечник'. Слово *айбагар* активно употребляется в говорах мишарского диалекта и в крещено-татарских говорах: *айбагар/айбағар/айбағыр. «Җизниләр бакчасында айбагар бар, сезгә дә бирермен*» («Кәҗүл читек», 264).

*Себерү* – литер. сөртү ‘вытирать’, имеется во всех говорах мишарского диалекта. *«Битләрне рәтләп себереп бетермәенчә йөгереп кердем*» («Кәҗүл читек», 268).

*Алаша* – литер. ат ‘лошадь’ – во всех говорах мишарского диалекта. *Кара, алаша, мескен, тирләгән...* («Кәҗүл читек», 264).

*Ашаяк* – литер. аш савыты ‘маленькая чаша, блюдце для супа’.

В диалектологическом словаре это слово записано из дрожжановского говора мишарского диалекта: *«Шыгыр-шыгыр арба, шыгырданга барма. Шыгырданга барсаң, бер ашайак салма».*

*Тустак* – литер. чынаяк; кечкенә савыт ‘чайная чаша, маленькое блюдце’. *«Теге абзый тагы бер ашаяк бәрәңге берлә бер башкорт тустагы шурпа да алып керде»* («Башкорт бәхете», 171).

*Кәләвә* – литер. хәлвә ‘национальное блюдо’. *«Рамазан айларында Фәхри кәләвә (хәләвә) сатарга димләгән иде»* («Бай угылы», 118).

*Йомшак* – литер. ак ипи, бодай күмәче ‘калач, белый пшеничный хлеб’. В таком же значении слово *йомшак* употребляется во многих говорах мишарского диалекта: *кузн., хвл., срг., чет., чпр., стрл.* и др. [2: 155].

*...кызларына күчтәнәч йибәрә торган кайнаналарның бәлешләре, йомшаклары пешә иде* («Теләнче кызы»).

*Кәкәш* – литер. эремчек, ит, бәрәңге пәрәмәче‘шаньги’. В таком же значении употребляется во многих говорах мишарского диалекта. *«Ул чынаяк асты кадәр итеп ясаган мишәрләрнең кәкәше яисә казаннарның кечкенә бәлеше иде*» («Башкорт бәхете», 171).

*Сумса* – литер. кечкенә бөккән ‘пирожок’. Слово *сумса* в таком же значении употребляется в говорах среднего и мишарского диалектов. «*Вахид хәзрәт чәйне ясагач та Сәгыйдә остазбикә йә пәрәмәч, йә йомшак, йә сумса күтәреп килеп утыра»* («Остазбикә», 294).

*Юка, җәймә, как-төш, коштеле ‘межнациональные блюда’. «Ике якта ике тәрилкәдә катырган как-төш, икешәр тәрилкәдә кош телләре»* («Ул икеләнә иде», 342).

*Кыстыбый* ‘национальное блюдо’. Это древнее блюдо и его названия в различных лексико-фонетических вариантах зафиксировано и в соседних тюркских и угро-финских языках: башк. *ҡыстымбый,* чув. *кастампи,* мари. *кыстывий,* удм. *кыстыбый* [2: 251]. *«Өйләрендә әлләникадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт-карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде. Ул кайвакытлар мич ягып күмәч сала, кыстыбый пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде»* («Сөннәтче бабай», 205).

*Тутырма* ‘домашняя колбаса’, *«Килен кулын юып пилмән ясап алды. Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, аның артыннан дөге бәлеше, аның артыннан тутырма белән ит, аннан соң җимеш суы...»* («Кияү», 247). *Борчак белене* – литер. борчак оны коймагы ‘блины из гороховой муки’. *«Иртәгә борчак белене бирермен»* («Кәҗүл читек», 263). *Күмәч* – литер. бодай оныннан пешерелгән икмәк ‘хлеб из пшеничной муки’. *«Шәкерт абый миңа май бирә, күмәч бирә, мине сыйлый иде»* («Шәкерт абый», 190).

В рассказе «Кияү» очень подробно описывается порядок преподнесения свадебной обрядовой пищи: *«Ашлар-сыйлар – һәммәсе муллаларча үтте: ак оннан ясалган пилмәнне ике төрле вак бәлет алыштырды, бәлешләрдән соң, муллаларча иттереп, серкәле-керәнле тураган ит (мужикларча турамаенча чыгарылган түгел), аның артыннан затлы йимеш суы, иң ахырдан ясап чыгарылган лимунлы чәй бирелде, чәй янына баллы как-төш чыгарылды. Бирнә күрсәтелде.*

*Асу* – литер. пешерергә салу, пешәргә кую, пешерә башлау – аш турында ‘заварить, начинать варить, поставить варить – о пище’. *«Мәрфуга абыстай үзе аскан яңа тәкә шурбасына токмач та кисеп салды»* («Кияү», 249). Слово *асу* в таком же значении широко употребляется во многих говорах среднего и западного диалектов: *трбс., кмшл., минз., тмн., лмб., чет., срг., влгг.* Например, в чистопольском говоре: *Асар идем каз – монда халык аз* [4: 375].

В касимовском и нагорно-кряшенском говорах это слово зафиксировано в значении ‘польза, добро’ – татарский файда, игелек: *«Йакшы балалар үстерсәң, асу күрәсең».* Словосочетание *асу итү* встречается в древних обрядовых, свадебных песнях. Например, в говоре нагорных кряшен:

| | |
|---|---|
| *Асрай белгән кешегә* | ‘Людям, ценящим меня |
| *Асу итәр кешидем* | могла бы принести пользу’ |

Слово *асу, асыг* употреблялось в древнекыпчакском языке, оно зафиксировано и в письменных памятниках. Ср. карачай.-балк. *асыу,* тур. *асу* ‘польза, выгода’ [7: 181; 10: 147].

*Аяк асты шил булу* – литер. аяк тавышлары тыну, хәрәкәт туктау, тынычлык урнашу ‘затихнуть – о шагах, о прекращении ходьбы’. *«Көндезләрен начальниклары, старшийлары күп йөргәнгә, мин аяк асты шил булгач кына, проверкалар беткәч кенә яза идем»* («Зиндан», 64).

Словосочетание *аяк асты шил булу, сәл булу* зафиксировано в камышлинском говоре, в говорах Оренбуржья, в закамском, балтасинском говоре и в говоре крещеных татар.

Часто употребляется в творчестве Исхаки следующие диалектные названия дней недели.

*Баш көн* – литер. дүшәмбе ‘понедельник’. *«Алай булса, хәзрәт, безгә фатиха бир инде, бүген баш көн, башламакчы булам – дия иде»* («Сөннәтче бабай», 209). *«Баш көнне акча салырга дип, тагы теге Шәрәфи абзый килде»* («Кияү», 236).

*Буш көн* – литер. сишәмбе ‘вторник’. *«Хәзрәт мәхдүм аркылы, яисә хезмәтче аркылы сөннәтче бабайга: буш көн (сишәмбе көн) кан алырга керсен дип, хәбәр китерә иде»* («Сөннәтче бабай», 213).

*Кече атна көн, кечатна көн* – литер. пәнҗешәмбе ‘четверг’. *«Кечатна көн йитте. Хәлим шәрикләре белән мәдрәсенең зурракларына мәҗлес бирде»* («Мулла бабай», 283). *«Кече атна көнне иртә берлән Фатыйх байны алырга пристаньга атлар төште»* («Бай угылы», 115).

*Базар көн* – литер. якшәмбе ‘воскресенье’. *«Базар көнне аллага тапшырырмыз»* («Кияү», 236).

Некоторым диалектным словам Г. Исхаки сам дает пояснения: *буш көн* – сишәмбе ‘вторник’, *кагау* – тилгән ‘коршун’, *дебрән* – чукрак ‘глухой’. А слова, характерные для чистопольского говора, которые понятны всем его окружающим, он употребляет без пояснения: *айбагар, канатым, ашаяк, алъяпма, тирес, кыйты* и др.

В произведениях Г. Исхаки использованы и некоторые русские заимствования, характерные для мишарского диалекта. Например, *барига* < рус. варежки, тат. литер. бияләй. *«Сәгыйдәнең кулыннан, чиләге төште, аның артыннан кулындагы зур баригасы җиргә тамды»* («Остазбикә», 282).

*Повозка* – литер. бөтен яктан ябык җиңел арба, көймә. Слово *повозка* часто употребляется в свадебных обрядах. В творчестве Исхаки оно встречается также как обрядовый термин: *«Алда күрше авыл боярыннан алган повозкада кияү мулла белән Саҗидә китте, арттан дүрт йөктә әйберләр китте»* («Кияү», 254).

*Мороз* < рус. мороженое – тат. литер. туңдырма. «*Бара-бара буйларның барып мороз ашаулылары, очраган кибеттән канфыт алып ашап йөрүләре тирән бер гадәт кеби булган иде*» («Бай угылы», 118).

Г. Исхаки в своем творчестве большое внимание уделяет таким тонким сторонам жизни, как переплетение религиозных и народных обрядов. Это особенно запоминается в произведении под заглавием «Сөннәтче бабай» ‘старик, который исполняет религиозный обряд обрезания’. «*Авылның картлары, ир урталары, яшьләре – һәммәсе дә үзләре белә башлаганнан бирле аны Сөннәтче бабай дип таныйлар, Сөннәтче бабай дип йөриләр иде*» (с. 198). Этот образ с уважительным названием *баба* сохраняется во многих диалектах и говорах: *баба* – в астраханском, *баба карт* – в красноуфимском, *сөннәт баба* – в мензелинском, *сөннәт паба* – в диалектах сибирских татар и других [5: 146].

В заключение отметим, что к числу особенностей писателя относится активное использование им лексики живого, народно-разговорного языка своего времени, своего родного чистопольского говора мишарского диалекта. В этом регионе были тесные этнокультурные и этнолингвистические связи с представителями среднего диалекта. Поэтому в говорах чистопольского региона имеются черты не только западного (мишарского) диалекта, но также особенности заказанской и юго-восточной диалектной зоны Закамья – мензелинского.

В творчестве Исхаки особое место занимает также лексика народных традиций, относящаяся к материальной и духовной культуре, названия пищи, одежды, обрядов и обычаев.

ӘДӘБИЯТ

1. Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск, 2003. 288 б.

2. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: Дом печати, 2007. 480 б.

3. Баязитова Ф.С. Халык традицияләре дексикасы: бирнә, кием-салымнар (этнолингвистик, культурологик, диалектологик концептлар). Казан, 2009. 412 б.

4. Баязитова Ф.С. Туй йолалары лексикасы (җирле сөйләш һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан: Паравитта, 2011. 976 б.

5. Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (йола һәм фольклор текстлар яссылыгында). Казан, 2012. 331 б.

6. Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы. Казан, 1999. 576 б.

7. Изысканный дар тюркскому языку (Грамматический трактат XIII в. на арабском языке. Ташкент, 1978.

8. Исхакый Г. Зиндан: Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.

9. Махмутова Л.Т. Современный татарский литературный язык и диалекты // Вопросы татарского языка и литературы. Кн. IV. Казань, 1969. С. 26–34.

10. Наджип Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV в. (на материале «Хосрау и Ширин» Кутба). Книга 1. М., 1973.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «ЗӨЛӘЙХА» ДРАМАСЫ ҺӘМ ЗӨЛӘЙХА ОБРАЗЫНЫҢ ПРОТОТИБЫ

***Ф.Ә. Бәйрәмова*** *(Яр Чаллы)*

В статье рассматриваются процесс создания трагедии Г. Исхаки «Зулейха» и история ознакомления с нею общественности. Представлен богатый материал о хронологии изображаемых событий и их исторической основе. На основе архивных материалов и истории деревни выдвинута гипотеза о реальном существовании прототипа главного героя пьесы Зулейхи, рассказано о его трагической судьбе.

**Ключевые слова:** первая трагедия, насильственное крещение, трагедия народа, образ, конфликт, прототип.

The article discusses the process of creating Iskhkii`s tragedy «Zuleikha» and the history of familiarization of the public with it. It is presented a rich material on the chronology of the depicted events and their historical basis. On the basis of archival materials and the history of the village, a hypothesis about the real existence of the prototype of the main character of the play Zuleikha is put forward, her tragic fate is told.
**Key words:** the first tragedy, forced baptism, a tragedy of the people, a conflict, a prototype.

Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы 1907–1912 елларда языла. Авторның әйтүе буенча, ул аны 1907 елның башында Чистай төрмәсендә яза башлый, әмма камерада тентү вакытында «Зөләйха»ның кулъязмасын алалар һәм ул юкка чыга. Бу хакта Гаяз Исхакый «Бер токарның саташуы» дип аталган хикәясендә хәбәр итә. «Беренче мәртәбә мин аны Чистай төрмәсендә язарга тотындым. Бер-ике утырып язгач та, безнең бүлмәдә тентү ясадылар, минем язган әсәремне алдылар. "Татарча язарга ярамый", дип әмер бирделәр, әсәр дә югалды, дәрт тә кайтты» [4: 236–237]. Үзенең «Зиндан» повестенда Исхакый бу драманың шартлы исемен дә әйтә, аны «Отпавший» дип атый. «Мин хәзер "Отпавший" исемле бер пьеса язарга хәзерләнә башладым. Беркөнне пьесаның пәрдәләрен бүлеп, планын бетереп, язарга гына тора идем, старший кереп безнең бүлмәдә тентү ясый башлады. Бездә әллә никадәр әйберләр булганга, китаплар, гәзитәләр, кәгазьләр алып чыкты. Һәм дә минем "Отпавший"ымның да планын алып чыкты» [3: 325].

Бу әсәр өстендә эшләвен Исхакый төрмәдән чыккач та дәвам итә, хәтта инде икенче пәрдәнең ахырына җитә, әмма торган җирендә чираттагы тентүне уздырганда, кулъязманы тагы алалар һәм ул юкка чыга. «Мине тагы төрмәгә алып киттеләр, минем берлән бергә әсәремне дә алдылар. Әлбәттә, прашение бирдем, кайтарыңыз, биреңез, дип сорадым. Кайтмады...», дип яза Исхакый бу хакта [4: 237].

Гаяз Исхакыйның бу чоры төрмә, сөрген, аннан качу, тагы төрмә һәм сөргеннәр белән бәйле, шуңа күрә ул «Зөләйха» әсәрен дә кат-кат башларга һәм югалтырга, мөмкинлек чыгу белән, тагы яза башларга мәҗбүр. Шундый мөмкинлек сөргеннән качып, 1911 елда Төркиягә килеп чыккач ачыла. Үзенең «Тәрҗемәи хәлем» әсәрендә Исхакый биредә «Зөләйха» әсәрен язып тәмамлавын әйтә, әмма сүз драманың өч пәрдәсе турында гына бара. «Бурада кәндемең әдәби әсәрләрем миянында мөһим йир тоткан "Зөләйха" драмамы язмайа башладым. 1911 елның язында Кандиллледә бу әсәремне тәмам итдем һәм дә "Сөннәтче бабай" вә "Шәкерт абый" хикәяләрен яздым», – дип хәбәр итә ул [6: 64].

Әмма үзенең «Бер токарның саташуы» әсәрендә Гаяз Исхакый «Зөләйха» драмасын Истанбулда тәмамлый алмавын әйтә. «...Бер пәрдә, ике пәрдә, өч пәрдә яздым. Уем белән Истанбулда язып бетерергә кистергәнгә, дүртенчегә тотындым. Мин аурупалы бер мәмләкәтнең тәмам аурупача идарәсеннән качып, кунак булып килгән хуҗаларымда зур кәефсезлек башланды» [4: 238]. Шушы күңелсез хәлләрдән соң, Исхакый әсәрен дәвам итә алмый, ноябрь ахырында Петербургка кайтып китә һәм «Зөләйха» әсәренең дүртенче, бишенче пәрдәләрен биредә язып бетерә, 1912 елның гыйнвар башына язып тәмамлый. Ул аны кат-кат укып чыга, төзәтә һәм татар яшьләренә кычкырып укый, кулъязманы сакларга да аларның берсенә бирә. Моннан соң Исхакыйны тагы тотып алалар һәм сөргенгә сөрәләр, ул аннан 1913 елда гына әйләнеп кайта.

«...Һич бетмәс дип уйлаган, һич очына чыга алмам, дип кистергән әсәр бетте, – дип яза Исхакый бу хакта. – Чын да беттемени? Һич ышанмый идем,

бу бәхетсез татарның бәхетсез тормышыны күрсәтә торган әсәрнең болай тәмам булуына ышанмый идем. Мин инде бу әсәрне әллә кайчаннан бирле бит, муеныма тагып, өстерәп йөрим. Шул йөк берлән берничә мәртәбә төрмәнең тимер челтәрле ишегеннән үттем, шул йөк берлән мин Архангельнең суык сахрасыны кичтем, йөкне һаман ташлый алмадым, амәнәтне иясенә ирештерә алмадым» [4: 236].

Бу изге амәнәт иясенә – халкына бары тик биш елдан соң гына килепирешә. «Зөләйха» драмасы милләткә бары тик 1917 елның февраль инкыйлабыннан соң гына әйләнеп кайта, шул елның мартында ук ул «Сәйяр» труппасы тарафыннан Казанда сәхнәгә куела һәм халыкка күрсәтелә, 1918 елда аерым китап булып басылып чыга. Милләт бу әсәрне тетрәнеп кабул итә, Зөләйханың фаҗигале, әмма кяферләргә буйсынмаган язмышында үзен күрә, аның дөньяга чыгуын татарга азатлык килү билгесе итеп таный. Әмма совет хакимияте заманында «Зөләйха» драмасы, патша вакытындагы кебек, иң куркыныч, зарарлы әсәрләр исемлегенә кертелә һәм тыела. Бу әсәр милләткә бары тик узган гасырның туксанынчы елларында, үзгәртеп кору чорында әйләнеп кайтты, ул яңадан татар сәхнәсендә куелды һәм аның буенча нәфис фильм төшерелде. Тик соңгы елларда «Зөләйха» әсәре тагы читкә этеп куелды, ул театрда да, экранннарда да юкка чыкты.

Ни өчен патша заманында да, совет чорында да, хәтта хәзер дә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәренә хакимият тарафыннан шундый тискәре караш соң? Чөнки бу драма XIX гасырда Россия империясендә татарларны көчләп чукындырулар турында язылган бердәнбер әдәби әсәр, ул тарихи чынбарлыкны чагылдыра. Гадәттә, көчләп чукындыруларны Явыз Иван һәм Петр Беренче чоры яки 18 гасыр белән генә бәйлиләр, әмма милләтебезгә карата бу явызлык 19 гасыр азагына кадәр дәвам иткән. Заманында көчләп чукындырылган татарларга рәсми рәвештә ислам диненә кайту бары тик 1905 елгы манифесттан соң гына мөмкин булган.

Исхакыйга да чукындыру темасына әдәби әсәр язарга бәлки шушы манифест тәэсир иткәндер, чөнки бу идеяне ул 1905 еллардан бирле башында йөрткәнлеге билгеле. Бу хакта аның замандашы Шакир Мөхәммәдьяров менә нәрсә яза: «Г. Исхакый Истанбулда 1905 еллардан бирле башында йөргән бер әсәрне яза башлаган. Бу әсәр – гасырлар буенча газиз диннәре өчен мужик үрәтниктән җәбер күреп килгән мөселман гаиләсен тасвир иткән дәһшәтле, авыр бер трагедиядер. Исеме «Отпавший» – «Мәкруһ», яһүд «Зөләйхадыр». Бу әсәрнең язмышы – эчендәге хәлләре кебек. Күптән язылган башы жандармнар кулында кала. Әсәр Петербургта язылып бетә [3: 396].

Ул елларда татар матбугатында мәкруһлар хәле турында язмалар да шактый басылып чыга, чөнки бу темага цензура бераз йомшара. Шушы мәкаләләр арасында тарихчы Гайнетдин Әхмәровның 1906 елның 3 маенда «Казан мөхбире» газетасында басылып чыккан «Мәкрүһләр хәленнән» дигән язмасы аерата әһәмиятле, чөнки анда сүз Гаяз Исхакыйның туган төбәге Чистай өязендәге хәлләр турында бара. Мәкаләдә Исхакыйның туган авылы Яуширмәдән ерак булмаган Тубылгытау авылындагы вакыйгалар сурәтләнә, заманында ата-бабалары көчләп чукындырылган керәшен татарларының исламга кайту өчен көрәшләре тасвирлана. «Бу мөселманнарның рәсмән нәсари саналып, кәнисә дәфтәрләренә кай заманда языла башлаганнардыр, мөгайян мәгълүм түгел, – дип яза автор. – Әмма 1829, 1830, 1831 елларда "отпавший" исемендә йөртелә башлаганнар, 1856 елда Чистай вә Спас өязләрендә булган гайре мәкрүһләр берлән бергә җыелышып, падишаһ исеменә татарча язып, ике прошение биргәннәр. Прошениеләре бу рәвештә язылган: "Падишаһның 1846 нчы елда булган фәрманы буенча, кәнисәле булган урыс авылларына күчерә башладылар.

Приход кәшишләребез нәсари динен өйрәттерү өчен; ләкин без дөреслектә чын мөселманбыз, нәсари динен кабул иткәнебез юк, кәнисәләргә һичбер вакытта йөрмибез, яңа туган балаларыбызга һичбер вакытта рус исемнәре кушканыбыз юк, семейный списокларда һәм ревизия сказкаларында рус исемнәре язылган булса да, ул кәшишләр үзләре теләгәнчә язып куйган исемнәр генә. Хәзердә становой пристав, окружной начальник, волостнойлар кәшишләр берлән авылларыбызга килеп, безне төрлечә җәзалый башладылар, үзебезне каравылга ябалар, хатыннарыбызны җибәреп, җәмәгатьләребезне тараталар, биргән кызларыбызны ирләреннән аерып алып, яшь балаларын ятим калдыралар, халыкны фәкыйрьлеккә төшерәләр", – дип язганнар» [1: 194].

Гаяз Исхакыйга бу язма нык тәэсир иткән булырга мөмкин, бәлки «Зөләйха» драмасын язарга этәреч тә булгандыр. Әсәрдә без аның билгеләрен дә, Тубылгытау белән бәйле вакыйгаларны да күрәбез. Әхмәтҗан исемле персонаж бу хакта болай сөйли: «Урман астыннан Тубылгы тавына бардым. Анда шулай Шәмси абзый дигән кеше бар икән. Бик һәйбәт тора, тегермән тота икән. Угылы, кызы йиткән, үзе дә унсигез елдан бирле шул эш артыннан йөри икән. Эшне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Попымыз бик усал, урман астына чиркәү салырга тели, балаларны көчләп урыс монастырена җибәртә, кызларны көчләп урыска бирә, шуны нишлик, санатка прошение бирергә телибез, дидем» [5: 375–376].

Әмма мондый трагик әсәр язар өчен газета материалы гына җитми, алардан мәгълүмат алырга гына мөмкин, драма өчен язмышы тетрәндергеч булган образ кирәк. Әсәрдә милләтнең бөтен фаҗигасе Зөләйха образы аша бирелгән. Кем соң ул – Зөләйха? Автор аны үзе уйлап чыгарганмы яки тормыштан алганмы? Ул вакыттагы матбугатта көчләп чукындырылган татар хатын-кызларының язмышы турында аерым материаллар юк. Бу елларда Гаяз Исхакый архивларда да утырмаган, һәрхәлдә, ул хакта мәгълүмат юк. Исхакый «Зөләйха» әсәре язылган 1907–1912 елларда төрмәләрдән һәм сөргеннән кайтып кермәгән. Алайса, Зөләйха образының прототибын кайдан алган соң ул, шушы хәтле фаҗигаи язмышны уйлап чыгарып булмый бит!

Гаяз Исхакый Зөләйха образын тормышның үзеннән алып язган, ягъни, бу төбәкнең тарихында әсәрдә тасвирланган хәлләр булган һәм алар халык хәтере, истәлекләр аша «Зөләйха» драмасына күчкән. Исхакый әсәренең башына «Вакыйга алтмышынчы елларда» дип язган, ягъни, «Зөләйха» драмасында тасвирланган вакыйгалар 1860 елларда бара, дип аңларга кирәк. Әмма биш пәрдәле әсәрнең өч пәрдәсендә вакыйгалар бер вакытта, ике пәрдәсендә егерме елдан соң бара, ягъни, Зөләйха каторгадан әйләнеп кайткач дәвам итә. Шулардан чыгып, әсәрдәге вакыйгалар 1840 елларда башланып, 1860 елларда дәвам итә, дип тә, 1860 елларда башланып, 1880 елларда дәвам итә, дип тә аңларга мөмкин. Әмма гасыр ахырында христианлаштыру сәясәте инде бераз йомшара, ә менә 1840 елларда исламга кайткан керәшен татарларын җәзалаулар иң югары ноктасына җиткән була.

Тарихка «Европа жандармы» дип кереп калган, үз халкын таяк белән суктырып үтерткән өчен «Николай Палкин» кушаматын алган Николай Беренче патша җирле халыкларны рәхимсез рәвештә христианлаштыру һәм урыслаштыру сәясәте алып барган. Патша фәрманы белән, чукындырылган, әмма христиан динен тотмаган татарларны көчләп чиркәүле урыс авылларына күчерү башлана, аларны хәтта Рәсәйнең иң ерак почмакларына, әйләнеп кайта алмаслык җирләргә җибәрәләр. Шул ук вакытта әгәр авылда берничә чукындырылган татар булса, шуларны сәбәп итеп, калган мөселман-татарларны үз ишләре янына күчерәләр, ә алар урынына тагы урысларны китертеп утырталар.

Татарларны урыс авылларына күчерүләр бик рәхимсез төстә бара, аларның үзләреннән сорап та тормыйча, өяз үзгеннән килеп, бөтен йорт-җирләрен, мал-туарларын сатканнар, аннан бернәрсәсез урыслар арасына китереп ташлаганнар. Шулай итеп, бу бичара татарлар Сембер, Әстерхан, Воронеж, Царицын якларына сөрелгәннәр, күбесе шунда юкка чыккан. 1830–1840 елларда татарларны дистәләп кенә түгел, йөзәрләп, меңәрләп урыс авылларына күчергәннәр, аларны анда таяклар белән суктырып, праваслау динен тотарга мәҗбүр иткәннәр. Шушы хәлдә калмас өчен, күп кенә татарлар, урыс арасына сөрелгәнне көтеп тормыйча, гаиләләрен алып үзләре чыгып качканнар, дистә еллар бәрелеп-сугылып сукбайлыкта йөргәннәр, дөнья буйлап таралганнар. Шулай ук яңа туган балаларын чиркәү кенәгәләрендә теркәтмәс өчен, авырлы хатыннар авылларыннан чыгып китеп, еллар буе сукбайлыкта качып йөрергә мәҗбүр булганнар.

Әмма бу җәзалар гына халыкны яңадан ислам диненә кайтудан туктатмаган, керәшен татарларының күпчелеге ачыктан-ачык тә, яшерен рәвештә дә ислам динен тоткан, яшерен яки указлы муллалар аларга никах укыган, балалары тугач, мөселманча исем кушкан, кеше үлгәч, поп килеп җиткәнче мөселманча күмәргә ашыккан. Әмма поплар да үзләрен бик агрессив тотканнар, татарларга каршы бөтен явызлыкларын полиция ярдәмендә башкарганнар, хәтта кайбер мөселман мәетләрен каберләреннән казып алып, христианча күмәргә омтылу, кабер өстендә сугышу очраклары да булган. Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасында бу хәлләр барысы да тарихи дөреслектә чагылдырылган.

Шунысын да әйтергә кирәк, ул чакларда милләтнең кимендә өчтән бере чиркәү кенәгәләрендә һәм ревизия документларында христиан буларак теркәлгән, әмма аларның күпчелеге исламнан аерылмаган. Чистай һәм Спас өязләрендә дә һәр авылда диярлек керәшен татарлары булган, шул исәптән, Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә дә. Шулай ук Яуширмә янәшәсендәге Кыр Шонталасы, Чирүле Шонтала, Урман асты Шонталасы, Гаделша, Мөслим, Нарат-Елга, Талкыш, Шәмә, Тигәнәле, Әдәмсу, Сарсаз, Үзи һәм бик күп татар авылларында да мәкруһлар яшәгән. Зөләйха аларның кайсыннан булган соң? Кайберәүләр аны Яуширмәдән, дип әйтергә теләсәләр дә, тарихта андый риваятьләр сакланмаган, патша архивларында да мондый эшләр юк, Исхакый үзе дә Зөләйханы Яуширмәнеке дип язмаган. Әсәрдә Зөләйха үзен Карга авылыннан, ди, әмма бу да шартлы исем генә булырга мөмкин. Алайса, Зөләйха кайсы авылдан булган һәм аның прототибы кем?

Бу очракта иң ышанычлы чыганаклардан булган архив материалларына мөрәҗәгать итәбез. Чистай өязендә 1840–1860 елларда яңадан исламга кайткан өчен кемнәр хөкем ителгән һәм алар арасында хатын-кызлар булганмы? Әйе, бу елларда Казан губернасында 138 татар авылыннан яңадан исламга кайтуны сорап патшага үтенеч-прошениеләр бирелгән, Чистай һәм Спасс өязләрендә 51 татар авылында халык баш күтәргән, земство һәм өяз судлары аларга каршы эшләр белән тулган. Шуларның берсе аеруча әһәмиятле, чөнки анда керәшенлектән ислам диненә кайткан Гөләйза исемле татар хатынының эше карала, анда ул Пелагея дип аталган. Бу эш «СЕКРЕТНОЕ ДЕЛО № 24 по рапорту Чистопольского уездного суда об отпадении от православия в магометанство крещенной из татар девки деревни Степной Шенталы Пелагеи, по отцу неизвестной», дип атала, Татарстан Республикасы Милли архивында саклана [8: 138].

Нигә без Гөләйза эшенә шулай игътибар иттек һәм аның язмышында Зөләйха образы белән уртаклыклар күрдек соң? Беренчедән, Гөләйза туып-үскән Кыр Шонталасы авылы Яуширмәнең күршесендә, кыр аша гына

урнашкан, бу ике авыл кыз биреп-кыз алып, гел аралашып яшәгән. Гөләйза кияүгә чыккан Чирүле Шонталасы авылы да Яуширмәдән ерак түгел, ике авылда уртак нәселләр шактый. Икенчедән, Гөләйзаның язмышы бик тетрәндергеч, ул дин-ислам хакына күп газаплар күрә, үзенең мөселманлыгын исбатлау өчен еллар буе мәхкәмә юлларын таптый, вакытсыз дөньядан китә. Гөләйза үзе үлеп котылса да, ике улын, аталарыннан аерып, чукындыралар һәм христиан динендәге кешеләргә тәрбиягә бирәләр, Гөләйзаның карт ата-анасын һәм туганнарын урыс авылларына күчерергә карар чыгаралар, Гөләйзаны мөселманча күмгән мулланы һәм азанчыны хөкем итәләр.

Әмма Гөләйза һәм Зөләйханың язмышлары арасында бераз аерма да бар. Зөләйханы мөселман иреннән аерып көчләп урыска кияүгә бирәләр, ул аны агулап үтерә һәм каторгага җибәрелә, егерме елдан соң шул урыс авылына кайтып үлә. Гөләйзага да шундый карар чыгарыла, ягъни ун ел яшәгән мөселман иреннән аерып, балалары белән Казан консисториясенә чукындырырга җибәрергә, диелә, әмма ул бу җәзадан үлеп котыла. 1838 елның 21 февраленнән алып, ягъни аңа суд башланган көннән, 1844 елның мартына – соңгы мәхкәмәгә кадәр Гөләйзаның һәр адымы, һәр сүзе диярлек теркәлеп барган, алар Милли архивның Казан губерна идарәсе, Казан җинаять эшләре палатасы, Казан рухани консисториясе, Чистай дини идарәсе, Чистай өяз һәм земство судлары, Чистай өязе 1 һәм 2 нче стан приставлары, 9 һәм 10 нчы ревизия материаллары фондларында саклана.

Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәрендә дә, Гөләйза тарихында да приставларның һәм стражникларның, попларның бу авылларга килеп, халыктан сорау алу күренешләре бар, Гөләйза эшендә ул мәхкәмә беркетмәләрендә теркәлеп калган. «Зөләйха» әсәрендә дә, Гөләйза тарихында да авыл ирләрен, кул-аякларын богаулап, кыйный-кыйный Казанга, чиркәү судына алып бару хәбәрләре бар. Зөләйханың да, Гөләйзаның да мөселман ирләреннән өч балалары була, Гөләйзаның төпчек улы әнисеннән соң үлә, Зөләйханыкы юкка чыга. Зөләйханың да, Гөләйзаның да яшьләре бер тирәдә – 35–37 яшьләр. Зөләйха да, Гөләйза да христиан динен танымыйлар, ахыргача ислам динен тоталар, иман хакына үлемгә баралар. Исемемнең чыннан да Пелагея икәнлеген белмим, чөнки мин бервакытта да русча исем белән йөрмәдем, элек тә, хәзер дә минем атым Гөләйза, – ди Гөләйза Чистай суды каршында. – Әнием мине тумыштан ислам динендә тәрбияләде, христиан кагыйдәләренә өйрәтелмәгәнмен, беркайчан да урысларның бернинди гореф-гадәтләрен үтәмәдем, христиан диненең нәрсә икәнен дә белмим. Мин ничек христиан булыйм?!» [9: 12]. Гөләйзаның сөйләгәннәре урыс теленә тәрҗемә ителгән һәм мәхкәмә беркетмәсенә теркәлеп калган. Зөләйханың өзгәләнеп сөйләгәннәре Гаяз Исхакый әсәрендә дә чагылыш таба... «Мине үз динемнән, хак диннән чыгарырга теләделәр, көчләп алып, ирем бар өстеннән руска иргә бирделәр. Көчләп чукындырдылар. Көчләп ата-анамнан, бала-чагамнан аердылар. Мин, әлхәмдүлиллаһ, барсына да чыдадым, барсына да! Дин ислам өчен мин зәхмәт чиктем. ... Алла юлында сугышка үткәргән гомер буш түгел. Әлхәмдүлиллаһ, хатын булсам да, күп ирләргә насып булмаган дин сугышында булдым. Егерме ел бербуйдан сугыштым. ... Егерме ел бербуйдан, төрмәдән каторгага, каторгадан Себергә, Себердән Себер аръягына. ... Юк, үкенмәдем. Хәзер дә үкенмим. Безнең китапта әйткән, Аллаһы Тәгалә дин юлында күргән бер авырлыкка ике җиңеллек бирер, дигән» [5: 421].

Тумышы белән Кыр Шонталасы авылыннан булган, шушы архив материалларын бик җентекләп өйрәнгән, туган авылы тарихы турында китаплар язган техник фәннәр кандидаты Галим Хисамиев, беренчеләрдән булып, Зөләйха об-

разының Гөләйза тарихыннан алып язылырга мөмкин булуы турында әйтте. «Әсәрнең герое җыелма образ булырга мөмкин яки аның төп прототибы булып Алексеевск районы Кыр Шонталасы авылыннан чукындырылган дип саналган татар кызы Пелагея (Гөләйза) торуы ихтимал, – дип яза ул. – Гаяз Исхакый әсәрендәге вакыйга XIX гасырның 60 нчы елларында барса, Гөләйзага бәйле хәлләр 1837–1850 елларда уза. Ихтимал, Гаяз Исхакый, күрше авылларга бәйле шушы хәлләрне эти-әнисеннән яки Яуширмә (элеккеге Кәләй, Кече Бахта) авылы кешеләреннән (мөселманлыкка кайткан авылдашларыннан) ишетеп үскәндер. Әсәрнең 1907 елда төрмәдә языла башлап 1912 елда тәмамлануын исәпкә алсак, аның Гөләйза вакыйгаларын төрмәдә ишетүе дә ихтимал. <...> Гаяз Исхакый исә, әсәре тәэсирлерәк булсын өчен аның кайбер элементларын көчәйтеп, күпертеп җыелма образ итеп язгандыр, шәт. Һәрхәлдә, Зөләйха образы, шул замандагы Гөләйза тарихына охшашлы хәлләргә нигезләнеп тудырылган (тик архивта мондый эшләр әлегә очраганы юк. – Г.Х.)» [10: 9–10]. Ягъни автор архивларда, Гөләйза тарихыннан кала, Зөләйха образына прототип булырлык документларның очрамавын әйтә.

Бу юлларның авторы, язучы Фәүзия Бәйрәмова да соңгы елларда Гөләйза тарихы белән тирәнтен кызыксына, аның Зөләйха образы белән тәңгәллеген өйрәнә, ул бу хакта матбугатта да чыгышлар ясады. «Әлбәттә, бу ике мөселман-татар хатын-кызы арасында уртак яклар күп булган кебек, аерымлыклар да бар, – дип яза ул. – ...Әйе, язмышлар уртак – иманны бирмәс өчен, үлемгә бару, ахыргача мөселман-татар булып калу өчен көрәшү. Бу газиз милләттәшләребезнең урыннары җәннәттә булсын!» [2: 335]. Хәзер Фәүзия Бәйрәмова «Гөләйза» дип аталган тарихи роман өстендә эшли. Автор Гөләйзаның туган авылы Кыр Шонталасында, Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә булып, тарихи урыннар белән танышты, чукындыру темасына язылган узган гасыр хезмәтләрен һәм архив материалларын өйрәнде. Татар тарихында һәм әдәбиятында Зөләйха һәм Гөләйза образлары, милләтебезнең фаҗигасен һәм бөеклеген сөйләп, янәшә атларлар, ин ша Аллаһ!

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасындагы Зөләйха образының тарихи прототибы булып 1838–1844 елларда Чистай судында хөкем ителгән Гөләйза Уразмәтова торырга мөмкин. Әсәрнең тарихи җирлеге булып Гөләйзаның туган яклары тора, шулай ук аның Зөләйха язмышы белән уртак яклары да күп. Гаяз Исхакый бу әсәре өчен материалны туган төбәгендә халыктан туплаган булырга тиеш. Шул ук вакытта ул чукындыру тарихы турында вакытлы татар матбугатында чыккан материалларны да файдаланган. Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы милли әдәбиятта моңа кадәр язылмаган фаҗигале теманы – XIX гасырда татарларны көчләп чукындырулар темасын, милләтебезнең аңа каршы көрәшен талантлы итеп ачып бирүе һәм тарихта теркәп калдыруы белән кадерле. Шуңа күрә ул үлемсез!


ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәров Гайнетдин: тарихи-документаль җыентык. Казан: Җыен, 2000. 194 б.
2. Бәйрәмова Ф. Милләт тарихы. Казан, 2016. 335 б.
3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 325 б.
4. Исхакый. Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 237 б.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 376 б.
6. Исхакый Г. Тарихи-документаль җыентык. Казан, 2011. 64 б.
7. Исхаков Р. Миссионерство и мусульмане Волго-Камья. Казань, 2011. 215 с.
8. ТР МА. 17 нче фонд, 48 нче тасвирлама, 22 нче эш.
9. Хисамиев Г. Гөләйза кыйссасы. Казан, 2015. 125 б.
10. Хисамиев Г. Кыр Шонталасы тарихы: мәчетләр һәм дин әһелләре. Казан, 2015. 226 б.

# ТАТАР ӘДИПЛӘРЕНЕҢ АКАДЕМИК БАСМАСЫ ӘЗЕРЛӘНГӘНДӘ, ТӨП ТЕКСТНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН САКЛАУ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

***И.Б. Бәширова*** *(Казан)*

В статье поднимается проблема сохранения основного текста, написанного на арабской графике, при подготовке современных академических изданий классиков татарской литературы на кириллице. В связи с трехкратным изменением печатной графики первоначального текста (на арабской, латинице и кириллице) встает вопрос о сохранении оригинальности основного текста. Татарским текстологам необходимо учитывать особенности традиций старотатарского литературного языка, на которых были созданы произведения татарских классиков.
**Ключевые слова:** старотатарский язык, арабская графика, орфография, тюрко-татарская письменная традиция, литературная норма, вариативности норм, кириллица, академическое издание, полное издание и т.п.

The article discusses the problem of preserving the orthographic of the texts written in the Arabic symbols when preparing modern academic publications of Tatar classical literature in Cyrillic. In connection with choosing the symbols used to publish the original text three times – in Arabic, Latin and Cyrillic – the question of preserving the original author text rises. Tatar academics in field of text originality should base their work on centuries of written traditions of Old Tatar literature language.
**Key words:** Arabic symbols, Cyrillic, orthography, literary norm, written tradition, academic publication, full publication etc.

Билгеле булганча, хәзерге рус-европа текстология фәнендә Академик басма төшенчәсенең мәгънәсе төрле яклап аңлатылган: авторның барлык әсәрләре туплана, фәнни-объектив комментарияләре бирелә, төп текстагы график-орфографик тәртип саклана [6: 8]. Бу юнәлештә, әдипнең академик басмасы әзерләнгәндә, ныклы традициягә нигезләнгән, югары дәрәҗәдәге фәнни-теоретик тикшерү бара, көндәлек-гамәли ихтыяҗ истә тотылмый [10: 23]. Өч мәртәбә графикасы алмаштырылу уңаенда, гарәп язуында, латинда һәм кирилл (рус) хәрефләре белән өч мәртәбә яңартып басылган текст орфографиясен, Академик басма югарылыгында аңлату өчен, татар текстологы нинди традициягә нигезләнеп эш итәргә тиеш? Әлеге мәсьәләнең асылына төшенү өчен, һәр том авторының хосусый субъектив фикеренә таянып булмавы, бәлки татар халкының дәверләр, гасырлар буена килә торган катлаулы язмачылык тарихының традициясенә нигезләнеп үсеш алган, иске татар теленә хас булган төп үзенчәлекләренең объектив сәбәпләрен күзалларга һәм хәзерге әдәби телгә ничек итеп күчерергә кирәклекне белергә кирәклек күренә.

Төрки дөньяның классик шагыйрь/әдипләре булып танылачак Г. Тукай (1886–1913), Г. Исхакый (1878–1954), Г. Ибраһимов (1887–1938), Ф. Әмирхан (1886–1926), Ш. Камал (1884–1942) һ.б. иҗат итә башлаган XX гасырның беренче елларында, татар язма әдәби теленең йөз гасырдан артыграк, ягъни мең еллар буена эзлекле рәвештә килә торган язмачылык тарихи – мирасы булуы мәгълүм. Махсус хезмәтләрдән аңлашылганча, язмачылык тарихы, V–VI йөзләрдә угыз-уйгур һәм кыпчак кабилә теле нигезендәге руникада башланып, VII–IX гасырларда согуд-уйгур язуында дәвам ителә. Идел буе Болгар дәүләтендә, 992 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәч, руника гарәп графикасы белән алмаштырыла. XI гасырда үзәге Кашгар булган Караханилар дәүләтендә, Йосыф Баласагунинның абруйлы төркидә «Котадгу Белек» әсәре иҗат ителә (462/1069–1070). Кашгар шәһәрендә тәмамланган «Диване лөгатет-төрек» дигән энциклопедик хезмәтендә (466/1072–1074), Мәхмүд Кашгари төркиләрнең күркәм сыйфатларга ия булуы, сөйләмә телләрендә уртак лекси-

каның күплеге, телләренең матурлыгы, мәгънә һәм форма ягыннан гарәп теле кебек үк бөек булуына ышандыра [11: 23–24]. Шушы вакытлардан башлап, ислам динендәге төркиләрнең, шул исәптән татар халкының, тормыш фәлсәфәсе белән мөселман дөньясының кануннарына нигезләнгән, дәүләти-хокукый, әдәби-мәдәни, сәнгати-эстетик яшәешенең мең елларга сузылачак хәрәкәте башлана. Бу яшәеш, гарәп-фарсы һәм төрки-татар телләрен камил белгән, аларның үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтен яхшы аңлаган, татар халкының бөек шәхесләре иҗатында чагылыш таба. Авторларның тезмә һәм чәчмә әсәрләре, фәнни-тарихи хезмәтләре белән, аларның үз исемләре дә, халкыбызның даны да, тулаем мөселман һәм төрки дөньяда, мәңге онытылмаслык югары күтәрелә, бүгенге көннәрдә дә әһәмиятен югалтмый.

XII йөздә, Идел буе Болгар дәүләтендә, суфи шагыйрь Әхмәд Ясәви (1091–1166): «...Айәт, хәдис мәгънәсе төрки булса муафикъ...» дип, «Котадгу Белек» әсәрендәге абруйлы төркидә мул кулланыла торган гарәп-фарсы алынмаларын киметебрәк, барлык төркиләр өчен җанлы-сөйләмә уртак сүзләрне әдәбиләштереп, халыкчан төркидә «Диване хикмәт»ләрен яза башлый, суфичылык тарикате үсеш ала, алга таба Төркестан (Яса) төбәгендә дәвам ителә [11: 25]. XIII гасырда, Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастанында, бер яктан Караханилар дәүләте язма теленә хас булган абруйлы төркилек (алынмаларның күплеге һәм традицион угызлашу) дәвам иткәне хәлдә, Ә. Ясәви иҗаты белән башланган (төрки-кыпчак-татарларның авыз иҗаты һәм сөйләмә теленә хас булган сүз һәм сүзформаларны әдәбиләштерү) юнәлеше дә үзенчәлекле рәвештә үстерелә. Нәтиҗәдә, Коръани-шәрифтән килә торган мәгълүм сюжет (12 сүрә) Кол Гали иҗатында гына дөнья күләм (ЮНЕСКО) дәрәҗәсендәге танылу югарылыгына ирешә, 800 ел буена эстетик тәэсирен югалтмый укыла, ятлана, тикшерелә: 160 кульязмасы татарлар яшәгән төбәктә табыла. Шул ук вакытларда, төрле ысулда, гарәп графикасы белән каберташларга штамп-текстлар языла (11: 34–36). Әлеге әсәрләрнең телен өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләреннән аңлашылганча, графо-орфографиягә караган язма норма дигән күренешнең берничә катламнан торуы күренә: а) үз графикасында бирелә торган гарәп вә фарсы алынмалары катгый үз чыганак теле кагыйдәсе белән языла, ә) төрки сүзләрен язу өчен җайлаштырылган гарәп графикасында, бер яктан, төрки-угыз кабилә телләренә хас булган сөйләм үзенчәлеге, икенче яктан төрки-кыпчак телләренә хас булган сөйләм үзенчәлегенең чагылыш табуы күзәтелә. Димәк, язма норма, ике әдәби телнең (гарәп һәм төрки) үзенчәлеге нигезендә формалаша һәм бу язылыш, Алтын Урда (XIV г.), Казан ханлыгында (XV г.), Русия (Мәскәү) дәүләтендә (XVI гасыр уртасыннан), классиклар иҗат итә башлаган XX йөзнең беренче чирегенә кадәр, төрле жанр-стильдә язылган, шәрехләнгән, тәрҗемә ителгән әдәби истәлекләрдә, эзлекле рәвештә дәвам ителүе мәгълүм [11: 37 һ.б.]. Шуның белән бергә, аларның төрле чорда төрле дәрәҗәдә барланып, тупланып, өйрәнелеп, укытылып килүе мәгълүм. Иске язулы телләрдәге истәлекләр фәнни тикшерелеп, укытылып килерлек әһәмияткә ия булсалар, алар классик телләр дип атала [1: 196]. Димәк, без классик иске татар теле белән эш итәбез була. Классик әдипләребезнең, мәдрәсәдә укыган һәм укыткан кешеләр буларак, әлеге гасырлар буена килә торган язма мирасның тарихын һәм аның язма традициясен камил үзләштергән, яхшы итеп аңына сеңдергән шәхесләр булуы шик тудырмый. Табигый ки, әлеге гыйлем, аларның әсәрләрендә, шул исәптән текст орфографиясендә,чагылыш тапмыйча кала алмый. Тикшерүләрдән күренгәнчә, бу әдипләрнең иҗаты, гасырлар буена дәвам итеп килә торган төрки-татар теленең бер буынын тәшкил итә. Гарәп графикасы белән язганда: 1)гарәп вә фарсы алынмалары катгый таләп

ителгәнчә, үз чыганак теле кагыйдәсе буенча бирелә, **бу юнәлештә ныклы норма саклана**; 2) төрки-угыз-уйгур, төрки-болгар-кыпчак, төрки-кыпчак-татар дәверләрен узып килә торган иске татар теленең сүзләре иске имляда ныгыган тәртиптә бара, **бу юнәлештә норма вариантлылыгы** күзәтелә [9: 36–134]. «Татар әдәби теле тарихы...» хезмәтен язу барышында, традиция булып килә торган әлеге вариантлылыкны: 1) гарәп-фарсы һәм төрки-татар телләренең үзара мөнәсәбәтенә, 2) гомумтөрки угыз һәм кыпчак кабилә төркеме телләренең әйтелеше/сөйләменең язуда чагылышына, 3) гомумтөрки кыпчак-татар кабилә телләренең аерым төбәк диалекталь/сөйләмә формаларның язуда чиратлашуына нигезләнгән, үзара бәйле өч юнәлештә карарга мөмкин булуы күренде. Иске татар телендәге әдәбиятта урын ала торган вариантлылыкның структур-функциональ табигате билгеләнде. 1. Гарәп-фарсы һәм төрки-татар телләренең үзара мөнәсәбәтенә нигезләнгән юнәлештә традиция булып килә торган графо-орфографик тәртип чагылыш таба дигәндә, сузык һәм тартык аваз/хәрефләрнең ике әдәби тел нигезендә язылышы истә тотыла. Гарәп-фарсы алынмалары үз чыганак теле кагыйдәсенә буйсындырыла, ныклы норма саклана.Төрки-татар сүзләренең сүз башы, беренче иҗек, икенче иҗек, сүз ахыры позицияләрендә, гарәп графемаларын куллану, билгеле бер дәрәҗәдә ныгыган иске имляда күрсәтелә, вариантлылык барлыкка килә. Сузык авазларның язылышына караган бу юнәлештәге вариантлылык, татар теленең 10 сузык авазын күрсәтү өчен, гарәп теленең 3 графемасын ничек итеп яраштырылуына нигезләнә [11: 420–421 һ.б.б.]. Тартык авазларның язылышына караган вариантлылык, татар телендәге /г-гъ/, /к-къ/, /х/ тартыкларын язганда, гарәп теленең – 2, /с/ һәм /т/ авазының – 3, /з/ авазының 4 төрле хәрефе белән белдерелергә мөмкинлегенә нигезләнә, ягъни гарәп теленең калын һәм нечкә әйтелешле тартык аваз/хәрефләрен файдалануда күренә. Әлеге таләп төрле аваз/хәрефне язган вакытта төрлечә реальләшә. Татар телендәге нечкә әйтелешле /г-кәф/, /к-кәф/ һәм каты әйтелешле /гъ-гайн/, къ-каф/авазларын язуда күрсәтү өчен гарәп алфавитында махсус графемалар булуы сәбәбле, сүзләрнең барлык позициясендәге язылышында да катгый эзлеклелектә дәвам ителә, тик /г/-/к/ авазларының рәсеме төрлечә күрсәтелеп, берсе икенчесеннән аерымлана. /з/, /с/, /т/ авазларының язылышы хосусый вазыйфа үти, калын әйтелешле сүзләр каты ظ зый, ص сад һәм ط тый хәрефләре белән бирелә, әмма алар ز зи, س сен, ت ти кебек нечкә вариантлары белән чиратлашырыла. Татар телендәге ирен-ирен /w/ тартыгы гарәп теленең /way-/ графемасы белән бирелә [11: 477, 489–491] һ.б. 2. Гомумтөрки угыз һәм кыпчак кабилә төркеме телләренең әйтелеше/сөйләменең язуда чагылышына нигезләнгән юнәлештә традиция дәвам ителә дигәндә, бер үк төшенчә – сүзнең, угыз төркеме һәм кыпчак төркеме телләренең әйтелеше чагыла торган, ике-өч төрле булып языла алуы истә тотыла. Төрлелек, нигездә, тартык авазларның язылышы белән барлыкка китерелә: аглау – йыглау, агыз – ауыз, агыр – ауыр, анлар – алар, әл – ил, бар – вар, бән – мән, бунда – монда, улса – булса, белә – илә, дулкын – тулкын, таг – тау, тупрак – туфрак, чыкар – чыгар һ.б. 3. Гомумтөрки кыпчак-татар кабилә телләре әйтелешенең язуда чагылышына нигезләнә торган традиция, бер үк төркемдәге телләрнең, яисә бер үк телнең аерым төбәк диалекталь/сөйләмә формаларының язуда чиратлашуына нигезләнеп дәвам ителә: агач – агас, белән – менән, йылау – җылау, чәй – сәй, сач – чәч, су – һыу һ.б. [11: 478].

Классик әдипләр, беренче әсәрләрен яза башлаганда ук, нәзари рәвештә әсәрләренең теле халыкның җанлы сөйләм үзенчәлегенә якын булырга тиешлеген күтәрәләр. Әдәби әсәр теле халыкның сөйләмә теленә якын булырга тиеш дигән фикерне, аерым бер кискенлек белән Г. Исхакый башлап җибәрә. Татар

телендә газета басыла башлагач, мөхәррир Г.Баязитов, газетага языла торган мәкаләне нинди тел белән язарга кирәклекне ачыклау йөзеннән, «Әдәби телебез нә делдер? Нә делдә йазармыз?» дип куелган соравына («Нур», 1905, №4), танылган яшь әдип Г. Исхакый болай дип җавап бирә: «...“борычны” “форыч” дип, “пәрдә”не “фәрдә” дип, “булыр” ны “улыр” дип язу әдәби язу түгел. Әдәби дип мәгънәсен ап-ачык иттереп аңлата торган һәр гыйбарәгә әйтелә. Бер мәкалә әдәби булыр өчен ни хакында язылганлыгы һәр укый белә торган кешегә тәмам аңлашырдай булырга тиеш. Шуның өчен мин “әдәби тел”не үз телемез димен. Үземез сөйли торган телдә язарга тиеш, димен. Һәм язамын. Минем мәсләгемдә язылган китаплар һәрвакыт халык арасында күп таралып, күп укылачак вә халыкка күп файда китерәчәкдер», – дип ассызыклый («Нур», 1905, № 8). Шулай итеп, әдипнең язма әдәби тел дигәндә, «үземез сөйли торган гавам теле»н, газетаның да, китап һәм рисаләләрнең дә фәкать шушы тел белән генә язылырга тиешлеген истә тотуы аңлашыла. Мәгълүм булганча, бу вакытта Г. Исхакый, «Тәгаллемдә сәгадәт...» (1899), «Кәләпүшче кыз» (1900), «Бай угылы» (1903) дигән хикәяләрен, «Өч хатын белән тормыш» (1900), «Ике гыйшык» (1903) кебек драмаларын язып бастырган, А.С. Пушкинның «Капитан кызы»н тәрҗемә кылган (1902), тормышының программасы буларак язылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте дөнья күргән (1904), әдипне мәшһүр итәчәк «Теләнче кызы» романы басылырга хәзерләнгән (1907) була. Димәк, язма-китаби татар теле нинди булырга тиешлеге турында, «Нур» газетасында бәян ителгән билгеләмәне, язма әдәби тел мәсьәләсенә карата да ныклы фикере формалашып җиткән, өметле яшь әдип буларак киң җәмәгатьчелеккә танылып өлгергән шәхеснең тел концепциясе дип кабул итәргә мөмкин булуы аңлашыла.

Автор үзе инанган фикеренә тугърыклы булып, үз төбәгендә кулланыла торган келәү, чикле (кадәр), дөбрән, кагау, өргәү, искәү, тиресләнү(киреләнү), койты кебек сүзләрне, күз чыгарып, баш ярып булса да кебек һ.б.халыкчан-сөйләмә тотрыклы тезмәләрне, бигрәк тә беренче чәчмә һәм драма әсәрләрендә, табигый бер җиңеллек белән файдалана. Әмма шул ук вакытта, авторның үз чоры әдәби теленә хас булган язма китаби традицияләрдән дә баш тарта алмавы күренә. Г. Исхакый үзенең әсәрләрендә, югарыда саналып бирелгән һәр өч вариантлылыкны да иркен файдалана: 1) гарәп-фарсы алынмалары үз графикасы белән үз телләре кануннары буенча языла; 2) гомумтөрки угыз кабилә телләре әйтелешенә нигезләнүе, аерым сүзләрнең башында: ينجو инҗү (энҗе) кебек яшьләр..., сүзнең уртасында: طوقز тукыз бала..., сүзнең ахырында һәм кушымча башланганда: سببدن сәбәбдән, یاشندن йәшемдән, берлә, тугъры, һ.б. чагыла (7: 4) һ.б. Аерым сүзләр кыпчак кабилә телләренең әйтелешендә бирелә торган сүзләр белән чиратлаштырыла: чыкыңыз-чыгыгыз, ... дулкынлы диңгездәге кимә йөрүе (7: 8), ...йәмсез тулкынлары, ...чак йыгъламады (7:12), ...җылаган күзләре(7: 22) һ.б.; 3) төрки-кыпчак-татар кабилә телләренең аерым төбәк диалекталь/ сөйләмә формаларына караган вариант күренешләр, гадәттә, /й/-/ж/ аваз/хәрефләренең чиратлашуында кабатлана:...ун ике یاشینه йәшенә ییتکاچ йиткәч, ...уйнаб جوردم җөрдем, ...кызлар берлә куышыб یورولری йөрүләре, ...җитәрлек инде, ...кайа җибәрәләр (7:4), ...иң биек җиргә (7:14), ...җаучы җибәрде (7:18),..барыб итмәгән,...чит ییرلرده йирләрдә үләр (7:22), Г. Исхакыйның бу тәрҗемә әсәренә кадәр язылган беренче хикәяләрендә, /й/-/җ/ аваз/хәрефләренең чиратлашуы бу дәрәҗәдә күзәтелми [8: 31–75 һ.б.б.].

Шулай итеп, үзем сөйли торган телдә язарга тиешмен дип белдергән авторның әсәрләрендә дә, төрки-угыз, төрки-болгар-кыпчак, төрки-кыпчак-татар дәверләрен узып килә торган иске татар сүзләренең иске имляда ныгыган тәртиптә баруы, бу юнәлештә норма вариантлылыгының күзәтелүе, ягъни

традиция булып килә торган үзенчәлекләрнең саклануы һәм актив файдаланылуы, гарәп һәм фарсы алынмаларының да үз графикасы һәм үз тел кагыйдәсенә туры китерелеп язылуы күренә. Аңлашылганча, классик әдипләребезнең иҗатында, төрле авторда төрле дәрәҗәдә, өч нигездә килә торган вариантлылыкның дәвам ителе мәгълүм була. Иске татар телендә язылган әдәби әсәрләрнең теле, теләсә нинди вариантлылык хата дип санала торган, хәзерге әдәби телдән нәкъ менә шушы яктан аерыла.

Авторларның күп томлыгын басмага әзерләүче текстологлар, гарәп графикасыннан кириллга күчергәндә, әлеге үзенчәлекләрнең кайберләренә, аларның саклану/ сакланмавына игътибар итәләр [5:6]. Ф. Әмирханның 4 томдагы әсәрләре басмага әзерләнгәндә, тел/орфография мәсьәләсе, /й/, /ж/ аваз/ хәрефләренең бирелешенә нигезләнеп аңлатыла, хәзерге әдәби нормада бирелүләре ассызыклана [2: 5]. Ләкин әсәрләрне уку барышында, йир, йиде сүзләре җир, җиде дип бирелсәләр дә [2: 10, 17], барлык сүзләрнең дә хәзерге әдәби нормага кертеп бетерелмәве күренә:...кычкырып егълый башлаячак идем, ...бөтен залда егълашкан булыр иде [2: 14] һ.б. Традицион язылышны тулысынча үзгәртеп бетерергә ярамаганлыгы хакында, башлап танылган текстолог Л. Гайнанова махсус аңлатма бирә: «Г. Исхакый әсәрләренең ...текстларына мөмкин кадәр сак килергә тырышылды. “Җ”ләштерү, “й”ләштерү очраклары төрле текстта, шулай ук төрле сүзләрдә төрлечә очрый. Бер үк текстта йер, йетү, йебәрү сүзләре “й” белән, җыр, җиләк, җиңел сүзләре “ж” белән языла. Алар бер төрлегә әйләндерелмәде, тексттагыча калдырылды. Әсәрләрнең кайберләре “й”ләштерүгә нигезләнгән (мәсәлән, “Ике йөз елдан соң инкыйраз”, кайберләре “ж”ләштереп язылган (мәсәлән, “Зиндан”). Шуңа күрә язылышка барлык тексттларга, бертоташтан түгел, ә һәр текстның үз эчендә игътибар бирелде» [8: 356]. /й/-/ж/ чиратлашуы, авторның ике әсәрендә төрлечә булуын искәртү бик мөһим. Болай дип белдерүе белән, текстолог, әдипнең язу үзенчәлегенә, шул исәптән, текст орфографиясенә сак килергә кирәклекне яхшы итеп аңлавын күрсәтә. Тик монда йер, йетү сүзләренең язылышына карата искәрмә сорала. Бу сүзләр, традицияне саклап, сузыксыз یر й(е)р [11: 602] һәм ییر йир, ییتو йиту, ییبرو йибәрү сүзләрендәге кебек, сөйләмә телгә якынайту максатыннан, сузыклы булып языла алганнар. Классик әдипләр иҗатында сузыклы вариантка өстенлек бирелә: йир, йиту дип языла. Текст эчтәлегеннән күренгәнчә, Г. Исхакый یغلاو йыгълау сүзен эзлекле куллана, йыгълау дип бирергә кирәклек аңлашыла [8: 68 һ.б.б.]. Академик басмалар әзерләнгәндә, /й/ аваз/ хәрефеннән башка, телебездә булган увуляр (кече тел-каты) /къ – гъ/ һәм ирен-ирен /w/ авазларының үз хәрефләрен файдаланырга кирәк булачак. Татар язуы фонетик принципка нигезләнә, бу безнең өчен төп кагыйдә булып санала.

Махсус әдәбияттан аңлашылганча, рус классик әдипләренең Академик басмасы әзерләнгәндә, берничә таләпнең берсе – төп нигез итеп аның автографы алына һәм ул үзгәртелмичә бирелергә тиеш. Автограф булмаган очракта, автор үзе исән вакыттагы беренче басмасын төп текст итеп алырга мөмкинлек бирелә. Классикларыбызнең мондый басмаларының булуы мәгълүм. Әмма татар классикларының Академик басмасын әзерләгәндә, без аларны автор язган графикада бирә алмыйбыз. Графика алыштырылуы һәм хәзерге язма нормага туры китерергә кирәклек белән бәйле яңартулар ясарга кирәк була. Классик әдипләрнең Академик басмасын төзибез дип эшкә тотынганда, а) гарәп теленең үз графикасында, катгый рәвештә үз кагыйдәсе белән языла торган гарәп һәм фарсы алынмаларын, татар теленең әйтелешенә җайлаштырырга тырышып, кириллицада күрсәтергә, ә) угыз һәм кыпчак кабилә телләренең әйтелеш үзенчәлеге сакланып языла торган гомумтөрки сүзләрне, хәзерге татар орфографиясе

таләбенә буйсындырып, вариантлылыгын күрсәтмәскә тиеш булабыз. Авторның автографы булган очракта да, аны үзгәртергә кирәк булганга, таләп ителә торган традиция саклана алмый була. Димәк, бу яктан караганда, татар классикларының Академик басмасын төзү эшен, рус-европа әдипләренең иҗаты мисал итеп алынган гомум үрнәк-тәртипкә нигезләп булмавы аңлашыла.

Рус теле үрнәгенә ярашырга мөмкин булмау мәсьәләсенә, «Татар теленең тулы сүзлеге»н төзү барышында, Җ. Вәлиди игътибар итә. Г. Тукай һәм башка язучыларның иҗатында кулланылган барлык сүзләрнең дә «...һәммәсен татар сүзлегенә кертә башласак, бу сүзлекнең эченә гарәп һәм фарсы телләрендәге бөтен сүзләр кереп бетмәсә дә, бик азы гына кермичә калыр иде. Монда рус классиклары белән чагыштыру урынлы түгел. ...Анда йөз елның бу ягында булган үзгәреш, безнең телдәге соңгы 10 ел эчендә булган үзгәреше кадәр дә юк. ...Әмма без рус классикларында мондый хәлне күрмибез, рус теленә яки башка шуның шикелле телләргә чагыштырып эш итәргә туры килми...» [4: 214]. Татар теленә мөнәсәбәтле мәсьәләләрнең, рус теленә яки башка шуның шикелле телләргә чагыштырып эш итәргә туры килми дигән фикернең объективлыгы шик тудырмаслык дәлилләнүе аңлашыла. Шулай булуга карамастан, татар әдипләренең Академик басмасы әзерләнгәндә, рус-европа телләренә куелган таләп теоретик нигез итеп алына. Г. Ибраһимов сайланма әсәрләре сигез томлыгының гыйльми-академик басма булмавының сәбәбен, әсәрләренең 8 нче томын төзүчеләрнең берсе, фәнни редакторы булган, танылган тел галиме Ф. Фәсиев болай аңлата: «...Бу басма бер үк дәрәҗәдә фән-гыйлем әһелләренә дә, киң катлау укучыларга да җиңел аңлаешлы булырга тиеш, ягъни ул массовый-популяр басмалар төренә керә. Бу- әдип һәм галимнең мирасын теләгән һәрбер укучы һәм студент, һәрбер укытучы һәм гыйльми хезмәткәр үзләштерерлек графикага күчерү дигән сүз; алар алдындагы язу һәм тел киртәләрен һ.б. алып ташлау дигән сүз. Шул нигездә аның текстология һәм транскрипция принциплары төзелде; шулар нигезендә томнар әзерләнеп, нәшер ителеп килә. ...Әгәр дә бу публикация саф фәнни-академик булса, бу үзенчәлекләрне текстларда тулысынча сакларга мөмкин булыр иде...» [6: 8]. Г. Ибраһимовның 15 томдагы әсәрләрен дә шундый ук текстология һәм транскрипция принципларына нигезләп төзергә тиеш булабыз, ягъни русларда кабул ителгән кагыйдәгә туры килмәве, димәк, Академик басма таләпләренә җавап бирә алмавы аңлашыла.

Әмма ләкин, рус-европа текстология фәненә туры килми дип, тулаем төрки дөньяда классик булып танылган әдипләребезнең Академик дип атала торган басмасын төзүдән һич тә баш тартырга тиеш түгелбез. V–VII гасырлардан язмачылыгы башланып, Болгар төркисендә язма нормасы формалашкан һәм мең еллар буена эзлекле рәвештә дәвам итеп килә торган язма традициянең бер буынын тәшкил итүче классикларыбызның иҗатын Академик басма итеп дөньяга күрсәтергә безнең тулы хокукыбыз бар. Бу юнәлештә, татар теле кебек үк, иске язулы (старописьменные языки) телгә ия булган, әзәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк халыклары белән уртак нигездә [12: 358], хәзерге графика һәм әдәби телебезнең мөмкинлегенә туры китереп, Академик төшенчәсенең мәгънәсенә объектив-фәнни аңлатма биреп, катгый ассызыкларга тиеш булабыз. Аңлашылганча, гарәп графикасына кире кайта алмыйбыз. Латинда язучы төрек һәм азәрбайҗаннар кебек, латинга күчкән булсак, эшебез бермәбер җиңеләер иде. Чит илдә яшәүче татарлар да, латинда укуы җайлы булыр иде дип белдерәләр. Әмма Россия дәүләтендәге халыклар бердәм графика белән файдаланырга тиеш дигән махсус карар игълан ителгән. Димәк, татар классикларының Академик басмаларын да кириллицада әзерләргә кирәк була. Текстның кириллицада язылуы аны киң катлау укучыларга да җиңел аңлаешлы

итә дигән фикернең чынбарлыкка туры килмәвенә басым ясарга кирәк булачак. Әдипләрбезнең әсәрләрендә чагылыш таба торган сәнгатьчә сөйләм байлыгын мөмкин дәрәҗәдә саклап, укучыга тәкъдим итәргә кирәк дигән максатны күтәрү зарурлыгы күренә.

Бу юнәлештә, чыганак теле кагыйдәсе белән үз графикасында языла торган гарәп-фарсы алынмаларының табигый халендә саклана алмавы аңлашыла. Димәк, әдипләрбезнең әсәрләрендә чагылыш таба торган сәнгатьчә сөйләм байлыгын сакларга тиешбез дигәндә, асылда, иске татар теленең статусын билгели торган төрки-угыз һәм төрки-кыпчак кабилә телләренә хас булган әйтелешнең язудагы вариантлылыгын мөмкин дәрәҗәдә тулырак итеп кириллицада күрсәтергә кирәк булачак. Гамәли язуда ныгыган нормага туры килми торган вариантлылыкны саклау өчен, әдипләрбезнең сайланма әсәрләрен Академик басма дип игълан итү зарурлыгы күренә. Академик басмаларга куела торган таләп буенча, классикларның үзләре исән вакытта дөнья күргән беренче әсәрләренең үзенчәлекләрен саклыйбыз була. Классик әдипләрнең әсәрләрендә, гарәп графикасы белән бирелә торган төрки-угыз һәм төрки-кыпчак кабилә телләренә хас булган әйтелешне, кирилл хәрефенә күчерергә кирәк була. Бу гамәлнең мөмкин булган дәрәҗәдә тулырак булып язуда күрсәтелүе, беренчедән, татар әдәби теленең үз вакытындагы байлыгы сакланышын, икенчедән, һәр әдипнең, текст орфографиясендә чагылыш таба торган, иҗат итү, ягъни сүз белән сурәт ясау үзенчәлеген күрергә нигез булачак. Мәгърифәтчеләрдән аермалы буларак, классик әдипләр, әсәрләрендә бара торган вакыйга-хәлләрне сөйләп түгел, укучының күзалдына бастырырлык итеп, тасвирлап бирү юнәлешен башлап җибәрәләр, язма телнең барлык мөмкинлегеннән файдаланырга тырышалар [3: 52–92].

ӘДӘБИЯТ

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1969. 606 с.

2. Әмирхан Ф.Әсәрләр: дүрт томда. 1 т. Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

3. Бәширова И.Б. Сәнгать чәчмә әсәрләр теле. Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 97 б.

4. Вәлиди Җ. Сайланма хезмәтләр:әдәби тел, грамматика, диалектология һәм лексикология мәсьәләләре. Казан: Мәгариф, 2007. 271 б.

5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. 1 т. Хикәяләр (1907–1929). Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 509 б.

6. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. 8 т. Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 431 б.

7. Исхакый Г. Капитан кызы: мөхәррире Пушкин, мөтәрҗиме Мөхәммәд Гаяз әл-Исхаки. Казань: Лито-типография И.Н. Харитонова, 1902. 57 б.

8. Исхакый Г. Әсәрләр. Унбиш томда. 1 т. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 397 б.

9. Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 139 б.

10. Ожегов С.И. Словарь русского языка. М., 1978. 846 с.

11. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 1 т. Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘһСИ, 2015. 696 б.

12. Языки мира: Тюркские языки. Бишкек: Кыргызстан, 1997. 543 с.

## СРАВНЕНИЯ В РАССКАЗЕ Г. ИСХАКИ «ТАТАР ГАКЫЛЫ»

***Р.М. Болгарова, Э.А. Исламова*** *(Казань)*

В данной статье осуществляется исследование произведения «Татар гакылы» выдающегося татарского писателя, публициста, деятеля татарского национального движения Г. Исхаки. Наиболее продуктивной формой являются сравнения, образованные при помощи послелогов, в особенности *кеби*. Вторым по частотности видом сравнений выступают конструкции с послелогом *төсле*. При сравнении происходит сопо-

ставление описываемых лиц, характеров, событий с образами, которые в большинстве случаев хорошо знакомы человеку. При этом сравнение уточняет, разъясняет понятие о предмете, по-иному освещает предмет, создает особое настроение, вызывает новые мысли и чувства.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, сравнение, образ, эталон сравнения.

In this work is the study of the work «Tatar hackily» prominent Tatar writer, journalist, leader of the Tatar national movement G. Ishaki. The most productive form are comparison formed with postpositions, especially ceby. The second most frequent kind of comparisons are constructions with the postposition tosle. In comparison, there is a comparison of the described persons, characters, events with images that in most cases are familiar to the person. The comparison clarifies, clarifies the concept of the subject, differently illuminates the subject, creates a special mood, causes new thoughts and feelings.
**Key words:** G. Ishaki, comparison, image, the standard of comparison.

Сравнение – это языковое явление, имеющее особую форму, специализированное значение и являющееся одним из древних видов интеллектуальной деятельности. Сравнения играют огромную роль в познании и восприятии действительности. Способность сравнивать органически входит в процесс человеческого сознания и находит отражение в языке. Сравнение является одним из таких широко и часто используемых приемов в художественной речи, как раскрытие и выражение образа [2].

Образность – это компонент коннотации, выражающий при помощи внутренней формы целостное, наглядное представление носителей языка о некотором реальном явлении, предмете или свойстве, закрепленное за единицами языка.

Образность компаративных конструкций основана на их внутренней форме, которой мотивируется общая целостность их семантики. При этом мотивация содержит в себе сравнение как отправную точку мыслительного процесса, поэтому основой образности является сравнение реалий внеязыковой действительности, которые становятся эталоном идеального качества или состояния и т.д. Следовательно, основу образности сравнительных конструкций почти всегда составляет сравнение явлений окружающей действительности, которые становятся эталоном или антиэталоном. Мотивация образной основы сравнительных конструкций происходит благодаря выявлению их внутренней формы [1].

Объектом нашего исследования избрано творчество выдающегося татарского писателя, публициста, деятеля татарского национального движения Г. Исхаки. Язык произведений этого писателя представляет нам его как глубокого знатока жизни и быта, языковых особенностей своего народа. Путем тщательного отбора и умелой подачи художественных средств писатель отражает самобытность татарского народа, его обычаи и традиции.

Благодаря умелому употреблению сравнительных конструкций писатель достигает особой образности, выделяет наиболее яркие и существенные признаки предметов иявлений, что полнее и глубже раскрывает их сущность. Автор сравнивает различные предметы и вещи, качества и свойства, действия, процессы и состояния.

Анализ произведения Г. Исхаки «Татар гакылы» позволил сделать вывод, что наиболее продуктивными являются сравнения, образованные при помощи сравнительно-уподобительных послелогов, в особенности *кеби*. Вторым по частотности видом сравнений являются конструкции с послелогом *төсле*.

Рассмотрим примеры, в которых образом сравнения являются люди, которые хорошо знакомы персонажам. При сравнении происходит сопоставление описываемых лиц, характеров, событий с образами. При этом сравнение

не просто уточняет, разъясняет понятие о предмете, но и вносит нечто новое, по-иному освещает предмет, создает особое настроение, вызывает новые мысли и чувства.

*Үзе кеби гакыллы, үзе кеби акчаның кадерене белә торган бер байның кызыны алып биреп, аны эшкә дә кушты* [3];

*Ул, тән җәһәтеннән генә түгел, күңеленнән дә кыз булды: аның күңеле дә, башка кызларның күңеле кеби, егетләрне уйларга тотынды; аның йөрәге дә, башка кызларныкы кеби, матур, таза-нык егет күргәндә леп-леп сикерә башлады; аның бәгыре дә әллә нинди бер матур егетне сөясе килә башлады; аның колагы шул томанлы матур егеттән: «Хәдичә, мин сине сөям!» – дигән сүзне ишетәсе, аның күзе шул матур егетнең Хәдичәне йотарга теләгән кеби күзе берлә сөзә торган тулы йөзене, яңа гына чыгып килә торган кара мыегыны күрәсе килде; аның шул нык, тулы куллары шул егетне кочасы килде; аның үзе аңар: «Бәгырем, җаным!» – дип, аның битенең уртасыннан үбәсе килде* [3];

*«Хәдичә туташ, мин сине сөям!» – дип, аның алдында әллә нинди тагы томанлырак бер Казан егете, әнә Маһирә җиңгиләренең Казан кияүләре кеби, ләкин аннан тазарак, аннан матуррак Казан егете килеп басты* [3].

Большую группу составляют сравнения, где основанием сравнения являются домашние животные. Автор часто обращается к данным эталонам, так как они помогают раскрыть образы персонажей, их характеры, особенности их поведения.

*Аның шул авырут өсле йөзе, аның шул, һәммә сүзне әйткәндә, бозаулый торган сыер күзенә охшый торган күзе Хәдичәгә чиркәнеч кеби тоелды* [3];

*Ләкин аның һәр хәрәкәтеме тикшереп, ул якын килә башлагач та сугышырга хәзерләнгән әтәч кеби хәзерләнә торган Хәдичәнең шул куркынычлы күзләре астында тагы изелде, тагы эреде; тагы хуҗаларга догалар укып, киләчәк өчен планнар корды* [3];

*Мәхдүм хәзрәт берлә абыстайның төпчек балалары булганга, оя төбе чебеш кеби, 15 яшендә әле һаман канатларны җәеп җиткереп, малай булып җитә алмавы да аның күңелене суытмады* [3].

Следующая группа состоит из сравнений, где в качестве эталона выступают различные предметы быта. Например:

*Хәдичә төрле ярыклардан мәҗлескә җыелган кешеләрне карады. Кайсыларының зур авызларыннан, кайсыларының артык зур борыннарыннан, кайсыларының озаеп, зонтик кеби күз өстенә чыгып тора торган кашыннан көлде* [3];

*Аның янындагы мәхдүмнең борчак чүмәләсе кеби чалмасыны гына карады да, чалма иясенә илтифат та итмәенчә; күзене башкаларга күчерде* [3].

Автор часто повторяет одни и те же сравнения, при этом усиливается образность и выразительность, раскрываются характеры персонажей. Для отца Хадичи сравнение юноши со стариком имеет положительную коннотацию, поэтому автор повторяет это несколько раз. Например:

*Галим абзыйга мәхдүм бик килеште. Ул мәхдүмнең шул башыны бөгеп утыруында да, шул аз сүзлелегендә дә, шул картлар кеби вәкарендә дә Хәдичә өчен бәхет казаны тапты* [3];

*Аның яшьтән үк картлар кеби башыны бөгеп утыруы, бервакыт та урамда кычкырышып, йөгерешеп малайлар берлә уйнамавы, алар берлә сугышмавы, аларны кыйнамавы, үзенең кыйналмавы Галим абзыйның бөтен ихласыны аңар беркетте* [3].

Но девушка воспринимает эти же черты как отрицательные – и голос, и поведение героя.

*Бераздан шул мәхдүмнең йөзенә әллә нинди, теш сызлаган кешенең кыяфәтене биреп, эченнән бик мәшәкать берлә тавышымы өстерәп чыгара торган кеби көчләнеп, сүзләрне сөзүене аерды* [3];

*Ләкин, аш ашаганда кинәттән икмәк катысы сызлаган тешкә тигән кеби, тегенең тавышы Хәдичәнең әллә нинди бик нечкә бер җиренә барып тиде* [3].

Г. Исхаки использует в своем произведении сложные сравнительные конструкции, когда одно явление или действие сравнивается с другим явлением или действием, тем самым подчеркивается сила чувств и переживаний героини. Например:

*Ул, тын алырга һавасы зөйдән качкан кеше кеби, атылып икенче өйгә чыгып китте* [3];

*Ул, үлемгә хөкем ителгән кеше кеби, кодачаларның каравылы астында кияү өенә чыкты* [3];

*Алар утырткан җиргә утырды; башында бер уй да юк төсле иттереп, өйнең бер почмагына күзене текте* [3];

*Ул, мәхдүм йөдәтә башлауны сизгәч тә, бик кадерле нәрсәсене саклаган кеби, бөтен куллары, аяклары берлә җыерылып утырды* [3];

*Галимнең йөрәгенә ук кадалган кеби, әллә кай җире әрни башлады* [3].

Также имеются единичные сравнения, где эталоном сравнения являются мифические существа и литературные герои. Например:

*Икесене Йосыф–Зөләйха кеби иттереп яшәтер өчен сөйдерергә кереште; ләкин бер мәгънә дә чыкмады: Хәдичә һаман ачылмады* [3];

*Ишек ачылып, ак бүрек, җилән кигән өрәк төсле мәхдүм килеп кергәч тә, ул кыймылдамады да* [3].

Таким образом, сравнение как средство художественной изобразительности достаточно широко используется в произведениях Г. Исхаки. Цель сравнения в художественном произведении – помочь читателю нагляднее представить описываемые предметы, явления, события, эмоции и вызвать к ним определенные чувства. Использование сравнительных конструкций представляется важным средством достижения образности, выразительности и точности речи персонажа.

ЛИТЕРАТУРА

1. Болгарова Р.М., Сафонова С.С. Сравнения в русском и татарском языках: опыт концептуально-семантического анализа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2016. № 9. Ч. 1. С. 65–67.

2. Замалетдинов Р.Р., Болгарова Р.М., Исламова Э.А. Специфика перевода сравнительных конструкций в художественных произведениях // Филология и культура. 2014. № 4(38). С. 91–94.

3. Татарская электронная библиотека: Гаяз Исхакый ttp://kitap.net.ru/ishaki1.php (Дата обращения: 20.03.2018).

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ МОРФОЛОГИК ҺӘМ БАШКА ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***М.Р. Булатова*** *(Казан)*

Гаяз Исхаки – один из выдающихся татарских писателей XX века. Он творил свои произведения в сложный период формирования татарского литературного языка – конец XIX – начала XX вв. являлся переходным этапом от старотатарского тюрки к новотатарскому национальному литературному языку, где тесно переплелись веками продолжающиеся письменно-традиционные нормы классического старотатарского языка и общеразговорные формы татарского народа. Как носитель чистопольского говора, произведениям Г. Исхаки характерно также употребление диалектизмов своего родного

края. В работе дана краткая лингвистическая характеристика произведениям писателя в сравнении с татарским литературным языком.
**Ключевые слова:** татарский литературный язык, старотатарский язык, Гаяз Исхаки, языковые особенности, морфология, мишарский диалект, чистопольский говор, диалектизмы.

Gayaz Ishaky is one of the outstanding Tatar writers of the XX century. He wrote his works in a difficult period of the formation of the Tatar literary language – the end of the XIX – early XX centuries was a transition phase from the Old Tatar Turki to the New Tatar national literary language, where for centuries the continuing written and traditional norms of the classical Old Tatar language and the general speaking forms of the Tatar people were closely intertwined. As the bearer of the Chistopol subdialect, his works are also characterized by the use of dialectisms of his native land. The work gives a brief linguistic description of the writer's works in comparison with the Tatar literary language.
**Key words:** Tatar literary language, Old Tatar language, Gayaz Iskhaky, linguistic features, morphology, Mishar dialect, chistopol subdialect, dialect words.

XX гасырда иҗат иткән һәм үзеннән соң гаять бай рухи мирас калдырган бөек милләтче, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулды. Г. Исхакыйның күпкырлы иҗаты бүгенге көндә дә зур кызыксыну уята, аның иҗаты барлана, төрле яклап өйрәнү дәвам итела.

Белүебезчә, XX гасыр башында иске татар язма әдәби тел нормаларыннан әкренләп арыну, хәзерге татар язма әдәби телен формалаштыру процессы бара. Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатында да иске татар язма әдәби теленә хас күренешләр актив кулланыла. Әлеге мәкаләдә «Өйгә таба», «Көз», «Олуг Мөхәммәд», «Татар кызы», «Тәүбәгә килгән хатын», «Дулкын эчендә», «Җан Баевич» һ.б. әсәрләрендә күзәтелгән морфология өлкәсенә караган һәм башка тел үзенчәлекләренә тукталып узабыз. Язучының туган төбәгенә (язучы туып үскәнЯуширмә авылы татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты чистай сөйләшенә карый) генә хас булган сөйләм берәмлекләренә дә игътибар ителәчәк.

Фонетик күренешләр. Г. Исхакый иҗатында иске татар язма әдәби теле белән уртак күренешләрдән: тәңгәллекләр – ***ңл~лг:*** *яңлыш* [6:45, 96, 304] – ялгыш, *яңлышлык* [6: 487] – ялгышлык; борынгы ***г*** авазының саклануы: *гакыл* [6: 113] – акыл, *тугры* [6: 109] – туры, *тугрысына* [6: 103] – турысына, *олуг* [6: 497] – олы (*олуг* сүзе әле дә кулланыла), *олуглык* [6: 104] – олылык, *угыл* [6: 21], *угылым* [6: 304] – улым, *еглавы* – елавы [6: 81], *тугрыдан-туры* [6: 55] – турыдан-туры, *еглама* [6: 304] – елама, *еглау* [6: 20], *үгрәнә* [6: 92] – өйрәнә һ.б.

Сирәк булса да мондый тәңгәллекләр очрый: ***т~ч:*** *тишелү* [6: 80] – чишелү, *тишендергән* [6: 80] – чишендергән, ***р~л:*** *шурпа* [6: 29] – шулпа, ***ә~и:*** *чәшмә* [6: 306] – чишмә, ***ы~а:*** *яңы* [6: 136] – яңа, ***э~ө:*** *эстәми* [6: 501] – өстәми. Метатеза: *бүрке* [6: 330] – бурек, *ягъмур* [6: 43, 88] – йамгыр (графич. яңгыр).

Мишәр сөйләшләренең төп үзенчәлекләреннән берсе булган ***й***-лаштыру күренеше хас, иске татар теленең китаби теле традициясе итеп каралган *й*-лаштыру Г. Исхакый әсәрләрендә еш очрый: *йиде* [6: 133], *йир* [6: 20, 305], *йыр* [6: 30], *йырлады* [6: 30], *йип* [6: 69], *йылы* [6: 103, 133], *йирлек* [6: 84], *йимеш* [6: 457], *йиттек* [6: 94] һ.б.

Урта диалект вәкилләре белән аралашу йогынтысы буларакмы язучы әсәрләрендә ***җ***-лаштыру күренеше дә игътибарны җәлеп итә: *җуатасым килде* [6: 94, 102], *җаучы* [6: 109], *җәмә* [6: 332] – яме, *җә* [6: 332] – йә, *марҗа* [6: 123] һ.б.

Г. Исхакый көнбатыш диалектка хас *й*-лаштыруны урта диалекттагыча *җ*-лаштыру белән иркен аралаштыра. Мәсәлән, *җеп* [6: 123], *йип* [6: 69].

Гомумән, XIX гасыр һәм XX гасыр башында иҗат иткән язучыларның әсәрләрендә сүз башы позициясендә *й*-лаштыруһәм *җ*-лаштыру параллель кулланылган. Бу факт әлеге күренешнең ул чорда нормалашып өлгермәгәнлегенә ишарә ясый. Мәсәлән, бөек язучыбыз Габдулла Тукайның «Бала оҗмахта» шигырендә бер үк сүз ике вариантта да, ягъни берсендә [*җ*], икенче юлдагы шул ук сүздә [*е(й)*] белән языла:

<...> *Мин җуанмыймын,* ***җылыймын****, син түгелсең, дим, әни!*

<...> ***Егълыймын****, алмыйм аларны, сез түгелсез, дим, әти!* [4: 233].

Морфологик үзенчәлекләр. Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек саны ике (тулы һәм кыскартылган) вариантта да кулланыла: *Почтага өлгертер өчен шушы хатны сызгал****ыйм*** [6: 176]. *Мин Төркиянең милли иминлеген боздырмас өчен тырыш****амын*** [6: 176]. *...бер эшчемне җибәр****әм****, телеграмманы ул тапшырыр* [6: 176]. *... дүрт тарафка йөгер****әмен*** [6: 176]. *Вакытлы гына кил****әмен*** [6: 139].

Исем, фигыль һ.б. сүз төркемнәренең I һәм II зат кушымчалары да язучы әсәрләрендә иске татар әдәби телендәгечә (*-мыз/-мез; -ңыз/-ңез).* Мәсәлән, ***-мыз/-мез:*** *Шатлана****мыз*** (әд. шатлана**быз**). *Шуның өчен һәрнәрсәне үз милли теләге****мез****, үз шәригате****мез*** *буенча эшли****мез*** [6: 323]. *Бөтен халкы****мыз****, бөтен зыялы****мыз*** *урыс өмәсенә йөри* [6: 32]. *...кичәдә без дә уйный****мыз*** [6: 33]. *Безнең еллык адвокаты****мыз*** *бар, алыр****мыз****!* [6: 368]. ***-ңыз/-ңез:*** *Үзе****ңез*** (әд. үзегез), *эзе****ңез*** (эзегез) [6: 309]. *Күсәк кебек башы****ңыз*** *белә хатыннар талап йөрергә оялы****ңыз****!* [6: 318]. *Биш минут вакыты****ңыз****ны әрәм итмә****ңез****!* [6: 319]. *...фикере****ңез****не сөйләп, тәрҗемә иттереп җибәре****ңез*** *әле* [6: 25]. *Мине күргәне****ңез*** *бар идеме, генерал?* [6: 26].

Хәзерге татар телендә кулланылышын саклаган *-мыйча/-мичә* (хәзерге заман хәл фигыль юклык формасы) Г. Исхакый әсәрләрендә ***-маенча/-мәенчә*** формасында даими кулланыла: *Алмания тукта****маенча*** (туктамыйча) *яңа корал күндерә* [6: 24]. *Кая барырга бел****мәенчә****, йөдәп калды* [6: 24]. *Аның бер сүз дәш****мәенчә*** *торуына кара****маенча****, ...сөальләр бирергә кереште* [6: 26]. *Ул сиз****мәенчә*** *дә шул гаиләнең әгъзасы кебек булып китте* [6: 29].

Иске татар әдәби телгә хас *-маенча/-мәенчә* формасы борынгы *-майын/ -мәйен* формасына + *-ча/-чә* рәвеш кушымчасы өстәлеп барлыкка килгән дип фаразлана. Мәсәлән, XVII йөз шагыйре М. Колтый текстларында *-маен/ -мәен* системалы төс ала: *Сән, гүзәл яр, аерылмаен торгыл мәндин* [5: 254]. Монда *аерылмаен* – ‘аерылмыйча’ дигән төшенчәне бирә.

Чагыштыр: *-маенча/-мәенчә* формасы *-маенса/-мәенсә* варианты белән урта диалектның кормантау сөйләшенә дә хас: *Машина туктамаенча китеп барды. Бидрәнең суын түкмәенсә ташый иде* [3: 149]. Кормантау сөйләшенә караган, Җилем-Каран авылында туган, шулай ук XX йөз башы халык язучысы Мәҗит Гафури иҗатында да күрәбез: *Монда шигырь язмаенча булмый чыдап, / Ачылды язар өчен безләргә баб* («Бай кеше») [3: 150].

Гомумән, әлеге форма бераз фонетик үзгәрешләр белән көнбатыш диалектының кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, Пенза, Ульяновск мишәрләрендә) (*-мыйынча/-мийенчә*), Башкортостанның учалы, тепекәй (*-майынса/-мәйенсә)*, стәрлетамак, бәләбәй (*-мыйынчы/-мийенче*), бәләбәй, турбаслы (*-майынчы/ -мәйенче*) сөйләшләрендә дә бик киң таралган күренеш [2: 140].

Язучы әсәрләрендә *-макчы* формасының, ният модальлеген белдерә торган башка формаларга караганда, бигрәк тәэшне үтәү турында карар кабул итү мәгънәсен белдерә торган ***-макчы бул-*** формасының категорик үткән заманы ешрак кулланылуы күзгә чалына: *Ләкин генерал һаман полковникны* ***тотмакчы****, аның берлә ачылып* ***китмәкче булды*** [6: 27]. *... кемнәр эшләгәнне*

***белмәкче булды*** [6: 34]. *Николай Николавичка мәсьәләне **аңлатмакчы булды*** [6: 37]. *...бик күп гафу **үтенмәкче булдым*** [6: 101]. *Эшне алай-болай **үткәрмәкче булды*** [6: 70].

***Бу*** алмашлыгы хәзерге татар әдәби телендә кыек килешләрдә килгәндә һәм төрле грамматик формалар ясалганда ***м*** авазына башланып языла. Иске татар язма әдәби телендә исә ул барлык очракларда да ***б*** авазына башлана. Г. Исхакый әсәрләрендә дә: *Полковник **бунда, буның** гаскәренең, атларының солысы таланганын ... аңлап, кемнәр эшләгәнне белмәкче булды* [6: 34]. ***Бундагы*** *халык бит, беләсең!* [6: 24]. *Әлбәттә, **бундагы** биш-алты йөз еллык мәсьәләләр бер кылыч кисүе берлә хәл ителми* [6: 45]. *... сүз кайтару **буңа** авыр тоелыр дип, рәхмәт әйтеп алдым* [6: 94].

Г. Исхакый әсәрләрендә *бу, ул* алмашлыклары юнәлеш килешендә, көнбатыш диалектының башка сөйләшләрендәге кебек (***-нарга***), икеләтелгән кушымчалар ярдәмендә ясалган. Әмма урта диалект сөйләшләрендәге кебек, ***ң***-варианты кулланылган: *Мин үзем сизми дә **моңарга*** (әд. моңа) *үземнең хәлемне аңлата башладым* [6: 94]. ***Аңарга*** (аңа) *татарчалап әлләниләр сөйләде* [6: 135].

Билгеле булганча, *-гар/-гәр* кушымчасы борынгы күренеш булып санала, ул татар теленең урта диалектында, аеруча Дөбьяз, Әтнә төбәкләрендә, керәшен, бәрәңге (Мари Эл), бастан, нурлат сөйләшләрендә таралган.

Язучы иҗатында чистай сөйләше өчен характерлы булган ***моңганча, аңынча*** рәвешләренең активлыгын күрсәтеп үтми мөмкин түгел: *Берничә көн эчендә **моңганча*** (әд. моңа кадәр) *алайда булмаган бер яңалык керттеләр, күтәрмә кубардылар* [6: 76]. ***Аңынча*** (ада кадәр) *карт хәзрәткә барып мәсьәләне аңлатып, аны җаучы итеп җибәрүнең кирәклеген белгерттем* [6: 108].

*Белән* бәйлеге дә иске татар язма әдәби телендәгечә – ***берлә***: *Үзе **берлә** һичбер төрле мөнәсәбәт ясап булмый* [6: 38]. *Гөлсем **берлә** кара-каршы килде* [6: 134].

Күләм, үлчәм, сан ягыннан чагыштыру өчен әдәби *чаклы* бәйлеге белән бер рәттән ***чикле*** диалекталь формасы да хас: *Ул **чикле** алтынны урыс иленнән ун елда да җыеп ала алмамыз* [6: 517]. *Соңгы көймә китәр вакыт җиткәнгә **чаклы** мәҗлес дәвам итә* [6: 232].

*Чикле* бәйлеге урта диалектның тау ягы, каргалы, түбән Кама керәшеннәре, лаеш, пермь, богрыслан, минзәлә, бөре, турбаслы, көнбатыш (мишәр) диалектның чистай, стәрлетамак сөйләшләрендә таралган [2: 168].

***-мы/-ме*** сорау кушымчасы татар телендә, гадәттә, сүзнең азагында килә, ә Г. Исхакый әсәрләрендә бу кисәкчәнең зат кушымчалары алдыннан килүе дә очрый: *Менә гәзитә, күрә**мсез*** (әд. күрәсезме), *гаскәри бер цензур астында чыга* [6: 25]. *Шуны иртәгә сәгать алтыда тәмамән өлгертеп бирә ала**мсың*** (аласыңмы), *әби?* [6: 106]. *Сау-сәламәт**месез**?* [6: 477]. *Сез, полковник, бара**мсыз**? – диде* [6: 33].

Гомумән, сорау кисәкчәсенең мондый тәртиптә куелуы иске татар язма әдәбияты әсәрләренә хас: *Әйди: и мәрд, балыкың сатмай**мысән**, / Балык биреп, бу җепне алгай**мысән**?* (Мөхәммәдъяр. «Төхфәи Мәрдән») [1: 396]. Бу күренеш татар теленең диалектларында да табыла, халык сөйләшләренең борынгы татар язма әдәби теле белән зур уртаклыгы булуын раслый торган мөһим факт булып санала.

Г. Исхакый әсәрләрендә үзенең җирлегенә генә (чистай сөйләшенә) хас булгантуганлык, гореф-гадәт, көнкүреш һ.б. атамаларны белдергән лексик берәмлекләр дә урын алган: *айбагар* – көнбагыш, *мивә* – җимеш, *алаша* – ат, *аран* – абзар, *йорт* ‘двор’ – лит. өй ‘дом’, *тәрилкә* (< рус. тарелка) – әд. тә-

линкә; *һәмширә* – апа, сеңел, туташ; *абызтай, тутакай, атай* (туганлык атамалары); *багу* – карау [6] h.б.

*Бүсә* – үбешү, туганлык күрсәтү: *Аларның шул озын, ерак йирдән килүләрен котларга, аларның рус боендырыгы астында үткәргән шул озын газаплы көннәрен сорарга һәмширәләре, кардәшләре килмәде, аларга аналык, апалык, туганлык бүсәсен беркем дә бирмәде* [6: 86].

*Как-төш* – чәкчәк: *Аның артыннан тау кадәр катырган, как берлә как-төшне икенче өстәллгә куялар* [6: 479].

*Кәнди* – кечкенә аш савыты: *Сугыш мәйданында арып, әлсерәп калган батырларымызга берәр кәнди кайнар шурпа, кайнар сөт эчерермез дип уйладык, рөхсәт бармы?* [6: 453].

*Күрәндә* – камыштан ясалган каты җәймә: *Өйләреннән күрәндәләр күтәреп капкага якынлашалар* [6: 453].

*Төнә* – кич, *төнәге* – кичәге: *Син әйткән олуг сыйфат миндә дә юк, төнә кечкенә, бүген зур, иртәгесе мәхһүл* [6: 473]. *Ләкин шуны онытмагыз, безнең бүген дошманнан куркуымыз юк, алар бүген төнәге безем хәлемездә* [6: 457].

*Тыну* – хәл җыю: *Өйгә кайткач тынып китәсең* [6: 477] h.б.

Гомумән, язучының туган як колоритын яктырткан диалекталь сүзләрнең күпчелеге гади тормыш-көнкүрешкә карый.

Йомгаклап әйткәндә, мәшһүр әдибебез Гаяз Исхакый язма әдәби телне дә, җирле сөйләш үзенчәлекләрен дә тирәнтен белеп, шуларны үзенең иҗатында тиешле дәрәҗәдә кулланган.

ӘДӘБИЯТ


1. Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 578 б.
2. Булатова М.Р. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань, 2013. 240 с.
3. Булатова М.Р. Курман тауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте. Казань: Магариф – Вакыт, 2016. 384 с.
4. Булатова М.Р. Тукай телендәге алынма сүзләр һәм җирле сөйләш үзенчәлекләре // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая. Казань: ИЯЛИ, 2016. Б. 92–96.
5. Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан, 2000. 288 б.
6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 5 т. Казан, 2009. 559 б.


## Г. ИСХАКЫЙ РОМАННАРЫНДА РОМАНТИК ХЫЯЛ ҺӘМ КЫРЫС ЧЫНБАРЛЫК


***Ф.И. Габидуллина** (Алабуга)*



В конце XIX в. одним из лидеров обновленческого движения в литературе был Гаяз Исхаки (1878–1954). Понимая преимущества прозы и драматургии в подробном и действенном освещении национального бытия, его актуальных проблем, свое литературное творчество он развивает именно в этом направлении. С целью разностороннего освещения масштабных и сложных проблем национального бытия и судьбы татарского народа, продолжая просветительские традиции, он обращается к эпической форме – роману. Г. Исхаки в своих романах через жизнь и судьбы отдельных людей анализирует и оценивает проблемы общенационального характера.



**Ключевые слова:** литература, Г. Исхаки, роман, конфликт, проблема, характер, герой.



At the end of the XIX century, one of the leaders of the revisionist movement in literature was Gayaz Iskhaki (1878–1954). Realizing the advantages of prose and drama in detailed and effective coverage of national life, its actual problems, he develops his literary work in this direction. For the purpose of versatile coverage of large scale and difficult problems of

national life and fate of the Tatar people, continuing educational traditions, he addresses an epic form – the novel. G. Ishaki analyzes and assesses problems of a national character in his novels through the life and fate of the individuals.
**Key words:** literature, G. Ishaki, novel, conflict, problem, character, hero.

Яңа заман татар әдәбияты өчен милли әһәмиятле мәсьәләләрне күләмле һәм колачлы формада – роман жанрында күтәрүен дәвам итеп, Гаяз Исхакый (1878–1954) аларны мәгънәлерәк һәм тәэсирлерәк итеп яктыртырга да омтыла, ягъни әсәрләренең укылуы, киң даирә укучыларга барып җитүен дә кайгырта. Бу исә язучыны жанрның үз эчендә дә эзләнүләргә этәрә. Әлбәттә, мондый эзләнүләр әсәрнең тирән мәгънәле булуын да күздә тота.

Мондый мәсьәләләрнең иң мөһимнәреннән берсе – XX гасыр башында татар зыялылар катлавының хәле тора. Бу мәсьәләгә игътибар зур булуның төп сәбәбе ул вакытта татар дөньясында милли яңарыш хәрәкәтендә зыялылар катлавына әйдәп баручы вазыйфа йөкләү белән бәйләнгән иде. Шундый тәкъдири әһәмиятле вазифа йөкләнү белән бергә, зыялылар кавеменә карата зур таләпчәнлек тә күрсәтелә. Бу мәсьәләне аеруча актив күтәргән Г. Исхакый үз иҗатында аны төрле яклап яктырта һәм биредә билгеле бер эволюция дә кичерә. Бер яктан, беренче әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт» (1899) хикәясендәге Хәлим образында ул үзенең милли-мәгърифәтчел идеалын, ягъни аң-белемле булып милли мәгърифәтләр өчен көрәшүче геройны чагылдырырга алына. Бу идеалына киңрәк яңгыраш биреп, Г. Исхакый үз героеның, иске карашлы этисенең каршылыгын җиңеп һәм мәдрәсәдә тырышып укып, күп белемле зыялыга әверелүен, тагын Аллаһе Тәгаленең дә Хәлимгә әлеге белемнәрне туган халкын аң-белемле итү өчен бирүе белән бәйләп аңлата. Ачыграк әйткәндә, әсәрдә яшь геройның мәдрәсәдә укып алган белемнәрен халыкка хезмәт итүгә багышлавын Аллаһе үзе хуплаган гамәл дип бәяләнә. Әгәр бу беренче әсәрендә яшь Исхакый үзенең зыялы герой идеалын әле күбрәк публицистик планда һәм сәнгатьлелек ягыннан «ялангачрак» төстә гәүдәләндерсә, алга таба, тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе арта төшкәч, үсеш-хәрәкәттә һәм психологик нигезләп яктыртуга иреште. Моны без язучының «Теләнче кызы» (1901) романы мисалында күзәтә алабыз.

1905–1907 еллар инкыйлабы вакытлыча чигенеп кара истибдад еллары башлангач, яңалык тарафдары буларак чыгыш ясаган бер төркем зыялы каушап кала. Шуның нәтиҗәсе буларак, барыр кыйбласын югалткан, якты идеалларына томан сарган кичәге «көрәшчеләрнең» асылын ачу зарурлыгы әдәбиятка яңа тема – урталыкта чайкалучы ихтыярсыз, икеләнүчән типларны фаш итү темасын көн тәртибенә куя. Әдәбият галиме Ф. Бәширов фикеренчә: «Реалист язучылар җимерелгән иллюзияләр, тормышка ашмаган хыяллар фонында интеллигентның психологиясе, эш-хәрәкәте белән чын-чынлап кызыксына башлыйлар» [1: 181]. Г. Исхакый да, әлеге темага мөрәҗәгать итеп, зыялылар кавеменнән үзенең әлеге идеалына җавап бирә алмаган кешеләрнең фаҗигасен яки драмасын ачуга игътибар итә. Бу мәсьәләне дә автор төрле яклап яктырта. Мәсәлән, беренче иҗат тәҗрибәләреннән булган «Бай угылы» (1903) повестенда ул үзәк героеның милләткә файдасыз кешегә әверелүенең сәбәпләрен ачуга басым ясый. Бу мәсьәләгә киң милли яңгыраш биреп, яшь Исхакый үз әсәрендә милләт яшәешендәге авыру якларны яшерүгә, аны бары матур яктан гына күрсәтергә тырышучы ялган «патриотлар» белән бәхәскә керә. Повестьның 1903 елгы басмасына кереш сүзендә ул үзе дә бу хакта ассызыклап үтә. Киң планда замандашларында «хәмияте миллиябезне», ягъни милләтне саклау хисен уяту нияте белән язылган бу әсәрендә Г. Исхакый милләт яшәеше өчен бик мөһим мәсьәләләрнең берсен – яшь буынны тәрбияләүне күтәрә. Һәм игътибарын шушы өлкәдәге күңелсез бер моментка юнәлтә. Төгәлрәк әйтсәк, по-

вестьта кайбер гаиләләрдә балаларга тиешле тәрбия бирелмәүнең бик күңелсез нәтиҗәләргә китерүе күрсәтелә. Болар барсы әсәрнең үзәк герое – татар бае Фатыйхның бердәнбер улы Кәрим образында чагылыш таба. Герой язмышында тәрбия факторын беренче планга чыгарып, автор Кәримнең тормыш фаҗигасен «Фатыйх байның дөнья рәтене белмәве, гыйлем кадрене белмәве, Сәгыйдә бикәнең бала тәрбиясендә хәбәрсезлеге, Сәхилә әбинең юк-бар сүзләренә ышанып, аның сүзе берлән баласыны мәктәптән алулары, Фәхри кебек мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән жулик малайга иптәш итеп, аның берлән йөртүләре» [4: 21] белән бәйләп аңлата.

Икенче бер очракларда Г. Исхакый башта яшь чакта милли-иҗтимагый яктан өмет уяткан геройларның үсә төшкәч, яшь чактагы идеалларын онытып, гадәти көнкүреш мәшәкатьләре белән яшәүчегә әверелүләрен аңлаудан туган драмаларын ачуга басым ясый. Шундый ният белән гомумкешелек характерындагы мәсьәләгә-шәхеснең яшәү мәгънәсе һәм максатына мөрәҗәгать итеп, Гаяз Исхакый «Тормышмы бу?» (1910) дигән романын яза һәм анда әлеге мәсьәләне милли юнәлтелгән рәвештә яктыртырга алына. Монда, күрәсең, әсәрнең нинди шартларда язылуы да үз ролен уйнагандыр. Билгеле булганча, 1909 нчы елның язында моңа кадәр Петербургта полициядән сакланып яшәгән Гаяз Исхакый яшерен рәвештә Төркиягә барып чыга. Чит илдә булу, дөнья күрү язучының тормышка карашларын киңәйтеп җибәрә. Яңа биеклектән торып, ул үз тормышын, һәм күпкырлы эшчәнлегенең төп максаты булган милләт яшәешен һәм язмышын тагын да уйланыбрак кайгырта, милли мәсьәләләрнең аеруча җитдиләрен ачыклый кебек. Һәм шулардан берсен үз романында яктыртырга алына. Шул ук вакытта үз фикерләрен укучыларга үтемлерәк итеп җиткерү турында да уйлый. Болар барысы әсәрнең эчтәлегендә һәм формасында чагылыш таба.

Әсәргә эпиграф рәвешендә язылган кереш сүзендә әдип роман язуның максатын һәм стиль алымын болай билгели: «Бер шәкертнең хатирәләре» дигән исем берлә кулыма төшкән шул дәфтәр безнең тормышыбызның иң җәрәхәтле җирләрене ачканга, бик күп яшьләремезнең тереклегенә охшаган бу бәхетсез шәкертләрнең буш, мәгънәсез гомеренә карау минем күңелемдә дә шул: «Тормышмы бу?» дигән сөальне китергәнгә, үзем хәл кыла алмаган шул мәсьәләне бәлки укучыларым хәл кылыр, мин җавап таба алмаган сөальгә бәлки алар табар дип, шул «Тормышмы бу?»ны китап итеп бастырырга уйладым» [3: 33]. Биредә язучының үзен каяндыр кулына килеп кергән бер шәкерт хатирәләрен китап итеп бастырып чыгаручы рәвешендә генә күрсәтергә теләве әсәрдә сурәтләнгәннәрнең тормышчан икәнен ассызыклавы белән бәйләнгән. Чынлыкта романдагы шәкерт хатирәләре, көндәлекләре ул бары автор тарафыннан уйлап чыгарылган. Әмма әсәрдә язылган башка вакыйгаларның тормышта киң таралган булуы аңлашыла. Тормышта киң таралганны, ягъни типик төс алган хәлне дәвамлы рәвештә чагылдыру өчен, әлбәттә, роман жанры кулай була. Тормыштагы типиклыкны шәхси көндәлек аша, ягъни үтә индивидуаль төстә чагылдыру да роман жанрының классик таләбенә җавап бирә. Мәгълүм ки, дөнья әдәбиятында роман жанры этник коллективтан аерыла башлаган яки инде аерылган һәм мөстәкыйльлек алган шәхеснең язмышын, эчке кичерешләрен, гомумән, хосусый тормышын яктырту юлы белән формалаша. Тасвирдагы мондый хосусыйлык гомумкешелеккә хас сыйфатларны ассызыклап чагылдыруны максат итеп куя, әлбәттә.

Шушы классик традицияне дәвам итеп, Г. Исхакый үз романында аерым шәкерт көндәлекләрен бирү алымы белән ул вакытта татар милләте яшәешендәге гомум «авыру» күренешләрне чагылдырырга алына. Нәтиҗәдә әсәрдәге

шәкерт язмышы бөтен милләт язмышы өчен борчу уята торган сәбәпкә әверелә. Роман игътибарны, барыннан да элек, үзенең эчтәлеге белән җәлеп итә. Биредә, Г. Исхакый әсәрләрендә, гомумән, фикри башлангычның көчле булуы да зур гына роль уйный. Монысы үз чиратында Г. Исхакыйның «саф сәнгать» әһеле генә түгел, ә ялкынлы көрәшче әдип булуы белән бәйләнгән. Әдәби иҗат та аны башлыча үзенең милләт яшәеше һәм язмышы өчен көрәшендә бер корал яки чара буларак кызыксындыра.

Роман лирик геройның шәһәрдән авылга чираттагы ялга кайтуы белән башланып китә. Әсәрнең беренче битләреннән үк яшь герой, гомумән, табигатькә дә, авыл тормышына да каршы яки алардан аерып куела. Табигать дөньясына үтеп кереп, аның ямен һәм тәмен белә алмаган кебек, яшь герой авыл тормышында да ала карга хәлендә кала, анда үзенә ямь таба алмый. Аның ялгызлыгы, яшәвенең мәгънәсезлеге авылда җәйге һәм көзге эш көннәрендә тагын да ныграк ассызыклап күрсәтелә. Авыл халкының бу вакыттагы алны-ялны белми торган тырыш хезмәтен күреп, герой үзенең бу хезмәттә катнаша алмаганына кыенсынып та куя: «Һәммә халык эш эшләгәндә, һәммә халык табигатьнең биргән байлыкларыны күбәйтергә тырышканда, ничек бер эш эшләми торырга кирәк? Ничек шул хезмәткә катышмаенча, шул хезмәтнең җимешләреннән файдаланырга кирәк?» [3: 56]. Әмма үзе бу дөньяга кереп китә алмый хезмәт кешеләренә мәдхия уку белән чикләнә. Героеның авылдагы рухи ялгызлыгын, андагы тормыштан ямь һәм тәм тапмавын автор аның гаиләдә хезмәт тәрбиясе алмавы, үзен гади халыктан өстен куеп, мулла булырга гына әзерләнүе белән бәйләп аңлата. Шунлыктан бөтен авыл халкы хезмәт белән дәртләнеп яшәгән бер вакытта, әсәр герое бөтенләй башка бер халәтне кичерә: «Күңел әллә ни тели, эч поша. Кәеф юк, төрлелек юк. Көннәр бары да берсенә берсе охшап үтеп бара. Күңелсез, мәгънәсез! Әллә ни эшлисе килә, әллә ни тудырасы килә. Берни дә эшләп булмый. Иртәдән кичкә кадәр йортта йөреп, ындырга барып вакыт уздырам. Үземнең язмышымнан үзем разый түгел» [3: 45]. Күренә ки, автор героеның үзенә тәнкыйтьчел күзлектән карый алуын да ачыклый [2: 50]. Авылда җәен мәгънәсез үткәргәнлеген, анда әрәмтамакка әверелгәнен аңлаган шәкерт, күз җиткәч, зур өметләр белән Казанга юнәлә. Әмма автор алга таба аның бу өметләре дә акланмавын күрсәтә. Барыннан да элек, шәкертнең мәдрәсәдә төплерәк белем алу теләге барып чыкмый. Чөнки ул укыган кадими мәдрәсә андый белем бирә алмый. Моннан соң герой үзлегеннән белемен арттырырга ниятли һәм төрле дөньяви фәннәрне өйрәнә башлый. Бераздан автор герой – «мин»нең шулай үзешчән юл белән алган белем дәрәҗәсен болай билгели: «Мин хәзер аз гына русча, аз гына төрекчә, аз гына гарәпчә, фарсыча, аз гына үз телем татарча беләм, бу телләрнең барысында да лөгать китаплары берлә, китаплар рисаләләр аңлый алам. Шуның өстенә, тарихтан аз гына, әллә нинди үләннәр, хайваннар хакында, аз гына өй тәрбия кылу, бала укыту, мәктәп идарә кылу хакында, аз гына дин вә игътикад хакында, аз гына тәфсир хәдис хакында, аз гына мантыйк вә хикмәт хакында кыскасы гына һәр нәрсә хакында аз гына мәгълүматым бар. Боларның һәммәсене өстән генә белсәм дә, берсене дә чынлап белмим. Менә шул белемем берлә нигә ярыйм» [3: 87]. Үз героеның гына түгел, башка бик күп шәкертләрнең дә белем дәрәҗәсе бик түбән булуын искәртеп, автор бу хәлне шактый дәрәҗәдә ул вакыттагы мәгариф эше белән дә бәйләп аңлата. Әйтергә кирәк, милләт өчен аеруча тәкъдири әһәмиятле дип каралган мәгарифнең гомум хәле белән Г. Исхакый үз иҗатының буеннан-буена диярлек кызыксынып килә. Мисал өчен программа характерындагы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә дә ул татарны милли инкыйразга алып бара торган төп сәбәпләрнең берсе итеп

мәгарифнең ул вакыттагы авыр хәлен билгели. Күп кенә мәктәп-мәдрәсәләрнең шәкертләргә заманча төпле белем бирә алмаулары проблемасына «Тормышмы бу?» романында кабат әйләнеп кайтып, әдип аны турыдан-туры милләт язмышы белән бәйләп карый. Мәгариф эшенең авыр хәлдә булуы ул вакытта башка әдипләрнең дә игътибарын җәлеп итә. Мәсәлән, Г. Тукай, Г. Ибраһимов «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни diләр», «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» кебек башлангыч әсәрләрендә үк иске типтагы мәдрәсәләрдәге тәртипләрне һәм алардагы белем бирү дәрәҗәсенең бик түбән булуын тәнкыйть утына алалар. Ф. Әмирханның «Урталыкта» романында исә мәдрәсә белеменнән канәгать булмаган Хәсән Арслановның, Казанга килеп, рус укытучысыннан дәресләр ала башлавы турында сүз бара. Әсәр тәгалләнмәгән булуы сәбәпле, үзәк геройның язмышы ничек булачагы билгесез. Романның язылган өлешендә авылдан килгән кичәге пишкадәмнең шәһәр дөньясына килеп керүе, шушы дөньяда үз-үзен тотышы, яңа уй-хисләре сурәтләнә. Гомумән, инкыйлабка кадәрге татар яшьләре мохитен тәнкыйть күзлегеннән чыгып яктыртырга алынып, Ф. Әмирхан алар арасындагы милли-иҗтимагый аерымлыкны күрсәтүгә басым ясый. Ә менә «Картайдым» (1909) хикәясендә Ф. Әмирхан Хәсән Арслановның буындашы булган Мостафаны инде гомер юлына һәм яшәвенә нәтиҗә ясаган зат итеп күрсәтә. Моның өчен отышлы сюжет алымы кулланыла. Үзенә егерме тугыз яшь тулган вакытта, яшьлегенең артта калуын аңлап һәм хәзерге яшәешеннән ямь тапмыйча, Мостафа, эч пошудан нишләргә белмичә, альбомын актара башлый, төрле елларда төшкән рәсемнәр ярдәмендә автор үз героеның яшәү максаты еш үзгәреп торганын, тормышта төпле карашы булмаган затка әверелүен күрсәтә. Шунлыктан утызга чыкканда Мостафа үзен инде рухи картайган, яшәвенең яме дә, тәме дә булмаган кеше итеп сизә.

Шулай ук кешенең яшәү максаты мәсьәләсен үзәккә куйган «Тормышмы бу?» романында Г. Исхакыйның романтик хыял белән кырыс реализм конфликтын үзәк геройның каршылыклы уй-кичерешләре аша ачуын басым ясап әйтергә кирәк. Әсәрнең күбрәк фикри башлангычка нигезләнүе аның лирик героеның уйчан булуына, тормышка һәм үзенә тәнкыйтьчел каравына китерә. Герой үзенең дөньяга карашларында һәм фикерләвендә билгеле бер эволюция кичерә. Шул ук вакытта бу эволюциянең каршылыклы уй-фикер агышына корылган булуын да әйтергә кирәк.

Баштарак, шәкерт вакытында, герой реаль тормыштан өстенрәк торган, үз-үзенә бикләнеп яшәгән романтик рухлы зат буларак гәүдәләнә. Чөнки аның француз, төрек романнары йогынтысында туган романтик хыял-омтылышлары көндәлек тормыштан ерак торалар, шунлыктан ул үзен бу дөньяда, дөресрәге, авыл мохитендә үзенә урын, аның кешеләре белән уртак тел таба алмый. Бер үк вакытта романтик рухлы шәкерт әлеге тормыштан ямь һәм тәм табып яшәүче кешеләргә, бигрәк тә үз яшьтәшләренә көнләшеп тә карый. Чит ил романнары уку белән мавыгу болай да романтик рухлы яшь геройны тагын да хыялыйрак итеп җибәрә. Моңа кадәр дә кешеләргә нинди дер кирәкле гамәлләр кылу турында уйлаган шәкерт хәзер тагын да зуррак хыялларга бирелә: аның «...бу бөтен дөньяда йоклап яткан, изелгән мөселманнарны күтәрәсе, аларны әлгәреге кеби зур ясыйсы килә» башлый.

Алга таба без әсәрдә геройның реаль тормыш басымы астында мондый зур хыяллардан арынып «җиргә» төшә баруын күрәбез. Шәкертнең уй-кичерешләрендә һәм үз-үзен тотышында үзенә бер борылыш башлануны автор аның мәдрәсә тәмамлавы белән бәйләп карый. Бу вакытта, бер яктан, геройның мөстәкыйль тормыш итүгә никадәр әзер булуы ачыклана. Балачакта ата-анадан, аннары мәдрәсәдә төпле аң-белем һәм тәрбия ала алмавы аркасында, геройның

алга таба зур эшләр башкарырга сәләтсез икәнлеге мәгълүм була. Автор биредә шәкертнең рухи-әхлакый яктан да җитлекмәгән булуына дикъкать итә. Әнә шундый халәттә ул мөстәкыйль рәвештә тормыш итә башларга тиеш. Әмма ул үзалдына яшәргә әзер түгел. Чөнки бер шөгыльне дә белми. Азмы-күпме белеме белән балаларны укыта алыр иде, әмма моңа әти-әнисе теше-тырнагы белән каршы. Чөнки алар күптән инде бердәнбер улларын авылда мулла итү турында хыялланалар. Нәтиҗәдә, без геройның хәле тагын да катлауలануын күрәбез. Чөнки ул үзен барлы-юклы белеме белән мулла булырга лаек түгел дип саный. Әмма герой үзенең рәтле аң-белем һәм тәрбия ала алмыйча, «ат та түгел, ишәк тә түгел» бер затка әверелеп калуын шәхси драма итеп кенә карамый, аңа киң, хәтта гомуммилли яңгыраш бирергә тели. Аныңча, яшьләргә төпле белем бирә торган мәгариф системасы булмау аркасында, аның кебек «меңләр-меңләр егетләремезнең, ике агым арасында йомычка кеби, бер тарафка китәргә хәле» юк. Һәм замандашларын «шул әллә никадәр яшьләремезнең харап итәчәк гомерләре өчен» [3: 100] борчылырга чакыра.

Бераздан алга таба нәрсә эшләү, ничек яшәү мәсьәләсе белән йөзгә-йөз калгач исә, герой, моңа кадәрге уй-хыялларының гамәлгә ашмаслыгын аңлап, әти-әнисе теләгенә, ягъни мулла булырга ризалаша һәм «мәгънәви зиндандагы» яшәү белән көн күрә башлый. Кыскасы, үзәк геройның гыйбрәтле иҗтимагый-рухи эволюциясе, мәдрәсәдә укыганда мәгариф эшенә реформа ясап, «бөтен халыкның фикерене үзгәртүне» максат итеп куйган шәкертнең, әти-әнисе сүзе буенча гына мулла булып, һәм яратмаган кызга өйләнеп, эшеннән дә, шәхси тормышыннан да канәгать булмаган, әмма үзен-үзе «шул баткаклыктан чыгара алмаган көчсез, хәлсез бер әрәмтамак»ка әверелүе рәвешендә алга бастырыла. Шундый эволюцияне шәкерт көндәлекләре алымы белән чагылдырганнан соң, автор укучы алдына «Шулмы гомер? Тормышмы бу?» дигән сорау куя. Әлбәттә, «гомер», «тормыш» төшенчәләре монда «мәгънәле яшәү» рәвешендә кулланыла. Соңгысын исә әдип милләткә файдалы булып яшәү мәгънәсендә аңлата. Әсәрдә геройның шундый тормыш белән яши алмавын аңлаудан туган рухи драмасы күрсәтелә.

Мәдрәсәдә дә төпле аң-белем һәм тәрбия ала алмавы аркасында, ул фани дөньяда яраткан һөнәре булмаган, «ат та түгел, ишәк тә түгел» бер җан иясенә әверелә. Шулай гомер кичерүен чагылдырган көндәлекләрен олыгайгач кабат күздән кичерү геройның яшь чактагы күңел җәрәхәтләрен кабат яңартып җибәрә. Һәм аның күңелендә инде искә алынган «Тормышмы бу?» дигән сорау туа. Автор бу сорауга адәм баласының фани дөньяда яшәвенең максаты рәвешендәге мәгънә бирә. Мондый мәгънәдәге әлеге сорауга герой уңай җавап бирә алмый, чөнки, автор фикеренчә, герой яшь вакыттагы милләткә файдалы булу хыялын онытып, көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән генә яшәүчегә әверелә.

XX йөз башы татар әдәбиятында замандашлар яшәешенә, аларның шәхесенә игътибар арту шартларында иҗат иткән Г. Исхакый, башка әсәрләрендәге кебек, «Тормышмы бу?» романында да героеның каршылыклы уй-хисләр дөньясын реалистик һәм романтик чаралар ярдәмендә чагылдырырга омтыла.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. Казан: Фикер, 2002. 285 б.

2. Габидуллина Ф. Проблемы изучения жанровой природы татарского романа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. Ч. I. № 7 (25). 2013. С. 49–51.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.

4. Мусин Ф. Гаяз Исхакый: тормышы һәм эшчәнлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 190 б.

# МӨҺАҖИРЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕ

***Л.Р. Гайнанова** (Казан)*

В статье представлены обширные сведения о жизни и творчестве Г. Исхаки периода эмиграции. Раскрываются причины отъезда писателя за границу, подробно и последовательно исследуется его деятельность по оказанию помощи соотечественникам и содействия в издании газет и журналов. Показана проделанная работа по сбору наследия Г. Исхаки и его популяризации среди народа, раскрываются предстоящие задачи.
**Ключевые слова:** эмиграция, политика, публицистика, журнал, наследие.

Information about Gayaz Iskhakii`s life and creation in the period of emigration is given in the article. Reasons of the author`s leaving abroad are revealed. His assistance to compatriots and newspapers and magazines edition are studied in details.
**Key words:** emigration, policy, journalism, a magazine, heritage.

1918 елның апрелендә большевиклар Уфада Милли идарәне туздырып, банктагы акчаларын да конфискацияләгәч, Г. Исхакый, Милли идарә әгъзалары белән бергә, Кызылъярга (Петропавелга) күченеп китәргә мәҗбүр була. Бу шәһәрдә ярты елдан артык яшәп алуы Г. Исхакыйның туган Иделйортыннан гомерлеккә чит-ят җирләргә китү вакыты арасында бер озын-озак күчеш чоры булып тора. Әдип большевикларның власть башында озакка калачакларына ышанмый әле. Себердә ул киң эшчәнлек җәелдереп җибәрә. 1918 елның 7 декабреннән «сәяси, әдәби төрек-татар гәзите» булган «Маяк» чыга башлый. Г. Исхакый гәзитәнең беренче саннарында ук Себердә яшәүче милләттәшләрен, Уфада Милли мәҗлес төзегән кануннарга нигезләнеп, шәһәрләрдә шәһәр мәҗлесе идарәләрен, авылларда авыл мәҗлесе идарәләрен сайларга чакырып чыга. Һәм, чыннан да, Кызылъяр шәһәрендә 28 кешедән торган Милли идарә сайлана да.

Бу чордагы сәяси вазгыять турында Г. Исхакый болай фикер йөртә: «Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң, 1918 елның 11 ноябрендә Аурупадагы вакытлы килешү игълан ителде. Без алманнарның җиңелүләренә ышанмаганга, бу эшне Аурупа дәүләтләренең бергәләшеп сугыш чыгымнарын Русия өстенә күтәртеп, шуларны каплатыр өчен Русияне бүлү башлануының башы дип аңладык. Шул Русияне бүлешүдә үзебезнең халкымызның сәяси “ризыгы” хуҗасыз калмасын өчен, Аурупага солых мәҗлесләренә катышырга вәкилләр күндерүне кичектерелми торган бер милли эш итеп карадык».

Г. Исхакый турында күп очракта «совет властен кабул итмәгән, чит илгә чыгып киткән» дип кенә язалар. Юк, чит илгә ул Ватанына әйләнеп кайтырга дип киткән. Югыйсә, нигә кирәк булыр иде аңа Парижга, Версаль солых конференциясенә барырга омтылу? Бу конференция Милли мәҗлес тарафыннан кабул ителгән Идел-Урал бәйсез җөмһүрияте төзү турындагы карарларны якларга, расларга тиеш. Милли мәҗлес делегатлары менә нинди өметләр белән бара Версальгә. Әмма С. Максуди, Ф. Туктар, Г. Исхакый катнашкан солых конференциясендә Россия ягыннан большевиклар булмый. Шуңа күрә делегатлар конференциядә Идел-Урал төрек-татарларының хәле, теләкләре мәсьәләләрен күтәрсәләр дә, гәзитәләрдә язып чыксалар да, сөйләшүләр берьяклы гына булып кала. Г. Исхакый шул китүеннән Ватанына кире әйләнеп кайтмый.

Гаяз Исхакыйның Ватаныннан читтә яшәгәндә иҗат иткән 11 әдәби әсәре мәгълүм. Алар: «Дулкын эчендә», «Өйгә таба», «Көз», «Җан Баевич», «Локман хәким», «Татар кызы», «Хәят юлында», «Тәүбәгә килгән хатын», «Олуг Мөхәммәд». Ә әсәрләрнең икесе – «Ике ут арасында» драмасы һәм «Олуг бәйрәм» исемле хикәясе, әдипнең кызы Сәгадәт Чагатай миңа язганча,

этисенең башка әйберләре белән бергә Варшавада бер саклык банкында кала, ул банкка бомба төшеп, бина җимерелә.

Чит илгә киткәч, Г. Исхакый 1920–1923 елларда гына да 7 әдәби әсәр иҗат итә. Әмма берсен дә бастыра алмый. Ул елларда әдип бик авыр матди кысынкылыкта яши. Г. Исхакыйның кызы Сәгадәт 1924 елның 2 мартында Берлиннан этисенең энесе Әхмәтхәсәнгә хат яза. Анда мондый юллар бар: «...китапны алгансыңдыр дип уйлыйм. Узган ай ахырында икенче китап җибәрелде, ул барып җиткәндер инде. Исән-сау барып җитсә, китаплар моннан тагын да җибәрелеп торыр. Китаплары басылса һәм укылса, этигә күңеллерәк булыр иде. Аның язган китаплары күп, ләкин язган бере чемоданнан ары китмәгәнгә, язу теләге дә сүрелә. Халык аның китапларын бик теләп укыр иде, әлбәттә. Сәяси китаплар түгел алар...». Гаяз Исхакый, күрәсең, шул китапларын Ватанында бастырырлар дип өметләнгән. Әмма аның китапларының кульязмаларын да, Сәгадәтнең һәм үзенең Әхмәтхәсәнгә язган хатларын да органнар эләктереп барган.

Г. Исхакый берничә тапкыр матбага ачарга омтылыш ясап карый. Бу мөмкинлек бары тик 1928 елда гына туа. Архангелдәге сөрген елларын бергә кичкән фикердәше, бу чорда исә Польша хөкүмәтенең башлыгы, маршал Иозеф Пилсудский (1867–1935) әдипне Варшавага чакырып ала, аңа үз матбагасын оештыруда ярдәм итә. Варшавада торып, кызы Сәгадәт һәм кияве Таһир Чагатайлар да катнашып, Берлинда «Милли юл»ны (соңыннан «Яңа милли юл») чыгара башлагач та (мәҗмуганың беренче саны 1928 елның декабрендә дөнья күрә) язган әсәрләрен 1937 елга кадәр бастыра алмый. Бу хәлгә беркадәр ачыклык кертер өчен махсус органнар туплаган документлар арасыннан бер хатка мөрәҗәгать итик: «Президент полиции г. Берлин. Полицейский отдел Шарлаттербург-Тиргартен. – В рейхоляйтунг HEDAN, отдел внешней политики г. Берлин, Маргаретенштрассе. Касательно Аяса Исхаки. Входные и нумерация обработки 2 ноября 1936. День записи 30 октября 1936. – Просьбу Айас Исхаки о разрешении ему, как исключение, открыть самостоятельную типографию (наборочную), согласно § 3, ст. 2 третьего распоряжения о временном построении немецкого ремесла от 18.1.1936 г., я утверждаю сегодня». По поручению подпись: Больц.

Бу документтан шул аңлашылса кирәк, Г. Исхакый үзенең «Милли юл» мәҗмугасын үз типографиясендә түгел, ә берәр чит кеше типографиясендә «өйдәш» булып бастырып килгән. Ә әдәби китаплары исә эшмәкәр буларак үз типографиясе оештырылгач кына басыла башлый. Басылган китапларның алгы тышының эченә: «Бу әсәр “Милли юл”ның үз матбагасында хәреф тезү машинасы илә тезелде» дип язылган.

Китаплары басылып тора, 11 ел инде «Милли юл» мәҗмугасы нәшер ителеп килә... Г. Исхакый 1919 елда туган иленнән киткәннән бирле, мөгаен, беренче тапкыр тынычланып, әсәрләр язса, бастырып чыгарырга мөмкинлек булуына куанып яшәп алгандыр. 35 еллык мөһаҗирлек чорында бу еллар әдипнең иң бәхетле еллары булгандыр. Әмма дәртләнеп, бөтен көчен иҗат эшенә җигеп, җимертеп эшләп ятканда, Гитлер Польшага сугыш ача. Г. Исхакый, Польша хөкүмәтенең киңәшен тотып, эмигрантлар оешмасы «Прометей» җитәкчеләре белән бергә 1939 елның 6 сентябрендә Варшавадан чыгып китәргә мәҗбүр була. Г. Исхакый, үзе язганча, өennән кулына бер сумка тотып кына чыгып китә. Шулай итеп, сугыш Г. Исхакый өчен шәхси фаҗига китерүдән башлана. Шуннан соң аңа беркайчан да үз матбагасын кору насыйп булмый. Мондый вазгыять килеп чыкмаган булса, без – укучылар да – әдипнең югарыда аталган тагын ике әсәрен күрә алган булыр идек.

Татарның үткәндәге шанлы тарихы, агымдагы хәлләре, киләчәккә өметләре турында утызынчы елларда язылган, рус, француз, поляк, япон телләрен-

дә басылып чыккан «Идел–Урал» очеркының татарча басмасы булмавы да югарыда бәян ителгән хәлләр белән аңлатыладыр, күрәсең.

Сугыш афәте шулай ук Г. Исхакыйның Аурупа һәм Ерак Көнчыгыш илләре белән бәйләнешен дә чикли. Төрле илләрдә бик иркен йөри ала торган әдип нигездә бер урында гына – Төркиядә генә яшәргә мәҗбүр була.

Г. Исхакый, Берлинда басылып чыккан (мөһаҗирәтнең баштагы чорында иҗат иткән) китапларыннан соң, 20 ел әдәби әсәрләр язмый. Бу чорда ул каләмен публицистика өлкәсендә эшләтә. 1928–1939 елларда нәшер ителгән «Милли юл» («Яңа милли юл») мәҗмугасының һәр санында (барлыгы 136 саны дөнья күрә) әдипнең бер яки ике зур мәкаләсе басылып бара. Мәҗмуга чыккан дәвердә, 1931 елда өч ай мөселман Көнчыгышында сәфәрдә булып кайта. 1933–1936 елларда Ерак Көнчыгыштагы илләрдә яши. Шул чорда гына «Яңа милли юл»да мәкаләләре бераз сирәкләнеп ала.

Г. Исхакыйның чит илдәге тормышын күзәткәндә, аның оптимизмына, оештыру сәләтенә сокланмый мөмкин түгел. Алыйк аның 1933–1936 елларда Ерак Көнчыгыштагы эшчәнлеген генә. Ул анда 1918 елда Уфадагы Милли мәҗлестә үзе һәм фикердәшләре тарафыннан тәкъдим ителгән Идел-Урал милли мохтариатының моделен кора. Мөһаҗирләрне милли байрак астына туплый. Милләттәшләренең дини мәхәллә тормышын дөньяви милли-мәдәни җәмгыять тормышына әверелдерә.

Ул Япония, Кытай, Корея, Манчжуриядә яшәүче татарларның 17 мәхәлләсен бер Милли мәркәз астына туплый. 1935 елның 4–14 февралендә Мукденда уздырылган Корылтайда Идел-Урал төрек-татар дини-милли җәмгыятенең Г. Исхакый төзегән Уставы кабул ителә. Мәркәз башкарма идарәсе каршында диния, мәгариф, финанс эшләре буенча шөгъбәләр (бүлекләр) оештырыла. Барлык мәхәлләләрдә дә шул шөгъбәләрнең бүлекчәләре төзелә. 1935 елның 1 нче ноябрендә Мукден шәһәрендә «Ерак Шәрекътагы Идел-Урал төрек-татарларының атналык гәзитәсе» «Милли байрак» чыга башлый. Гәзитәне оештырып, ярты ел чыгарышкач, Г. Исхакый 1936 елның мартында Аурупага китеп бара. Гәзитәнең һәр санында «мөәссисе (коручысы, нигезләүче) Г. Исхакый» дип языла.

Гәзитә җитәкче бер органга әверелә. Бөтен мәхәлләләр тормышын яктыртып бара. Милләттәшләребез үз Ватаннарында уйларга да мөмкин булмаган тормыш белән яши. Әйтерсең лә алар башка – параллель дөньяда тереклек итә. Әйтик, Явыз Иванның Казанны алган көнне – 15 октябрьне ел саен кайгы көне дип игълан итеп, һәр мәхәлләдә җыелышып Коръән укып, шәһид киткәннәрне искә алалар. 1917 елда Ватаннарында корылган Милли мәҗлеснең 20 еллыгын зур тантаналар ясап билгеләп үтәләр. Ураза, Корбан гаетләре бөтен шартларын туры китереп олы бәйрәм көннәре итеп үткәрелә (ә бу елларда Советлар берлегендә мәчет манаралары киселә, муллалар эзәрлекләнә, ураза һәм Корбан бәйрәме көннәренә туры китереп, атеистик тамашалар оештырыла).

Бу чараларның барысы да гәзитә аша алдан хәбәр ителеп, урыннарда кичәләр уздырылып, соңыннан һәр мәхәлләдә узган кичәләрдән хәбәрләр басыла. Һәр елны Тукай көннәре дә милли бәйрәм итеп уздырыла. Гәзитә кайчагында 12 битле дә булып чыга. Төрле мәхәлләләрдә яшәгән милләттәшләрнең бер-берсен котлаулары, кайгы уртаклашулар, яки иганәчеләрнең исемнәре, сәүдәгәрләрнең рекламалары берничәшәр битне ала. Һәр төбәктә яшьләр, хатын-кызлар түгәрәкләре эшли, концертлар, спектакльләр куела.

Алты еллык дини-милли мәктәпләр дә ачыла. Идел-Урал комитетының уставы буенча, шул мәктәпне тәмамламый торып, балаларны чит уку йортларына

бирү тыела. Һәр гаилә шул кагыйдәне төгәл үти. Яшь буынның чит-ят мохиттә үсеп, үз милли гореф-гадәтеннән, теленнән читләшер дип, ят милләтләр эчендә югалырлар дип куркып яшәгән татарлар бөтен күңелләре белән җирле җәмгыятьләрнең эшенә катнашалар. Гәзитәдә һәр мәхәлләнең тормышы көзгедәге кебек чагыла. Татар яшьләренең үз ишләрен табып өйләнешүләр мөмкинлеге туа.

Мөһаҗирләр, туган илләрендә үзгәрешләр булыр да большевиклар властьтан китәр дә, ирекле илебезгә кайтып яшәрбез дип өметләнә. Бөтен хосусиятләрен саклап яшәп, алар үзләрен Советлар илендә динсез, телсез калган милләттәшләренә беренче ярдәмчеләр булачакларына ышана. «Милли байрак»та үзара котлашулары һәрвакыт «киләсе бәйрәмнәрне үз Ватаныбызда каршыларга язсын» дигән сүзләр белән тәмамлана. Аурупадан Г. Исхакыйдан килгән котлауларда да шундый ук теләкләр кабатлана: «Мөхтәрәм милләттәшләр, Корбан бәйрәмеңез мөбарәк булсын. Милли-дини эшләремездә эшләүче, чалышучы, матди-мәгънәви ярдәм итешүче бөтен милләттәшләребезнең эшләре уңышлы булып, тиз көндә хөр-мөстәкыйль илебездә бәйрәмнәребезне бергә-бергә итәргә Тәңре насыйб итсен. Варшава».

«Милли байрак» гәзитәсенең 116 саны кулдан языла. Бу эшне Ибраһим Дәүләткилде башкара. Аның хатыны – гәзитәнең нигездә алып баручысы Рокыя Мөхәммәдиш-Дәүләткилде һәр санда үзенең төпле мәкаләләре белән мөһаҗирләрнең милли хисләрен куәтләндереп тора. Бу ике фидакярның милләткә иткән ун еллык хезмәтләре соңыннан Советлар төрмәсендә ун еллык тоткынлык белән түләнә...

Бу бердәм җәмгыятьнең, Г. Исхакый төзеп калдырган хөкүмәтнең нигезе шундый нык була ки, балигъ булган милләттәшләрдән җыелган взноска һәм бaерак кешеләрнең иганә акчасына гына яшәсә дә, ул ун ел дәвамында – 1945 елда Совет гаскәрләре Манчжуриягә басып кергәнгә кадәр эшли: гәзитә дә чыгып килә, дини-милли мәктәпләр дә эшли, шул мәктәпләр өчен китаплар, уку әсбаплары да нәшер ителеп тора. «Идел-Урал» комитетының бу ун еллык эшчәнлеге Ерак Шәрекъта яшәүче татарларның милли аңы үсүгә нык ярдәм итә. Хәзер төрле илләргә таралып яшәгән милләттәшләребезнең күбесе Ерак Шәрекътан киткән кешеләр. Туксанынчы еллардан башлап алар Казанга күпләп килде. Чит-ят җирләрдә гомер иткән татарларның туган телебезне, динне генә түгел, тарихыбызны да бик әйбәт белүләре, милләт җанлы булулары гаҗәпкә калдыра иде. Ә алар безнең телсезлеккә, динсезлеккә, бездәге битарафлыкка гаҗәпләнде... Алардагы һәм балаларындагы югары милли үзаң, дингә, телгә, үткән тарихыбызга хөрмәт, баксаң, Г. Исхакый чәчкән орлыкларның җимеше икән.

Г. Исхакый гомеренең соңгы 15 елын Төркиядә яши. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Алманиядә калган әсир милләттәшләр Төркиягә күчәргә ярдәм итүен сорап иң беренче Г. Исхакыйга мөрәҗәгать итә. Әдип җиң сызганып әсирләргә беренче ярдәм – посылкалар җибәрүне оештырып йөри. Чит җирләрдә яшәүнең ачысын-төчесен үзе татыган Г. Исхакый, милләттәш әсирләрнең язмышын йөрәгенә якын алып, аларга матди ярдәм оештыру белән генә чикләнми, өзлексез рәвештә аларны Төркиягә китерү буенча эшли. 1948 елның 4 июлендә ул Сәгадәткә: «Кичә... тупланып киләчәк әсирләргә ярдәм эшен юлга куярга карар алдык», – дип хәбәр итә. Дөньякүләм танылган галим Әхмәт Тимергә язган хатында ул: «Безнең 180 якташыбыз бирегә килүчеләрнең исемлегеннән төшереп калдырылган. Аларның хокукларын кайтару эшендә тырышабыз», – ди. Йөзләрчә татар әсирләре Г. Исхакый ярдәме белән Төркиягә килеп урынлаша.

Г. Исхакыйга Ерак Көнчыгыштагы илдәшләре исә Төркия гражданлыгы алуда ярдәм итүен сорап язалар. 1949–1951 елларда Кобеда яшәүче Габбас

Мөхәммәдҗанга җавап хатларында әдип аталарча һәм дипломатларча Төркия гражданлыгы алу өчен нәрсәләр эшләргә, кемнәр белән ничек сөйләшергә, хәтта гаризаны ничек язарга кирәклеген дә өйрәтә. Аларның гозерләрен үтәү юлында үзенең нәрсәләр башкарганын тәфсилли. Ә бу тәфсилләр артында никадәр мәшәкать һәм кыенлыклар ята. Истанбулдан Анкарага барып йөрүләр, хөкүмәт кешеләре белән күрешүләр, дус-ишләрен дә шул юлда ярдәм итүгә тартулар һ.б. Бу хатлар Г. Исхакыйның чит мохиттә, тар кысаларда яшәгәндә дә милләттәшләренең тормышларын мәгънәлерәк итү, җиңеләйтү юлларын эзләшүен, инде үзе ярдәмгә мохтаҗ көннәрдә дә мөһаҗирләр турында кайгыртып, аларга таяныч булып яшәвен күрсәтә.

Г. Исхакый бу хатларда үзенең хәле, сәламәтлеге турында ләм-мим сүз сөйләми. Ә бит ул елларда әдип бик фәкыйрьлектә һәм саулыкка туймыйча яши. Бу хакта ул кызына гына зарлана: утының бетеп китүе, ә көннәрнең һаман суык торуы, ашказаны авыртуы, «һеморрой» белән интегүе турында яза. Ә шул арада ул Тукай көннәрендә үткәреләчәк «кичәнең репетицияләренә йөрибез», ди. 15 октябрь мәрәсеменә чыгышлар әзерли. Шул тынгысыз мәшәкатьләр арасында хастаханәгә дә кереп ята. 2011 елда Габбас Мөхәммәдҗанның кызы Рокыя ханым Вафаның миңа әйтүенчә, алар 1953 елда Төркия гражданлыгы алуга ирешкәннәр.

Төркиядә Г. Исхакый тырышлыгы белән юлга салынган тагын бер зур казанышны әйтеп китәргә кирәк. «Айлар, еллар маташа торгач, “Америка авазы” радиосын татарча сөйләтергә карар бирделәр», – ди ул Габбас әфәндегә язган хатында. «Америка авазы» – АКШ хөкүмәтенең чит илләргә тапшырулар алып бара торган радиостанциясе. Вашингтонда 1942 елда нигез салынган радио 40 тан артык телдә «сөйләшә», шул исәптән урыс телендә дә (СССРда бу «аваз»ны тыңлау тыела).

Күрәсең, мөһаҗирләр шул каналда татарча һәм башка төрки халыклар телендә тапшырулар алып баруны дәгъвалаган һәм уңышка ирешкән. Г. Исхакый Истанбулдан Анкарага кызы Сәгадәткә язган хатында «татарча радионың сәгате 4.30 да башлый, 15 дәкыйка (минут) сөрә, аннан соң Төркестан, аннан соң азәри...» дип хәбәр итә. Кызына язган тагын бер хатында исә: «15 октябрь өчен мин “Америка авазы” радиосына үз исемемнән бер сүз сөйләп күндердем», – ди, ә икенчесендә: «Без бу арада биш татар көе җырлатып, “Америка авазы”на күндердек. Шуны вөҗүдкә чыгарыр өчен айдан артык куыштым, телефоннарын сорама да»,– ди.

Г. Исхакый «салкын сугыш» чорында 1953 елның май аенда Германиянең Мюнхен шәһәренә Америка инициативасы белән оештырылган гайре рус мөһаҗирләренең конгрессына бара. Чыгышлар ясый, «Милли байрак» исемле кулъязма мәҗмугада мәкаләләре чыга. Конгресска Америкадан килгән вәкилләр белән әңгәмәләр кора. Шул Конгресстан соң 1953 елның 11 декабрендә Мюнхенда СССР халыклары өчен оештырылган «Америка авазы»ның бер тармагы булган «Азатлык» радиостанциясе эшли башлый. Татарча тапшыруларны инде шул «Азатлык» радиосы яңгырата. Мондый зур эшнең оешуында Г. Исхакыйның да роле булган дия алабыз.

Шул Мюнхендагы конгресска китәр алдыннан Г. Исхакый васыятьнамәсен яза. Бу вакытта ул каты авыру. Аны бит Мюнхеннан килеп алалар, мөһаҗирләр бөек юлбашчының конкгресска килүен хәлиткеч эш дип саныйлар. Бу шулай була да. Әдип үз хәлен аңлап, я берәр җирдә үлеп калырмын дип уйлаптыр (текстта шул ихтималны әйтә дә) васыятьнамәне бик җентекләп яза. Аны тетрәнеп укыйсың. Ул ватаннарында репрессияләнгән туганнарына да «өлеш» чыгара. Мәсәлән, Исхакый энесе булганга кулга

алынып, ГУЛАГ газапларыннан котылып кайткач, 1940 елда 44 яшендә асылынып үлгән бертуган энесе Әхмәтхәсәнне берничә урында телгә ала, әйберләрен васыять итә...

Әйе, тимер коймалар бик текә булган шул... Г. Исхакый туганнары хәленнән бихәбәр булган. Чистай төрмәсендә таш идәнгә су сибеп яланаяк бастырып тотып, 14 ай газаплаганнан соң аяксыз калган сеңлесе Гайнелмәрзия турында да, Яуширмәдә Исхакыйларның оясын туздырып, йортларын, малларын тартып алып, туганнарын урамда калдыруларын да, сеңелләренең балаларын укырга алмауларын да, әтисе белән бертуганының улы Касыйм мулланы «Исхакыйдан нинди директивалар аласың?» дип, газаплап, ахыр чиктә Һади Атласилар белән бергә атып үтерүләрен дә, 1938–40 елларда Исхакый туганнарының репрессияләнүләре кайбер гаиләләрнең фамилияләрен алыштырырга мәҗбүр булуларын да әдип үзе дә, кызы Сәгадәт тә белми яшиләр...

Гомере буе, революция озакка сузылды, әмма большевиклар барыбер юкка чыгачак, татар халкы бәйсез, хөр мәмләкәт коруга ирешәчәк, дип инанган әдип «Идел-Урал мөстәкыйль дәүләте академиясе идарәсе»нә иҗатын бастырудан, 37 дәфтәрдән торган көндәлекләрен чыгарудан килгән табышны «милли юлда әсәр биргән кыйммәтле әдипләрне кызыксындыру өчен милли премия сыйфатында бирелүен васыять итәм», дип язган. «Әгәр Ватаным руслардан азат ителсә, мәетем туган илемә, Казан шәһәренең ислам зиратында, мөмкин булса, Шиһабеддин әл-Мәрҗани, Габделкаюм ән-Насыйри, Һади әфәнде Максуди, Габдулла Тукайларның каберләре янына куелсын», дигән... Ул ашказаны рагы авыруыннан интегә. Үләренә ике ай калгач кына кызы Сәгадәт янына Анкарага күченә. Халкыбызның бөек улы Гаяз Исхакый 1954 елның 22 июлендә 76 яшендә Анкарада вафат була, үзенең васыяте буенча Истанбулда «Әдернәкапы шәһидлеге» зиратында җирләнә.

Илендә чагында башы төрмә-сөргеннәрдән чыкмаган, сөргеннән котылгач та Идел-Уралында яшәүдән мәхрүм ителгән, киләчәген бәйсез дәүләт итеп күрергә теләгән Ил-йортыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган, дөньяның барлык кыйтгаларын айкап, туктап яшәп алган һәр җирдә үзенең якты эзен калдырган, матбагалар корган, гәзитә-журналлар чыгарган, чыгышлары, мәкаләләре белән татарны, аның уй-хыялларын таныткан, үзе гомере буена йортсыз-җирсез булган сәйяр язучыбыз Гаяз Исхакый кебек бик зур каршылыкларны үтеп, чиксез зур мирас калдырган тагын кем бар бездә?

1992 елда безнең тарафтан төзелгән Г. Исхакый әсәрләренең 15 томлыгы проектына әдипнең кулыбыз җитәрдәй татарча һәм беркадәр төрекчә мирасы гына теркәлгән иде. Хәзерге көндә аның энтузиастлар кулы җитмәстәй, бик күп илләрдә чәчелеп калган мирасын чамалаганда, күптомлык икеләтә, ә бәлки аннан да артыграк күләмдә, 30–35 томнар булып күзаллана. Г. Исхакыйның чит илләрдә гарәп, фарсы, алман, инглиз, француз, поляк, фин, кытай, япон һ.б. телләрдә, шулай ук эмиграциядә нәшер ителгән рус, украин, азербайҗан, әрмән, кырым-татар матбагаларында басылып чыккан мирасын кайчан һәм ничек җыярбыз икән?

Төркиядә күп дистә еллардан бирле мәдәният файдасына эшләп килгән бай фондлар бар. Шул фондлар ярдәмендә төрек галимнәре, Казанга килеп, айлар, еллар буена бездәге чыганакларны өйрәнәләр. Бездә андый мөмкинлек юк. Революциягә кадәр мәдрәсәләр токкан, нәшриятлар ачкан байларыбыз юк. Традиция өзелгән. Безгә хөкүмәт ярдәменә сыенырга туры килә. Г. Исхакыйның дөнья буенча сибелгән мирасын җыйнау буенча киң хөкүмәт программасы төзелергә тиеш. 35 ел гомерен чит илләрдә үткәргән әдипнең иҗатын башкача кайтарып булмаячак.

1993 елда Яуширмә авылы мәдәният йортында Г. Исхакыйның тууына 115 ел тулу уңае белән музей ачылган иде. 2–3 энтузиаст тырышлыгы белән генә оешкан бу музей беренче елында ук дәүләт музее статусына ия булды һәм Татарстан берләштерелгән дәүләт музее составына керде. Музей, елдан-ел байый барып, алты ел дәвамында Казаннан, республика шәһәр һәм районнарыннан, башка төбәкләрдән язучыларны, галимнәрне, хөкүмәт җитәкчеләрен, журналистларны, укытучыларны, укучыларны, студентларны һ.б. үзенә җәлеп итеп, кабул итеп торды. Бу музей экспонатлары 1999 елның 30 июлендә ачылган Г. Исхакый музей-утарының фото һәм документлар экспозициясенә нигез булды. Г. Исхакыйның әдәби томнарында төзүче тарафыннан нигездә үз тупланмасыннан биреп барылган фоторәсемнәр, документларның барысы да диярлек башта Г. Исхакый музеенда урын алган иде. Музей хәзер дә экспонатларга байый тора.

Шулай итеп, җитмеш ел онытылып торган Г. Исхакый иң беренче туган туфрагына, үз нигезенә кайтып төште. Ул шулай булырга тиеш тә иде. Әмма Г. Исхакыйның музеен Казанда да ачу зарури. Казанның дүрт йортлы урамына Гаяз Исхакый исеме бирелде. Шуннан башка башкалабызда татарның бу олуг затын искә төшерә торган бернәрсә дә юк. Мәркәзебездә Г. Исхакый кебек бөекләргә музей ачу – ул һәркемгә милләтебезнең дә бөеклеген күрсәтүче символ булыр иде.

Булачак музейның бинасын да эзләп торасы түгел – әдип үзе укыган Күл буе (Касыймия) мәдрәсәсе. Бу бина Мәрҗани урамында (28 нче йортта) урнашкан. Элек шәкертләр сабак укыган һәм йокы бүлмәсе булган зур бүлмәләр нәкъ музей залларын хәтерләтә. Шунда ук һәйкәлен дә куярга була. Бинаның тирә-ягы туристлар йөри торган маршрутка керә бит. Г. Исхакыйга истәлек тактасы куярлык урыннар да бар. Пушкин урамында «Марусовка» дигән йортта М. Горький да, Г. Исхакый да торган. Истәлек тактасы Горькийга куелган, янәшәсендә Исхакыйга да кирәк бит. Апанаевларның «Доходный дом» дип аталган йортында 1907 елда Г. Исхакыйны кулга алалар, әйберләрен тәяп китәләр. Истәлек тактасын шунда да куярга кирәк. Казаннан Яуширмәгә барган вакытта зур юлда музей барлыгы турында зур элмә такта эленсә, азмы-күпме музейга да, авылга да, әдипкә дә шөһрәт булыр иде.

Г. Исхакый – татар әдәбиятына идеал алып килгән язучы, татарның күңел төпкелендә яткан хыялын – милли бәйсезлек, дәүләтчелек идеясен – күтәреп чыккан зат. Аңа 140 ел, әмма аның бөтен иҗатында бүгенге көн проблемалары – мәңгелек идеаллар чагыла.

## «ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ДАҺИ БЕР ӘДӘБИЯТЧЫ, СӘЛӘТЛЕ БЕР МӨХӘРРИР, ЯЛКЫНЛЫ БЕР ИНКЫЙЛАБЧЫ ИДЕ»

***М.Р. Гайнанова*** *(Казан)*

Начало XX века характеризуется как расцвет татарского общества, образованием партий, татарские деятели стремятся добиться лучших условий для своей нации в российском обществе. В это время появляется значительный слой татарских деятелей, выступающих за права татарского народа и к таким интеллектуалам мы относим Садри Максуди и Гаяза Исхаки. В статье описывается дружба этих известных деятелей. Также в работе представлена активная политическая работа джадидистов Максуди и Исхаки в России до 1917. На основе воспоминаний Габдуллы Баттал-Таймаса, Гали Акыша раскрывается знакомство Садри Максуди и Гаяза Исхаки, рассматривается жизнь и деятельность в Турецкой Республике, дается анализ письмам Гаяза Исхаки. В статье автором дается общая оценка деятельности татарских деятелей в Турции.

**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Садри Максуди, Россия, Миллет меджлисе, эмиграция, Турецкая Республика, Гали Акыш.

The beginning of the XXth century is characterized as the flowering of the Tatar society, the formation of parties, the Tatar figures strive to achieve better conditions for their nation in Russian society. At that time there appears a significant layer of Tatar figures who are in favor of the Tatar people rights and we attribute Sadri Maksudi and Gayaz Iskhaki to such intellectuals. The article describes the friendship of these famous figures. Also the work represents the active political work of the dzhadidists Maksudi and Iskhaki in Russia until 1917. Based on the memoirs of Gabdulla Battal-Taymas, Gali Akysh, the acquaintance of Sadri Maksudi and Gayaz Iskhaki is revealed, life and activity in the Republic of Turkey are examined, and the letters of Gayaz Iskhaki are analyzed. The author gives an overall assessment of the activities of Tatar figures in Turkey.
**Key words:** GayazIskhakiy, Sadri Maksudi, Russia, Millet Mejlis, emigration, the Republic of Turkey, Gali Akysh.

1955 елның май аенда Гали Акышның чакыруы буенча аларның Әнкарадагы өйләренә кунакка Садри Максуди килә. Гали бәйнең әнисе белән кыз туганнары матур итеп өстәл хәзерләп кунакларны каршы алалар. Чәй арасында сүз мәрхүм Гаяз Исхакыйга килде дип яза Гали Акыш. Шул вакыт Садри бәй шуларны сөйләде: «Гаяз, бөек бер галим түгел, ул эшкәртелмәгән бер алмаз иде. Ул иң элек даһи бер әдәбиятчы, сәләтле бер мөхәррир һәм ялкынлы инкыйлабчы» диде. Садри бәй Гаяз Исхакыйны бик югары бәяләде. Казанлы галимнәребездән профессор Ибраһим Нуруллин дә Гаяз бәй турында нәкъ шундый шәкелдә аңлатты. Фәкать сталинист Камил Фасиев даһи әдәбиятчыбызга карата гел хурлау һәм гайбәт сүзләрен әйтүдән котыла алмады [8: 79].

Гали Акышка килгәндә, ул – татар милли хәрәкәте каһарманы. Эмиграциядәге татарларның «Милли мәркәз» җитәкчесе итеп 1954 елда Г. Исхакый тарафыннан билгеләнә. Һәм шул елдан башлап үзенең «Азатлык» радиосы аша алып барган тапшырулары белән бөтендөньяга таралып яшәгән татарларны берләштерү, алардагы милли хисне үстерү, туган телне саклап калу юлында дәрәҗәле эш алып баручы шәхес иде [3: 6–7].

Гали Акыш «Aklımda kalanlar...» китабында Садри Максудины Гаяз Исхакыйның якын дусларыннан иң беренчесе итеп атый. Гаяз бәйнең иң якын дусларыннан өч кеше иде: боларның беренчесе Садри Максуди. Белгәнебезчә, Садри Максуди белән Гаяз Исхакый яшьлек елларыннан бирле дуслар, фәкать 1905 елда Русиядә сәяси партияләр оешканнан соң Гаяз бәй үзе өчен Социаль инкыйлаб партиясен сайлый. Садри Максуди исә Конституцион демократлар партиясенә керде. Сәяси фикерләре төрле булуларына карамастан ике бөек шәхеснең арасындагы дуслык бетми. Шулай итеп 1940 елдан 1953 елга кадәр Садри Максуди белән Гаяз Исхакый арасындагы дуслык җепләре өзелмичә дәвам итте [8: 57].

Югарыда әйтеп узылганча, Г. Исхакыйның өч якын дусты була дип белдерә Гали Акыш. Икенче якын дусты Төньяк Кавказның мәшһүр каһарманы Шамил Шәйхнең оныгы Сәед Шамил иде. Исхакыйның тууына 100 ел уңае белән хәзерләнгән «Мөхәммәд Гаяз Исхакый – тормышы һәм эшчәнлеге» исемле китапта Сәед Шамил белән аның дуслыгы хакында мәгълүмат бар. Бу ике дус арасындагы самими мөнәсәбәтләр «Прометей» заманында да дәвам итте.

Гаяз бәйнең өченче чын дусты Билал бәй[1]. Төрек милләтеннән булган бу кеше Гаяз бәйнең идеализмына, әдиплегенә нык әһәмият бирә торган иде.

[1] Трабзон фольклорын өйрәнү буенча фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф министрлыгында да инспектор булып эшләгән кеше.

Шул ук вакытта инсани фикерләренә дә хәйран булган кеше. Профессор Әкдәс Нигмәт Курат, профессор Рәшит Рәхмәти Арат, филология докторы Хәмит Зөбәер Кошай, доктор Исмаил Зыя Тирегүл, укытучылар Касым Байчан, Хидаят Йашын, Кәбир Канбир, генерал Фикри Алтан, инженер Кемаль Локман, Азәрбайҗан төркиләренең лидеры Мәхмәт Әмин Рәсүлзаде, Мирза Бала, Абдулвахар Йуртсевер дә аның дуслары иде. Фәкать Садри Максуди, Сәед Шамил һәм Билал бәй аның иң якыннары иде [8: 58–59].

1954 елның июлендә Садри Максуди кайгылы хәбәр ала: ул үзенең кыйммәтле, якын, күптәнге дустын югалта. Мәшһүр татар язучысы, милли җанлы Гаяз Искакый Әнкарада вафат була [1: 231]. Садри Максудиның бу хәбәрне йөрәгеннән авыр кичерүен кызы Гадилә Айда үз китабында билгеләп үтә.

XX гасыр башында татар милли хәрәкәтенең идеологларына, лидерларына әверелгән, гомерләрен татар халкының бәйсезлегенә, якты киләчәгенә багышлаган, ә соңыннан Төркиядә үз урыннарын тапкан шәхесләребез Гаяз Исхакый белән Садри Максуди яшьлек елларыннан бирле дус иделәр. Алар бергә Учительская школада белем алалар, икесе дә монда рус әдәбияты, рус теленә тәрҗемә ителгән дөнья әдәбияты белән танышалар. Дустыннан калышмыйча яшь Садри дә беренче әсәрләрен иҗат итә, аның «Мәгыйшәт» романының беренче басмасы 1898 елда, икенчесе 1914 елда басылып чыга. Әлеге әсәре белән ул татар милләтенең киләчәге хакындагы уйлануларын күрсәтергә тырыша. Парижда укыган елларында «Йөз ел соңра» исемле әсәрен яза. Билгеле булганча, Садри Максуди сәясәттә, хокук дөньясында үз урынын таба, ә Гаяз Исхакый исә мәшһүр язучы булып танылa. «С. Максуди школаны 1901 елда, ә Гаяз Искахый 1902 елда тәмамлыйлар, икесе дә башлангыч мәктәптә рус теле укытуга хокук бирә торган дипломнар алып чыгалар. Ләкин алар икесе дә бу юл белән китмиләр, рус теле укытучысы булу юлына басмыйлар. Аларның максаты – үз белемнәрен үстерү, “милләткә хезмәт итү”. Дөрес, Гаяз Исхакый, школаны тәмамлагач, башта ысулы җәдид мәктәбендә укытучы булып эшли, шул ук вакытта аны авылның имамы итеп тә сайлап куялар. 1905 елгы революция башлануга ул, имамлыгын ташлап, милләткә хезмәт итү юлына баса, сул сәясәтче, журналист-публицист булып китә. Милли азатлык юлын сайлаган Гаяз Исхакыйны патша ялчылары кулга ала, төрмәләргә яба, сөргеннәргә сөрә. Тиз арада ул танылган көрәшче-сәясәтчегә, “милләт хадименә” әйләнә, әдәби иҗат эшен дә дәвам итә, дистәләгән милли хикәя, роман, пьесалар яза... Ә аның сабакташы Садретдин Максуди икенче юлдан китә» [2: 28–29]. Ике дусның юллары Учительская школаны тәмамлаганнан соң бераз аерылып торса да, 1906 елдан соң сәяси тормышта алар татар халкының киләчәге өчен, дин һәм мәдәни тормышындагы кыенлыкларны хәл итү өчен әлеге ике шәхес актив хезмәт итә башлый. 1917 елгы инкыйлаб барлык кешеләрнең, шәхесләрнең карашларын, тормышларын үзгәртә. Милли-мәдәни мөхтәрият барлыкка китерү идеясен яклаучылар да, каршы килүчеләр дә була. Казанда үткәрелгән Икенче Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда бу мөхтәриятнең нигезләре карала һәм кабул ителә. 20 ноябрьдә Уфада Милли мәҗлес ачыла. Әлеге мәҗлестә татар халкының барлык милләтпәрвәрләре катнаша дисәк, ялгыш булмас, шул исәптән Гаяз Исхакый да. Милли-мәдәни мөхтәриятнең төп нигезләре итеп түбәндәге мәсьәләләр санала: Русия хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның милли эшләре рус халкының милли эшләре кебек үк бер дәрәҗәдә хокуклы; Русия хөкүмәтенең татар халкының дин һәм телгә, милли мәдәниятка бәйле эшләргә катнашмавы һәм аларны хәл итү татар халкының үз эше булу мөхтәриятнең төп әсаслары итеп билгеләнә. Милли мәҗлеснең эшчәнлеге хакында, әгъзалары хакында тулы белешмә Надир Дәүләтнең «1917 Октябрь инкыйлабы

вә төрк-татар Милләт Мәҗлесе (Эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе. 1917–1919)» исемле хезмәтендә бирелә [4].

1918 елда Милли Идарә куып таратыла. Милләт Мәҗлесе әгъзаларының күпчелеге большевиклар тарафын сайлый, бер өлеше (Ә. Максуди, Ф. Кәрими, С. Мәмлиев, Ш. Алкин, Г. Салихҗан, Н. Корбангалиев һ.б.) большевиклар тарафыннан җәбер-золым күрәләр, атып үтерелә. Чит илгә чыгып кача алганнар: Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Закир Кадыйри, Габдулла Баттал, Зәки Вәлиди һ.б.

Качарга мәҗбүр булган Садри Максуди 1918 елда Уфадан Мәскәүгә китә, анда Гаяз Исхакый белән мөселманнарның Милли идарәсен ябуга протест белән Совет хөкүмәтенең Югары органнарына шикаять җиткерәләр... Бу катлаулы көннәрдә Садри Максуди һәм Гаяз Исхакый кеше күзеннән ераграк булырга тырышалар, алар Мәскәүдән икәүләп Түбән Новгород вилаятенең мөселман төрекләр яши торган авылларына юл тоталар. Биредә аларның юллары аерыла. Төрмәләрдә, сөргеннәрдә «чыныккан», күпне күргән Гаяз Исхакый кыяфәтен үзгәртеп, крестьян киеме киеп фронт линиясен узып Казанга килә. Бу вакытта Казан чехославаклар кулында була. Аннан, чехлар восстаниясе үзәге булган Самарага юл тота [2: 41]. Садри Максуди дә өс-башын үзгәртеп, сакал-мыеклар үстереп Петербургка килә. Монда аңа дусты Муса Бигиев Финляндиягә чыгарга ярдәм итә. Финляндиядә 9–10 ай яшәгәннән соң, 1919 елның май аенда ул Парижга килә, чөнки монда Париж тынычлык конференциясе (18 гыйнвар 1919 – 21 гыйнвар 1920) уза иде. Бу конференциядә Гаяз Исхакый һәм Фуад Туктаров та катнашырга тиеш булалар, тик алар виза, юл белән бәйле мәсьәләләр өчен Парижга апрель аенда гына килеп җитәләр. Монда аларны Садри Максуди каршы ала һәм ул версаль килешүенә Русиянең төрек-мөселманнарның хокукларын яклау буенча меморандумы белән мөрәҗәгать иткәнен дусларына аңлата. Әлеге меморандумда Садри Максудиның имзасы гына куелган булырга тиеш, чөнки алда әйтеп кителгәнчә, Г. Исхакый белән Ф. Туктаров әлеге меморандумга кул куярга соңга калган булалар. Моннан тыш, С. Максуди җитәкчелегендәге һәйәт әгъзалары төрле халыкара җыеннарда катнашып, татар халкының проблемалары белән Аурупа һәм дөнья җәмәгатьчелеген таныштыралар. Шул исәптән, Милләтләр Лигасына да мөрәҗәгать итәләр. Шулай ук алар 1921 елда Париждагы конференцияләрдә катнашалар. Тик матди һәм мәгънәви яктан ярдәмсез калгач, Милли Мәҗлеснең соңгы органы булган солых һәйәте дә 1922 елда тарала [7].

Шулай итеп, Милләт Мәҗлесенең эше тулаем туктатыла. С. Максуди һәм Г. Исхакыйның тормыш юлы, эшчәнлекләре чит илләрдә дәвам итә башлый. Аларның исемнәре туган җирләрендә тик 1990 еллардан соң гына яңгырый башлый, татар милләте асыл улларының хезмәтләре, эшчәнлекләре белән үзгәртеп кору вакытында таныша алу мөмкинчеленә ия була.

Парижда эшләре уңмагач, Садри Максуди Русиядән гаиләсен чыгару юлын эзли башлый. Дуслары, туганнары, Муса Бигиев ярдәме белән ул 1922 елда гаиләсе белән Финляндиядә күрешә. 1923 елда алар Берлинда яши башлый. Бу вакытта Германиядә аларның дуслары да тукталган була, милләттәшләрнең Максудиларның өйләрендәге очрашуларын Габдулла Баттал-Таймас китабында матур истәлек итеп тәкъдим итә: «Максудиның хатыны кунакчыл, ачык йөзле мөхтәрәм Камилә ханым кунаклар өчен күп итеп “Төркестан пылауы” пешергән. Безгә, Берлинның арзанлы ашханәләрендә тамак туйдырып йөрүчеләр өчен, өй шартларында, тәмле итеп әзерләнгән пылау җәннәт ашы кебек тәмле булды. Өстәлдә тау кебек итеп куелган бу пылауны без, ач бүреләрдәй, күз ачып йомганчы диярлек сыпырып та куйдык» [2: 49]. Әлеге

кечкенә мисал белән татар дусларының бер-берсе белән тыгыз элемтәдә торулары, ярдәмчел булулары, татар хатын-кызларына хас кунакчыллыклары яхшы үрнәк итеп күренә.

Әхмәтзәки Вәлиди Тоган үз хезмәтендә ике яшьтәшнең дуслыгын болай аңлата: тәсадефка (бердәмлеккә) карамастан Садри бәй Гаязны, Гаяз да Садри бәйне самими яратмады, хөрмәт итмәде [9: 22]. Әлеге фикер белән килешеп булмый, югарыда әйтеп үтелгәнчә, Максуди Гаяз Исхакыйның якын дусты дип Гали Акышта язып калдыра, Габдулла Баттал-Таймас та аларның яхшы мөнәсәбәтләрен ассызыклый һәм Исхакыйның кызына язган һәр хатында диярлек ул Максудиләр гаиләсе турында хәбәрләр җиткерә.

Кызганычка каршы, бүгенге көндә безнең кулларда Садри Максудиның язган хатлары, көндәлекләре юк. Аның хис-кичерешләре, уй-фикерләре турында Гаяз Исхакыйның хатлары аша гына бөртекләп өйрәнә алабыз. Әлеге хатларда бу ике дусның никадәр бер-берсенә ышанычы, хөрмәте сизелә дип әйтсәм һич ялгышмам. Мәсәлән, *«Садри! Синең хатыңны алып бик сөендем. Сине күптән бирле эзләсәм дә, һичбер йирдән хат-хәбәр юк иде. Җәй көне синең кайдалык хакында Япониядән Истанбулга, Кырымга, Финляндиягә мәктүбләр яздым. Берничә мәртәбә телеграмма сукдым. Һичбер җавап булмады...Шуның өчен синең табылуың миңа үлгәннән соң терелү кебек тоелды.Югары дәрәҗәдә сөендерде...»* (1920 ел, 16 гыйнвар) [6: 28]. *«Садри! Синең кәефсез мәктүбеңне алдым. Син тәэвил иткәнчә булмаса да, сиңа шундый хис калдырган икән, әхвале рухияң шундый булгандыр шул...Әйдә, бик үк төшәргә ярамый әле. Ни булса да булыр, Аллаһ ярдәм итәр...»* (1923 ел, 3 октябрь) [6: 35]. *«Садри тәмамән савыкды. Муса әфәнде*[1] *тагы хәлсезләнгән. Зәки Вәлидидә утырганга, барып күрә алганым юк...»* (1948, 3 июнь) [6: 134]. Кызы Сәгадәткә язган хатларында Садри Максуди белән булган дуслык җепләрен аңлый алабыз. *«Камилә ханым*[2] *синдән мәктүб алып сөенгән. Җавап язачагым, дип, миндән адресыңны яздырып алды. Садри бәй, инде адрес язылды, бер мәктүб язучыны гына табарга калды, дип шака итде. Камилә ханым, язам, үзем язам, дип, бик ихласлы җавап бирде. Бакалым»* (1949, 14 апрель) [6: 187]. *«Кичә шимбә көн Садри бәйләргә китдем. Чәй эчдем. Акшам йәмәгенә дә быракдылар. Камилә ханымның гүзәл ләззәтле пилмәнендән тулы бер табак йидем. Бераз сәбзә дә,йөзем дә ашадым, каһвә дә эчдем. Һичбер агырлык хис итмәдем»* (1953, 15 февраль) [6: 299]. *«Садри бәй монда булганга, һәфтәдә бер-ике көн аларга барып, Камилә ханымның тәмле ашын ашап, Садри бәй берлә сөйләшеп, күңелемне ачып киләм»* (1953, 13 декабрь) [6: 323]. Гаяз Исхакый кызы Сәгадәт Чагатайга язган һәр хатында диярлек Садри Максуди, аның тормыш иптәше Камилә ханым, кызлары Гадилә һәм Наилә турында хәбәрләр җиткерә торган була.

Мөһәҗирлектә Гаяз Исхакыйның тормышы һич тә җиңел булмый. Гали Акыш «Хатирәләр...» хезмәтендә Төркия Җөмһүрияте хөкүмәте 1950 елдан соң Гаяз Исхакыйга аерым игътибар бирә башлады. 1940 нчы белән 1950 нче еллар арасында дәвам иткән Исмет Инөнү чорында миллиятчеләргә гадәттә дикъкать бирелмәде. 1950 елда мәрхүм Мендерес[3] премьер-министр булганнан соң Гаяз Исхакыйның игътибары артты диелә.

Төркиядә яшәгән елларында Гаяз Исхакый рәсми эшкә урнашмады. Төрек мәдәни берлеге исемле ассоциациядә, Идел-Урал, Азәрбайҗан һәм Төркистан

---

[1] Муса Бигиев.

[2] Садри Максудиның тормыш иптәше Камилә ханым.

[3] Аднан Мендерес – Әнкара Хокук факультетында Садри Максудиның студенты. Төркия Җөмһүриятенең 1950–1960 елларда премьер-министры һәм Демократия партиясен оештыручыларның берсе.

темаларына конференцияләр бирә торган иде. Әмма бу озак бармады. Ярдәм вакфыннан олы яшьтәге төрек кешеләренә ай саен 150 лира акча бирелде һәм шул исәптән Гаяз Исхакыйга да. Татар әдибе Истанбулда ялгыз яшәде. Атнада бер көн өен җыештырырга дип бер хатын-кыз килеп ярдәм күрсәткән. Кызы Сәгадәт әтисенә ай саен 100 лира акча җибәреп торган, ул вакытлар өчен бу сумма аз түгел һәм аңа яши торырлык иде дип Г. Акышның истәлекләр китабында бирелә. Гаяз Исхакыйның хасталыгы булса да, кәефе һич бозылмады, ул һәр заман оптимист, юмор хисе белән яши торган кеше иде. Рәссамчы булмаса да, бик күп рәсемнәрне тәнкыйтьләүче дип язганнар аның танышлары. Бер татар рәссам ханымы: «Ничек була инде, үзе язучы һәм яшьле, һәм дә рәссам булмыйча да күп рәсемнәргә бәя бирә ала? Төркиянең танылган рәсем тәнкыйтьчеләре дә бу кадәр белмиләр!» дип еш шаккатып әйтә торган булган. Гаяз Исхакыйның әдәби шәхесенә каршы һичкем дә каршы килмәде, ул һәр заман югарыда иде. Бары тик сәяси лидерлыгына каршы төрле фикерләр әйтелә торды [8: 98–99].

Озын авырудан соң 1954 елны 22 июльдә Гаяз Исхакый вафат була. Үзенең васыятендә, әгәр мәмләкәтебез бәйсезлеге белән кавышса, Казан зиратында Ш. Мәрҗани белән Г. Тукай каберләре арасында күмелүен теләгән. Истанбулны яратканга күрә монда кабере булуы соң теләге иде дип Гали Акыш язып калдыра үзенең хәтирәләрендә. 24 июль көнне меңнәрчә кешенең катнашында мәрхүмнең җеназасы узды. Кабере башында иң беренчеләрдән булып Садри Максудиның, аннары Хасан Агай һәм башкаларның соңгы сүзләре яңгырады. Күз яшьләре белән сөйләгән нотыгында С. Максуди дусты Г. Исхакый белән танышу вакытларыннан башлап гомерләренең якты мизгелләрен искә алды, әдипнең осталыгы, таланты турында, сәяси тормышындагы эшчәнлекләрен сөйләп узды. Гаяз Исхакыйның васыяте буенча Япониядә Казан төркиләре бүләк иткән көмеш кул таягы Садри Максудига бирелә [1: 231–232].

Мәшһүр Гаяз Исхакыйның күпчелек еллары Төркиядә кичә,әлеге яңа мәмләкәтен ярата дип фикер йөртеп була. Аның Ататөрек турында язып калдырган фикерләре, уйлары анализ өчен кызыклы, бу кешегә карата хөрмәте ачык сизелә. Ататөрекнең үлеме белән күп төрек балалары кайгырса да, киләчәктә моңардан да күбрәк төрек балалары Ататөрек Гази пашаның җиңелми торган команданлыгы берлә мактаначаклардыр. Бөек командан, Гази паша, бөек сәяси дәүләт ире Ататөрек бу көн җисмән үлсә дә, төрек балаларының күңелендә ул мәңге яшәячәктер [5: 338]. Г. Исхакыйның бу сүзләре дөрес була, белүебезчә, Төркия Җөмһүриятендә бүгенгә кадәр Ататөрекне бөек илбашчы, бөтен төрек халкының атасы итеп саныйлар. Ә хакимияткә Исмет Инөнү килгәч, Г. Исхакый мондый җөмлә яза: «Без Төркиянең яңа рәисе җөмһүриен йөрәктән котлап, милләт вә Ватан юлында хәерле эшләрендә Алладан муаффәкыять телибез» [5: 341]. Игътибар итсәк, Исхакый милләт вә Ватан дип яза, димәк Төркияне ул үзенең яңа Ватаны дип саный һәм аның киләчәген кайгыртып иң хәерлесен тели. Ватан дип без үзебезгә, җаныбызга якын җирне генә атыйбыз.

Нәтиҗә ясасак, XX гасырның беренче яртысында татар һәм төрек мәмләкәтләрендә безнең шәхесләребез үз эзләрен калдырып китәләр, исемнәре тарихка кереп кала һәм хәзерге көнгә кадәр алар белән бәйле һәр эш һаман актуаль, әле өйрәнәсе, тикшерәсе эшләребез бихисап. Садри Максуди һәм Гаяз Исхакыйның 2018 елда тууыларына 140 ел була. Бу ике шәхеснең дуслыклары, милләттәшләренә ярдәмчеллекләре, намуслы тормышлары бүгенге көн татар иҗтимагый фикерендә матур бер үрнәк булып калачак.

ӘДӘБИЯТ


1. Айда А. Садри Максуди Арсал. М., 1996. 359 с.
2. Баттал-Таймас Г. Ике бертуган Максудила. Казан: Фән, 1999. 144 б.

3. Гали Акыш: милләткә багышланган гомер / төз. Ф.Ю. Гаффарова. Казан: ТФАның Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2005. 116 б.
4. Дәүләт Н. 1917 Октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт Мәҗлесе (Эчке Русия вә Себер мөселманнарның Милләт Мәҗлесе. 1917–1919). Казан: Җыен; Милли китап, 2008. 384 б.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 12 том: публицистика / төз., текст, иск. һәм аңлат. әзерл. З. Мөхәммәтшин. Казан: Татар кит. нәшр., 2012. 417 б.
6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 14 том: хатлар һәм автобиографик язмалар / төз., текст һәм аңлат. әзер., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 479 б.
7. Исхакый Г. Беренче Милләт мәҗлесенең 15 еллыгы // Яңа милли юл. 1933. № 4.
8. Akış A. Aklımda kalanlar. Hatıralar – konuşmalar. Ankara, 2002. 308 s.
9. Togan-Velidi Z. On yedi kumaltı şehri ve Sadri Maksudi Bey. İstanbul, 1934. 60 s.

## «ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ» ӘСӘРЕНДӘГЕ ГОЛЯМАЛАР

***А.М. Гайнетдинов*** *(Казан)*

Статья посвящена анализу духовных деятелей, которые описаны в произведении Гаяза Исхаки «Ике йөз елдан соң инкыйраз» («Исчезновение через двести лет»). В этом произведении резко критикуются ишаны, которые обманывали простой народ и неправильно трактовали религию ислам. Именно кадимистов Г. Исхаки считал препятствием на пути национального прогресса, т.к. он подробно описал какой вред приносит обществу консервативная часть духовенства. Можно утверждать, что некоторые идеи, мысли Г. Исхаки позаимствовал у выдающихся религиозных реформаторов Г. Утыз Имяни, Г. Курсави, Ш. Марджани, которые также уделяли большое внимания на возрождению национального самосознания, духовной культуры и нравственности. Произведение «Ике йөз елдан соң инкыйраз» оказало влияние и на творчество, деятельность других поэтов, писателей, ученых.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, вырождение, ученые, ишаны, ислам.

The article is devoted to the analysis of spiritual figures, which are described in the work of Gayaz Iskhaki «Ike yaz yeldan sok inkyraz» – «Degradation two hundred years later». This work sharply criticizes the Ishans, who deceived the common people and misunderstood the religion of Islam. G. Iskhaki considered an obstacle to the national progress the kadimists, because he described in detail what harm the conservative part of the clergy brings to society. Some ideas of Iskhaki borrowed from the outstanding religious reformers G. Utiz Imani, G. Kursavi, Sh. Mardjani, who also paid much attention to the revival of national identity, spiritual culture and morality. The work «Degradation after two hundred years» had an impact on the work of other poets, writers, and scholars of religion.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, degradation, scholars of religion, Ishans, Islam.

Гаяз Исхакый тормышы, эшчәнлеге, иҗаты ислам дине белән уралган: ул үзен мөселман дип санаган, Чистай һәм Казан мәдрәсәләрендә гыйлем алган, соңрак Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыткан, аның ике ягыннан да бабалары мулла вазыйфаларын башкарган. Дини мохитта үскәнгә, эшләгәнгә күрә, Г. Исхакый үз заманындагы дини тормыш белән бик яхшы таныш, бөтен дини-әхлакый проблемалардан хәбәрдар булган. Үзенең байтак әсәрләрендә ул кадимче дин әһелләренең бик күп төрле тискәре якларын ачкан һәм аларның милләт үсеше өчен киртә булып торуын исбатларга тырышкан. Руханиларның наданлык белән сугарылган гамәлләре белән килешәсе килмичә, Г. Исхакый 1902 елда, кулына каләм алып, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле «ачы телле» фантастик-публицистик повестен язган. Ул басылып чыгуга ук, әлбәттә, дин әһелләре аннан риза булмаганнар, чөнки әсәрдә ислам дине руханилары бик нык тәнкыйтьләнгән. Г. Исхакыйга хәтле әле бер әдипнең дә дин әһелләрен матур әдәбият аша шундый масштабта тәнкыйть утына тотканы юк иде дияргә мөмкин.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә милләтнең үсешен тоткарлый, артка өстери һәм ахыр чиктә бетүгә китерә торган төп биш җитди сәбәп аталган, шуларның иң беренчесе итеп иске карашлы руханилар икәнлеге күрсәтелгән: «Мин һәр эштә "голяма"ның манигы тәрәкъкый икәнен күргәч, милләтне тәрәкъкый иттерәсемез килсә, аны башка милләтләр арасына кертәсемез килсә, аңа манигъ булган "голяма" сыйныфының сүзенә илтифат кылмаска, үземезнең ыштан алудан башлап кыз бирү, угыл өйләндерү, самавыр төзәттерү эшләремезгә кадәр катышуларын бетерергә тиешлегенә һәм аларның сыйныфларына бер артыклык (привилегия) бирмәенчә, кешесенә күрә генә эш йөртеп, алар хакындагы хазир гавамымызның фикерен үзгәртү кирәкле уена йеттем [2: 155].

Күргәнебезчә, әлеге әсәрендә ул «голямалар» сыйныфын аерып чыгарып, аларны һәр эшкә катыштырмаска, һичбер сүзләренә игътибар бирмәскә өнди. Хәтта Испания, Бохара мәмләкәтләре элек иң зур дәрәҗәләргә ирешкән булса да, хәзер шул надан голямалар аркасында иң түбән дәрәҗәгә төшкәннәрен искә алган. Әсәр башында автор башта ни өчен шулай эшләгәнен язмакчы, аңлатмакчы булган, ләкин соңыннан нәрсәгә мин алар алдында акланырга тиеш, дип ул уеннан кире кайта. Әмма ул аларга ниндидер шәхси дошманлык өчен түгел, бәлки наданлыкны яклаганнарына күрә шулай тәнкыйтьләргә мәҗбүр булган.

Дөрестән дә, XIX йөздә кадимчеләр халыкка әхлакый тәрбия бирү, милләт файдасын кайгырту урынына, еш кына башка төрле вак фикыһ мәсьәләләре хакында бәхәсләшеп, тарткалашып көн уздырганнар. Мәсәлән, җәйге көннәрдә ястү намазын уку мәҗбүриме, юкмы, дип сүз көрәштергәннәр, теге яки бу фикер белән килешмәү өчен генә бер-берсен кәферлеккә чыгарганнар. Бу намаз хакындагы тарткалашулар әле бик озак дәвам итәр иде, әмма галимебез Ш. Мәрҗани «Нәзурәтел-хаккый фи фәрадыйятил-гыйшаи вә ин ләм ягыйбәшшәфәкъ» («Шәфәкъ кызыллыгы бетмәсә дә, төнге намазның фарызлыгы өстән төшмәве хакында хакыйкатьне карау») исемле китап язып, бәхәскә нокта куйган, ястү намазы җәйге озын көннәрдә дә фарыз, дип фәтва биргән һәм төрле нык дәлилләр китереп, үз фикеренең дөреслегенә инандырган. Р. Фәхретдин шул чорны «схоластик дәвер» дип атаган һәм ул Оренбург шәһәре төзелүеннән алып һиҗри ундүртенче йөз башына, ягъни милади белән XIX гасырның ахырына кадәр булган аралыкны үз эченә алган: «Бу вакытта Русия дәүләте дин иреге игълан иткән һәм ислам динен рәсми рәвештә тануыннан, Бохарадан кайткан галимнәр хәтта олы мәдрәсәләр төзеп, тулы ихтиярлары белән укыта башлаганнар. Бохарада рәсми дәресләр юнан (борынгы грек) методлары, китап кереш сүзләре, шәрехләрнең һәм хашияләрнең (аңлатмаларның) бәхәс һәм сүз көрәштерүләр булганлыктан, боларны үрнәк итеп тоткан безнең мәдрәсәләребездә Коръән һәм хәдис гыйлемнәре белән җитди рәвештә шөгыльләнә алмаганнар» [9: 51]. Р. Фәхретдин, бу вакытта инде Г. Курсави, Г. Түнтәри, Ш. Мәрҗани кебек шәхесләр хәдис китапларыннан дәрес бирә башласалар да, әле халыкның күпчелеге һаман схоластикадан чыгып бетә алмаган, дип санаган. Г. Исхакый нәкъ менә шул заманда яшәгән дин әһелләрен күздә тоткан дип уйларга кирәк.

Гомумән, Ш. Мәрҗани кешеләрнең дини авторитетларга сукырларча иярүен нык тәнкыйтьләгән, ягъни тәкълидтән тыйган, кадимчеләрне фаш иткән. Ул заманда Коръән-хәдисне гади кешегә аңларга һәм аларга мәгънә бирергә ярамый, дигән фикер куәтле булса да, галим иҗтиһад капкаларын ачкан һәм башкаларны да шул капкадан керергә чакырган. Г. Исхакый галим Ш. Мәрҗанине татарларны схоластика йокысыннан уятуда зур роль уйнаганлыгын ассызыклаган, аны «милләтебезне яңа нигезгә корышучы, милләтебезнең киләчәк җил-давылда саклануы өчен аның тамырын тазартучы бер милли хезмәтчебез, бер ил төзүчебез» дип атаган [5: 10]. Шулай ук ул, галимнең байгураларның

ахмаклыкларын җиңеп чыгуын искә төшереп, үзенә көч алган [5: 10]. Димәк, Г. Исхакый күпмедер дәрәҗәдә Мәрҗанигә ияргән һәм дини наданлыкка, кадимчелеккә каршы көрәшүендә аннан үрнәк алган, җәдидчегә әверелгән.

Г. Ибраһимов та бөтен ислам дөньясын күп бәлаләрдән коткаручы шәхес итеп Ш. Мәрҗанине санаган. Дөрес, аңа хәтле Габденнасыйр Курсави да халыкның акылына салынган богауны өзәргә тырышкан, тик, Г. Ибраһимов фикеренчә, аның халыкка тәэсире алай ук көчле булмаган [4: 13]. Үзләренең иреклe карашлары өчен мәшһүр дини реформаторларыбызга кадимчеләр тарафыннан «кяфер», «имансыз» мөһере сугылган.

Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә мәдрәсәләрдә шәкертләрнең гомерләре, кирәкмәгән нәрсә укып, әрәм булуына һәм аларның бер эшкә ярамый торган кешеләргә әверелүләренә борчыла. Руханилар дини уку йортларында дөньяви белемнәрне һәм рус телен укытмауга теш-тырнаклары белән каршы торганнар. Өстәвенә, русча укыту – хәрам, дип надан муллалар халыкка акылсыз фәтваләр биргәннәр. Алар гади халыкны бик нык куркуга салалар һәм кешеләр туган илләреннән күченеп китә башлаганнар һәм һиҗрәтләрендә күп җәфалар күргәннәр. Шул рәвешле, Г. Исхакый фикеренчә, надан муллалар аркасында халык күпме авырлыклар татырга мәҗбүр булган. Кадимче муллаларның ысуле җәдидкә, русча укытуга каршы булу сәбәбен шунда күрә: гади халык китап укый башласа, руханиларның сүзләренә колак салучы булмаячак, үзләренчә эшли башлаячаклар, шуңа күрә җәдидчә укыту – хәрам, дип фәтва биргәннәр һәм үзләре белән бу мәсьәләдә килешмәүчеләрне көферлеккә чыгара башлаганннар. Шул рәвешле үз файдаларын гына кайгыртканнар. Бу инде бөтенләй ислам өйрәтүенчә булмаган, кешене имансызлыкта гаепләргә ярмаганлак хакында Р. Фәхретдин болай кисәткән: «Шуның өчен бер мөселман никадәр галим һәм үзенчә никадәр диндар булсын, башка бер мөселманның диненә хуҗа булырга, аның иманы, мәзһәбе һәм ахыргы хәле хакында хөкем итәргә хакы юк. Галим затларның вазифалары халыкларны диннән сөрү түгел, бәлки дингә керту һәм якынайтудыр».

Г. Ибраһимов та үзе укыган мәдрәсәдә ни рәвешле укытканнарын кыскача әйтеп узган: анда схоластик белемнәр биргәннәр, урта гасырда яшәгән галимнәрнең сүзләренә сукырларча ияреrгә өйрәткәннәр, төрле гыйбарәләрне аңламыйча, фикерләмичә, ятлату белән мәшгуль булганнар, «әшгари», «хәнәфи» сүзләре белән шәкертләрнең йөрәген һәм акылын томалаганнар [4: 13].

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә курчак туе тасвирланганда, Г. Исхакый никах укучы мулланың Коръәнне үзенә ошаган җирләрне яхшылап, сузып укуын, үзенең нәфесенә туры килмәгән җирләрен бөтенләй төшереп калдыруын сурәтләгән. Аның аша автор үз заманындагы дин әһелләренең типик портретын биргән. Элекке руханилар шул рәвешле Коръәннең үзләре теләгән аятьләрен генә кабул иткәннәр, шулай ук Коръән һәм хәдисләргә үзләренә кирәк булган мәгънә биргәннәр.

Г. Исхакый белдергәнчә, иске карашлы голямалар халыкка бер файда китерә алмаганнар, тик яңа тарикатьләр, яңа ишанлыклар, яңа ялган карашлар, Иблис үзе дә белмәгән хәйләләр генә тудыра алганнар. Автор иске карашлы голямалар дигәндә, нигездә, ишаннарны күздә токан, татар руханилары уйлап чыгарган иң зур афәт итеп ишанлыкны санаган һәм аны милләт бетүенең төп сәбәбе итеп күрсәткән: «Яурупа халкы чыбыксыз телеграфлар, телефоннар эшләтүне кәшеф кылдылар. Әмма без аннан да зур нәрсә кәшеф иттек. Ул нәрсә дисеңме? Ул – ишанлык!! Шундый нәрсә ул, әгәр ул бер кешедә булса, дөньяның һәммә тәрәкъкыяте бер якта торсын! Ул сиңа дәүләт бирә! Ул сиңа дәрәҗә бирә! Ул сиңа, кирәксә, фатиха, алырга теләүчеләргә гүзәл-

гүзәл хатыннар бирә! Хасыйле җаның ни тели шуны бирә! Яурупа голямасы безнең шәрык халкын хәйләкәр, үткен таифә дигән сүзләренә мин моңарча ышанмый идем. Моннан соң ышандым, ышанмый хәл дә юк. Телеграф берлән халык берлән сөйләшеп кенә була. Буның берлән бөтен халыкны үзенә кол итеп була. Моннан зур тагы ни эш бар?!!» [2: 181–182].

Г. Исхакый ишанлыкны фәхеш һәм зина кебек начарлыклар белән бер рәткә куйган һәм аларның агуларын эчкәнгә халык һәлакәткә дучар булган, дип язган. «Ике йөз елдан инкыйраз» әсәрендә Җәгъфәр атлы герой «Ишанизм и его подследствия» исемле бер китап укый. Анда болгарларның, ягъни татарларның бетүенә нәкъ менә шул ишанлык сәбәпче икәнлеге язылган. Әдип, моның белән генә чикләнмичә, аны хәтта урта гасыр мәҗүсилеге дип атаган. Ишанлык «шулкадәр гайрәтле, эшлекле, тырышчан болгарларны бернигә ярамаслык ялкау сыер төсле, хайванлык дәрәҗәсенә төшерергә ишаннар гына сәбәп булган иде» [2: 216]. Димәк, Г. Исхакый, болгарларга ишаннар китергән кадәр зарарны бер сыйныф та китермәгән, дип санаган.

Суфи тарикатьләре Урта Азиядән татарларга үтеп кергәч, әхлакка өйрәтә дип, кешеләр шуларга керә башлаганнар, әмма аларның әхлаклары, киресенчә, бозылган гына. Моның сәбәбен Г. Исхакый «һәр начарлык намаз укыгач бетә, ишаннар – оҗмах юлын күрсәтүчеләр» дигән беркатлы ышануда күргән, чөнки җәмгыятьтә, ишанга кергән кеше никадәр гөнаһлар эшләсә дә, кыямәт көнендә котылыр, дигән ялгыш караш киң таралган иде. Автор фикеренчә, ишаннар, киресенчә, халыкны тәмугка гына алып баралар һәм кыямәт көнендә һичшиксез җәзаларын алачаклар. Г. Исхакый кебек галим Р. Фәхретдин дә шәехләр, ишаннар һәм вәлиләр хакында «галәмдә идарә итәләр, үзләреннән ярдәм сораучыларга һәм үз мәсләкләрендә булган мөритләргә мәгънәви сурәттә ярдәм бирәләр, хәтта каберләргә дәфен ителгәч, сөаль фәрештәләре килгән сәгатьләрдә дә хәзер булалар һәм мөритләргә булышлык кылалар, шуның өчен алардан ярдәм сорау һәм ялваруда файдалар бар» дип ышануларны арттыру, адашу һәм зур ялгышу дип санаган [8: 163]. Гомумән, ул үзенең «Җәвамигыль-кәлим шәрехе», «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» һ.б. хезмәтләрендә суфи-ишаннарны начар яктан сурәтләгән. Р. Фәхретдиннең ишаннарга карата шундый начар мөнәсәбәттә торуына, Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» фантастик-публицистик повесте дә йогынты ясамыйча калмагандыр, дип уйлыйбыз.

Г. Исхакый үзенең әлеге тирән мәгънәле әсәре аша башка әдипләргә, галимнәргә ишаннарның милләткә китергән зарарларын үтемле итеп аңтата һәм иҗатларына тәэсир итә алган. Мәсәлән, бөек шагыйребез Тукай «Мөридләр каберстаныннан бер аваз» шигырендә «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре телгә алынган:

«Инкыйраз» исемле әсәр безгә гыйбрәт сабагы бирде;
Аһ, моны язган кеше инсан икәндер, белмәдем.
Үземне суфи исәпләп, оҗмахны искә ала идем;
Чынында кадерем эт белән бер икәндер, белмәдем.

Бу озын булмаган әсәрендә шагыйрь ишаннарны милләтне таркатучылар, милләт дошманнары, милләтне бетерүчеләр, милләтне кимерүчеләр, үләксә ашаучы сыртланнар, ә аларга иярүчеләрне исә куяннар, бичаралар, милләтне аздыручылар, ахмаклар, шарлатаннар дип атаган. Гомумән, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» фантастик-публицистик повесте Г. Тукайның байтак әсәрләренә көчле йогынты ясаган һәм «шигъриятенең төп эстетик-фәлсәфи концепциясен төзүдә катнашкан» [7: 88].

Г. Исхакый ишаннар хакында язып калдырган фикерләрне соңрак, ягъни ун елдан соң, халыкка З. Камали җиткергән. Үзенең атаклы «Дини тәдбирләр»

хезмәтендә ул Коръәннән һәм хәдисләрдән дәлилләр китереп: «Ислам динендә силсилә, рәһбаният дигән нәрсә юк. Ягъни ислам динендә ишанлык – тәсаувыф дигән нәрсә юк. Һич курыкмыйча кабатлыйм: ислам динендә ишанлык юк, Аллаһ өйрәткән ислам дине ишанлыктан пакь», – дип язган [1: 59–60]. Шул фикерен галим байтак шәргый дәлилләр, ачык мисаллар күрсәтеп исбатлаган һәм түбәндәге нәтиҗәгә килгән: «Ислам дөньясының кайсы гына җиренә ишанлык аяк басса, һичшиксез шул җирдә исламның гүзәллеге бетте, сафлыгы югалды, әхлакы һәм әдәбе җимерелде, әхлаксыз һәм әдәпсезлек таралды, җитдилек, гайрәт, зарардан саклану, батырлык сыйфатлары сүнде. Ялкаулык, эшсезлек, йөрәксезлек, зарардан сакланмаучылык сыйфатлары үсте» [1: 67].

Г. Исхакый милләт өстенә яуган бөтен бәлаләрнең сәбәбе исламны дөрес аңламаудан килгән, дип санаган. Руханилар фикыһның истинҗа, хәез, нифас кебек вак мәсьәләләрен бик яхшы белгәннәр, ә җитди мәсьәләләрне аңларлык дәрәҗәдә булмаганнар. Г. Исхакый шикелле галим Габдулла Буби да «Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме» хезмәтендә нәкъ шул ук проблемага игътибар итеп, түбәндәгечә язып калдырган: «Соңгы фәкыйһләрнең Коръәндә юк хәез, нифас хөкемнәренә караган йөзләрчә сәхифә язулары хәлдә, Коръәннең эче тулы туры килгән хөкемнәргә карамаулыкларына сәбәп тә менә бу тәкълид. Болар фикыһ хөкемнәренә сарыф ителүләре заманнарының уннан берен Коръән Кәримнең бик күп җирдә әмер ителүе хөкемнәренә караган нәрсәләргә сарыф кылсалар иде. Бәлки, мөселманнар бу кадәр наданлыкка һәм ахмаклыкка төшмәсләр иде» [3: 5].

Әдип фикеренчә, болгарлар ислам диненә кермәгәннәр, алар исламның өске кабыгы белән ябылган бер мәҗүси динне генә тотканнар, тыштан карагандa ул ислам кебек күренсә дә, эчтән чып-чын мәҗүсилек булган, болгарларның үсешен тоткарлаган шундый дин Мөхәммәд пәйгамбәр алып килгән дин булмаган. Аның бу карашлары күпмедер дәрәҗәдә Г. Курсавиныкы белән аваздаш: ул да, пәйгамбәр заманындагы элекке исламга кайтсак кына, җәмгыять төзәлә алачак, дип санаган.

Чыннан да, татарлардагы ислам дине башка халыкларның ислам диненнән аерыла, чөнки бездәге диндә тәңречелектән калган элементлар юк түгел, хәтта Аллаһ күп очракта Тәңре дип йөртелгән. Г. Рәхим язганча, татарлар ислам динен кабул итсә дә, традицион мәдәниятендә мәҗүсилектән калган догалар (им-том иткәндә), теләкләр, төрле серле җөмләләр, сүзләр байтак сакланып калган: «Әүвәлге мәҗүс каһарманнары – Гали, Хәсән, Хөсәен мөселман изге һәм батырларына әйләнделәр. Әүвәлге шаман догалары мөселман диненчә булган төрки догаларга алмаша башладылар. Тәңреләр Аллага һәм мөселман изгеләренә әверелделәр; шаманның ролен дә мулла алды. Ләкин төп, әсаси аһәң (нигез аһәңе. – *А.Г.*) калды. Халык арасына таралган төрле мөселман хорафаты, легенда һәм әкиятләре үзләре акрынлап тәмсил ителделәр (ассимиляцияләнделәр. – *А.Г.*), төрекләштеләр» [6: 202, 204].

Г. Исхакый шулай ук бездәге ислам диненә Конфуций тәгълиматлары үтеп керү сәбәпле дә, чын дин бозылган, дигән фикер әйткән. Г. Гобәйдуллин аның бу сүзләрен аңламый, әдипне Конфуций динен кытайлар гына тотуын белмәвенә гаҗәпләнә һәм бу диннең татарлар белән берниндн катнашы булмавын әйтә. Безнең уйлавыбызча, Конфуций тәгълиматлары дигәндә, автор кәлям һәм дини фәлсәфәне күздә тоткан. Тарихтан мәгълүм булганча, Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани һ.б. могтәзилә, әшгари һәм матүриди кебек кәлям әһелләренең фәлсәфәләренә каршы көрәш алып барганнар. Г. Исхакый да әлеге дини реформаторлар әйтеп калдырган фикерләрне «Ике йөз елдан инкыйраз» әсәрендә шул рәвешле чагылдырган.

Г. Исхакый консерватив дин әһелләренең зарарын, тискәре якларын киң аудиториягә матур әдәбият аша җиткерүчеләрнең беренчеләреннән булган, чөнки шәригать мәсьәләләрен яхшы белгән, динне дөрес аңлаган, җәдидчелекне актив рәвештә яклаган. Үзенең «Ике йөз елдан инкыйраз» әсәрендә ул руханиларга тәнкыйди күзлектән карап бәя биргән, бик күп кешеләрнең күзләрен ачкан, иске карашлы руханиларның чын йөзен күрсәткән һәм моны төрле дәлилләр белән үтемле итеп, нәфис чаралар ярдәмендә оста итеп эшли алган. Дини наданлык, әхлаксызлык белән көрәшүендә аңа күренекле дини реформаторларыбызның эшчәнлеге, иҗатлары үрнәк булган һәм ул аларның эшен күпмедер дәрәҗәдә дәвам иткән. Г. Исхакый «Ике йөз елдан инкыйраз» әсәре аша үзеннән килгән әдипләр иҗатларына, галимнәр эшчәнлекләренә тәэсир иткән, йогынты ясаган. Соңгы елларда кайбер дин әһелләре тарафыннан кадимчелекне һәм тәкълидне яңадан торгызу процессы, кадими карашлы дин әһелләренең хезмәтләрен артык пропагандалау күренеше күзәтелә башлады, әмма моның яхшыга илтмәве, милләтебезне саклап калуда куркыныч тудыруы, торгынлыкка алып баруы хакында Г. Исхакыйның безне кисәтеп калдырганын онытмаска кирәк.

ӘДӘБИЯТ


1. Әл-Камали Зыяэддин. Дини тәдбирләр. Уфа: Бертуган Кәримовларның «Шәрык» матбагасы, 1913. 77 б.

2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 8 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 447 б.

3. Буби Г. Замане иҗтиһад мөнкарыйзмы, дәгелме? Казан: Милләт, 1909. 70 б.

4. Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть // Аң. 1915. № 1. Б. 7–19.

5. Исхакый Г. Шиһабетдин әл-Мәрҗани // Яңа милли юл. 1936. № 3. Б. 10–11.

6. Рәхим Г. Сайланма әсәрләр = Избранные труды / төз. М.И. Ибраһимов, А.М. Гайнетдинов. Казан: Ихлас, 2018. 560 б.

7. Сәхапов М.Җ. Яңарыш хәбәрчесе: Г. Исхакый иҗаты турында. Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.

8. Фәхреддин Р. Җәвамигыль-кәлим шәрехе. Оренбург, 1916. 552 б.

9. Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / китапны басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. Казан: РИИ, 2016. 140 б.


## ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ И ИСТОРИЧЕСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ Г. ИСХАКИ В ГОДЫ РЕВОЛЮЦИЙ И ЭМИГРАЦИИ


***Б.Т. Гали** (Казань)*



В статье рассматривается общественная и историческая деятельность Г. Исхаки, проект создания татарской автономии «Идель-Урал». Политическая деятельность и участие в мусульманских съездах, создания политических газет и журналов, годы пребывание его в эмиграции.



**Ключевые слова:** «Идель-Урал», газета «Иль», Г. Исхаки в эмиграции.



The article deals with the public and historical activity Ishaki, a project for the creation of the Tatar autonomy «Idel-Ural». Political activities and participation in Muslim congresses, political newspapers and magazines, the years of his stay in exile.



**Key words**: «Idel-Ural», newspaper «Il», G. Ishaki in emigration.


В дни февральской революции Г. Исхаки оказался в Москве и, естественно, в гуще военно-исторических и политических событий. Искренне ждавший падения ненавистного царского самодержавия, писатель с одобрением воспринимает переворот и с воодушевлением втягивается в общественно-политическую жизнь. Его кипучая энергия, жажда перемен реализуется в его многочисленных публичных выступлениях, статьях. Он очень торопится, как

бы предчувствуя, что демократические перемены в России могут оказаться кратковременными, ибо вековые имперско-бюрократические традиции легко не сдадут свои позиции.

Общественно-политическая деятельность Г. Исхаки между двумя революциями 1917 года требует отдельного монографического исследования. Забегая вперед отметим, что его публицистика во многом предопределила и ускорила ход развития татарской общественной мысли.

Г. Исхаки возобновляет выпуск газеты «Иль» (Родина), где на протяжении 1917 г. публикует серию общественно-политических статей, раскрывающих сложившуюся ситуацию в стране.

Как уже отмечалось, он полностью одобряет и защищает политику Временного правительства и Учредительного собрания в части обещаний решения проблем национальных меньшинств, населяющих Россию. Он самолично готовит и издает в периодической печати серию документов, в которых раскрывает сущность политики новых правителей. Г. Исхаки призывает татарский народ объединиться вокруг единой национальной идеи без разделения на богатых и бедных, т.е. выступает приверженцем и теоретиком движения «единого потока».

Историко-философские взгляды Г. Исхаки того времени с особой полнотой раскрылись в серии его публицистики под общим названием «В орбите политики», которые затем, по просьбе читателей, были выпущены в Москве отдельной брошюрой. Эти статьи, отличающиеся глубиной и четкостью оценки политической ситуации в стране, пронизанные глубокой аналитической мыслью созданы с целью определения хода дальнейшего развития татарского общества. В этих очерках Г. Исхаки выступает не только как зрелый мыслитель, патриот, но и как ученый, стремящийся раскрыть ситуацию в стране историческими аналогиями, экскурсами в прошлое. Так он раскрывает античеловеческий и грабительский характер войн вообще. Англия, по его мнению, стала богатейшей страной мира за счет экспансии и грабежа колоний. Выйдя на историческую арену позднее, Германия начала претендовать на новый дележ мирового пространства. В результате возникли два противодействующих блока: на одной стороне оказались Германия, Италия и Турция, а на другой – Россия, Англия, Франция. В результате их противостояния началась первая мировая война. Больше всего пострадали народы менее развитых в экономическом и политическом отношении стран. Турция оказалась чуть не разделенной на части между победителями. Россия, поставщица дешевого пушечного мяса, также оказалась в проигрыше. И плюс ко всему «заработала» серию революций. Раскрывая ситуацию в мире перед 1917 годом, Г. Исхаки осуждает эту бессмысленную бойню. К более глубокой оценке этой войны с точки зрения татарского народа он придет позднее, в историко-публицистическом романе «К дому».

Идеи обустройства социальной жизни народов, населяющих Россию, он продолжает развивать в работе «Наши пути», представленной как основной доклад на Всероссийском съезде мусульман, прошедшем с первого по одиннадцатое мая 1917 года в Москве. Г. Исхаки здесь размышляет не только о своем народе, но и о судьбе 30-миллионных российских мусульман, подвергая историческому анализу жизнь мусульман-тюрков за многие годы совместного сосуществования в составе Российской империи. Писатель ищет рецепт для их самоспасения, пытается прогнозировать будущее национальных окраин. Г. Исхаки – не слепой фанатик. Он верно подмечает, что мусульмане России никогда не смогут добиться полного единения, ибо они разные по национальности, языку, по экономическому, этнокультурному развитию, но могут и обязаны выработать единую платформу борьбы за свое будущее. В основе этой идеи

объединения должны лежать стремление быть хозяином своей земли, ее недр, богатств, требование свободы в области культуры, литературы и искусства.

Платформа тюрков-мусульман должна быть широкой, емкой и демократичной, способной вобрать в себя различные общественно-политические направления и выдвигать светские, жизненные требования. Российские мусульмане должны брать в свои руки экономические, культурные, религиозные проблемы с участием широких слоев населения, но под руководством вновь избранного «Милли шура». Съезд принимает рекомендации и относительно устройства будущего России. Она, по их мнению, должна быть федеративно-демократической республикой. Избирается Всероссийский мусульманский комитет с центром в Петербурге.

Г. Исхаки в своем заключительном слове, получившем единодушное одобрение участников Первого мусульманского съезда, выдвигает идею национально-культурной автономии для татар и других тюркских народов в составе России. Как видим, он не предлагает создания самостоятельного государства с выходом из состава России, а настаивает лишь на широкой культурной автономии.

В июле этого же года состоялся второй Всероссийский съезд мусульман в Казани. Однако этот съезд, по сравнению с первым, оказался локальным. В связи с обострившейся военно-политической ситуацией в стране, делегации Кавказа, Крыма, Туркестана не смогли добраться до Казани и принять участие в его работе. На съезде были в основном представлены тюркские народы Поволжья, Урала, т.е. центральной части России. Участники данного форума поддержали идею создания национально-культурных образований, в частности, в регионе Идель-Урал. Было принято решение о проведении заседания Милли меджлиса в Уфе. В подготовительное бюро вошел и Г. Исхаки.

Увлекшись созданием новых государственно-культурных автономий, писатель «проглядел» октябрьский переворот большевиков.

Двадцать второго ноября 1917 г. в Уфе открылось заседание национального меджлиса (Милли шура). Основные споры и дискуссии развернулись вокруг будущего статуса национальных образований. Здесь четко выделились две позиции, два направления. Г. Исхаки, Х. Максуди, Г. Терегулов, З. Кадыйри выступили с идеей создания в составе России национально-культурных автономий с широкими полномочиями для всех тюркских народов. А другие, в частности, Г. Шараф, И. Алкин, Ф. Сайфи, С. Атналулов настаивали на формировании самостоятельного штата Идель-Урал. Национальный меджлис поддержал последний вариант. Метания из крайности в крайность в зависимости от сложившихся обстоятельств, ситуации объяснимы. Ибо она была не простой, ориентироваться было не легко. Создается специальная коллегия по решению вопросов создания штата Идель-Урал. Просматривался в документах и случай полного отделения от России, если не будут созданы условия для совместного сосуществования. А Всероссийский мусульманский военный съезд организовал военный совет, который приступил к созданию национальных полков и был создан мощный блок, который впоследствии был использован большевиками в корыстных целях в Средней Азии в борьбе против национально-освободительного движения басмачей и впоследствии был уничтожен. К власти пришли ненавистные Г. Исхаки большевики. Как и другие представители партий эсеров и меньшевиков, он по-прежнему считает, что Россия и особенно ее национальные окраины, не созрели для социалистической революции и марксистских идей.

Летом 1918 г., когда в Казани бесчинствовали мятежные чехи, Г. Исхаки, вместе с Ф. Туктаровым, Г. Батталом оказался в Самаре и осенью со своими соратниками через Уфу, отправляется на Дальний Восток. К ним присоедини-

лись известный режиссер, основатель татарского профессионального театра Г. Кариев, актер Ш. Шамильский, но доехав до Петропавловска, они отказались от этой затеи и вернулись назад. Г. Исхаки, глубоко осознавший политику большевиков по отношению к инакомыслящей интеллигенции, покидает родину. Человек до боли любивший свою страну, народ, патриот, националист в хорошем смысле слова до конца жизни отлучается от родной земли, от родных корней. Главной причиной его эмиграции, как уже отмечалось, было принципиальное неприятие Октябрьской революции и политики большевиков. Как член партии эсэров, он остался верен ее программе и уставу в целом и в годы эмиграции. Он быстро осознал, что общественно-политический, вернее диктаторский режим, установившийся в России, не собирается решать национальные проблемы так, как этого хотелось и мечталось Г. Исхаки. Он остается верным своей идее национальной автономии, но уже под названием «Идель-Урал» в составе России.

Он по характеру был бойцом, человеком бескомпромиссным, а бойцу всегда нужен противник. Его противником на всю жизнь стал большевизм. Он боится «красной экспансии» и предупреждает об этом правителей всех стран и мировое сообщество. Страстная ненависть к большевистскому режиму и верность идеалам своего народа помогли ему стать великим и несгибаемым борцом. В этом направлении он развивает бурную и кипучую деятельность: с агитационно-пропагандистскими задачами он побывал во многих странах мира, участвовал в различных конгрессах, съездах, симпозиумах, везде выступал с докладами, статьями в периодической печати.

В начале 20-х годов переживает второе рождение его художественное творчество. Находясь в Польше, как гость и друг у самого Пилсудского, с которым познакомился во время архангельской ссылки, а затем, живя в догитлеровской Германии, он наслаждается демократией, возможностью спокойно творить, наблюдая издали за злодеяниями и перегибами Советского строя. Пишет пьесу «В волнах» (1920), где изображает бесчинство большевиков в самом начале революции и гражданской войны, роман «К дому» (1922), посвященный Первой империалистической войне, русско-турецким отношениям, остро психологическую повесть «Осень» (1923), драму «Жан Баевич» (1923).

В историческом плане нас интересует роман «К дому», где тесно переплетаются публицистика, политика и литературный вымысел. Это – плод его многолетних размышлений о путях развития народов России и других стран мира. Произведение имеет глубокие исторические корни. Дело не только в том, что писателя волнуют общечеловеческие и гуманистические ценности. В центре внимания автора события Первой мировой войны; действия происходят на участке Кавказа и на границе России с Турцией. Главный герой романа полковник Мирхайдар Тимергалиев честно и добросовестно служит в Российской армии, имеет большие заслуги перед Отечеством. В свое время он мужественно защищал Порт Артур. И вот его полк отправляется на турецкий фронт. Он, как солдат, патриот, никогда не задумывался о последствиях, причинах войн, полковник всегда выполнял приказы вышестоящего начальства. И перед атакой турецких войсковых линий к нему приходит прозрение. Для чего он воюет? Для обогащения английской казны, для удовлетворения имперских амбиций царя и его окружения? Против кого он воюет? Против единоверцев-мусульман, в чьих жилах течет общая тюркская кровь? Не легко ему принять решение. Ведь он дал клятву всю свою сознательную жизнь верой и правдой служить царю-батюшке. Через тревожные раздумья и глубокий анализ, скепсис, он доходит до нарушения армейской клятвы и со своим аланом (отрядом) переходит на сторону турок. Важное место в романе занимает мотивация поступков героя и

психологический анализ. Войну Тимергалиев начинает с тщеславными надеждами («его имя войдет в историю, он станет героем, станет генералом Тимергалиевым»), старательно, надо сказать, талантливо, готовит военные операции.

Однако на фронте, под влиянием прямых и косвенных событий, к нему приходит другая, правда. В определении нового поведения сыграли определенную роль моральный облик и действия царских военных руководителей. Тимергалиев убеждается, что основная масса высшего командования заботится лишь о своем личном обогащении и благополучии, и его коробит пренебрежительное отношение царских сановников к инородцам, особенно мусульманам. Один штабной генерал откровенно исповедуется: «Если бы мне дали на три года армейскую мощь, от грузин, татар, дагестанцев остался бы лишь пепел».

Сей генерал во время русско-японской компании, будучи в чине капитана, под Порт Артуром предательски сбежал с военной позиции, поставив армию в трудное положение, однако стал генералом, а Тимергалиев, не покинувший своего боевого участка, несмотря на ранение, прочно застрял в чине полковника.

Еще два события ускорили прозрение Тимергалиева. На вечере у адвоката он узнал много нового об истории государственности татар, о потере Казанского ханства, о предательстве Шахгали; разбередили его душу и народные мелодии, исторические песни.

На его решение перейти на сторону турков сыграло еще одно обстоятельство. Начальник генштаба перед решающим сражением выступил перед высшим офицерством с программной речью: «Перед нами стоит одна из величественных, национальных, религиозных задач, поставленных еще во времена Великого Петра, но до сих пор не выполненного. Еще более великая Россия должна оставить стоящей на ее пути Турцию в середине своей территории». В этом выступлении ярко выражаются имперские амбиции военщины России, претензия Москвы называться третьим Римом или стремление к владычеству, обозначенном в известном завещании Петра Великого.

Полковник Тимергалиев осознает, что он является игрушкой в руках военной верхушки и монархии в исполнении их гегемонистических притязаний.

Чтение книги «К дому» – экскурсия внутрь России, ибо писатель раскрывает гнилость армии, продажность и бездарность генералов, что способствовало легкому приходу к власти большевиков в 1917 году. Г. Исхаки понял, что войны – это организованные авантюры, на которых крупно обогащаются власть держащие. Что дает русскому народу эта победа? Ничего, кроме потерь сыновей, мужей, близких. Не случайно и большевики вот хотят, чтобы Россия проиграла войну. Тимергалиев далек от принятия идей большевизма, но в данном случае, по его мнению, они правы, в этом их выигрышная сторона.

После долгих раздумий, бессонных ночей, бесед с приближенными, чтобы избежать напрасного, никому ненужного кровопролития, он со своим полком переходит на сторону турков. Этот акт он называет возвращением «домой», к главному дому всех тюркских народов. Выполнив свою миссию, тяжело раненный Тимергалиев умирает с улыбкой на устах.

Смерть главного героя наталкивает на мысль о том, что переход татарского полка на сторону противника не является еще окончательным решением проблемы самостоятельности татарского народа. Сближение с турками один из вариантов против инкыйраза – исчезновения нации. Г. Исхаки еще не теряет надежды, что режим большевиков рухнет, и он сможет вернуться на родину. Но его иллюзии рассеялись как утренний туман. Он с напряженным вниманием следил за событиями на своей бывшей родине. В 1922 г. в Москве прошел громкий судебный процесс над представителями правых эсэров, среди которых

было много знакомых Г. Исхаки. Философы Н.А. Бердяев, С.Л. Франк, экономист Г. Бруцкис и другие были выдворены за рубеж. На родине началась официальная атака и на творчество Г. Исхаки. Пресса называла его предателем, отщепенцем, врагом народа, буржуазным националистом и т.п. Начиная с конца 20-х годов его имя начисто исчезает из печати, а произведения изымаются из оборота, попадая в раздел «совершенно секретно».

В этих условиях Г. Исхаки, как человек деятельный, энергичный не может сидеть за письменным столом, увлекаясь лишь поиском новой вязи изобразительно-выразительных средств, он включается в активную борьбу против большевизма всеми доступными ему средствами. В годы эмиграции он стал и в своих художественных произведениях, публицистике более жестким, целенаправленным, и в какой-то мере потерял чарующую теплоту естественного лиризма, необходимого для прозы не меньше, чем для поэзии. Он не щадит себя, изматывая свою душу бесконечными прожектами об устройстве России, объединении всех татар, разбросанных как осколки разбитой хрустальной вазы по миру, становится одновременно и пронзительно мудрым и по-детски наивным.

Татары по разным причинам покинувшие родину в конце XIX и начале XX века и вынужденные эмигрировать после 1917 г., живут небольшими колониями в различных странах, не имея возможности общаться со своими соплеменниками, теряя язык, обычаи. Изоляция может привести к быстрому исчезновению – Инкыйразу. Г. Исхаки считает своим гражданским и национальным долгом объединение татар-эмигрантов вокруг национальной идеи и родного языка. С этой целью в 1920 г. в Париже он создает комитет «Идель-Урал» и формирует его филиалы в различных странах.

Г. Исхаки стремиться концентрировать свою деятельность на самом главном: на выживании генетической и пассионарной силы нации. В своих выступлениях он осуждает гражданскую войну, потопившую страну в крови ни в чем не повинных людей, не согласен и с решением национального вопроса, требуя для народов, населяющих Россию, более широкую национально-культурную автономию, экономическую самостоятельность. Его мысли и идеи в этой области созвучны современным поискам разрешения государственной и языковой проблемы в наши дни в Татарстане.

Г. Исхаки постоянно интересуется положением своих соплеменников в СССР, в других странах, пытается их объединить, подбодрить добрым словом, зажигательной речью. Не обманывая их ложными иллюзиями, обещаниями счастливого будущего, стремится не погасить в них искорки оптимизма. Он живет в постоянном контакте с татарами-эмигрантами, знакомит их со своими произведениями, созданными до Октября и в годы вынужденной эмиграции.

Осенью 1933 г. он отправляется в страны Дальнего Востока и три года работает в Японии, Китае, Манчжурии, где в те годы проживало большое количество татар-эмигрантов, беженцев. Он стремится своим соплеменникам внушить идею единства татар, где бы они не проживали. Братья по крови, по языку, по мнению Г. Исхаки, должны объединяться вокруг комитета «Идель-Урал». В эти же годы он создает свой историко-социологический трактат «Идель-Урал».

По мере укрепления сталинизма и усиления репрессий в СССР, Г. Исхаки становится ярым противником советского режима и весь свой талант и темперамент направляет на разоблачение кровавого большевистского строя. В устных выступлениях, в печати он подвергает резкой критике порядки, насаждаемые в его бывшей родине.

С 1928 по 1939 гг. он издает в Берлине журнал «Яна милли юл» («Новый национальный путь»), с 1935 г. с его же помощью в Китае начинает выходить

газета «Милли байрак» («Национальное знамя»). Для татар всего мира Г. Исхаки становится духовным отцом, вдохновителем, моральной опорой. Здесь важно подчеркнуть и тот факт, что в отличие от некоторых представителей татарской и башкирской интеллигенции в эмиграции, перешедших на службу своим новым хозяевам, и естественно, обеспечившим себе более благополучную материальную жизнь, Г. Исхаки остался верен своим национальным идеалам, не дал «втиснуть» себя в золотую клетку (забегая вперед отметим, что он жил небогато, а в конце жизни даже бедствовал). Единственным близким человеком и опорой для него была дочь Сагадат Чагатай Исхаки (1906–1989), филолог-профессор, известный языковед и ее муж – Тагир Шакир Чагатай, которые переехали жить к нему в Анкару. Кроме многосторонней общественно-политической и исторической деятельности, Г. Исхаки уделял огромное внимание изданию и распространению книг татар-эмигрантов. Когда он жил в Берлине и в Варшаве (до 1939 г., т.е. до начала вторжения немецких войск в Польшу), Г. Исхаки основывает издательство «Милли юл» («Национальный путь»), вокруг которого он консолидирует писателей-эмигрантов, живущих в разных странах и континентах, издает произведения татарских писателей. После переезда в Турцию (1940), он лишается возможности издания своих произведений и других писателей на татарском языке (типография и шрифты остаются в Берлине).

В своих статьях последних лет, он считает себя мессией, истиной в последней инстанции. Подобная идея помогла ему выжить в неравной борьбе с многомиллионной коммунистической партией и КГБ, а иногда и враждебным эмигрантским окружением. Как отмечалось, он был чужим и среди своих, поскольку не шел на службу властям стран, в которых он жил. Г. Исхаки не разменивается на легкую и сытую жизнь, поскупившись со своими идеалами. Его обращение к потомкам – это крик души, который услышан только сейчас, когда писателя уже нет в живых. Патриот не увидел бесславную гибель советского режима, но он в целом вышел победителем в борьбе с тоталитаризмом. Он считал, что нет ничего страшнее коммунизма, но он счастлив тем, что не увидел мафиозного отечественного капитализма на своей бывшей родине.

ЛИТЕРАТУРА

1. Гали Б.Т. Татарская художественная литература начала XX века как исторический источник. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2009. 335 с.

2. Гали Б.Т. Эволюция татарской общественно-политической мысли в литературе и публицистике на рубеже 19–20 вв. Казань: Ихлас, 2009. 276 с.

3. Исхаки Г. Идель-Урал. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. (печатается по изданию: Гаяз Исхаки, Идель-Урал. Париж, 1933).

4. Сахапов М.Ж. Творчество Гаяза Исхаки и татарская литература XX века: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 1998. 60 с.

5. Султан С. Г. Исхаки-Иделле: Этапы и жизни и творчества / пер. с английского Р. Ахметзянов // Татарстан. 1991. № 2. С. 140–146.

6. Тагиров И. В борьбе за власть советов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 139 с.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ 1917 ЕЛГЫ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ «ИЛ» ГАЗЕТАСЫ

***Э.М. Галимҗанова*** *(Казан)*

В данной статье рассматривается общественно-политическая деятельность Гаяза Исхаки в 1917 году. Промежуток времени между двух революций (Февральской и Октябрьской) дает ему возможность воплотить свою мечту о единстве тюркских народов. В этом направлении газета «Иль» играет большую роль в реализации своих идей.

**Ключевые слова:** общественно-политическая деятельность, Гаяз Исхаки, публицистика, татарская литература, текстология, газета «Иль».

This article discusses the socio-political activity of Gayaz Ishaki in 1917. The time interval between the two revolutions (February and October) gives him the opportunity to realize his dream of unity of the turkic peoples. In this direction, the newspaper «Il» plays an important role in the implementation of their ideas.

**Key words:** Social and political activity, Gayaz Ishaki, journalism, tatar literature, textology, «Il» newspaper.

Ялкынлы публицист, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый XX йөз башы татар иҗтимагый тормышында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе. 1917 елгы февраль инкыйлабы, милләт язмышын кайгырткан милләтпәрвәр өчен, киләчәккә зур ышаныч һәм өметләр алып килә. Патша Николай пайтәхеттән төшерелә, кенәз Львов җитәкчелегендә Вакытлы хөкүмәт төзелә. Әлеге хөкүмәт беренче эш итеп элеккеге хөкүмәт вәкилләрен алыштыра, полиция, жандармерия көчләрен тарата. 1917 елның 20 мартында (2 апрель) «Русиядәге бөтен гражданнарның бертигез булуы» турында карар игълан ителә. Ниһаять, Россиядәге башка халыклар кебек, татарларга да үзләренең милли мәнфәгатьләрен кайгыртырга, мәдәни, икътисади, мәгариф эшләрен тормышка ашырырга юл ачыла. Күптән хыялланган сүз иреге бирелә, матбугатта цензура бетерелә.

Гаяз Исхакый «Ирекле матбугат» исемле мәкаләсендә Февраль инкыйлабына кадәр матбугатка карата булган игътибарның көчле булуын искәртә. «Безнең милли матбугатыбыз иске идарәнең эчен акрын гына булса да кимерә иде, чөнки безнең матбугатыбыз акрын гына булса да халкыбызның хокукы хакында баш күтәрәчәген аңлата иде». Шуңа күрә дә, «безнең матбугат өч мәртәбә эскәнҗә астына кысылган», беренчедән, «гражданский цензорлар», икенчедән, «военный цензорлар», өченчедән, үзебез арасында булган бозык кешеләр, ягъни шпионнар күзәтчелеге астында иде, ди. «Инде татар матбугаты элгәреге богаудан ычкынды. Аны богаулар өчен генә куелган, шуның белән хәят кичерә торган, шуны кыйнау-изүне генә кәсеп иткән Шәехгаттар Иманаев, Ашмарин, чукынчык Катановлар, Җүзиләр вә башка әллә нинди фикер жандармнары, уй шпионнары читкә ыргытылды» – дип, матбугат ирегенә зур өметләр баглый [2]. Милли көрәш юлында төп коралы булган, төп трибуна буларак оештырылган, шуңа да күп тапкырлар хөкемгә тартылган, яптырылган, берничә тапкыр исемен алыштырган «Ил» газетасын яңадан үз исеменә кайтара («Ил» (1913–1915), «Сүз» (1915–1916), «Безнең ил» (1916–1917)). Моңа кадәр «Йорт-җир файдасын күзәтүче төрек-татар гәзитәсе» исеме астында яшеренеп килгән «Ил» газетасы 1917 елның 23 мартында «Яшәсен халык җөмһүрияте! Русия мөселманнарының бөтен хокуклары башка миллләтләр белән тигез булуы фигълиятькә чыгарылсын! дигән шигарь(лозунг) белән яңадан Г. Исхакый мөхәррирлегендә һәм Мәскәү мөселман комитеты наширлегендә чыга башлый.

1917 елда, илдәге вазгыятькә бәйле рәвештә, Русия мөселманнары тормышында вакыйгалар күп була. 24 апрельдә Казанда Беренче мөселман хатын-кызлары корылтае, 1–11 майда Мәскәүдә Бөтенруссия мөселманнары корылтайлары уза. Милләт мәҗлесе төзү турында карар кабул ителә. Учредительное собраниегә сайлау алды вакыйгалары килеп туа. Ниһаять, моңа кадәр рәсми тыелып килгән «Зөләйха» пьесасын сәхнәгә куярга юл ачыла. Ул беренче тапкыр «Сәйяр» труппасы тарафыннан, аның җитәкчесе – күренекле артист һәм режиссер Габдулла Кариев бенефисы рәвешендә, 1917 елның 17 мартында Казанның зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Спектакль җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителеп, вакытлы матбугат битләрендә бер-бер артлы бәяләмә-мәкаләләр басыла. Мәсәлән, «Кояш»та Ф. Әмирханның «Зөләйха»

[6], «Йолдыз»да Ш. Әхмәдиевнең «Зөләйха» [7], «Ил»дә Р. Тюменевнең «“Зөләйха” Мәскәүдә» [4] һ.б.ларның язмалары дөнья күрә. Г. Исхакый үзе дә Казанга «Зөләйха» спектаклен карарга дип, Мәскәү «Мөселман комитеты» рәисе сыйфатында Русия мөселманнарының беренче корылтаен әзерләү белән шөгыльләнгәндә килә. Аннан «Сәйяр» труппасы Казаннан Мәскәүгә махсус килеп, 4 майда корылтай делегатларына спектакльне тәкъдим итә. Бу корылтайны әзерләүдә һәм үткәрүдә дә Исхакый актив катнаша. 12 кешедән торган президиум составына керә һәм төп докладчыларның берсе була.

7 апрель көнне Казанның Новый клубында Гаяз Исхакый хөрмәтенә банкет үткәрелә. Монда күп кенә җәмгыятьләрдән: «Мөселман комитеты», «Җәмгыятел голяма», «Хатын-кызлар җәмгыяте», «Укытучылар җәмгыяте» һ.б. җәмгыятьләрдән, матбугат органнарыннан шактый гына вәкилләр, гомумән, татар зыялылары, 160 тан артык кеше җыйнала. Монда ясаган чыгышында ул: «Бу көндә бөтен милләт, бербөтен буларак, кулга-кул тотынышып хәрәкәт итәргә тиеш, демократы, буржуазы, зыялылары, руханилары – һәммәсе, һәммәсе милләтнең һәрбер сыйныфы милли бөтенлек байрагы астында сәхнәгә чыгарга тиеш», – дип,бердәм булырга, алай гына да түгел, барлык «шималь төркиләрен, Русия мөселманнарын бер бөтен буларак» милли көрәшкә чыгарга чакыра [5].

Ике революция аралыгын Гаяз Исхакый милли проблемаларны чишү өчен иң кулай вакыт дип саный. «Минем иманым хәзер хәяткә чыкты. Мин ул чакта омтылган, ашкынган нәрсәләрем хәзер тормышка ашты. Моның кадере минем алдымда бик зур», – ди ул үзенең I Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда ясаган чыгышында. Үз фикерләрен халыкка җиткерү трибунасы вазифасын, әлбәттә, «Ил» газетасы үти. Газетаның беренче саннарында ук ул мөселманнарны әлеге хөрriяттән файдаланып калырга чакыра. «Саф башына!» исемле мәкаләсендә иске идарә җимерелүне хуплап: «Хәзер халыкның файдасына эшләнгән һәрбер сәяси, мәдәни, милли хезмәт өчен төрмәләргә, зинданнарга яба торган мәхкәмә, суд юк, һәрбер яхшы эшкә каршы килә торган закун-макун юк» [3] дисә, «Вәкилләр эшкә!» исемле язмада: «Хәзер эш вакыты, кызу эш вакыты, лыгырдау, кызылдан-кызыл сүз сөйләү вакыты үтте» дип эшкә тотынырга өнди [1].

Июль аенда большевикларның активлыгы арта. Вакытлы хөкүмәт җитәкчесе итеп Керенский билгеләнә, ә яңа хөкүмәттә татарларга бер дә урын бирелми, шуңа бәйле рәвештә, июль аенда гына да берьюлы өч корылтай ачыла: 1) Мөселман гаскәриләр корылтае (1917, 17–22 июль); 2) Бөтенрусия голямалары нәдвәсе (1917, 18–26 июль); 3) II Бөтенрусия мөселманнары корылтае (1917, 21–31 июль).

Озакламый большевиклар хакимиятне үз кулларына алалар. Катлаулы шартларда Милләт мәҗлесе эшли башлый. Милли территориаль автономия һәм «Идел-Урал штаты» идеясе калкып чыга. Исхакый бу вакыйгаларның үзәгендә кайный, чыгышлар ясый, матбугатта мәкаләләр бастырып шуларга мөнәсәбәттә үз фикерләрен белдерә.

Гаяз Исхакыйның чыгышлары илдә барган сәяси үзгәрешләрнең тизлеге белән дә бәйле була. Аның бу чорда язган публицистик язмалары гаять күп. Атнасына ике-өч тапкыр дүрт битле булып чыккан «Ил» газетасының һәр санында диярлек икешәр мәкаләсе басыла.

Февраль инкыйлабы биргән ирекләк тә озакка бармый. Гаяз Исхакый газетаны саклап калу ниятеннән булса кирәк, «Ил»не яңадан 10 ноябрь (84) саныннан «Йорт-җир файдасын күзәтүче төрек-татар гәзитәсе»исем асты белән чыгара башлый. 1918 елның 16 гыйнвареннән, ягъни большевиклар хакими-

яткә килгәч, газетаның шигаре алынып, бары «Йорт-җир файдасын күзәтүче» газета гына булып кала. Озакламый большевиклар милли оешмаларны җимерәләр, милли матбугатларны ябалар. Бары 133 саны гына дөнья күрә алган «Ил» газетасы («Гәзитчелек эшендә егерме биш ел» исемле мәкаләсендә 138 дип күрсәтә) Мәскәүдә, читтәрәк булу сәбәпле азрак ышыкланыбрак торса да, 1918 елның 10 апреленнән бөтенләйгә туктатыла.

Шулай итеп, Февраль инкыйлабы Исхакыйга зур өметләр, дистә еллар буена тупланган хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Шуңа да ике инкыйлаб аралагында ул бар көчен иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә юнәлтә. Фикерләрен җәмәгатьчелеккә җиткерүдә аңа «Ил» газетасы ярдәмгә килә.

ӘДӘБИЯТ

1. Гаяз. Вәкилләр эшкә! // Ил. 1917. 2 май.
2. Гаяз. Ирекле матбугат // Аң. 1917. № 3/4.
3. Гаяз. Саф башына! // Ил. 1917. 23 март.
4. Рамазан Тюменов. «Зөләйха» – Мәскәүдә // Ил. 1917. 10 май.
5. Ф. Гаяз әфәнде шәрәфенә // Кояш. 1917. 11,13 апрель.
6. Ф. Зөләйха // Кояш. 1917. 19 март.
7. Ш.Ә. Зөләйха // Йолдыз. 1917. 22 март.

# Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ Г. КАМАЛ ТЕАТРЫ КУЕЛЫШЫНДА МУЗЫКАЛЬ БИЗӘЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***Э.М. Галимова*** *(Казан)*

В данной статье раскрываются особенности музыкального оформления постановок театра им. Г. Камала по пьесам Гаяза Исхаки в 90-е годы. Драматургия Гаяза Исхаки привлекает режиссёров многих театров. Как драматург он имеет свою концепцию изложения и развертывания сюжета. Какова роль композитора и средств музыкального оформления в восприятии философских и жизненно важных тем в разножанровой драматургии Гаяза Исхаки. Именно в этом заключается актуальность выбранной темы.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, театр им. Г. Камала, Празат Исанбет, драма, комедия, музыкальное оформление.

In this article, features of musical design of the productions of the Theater are revealed. G. Kamala on the plays of Gayaz Iskhaki in the 90s. The playwriting of Gayaz Iskhaki attracts the directors of many theaters. As a playwright, he has his own concept of narrating and unfolding the plot. What is the role of the composer and the means of musical design in the perception of philosophical and vital themes in the multi-genre drama by Gayaz Iskhaky. This is the relevance of the chosen topic.
**Key words:** G. Iskhaki, the theater G. Kamal, Prazat Isanbet, drama, comedy, musical composition.

Гаяз Исхакый – XX гасыр башында ук милли драматургиянең казанышларын билгеләүдә иң алдынгы урыннарның берсен били. Әдипнең иҗаты татар прозасын яңа югарылыкка күтәрүе белән билгеле. Бүген Г. Исхакыйны «классик әдип» дип атыйбыз икән, димәк без аның проза һәм публицистика өлкәсендәге уңышлары белән янәшәдә сәхнә әдәбиятындагы новаторлыгын да күз алдында тотарга тиешбез.

Г. Исхакый – үз чорының фаҗигале вакыйгаларын шактый тирән ачып биргән шәхес, шул нисбәттән аның исеме XX гасырның 90 нчы елларында гына халыкка әйләнеп кайтты. Шуңа күрә соңгы дистә ел эчендә аның иҗаты төрле дәрәҗәдәге фәнни-тикшеренү эшләренең җитди максатына әверелде. Татар халкының танылган әдибе Гаяз Исхакыйның 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын язучының «дөньяга карашы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә

мөнәсәбәте, әдәби эстетик зәвыгы, сәнгатьчә фикерләве, әсәрләренең идея юнәлеше, язу стиле» ягыннан фәндә өч чорга бүлеп тикшерү гадәткә кергән: 1. Мәгърифәтчелек дәвере (1897–1904); 2. «Таңчы»лык дәвере (1905–1911); 3. Милләтчелек дәвере (1912–1918) [2].

Әйтергә кирәк, Г. Исхакый әдәби мирасының шактый зур өлеше драматургия өлкәсенә карый. Аның каләме белән дистәдән артык сәхнә әсәре язылган. Ул милли драматургиянең формалашуына, үсешенә зур өлеш кертте. Әдипнең беренче «Өч хатын белән тормыш», дип исемләнгән драмасы 1900 елда басылган. Күп кенә чыганаклардан белүебезчә, татар театры рәсми рәвештә 1906 елның 21 апрелендә Г. Исхакыйның шушы әсәре белән ачыла.

Гөмүмән, әдипнең драматург буларак иҗатын ике чорга карау мәслихәт булыр. Беренче чор – 1906–1923 еллары белән билгеләнә. Татар театр сәнгатенең туу көннәреннән алып, Гаяз әфәнде эмиграцияга киткәч, аның әсәре буенча куелган иң соңгы спектакль уйнау еллары бу. Исхакыйның шул вакытта татар сәхнәсенә күтәрелгән иң соңгы әсәре «Салих хаҗи балалары» («Юлсызлар») 1923 елның 9 ноябрендә уйнала. Икенче чор – театр сәнгатендә 1992 елның «Зөләйха» драмасын Г. Камал театры сәхнәләштерүе белән башланып китә [1]. Гомумән, Гаяз Исхакый фикере буенча, милли театр өчен язылган пьесалар татар тормышын чагылдырырга тиеш һәм ул үзенең иҗатын шул юнәлеш белән алып бара. Әдип, ул чор татар тормышы өчен җитди мәсьәләләрнең берсе булган хатын-кыз азатлыгы, ирекле никах, намус хакында, милләтнең киләчәген күзаллап яза.

Әлеге мәкаләдә без Г. Исхакый әсәрләренең Г. Камал театры куелышында музыкаль бизәлеш үзенчәлеген билгеләү өчен игътибарны режиссёр Празат Исәнбәт куйган: «Зөләйха» (1992 ), «Алдым-бирдем» (1994), «Җан Баевич» (1995), спектакльләренә юнәлтербез. Әлбәттә анализлауга килгәндә, һәрбер әсәр төрле әдәби жанрда язылган һәм шул ук вакытта әлеге үзенчәлек спектакльнең музыкаль концепциясен билгеләүдә бер ысул буларак ярдәм итә.

«Зөләйха» әсәрен Гаяз Исхакый 1912 елда иҗат итә һәм үзе ук драма дип атый, ләкин әлеге жанр төшенчәсе белгечләрдә берникадәр каршыклы фикерләр дә тудыра. Чөнки күп кенә театр һәм әдәбият өлкәсендәге тәнкыйтьчеләр, әлеге әсәрне «трагедия» дип анализлыйлар. Гаяз Исхакый иҗатын күздә тотсак, аңа кадәр «трагедия» – жанр билгеләү төшенчәсе буларак кулланылмаган. Тәрҗемә аша килеп кергән кайбер әсәрләрне генә афишаларда Шекспир, Корнель трагедияләренең жанрын билгеләп язганнар. Г. Кариев 1917 елны әлеге әсәрне сәхнәләшетерергә алына һәм өр-яңа сүрәтләү алымнары белән эшли. Әсәргә музыканы Солтан Габәши яза. Күп кенә чыганакларда язылганча, әсәр сәхнәләштерүгә бик авыр бирелә. Биш пәрдәле драмада төп урынны күп кешеле күренешләр, кискен көрәш моментлары алып тора. Вакыйга урыны да бик оригиналь сайлана: зират, татар һәм рус авылы күренешләре, мәчет, чиркәү яннары. Г. Кариев әлеге әсәрдә ике рольдә уйный, ә Г. Болгарская башкаруындагы – Зөләйха образы тамашачыны таң калдыра. Уфадагы «Нур» театрында яшь режиссёрлар Б. Ибраһимов белән Ф. Бикчәнтәв шулай ук әлеге шактый катлаулы әсәрне куярга алыналар.

«Зөләйха» дип исемләнгән драма үз эченә трагик герой образын, көчле хатын-кыз язмышын ала, һәм әлеге образ Рус хөкүмәтенең татарларга каршы көрәш алып баруы, мөселман динен юк итү максаты аша бирелә. Зөләйханы көчләп чукындыралар, ата-анасыннан, балаларыннан аерып алалар, бер урыска кияүгә бирәләр. Ләкин ул тез чүкми, хак динен сатмый, уңга һәм сулга тайпылу аның өчен ят нәрсә. Нәкъ менә әлеге сыйфатларга ия булган Зөләйха образы – трагедия герое булып формалаша. Гаяз Исхакый әлеге образ аша рус хакимияте-

не алып барган сәясәтнең киләчәге булмавы турында ассызыклый. Дин, милләт, тугрылык билгесе, азатлык өчен көрәш һәм көчле рухлы татар халкы темалары– «Зөләйха» әсәрендә тирән чагылыш таба, шул ук вакытта авторның да эчке кичерешләрен тулысынча тасвирлый. Музыкаль бизәлешкә килгәндә, Г. Камал театры тарафыннан, Празат Исәнбәт 1992 елда куйган «Зөләйха» драмасы Солтан Габәши язган музыкага нигезләнеп бара. Бары тик, берникадәр үзгәртү кертеп, оркестровканы Фоат Әбүбакиров эшли. Спектакль башында ук, лейтмотив буларак «Зөләйха» темасы бирелә, соңыннан ул «Зөләйха белән Сәлимҗанның» лирик бию буларак бирелә. Әсәрнең башында ук халыкның дингә ныклы мөнәсәбәтен исбатлар өчен ике мөнәҗәт яңгырый, һәм аны Зөләйханың әнисе оныклары белән башкаруы, аеруча китап уку көйләрен киләчәк буынга өйрәтеп калдыру, милләтнең киләчәген саклау һәм кайгырту буларак кабул ителә. Әйтергә кирәк, әсәрдә күпсанлы халык башкаруындагы бию өлешләре бик күп. Туй вакытындагы авыл халкы биюе музыкаль теоретик ысул буларак «рондо» формасында язылган, аның артыннан яшь егетләр биюе әлеге өлешне җанландыра, кызлар биюе дә әлеге ритмнан калышмый. Лирик һәм кульминацион өлеш буларак «Зөлейха һәм Сәлимҗанның» лирик биюе бәхетле тормышның соңгы күренеше буларак кабул ителә. Әлбәттә, әлеге музыкаль өзек спектакльнең төп лейтмотивы һәм драманың тугры мәхәббәт хисенә уралган күренешен тасвирлый. Зур күләмле хореографик өлешне «Көянтә белән бию» тәмамлый һәм алга таба бәхетле тормышка фаҗига киләсен кисәткән кебек тоела. Ни өчен дигәндә, рус интонацияләре кулланып язган әлеге тема, үзенең алага таба формалашуында пентатоника алымнары өстен булып тәмамлануы, шуның бер дәлиле. Зөләйханың сынмавы-сыгылмавы хакында музыкаль бизәлеш тә исбатлый. Шулай да спектакльнең иң драматик өлешләренең берсе, халык биеп, күңел ачкан вакытта Попның килеп керүе, һәм драматик диалоглар чишелеше нәтиҗәсендә кискен рәвештә, көтмәгәндә «Кичке азан» яңгырый. Поп шакката, авыл халкы Ходай Тәгаләнең барлыгына һәм кодрәтенә тагын бер кат инанып, бер-берсенә карап сөенәләр. Беренче бүлек әлеге халәттә тәмамлана. Әйтергә кирәк, «Кичке азан» Солтан Габәшинең киң таралган көйләренең берсе һәм спектакльнең финал өлешендә аның тагын бер кат яңгыравы, Гаяз Исхакый күтәргән проблемага музыкаль җавап буларак ишетелә.

Әдипнең «Алдым-бирдем» драмасы 1907 елда Казан төрмәсендә утырганда язылуы белән билгеле. Әсәр «Сәйяр» труппасының артистлары тарафыннан беренче тапкыр Уральск шәһәр театрында 1908 елның 31 гыйнварында С. Гыйззәтуллина-Волжская бенефисында уйнала. Ул – нәкъ менә Галия ролен башкара. Празат Исәнбәт куелышында «Алдым-бирдем» спектакле шактый унышлы килеп чыга: режиссёр әһәмиятле булмаган персонажлардан котыла, монологларны кыскарта, спектакльгә үсеш динамикасы өсти. Ләкин, финал өлешендәге мөхим күренешләрне кыскарту, сизелерлек югалтуга да китерә. Әйтергә кирәк, «Алдым-бирдем» спектакленең баштагы сәхнәләре Г. Камалның «Банкрот» комедиясенең экспозициясен хәтерләтә. Әсәрдә төп фикер буларак, мәхәббәт, никах, кеше хокукы проблемалары куелган, бу мәсьәләгә караштa «аталар» һәм «балалар», кадимчеләр белән җәдитчеләр, консерваторлар белән европалашкан зыялылар арасындагы тартыш-көрәш күрсәтелгән. Әлеге әсәрдә режиссёр Празат Исәнбәт куелышның музыкаль бизәлеш юнәлешендә зур яңалык итеп «Stella» фонографын куллануны күрә. Спектакль башлануга ук тамашачы игътибарны бик кызыклы фонографка юнәлтә. Аннан лирик рухтагы милли тема агыла. Шулай итеп безне режиссёр бай тормыш мохитенә алып кереп китә. Агачтан ясалган декорация, җиһазлар да бай тормышны сүрәтли. Әсәргә музыканы Фоат Әбүбәкеров яза. Төп образлар Галия белән

Ибраһим ике лейттема аша бирелә. Берсе йорәк өзгеч тема скрипка кыллары аша бирелсә, икенчесе «Яр-яр» җыры алга таба «алдым-бирдем» күренешеннән соң яшьләр биюенең интонацион чыганагы булып тора. Спектакльнең финал чишелешендә шулай ук «Яр-яр» җырының тагын бер кат яңгыравы – яшьлек мәхәббәтенең җиңүе, Галия белән Ибраһим үзләренең хисләренә тугры булып калуларына җитди дәлил булып тора.

Гаяз Исхакый, 1923 елда язылган «Җан Баевич» комедиясендә үзеннен милләтенә булган саксыз карашны, хөрмәт итмәүне сурәтли. Әсәрнең төп герое – Шакирҗан, авылдан килгән сәүдәгәр. Комедиядә Шакирҗан культуралы кеше булырга тели. Уйлый торгач, ул урыс милләтенә күчмәкче була, чөнки урысларны иң акыллы, интеллигентлы, культуралы халык дип уйлый һәм үзенә Җан Баевич исеме бирә. Җан Баевич, урыс милләтенә күчәсе килү гамәле белән, үзен генә түгел, татар милләтен, туган телен рәнҗетә, мыскыл итә. Әлеге спектакльне, комедия-фарс дип, тә билгеләп була. Күп кенә чыганакларда, театр белгечләре әлеге әсәрне шулай ук типологик яктан Мольерның «Мещанин во дворянстве» комедия-фарсы белән бик нык якынлыгын күрә. Әлеге охшашлык билгеләре әсәрнең диалог төзелешләрендә, баш һәм икенче пландагы рольләрдә, комедия-фарс алымнарында чагыла. Таяк белән болгау ишәрәләре дә шуның бер билгесе. Җан Баевич һәм господин Журден үз-үзен тотышларында, ишарәләр куллануда, тормышка надан карашлары белән – комик образ буларак тамашачы алдында формалаша. Киемнәрендә дә стиль ягыннан клоун образына якынлашалар. Музыкага килгәндә, композитор Фоат Әбүбәкеров комедия-фарс стилен чагылдырыр өчен, оркестровка ягыннан цирк музыкасы белән тәңгәл килгән көйләр иҗат итә. Шакирҗанның лейттемасы Асрау белән дуэт башкарганда яңгырый. Әлеге лейттема яңадан кредиторлар хорында да чагылышын таба. Композитор цитаталарны да ят итеп күрми һәм «Собачий вальс», яһүдләрнең «7, 40» көйләрен, шактый танылган «Сизый голубочек» рус халык җырын кулланып, оркестр өчен эшкәртмә ясый. Композитор, шулай ук опера «буффо» жанрдагы инструменталь өлешләрне дә күздә тотып төп комедия-фарс рухын сакларга тырыша, истә кала торган, күтәренке кәефне чагылдыра торган, шул ук вакытта абсурд һәм комик темаларны тамашачыга зур осталык белән профессиональ дәрәҗәдә җиткерә.

Әлеге мәкаләдә, тамашачы һәм театр тәнкыйтьчеләре тарафыннан зур игътибарга лаек булган, 2009 елда куелган Г. Камал театрының «Курчак туе» премьерасын югары зәвыклы куелыш икәнен исбатлап үтәсем килә. М. Гыйләҗев һәм Р. Хәмид белән авторлашлыкта 2001 елда иҗат иткән «Курчак туе» драмасы, Гаяз Исхакыйның 1900 елда язылган «Кәләпүшче кыз» повестенә нигезләнә. Режиссёр Фәрит Бикчәнтәв бу әсәрнең тирән фәлсәфи мәгънәсен, төрле символик алымнар ярдәмендә, декорацияне беренче планга чыгарып, эпизодларда диалогларны тын билгеләре аша, бер сулышта тамашачыга җиткерә ала. Димәк, бер гасырдан артык вакыт үтсәдә, татар милләтенең язмышы, намуслыкны саклау, гореф-гадәтләрне пропагандылау, ә иң мөһиме кеше язмышын курчак уенына тиңләү, проблема буларак бүген дә безнең тормышта актуаль икәнлеге ачыклана. Шекспир фикеренә якын килеп әйткәндә, бүгенге көндә бары тик халык һәм актёрлар башка. Музыкага килгәндә, режиссёр әлеге куелышта композитор Гия Канчеллиның әсәрләреннән өзекләр куллана, һәм бу бик отышлы ысул. Чөнки монда музыканың милли ягын өскә калкыту түгел, ә фәлсәфи идеяны беренче планга чыгару мөһим. Бу очракта, нәкъ менә Гия Канчелли иҗаты тулаем туры килә. Курчаклар уенын, ә бәлки аларның виртуаль йөрешен, фәлсәфи күзлектән карасаң – гомумән, яшәешен музыкаль тасвирлау бик җиңел түгел. Әлеге проблеманы, гүя жанрларга бай зур күләмле әсәрләр иҗат итүче, бигрәк тә симфо-

ния калыбын колачлап ала алган, оркестр тавышлары ярдәмендә көчле тойгылы күренешне тасвирлый алучы композитор Гия Канчелли гына чишә ала.

Йомгаклап әйткәндә, Гаяз Исхакый – зур талант иясе. Аның һәрбер әсәрендә бик зур мәгънә ята. Бу әсәрләрнең барлык укучыларга да рухи азык булуы һичшиксез. Аның әсәрләре кешене тәрбияли, әхлакый яктан ныгыта торган. Хәзерге заман кешеләре өчен дә Гаяз Исхакыйның әсәрләре актуаль, чөнки бүгенге көндә дә гадәти тормышны күздә тотсак та, язучыларның иҗатында да төп тема буларак катнаш никахлар, дорфалык, тәртипсезлек, милләтнең бетүе, искелек белән яңалык көрәше игътибарны үзенә ала. Ә Гаяз Исхакый бу проблемаларны инде бер гасыр элек күргән һәм моңа битараф кала алмаган. Бүгенге көндә дә сәхнәдә уйналган әсәрләрен карап, тамашачы беркайчан да тирән уй-кичерешләрсез таралмыйлар, ләкин теләсә кайсы режиссёр да Гаяз Исхакый әсәренә алына алмый. Моның өчен гаять күпкырлы шәхес булырга кирәк, тормыш фәлсәфәсен сәхнә теләнә күчерә белү кирәк. Аның әсәрләре буенча куелган спектакльне караган һәр кеше күңелендә ирексездән үз теленә, үз милләтенә, үз диненә соклану хисе уяна, – уйлата, елата, моңландыра. Гаяз Исхакый – бөек әдип. Ул үз каләме белән көчле! Гаяз Исхакый безгә алтыннарга тиң зур мирас калдырган. Ул иҗаты белән безгә татар милләтенең үлемсезлеген аңлата һәм гаҗәеп көчле халык икәнлегебезне әсәрләре аша исбатлый.

ӘДӘБИЯТ

1. Арсланов Г.М. Гаяз Исхакый һәм татар театры // Казан утлары. 1999. № 9. Б. 172–178.

2. Татар әдәбияты: теория, тарих. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.

## ЯҢА ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КАРАШЫ ЯКТЫЛЫГЫНДА

***Ф.Г. Галимуллин*** *(Казан)*

В статье идет речь о проблемах, поднятых Г. Исхаки в докладе, сделанном в тюркском обществе города Стамбула в 1910 году, где он прослеживает первые шаги новой татарской литературы, которая стала развиваться в конце XIX века. При этом рассматривает татарское искусство слова в сопоставительном плане с тюркской и русской литературами. Особое внимание уделяет внимание и на процесс развития татарского литературного языка, выделяя в этом деле роль Каюма Насыйри.

**Ключевые слова:** татарская литература, тюркская литература, русская литература, литературные направления, Каюм Насыри.

The article deals with the problems raised by G. Iskhaki in a report made in the Turkic society of the city of Istanbul in 1910, where he traces the first steps of the new Tatar literature, which began to develop in the late nineteenth century. At the same time he considers the Tatar art of the word in comparative terms with the Turkic and Russian literature. Particular attention is paid to the development of the Tatar literary language, highlighting the role of Kayum Nasyri in this case.

**Key words:** Tatar literature, Turkic literature, Russian literature, literary trends, Kayum Nasyri.

Үткән дәверләрдә халкыбыз турында гамьләнеп гомер кичергән олы, зыялы шәхесләребез арасында Гаяз Исхакый иң күренекле урын тота дип тулы хокук белән әйтә алабыз. Ул нинди генә шартларда да милләтебез мәнфәгатьләре белән яшәде, борчылды, гамәл кылды. Соңгы өч дистә ел дәвамында без моның бик күп мисаллары теркәлеп калган мәкаләләр, хезмәтләр белән таныша алдык, аның турында бихисап истәлекләр, язмалар кулыбызга килеп керде. Туган халкының бәхете өчен көрәшне үзенең төп кыйбласы иткән бу

шәхесебез милләтнең олы тарихын, ул яшәгән мохитне, аның күңел дөньясын, рухын, телен тирән белгән, һәм әсәрләрендә, иҗтимагый эшчәнлегендә шул хәбәрдарлыгына таянып эш иткән. Аның мәгълүматлылыгы шул дәрәҗәдә тулы һәм киң, ул төрле хәл-әхвәлләрдә, аларны бер мантыйклы эзлеклелектә тезеп, теге яки бу мәүзугка тулы бер фәнни эш дәрәҗәсендәге импровизация характерындагы сөземтәләр ясау куәсенә ия.

Әйтик, 1910 елда ул, Руссиянең салкын сөргененнән качып, җылы Төркиягә барып чыга. Бу ил, үзенең йомшак табигатенә өстәп, төрки кардәшләребезнең аңа ихлас туганнарча мөнәсәбәт күрсәтүләре белән дә якын, үз. Биредәге җылы мөнәсәбәт, шималь төркиләренә карата кайгыртучан караш мохите аның күңелен кинәндерә. Үзенә карата мондый ихтирамлылыкны Г. Исхакый гомумән татар халкына булган караш дип кабул итә. Ул, мондый якынлыкны тагын да арттыру максатында, төрки кардәшләрнең «дөрнәгендә» (оешмасында) аларны халкыбыз белән тәфсилле итеп таныштырырга ният итә һәм алар алдында таныту чыгышы ясарга ризалык бирә. Язучы буларак, ул, әлбәттә, тыңлаучыларны иң әүвәл әдәбиятыбыз белән таныштыруны максат итә.

Анда бәян ителгәннәр үз вакытында төрек һәм татар матбугатында урын ала, бу үзе генә дә Г. Исхакый чыгышында күтәрелгән мәсьәләләргә игътибарның зур булганлыгы турында сөйли. Аннан күренгәнчә, ул сүзне әдәбиятның үзеннән түгел, бәлки үз кавеменең әсәрләрдә чагылдырыла торган яшәү мохите, аны чолгап алган табигый шартлар үзенчәлекләрен аңлатып бирүдән башлый һәм дөрес итә. Ник дигәндә, Кара диңгез артында кояшның рәхимле нурларын тоеп яшәгән төрекләр өчен кайдадыр шимальдә көн итүче татарларның холык-фигыльләрендә, яшәү рәвешләрендә, үз-үзләрен тотышларында шактый гына аерымлыклар булуы бәхәссез. Алар каян килә, ничек формалаша? Аның кардәшләребезгә сөйләгәннәреннән шул аңлашыла: безгә тереклегебезне, тормышыбызны тәэмин итү өчен, һәрвакыт аларда бик булмаган каршылыкларны җиңеп, көрәшеп яшәргә кирәк, болар, табигый рәвештә, безнең алда әйткән үзенчәлекләребезне дә билгели. Чыннан да шулай бит. Ел тәүлегенең алты аен татарлар кышкы шартларда яши. Әдип аңлатуынча, «Идел буйлары ап-ак кар диңгезенә әйләнә. Суыкта үлмәс өчен, табигатьнең бу куркыныч куәте алдында изелмәс өчен, анда яшәгән кешеләр очы-кырые күренмәс, утыз-утыз биш градуска җиткән суык белән көрәшәләр. Шималь төркиләренә яшәеш һәм табигатьләренә климатның никадәр тәэсире булса, сәясәтнең дә тәэсире аннан аз булмагандыр. Казан һәм Әстерхан ханлыклары Русия дәүләте тарафыннан басып алынды. Мөселман шималь төркиләре, миллилекләрен саклый белү, мәдәниятләрен югалтмас өчен, рус христиан миллиәте һәм мәдәнияте белән көрәшергә мәҗбүр булдылар. Сәяси яктан җиңелгән бу хәлдә мәдәнияттә җиңәргә телиләр иде. Бу гаугада хәзергә кадәр җиңелмәделәр. Җиңелмәүнең төп сәбәбе – климатның аларга һәрвакыт һөҗүм итүе, һәр көчкә каршы торырлык дәрәҗәдә ныклы тәрбия алуларыдыр. Миллилекне саклау максаты белән дәвам иткән низагта шималь төркиләренең каты табигатьләре чыныкканнан-чыныга барды» [1: 191]. Шул рәвешле, Г. Исхакый шималь төркиләре гадәти яшәү алып бару өчен дә көрәшергә, тирә-ягын әйләндереп алган киртәләргә эчке, рухи каршылыкларын куярга тиеш булуын да әйтергә тиеш дип саный. Шул шартлардагы барышта аларга таяныч булган катлауны да күрсәтә. «Шималь төркиләренең диннәрен, милләтләрен саклауда иң күп эшләгән сыйныф руханилар булды,– ди ул. – Дин вә миллилекләрен саклау буенча эшләре аркасында,халык аларны милли каһарманнар, хокук, дин вә миллилекләрен саклаучы итеп кабул итте. Рухани сыйныфның рәсми рәвештә һичбер өстенлеге булмаган хәлдә, чынлыкта халык аларның хөкеме астында вә тәэсирләрендә иде» [1: 193]. Шул ук вакытта

Г. Исхакый XIX гасыр шартларында, ягъни руслар белән сәүдә, сәнәгать өлкәләрендә хезмәттәшлек күпмедер ешая башлагач, татарларның мәдәни, икътисадый тормышларында да чикләнүләрнең бераз йомшара баруын искәртә. Аның каравы инде ул милли каршылыкларга сыйнфый нигездәгеләренең өстәлә баруын да әйтә. Фабрикаларда, тимер юлларда, шахталарда «рус вә татар эшчесе бергә эшләп яши башлады», – ди.

Менә шундый шартларда, Г. Исхакый карашынча, «шималь төркиләренә Русия, Аурупа тәэсирен керткән бер гамәл мәйданга чыкты ки, ул да булса – рус әдәбияты» [1: 194]. Ул бу әдәбиятка мондый бәя бирә: «Хөррият вә тәрәккый тарафдары, зәгыйфь вә фәкыйрьләрнең яклаучысы». Русиядәге «народниклык әдәбияты» – бары русларга хезмәт итү, бары русларга файдалы булырга теләми иде, ягъни тар мәгънәсендә милли түгел иде. Аның идеясе бөтен адәм угылларына, бөтен инсаниятκә файдалу булу иде. Гавәмпәрвәр әдәбият, рус, татар, яһүдине аермыйча, барысына да бердәм мөрәҗәгать итте» [1: 195]. Менә болар, әлбәттә, татарларның фикерле вәкилләренең игътибарын рус әдәбиятына дикъкат итәргә, анда үткәрелгән карашлар белән танышырга, билгеле бер чагыштырулар, нәтиҗәләр ясауга китерде. Шуның нәтиҗәсендә татарлар да, як-якка каранып, шушы хәлләрдә үзләренең нинди урында булуларын да билгеләргә омтылдылр. Шундый шәхесләрнең беренчеләреннән итеп Г. Исхакый Шиһабетдин Мәрҗанине атый. «Бохара фикер вә гыйлемнәренең җитәрлек булмавын башлап күргән галимебез шәригать законнарын яхшы белүче вә тарихчы ахун Шиһабетдин әл-Мәрҗани мәдрәсәләремезне вә мәдрәсәләремездәге гыйлем алу ысулларын тәнкыйтьли башлады. Русча гыйлем алган, хәзерге әдәбиятымызның тәүге хезмәтчесе Габделкаюм әфәнде ән-Насыйри исә, әкренләп, Аурупа фикере вә гыйльмен таратуга кереште» [1: 195].

Күрәбез, Г. Исхакый төрек кардәшләр алдында татарлар турында, үткәне, хәзергесе, яшәү шартлары, күңел дөньясы үзенчәлекләре, тулаем Русия шартларындагы хәле хакында җентекле күзәтү ясый. Дөресен әйткәндә, аның бәян иткәннәре төрекләр өчен генә түгел, ул вакыттагы татарларның үзләре өчен дә күп яктан яңача булулары белән әһәмиятле иде. Әдәбиятыбызның берберләреннән аермалы булуларының сәбәпләрен шул рәвешле аңлатып бирү мантыйгына игътибар юнәлә.

Әдәбият – сүз сәнгате. Шуңа күрә Г. Исхакыйның сүз сөрешен татар әдәби теленең формалашу үзенчәлекләренә игътибар биреп дәвам иттерүе дә үзеннән-үзе аңлашыла. Саф Казан татарчасын китап битләренә мендерүдә ул шул ук К. Насыйри хезмәтләрен тәкъдир итә. «Габделкаюм әфәнде хәзерге татар әдәбиятының бабасы. Ул татар әдәбиятына нигез корды һәм шималь кышының тәэсиренә каршы торырлык ныклы бер нигез корды», – ди ул [1: 195]. Әлеге «милли уяну Казан татарларының әдәбиятына гына кагылмыйча, бөтен хәятларын да үз эченә алды. Аурупа мәдәните илә коралланган кавемнәргә каршы көрәштә җиңелмәс өчен, татар хәятын Аурупа мәгарифе белән коралландыру мәҗбүрияте хис булынды. Мәктәпләргә, мәдрәсәләргә ислях ясау мәсьәләсе мәйданга чыкты. Әдәбиятка, театрга, гәзитләргә ихтыяҗ көчле тоелды» [1: 195].

Шуннан соң Г. Исхакый 1883 елдан алып Кырымда чыгып килгән «Тәрҗеман» гәзитенең татарларның заманча фикерләү дәрәҗәсенә һәм мәдәни үсешебезгә ясаган йогынтысын да тиешенчә бәяли. Исмәгыйль Гаспринскийның бу гәзитәсеКырым татар телендә чыкса да, «иң күп укучылары Казан татарлары булды»,– ди. – Шуңа күрә аның тәэсире Кырымга, Кавказга караганда безгә зуррактыр», дигән нәтиҗә ясый. «Искелекне саклаучы ролен үзләренә йөкләгән руханилар ислях тарафдарлары белән көрәшә башладылар. Аларның низагына иң беренче сәбәп, шул рәвешле, «педагогика мәсьәләсе булгандыр», – дигән

нәтиҗәгә килә. Аның дөрес аңлатуынча, – «ысулы җәдид вә ысулы кадим тарафдарларыикегә аерылган иде. Соңрак бәхәсле мәсьәләләрнең даирәсе бөтен иҗтимагый мәсьәләләргә күчте» [1: 198]. Боларны бәян итү Г. Исхакыйга шулай ук яңа әдәбиятыбызның асылын җиткерү, шушы көрәшләр эчендә «безнең яңа шималь төрки әдәбияты туды, үсте», – дигән нәтиҗә ясау өчен кирәк иде.

Аннан соң гына Г. Исхакый бу яңа әдәбиятның үзенчәлекләрен билгеләүгә күчә. «Көрәш мәйданында туган, үскән, таза вә көчле бер әдәбиятның төп сыйфаты сугышчан булуы табигыйдер»,– ди. «Көрәшчән, гаугалы, даими бәрелешүчәндер» дип тә өсти [1: 197]. Әдәбиятыбызның икенче бер үзенчәлеген ул аның демократик булуында күрә. Халык мәнфәгатен саклау, милләтебезнең күпчелеге теләкләрен яктырту, зәвыгын үстерү, җаһиллеккә каршы һәм тәрәкъкый яклы булучыларның сугышчанлыгы, конфликтлылыгы хас. Өченче бер сыйфаты итеп мәсләклелеккә хезмәт итү икәнлеген әйтә. «Төп мәсләк – татарларның милли характерларын саклаган хәлдә, Аурупа мәдәниятенә кертүдер», ди [1: 200]. Әгәр төрек әдәбиятында французлардан күчереп алынган образлар төрекләштерелеп бирелсә, бездә типлар бары хәятыбыздан алына, дип, аларның үз әдәбиятлары белән дә чагыштырып күрсәтә. «Безнең хатын-кызларыбыз, хәятта булган кеби, китапта да ирләрдән көчлерәк фидакярләр», диеп куюында аның үз милләтен ихлас яратуы һәм төрле яклап белүе күренеп кала. Шуны раслау максатында ул үзенең «Кыямәт», «Алдым-бирдем», «Өч хатын белән тормыш» әсәрләрендә сурәтләнгән хатын-кыз образларын мисал итеп китерә.

Аның бу чыгышындагы тагын бер мөһим нәрсәгә игътибар юнәлә. Без, пролетариат диктатурасы хакимлек иткән дәверләрдәге кайбер традицияләрне дәвам иттереп, һаман да әдәбият тарихының мәгълүм бер чоры булган XX йөз башы татар әдәбиятын 1905 елгы вакыйгалар тәэсирендә башлана дип әйтеп киләбез. Моны нәкъ шул вакыттагы инкыйлаб нәтиҗәсендә татарларга да вакытлы матбугат булдыру мөмкинлеге бирелү, шушы хәлнең сүз сәнгате үсешенә уңай йогынты ясавы, җәмгыятебездәге хәятка аваздаш темаларның әсәрләр үзәгенә куелуы, каләм әһелләребезнең иҗади сулышлары киңәеп китүләре белән аңлатабыз. Болар барысы да дөрес, аларны инкарь итү кирәк тә түгел. Г. Исхакый исә, шул заман кешесе буларак, мәсьәләгә икенчерәк карый һәм сүз сәнгатебезнең бу чоры чиген башкача билгели. «Әдәбиятыбызның күзгә күренеп мәйданга чыгуы 1895 елдыр: бу елда әдәби роман дип әйтерлек бер әсәр – казый Ризаэддин әл-Фәхретдиннең «Сәлимә»се таралды. Унбиш ел эчендә бу яңа әдәбият шактый үсте: «Сәлимә»дән соңрак, минем, Галиәсгар Камалның, Фатих Әмирханның, Ярулла Вәлинең вә тагын яшь мөхәррирләрнең хикәя, роман вә драма әсәрләре бер-бер артлы чыга торды» [1: 197].

Шул ук вакытта ул тезмә әсәрләрнең нык күзгә ташлануын да шатланып хәбәр итә. «Бүген үзенә генә хас булган фикерле шагыйрьләремез бардыр, аларның иң алдынгы карашлысы, һич шөбһәсез, Габдулла әфәнде Тукаев исемле бер яшь егеттер. Тукаевтан соңрак Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд кушаматы артына яшеренгән хөрмәтле вә шактый яшь бер зат илә Габделмәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Укмаси, Бәшири кебек яшьләр килә» [1: 198].

Яңа әдәбиятыбызның йөзен билгеләгәндә, Г. Исхакый әсәрләрнең телендәге аерымлыкларга да игътибар итә. Ягъни мөхәррирләребез әсәрләренең темасы, күтәргән мәсьәләләре белән беррәттән, аларның тел җәһәтеннән дәбөтенләй аерылып торуларын әйтә.»Бөтен әсәрләремез халык кулланган, аңлашкан бер тел илә, гавәм теле белән язамыз. Безнең шималь төркиләренең әдәби телләре сезнеке кеби (төрекләрнеке кебек. – *Ф.Г.*) гарәпчә-фарсыча, итальянча сүзләрнең төрки кушымчалар белән багланмасыннан хасил булган бер гашура түгелдер, безнең телемез төрки теленең бер сөйләшедер» [1: 198]. Аның бу хактагы уйла-

нуларыннан шул аңлашыла: әдәби әсәрләрнең теле иң беренче чиратта укучыга җайлаштырылган булырга тиеш. «Без язуларымызны халык аңлаган тел белән язуымыз табигый түгелмени? Һич курыкмый дәгъва итә алам ки, безнең әдәбиятымыз, сезнең әдәбиятыгызга нисбәтән, тагы да ныклы бер мәдәният нигезе кора. Без милләтемезгә язуыбыз белән сездән дә күбрәк хезмәт итәмез» [1: 199]. Доклад киләчәккә ышаныч булән сугарылган сүзләр белән тәмамлана. «Безнең шималь төркиләре яшьтер. Бу яшь милләт якты бер идеалга омтыла, теләгенә ирешү өчен һәртөрле киртәне бетерәчәгенә, бөтен пәрдәләрне каерып атачагына тәмам инангандыр. Шул иман белән ул көчле һәм тапкыр. Көлә, ерлый, хәтта Газраилне күргәндә дә ер ерлый, гауга итә, йөри, яши... Бу шуклык, бу ерлау, бу гауга, бу хәрәкәт, нәтиҗәдә... менә, әфәнделәр, безнең әдәбиятымыз!» [1: 203].

Күреп үткәнебезчә, әлеге докладында XX йөз башы татар әдәбияты үсеше мәсьәләләре турында сүз алып барганда, Г. Исхакый бу эшкә үзенең дә турыдан-туры катнашы барлыгы турында да әйтергә онытмый. Болай итәргә аның тулы хокукы бар. Ул инде яңа гасырның икенче елында ук, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәрен язып, якындагы йөзьеллыкларда милләтебезгә юкка чыгу янаячагы турында кисәткән, бу афәтнең сәбәпләрен дә күрсәткән иде. Мондый фаҗигага юлыкмас өчен, нинди юнәлешләрдә уй-фикер йөртергә һәм гамәл кылырга кирәклеге турындагы мәсьәләләрне зыялыларыбыз алдына куюы белән замандаш зыялыларны сискәндереп җибәрә. Һәм бу юнәлешләрдә үзе үк җиң сызганып эшкә керешүе аның И. Гаспринский әйткән «фикердә, эштә бердәмлек» шигарен үзе өчен дә яшәү һәм иҗат итү кагыйдәсе итеп алганлыгын раслады. Бу вакытта инде аның иҗат байлыгында «Зиндан», «Тормышмы бу?», «Татар гакылы», «Мәдрәсә җимеше», «Башкорт бәхете», «Шәкерт абый» кебек проза, «Алдым-бирдем», «Тартышу», «Җәмгыять» кебек драма әсәрләре бар иде. Аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең аның «Инкыйразы»ыннан килеп чыгуына, шуларны тормыш чынбарлыгына тугры калып тасвирлавына сокланырга гына кала.

Җыеп кына әйткәндә, Г. Исхакый әлеге докладында 1895 елдан алып 1910 елга кадәрге, ягъни 15 ел вакыт аралыгындагы әдәбиятыбызга төрле яклап тәфсилле аңлатма бирә, һәрбер күренешне үз карашы белән яктырта, ачык итеп дәлилли. Аның әлеге чыгышы моннан йөз ел элеккеге әдәбиятыбызның гомуми асылын аңлауда XXI гасыр башында яшәүчеләргә дә ышанычлы нигез булып хезмәт итә ала диясе килә.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Гаяз Исхакыйның татар әдәбияты турындагы доклады // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Т. 6. Б. 191–203.

## УТОПИЧЕСКИЕ И АНТИУТОПИЧЕСКИЕ МОТИВЫ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ИСХАКИ, Ф. АМИРХАНА И Г. ГУБАЙДУЛЛИНА

***Р.Р. Галиуллин*** *(Яр Чаллы)*

В статье рассматривается особенности фантастической прозы, своеобразие жанра утопии и антиутопии в татарской литературе начала XX века. Рассматриваются особенности жанра утопия / антиутопия на примере творчества Г. Исхаки, Ф. Амирхана и Г. Губайдуллина.

**Ключевые слова:** татарская литература, жанр фантастики, утопия/антиутопия, Ф. Амирхан, Г. Исхаки, Г. Губайдуллин.

Features of fantastic prose are considered in the article. The originality of the genre of utopia and anti-utopia in the Tatar literature of the early twentieth century. Specifics of the

genre of utopia / anti-utopia are considered as an example of creativity, G. Ishaki, F. Amirkhan and G.Gubaydullin.
**Key words:** The tatar literature, genre fiction, utopia/anti-utopia, F. Amirkhan, G. Iskhaki, G. Gubaydullin.

В настоящий момент существуют три основных жанра фантастической литературы: научная фантастика, фэнтези, социальная фантастика.

В социальной фантастике ведущую роль играет описание отношений между людьми в обществе. Использование фантастических мотивов позволяет показать развитие общества в необычных, никогда не существовавших в реальности условиях. К социальной фантастике относится утопия и антиутопия, т.е. «что должно быть в идеале» и «чего не должно быть в идеале» [1: 45].

Ученые склонны полагать, что утопия и антиутопия являются единым жанром по природе. Разница лишь в том, что антиутопия это своего рода реакция на утопию. Об этом в частности пишет Н. Воробьева: «Антиутопия произошла из утопии, как в любой другой сфере из одного и того же явления появляются pro и contra. Антиутопия появилась как *реакция* на утопию, как *необходимая полемика* с ней, порожденная или спровоцированная ею же для упрочения своих позиций, как недостающая опора для прямостояния конструкции. Появляются, формируются и закрепляются на всем большом пути эволюции общие черты, определившие и составившие специфику жанра утопии» [2: 78]. Об этом же пишет А. Осипов: «Антиутопия – разновидность фантастики, выступающая как антитеза утопии» [8: 28].

В современном теоретическом литературоведении помимо классического понятия «жанр» появились и новые понятия, а именно «антижанр» или «жанровая модификация». «Художественная структура антижанра, в значительной мере определяющаяся особенностями формы «породившего» его классического жанра, наполняется, по сравнению с исходным жанром, содержанием с противоположной идейной направленностью, так как антижанр ставит под сомнение целостность идей, воплощаемых, как правило, в произведениях исходного жанра» [5: 60]. Таким образом происходит наложение идейного содержания антижанра, на идейное содержание исходного жанра.

Художественное своеобразие антижанра хорошо видно на примере антиутопии. Основной жанрообразующий элемент антиутопии – спор с утопией, полемика с ней на уровнях отбора обобщаемого в произведении жизненного материала, идей, проблем, образов героев. «Как и утопия, антиутопия изображает целостный образ мира с характерными для него политикой, экономикой, научными представлениями, культурой, религией, моралью. Но эти художественные средства воплощают содержание с противоположной идейной направленностью» [5: 62].

Большинство определений «утопии» объединяет два понятия: пространство, изолированное от большого мира (город, остров), и время, точнее будущее. «Утопия литературная – художественное произведение, содержащее воображаемую картину будущего общества» [5: 854]. С течением времени принципиальное различие между ними становится все более проблематичным.

Парадоксальность утопии в том, что ее «фантастическое будущее» изначально несбыточны с точки зрения антиутопического мира. С другой стороны, утопические проекты вполне реализуемы, воплощаясь в идеологии, которая всегда утопична. «Обычно в утопии преобладает социально-бытовая, нравоописательная проблематика. А антиутопия, подобно роману, воссоздает судьбу личности в мире. Сюжет утопии статичен. Антиутопия, напротив, отличается динамичным действием» [5: 62].

Антиутопия обычно направлена на развенчивание утопических тенденций, высмеивает увлечение НТР. Отсюда проистекает еще одна нить тесной связи утопии и антиутопии: как только антиутопия отойдет от своего вектора, показав возможный путь исправления «плохого» общества, сделает хотя бы намек на возможность положительного исхода, тут же она оборачивается новым утопическим проектом.

Любой эпохи характерна та или иная утопическая идея. В Древней Греции идеи Платона, в Средневековье идеи Т. Мора, эпоха Возрождения, эпоха Просвещения, соц. реализм.

Нас в частности интересует утопия эпохи Просвещения. «Утопия Просвещения – это идея воспитания и образования, приобщения к знаниям всех граждан» [2: 87]. Именно эти идеи культивировались в татарской литературе через просветительский реализм. И были очень популярны в обществе в конце XIX начале XX века. В эту же эпоху видоизменяется движение джадидизма, которое зародилось в XIX, стремясь избавить народ от невежества, рабских оков средневековья, и хотело сделать его просвещенным. «В начале XX века под благоприятным воздействием внешних, общероссийских и внутренних факторов, это движение превращается в крупную силу, новую национальную идеологию, способную проникнуть во все слои татарского общества» [10: 7].

В эту же эпоху творит и Ф. Амирхан, один из ярчайших представителей просветительского реализма. В его первом рассказе «Сон накануне праздника» («Гарәфә кич төшемдә», 1907) преобладало ироничное отношение к действительности. «Обращаясь к приёму контрастов – утопии и антиутопии, яви и сна, к эстетике прекрасного и безобразного, идеального и реального, автор подвергает критике феодальную косность, царящую в татарском обществе, утверждает идеалы национального возрождения» [7: 145].

Именно его перу принадлежит одно из произведений фантастики, которое мы можем рассмотреть в рамках антиутопии – это повесть «Фатхулла хазрат» («Фәтхулла хәзрәт», 1909). В данной повести события разворачиваются в середине XX века, «чтобы выявить комичность феодально-патриархальных устоев, средневековой морали, религиозной схоластики, автор воскрешает главного героя, кадимиста Фатхуллу, в лаборатории Казанского университета через сорок лет после его смерти и переносит события в 1950 год, то есть в середину двадцатого столетия, в век научно-технического прогресса, торжества гуманистических нравственных идеалов» [7: 145]. Это собирательный образ, через который автор критикует религиозных деятелей схоластов-кадимистов начала века, обвиняя их в невежестве, лицемерие.

Безусловно, это сатирическая повесть [4], но в ней есть место и утопическим представлениям. По замыслу автора движение джадидистов, просветителей одержало вверх над схоластами, проникнув во все сферы жизни общества (наука, религия, искусство и т.д.). Р. Ганиева пишет: «На наш взгляд, конфликт произведения «Фатхулла хазрат» далёк от отражения социально-экономических проблем тогдашнего татарского общества. На всех художественных уровнях произведения внимание автора направлено на показ духовной нищеты и низкой морали защитников феодальной старины. Фатхулла хазрат Ф. Амирхана – собирательный образ, вобравший в себя типические отрицательные черты кадимистов, “святых отцов” нации. Повесть Амирхана “Фатхулла хазрат” – классический образец произведения просветительского реализма, соотнесённого с элементами романтической утопии об идеальном будущем татарского общества» [5: 93].

Другое произведение этого же автора носит уже антиутопический характер – это повесть «Дядя Шафигулла» («Шәфигулла агай», 1924). Это тоже

своего рода шарж, но уже не на кадидистов, на правительство советов. «Через судьбу Шафигуллы показывается, какие духовно-нравственные потери понес татарский народ в эпоху «советов» [10: 59]. В этом произведении ярко прослеживаются то, каким образом разрушились мечты интеллигенции, связанные с падением царизма и приходом к власти большевиков. Именно в этом мы можем проследить антиутопические моменты. «Хотя автор рекомендует его как дружеский шарж, рассказ больше напоминает памфлет на молодое советское государство и объединяет в себе черты сатиры и футурологии, является модификацией утопии – антиутопией» [7: 146].

Еще одна фантастическое произведение, написанное в это время, повесть Г. Исхаки «Исчезновение через двести лет» («Ике йөз елдан соң инкыйраз», 1902). Р. Ганиева жанр этого произведения определяет как антиутопия, дистопия [10: 88]. В этом произведении мы можем обнаружить как утопические мотивы (это всемирная известность булгар, развитие булгарской культуры, искусства, музыки и т.д.), так и антиутопические (исчезновение нации) Здесь ярко проявляется то как «автор антиутопии воплощает свою позицию с помощью приемов и художественных средств утопии» [5: 62].

А. Сахапов в своей монографии проводя параллели между фантастическими произведениями Ф. Амирхана и Г. Исхакыя, говорит, что оба произведения это две части одного целого [12: 109].

Г. Исхаки в рассказе «Лукман-хаким», написанном в Берлине в те же годы, что и «Шафигулла агай» Ф. Амирхана, также перенёс в будущее отрицательные тенденции общественного развития в России, присущие настоящему, и нарисовал худший образ мира по сравнению с той действительностью, которую он хорошо знал. «Шафигулла агай» отличается от антиутопической повести Г. Исхаки тем, что в последней смещены временные и пространственные структуры, используются фантастика, символы, аллегории, гиперболы, устойчивые мифологемы, архетипы, что обусловливает и особенности образно-композиционной структуры и стиля. Эти художественные средства воплощают содержание с противоположной идейной направленностью, но без комизма. «Лукман-хаким» ближе к субжанру дистопии – типу антиутопии, который разоблачает утопию, описывая результаты её реализации. Она отличается от тех антиутопий, которые изобличают саму возможность осуществления утопии или абсурдность и ошибочность логики её создателей.

Также в качестве антиутопического можно отметить произведение Газиза Губайдуллина «Одна мечта» («Бер хыял», 1913). Повествование начинается с описания райской жизни на земле, где царит всеобщий мир, покой и дружба, где хищники и их жертвы умиротворенно сосуществуют. Но наступают «страшные» времена, нарушаются законы мира и порядка, земля погружается в греховный мрак. Автор делит человеческое существование на две эпохи – «до» и «после». «До» – период гармонии человека и природы, а «после» – период нарушения законов мироздания, эпоха кровопролития, убийств, тюрем, т.е. современность. «Г. Губайдуллин объясняет жестокость современной эпохи как наказание человечеству» [11: 98]. Но есть выход из сложившейся ситуации – это духовное очищение. Безусловно, в произведении ярко прослеживаются библейский мотив грехопадение человека, а самому повествователю свойственны пророческие черты, но он бессилен что-либо изменить. «Его мечта неосуществимая утопия – свободная, спокойная жизнь» [11: 98].

Таким образом мы видим, что в начале XX века в татарской литературе под влиянием социальных, общественных конфликтов возникают фантастические, утопические/антиутопические произведения, требующие более глубокого изуче-

ния. Но мы с четкостью можем сказать, что все они создавались с целью показать каким должен быть идеальный социальный строй, общественная жизнь.

ЛИТЕРАТУРА


1. Брандис Е.П. Научная фантастика и художественное познание действительности // Художественное творчество. М.: Наука, 1983. С. 37–58.
2. Воробьева А.Н. Русская антиутопия в контексте мировой антиутопии: дис. ... д-ра филол. наук. Самара., 2009. 585 с.
3. Ганиева Р. Художественные поиски Фатиха Амирхана // Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. С. 92–101.
4. Галиуллин Р.Р. Ф.Шәфигуллин иҗатында юмор һәм сатира // Диалог культур в образовательном пространстве: Всерос. научно-практ. конф., Набережные Челны, декабрь 2017 г.: сборник материалов / отв. редактор Д.Ш. Гильманов. Набережные Челны: НГПУ, 2017. С. 59–62.
5. Давыдов Т.Т., Пронин В.А. Теория литературы: учеб. пособие. М.: Логос, 2003. 232 с.
6. Краткая литературная энциклопедия. Т. 7. М.: Советская энциклопедия, 1972. 1008 с.
7. Макарова В.Ф. Антижанровые формы: особенности проявления смеха в татарской литературе начала XX века (на примере сатирических произведений Фатиха Амирхана) // Ученые записки Казанского Государственного университета. Т. 150. Кн. 6. Гуманитарные науки. 2008. С. 144–149.
8. Осипов А. Фантастика от А до Я. Краткий энциклопедический справочник. М.: Дограф, 1999. 352 с.
9. Философский энциклопедический словарь. М.: Сов. Энциклопедия, 1983. 840 с.
10. Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты: дәреслек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. 230 б.
11. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр, 2003. 255 б.
12. Сәхапов Ә. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты: монография. Казан: Мирас, 1997. 528 б.


## БЕЗ ҺАМАН АҢА БУРЫЧЛЫ
## (Татар шигъриятендә Гаяз Исхакый)

***Т.Н. Галиуллин*** *(Казан)*


Создание поэтического облика писателя, борца, общественного деятеля Гаяза Исхаки, начатый еще Г. Тукаем, после реабилитации его имени и наследия было продолжено современными татарскими поэтами, как Г. Афзал, А. Халим, Г. Мурат, Ф. Сафин, Ф. Тарханова и др. Созданы поэмы «Пророк» А. Махмудова, «Два эмигранта» Р. Низами, «Три вечера с Г. Исхаки» Р. Маннана, в которых сделана попытка более глубокого обощения жизни и творчества классика татарской литературы.


**Ключевые слова:** классик, литература, наследие, современность, поэзия, личность, творец.



The creation of poetic image of a writer, a fighter G.Ishaki, G. Tukai started after the rehabilitation of his name and heritage was continued contemporary Tatar poets such as H. Afzal, A. Halim. A. Murat, F. Tarhanova and others. Created poems “Prorok” A. Mahmutova, “Two emigrant” R. Nisami, “Three evenings Ishaki” R. Manana, in which an attempt is made deeper generalizations in the life and work of classic of Tatar literature.


**Key word:** classic, literature, heritage. present day, poetry, personality, creator.


Халыкның аң үсеш дәрәҗәсе, мәдәни-әхлакый өлгергәнлеге, күпмедер күләмдә, тарихына, шул юлны билгән асыл ул-кызларына, энҗе бөртекләредәй балкып утырган әдәби җәүһәрләренә, фәнчәрәк әйтсәк, иҗади мирасына мөнәсәбәтендә күренә. Бу җәһәттән бәяләгәндә, шәхесләребезне олылау, кем икәнебезне, нинди рухи байлыклар варисы булуыбызны оныттырмау, искә төшереп тору юнәлешендә, үзебезчә, хәлебездән килгәнчә, тырышкан булабыз. Аерым алганда, олуг галим-тарихчы, акыл иясе, дин реформаторы Шиһаб Мәрҗәнинең олуг юбилеен зурлап уздырдык. Әлбәттә, кемдер ничек кенә тырышсагыз да, мәгариф, мәгърифәт өлкәсендәге хезмәтләренә, шәхесенә, «Шиһаб хәзрәт»

мәрсиясендә Тукай биргән югарылыкка күтәрелә алмадыгыз дияр. Шулай да, Тукайның «Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне мәшхәргәчә телләр сөйләи, язар каләм!», дигән васыятен үтәү юлында кала алды дип уйлыйм.

Беркадәр соңарып булса да, фани дөньяда яшәвенең мәгънәсен туган милләтенә хезмәттә, аны батыр йөрәкле, азат, ирекле итеп күрәсе килгән, шуның өчен барлык авырлыкларга, кимсетүләргә түзгән олы шәхес, бөек язучы, журналист, көрәшче Гаяз Исхакыйның 140 еллыгын билгеләп үтәбез. Ул бүгенге сәяси-мәдәни вазгыятьтә дә киңәшчебез, ярдәмчебез булып кала һәм аның рухы дөрес аңлавыбызга, бәябезгә мохтаҗ. «Мәдәни җомга» В. Имамовның «Кайталмаган Исхакый» исемле җан авазы мәкаләсендәге «Республикабызның бер генә почмагында да аны лаек рәвештә билгеләп үтү күренми», дигән фикере белән бәхәсләшеп булмый.

Г. Исхакый иҗатына игътибар туган елын, аен искә төшергәндә, дөрләп кабынып ала да, әүвәл сүлпәнәя, акрынлап бөтенләй дярлек сүнә. Җөмләдән, аның 130 еллыгына Казан дәүләт университетының яшь шагыйрьләре Г. Исхакыйга юлланган әсәрләрдән торган газета чыгардылар. Аның 140 еллыгына шундый гамәлне башкарырлык иҗади көчләр табылырмы?

Олы шәхесләргә мөнәсәбәт нәкъ туган көнендәге чыгышлыр белән бәяләүдән бигрәк, аның образының, әсәрләрендә, чыгышларында алга сөргән мөстәкыйльлек таләп итеп чаң суккан фикерләрнең халкыбызның җанына үтеп керердәй әдәби, публицистик әсәрләрнең сыйфаты белән билгеләнә. Бу очракта да, янәдән зирәклеге һәм алдан күрүчәнлеге белән Тукай шигырьләре искә төшә. Шул хәтлесе үзенчәлекле:Тукай белән бер чорда исән-имин яшәгән шәхесләрдән бары тик Гаяз Исхакый гына аның игътибарына лаек була. Соңгысы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге, мөстәкыйль газеталар чыгаруы, туктаусыз кулга алынып, Чистай, Казан, Себер төрмәләрендә тотылса да, сынмаган, сыгылмаган холкы белән ерактагы якты (алар бер тапкыр да очраша алмаганнар) йолдыз кебек Тукайда соклану, теләктәшлек хисе уята. Шагыйрь Исхакыйның халыкта милли рухны саклау, мәгърифәтен үстерүюнәлешендәге үҗәтлеген хуплап, 1907 елда бер-бер артлы «Тавыш хакында» һәм «Кем ул?» исемле шигырьләрен язып чыга. Ундүрт юлдан торуы, кафияләү үзенчәлеге белән сонет жанры таләпләренә җавап биргән «Кем ул?» әсәрендә Тукай лирик затны сәләтен, рухи күәсен халык мәнфәгатьләрен яклауга багышланган мөрәүвәтле зат итеп сурәтли.

Исхакый туган иленә «кайтып», тулысынча акланып, татар халкының милли аңын уяту, милли рухын ныгыту, милләттәшләрен берләштерү юнәлешендәге эшчәнлеге тулырак ачыла барган саен Тукай белән Исхакыйны янәшә кую ихтияҗи традиция буларак кабул ителә, шигырь юлларына үтеп керә.

Типсә әгәр йөрәгеңдә Тукай йөрәге
Әйткән сүзең, кылган догаң –халкың кирәге.
Исхакыйча фикерләсәң илнең язмышын –
Шыңшыу түгел, күкрәү булыр сөрән тавышың.
(Риза Шәфи. «Иң-иң кирәк»).

«Без – Тукайлы» лиро-эпик поэмасында Э. Шәрифуллина шагыйрьнең шәҗәрәсе, татар сүз сәнгатенә алып килгән яңачалыгы турында яза да, Исхакыйга килеп чыга.

Акчурасы, Бигиевы, Түнтәрие,
Үзе генә ни тора бит Исхакые!.
(Э. Шәрифуллина. «Без – Тукайлы!»).

Г. Исхакыйның иҗаты, исеме, эшчәнлеге хәтта аның исеме турыдан-туры әйтелмәгән очракта да, аның идеяләренең, хыялларының тәэсирен бик күп

шигырьләрдә сиземләве, ягъни аның наменә атап язылмаган юлларда да аңа кинаяне аңлавы кыен түгел:

Дөнья куып, мәшәкатьләр гизеп
Йөресәк тә әллә кайларда,
Оныттырып барлык борчуларны
Туган нигез дәшеп кайтара.
(Р. Корбан. «Туган нигез»).

«Шәхес» шигырендә Р. Рахмани Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге, илдән-илгә гизеп азатлык, көрәш идеясе белән янып йөрүен берничә сүзгә сыйдыра сыман.

Малы юк...
Иң зур байлыгы –
Аның сүзе бар!
(Р. Рахмани. «Шәхес»).

Гаяз Исхакыйның исеме вә иҗаты ясалма киртәләрне вата-җимерә халкыбызга кайткач, әдипнең шигъри сынын тудыру юлына беренчеләрдән иң милли рухлы, татарлыгы, көрәш дәрте һәр юлыннан аңкып торган Гамил Афзалның чыгуы табигый иде. «Инкыйразга каршы» (Г. Исхакыйга), «Күңел яктысы» шигырьләрендә Г. Афзал остазын милли идеалына турылыклы, башбирмәс холыклы шәхес итеп сурәтли. Шагыйрь Исхакыйны туган халкы язмышы өчен үзен-үзе аямыйча көрәшүче, дөньяга сибелгән татар балаларын уртак зиһиният (идеал) тирәсенә туплау өчен янып-көенеп яшәүче пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрә. «Инкыйраз дисең син, мелла Гаяз, Син акыллы егет булгансың», дип гади генә мөрәҗәгать белән башлап, ул аны тизрәк туган иленә «кайтуын» тели, чакыра.

Мин дә кайтам, Илдә кем бар дисәң,
Эш табылыр, агай, сиңа да.
Кол Гали дә, «Идегәй» дә исән,
Тукай да бар әле дөньяда.
(Г. Афзал. «Инкыйразга каршы»).

А. Хәлим «Исхакый каурые», Ә. Мәхмүдов «Милләт сакчысы», Ф. Сафин «Җомга көн, кояш чыкканда...», Ф. Тарханова «Яуширмә» һ.б. багышлауларның фәлсәфи-әхлакый эчтәлеге, мәгънәви юнәлеше Көнчыгыш шигъриятенә хас «каурый», «йөрәк тәхете», «шәм», «изге теләк», «күңел яктысы» кебек символик образлар ярдәмендә романтик яссылыкта, психологик анализ алымнарын иркен куллануда ачыла.

Татар йөрәгендә тәхет биләп,
Кара почмакларын балкытып,
Безнең алда, изге теләк теләп,
Син баргансың икән шәм тотып.
(Г. Афзал. «Күңел яктысы»).

Киң гомумиләштерүгә, шәхесне төрле яклап сурәтләүгә, идеалларын, омтылышларын, холкын-менәзен аңларга мөмкинлек биргән поэма жанрында да үзенчәлекле эзләнүләр бара. Бу очракта Ә. Мәхмүдовның «Пәйгамбәр», сәнгать, музыка үсешенә зур өлеш керткән фидаи шәхесләргә игътибарлы Р. Низаминың «Ике мөһаҗир», Р. Мәннынның балалар, үсмерләр өчен язылган «Исхакый белән өч кич» поэмаларын күздә тотам.

Г. Исхакыйның наменә багышланган тезмә әсәрләрне кабызган милли ялкынны, аның әсәрләренә хас кешегә, туган җиргә бирелгәнлекне, хөрмәтне яңа

буынга җиткерү, даһи язучының тормыш юлы, эшчәнлеге белән горурлану мотивы якынлаштыра. Шагыйрьләр инкыйразны булдырмау, милләттә киләчәккә ышану хисен саклау турындагы хыялларныбүгенге көн проблемалары белән бердәмлектә карарга тырышалар.

Мин Ә. Мәхмүдов, Р. Низами поэмалары турында үз фикеремне укучыга җиткергән, тәфсилле сүз алып барган идем. Кабатланып тормастан, ошбу әсәрләрнең берничә үзенчәлегенә генә игътибарны юнәлтәсе килә.

Бер яктан, шагыйрьләр Г. Исхакыйның әдәби-сәяси эшчәнлеген генә түгел, ә аның кешеле сыйфатларын тирәнрәк ачарга тырышсалар, икенчедән, остазларының идеяләрендә хәзер татар халкы кичергән авыр вазгыятьтән чыгу юлларын эзлиләр.

Шагыйрьләр фикеренчә, пәйгамбәрләрдәй олылыкка, хөрмәткә Г. Исхакыйны халык мәнфәгатьләре белән яшәү, намуслы, иманлы тормыш алып бару, милләттәшләре илә бердәмлек эзләү күтәрә. Әлеге әхлакый-фәлсәфи катлам Ә. Мәхмүдов поэмасында «халыкның гомерен даһилар озайтыр», «Гаяз фикере... үлемсез» кебек үтемле, афористик юлларда ачыла. Хронотопның (вакыт белән ара пространство бердәмлеге) иркен уйлануларга, нәтиҗәләргә мөмкинлек бирүе, каһарманның яшәү рәвешен еш кына торган урынның билгеләве, Исхакый әсәрләренең халыкка тәэсири көче турында уйланулар шәкелне дә үзгәртеп, төрләндереп торырга мөмкинлек бирәләр, ягъни эчтәлекнең байлыгы форма ireклегенә юл ача. Җыеп кына әйткәндә, Ә. Мәхмүдов каһарманын дөреслек эзләү юлында кыйбласын тәгаенләгән, максатын, ниятен, омтылышын анык белгән, җитлеккән милләтпәрвар шәхес итеп сурәтли.

Р. Низаминың «Ике мөһаҗир» поэмасы ике тарихи затны – татар әдибе Гаяз Исхакый белән төрек шагыйре Назыйм Хикмәтне үзәккә ала. Бу каһарманнарны илдә урнашкан сәяси вазгыять аркасында читтә гомер сөрү мәҗбүрияте тудырган фаҗигале язмышлары якынлаштыра. Әмма конфликтның шартлары, мотивлары төрле, капма-каршы. Мәкер, алдау юлы белән хакимиятне кулларына төшергән большевикларның асылын, пәйгамбәрләрчә сизгерлек белән төшенгән Гаяз Исхакый чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр була һәм көрәшен шунда дәвам итә. Назыйм Хикмәт исә, киресенчә, коммунистлар йөзендә дөньяны коллык богауларыннан коткарырга килгән изге көч күрә һәм Ататөрек төзеп калдырган республикага каршы көрәш юлына баса.

Исхакыйны Назыйм Хикмәт белән  
Куеп карыйм кайчан янәшә.  
Назыйм Хикмәт – сәяси бер корбан,  
Ә Исхакый –  
Туры Тукайга тиң ләбаса.

Поэмалар Исхакый образын, аның сәяси, мәдәни эшчәнлеген, көрәшен үзәккә алсалар да, нигездә, татар халкы язмышы, аның киләчәге турында сүз барганга, бүгенге вазгыятьне дә әйләнеп үтә алмыйлар. Аерым алганда, Р. Низами дәртле елларда Ирек мәйданында азатлык таләп итеп, ачлык игълан иткән Рәшит Әхмәтҗанов, З. Зәйнуллин, Ф. Бәйрамова кебек каләм осталарының татар телен саклап калыр өчен халыктан ярдәм сорауларын хуплый. Илдә вак халыкларга каршы алып барылган сәясәтне фаш итеп, һәр халык үз теле, менталитеты, холкы, моңы, җыры белән яшәргә хаклы дигән фикер уздыра.

«Тел югалса – илең югалачак, Ил югалса– телең үләчәк» кебек юллар хәзерге һәм киләчәктәге аяныч хәлебезне искә төшереп, авторның шигъри мөмкинлекләре зур булуга да ишарә ясыйлар.

Хәзерге әдәбиятта Г. Исхакый образының гәүдәләнеше турында сүз алып барганда, сатирик парчалар, эпиграммалар, пародияләр һәм багышлаулар авторы буларак мәгълүм Ринат Мәннанның Г. Исхакыйны таныту юнәлешендәге эзләнүләре игътибарга лаек дип саныйм. Аның «Исхакый белән өч кич» (Казан университеты нәшрияты, 2007), «Исхакый әлифбасы» («Матбугат йорты» нәшрияты, 2008), әсәрләре Г. Исхакыйның тормыш һәм иҗат юлын әхлакый-тәрбияви максатларны күздә тотып, максатчан язылулары белән югары-патетик өслүбтә иҗат ителгән әсәрләрдән гади, яшь укучыларга аңлаешлы тел белән язылган булулары илә аерылып торалар.

«Исхакый әлифбасы»нда ул һәр хәрефкә дүрт йә биш юллык «багышлап», Гаязның туган ягы, әти-әнисе, дөнЬяга аваз салуы, яшьли зирәк бала булып үсүе, Чистай, Казан мәдрәсәләрендә аң-белем алуы белән таныштыра. Татар әлифбасының һәр хәрефенә мәгънәви-эстетик функция йөкләнә.

Исхакый үзенең истәлекләрендә җомга көнне кояш чыкканда тууы хакында язып калдыра. Ф. Сафин шуларга таянып, шигырен «Җомга көн, кояш чыкканда...», дип атый һәм Яуширмә кешеләренең «Илдә нарасый күреп...» сөенүен искәртеп, булачак әдипнең төрмәләр, сөргенлек, мөһаҗирлек сынауларын үтеп, корыч холыклы көрәшче буларак күтәрелүен, вафатыннан соң, илгә изге зат булып кайтуын үзәккә ала. «Бер таң сискәнеп уяндык, Илдә пәйгамбәр күреп». «А» хәрефенә Р. Мәннан шул ук хәбәрне «йөкли».

Аяз көнне, таң атканда
Дөньяга килә Гаяз.

Шуннан соң инде, булачак бөек шәхесне милләткә бүләк иткән затлар белән таныштыру ихтыяҗы туа:

Гыләҗетдин хәзрәт кем ул?
Кемнең килә әйтәсе?
Яуширмәдә мулла булган
Ул – Гаязның әтисе.

Яисә

Камәрия абыстайны
Беләләрдер һәммәсе.
Бөек заты, матур заты,
Сөйгән заты – әнкәсе!

Дүрт-биш яшеннән намазга басып, өстәлендә һәрдаим Корьән тоткан, киемендә, күңелендә чын мөселманча пакълек саклаган Гаяз үзен олы сынауларга, олы гамәлләрчә әзерли сыман. Төрмәләрне, кагу-рәнҗүләрне, эзәрлекләүләрне җиңүдә миллилеге, халкы өчен яшәве сынмаска-сыгылмаска өйрәтә.

Татарстан – гүзәл җирем,
Гаяз Исхакый ягы.
Тагын бер гомере булса,
Азатлык өчен анысын да
Бирер иде ул тагын.

Автор туган җиренә, Казанына, «безнең өчен бик якын» Истанбул шәһәрләренә бәясендә югары өслүбкә мөрәҗәгать итүдән дә тайчынмый. Анда да «Исхакыен» онытмый.

Башкалам Казанга мең ел,
Даны аның тутыкмас,
Йөз мең ел үтсә дә, халкы
Бөек улын онытмас.

Менә шундый гади, аңлаешлы сүзләр белән, ритм, ритмика, кафия, рәдиф таләпләрен үтәп (кайбер кытыршылыклары табиб кешегә гафу ителә), Р. Мәннан балалар күңелендә Исхакыйга хөрмәт тәрбияләү белән беррәттән, укучыларына милләтпәрвар шәхесләр менә шундыйбулырга тиеш дигән оеткы сала.

Шигъри новеллалар дип аталырга лаеклы, өч мөстәкыйль өлештән торган «Исхакый белән өч кич» әсәрендә автор «Бу каһарман –безнең якташ һәм тугры татар улы», дип Гаяз Исхакый белән «таныштырып», аның башыннан узган өч вакыйганы бәян кыла. «Чистай зинданы» исемлегендә сүз үз милләтенә азатлык даулап, яшьләрчә кайнарланып ясаган чыгышлары өчен каһарманының төрмәгә ябылуы, шул авыр шартларда качып-посып, рәхимсез рәвештә эзәрлекләнү шартларында «Зиндан» әсәрен язып, халкына ирештерүе турында сүз барса, «Штраф» дип аталган икенче кичәдә автор ун яшьлек кызына «Ил» гәҗитендә халыкларны үз хокуклары өчен көрәшкә чакырган мәкаләләре өчен Гаязга 350 сум штраф салыну, «Акчасы булмау сәбәпле, төрмәгә» риза булуы турында сөйли. Мөхәррирнең шундый аяныч хәлдә калуын ишеткән татар дөньясы «Бәладә калдырмадылар Исхакыйны ялгызын». Тиз көндә тиешле сумма җыела.

Петербург, Финляндия
Татарлары да җыя.
Бөек халык күңеленә
Шатлык кайгы да сыя!

Күренә ки, соңгы елларда шагыйрь югары өслүбкә күчеп, укучы күңелендә тирәндә яткан горурлык агымын хәрәкәтләндерү, уяту алымнарын эзли.

«Әрнү» дип аталган өченче кичтә бер байның кабакта кәефләнеп утырганда акчасын җәлләмичә туздырса да, мәйданга «Җир һәм Ирек» таләп иткән лозунглар күтәреп чыккан Миңлегәрәй белән Мусаны зинданнан йолып калу өчен акча түләүдән баш тартуы турында сүз бара. Көрәшче егетләрне коткару өчен җан атып йөргән Гаязның күңеле сыкрана. Ул үз халкын мөкиббән китеп яратса да, аның башка милләтләр харитасында лаеклы урынын югалтуга алып килгән тар күңеллелек, үз мәнфәгатьләре турында гына кайгыртып яшәү, бердәмлек җитмәү кебек сыйфатлары өчен ихластан борчыла. Шигъриновелла авторы шул ук хәлнең, ягъни халык исәбенә миллионнар, миллиардлар «булдыручылар» белән хәерчеләр арасындагы упкынның хәзергәчә саклануына да киная ясый, ягъни Р. Мәннанның сакраменталь соравы әле дә көчендә кала.

Ә ник бу якты дөньяда
Барсы да түгел тигез?
Югыйсә бит барыбыз да
Алла коллары бит без!

Кыскасы, автор Г. Исхакыйның тормыш юлыннан берничә вакыйганы алып, аларны публицистик гомумләштерүләр, лирик чигенешләр белән «бизәп «бара һәм каһарманның эшчәнлеге, иҗаты белән соклануын алгы нәүбәткә чыгара.

Милләттәшләренең күбесен, булдыклы. намуслы, эшчән, сүзендә торучан итеп сурәтләүдә шагыйрьләр, шул исәптән, Р. Мәннан да пафослы сүзләргә, югары өслүбкә дә иркен таяналар.

Безнең халык күндәм, тырыш,
Эшли ул сабыр гына.
(Р. Мәннан. «Өченче кич. Әрнү»).

Р. Мәннанның «Көрәштәшләр» исемле тарихи поэмасында үзәккә Гаяз Исхакыйның якын дусты, гаяр журналист Фуад Туктаров образы һәм иҗаты алына. Кереш нәкъ шул хакта бәян итүдән башлана.

Чистай шәһәре бәхетле
Зур шәхесләре белән.
Исхакый, Фуад Туктаров –
Икесе дә аның тыкрык,
Урамнарыннан йөргән.

Поэмада Фуадның шулай ук Чистай мәдрәсәсендә укуы, Исхакый тәкъдиме белән бик күп татар зыялыларын тәрбияләп чыгарган «Учительская шкогла»га юл тотучы, соңрак бергәләп яшерен «Тәрәкъкый», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Ил» газеталарын чыгарганнары өчен Туктаровның да эзәрлекләнүе, большевиклар хәкимияткә килгәч, читкә чыгып китәргә мәҗбүр булуы, Париж, Берлин, Анкара шәһәрләрендә узган мөһаҗирлек чорында да көрәшен дәвам итүе, Төркиядә Хөкүмәт китапханәсе оештырып, милләт балаларын бер үзәккә җыю рухы белән яшәве хакында сүз бара. Исхакый кебек үк, туган җирен, аның «сөтен» сагынып яшәсә дә, исән чакта Ватанга кайту аңа да насыйп булмый.

Исхакыйның якын дусты,
Якташы аның иде.
Тырыш, батыр көрәштәше
Чит җирләрдә күмелде.
(Р. Мәннан. «Көрәштәшләр»).

Иҗатчы әсәрен «Халык мәңге онытмас», аның исеме «Һәр татарны, мөселманны мәңге торыр җылытып», дигән нәтиҗә белән тәмамлый.

Кемдер Р. Мәннан әсәрләренә сурәтләү чаралары байлыгы, шигъри нәфислек, ритмик төгәллек җитми дип тә әйтә алыр. Ул хаклы да булыр. Вакыйгага сөйләү, биографиягә ияреп барулар өстенлек итсә дә, хәтерне яңарту, яшь буынга язмышларын милләтләренең киләчәгенә багышлаган бөек шәхесләребезне үрнәк-өлге буларак тәкъдим итү – уңай һәм үзен аклый торган гамәл. Шул рәвешле, Исхакый кебек даһи шәхесебезгә багышланган шигырь-поэмаларның үзәгендә, бер яктан, бөек шәхесебезнең милләт мәнфәгатьләре белән яшәве, эшчәнлеге үрнәк-өлге буларак китерелсә, икенчедән, мондый фидакяр затларның, үзен аямыйча көрәшкә әзер кешеләрнең арабызда аз булуы, милләт язмышына битараф маңкортлар сафы ишәя килүе борчый, хәсрәт хисе уята.

* * *

XX гасырда татар сүз сәнгате үсешенә зур өлеш керткән һәм туган халкының бәйсезлеге өчен ихластан һәм нәтиҗәле көрәшкән иң бөек затыбыз кем, дип сорасалар, иреннәр аң шәрифләре белән киңәшеп тә тормыйча, Гаяз Исхакый исемен пышылдыйлар. Чит илләрдә яшәүче татарлар аны үзе исән чакта ук милләт юлын яктыртып торучы кояшка тиңләгәннәр. Минһаҗ Исмәгыйли аңа түбәндәге шигъри юлларын багышлый.

Гаяз ага, син безгә кояш идең,
Синең юлың ак юл, бәхет юлы иде.
Шуңа күрә курыкмадың дошманнардан,
Чөнки син батыр татар улы идең!

Без Г. Исхакый иҗаты, сәяси-әхлакый эшчәнлеге турында күпме генә язсак та, сөйләсәк тә һаман әле аңа бурычлы булып калабыз!

ӘДӘБИЯТ

1. Афзал Гамил. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.
2. Галиуллин Т.Н. Яктылык: Әдәбият-тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.
3. Низами Р. Тормыш трамвае. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
4. Мәннан Р. Исхакый әлифбасы. Казан: Матбугат йорты, 2008.
5. Мәннан Р. Исхакый белән өч кич. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007.

# Г. ГОБӘЙДУЛЛИН Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ» ӘСӘРЕ ТУРЫНДА

***Д.М. Галиуллина** (Казан)*

Работа посвящена анализу критической статьи известного историка Г. Губайдуллина на произведение Г. Исхаки «Исчезновение через двести лет». Также, рассматриваются основные проблемы выделенные Г. Губайдуллиным в повести Г. Исхаки. Прежде всего, проблема сохранения татарской нации в эпоху индустриализации через просвещение. Отношение Г. Исхаки к исламу и мусульманскому духовенству. И, татарская женщина начала XX в. через призму восприятия Г. Исхаки.
**Ключевые слова:** татарская новометодная школа, джадидизм, история, культура, национальное самосознание, просвещение, политика, власть.

The research work is devoted to the analysis of the critical article of the famous historian G. Gubaidullin on G. Iskhaki's story «Disappearance in two hundred years». The author also examines the main problems revealed by G. Gubaidullinin in G. Iskhaki' story. First, it is a problem of preservation of the Tatar nation in the era of industrialization through education. Secondly, G. Iskhaki's attitude to Islam and Muslim clergy. And, thirdly, the Tatar woman's fate in the early XX century through the prism of perception of G. iskhaki.
**Key words:** Tatar new method school, dzadidizm, history, culture, national consciousness, education, politics, power.

Соңгы вакытта татар телен, мәдәниятен саклап калу мәсәләсе күпләрне борчый, уйландыраһәм проблеманы чишү юлларын эзләргә мәҗбүр итә. Тарихка күз салсак телне, динне, милләтне саклап калу өчен безнең ата-бабаларыбыз гасырлар буе көрәшкәннәр. Ләкин, еллар үтү белән проблема катлаулана гына барган. Бигрәктә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында индустриализация чоры башлангач татар зыялылары мәсәләне хәл итү юлларын эзли башлыйлар. Элекке вакытта татар җәмгыяте үз мохите эчендә яшәгән, рус халкы һәм мәдәнияте белән аз аралашкан. Башка дин һәм милләт кешеләре булганга күрә татар халкының иң бай, зыялы вәкилләрен дә дәүләт, идарә эшләренә катнаштырмаганнар. Шуңа күрә рус телен өйрәнүне күбесе кирәк дип тапмаган. XIX гасыр ахырында татар халкы арасында җәдитчелек хәрәкәтенең җәелүе рус, европа мәдәнияты һәм телләре белән дә кызыксынуны уята. Иң беренче булып чит, ят мәдәниятның балалар һәм яшьләр өчен «зарарлы», гасырлар буе саклап киленгән яшәешнең бозылу мөмкинлеген татар дин әһелләре «күреп» алалар. Озак еллар буе фәнни әдәбятта, яңа уку системасына каршы төшкәннәре өчен аларны «дини фанатиклар» дип атап йөрттеләр. Бәлки, бу үзенә бер төрле протест һәм милләтне юкка чыгудан саклап калу чарасы булгандыр?Чынлыкта исә, кадими система татар милли мәктәпләре һәм педагогик фикер үсешендә котылгысыз һәм закончалыклы этап булган. Аның нигезендә җәдитчелек үсеп чыга. Җәдит уку системасын яклаучылар да «яңа» һәм «иске» педагогик ысулларны берләштерү юлларын эзлиләр. Нәтиҗәдә ана телендә белем бирә торган, милли һәм дини гореф-гадәтләрне саклаган татар мәктәбе туа. Бу яңалыкларга карата татар зыялылары арасында төрле карашлар яшәгән. Милли бөтенлекне «югалту» куркынычы, татар милли мәдәниятының европалашып китү ихтималы сагаерга мәҗбүр иткән. Әмма башланып киткән үзгәрешләрне туктату инде мөмкин булмаган. Уку системасына гына түгел, татар җәмгыятенә дә үзгәрешләр кирәк булганлыгы шик тудырмый. Татар милли интеллигенциясенең алдынгы карашлы вәкилләре бу проблемага аеруча зур ихтибар бирә башлыйлар. XX гасыр башы татар әдәбятында тирән эз калдырган әсәрләрнең берсе Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйразы». М.Җ. Сәхапов фикеренчә бу әсәр «татар милләтенең аңын

тәрбияләүдә, фикерен үткенәйтүдә гаять зур роль уйнап кына калмый», ә милли азатлык хәрәкәтенә дә зур йогынты ясый [14: 6]. Соңгы вакытта «инкыйраз» сүзе татар матбугатында еш кулланыла. Ләкин, хәзерге заман «инкыйразы» белән Г. Исхакый «инкыйразы» арасында зур аерма бар.

Бу әсәр Казанда 1904 елда басылып чыга һәм фәнни әдәбиятта Г. Исхакыйның көрәш программасы буларак классификацияләнә. Әдип үзе әсәрен «хыялый роман» [8: 27], ә Г. Гобәйдуллин милли рухта язылган «үземезнең иҗтимагый романыбыз» дип атый [6: 21]. Әсәр «татар сөйләү түгел, рус үзе дә сөйли алмый» торган заманда басыла [6: 31]. Г. Гобәйдуллин фикеренчә татар җәмәгатчелеге бу әсәрне салкын яисә аның сүзләре белән әйткәндә «берничек тә каршыламады» [6: 21]. Ул үзенең тәнкыйть мәкаләсен 1911 елда бастыра [4: 3–24] һәм «Инкыйразның» беренче басмасы «һаман китапчыларда сатлып беткәне юк», дип яза [3: 21]. Сәбәбен татар җәмгыятенең китап укуга битараф булуында күрә. Беренче булып бу әсәрне «Тарих вә голум» рисаләсендә Й. Акчура бер ничә җөмлә белән генә булса да искәртеп китүе турында да хәбәр итә [6: 21]. Г. Гобәйдуллин 1911 елны әдәбият һәм фән өлкәсендә әлегә тәҗрибәсе аз булган Казан университеты студенты. Ләкин, ул мәкаләсендә атаклы әдипнең әсәренә бик житди һәм тирән мәгънәле анализ ясый. Чөнки «милләт» мәсьәләсе Г. Гобәйдуллин өчен иң актуаль проблемаларның берсе. Киләчәктә аның иҗатында татар халкы тарихы бернче урында торачак.

Г. Исхакый әсәрендә тәнкыйтьче берничә төп проблемамы аерып, блокларга бүлеп карый: «Исламият һәм “Инкыйраз”», «Милләт, миллият һәм “Инкыйраз”», «“Инкыйраз” һәм татар хатыннары», «Хөкүмәт һәм “Инкыйраз”». Г. Гобәйдуллин фикеренчә Г. Исхакый әсәрендә ислам диненә түгел, ә киресенчә аның асылын дөрес аңламаучы дин әһелләренә каршы чыга [6: 24–25]. Ул чорда Г. Исхакый гына түгел күпчелек татар зыялылары да реформаторлык идеяләре белән янып яшәсәләр дә мөселман җәмгыяте өчен ислам диненең, шәригать кануннарынның әһәмиятлеген аңлаганнар. Ислам дине беркайчанда белем алырга омтылуга киртә куймаган. Киресенчә Коръән һәм дини китапларда «Белем эстәү һәр мөселман кешесенең һәм хатын-кызының бурычы», «[Кытайга барып җитәргә туры килсә дә] белем алу юлын эзлә» кебек гыйбарәләр мөселманнарның белем алуга булган омтылышын күрсәтәләр [13: 26]. Татар халкының укымышлы булуы турында беренчеләрдән булып XIX гасырның 40 нчы елларында Карл Фукс язып калдыра. 1884 елда «Волжский вестник» газетасы хәбәр итүе буенча ул чорда татарларның – 60%, ә русларның бары тик 10% гына грамоталы (туган телләренә нисбәтле рәвештә) булган [5: 26]. Ни өчен соң Г. Исхакый татар халкын наданлыкта гаепли, ә мәктәп һәм мәдрәсәләребездә укытыла торган гыйлемне «эшкә яраксыз бер чепуха», – дип атый? [8: 111] Ә, җавап бик гади. Чөнки, аның фикеренчә, бу белем белән татар халкы индустриализация чорында икътисади, иҗтимагый, сәяси үсешкә ирешә алмый. Г. Исхакый рус мәктәпләренә укырга керергә өнди һәм «Русия идарәсенә табигъ булганымызга өч йөз илле ел булса да, шул озын гомердә руслардан файдадан башка һич нәрсә күрмәсәк тә... руслардан әллә нинди куркып, аларның һәммә эшләренә шикләнеп караучыларның исәбе-хисабы юктыр», – дип яза [8: 112]. Әйе, хак өстәмә тел белү, яңа фәннәр өйрәнү файдага гына. Ләкин, татар халкының куркуын да, шикләнүен дә аңлап була. Рус теле, әдәбиятын мәктәпләрдә укыту яңадан «руслаштыру», «христианлаштыру» процессына юл ачыр дигән шик халык арасында киң таралган була. Г. Исхакый бу фактны үзе дә искәртеп үтә [8: 133]. Шулай ук, рус хөкүмәтендән «файда» гына күрдек дигән фикер белән дә татар халкы әлбәттә килешмәс иде. Бәлки, бу адымга Г. Исхакый цензураны үтәр өчен баргандыр? Хәзер инде бу сорауга җавап бирүе авыр.

Милләт мәсьәләсенә килгәндә, «Инкыйраз»да «татар халкы», «татар милләте» дигән төшенчәләр бөтенләй кулланылмый. Г. Исхакый «болгар» этнонимын куллана. Әдип фикеренчә заманында болгарлар татарлар белән кушылсаларда «болгарлар һаман болгар киенчә калмый, татарлар акрын гына болгарларга кушылып бетеп китмешләрдер», – дигән фикергә килә. Этногенез күзлегеннән чыгып караганда Г. Исхакыйның сүзләрендә хаклык бар. Ләкин, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казан губернасында яшәгән төрки телле мөселманнарны «болгар» дип атап йөртү дөрес булмас иде. Бу чорда татар милли интеллигенциясе арасында милли этноним, әдәби телмәсьәләләрен чагылдырган дискуссияләр бара. Татар тарихчыларын «татар» этнонимының килеп чыгуы кызыксындыра. XIX гасырга кадәр җирле халык «татар» этнонимын танырга теләми. XIX гасыр ахыры XX гасыр башында этноним язмышы татар милләте язмышы белән турыдан-туры бәйләнгән була. Б. Баттал фикеренчә Ш. Мәрҗани белән К. Насыйри беренчеләрдән булып үзләренең тарихи хезмәтләрендә «татар» этнонимын кулланалар һәм аны яклап чыгалар [2]. Ләкин, бу четрекле мәсьәләне чишәр өчен Ш. Мәрҗанинең дә авторитеты җитми. Р. Фәхретдинов үзенең «Болгар һәм Казан төрекләре» дигән китабында «татарлар» дип Алтын Урда халкын гына атый. Казан татарларын «төрекләр» яисә «мөселманнар» дип атап йөртә [18]. Әсәр ахырында Г. Исхакыйда «без Русия мөселманнары булырга кирәк», – ди [6: 29]. Г. Гобәйдуллин фикеренчә, бу әсәрдә очрый торган күп кенә каршылыкларның берсе [6: 29]. «Татар» этнонимына каршы чыгучылар арасында Г. Гобәйдуллин үзе дә була. Октябрь инкыйлабыннан соң язылган «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» дигән хезмәтендә ул халыкның «татар» атамасына каршы чыгуын, бу исемне руслар тарафыннан тискәре мәгънәдә куллану да күрә [5: 5]. Ун елдан соң бу мәсьәләгә тарихчы «К вопросу о происхождении татар» дип аталган мәкаләсендә яңадан әйләнеп кайта һәм бөтенләй башкача фикер йөртә. Бу хезмәтендә ул «татар» атамасы яклы [7]. Ләкин, этноним мәсьәләсе бу елларда сәясәт белән дә тыгыз бәйләнгән була. 1920 елны Татарстан автономияле җөмһүрияте төзелгәннән соң этноним буенча дискуссияләрнең кирәклеге калмый. «Болгар» этнонимын куллануы белән Г. Исхакый дәүләт тарафыннан үткәрелгән милли сәясәткә каршы булуын күрсәтергә теләгәндер? Чөнки, рус чыганакларында урта гасырлардан башлап Алтын Урда, Казан ханлыгы җирләрендә яшәгән төрки телле мөселманнарны «татарлар» дип атап йөрткәннәр.

XX гасыр башы өчен традицион булган тема татар хатын-кызларының җәмгыяттәге урыны, аларның хокуклары белән бәйле мәсьәләләрне дә Г. Исхакый әсәрендә дә күреп була. Г. Гобәйдуллин фикеренчә «Гаяз әфәнде бу әсәрендә хатыннар өчен чынлап та бик зур көрәшче, аларны азат кылуга тырышучы баһадирлардан берсе» [6: 30]. Мөселман җәмгыятендә хатын – кызның төп бурычы балалар үстерү, аларга милли, дини тәрбия бирү. Бу вазифаны тиешле итеп башкару өчен, Г. Исхакый фикеренчә, ана кеше үзе дә белемле булырга тиеш [9: 126–127]. Татар хатын-кызлары бу вакытта белемсез, надан булган дип әйтеп булмый. Кызларга белем биргән абыстайларны күп очракта тәнкыйтьлиләр, ләкин аларның күбесе заманы өчен укымышлы, яхшы белем алган ханымнар булганнар. Алар хезмәт хакы да алып эшләмәгәннәр. Абыстайларның төп бурычы динне, гореф-гадәтләрне саклап калу булган. Шуңа күрә, Г. Исхакыйның тәнкыйте белән килешеп булмый. Ләкин, XX гасыр башында кыз балаларны укыту эшендә үзгәрешләр кирәк булу мәсьәләсендә Г. Исхакый билгеле хаклы. Г. Гобәйдуллин Г. Исхакый «хатыннар мәсьәләсен» ачып бетермәде, бигрәк тә ислам әдәбиятына «әйләнеп карамый», – дип яза [6: 31]. Г. Исхакыйны татар хатын-кызларының хокуклары өчен көрәшче дип

атап була. XIX гасырның икенче яртысында АКШта, һәм Көнбатыш Европада феминизм хәрәкәте киң тарала. Шуңа күрә, Г. Исхакыйның хатын-кыз хокуклары турында сөйләве гаҗәп түгел. Ләкин, язучы беренче урынга әхлак проблемасын куя. А.А. Шәмсутова үзенең хезмәтендә «Инкыйраз» повестында гаилә, никах кебек гомумкешелек кыйммәтләренә дөрес караш тәрбияләү максат итеп алынган», – дип яза [21: 51]. Шулай ук, Г. Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идея-эстетик эволюциясен анализлый. Феминизм бит ул хатын-кызларларның иҗтимагый-сәяси хәрәкәте, беренче чиратта сәяси хокуклар, мәсәлән сайлау хокукы, өчен көрәш [19]. Г. Исхакыйны татар хатын-кызларының язмышы борчыган, ләкин феминистик проблемаларны әсәрләрендә күтәргән дип әйтеп булмый. Бу чорда татарлар арасында феминистик хәрәкәт әле оешмаган да була. Әйе, бу чорда хатын-кызлар арасында язучылар, шагыйрәләр, мөгаллимәләр саны арта (Г. Биктимирова, Х. Гисматуллина, Г. Рахматуллина, Г. Самитова һ.б). Ләкин, бу феминизм түгел, ә җәмгыятьнең заман таләпләре басымы астында уңай якка үзгәрүе. Беренче хатын – кызлар оешмасы «Уфа мөселман хатын-кызлар җәмгыяте» 1907 елда гына оеша [4: 143]. Аның эшчәнлеге мәгариф, әхлак, тәрбия мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән була, ә сәяси проблемаларны оешма әгъзалары күтәрми.

Г. Исхакыйны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе татар хатын-кызлары арасында «зина, фәхеш» таралу. Казанда фәхешханәләр татар бистәсендә дә булган. Иң аянычы XIX гасыр уртасыннан алып – XX гасыр башына фәхешханәләрдәге татар кызларының саны арта гына барган [10: 61]. Бу проблема алдынгы карашлы татар зыялыларын нык борчыган. Хәтта, Г. Тукай да бу теманы читләп үтмәгән. Мәсәлән, «Поезд барган көйгә» [17: 187–189] шигырендә татар кызларының әхлагы бозылуын һәм фәхешханәдәге бер төнне бик оста тасвирлап бирә:

«Мискин безнең Фатима
Кече яшьтән ятимә;
Шуңар күрә төшкән ул
Сатлык кызлар рәтенә.

Һәр төн шул эш бу йөртта, –
Исрек татар фарситта,
Ниләр, ниләр булганын
Саный алмый бер чорт та».

Г. Гобәйдуллин фикеренчә Г. Исхакый беренче булып татар әдәбиятында «күп хатынлылык» мәсьәләсен күтәрә. Бу канун ислам дине аякка басып, ныгып килгән елларда хатын-кызларларны авыр тормыштан саклап калу өчен кретелә. Ләкин, соңрак күпчелек хатын-кызлар өчен язмыш фаҗигасына әйләнә. XX гасыр башында мөселман җәмгыятен тискәре яктан сүрәтләгән бу гадәт татар әдәбиятында да урын ала. Мәсәлән, Т. Соловьев «Биби-Казан» әсәрендә фәхишәләрне Мәкәрҗә ярминкәсенә шунда баручы бер ирнең хатыннары итеп фиктив никах укытып алып чыгулары турында яза [15]. Соңрак, К. Тинчуринның атаклы «Зәңгәр шәл» [16] пьесасы бу проблемага аеруча зур игътибар бирә. Мөселман дин әһелләре бу әсәрнең эчтәлеге белән хәзер дә килешә алмыйлар. Чынлкта исә, казан татарлары арасында күпхатынлылык киң таралмаган була. Мәсәлән, бу фактны К. Фукс «Казанские татары в статическом и этнографическом отношениях» (1844) әсәрендә статистик мәгълүматларга таянып билгеләп үтә. «Казан татарларындан 55 кешенең 2 хатыны, 6 сының 3, тик 2 кешенең генә 4 хатыны бар», – дип язып калдыра. Ул вакытта татар бистәсендә яшәгән халыкның саны 6 500 кеше исәпләнә [20: 144–146].

Билгеле, XX гасыр башында татар җәмгыяте үзен алдынгы карашлы милләт дип танытырга теләсә, бу проблеманы да чишәргә тиеш була.

Г. Исхакый әсәрен «Русиядәге шулкадәр безгә бирелгән иркенлек, безнең хактагы гадәләт һичбер милләт мәхкүмәгә бирелмәгәндер», – дигән сүзләр белән тәмамлый [9: 148]. Күп тарихчылар бу сүзләр белән килешмәсләр иде.Татарлар арасында җәдитчелек хәрәкәте җәелү, яңача белем бирә торган мәктәпләр ачылу рус миссионерларын һәм хөкүмәтне борчуга сала. Бу чорда дәүләт милли мәктәпләр өстеннән каты контроль урнаштыра. Мәсәлән, мәдрәсәләр дөньяви фәннәрне укыту өчен махсус рөхсәт алырга тиеш булганнар [4: 36]. Дәүләт карары буенча татар уку йортлары дини булып калырга тиеш була. Хәтта, 1905–1907 елгы инкыйлаптан соң да татарларга дөньяви уку йортлары ачу катгый тыела [1: 38]. 1910–1911 елларда патша хакимиятләре татар җәдит мәктәп-мәдрәсәләрен аяусыз рәвештә яптырдылар. Атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсенең «панисламизм» тарафтуда гәепләнеп 1912 елда ябыла. Күп китап, кулүязмалар яндырыла, мөгаллимнәр кулга алына [3: 8]. Бу вакыйгаларны дәүләт тарафыннан үз халкына биргән «иркенлек» дип карап буламы? Бәлки, әсәр соңрак язылса Г. Исхакый да рус хөкүмәтенә ышанырга, «аларның һәммә эшләренә шикләнеп» [8: 112] карамаска өндәмәс иде? Г. Гобәйдуллин фикеренчә, «Инкыйразны» укыганда баштан төрле уйлар уза: «Аның тасвирлавы безне шаккаттырып калдыра». Шунда ук, бөтенләй өметсез итә, я өмет уятып «көрәшкә өнди». Нәтиҗә итеп тәнкыйтьче «Инкыйраз фикер җәһәтеннән бераз искергән булса да, тасвир, чын әдәби җәһәтенннән мәңгелек бер әсәрдер», – дип яза [6: 32]. «Инкыйразның» татар әдәбияты, иҗтимагый-сәяси фикер үсеше тарихында «мәңгелек бер әсәр» булып калуында шик юк. «Фикер җәһәтеннән бераз искергән» дигән төшенчәгә килгән дә, киресенчә соңгы йөз ел эчендә булган вакыйгалар, татар милләтенең юкка чыгу куркынычы уйдырма түгел, ә чынбарлык икәнен исбатлый. Ләкин, татар милләте XXI гасырда Г. Исхакый уйлаганча наданлыктан түгел, ә үзенең милли асылын, тарихын, мәдәниятен, телен оныткангa юкка чыгарга мөмкин. Г. Исхакыйның әсәрендә чагылыш тапкан кайбер фикерләр белән килешеп булмаса да, милләтне саклап калу проблемасын күтәргәне өчен без аңа рәхмәтле булырга тиешбез. Г. Гобәйдуллин язганча, бу әсәр җырлата да, елата да.

ӘДӘБИЯТ


1. Амирханов Р.Г. Развитие народного образования у татар в дооктябрьский период // Мәгариф. 1992. № 8. С. 36–39.

2. Баттал Б. Казан төркиләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 190 б.

3. Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: тарихи-документаль җыентык. Казан: Рухият, 1999. 239 б.

4. Биктимирова Т.А. Ступени образования до Сорбонны. Казань: Алма-Лит, 2003. 184 б.

5. Газиз Г. Милләтчелекнең бәгъзе әсәслары. Казан: Тип. «Аң», 1918. 40 б.

6. Гобәйдуллин Г. «Ике йөз елдан соң инкыйраз (Гаяз Исхаков әсәре) // Мирас. 1993. № 9. Б. 20–32.

7. Губайдуллин Г. К вопросу о происхоңдении татар // Вестник научного общества Татароведения. 1928. № 8. С. 130–140.

8. Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз // Казан утлары. 1990. № 1. Б. 110–142.

9. Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз // Казан утлары. 1990. № 2. Б. 109–148.

10. Малышева С.Ю. «Профессионалки», «Арфистки», «Любительницы»: публичные дома и проститутки в Казани во второй половине XIX – начале XX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2014. 187 с.

11. Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый (тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 190 б.

12. Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре. 1 нче китап. Казан: Тип. В.Е. Казакова, 1911. 32 б.

13. Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Татар «Әлифбасы»: үткәне һәм бүгенгесе. Татарская «Алифба»: История и современность. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 194 б.

14. Сәхапов М.Җ. Бәек мирас ядкаре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 379 б.

15. Соловьев Т. Биби – Казан. Оренбург: Типо-литогр. М.Ф. Каримова, 1906. 16 б.
16. Тинчурин К. Зәңгәр шәл // Драмалар һәм комедияләр. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 200–263.
17. Тукай Г. Шигырьләр. Поэмалар (1909–1913). Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 400 б.
18. Фәхретдинов Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 286 б.
19. Феминизм: Восток, Запад. Россия. М.: Наука, 1993. 243 б.
20. Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях // Карл Фукс о Казани, Казанском крае. Казань: Жиен, 2005. С. 143–222.
21. Шәмсутова А.А. Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идея-эстетик эволюциясе (1897–1954). Казан: Gumanitarya, 2003. 190 б.

## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Ф.Г. Галләмов*** *(Алабуга)*

В статье рассматриваются языковые особенности произведений Г. Исхаки. Анализируются конструкции разговорной речи, диалектизмы. Особое внимание уделяется синтаксическим фигурам: лексическим повторам, сравнительным и уточнительным конструкциям, стилистическим оборотам, риторическим обращениям и риторическим вопросительным предложениям и т.д.
**Ключевые слова:** язык писателя, просторечные слова, диалектизмы, синтаксические фигуры, сравнительные конструкции, стилистические обороты.

The article deals with the characteristic linguistic properties of G. Ishaki's works. The constructions of colloquial language and dialecticisms are analyzed. Special focus is paid to the syntactic figures: lexical repetitions, comparative and refined constructions, stylistic phrases, rhetorical addresses and rhetorical questions etc.
**Key words:** writer's language, colloquial words, dialectal expressions, syntactic figures, comparative constructions, stylistic devices.

Г. Исхакый иҗаты әдәбият галимнәре тарафыннан шактый җентекләп өйрәнелгән һәм бу эш бүгенге көндә дә дәвам итә, ә тел үзенчәлекләрен өйрәнү әле башлангыч чорда гына. Татар телчеләре арасыннан әдип иҗатына, беренче булып, профессор Ф.С. Сафиуллина игътибар итте [4: 225–253]. Ул бу хезмәтендә Г. Исхакыйның хикәяләү үзенчәлекләрен һәм осталыгын ачып бирә. 1990 елда дөнья күргән «Зиндан» китабында туплап бирелгән проза әсәрләрен анализлап, әдип иҗатына зур бәя бирде: «Татар прозасының өлгереп җитеп, классик дәрәҗәгә менүе Г. Исхакый исеме һәм иҗаты белән турыдан-туры бәйле икәне хәзер инде беркемдә дә шик уятмый» [4: 225; 5: 98].

Безнең максат – Г. Исхакый әсәрләренә хас, аны башка язучылардан аерып тора торган тел үзенчәлекләрен күрсәтү. Иң беренче күзгә ташланганы шул: беренче зат исеменнән алып барылган хикәяләүләрендә гади сөйләм теле үзенчәлекләрен, диалекталь сүзләрне һәм формаларны аеруча күп куллана: *елавык, бикәч, җамид, ягъмур, йир, анлар, улсыны* (аны), *әверәләр* (әвереләдерәләр), әллә *авырыймсың, эшенә* (эшен) *дәвам итте*, *йорт* (ишек алды), *пыраклар*, *тишеп* (чишеп), *тишенү* (чишенү), *тиресләнми* (киреләнми), *тирес* (кире, үзсүзле) бала, *өсәк, алъяпмалык, лакшә* (токмач), *чәверде* (әйләндереп алды), бәрәңге *арчып* утыра, *әүем-әүем* (өем-өем), *кәкәш* (эремчек пәрәмәче), *дөбрәң* (саңгырау), *как-төш* (чәкчәк), *чагаю* (начараю), *тоткар* (тоткын), *куллык* (перчатка), *бари-га* (бияләй), *ил* (умарта), *айбагар* (көнбагыш) һ.б. Әсәрләрдән берничә җөмлә карап китик: ... башындагы арттан бәйләгән яулыгыны *тишеп*, муен астыннан бәйләде (Тормышмы бу?). *Имут-имут* өеп кулган тиреләрне нишлиләр (Тормышмы бу?). Кышкы төнне үткәрә-үткәрә арып бетеп эштән чыккач, өстемә киенеп *йортка* чыктым (Тормышмы бу?). *Кышның көне* иде (Сөннәтче бабай).

Әдәби телдән аермалы буларак, *башка* бәйлеге үзеннән алда килгән сүзнең юнәлеш килешендә торуын таләп итә: *балаларга* (балалардан) *башка*; *Миләшкә башка да* бабайның байлыгы юк түгел иде (Сөннәтче бабай).

Моннан тыш, гарәп-фарсы алынмалары бик күпләп кулланылган. Алар төрле өлкәләргә карый, аларны шулай ук тематик яктан төркемләргә мөмкин булыр иде.

Фигыль формаларының исемләшеп исемгә хас кушымчалар кабул итүе диалекталь үзенчәлек буларак күзгә ташлана, хәтта затланышлы фигыльләрдән категорик үткән заман хикәя фигыль дә исем категорияләрен үзенә алган. Бу, әлбәттә, мишәр сөйләшләренә хас күренеш, моңа мисалларны Г. Ибраһимовта да табарга була: Әти дә, төрлечә уйлап, миңа күпме акча *бирергәлегенең* очына чыга алмый. Үзем дә күпме акча барлыгыны, җәй буе күпме *җыелдыгыны* хисапладым (Тормышмы бу?).

3 нче зат исеменнән алып барыла торган әсәрләрендә этнографик детальләр, татар халкының көнкүреше, тормышын, татар мохитен чагылдырган сүзләр күп урын алган: *камалы бүрек, кама бүрек, тамак эчле камзул, тамак толыбы, дублы тун, манчестер казаки, укалы такыя, чулпы, колак алкасы, чәч такмасы, беләзекләр, кершән, иннек, постау җилән, катлама, ширбәт, кактөш, сумса, җимеш суы, бәлеш, таба ашы, вак пәрәмәч, катырган корт, кош теле, борай төше* һ.б.

Г. Исхакый әсәрләрендә хикәяләү күпчелек бер заман формасында алып барыла. Мәсәлән, «Татар гакылы»ндагы хәбәр формасына игътибар итсәк, ул башлыча категорик үткән заман хикәя фигыль *-ды/-де* формасында бирелә. Ә менә «Сөннәтче бабай» әсәрендә гел *-а иде* тәмамланмаган үткән заман кулланылган. Шуңа карамастан, бу рәвешле хикәяләү укучыны бер дә ялыктырмый.

Әдипнең әсәрләрендә хикәяләү укучы белән гаять тыгыз мөнәсәбәттә бара. Аның алдына еш-еш кына сорау куя, аңа сорау белән мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә аның әсәрләрендә сорау җөмләләр шактый күп урын алган. Кайбер әсәрләренең исемнәре үк сорау җөмлә итеп формалаштырылган. Мәсәлән, «Тормышмы бу?».

Автор прозасында кабатлаулар, эпифоралар, рефреннар кебек синтаксик фигуралар да күпләп кулланыла. Янәшә килгән җөмләләрдә килгән кабатлаулар текстта мөстәкыйль җөмләләрне үзара бәйләүдә катнашалар [2: 93; 3: 187], алдагы җөмләдә әйтелгән фикер алга таба үстерелә. Шулай итеп, мөстәкыйль җөмләләр арасында структур һәм семантик бәйләнеш барлыкка килә: Ул тагы Гөлйөзем әби хакында *уйларга тотынды. Уйлый-уйлый*, ничектер, «тагы өйләнергә» дигән фикер башына килеп керде (Сөннәтче бабай). Бик озак йоклый алмаенча уйлап торганның соңында, ул өйләнү фикеренә *килде. Килде генә түгел*, шул уйдан аерыла алмады (Сөннәтче бабай). Ул, әллә ничә көн чәй эчмәгән кеше кеби, бик тәмләләп-тәмләләп *эчте. Эчә-эчә* бераз кәефе дә килде (Сөннәтче бабай). Күрше карты аның өстенә дә *каен* илтеп утыртты, Ике *каен* бер-берсе берлән бәрелә-бәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар (Сөннәтче бабай). Үземнең хәлемне түгел, шул авылның наданлыгыны, анларның шул теге мин романнарда укыган тормыштан ераклыгыны, анларны шул тормышка кертүнең юлларыны *төшенәм. Төшенәм... Төшенәм дә*, ләкин бер очына чыга алмыйм (Тормышмы бу?).

Алар бер җөмләдә генә кулланылмыйча, абзацтагы бөтен җөмләләрдә дә урын алып, үзенчәлекле синтаксик бөтеннәр барлыкка китерәләр. «Тормышмы бу?» әсәренең 17 нче бүлеген искә төшерик. *Им, бала, им!* гыйбәрәсе һәр җөмлә, һәр абзац башында кабатланып, үзенчәлекле анафорик рәт барлыкка китер-

гән. Кабатлаулар бу очракта мөстәкыйль җөмләләрне генә бәйләп калмыйча, абзацларны да бер синтаксик бөтен итеп оештыруда төп рольне башкаралар.

Анафорик кабатлаулар шулай ук бер абзац эчендәге җөмләләрне үзара бәйләүдә катнашалар. Алар, мәгънәне көчәйтеп, эмоциональлекне арттыралар: Хәзер малай ат җигеп маташа. Әти аштан кайткач, китәм. *Хуш,* авыл! *Хуш,* миңа кызларыңнан бер файда бирмәгән, минем эчемне генә пошырган авыл кызлары! *Хуш,* иген тулы ындырлар! *Хуш,* җырлый торган тавыклар! *Хуш,* кичке авылдагы тынычлык! *Хуш,* авылның моң-кайгысыз тормышы! *Хуш,* авылның майлы бәлешләре, тәмле итләре! *Хуш,* яшьтәш егетләр! *Хуш,* урамнарда туңып уйнап йөри торган балалар! *Хуш,* бу елгы җәем! *Хуш,* мәңгелеккә кайтмый торган бу елгы гомерем! Һәммәсе, *хуш*! (Тормышмы бу?)

Кабатлаулар, һәр тиңдәш кисәк алдында килеп, мәгънәне көчәйтәләр: Минем фикерем дә мәгълүматым кеби. Анда да *аз гына* вөҗдан, *аз гына* шәфкать, *аз гына* эшкә мәхәббәт, *аз гына* халкыны сөю, *аз гына* үзене корбан кылырга хәзерлек, *аз гына* шөһрәт сөю, *аз гына* байлык сөю, *аз гына* үзен үзе сөю, *аз гына* тормыш сөю, *аз гына* ялкаулык, *аз гына* эш яратмау бар (Тормышмы бу?). Әгәр дә без бу сүзне тиңдәш кисәкләр рәте алдында бер генә тапкыр куллансак, бөтенләй башка җөмлә килеп чыгар иде, аның эмоциональ бизәге юкка чыгар, тәэсир көче кимер иде.

Кабатлауга нигезләнеп төзелгән тойгылы атау җөмләләр тезмәсе дә мәгънәне көчәйтү өчен кулланылганнар: Һәммәсе кап-кара булып кояшка пешеп, тазарып, зураеп, ирләнеп киләләр. *Һәммәсендә дә әллә никадәр гайрәт! Әллә никадәр куәт! Әллә никадәр дәрт!* (Тормышмы бу?)

Г. Исхакый әсәрләрендә кабатлаулар, сүз уйнатулар күп очракта тойгылы юмористик интонациягә төреп бирелгәннәр: Ләкин миндә әүвәлгесе дә юк, ахыргысы да юк. һәр нәрсә бар, бер нәрсә юк! Шуның өчен мин – ул да түгел, бу да түгел! Тәвә дә түгел, кош та түгел! Ат та түгел, ишәк тә түгел! Мин – иске мулла гыйлеме, иске мулла фикере берлә яңа фикерләр, яңа гыйлемнәрдән катыштырып начар иттереп ясалган мулла азгыны! Менә шул мулла азгыны үзенең шул чуалчык башы, чуалчык фикере, начар тәрбиясе берлә нишләсен? Сез дә җавап биреңез?! Бунның шулай калуында үзе генә гаеплеме? Нигә көлеп торасыз?! Бунның шулай, бер элгәреге игътикадыны бозып, яңа игътикадсыз калуында сез дә, аны чолгап алган бөтен татар тормышыңыз да гаепле түгелме? (Тормышмы бу?). Бу өзектән күренгәнчә, сорау җөмләләр тезмәсе белән язучы укучыга мөрәҗәгать итә. Шул рәвешле укучы белән язучы арасында тыгыз мөнәсәбәт урнаша

Язучы стиль әйләнмәләреннән дә бик оста файдалана, монда да юмористик интонация өстенлек итә: Мин иртә берлә бернәрсә дә уйламаенча, *мин аны сөйми, ул мине сөйми торган* авылдан *ул мине сөйми, мин аны сөйми торган* бикәчемә киттем (Тормышмы бу?).

Юмор сөйләмне бүлеп килеп кергән керешмәлар белән дә белдерелә: – Хатыныңнан уңмасаң безгә үпкәләмә *(шул сүзне әйткәндә бүлмәдә самовар өрә торган киленнең зур чүлпылары, протест ясаган кебек, шалтырап куйдылар),* үзеңә үпкәлә («Кияү»).

Кабатлаулар күп очракта градацион төзелмәләр, риторик эндәшләр барлыкка китерәләр: Мин туңдым, мин каттым, мин беттем! (Тормышмы бу?). Бу очракта градация кабатлаулар ярдәмендә барлыкка китерелгән. Риторик эндәшкә бер мисал: Мин еглыйм, сез дә еглаңыз! Минем генә түгел, минем кеби меңнәр-меңнәр егетләреңезнең, ике агым арасында, йомычка кеби, бер тарафка китәргә хәле булмаганыны, бер тарафның да куәтене арттырырга да көче йитмәгәнене – үзенә үзе ышанмаганыны күреп еглаңыз! Шуңарга таза, нык аяк

басар урын табарга уйлап, шунларны хәзерге хәлләреннән коткарырга теләп еглаңыз! Бунларның харап булган гомерләре өчен, шул әллә никадәр яшьләремезнең харап итәчәк гомерләре өчен еглаңыз! Үзеңезне чолгаган дөньяңызның шул егетнең башы кеби идеке өчен еглаңыз! Еглаңыз! (Тормышмы бу?)

Г. Исхакый әсәрләрендә чагыштырулар еш кулланыла. Риторик сорау җөмләләр белән үрелеп бирелүе чагыштыруларның тәэсир итү көчен артттыра:

Ник бездә шулай булмаган? Әнә ул гарәпләрдә шулай булган, ник бездә булмаган? Без дә мөселман ич! Ник анларда уку ул кадәр алга киткән дә, бездә наданлык шулкадәр падишаһлык сөргән? Ник бездә шулкадәр золым-җәбер җәелгән дә, анларда ул беткән?

Ник бездә бөтен урамнар хәерче, карак берлә тулган да, анларда ул беткән?

Ник бездә хатыннар җарияләр кеби калган да, анларда падишаһлар булганнар? Буның сәбәбе ни?..

Тәкъдирдер шул!

Ник безгә Ходай шулай тәкъдир иткән? Анларга тегеләй?

Әй! Безгә дә Ходай анларныкыча тәкъдир иткән булсачы! (Тормышмы бу?)

Кабатлауларга корылган чагыштырулар актив кулланылган. Нинди дә булса җөмлә кисәге, синтаксик яктан җәенкеләндерелеп, башка җөмлә кисәге булырак кабатлана. Мәсәлән, ия булып килгән сүз, синтаксик яктан җәенкеләнеп, хәбәр булып кабатлана: Бакышы – падишаһлар бакышы, Йөреше – баһадирлар йөреше (Остазбикә).

Чагыштырулар күп очракта *кеби* бәйлеге ярдәмендә барлыкка китерелгән: Ике атна вакыт үтмәде, Гөлйөзем әбинең тарихы онытылган көннән бирле керткән тәртипләре бозылды. Аның заманасында сары гәрәбә *кеби* ялтырый торган идәннәр мәдрәсә әчелеге хәлене алды. «Английский пыяла»дан ясалган *кеби* ялтырый торган тәрилкәләр уңмаган хатынның алъяпкычы төсенә керде. Әби заманасында йөзендә аллы-гөлле кояш уйный торган самавыры казан төбе *кеби* катты. Чынаякларның тоткалары, чәйнекнең капкачлары маңка малайның борыны төсле булды (Сөннәтче бабай).

Шулай итеп, чагыштыруларда *кеби* бәйлеге бик еш кулланыла, ул артык озын, күләмле җөмләләрдә 8–10 тапкыр очрарга мөмкин, ләкин бу бәйлекле төзелмәләр рәттән күп тапкырлар кабатланса да, укучыны ялыктырмый, киресенчә, алар әсәрнең тәэсир итү көчен арттыралар гына: Ялтыраган ай яктысы берлә нурга коенган, ап-ак кар диңгезе *кеби* Кабан күленең кар бөртекләре шул матур түгәрәк айга, шул кәндилләр *кеби* сирәк-сирәк күренә торган йолдызларга җем-җем иттереп, елтыранып көлемсерәшәләр, анлар берлә уйнашкан *кеби*, күз кысышкан *кеби* елмаешалар, Кабан күленең теге тарафындагы фонарьлар да, тәрәзәләрдәге утлар да бу көннең матурлыгына кызыккан *кеби*, аның көмеш *кеби* саф елтырауларына, сөт *кеби* аклыгына көнләшкән *кеби*; аның шул ай, йолдызлар берлә күз кысышып уйнаш итүенә гаҗәпкә калып каткан *кеби* вә шул матурлыктан, ләззәтләнүдән аерылудан куркып, бер минутка да күзләрене аера алмаган *кеби*, туп-тугры ак карларга тегәп карап торалар (Тормышмы бу?).

Шулай итеп, чагыштыруларда күп очракта *кеби* бәйлеге кулланылган, хәтта ул бәйлекле төзелмәләр янында да үзен табигый хис итә: Үзләренең куышта икәнлегене белдерер *өчен кеби* кычкырып көлешәләр (Тормышмы бу?). Ат та, бу матур көннең гади бер көн түгел икәнлегене белгән кеби, шул матурлыкның әллә нинди тулмаган җирене хис итеп, шуны тутырыр *өчен кеби*, бик матур итеп кешнәп йибәрде (Тормышмы бу?).

Эпитетлар, ягъни җөмләдә аергыч булып килгән кисәкләр, әйберләрнең, күренешләрнең сыйфатларын санап күрсәткәндә, күпләп кулланылалар.

Беренче карашка ялыктыргыч күренгән сүзләр тезмәсе, мәсәлән, табигать күренешләрен тасвирлауда уңышлы кулланылганнар: Авылны чыктым, яшел игеннәр эченнән диңгездән ярып бара торган көймә кеби, шул яшеллекне кара атым, кара арбам берлә ярып бара башладым. Кырның хуш исләре, мине каршы алыр өчен хәзерләнгән кеби кошларның оркестрлары, мин үткәндә ике тарафтан да ашлыкларның баш иеп миңа сәлам биреп калулары мине тәмам исертте... (Тормышмы бу?).

Әсәрләрендә язучы аныклагычлардан да оста файдалана. Әдәбиятта иң беренче Г. Тукай кулланышка кертеп җибәргән дип исәпләнелгән [1: 155] аныклагычларга уңышлы мисалларны Г. Исхакый хикәяләвендә үк табарга мөмкин: Бала да – *теге Сары башлы урыс баласы да,* Шәмсинең күңелен чиркандырмады (Ул әле өйләнмәгән иде). Шуннан соң, солдатта вакытта бергә хезмәт иткән бер фельдшер – *таныш урысым* бар иде (Башкорт бәхете). Әллә нинди яшел тавыш берлә – *әнә теге, өйдән өйгә кереп, коръән укып йөри торган чулак хатын тавышы берлә* – бер кеше коръән укырга тотынды (Татар гакылы).

Әдипнең хикәяләре тиңдәш кисәкләр, тиңдәш җөмләләр, аерымланган иярчен кисәкләр, эндәш һәм кереш сүзләр, керешмәләр һ.б. белән катлаулandырылган шактый күләмле җөмләләр тезмәсеннән, синтаксик бөтеннәрдән оешкан. Бер үк грамматик формада бирелгән тиңдәш кисәкләрне автор геройларның портретларын тасвирлаганда куллана. Мәсәлән, «Көтелгән бикәч» хикәясендә бикәч портреты: зифа буйлы, нечкә генә билле, күләмчән йөзле, озын керфекле күзле, алар нурлы, бит уртасы аз гына эчкә уелып кергән, калфак астындагы чем-кара урмандагы җансыз күл кеби томрап тора; бик матур, бик зифа, бик пөхтә (Көтелгән бикәч). Сөннәтче бабай портреты үзенең өе белән чагыштырып сурәтләнә. Монда әдип охшату-чагыштыру алымын бик оста файдаланып эш итә.

Г. Исхакый. әсәрләрендә гади җөмләләр дә шактый озын, бер җөмлә эчендә тиңдәш кисәкләр дә күп кулланыла, алар бик нык җәенкеләндерелеп, катлауландырылып биреләләр. Артык җәенке тиңдәш кисәкләр җөмлә ахырында, кагыйдә буларак, гомумиләштереләләр: Аның ямь-яшел кырларга, моңлы-куркынычлы урманнарга, сузылып яткан ялтыраган суларга күз кысулары, айларга төрле мәгънәләр аңлата торган елмаюлары, яшел кырларның, чәчәкләр берлә бизәлгән болыннарның, һавалы урманнарның аңар каршы башларыны акыртын гына иеп, аңар каршы нәфис исләре берлә сәлам җибәрүләре; кыр тургайларының, шул сәламнәрне алып тизрәк хуҗасына бирергә ашыккан кеби, җырлый-җырлый, борылып-бормаланып кояшка таба очулары; аллыгөлле төстәге күбәләкләрнең хәтфә кеби йомшак канатлары берлә шул саф һаваны яшелле, сарылы, кызыллы, аллы йолдызлар берлә бизәкләүләре; төрле бал кортларының матур тавыш берлә кызуланып, бер чәчәктән икенче чәчәккә күчеп бал җыюлары – *һәммәсе* бу көнгә бик зур бәйрәм төсе бирә, бу көнне гади көннәрдән аера иде (Тормышмы бу?)

Катлаулы җөмләләр дә күп кулланылган. Җөмләләр күләмле, гаять катлауландырылган булуга карамастан, алар структур һәм семантик яктан тыгыз бәйләнгәннәр: Киленнәр, эшләр беткәч, тавыклар йомырка салудан туктагач, бәрәңгеләр алынып беткәч, казлар, үрдәкләр су буеннан җыелып алынгач, курыккан кеби генә җылыта торган көзге җылы кояшлы көннәрдә яшел уҗым араларыннан үтә торган юллардан, кашка алашаны җигеп, арбага кызыл ястыкны салып, күчтәнәчкә төче, ачы күмәчләр пешереп, сандык төпләреннән алган, бикәч вакытта китерелгән читекләрне киеп, ире берлә әниләренә кунакка барырга, анда өч-дүрт көн кунак булып, һәр иртәне мунча кереп, карендәш-кабилә, дуст-ишкә ашка барып йөрүне уйлыйлар иде (Тормышмы бу?).

Г. Исхакый ел фасылларын үзенчә сәнгати югарылыкта сурәтли. Ел фасыллары бериш җөмләләр тезмәсе белән тасвирланалар. Мәсәлән, «Тормышмы бу?» әсәрен генә алыйк, анда җәй картинасы җырлап торган теземнәр белән бирелә. Шушы әсәрнең 18 нче бүлегендә урак тәмамланганнан соңгы авыл тормышы сурәтләнә, туй үткәрү кагыйдәләре, кием-салым, кыз бирү, килен төшерү, кияү керү, кунакларны каршы алу һәм сыйлау тәртибе, бәби туе һ.б. гореф-гадәтләр турында сөйләнелә. Шушы өлкәләргә караган лексик байлыкны махсус алып өйрәнергә була. Алар бөтен тулылыгы белән бу әсәрдә чагылыш тапканнар.

Г. Исхакый әсәрләре, геройларның психологик кичерешләрен бирүдә уңышлы алым буларак, уртак сөйләм күпләп куллланылу белән аерылып тора. Бу сөйләм, әлбәттә, автор сөйләме белән үреп бирелгән. Бары тик автор сөйләме контекстында гына уртак сөйләм бөтен тулылыгы белән ачыла. Уртак сөйләм бик сирәк кулланыла торган чорда, әдип аны хикәяләү алымы буларак, проза әсәрләренә алып керә. «Хикәяләүдә бу алымны оста куллану – прозаның өлгергәнлеген күрсәтә торган сыйфат», – дип бәяләнә [4: 235]. Уртак сөйләмне язучы бигрәк тә 3 нче зат исеменнән хикәяләгән әсәрләрендә күпләп кулланa. «Остазбикә» әсәрендә Сәгыйдәнең уй-кичерешләре, хисләре уртак сөйләм итеп бирелә. Уртак сөйләмгә күчү кереш сүзләр, фигыль формаларының үзгәрүе, сорау һәм сүз җөмләләгә күчү, гадәти сөйләмнең тойгылы сөйләмгә күчүе белән белдерелә. «Кияү» хикәясендә Мәрфуга абыстайның туй турындагы уйлары да уртак сөйләм тәшкил итә. «Ул әле өйләнмәгән иде» хикәясе дә уртак сөйләмгә бик бай. «Остазбикә» хикәясеннән бер мисал: ...аның башыннан «Ул кая?», «Ни булды?» – дигән сөаль китмәде.Чын, ул кая? Иртәгә, йә аннарыга кайтам дип киткән кешегә дүрт көн булды, һаман юк! Кайдан собраниесе шул юк кәгазьне тикшерергә җибәрде! Кайдан ул шундый караңгы төнле, кыска көнле көзге айларда белмәгән-нитмәгән авылга китеп барды? Төне нинди? Аты, килеп, күпер астына төшеп батып үлсә... Үлсә?!. Шул сүз аның бөтен тәнен-җанын өшетеп җибәрде (Остазбикә).

Бу мәкаләдә әдипнең 15 томлыгының 2 нче томына туплап бирелгән әсәрләренең кайбер тел үзенчәлекләре анализланды. Башка язучыларның теле белән чагыштырып, аның иҗаты өчен хас булган гади сөйләм сүзләре, мишәр диалектына хас лексика, аларның морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре, төрле синтаксик фигуралар, аларның хикәяләүдәге стилистик роле күрсәтелде. Гади җөмлә, катлауландырылган җөмлә, кушма җөмлә, катлаулы кушма җөмләләрнең дә төзелешенә игътибар ителде. Аларның Г. Исхакый теленә хас үзенчәлекләре яктыртылды. Алга таба Г. Исхакый әсәрләренең тел үзенчәлекләрен галимнәр тирәнрәк өйрәнерләр дигән өметтә калабыз.

ӘДӘБИЯТ


1. Рамазанов Ш. Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 200 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 154 б.

3. Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. 254 с.

4. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 263 б.

5. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского литературного языка (20 век): дис. в виде науч. докл. ... д-ра филол. наук. Казань, 2000. 116 с.

# Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ ЯЗМА ҺӘМ МУЗЫКАЛЬ МИРАС ҮЗӘГЕНДӘ Г. ИСХАКЫЙ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ

***Л.Ш. Гарипова*** *(Казан)*

При содействии организатора фонда «Аяз Тахир (Туркестан – Идель-Урал)» доктора Тулей Дурана из Турции на историческую родину было возвращено богатое письменное наследие классика татарской литературы Гаяза Исхаки. Часть этого наследия в настоящее время хранится в ЦПиМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Среди этих материалов большое значение имеют электронные копии личных дневников писателя, которые он вел в период с 1919 по 1953 г. Гаяз Исхаки в 1919 году, будучи делегатом Версальской конференции, выезжает через Дальний Восток в Европу, где и остается до конца своей жизни. В этих дневниках раскрывается жизнь и деятельность писателя в эмиграции.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, дневники, эмиграция, история, наследие.

With the assistance of the Fund organizer «Ayaz Tahir (Turkestan – Idel-Ural)» Dr. Tuley Duran from Turkey to the historical homeland the rich written heritage of the Tatar literature classic Gayaz Iskhaki was returned. Part of that heritage is currently stored in the archive of rear book and musical heritage centre of language, literature and art institute by name G. Ibragimovof AN RT. Among these materials the electronic copies of the personal writer diaries, which he led in the period from 1919 to 1953 are most importance. In 1919 Gayaz Iskhaki as a delegate to the Versailles conference, travels through the far East to Europe, where remains until the end of his life. These diaries reveals the life and activities in emigration.

**Key words:** G. Iskhaki, diaries, emigration, history, heritage.

Татар халкының күренекле улы, горурлыгы булган олуг язучы Г. Исхакый мирасы ТР ФА Г. Ибраһимов исем. тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә археографик экспедицияләр нәтиҗәсендә, шулай ук аерым кешеләрнең ярдәме белән туплана башлый. Алар нигезендә 1990 нчы елларда язучының шәхси фондын оештыру да мөмкин була һәм шул елны Әдибә Сабирова тарафыннан аның беренче тасвирламасы да төзелә (135 нче фонд). Соңрак, Г. Исхакый мирасының халкына кайтарылуы, гомумән язучының тормышын, иҗатын яктырткан материаллар күпләп басыла башлагач, аларның күчермәләре дә үзәккә туплана бара. Шулай ук 1995 елда галимә Лена Гайнанова әдипнең мөһаҗирлектәге тормышына кагылышлы кыйммәтле документлар күчермәсен бүләк итә. Алар да фондны баетып җибәрә. 2008 елда, язучының юбилее уңаеннан, Төркиянең «Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал» фонды җитәкчесе Түләй Дуран Г. Исхакыйның зур мирасының бер өлешен ватанына кайтаруда зур ярдәм итә: олуг ватандашыбызның сирәк документлары, язмалары, кайбер мәкаләләренең, хатларының электрон күчермәләре Институт Мирасханәсенә тапшырыла. Язучының мөһаҗирлек дәверен яктырткан әлеге материаллар арасында Г. Исхакыйның көндәлек дәфтәрләре гаять зур әһәмияткә ия.

Көндәлекләр 1919 елның апрельаеннан башланып, 1953 елның 10 нчы ноябренә кадәрге вакыйгаларны, ягъни Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге хәятен үз эченә ала. Алар гарәп язуында гади укучы дәфтәренә язылганнар, күләмләре ягыннан төрлечә. 1919 елдан 1921 елга кадәр алып барылган көндәлекләр үзләре 22 дәфтәрдән гыйбарәт булып, һәр көн булып үткән вакыйгаларга җентекле анализ ясалып барыла. Ләкин шуннан соң көндәлек алып бару эше тукталып кала һәм 1930 елларда гына дәвам ителә. Әлеге еллардагы хатирәләр бер дәфтәргә тупланган. Аннан тагын, ягъни 1932 елдан 1942 елга кадәр вакыт аралыгында тынлык, өзеклек. Яңадан көндәлек алып бару соңрак, бары 1943 елда Төркиядә яңартыла. «Истанбулдагы хатирә дәфтәрләрем» дип

аталган әлеге истәлекләр үзләре 19 дәфтәрдән гыйбарәт, бу – 1943 елның 13 августыннан 1953 елның ноябренә кадәр вакыт арасы.

Билгеле булганча, Версаль тынычлык килешүенә 1919 елның 28 июнендә кул куела. Бу килешү төзелгәнче, Парижда 1919 елның 18 гыйнварында Тынычлык конференциясе ачыла. Милләт мәҗлесе аңа делегатлар җибәрергә ниятли һәм аның 1918 елның 8 гыйнвар утырышында солых һәйәтенә вәкилләр сайлана. Моңа Ә. Цаликов, Г. Исхакый, Ф. Кәримине тәкъдим итәләр, ләкин шул елның язында Милләт Мәҗлесенең кече Милләт Мәҗлесе җыелышы солых һәйәтенә яңа составны карый, аның карары нигезендә яңа составка хокук белгече, сәясәтче һәм журналист Гомәр Терегулов (1883–1938), сәяси эшлекле, публицист, «Таңчылар» төркемен оештыручылардан, аның җитәкчеләреннән берсе булган Ф. Туктаров (1880–1938) һәм Г. Исхакый кертелә. Көндәлекләр нәкъ менә шушы Версаль килешүенә баргандагы авыр, михнәтле һәм дә җаваплы юлның төрле яктан тасвирлануы белән башланып, әдипнең мөһаҗирлектәге – Европа һәм Азиянең төрле мәмләкәтләрендә яшәгән тормышын, эшчәнлеген тулы күзалларга ярдәм итә.

Барлыгы 41 дәфтәр тәшкил иткән көндәлекләрнең Мирасханәгә, кызганычка каршы, беренчесе килеп җитмәгән. Кулыбыздагы икенче санлы дәфтәр-көндәлек 1919 елның 26 апрель көне белән ачыла. Бу вакытта инде Г. Исхакый иптәше Г. Терегулов белән Японийдә: «Без Гомәр берлә, Япониягә барып, Аурупага чыгар өчен юл визалары эстәсәк дә, дүрт ай эчендә һичбер җирдән мөсагадә ала алмаенча, кире Харбинга кайткан идек» дип яза әдип үзенең «Солых һәйәте әгъзасы Фуад Туктар вафат» дигән мәкаләсендә [1: 36]. Шушы дүрт ай эчендәге һәр көннең вакыйгалары дәфтәрләрдә ачык чагылыш таба: виза артыннан бер илчелектән икенчесенә йөрүләр, бер сүз, бер җавап алу өчен ялыну-ялварулар, кимсетелү-кимсенүләр, язучының күңел газаплары, рухи куәсенең кимүе... Мөһаҗирлекнең беренче өч елында Г. Исхакый көндәлекне эзлекле рәвештә, көннекен-көнгә язып барырга тырышкан: һава торышыннан алып, илнең икътисадый хәле, иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышы, язучының аларга мөнәсәбәте,үзенең рухи һәм физик халәте хакында кайчак кыска гына мәгълүмат бирелсә, кайбер урыннарда алар берничә биткә сузыла.

Г. Исхакый чит туфракка аяк атлау белән, аны һәрьяклап өйрәнә башлый, кая гына барса да, аны туган иле, ватаны белән чагыштырып бара. Чит җирнең халкы, аның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре генә түгел, алар ни уйлый, нинди хыяллар белән яши – язучы өчен барысы да әһәмиятле. Менә алар Японийнең зур шәһәре булган Токиода. Биредәге музей-күргәзмәләр, аларның байлыгы, күргәзмәдәге рәсем-картиналар, рәссамнарның осталыгы, гомумән, япон халкының сәнгатькә мөнәсәбәте, сәнгатьнең ни дәрәҗәдә булуы язмаларында ачык чагыла. Уку йортлары белән танышканнан соң, Г. Исхакый биредәге уку-укытуның торышы, аның куелышын җентекләп тасвирлый да: «...мәктәб мондан алтмыш йыл элек бер мөгаллимнең дәрде берлә хосусый өйдә генә башланган. Шундан бирле тәрәккъый итә. Японийнең иң зур гыйлем йортына әйләнгән. Хәзер бөтен сыйныфларында җиде мең шәкерд бар. Дөнья кадәр биналары бар, үзенең гәзитәсе бар. Гали кыйсмендә генә алтмышлаб профессор бар. Укучылардан йылына гына утызар иен алыб укытса да, йылына өч йөз мең иен мәсарыф тота икән. Бу мәктәбкә караганда монын тәрәккъый тарихын күздән кичергәндә, бик тирән уйларгакитәсең. Ник безнең Шиһаб хәзрәтнең мәдрәсәсе бүгенге көндә шул гыйлем йорты дәрәҗәсен алмаган да, ник "Мөхәммәдия" шуның юлына басмаган, ник "Хөсәения" шул эзгә кереп китмәгән дә, агач башмаклы японларның алтмыш ел элек башлаган ибтидаи мәктәбләре җиде мең шәкердләре Яурупада урын тота торган гыйлем йортына

әверелгән. Бу сөальләр тугрысында уйларга ярый...» дип ачына. Кызлар гимназиясеннән дә язучы зур тәэсирләр белән чыга, биредәге оештыру эше, укытуның гамәли ягына зур басым ясалуы, язучы сүзләре белән әйткәндә «өйрәтү тәмамән күзгә күрсәтү ысулы куелган», хатын-кызны тормышка чын мәгънәсендә әзерлекле итеп чыгаруга корылган уку йорты булуына басым ясый: «Мондагы иҗтиһад, мондагы тырышлыкны күргәндә бу халыкның алтмыш ел эчендә шулкадәр зур адым атлавының мәгънәсен дә аңлыйсын. Сөендерә беләсез – монда хатынларны эш кешесе итдереп чыгаралар. Монда хатынларга уенчык, курчак, ирләренең хәятен төрлеләндерүче дип карау кермәгән. Монда алар да ирләре берлә бергә эшләүчеләр, туйдыручылар» (135 ф., 2 дәфтәр).

Г. Исхакый япон матбугатында да актив катнаша, ләкин, мәкалә басылып чыкканчы, күп киртәләр аша үтәргә кирәк була – җаваплы тәрҗемәче табу өчен ничәмә-ничә кеше белән сөйләшүләр алып бару, инде тәрҗемәче тапканнан соң да, аннан җавап көтү. Язучы Япониянең күп кенә дәүләт эшлеклеләре белән дә таныша. Мәсәлән, тышкы эшләр министры булып торган граф Окума Сигенобу (1838–1922) белән очраша. Әлеге очрашуның тәэсирле мизгелләре тулы бер истәлек рәвешен алган: «Япониянең ихтилялы вакытында алтмышынчы елда маркиз Окума революционер булып, сугышып, аягын сындырган, шундан бирле аның аягы аксак калган. Зур, таза бер карт. Киң маңгайлы, ачык күзле, зур башлы. Өстенә японча җилән кигән, бай авыл ахунларына охшаган. Күрешәмез дә утырышамыз. Маркиз: “Мин күбдәндән бирле татар милләтенең вәкилләрен күрергә зар булып тора идем, сез килгәнен ишеткәч дә күрешәсем килде” – ди. Без шундый олуг кешеләрнең булуы, халык өчен шулкадәр хезмәт иткән кеше күрергә мөяссәр булуымыз өчен шатлыгымызны изһар итәмез (*белдерәбез*)... Маркиз Окума әфәнде эшләгән эшләренең йимеше йитешкәнен үзе күргән, ул үзенең милләтенең зур бер милләт булуын күзе берлә күргән, үзенең милләтенең олуг дәүләт булуын үзе күргән, шуның олуглыгыны соңындан үзе файдаланган» (135 ф., 2 нче дәфтәр).

Әйтеп үтелгәнчә, язучы көндәлеген 1919 елдан 1921 елга кадәр эзлекле рәвештә алып бара, әдипнең язмый калган, каләм алмаган көннәре бик сирәк. Каты авыртканда да, эшне алга таба ничек дәвам итәргә, нәрсә эшләргә? дип бәргәләнгәндә дә ул кулына каләм ала: «Бөтен авыру буе Агишевларда ятдым. Үзең кеше өстендә, үзең авыру, үзең паспортсыз, үзең бара торган юлыңдан өзелгән. Әлбәттә, болар рухка бик начар тәэсир итеп торды» (135 ф., 6 нчы дәфтәр). 1921 елдан соң көндәлек алу бару тукталып кала һәм 1928 елда гына кабат дәвам ителә. Моның сәбәпләре, әлбәттә, күп төрле, бу, бер яктан, әдипнең бөтен җаны-тәне белән дөнья буйлап таралган, сибелгән милләттәшләрен берләштерү өчен төрле илләрдә милли оешмалар төзү, милли матбугатны булдырудагы көрәше, тынгысыз эшчәнлеге, икенче яктан: «Русиядән чыкгандан башлаб, көндәлек дәфтәр язу гадәтем иде. Ләкин бу өч сәнәдән артык дәвам итә алмады, Германиягә күчеп килгәч, хәятем бик гади юлга керде. Нимесләрнең тормышында төрле үзгәрү булса да, никтер аңарга сәерче (*читтән карап торучы*) булыб калдым. Зур әһәмият бирмәдем. Төркиягә килдем. Анда бик зур өмид берлә, бик күп ихласлар берлә килгән идем. Төркия, хакыйкатән, безнең кебекләрнең хезмәтләренә мохтаҗ иде. Һәм дә безнең буш вакытымыз күп иде. Төркия үзенең тормышында бик күп өстендәге үзгәрүләргә мәгъруз кала иде, язарга бик күп нәрсә бар иде. Ләкин Төркиядә аз гына да хөррият булмаганга, хатирә дәфтәрем язмадым» дип, үзе дә бу хакта аңлатып китә.

Исхакыйның 21 нче көндәлек дәфтәренең тышында 1928 елның 26 марты дигән дата тора һәм ул: «Хәзер менә дүрт айдан бирле Варшавада торам. Хезмәтем – Шәрык мәктәбендә мөгаллимлек итү. Максадым – милли

фикерләремне монда аңлату, инде дүрт айдан бирле шул хакда тырышам» дип башланып китә. Ләкин әлеге датаның куелышы сорау астында кала, чөнки, беренчедән, ул әдип кулы белән түгел, соңрак язылган булырга мөмкин, икенчедән, дата астында җәяләр эчендә сорау билгесе дә тора, шулайук, күп чыганакларда Г. Исхакыйның бу вакытта Германиядә яшәве әйтелә. Польшада язучы күптөрле иҗтимагый-мәдәни эшчәнлек алып бару белән бергә, бу илдәге милләттәшләре тарихы, язмышлары белән дә ныклап кызыксына, матбугатта мәкаләре басыла. 1928 ел – язучының юбилей елы да: «Мин 1878 нче елда 23 нче февральдә туганмын. Шуның өчен бу ел илле яшем тулды. Шуны бераз бәйрәм ясарга уйлаган идем, ләкин ярдәмче булмаганга, эшли алмадым. Ләкин шул көн бөтенләй буш үтмәсен дип, тавык тутырды. Аз гына кунакларга коньяк алдым. Кунакларым күбесе минем иттифакый дусларым иде. Үземнең милли даирәмдә бергә булган кеше берәү дә юк иде. Татар хәрәкәтендә бергә булынган Гомәр (*Г. Терегулов. – авт. иск.*) генә бар иде. Татар исемендән икенчесе мондагы акыллырак бер агай-эне Мөхәммәдҗан Ибраһимов. Башкалары кавказлы Әхмәд Салихан, андан соң дүрт поляк. Мәҗлес үзенә күрә матур үтде. Озын итдереп утырдык. Сәгать җидедән башланган мәҗлес бердә генә бетде. Нотыклар-теләкләр сөйләделәр. Эз калдырырга бер нәрсә булмаса да, үзенә күрә ярыйсы үтде. Милли мөхәйялчеләрнең беренче буыны, үзең мөселман, үзең төрк, үзең мөһаҗир, үзең шул пычрак берлә томаланган дөньяда пакь булып яшәргә теләгән ахмак язучыга ярый инде. Шундан артык тагы ни кирәк» дигән сүзләрдә күпме әрнү, сыкрану-сызлану, йөрәк ачысы. Мөһаҗирлектә, туган иленнән еракта, аны гел искә төшереп яшәгән милләтпәрвәр әдипнең чит җирләрдә яшәгән милләттәшләрен берләштерү, татарларның, гомумән төрки халыкларның милли азатлыгы өчен үзен аямыйча көрәшкән фидаи җанның сыктавы да бу.

Гомер буе «шәхси тартыш, милли тартыш, сәяси тартыш» белән яшәгән әдип көндәлекләренең ахыргы битләрендә аның авыру тарихы языла. Хастаханәдә ятканда да ул көндәлек дәфтәрен ташламаган, кыска гына булса да теркәп барырга тырышкан. Үзен караган табиблар, дәвалану барышы, нәтиҗәләре турында күп мәгълүмат бирелә аларда: «Бик күпләр килде-китде, мине ялгыз, үзбашым калдырмадылар. Халыкның җылы дустлыгы, безнең кебек халык юлында хаста булганларга, мәгънән, шифалы дару кебек буладыр. 15 октябрь 1953».

Гомумән, язучының тәрҗемәи хәлен, мөһаҗирлектәге тынгысыз, милләтенең якты киләчәге өчен алып барган эшчәнлеген дә, Азия һәм Европа мәмләкәтләрендәге вазгыятьне дә яктырткан әлеге көндәлек дәфтәрләре, бер язучыныкын гына түгел, халкыбыз тарихын өйрәнгәндә дә кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә.

«Хаклык югалмаган кеби, хаклык корбаны да онытылмыйдыр» дип яза Г. Исхакый Фуад Туктаров турындагы мәкаләсендә. Бу сүзләрне без аның үзенә карата да әйтә алабыз. Татар милли азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы булган, бу юлда үзен аямыйча көрәшкән олуг язучыбызның мирасын халкы өйрәнергә, сакларга-якларга бурычлы.

### ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Әсәрләр: 15томда. 13 т.: публицистика / [томны төз., иск. һәм аңлат. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин]. 2013. 335 б.

2. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

3. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 135 нче фонд.

4. Нуруллин И. Гаяз Исхакый: (Әдипнең тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача бер күзәтү). Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 210 б.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ЖУРНАЛИСТИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

***В.З. Гарифуллин*** *(Казан)*

В статье анализируется публицистическая деятельность Гаяза Исхаки. Он оставил яркий след в истории татарской национальной журналистики дореволюционной России: был учредителем первых газет на татарском языке, автором большого количества оригинальных журналистских произведений. После октябрьской революции 1917 года Исхаки выражал свое несогласие с политикой большевиков, за что был вынужден эмигрировать из России и активно продолжил журналистское творчество за рубежом, организовав несколько газет и журналов на татарском языке, вокруг которых объединялась национальная интеллигенция из числа эмигрантов. Публицистическое творчество Гаяза Исхаки в условиях вынужденной эмиграции характеризуется острой полемичностью и сильной критикой действий советского режима.
Изучение богатого творческого наследия Г. Исхаки в сфере периодической печати актуально для восполнения белых пятен в истории татарской журналистики.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, татарская периодическая печать, публицистика, наследие, история журналистики, эмигрантская пресса.

The article analyzes the journalistic activity of Gayaz Ishaki. He left a vivid trace in the history of Tatar national journalism of pre-revolutionary Russia: he was the founder of the first Newspapers in the Tatar language, the author of a large number of original journalistic works. After the October revolution of 1917, he expressed his disagreement with the Bolshevik policy. During this time he was forced to emigrate from Russia and actively continued his journalistic work abroad. He organized several Newspapers and magazines in the Tatar language. Around these publications United national intelligentsia from among the emigrants. The publicistic of Gayaz Ishaki in conditions of forced migration is characterized by acute polemic and strong criticism of the Soviet regime.
The study of the rich creative heritage of Iskhaki in the sphere of periodicals is relevant to fill the white spots in the history of Tatar journalism.
**Key words:** Gayaz Ishaki, tatar periodicals, journalism, heritage, history of journalism, emigrant press.

Татар матбугатының нигез ташларын салучылар рәтендә, һичшиксез, халкыбызга яңадан әйләнеп кайткан бөек әдип һәм журналист Гаяз Исхакый исемен дә атарга мөмкин. Кабатланмас публицистик осталыгы белән ул чордашларын гына түгел, әле бүгенгә кадәр күп буын укучыларны таңга калдыра. XX гасырның 90 нчы елларыннан башлап, Исхакый мирасын өйрәнүче галимнәр беренче чиратта аның бөек язучы һәм драматург булуына басым ясасалар да, күп кенә фәнни хезмәтләрдә әдипнең бай публицистик мирасына да игътибар ителә. Әйтик, профессор Хатыйп Миңнегулов тарафыннан Гаяз Исхакыйның эмиграциядә нәшер иткән «Милли юл» журналындагы язмаларга җентекле анализ бирелде [18], Лариса Усманованың төньяк-көнчыгыш Азиядәге төрки-татар диаспорасын өйрәнүгә багышланган монографиясендә шулай ук Гаяз Исхакыйның мөһаҗирләр матбугатын оештырудагы зур роленә басым ясалды [23], Исхакый публицистикасының тематик юнәлешләре һәм жанр үзенчәлекләренә багышланган диссертация якланды [19], шушы аспектны өйрәнүгә багышланган мәкаләләр язылды [20: 22].

Журналистикада тәүге адымы булган һәм К. Насыйриның вафаты белән бәйле беренче мәкаләсен Исхакый 1902 елда «Тәрҗеман» газетасында бастырып чыгара. Шул чордан башлап, журналистика Гаяз Исхакыйның мөһим иҗат тармагына әверелә.

Г. Исхакыйның журналистлык һәм публицистлык эшчәнлеген төп өч этапка бүлеп карарга булыр иде. Беренче этап 1905–1912 елларны үз эченә ала. 1905 елда Гаязны «Казан мөхбире» газетасына эшкә чакыралар, ләкин ул үз басмасын булдыру хыялы белән яна. Чөнки бу чорда ул социалистик идеяләр

белән кызыксына, татар эсерлар хәрәкәтен җитәкләүчеләрнең берсенә әверелә, әлеге партия карашларын тарату өчен үз басмасын булдырырга хыяллана. Нәтиҗәдә фикердәшләре белән бергә «Таң йолдызы» газетасын чыгара башлый. Формаль рәвештә газетаны үзе җитәкләмәсә дә, фактик редактор булып гел үзе кала.

Газетаның программасында максаты ачык куелган: «Мондый куркыныч, чуалчык вә бик мөһим бер вакытта без дә эшче һәм үзе эшләп көн күрә торган авыл халкының файда вә сәгадәтләрен күзәтеп, аларны үзләренең дошманнары байлар, бюрократлар һәм болар җырын җырлый торган төрле вөҗдансыз, оятсыз партияләрнең аздыру агуларыннан саклап, үз мәсләкләре, үз сәгадәтләре өчен тырышырга вә шул караңгы төндә, кара урманда таң йолдызы булмакчы булабыз» [21: 78]. Г. Исхакый әлеге газета аша татар тормышындагы нинди мәсьәләләрне күтәргән соң? Беренче чиратта, сәяси тормыш, мәктәп-мәдрәсәләр реформасы, матбугатка күзәтүләр. Баш мәкаләләрдә исә көндәлек проблемаларга мөнәсәбәт күрсәтелә. Бу чорда Исхакый җәмгыятьтәге проблемаларны милли ноктадан түгел, иҗтимагый гаделлек мәнфәгатеннән чыгып бәяли [21: 79]. Күп кенә язмаларында ул сыйнфый көрәштә руслар белән берләшергә чакыра. «Татарлар һәм революция» дигән мәкалә [15] шундыйлардан. Анда Исхакый: «бу самодержавиедән татарлар да, руслар да бергә җәберләнделәр, бергә изелделәр», – дип яза [15: 41].

«Таң йолдызы» газетасы үз заманында чыккан басмалар арасында тоткан кыйбласының аныклыгы, фикерләренең гаять аңлаешлы чиста татар телендә бәян ителеше, укучыны ялыктырмый торган кызыклы алымнар табуы белән аерылып тора. Әйтик, иң мөһим сәяси һәм иҗтимагый вакыйгаларга мөнәсәбәтне Г. Исхакый «Таң йолдызы» битләрендә Бикмулла белән Биктимер атлы ике кода арасындагы хатлар рәвешендә бирә. 22, 24, 27, 36, 38, 46, 52, 59 нчы саннарда чыккан һәм «Гыйззәтле вә хөрмәтле Бикмулла кода!» дигән уртак баш исем астындагы мондый хатлар нигездә милли тормыш мәсьәләләренә багышланган.

Гаяз Исхакыйның «Ачлык башланды» дигән публицистик мәкаләсе [2] укучыга аеруча зур тәэсир көченә ия. Мәкаләнең төп фикере шуннан гыйбарәт: Россиядә башланган ачлыкның сәбәбе крестьяннарның җирсезлеге белән бәйле, шуңа күрә, җир мәсьәләсен хәл итәрдәй кыю депутатлар сайлап, Думаны яңартырга кирәк. Бу фикерне куәтләү максатында автор икеләтә тәэсир көченә ия булган дәлилләр системасыннан файдалана: беренчесе конкрет саннар һәм фактлар булса, икенчесе аерым тел чараларын кабатлаулы куллану:

*Ачлык башланды: үзенең маңлай тире берлә тапкан акчасына куелган зимский начальникларны ашатып, аларга һәр елны 10 миллионнан артык жалунья бирүче авыл халкы ач тора башлады.*

*Ачлык башланды: стражникларга елына 34 миллион үзенең акчасыннан биреп торучы авыл халкы ач тора башлады.*

*Ачлык башланды: ике йөз меңле казак гаскәренә йөзәр миллион расход тотучы авыл халкы ач тора башлады.*

*Ачлык башланды: үзенең туганнарын, үзенең балаларын ябар өчен, аларны черетеп яткырыр өчен ясалган төрмәләр расходына 30 миллион акча бирүче авыл халкы ач тора башлады.*

*Ачлык башланды: үзенең иң файдалы кешеләрен, үзенең дустларын әллә кайларга, Себергә җибәрер өчен куелган жандармнар, шпионнарга йөзәр миллион акча бирүче авыл халкы ач тора башлады.*

*Ачлык башланды: бөтен алпавытларны үзенең хезмәте берлә оҗмахтагы кебек тик кенә, рәхәтләндереп кенә тоткан авыл халкы ач тора башлады* [2: 89].

Мәгариф мәсьәләләре, бигрәк тә мәдрәсәләргә реформа ясау, анда уку-укыту тәртипләрен үзгәртү, укытыла торган фәннәрнең составын тулыландыру, яңарту, заманга яраклы итү проблемалары – «Таң йолдызы»ның үзәгендә. Ләкин Исхакый мәгариф һәм мәдәният мәсьәләләрен илдә сәяси һәм икътисадый шартларны үзгәртмичә торып хәл итеп булмый, дип саный, «идарә үзгәрмәгәндә, хәзерге бюрократиянең золымы астында мәдрәсәләр һәм мәктәпләрдә ислах итү мөмкин түгел», – дип яза [7: 60]. Ул шәкертләрне, халыкны, мөгаллимнәрнең үзләрен җәмгыять эшләрендә актив катнашырга чакыра. Моның ачык мисалы – Исхакыйның «Таң йолдызы» газетасында 1906 елның 27 июнь санында дөнья күргән һәм татар шәкертләренә адресланган ачык хаты [17].

Текст, эпистоляр жанрларга хас булганча, адресатка мөрәҗәгать итү белән башланып китә. «Туганнар, шәкертләр!» – ди автор. *Туганнар* дигән сүзне текст башында ук кулланып, ул үзенең шәкертләргә карата эчкерсез һәм якын мөнәсәбәттә булуын ассызыклый: *Сез кайда торасыз? Кая киттеңез? Ник бер дә сезнең тавышыңыз ишетелми?*

Текст кире тәртиптәге дәлилләү ысулы белән корылган: башта төп фикерне, ягъни татар шәкертләренең бүгенге җәмгыятьтәге проблемаларга битараф булуын күрсәтеп бирә торган дәлилләр китерелә. Аларның тәэсир көчен арттыру өчен автор тагын да шул кабатлау ысулын актив файдалана:

*Сезнең мәдрәсәләрдә укырга ярарлык нәрсә юклыгыны белеп, мәдрәсәне ташлап чыкканнан бирле, бик күп вакытлар булып үтте, бик күп сулар акты, бик күп үзгәрүләр булды. Дума чакырылды, дума йир мәсьәләсен хәл итә алмады, дума үзенең бер төрле дә эшкә яраксызлыгын белдерде. Моны күреп завод-фабрикаларда хәрәкәт башланды. Авылларда чуалыш китте.*

Кабатлау алымы текстның моннан соңгы өлешендә, югарыда тасвирлап бирелгән проблемага кагылышлы конкрет сораулар белән шәкертләргә мөрәҗәгать иткәндә дә актив кулланыла:

*Сез шул вакытта нишләдегез? Рус шәкертләре кебек, авылларда халыкны җыеп, авыл халкынаирекнең нәрсә икәнлеген аңлаттыгызмы? Рус шәкертләре кебек, завод-фабрикаларның эшчеләре янына барып, приказчик, конторщиклар берлән берләшеп, аларның тормышларын яхшыртыр өчен бер-бер хәрәкәттә булдыңызмы? Үзләренең хәлләренең ничек яхшыртуны аңлатыр өчен, аларга лекция ясап, кружоклар ясадыңызмы? Авылларда, завод-фабрикаларда тугры язган китаплар тараттыгызмы? Юк, юк.*

Текст болай тәмамлана:

*Уяныгыз, туганнар, үзеңезнең вазифаңызны эшли башлаңыз!*

Хөкүмәткә ачыктан-ачык оппозициядә торып, заманның кискен проблемаларын тирәнтен чагылдырган «Таң йолдызы»н даими эзәрлекләп торалар һәм 1906 елның ноябрь урталарында бөтенләй туктаталар. Исхакый үзе дә эзәрлекләүләргә дучар була, төрмәгә ябыла.

Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңаеннан төрмә һәм сөргеннәрдән 1913 елда гына азат ителгән Гаяз Исхакый матбугаттагы эшчәнлеген кабат дәвам итә. Аңа Казанда яшәргә рөхсәт ителми. Шул ук елны ул Петербургта «Ил» газетасын чыгара башлый. Бу – Исхакый фактик редактор булган беренче газета. Әлеге абруйлы басма авторлары арасында без даими рәвештә Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Фуад Туктаров исемнәрен очратабыз. Бераздан газета Мәскәүгә күчә.

Бу чорда (ә без 1913–1917 еллар аралыгын Гаяз Исхакыйның журналистлык эшчәнлегендәге икенче этап буларак билгелибез) аның карашлары да беркадәр эволюция кичерә. Ул инде сыйнфый көрәш идеясеннән баш тартып, чын ирекнең милләт азатлыгы белән бәйле булуын алгы планга куя. Моның өчен

милләтнең барлык катлаулары берләшергә тиешлеген асызыклый. Күп кенә язмаларында милләтне кайнар яклап чыга. Мәсәлән, «Мөселман фракциясе» (Ил, 1913, 13 дек.) [9] язмасында татар милләтенең битараф, ягъни җәмгыять эшләренә карата гафил булуы турындагы фикерне хисле-тәэсирле рәвештә кире кага. Моның өчен шулай ук кабатлау алымын актив эшкә җигә:

*Шул «гафил милләт» бит үзенең милли мәктәбен тәрбия итеп килә! Берне, унны, йөзне, меңне түгел, берничә меңне тәрбия итеп килә.*

*Шул «гафил милләт» бөтен халкымызга йитеп торырлык муллалар чыгара торган мәдрәсәләрне тәрбия итеп килде, һаман да килә.*

*Шул «гафил милләт» тырышып-тырмашып хөкүмәт мәктәпләрендә укучыларга ярдәмгә кереште. Көннән-көн ярдәмен арттыра.*

*Шул «гафил милләт» көннән-көн арта торган, соңгы сигез елда йөз мәртәбә арткан китап базарын күтәреп килде һәм килә.*

*Шул ук «гафил милләт» беренче, икенче, өченче Думаларда фракцияләрен күтәреп килде.*

Гаяз Исхакый, күп кенә ура-патриотлардан аермалы буларак, беренче бөтендөнья сугышының империалистик асылын тәнкыйтьли. Мондый характердагы язмалары өчен цензура «Ил»не тиз арада яба. Гаяз Исхакый журналистлык эшчәнлеген туктатмый, «Сүз» (1915–1916), «Безнең юл» (1916–1917) газеталарын җитәкли. Аларда илне, халыкны, милләтне борчыган иң актуаль проблемаларны күтәреп, күп санлы мәкаләләр белән чыгыш ясый.

*Bütün kır çalışıyordu. Bütün kır işin varlığıyla şendi. <...> Bu iş denizinde, işçiler arasında atımı yavaş yavaş süren işsiz ben, bu işçilerin bayramında kendi işsiz güçsüzlüğümü bilip, onların bu güzel iş bayramında olmaya hakkım olmadığını düşünerek beni fark etmesinler der gibi ağır ağır sürsem de içimden kendi kendimi ayıplıyordum.*

Bu, delikanlının köylüler ile kendisini bir karşıtlık içinde ilk görüşüdür. Bu yabancılaşma duygusu artar ve sonunda delikanlı tıpkı babası gibi kendi hemşerilerinden de uzağa düşer:

*Köyde ömür geçirmek çok zor. Burada ne bahçe var, ne müzik var, ne güzel giyimli melek yüzlü kızlar var, ne arkadaşlar var! <...> Dünyada bunda başka iş yokuş gibi on yıl önceki Kaşka aygırın gidişini, Kara ineğin vebadan ölümünü, Rehile ninenin keçisini kurt kaptığını konuşuyorlar. Bu sözlerin tadına doymuyormuş gibi konuklar bundan vazgeçemiyorlar. Ben sözü daha önemli meselelere, usul-i cedide, dünyanın yuvarlaklığına getirmeyi diliyorum, ama bu sözlere hiç iltifat göstermiyorlar. İçim sıkılıyor, bunlara sövesim sayasım geliyor. Şu büyük köyde kendimi yapayalnız hissediyorum.*

Delikanlının köy yaşantısıyla ve köylülerle olan bağları yıldan yıla kopmuştur ancak modernizmle ilişkilendirilen şehir hayatına da uyum sağlayamamıştır. Yazarın göstermek istediği de işte bu arafta kalıştır. Kültür çatışmasının yanı sıra Kazan'daki yaşantının tasviriyle dönem aydınların usul-i cedit hareketini içselleştirmekten uzak yüzeysel bakış açıları da eleştirilmiş olur.

İlk başlarda «benim gönlümü verdiğim bir işim, bir eşim, dostum yok. Her vakit yapayalnız, farazi düşüncelerimle baş başayım» diyerek boşluk duygusuyla şikâyet eden genç delikanlı, şehirde sözünü ettiği gibi dini ve milleti için kaygı duyan birisi gibi hareket etmez. Rusça öğrenmeyi genç kızlarla tanışabilmek için, modern kıyafetler giymeyi beğenilmek için, yeni çıkan romanları okumayı şehir hayatında tumturaklı sözler söyleyebilmek için ister.

*Bugün çıkıp palto aldım. Alfredler böyle giyiniyor ya, benim neyim eksik! Şimdi ayağa bot, pantolon bir de iyi bir şapka almak kaldı. Ondan sonra ben de onlar gibi bu rahat yaşamda kızlarla kaynaşırım.* Parklara giderim. *Orada güzel kızlarla romanlardaki gibi konuşurum.* diye tasarlayıp iki hafta boyunca Bakır Babay bahçesinde bekleyen genç delikanlı, alafranga kıyafetleri, Fransızca öğrenmekteki niyeti ve Çamlıca bahçesi gezintisindeki başarısız aşk macerasıyla literatürde Türk edebiyatının ilk alafranga züppesi olan Bihruz Bey'in bir diğer örneğidir:

*Bihruz Bey ilk hevesle beş altı ay kadar kaleme devam ederek daha Fransızca bir ibare okumaya iktidar kazanmadan ağızdan bellediği bir hayli söz ve tamlamalar ile en alafranga genç beylerin tavır, kıyafet, hal ve hareketini taklitte hakikaten büyük bir yatkınlık gösterdi. <...> Çamlıca Millet Bahçesi'nin açılacağını yakınlık münasebetiyle elbette herkesten evvel haber alan Bihruz Bey, Mart gelir gelmez validesini zorlaya zorlaya sayfiyeye taşınmaya razı etmiş ve köşke taşınmalarının ertesi günü hemen jarden püblike1 aceleyle gidip içerisini ve dışarısını muayene ederek buranın pek alâmod ve özellikle kendi arzusu olması bakımından süslerini başkalarına göstermeye pek favorabl bir promenad mahalli olacağını anlayınca ekipajına biraz daha süs vermek için Beyoğlu'nda tedarik ettiği bazı vesaitle Bender fabrikası üretiminden olmak üzere gayet hafif ve zarif bir araba ile mevcutlarına nispeten ikişer parmak daha boylu bir çift eğitimli Macar araba hayvanı ısmarlamıştı. Araba ile hayvanlar, tam bahçenin açılışının ikinci haftasında geldi yetişti. Bihruz Bey de hemen o haftadan itibaren her cuma ve pazar günü Millet Bahçesi seyircileri arasında görünmeye başladı* (Ekrem, 2017: 50, 52–53).

Kendini usul-i ceditçi olarak niteleyen genç delikanlının gerçekte «usul-i cedit» hareketine bihaberliği onun felaketi olur. Delikanlının günlüğündeki son satırları aynı zamanda yazarın okuyucusuna ihtarıdır:

*Bir yerde gizlenip kalmış bu kâğıtları, evi temizlemek için toplarken buldum. Başından sonuna dek okudum. Eski yaşantılar gözümün önünden geçti. Ve dahası bunlar benim uyuklayan yüreğimde derin bir yara açtı. Gece boyu uyuyamadım. Ne yaptığımı, ne yapıyor olduğumu ve ne yapacağımı düşündüm.! Uzun süre düşündükten sonra: «Bu mu ömür? Yaşamak bu mu?» diye bir sual düştü gönlüme. Bu «Yaşamak bu mu?» sorusu, ölmüş insanın hayaleti gibi belirdi önümde! Bir cevap veremedim. Size soruyorum: «Yaşamak bu mu?»*

KAYNAKÇA

1. Akyol, Taha. Cedidcilik // İslam Ansiklopedisi. İstanbul: TDAV, 1993. S. 211.
2. Berkes, Niyazi. Türkiye'de Çağdaşlaşma. İstanbul: YKY, 2008. S. 380, 416.
3. Ekrem, Recaizade Mahmud (Yayına Hazırlayan: Fatih Altuğ). Araba Sevdası, İstanbul: İletişim, 2017. S. 50, 52–53.
4. İshaki, Ayaz. Tormış mı Bu. Erişim Tarihi: 25.03.2018 https://tt.wikibooks.org/wiki/

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ 1905–1910 ЕЛЛАР ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА ПРОБЛЕМАТИКА

***Т.Ш. Гыйлаҗев** (Казан)*

В статье изучается публицистическое наследие основоположника татарской литературы Нового времени, прозаика, драматурга Гаяза Исхаки. С 1905 года полностью посвятив себя общественно-политической деятельности, он стал признанным лидером национально-освободительного движения. Бурное развитие татарской периодической печати стало импульсом для формирования татарской публицистики в начале XX века. Становясь и ведущим журналистом Г. Исхаки сыграл большую роль в ее развитии. В работе определяются этапы публицистической деятельности писателя. Рассматриваются его общественно-политические взгляды на происходящие в стране события, а также на преобразования в татарском обществе. Выявляются основные характеристики его публицистики 1905–1910-х годов.
**Ключевые слова**: публицистика, писатель, общественно-политическая жизнь, взгляд, проблемы, татарский народ, периодическая печать, национальное движение.

This article examines journalistic heritage of the founder of Tatar literature of the New time, novelist, playwright Gayaz Ishaki. From 1905 to devote himself to political activities, he became acknowledged leader of the national liberation movement. The rapid development of the Tatar periodical press became the impetus for the formation of the Tatar journalism in the early twentieth century. Becoming and leading journalist G. Ishaki played a major role in its development. The work defines the stages of journalistic work of the writer. Discusses his political views on what is happening in the country, as well as the conversion to the Tatar society. Identifies the main characteristics of its journalism 1905–1910 years.
**Key words:** journalism, writer, social and political life, view, problems, Tatar people, periodical press, national movement.

Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салган язучы, драматург, сәясәтче Гаяз Исхакый XX гасыр башында әдәби иҗатның бер төре буларак мөстәкыйль үсеш сукмагына чыккан публицистиканы формалаштыруга һәм үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Билгеле булганча, 1905–1907 елгы Беренче рус инкыйлабының шифалы җилләре тәэсирендә Россия күләмендә башланган демократик үзгәрешләр «татар матбугатының зур тизлекләр белән үсеп китүенә шартлар тудыра» [8: 508]. Татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә бер-бер артлы нәшер ителә башлаган газета-журналларда эшләп, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Камал, Г. Ибраһимов һәм башкалар үткен телле журналист һәм ялкынлы публицист буларак танылалар.

Татар язучыларының публицистик эшчәнлеге совет чорында актив өйрәнелеп киленсә дә, соңгы елларда аңа игътибар кими төште. Әлеге бай мирас махсус тикшерү объекты булып тормаса да, әдипләрнең әдәби яисә тәнкыйди мирасларын яктыртканда, публицистик язмаларына, алардагы тема һәм проблема, жанрлар системасы мәсьәләләренә игътибар ителә. М. Гайнуллин, Г. Халит, И. Нуруллин, Ф. Әгъзәмов, Р. Нуруллина, М. Борһанова, М. Мәһдиев, Ф. Мусин һ.б ларның бу юнәлештәге традицияләре бүгенге көндә дә дәвам ителә.

Г. Исхакыйга килгәндә, аның публицистик мирасы 1990 елларда шактый эзлекле өйрәнелә башлый: бу юнәлештә Ф. Мусин, М. Хәсәнов, И. Нуруллин, Р. Әмирхан һ.б.ларның язмалары игътибарга лаек. Әмма аны тулы һәм коплекслы тикшерү киләчәк эше булып кала. Г. Исхакыйның 1905–1910 еллар публицистик эшчәнлегендә проблема төрлелеген һәм язучының иҗтимагыйсәяси карашларын ачыклауда хезмәтнең яңалыгы билгеләнә.

1904 елда Казанга килгәч, Г. Исхакый тулысынча үзен иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә багышлый. Ул шәкертләрнең «Берек» яшерен оешмасын төзи, Казан татар зыялы яшьләренең сәяси «Хөррият» җәмгыятен җитәкли. 1905 елларда социалистик юнәлештәге татар эсерлары – «Таңчы»лар төркемен

нигезли. Ул азатлык хәрәкәтенең «Россия халыкларының демократия һәм азатлык юлында төп каршылыкны самодержавиедә күргән революцион фиркаләр белән бәйләнгән радикаль канатын җитәкли. Әлеге беренче дәрәҗәдәге бурыч «таңчы»лар тарафыннан патша хакимиятенә һәм полиция-бюрократия режимына каршы киң фронт оештырган социалист-революционерларының сәяси платформасын туплауга китерә» [7: 178]. Моннан тыш ул шушы елларда нәшер ителгән «Таң йолдызы», ул ябылгач, аның дәвамчылары булып чыккан «Таң мәҗмугасы» һәм «Тавыш» газеталарының идея җитәкчесе була. Г. Исхакый татар халкының Яңарыш һәм милли азатлык хәрәкәтенең юлбашчысына әверелә.

Язучының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге журналистлык эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнеп, бер-берсен тулыландырып яши. Аерым мәгълүматларга караганда, әдипнең публицистик характердагы беренче язмалары 1902 елларда ук языла. Әмма иҗат активлыгы Беренче рус революциясе башланган вакытка туры килә. Г. Исхакыйның Россиядә җир мәсьәләсен яктырткан иҗтимагый эчтәлекле язмасы «Казан мөхбире» газетасының 1905 ел 8 декабрь санында басыла һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу юнәлештә активлыгын киметми. Аның 1998–2014 еллар аралыгында нәшер ителгән 15 томлык «Әсәрләр» басмасының алты томы (7, 9, 10, 11, 12, 13) бары тик публицистик хезмәтләрен, 6 нчы томы публицистикасын һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләрен туплаган. Менә бу факт Г. Исхакыйның XX гасырның иң ялкынлы һәм иң актив публицисты буларак таныта. «...ул, беренче нәүбәттә, сәясәтче, татар дөньясын үзгәртеп кору өчен ялкынлы көрәшче иде. – дип яза М. Хәсәнов. – Аның язу өстәле артына утырып, иҗат дәрьясына чумып, рәхәтләнеп әдәби әсәрләр язарга вакыты да, мөмкинлекләре дә булмый. Әсәрләренең күбесе зинданнарда, сөргендә чагында, бер җирдән икенче җиргә күчеп, юл йөргәндә язылган» [6: 26]. Г. Исхакый исеменең һәм мирасының үзенә лаек мәртәбәдә Ватанына, татар халкына әйләнеп кайтуы өчен фидакарьләрчә көрәш алып барган И. Нуруллин аның бу төр мирасының кыйммәтен шулай ук югары бәяли: «Унтугызынчы гасырның ахырында әдәбиятка килеп, зур әдәби һәм публицистик мирас калдырган бу шәхестән башка XX гасырның беренче чиреге татар иҗтимагый фикеренең һәм реалистик әдәбиятның кызу үсеп китеп, сыйфат сикереше ясавын туры дөреслегендә аңлап та, аңлатып та булмый» [5: 5].

Г. Исхакыйның киңкырлы мөһаҗирлек иҗатын тирәнтен өйрәнгән Х. Миңнегулов бу чор публицистикасының тематик киңлеген билгели: «Журнал “Яңа милли юл”, в первую очередь, адресован татарским читателям, поэтому в нем преобладает татарская тематика, т.е. комплексное освещение татарской истории и современности во всех ее проявлениях и формах. В частности, журнал регулярно предлагает своим читатателям материалы о Шигабуддине Марджани, Каюме Насыри, Исмагиле Гаспралы, Ризаэтдине Фахруддине, Габдулле Тукае и о других великих людях науки и литературы» [2: 245–246].

Исхакыйның публицистик язмалары «Таң йолдызы»ыннан тыш «Бәянелхак», «Әльислах», «Таң мәҗмугасы», «Казан мөхбире», «Тавыш», «Ил», «Сүз», «Безнең ил», «Мәктәп» һ.б. газета-журнал битләрендә урын ала. Тарихи барыш аның иҗтимагый-сәяси карашларын һәм сәнгатьчә фикерләвен үзгәрткән кебек, әдип публицистикасының да үсеш баскычларын аерып чыгарырга мөмкин. Дөрес, ул бүгенге көндә галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән әдәби иҗат чорларына, нигездә, туры килә. Исхакыйның 1905–1910 еллар аралыгында язылган публицистик мәкаләләрендә революция һәм сыйнфый көрәш идеяләре кызыл җеп булып сузылса да, аларда Россия сәяси тарихы контекстында татар тормышының актуаль, көнүзәгендәге проблемалары да карала.

Дөньяга карашлары, иҗтимагый позициясе, тарихи барышны аңлавы тарихи вакыйгаларга бәя-мөнәсәбәте әдипнең публицистик эшчәнлегендә хәлиткеч

роль уйный. Иҗтимагый гаделлек, милли, социаль азатлык, тигезлек, шәхес ирege өчен көрәш идеясе Г. Исхакый эшчәнлегенең кыйбласын билгели. «Безнең мәсләкемез һәм миллият» (1906) мәкаләсендә милли тигезлек, хөррият, сайлау ирege һәм хокук мәсьәләләре куела: «Һәр милләт, һәр кавем үзенең милли правоʼларын саклый алсын өчен, без сайлау правосының да һәр халыкның саны белән мөтәнасиб (туры килгән) булып, мәмләкәттә милләте хәкимә вә милләте мәхкүмә (идарә итүче милләт һәм хокуксыз милләт) исемнәре бетереп, бер падишаһлыкта никадәр төрле-төрле милләтләр булсалар да, аларның бер падишаһлык ясап бергә торулары һичбер милләтнең икенче милләтне көчләвенә бина кылмаенча, дустлык һәм тигезлеккә бина кылынуын требовать итәмез» [1: 28–29].

Г. Исхакый Дәүләт Думаларының эшчәнлеген, анда тикшерелгән һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең хәл ителеше белән актив кызыксына һәм үз мөнәсәбәтен белдереп, газета битләрендә яктыртып бара. «Хөкүмәт һәм халык» (1906), «Җирне халыкка бирү мәсьәләсендә думада өч партия» (1906) язмаларында җир мәсьәләсе үзәккә куелып, конституцион-демократик, кадетлар һәм авыл халкы партияләрненең җир мәсьәләсенә өч төрле позициядә торуын яза. Язучы авыл халкы депутатларының карашын яклый: «Йир мәсьәләсе эшче һәм авыл халкының киләчәктәге тормышының нигезен үзгәртә торган эш булганга, болар әлбәттә, бу мәсьәләне эшче һәм авыл халкы теләгәнчә хәл кылыр өчен казенный, монастырь, удельный һәм алпавытлар йирләренең һәммәсен элгәрге хуҗалары кулыннан алып халыкка бирелүне һәм авыл халкының барчасыннан да тигезлек берлән тугрыдан-туры яшерен тавыш берлән сайланган авыл комитетлары ихтыярларына бирелүен требовать иттеләр» [1: 31].

Татарлар һәм инкыйлаби хәрәкәт, революцион вакыйгаларда көрәш тактикасы проблемалары Г. Исхакыйны кызыксындыра. Аның Чыңгыз имзасы белән басылган «Татарлар һәм революция» (1906) язмасының башлам өлешендә татарларның сыйнфый көрәшкә битарафлыгының сәбәпләре ачыклана. Автор аны самодержавиенең татарларга нисбәтле гасырлар буенча алып барган милли-колониаль сәясәте белән бәйләп карый: «Өч йөз илле ел изгән самодержавие татарларны шулкадәр зәгыйфьләткән, аларны шулкадәр кешелектән чыгарган ки, аларда үзләренә ышану беткән. Алар үзләренең хәлләренең начарлыкларын бик яхшы белсәләр дә, үзләренең шул начар хәлләреннән чыгуның имкяны барлыгына һич ышанычлары юкка алар хәзерге хөррият хәрәкәтләренә дә «яхшы эш инде, әмма файда гына чыкмый» [1: 4]. Автор татар милләтенең менталь сыйфатларын Казан ханлыгы басып алынып, мөстәкыйльлеген югалтканнан соң, халык кичергән фаҗигале тарихка нисбәтле аңлата.

Исхакый гади рус халкының үз азатлыгы өчен алып барган көрәшен мисалга китереп, алар үрнәгендә татарларны активлашырга чакыра. Золымның рус халкы түгел, ә самодержавие тарафыннан эшләнүен әйтеп, ул рус халкына ышаныч уятырга тырыша һәм рус халкы белән берләшеп, хакимияткә каршы тартышка чакыра. Шулай итеп, Россиядә беренче революция елларында Г. Исхакый һәм аның «таңчы» фикердәшләре, монархияне һәм аның империядәге социаль таянычын юк итми торып, барлык милләтләрнең азатлыгына һәм демократиягә башка юл күрмиләр. «Аларның сәяси көрәшенең лейтмотивы, сәяси программаларының үзәге буларак, социаль тигезлек һәм гомумгражданлык сәяси ирекләре лозунгы ташлана» [7: 179].

«Таңчы»лык чоры публицистикасында әдип сыйнфый көрәш юлы белән генә иҗтимагый гаделлеккә, милли тигезлеккә һәм татар тормышын яхшыртуга ирешеп була дигән караш тора һәм аны үз язмаларында кат-кат ассызыклый. Инкыйлаб чорындагы «Чуалулар көчәйгәннән-көчәя» (1906) мәкаләсендә сыйнфый көрәш мәсьәләсендә социалистларның дөрес позициядә торуы

дәлилләнә: «Без – социалистлар – боларны әллә кайчан белгәнгә, без әллә кайчаннан бирле революциясез халыкның тормышы, революциясез халык йир һәм ирек ала алмый, революциясез беркем дә үз-үзенә хуҗа була алмый, дип кычкыра идек вә, шул революциягә генә ышанганга, халыкны шул золым, шул караңгылык, шул ачлыктан коткарыр өчен, Русиядә тынычлык, рәхәт, иркенлек мәйданга чыксын өчен, революциягә чакыра идек. Бу көнге көндә безнең фикеремезнең дөрестлеге беленде. Халык, үз хакларын алыр өчен, үзе революция юлына керде» [1: 43].

«Мәктәп-мәдрәсәләләр» (1906), «Оренбургтагы Хөсәеновлар мәдрәсәсе» (1906). «Хөсәеновлар мәдрәсәсе» (1906) һ.б. мәкаләләрендә Исхакый милли мәгариф, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту программалары, төрле катлау балаларына белем алу мөмкинлекләре булдыру мәсьәләләрен күтәреп чыга. «Мәктәп-мәдрәсәләләр» (1906) мәкаләсендә автор уку-укыту эшләре мәсьәләсен иҗтимагый-милли яссылыкта карый, ягъни уку-гыйлемне халык тормышын яхшырту чарасы буларак бәяли: «Уку-укыту эшләре бик зур мәсьәлә булганга һәм дә укуның халыкның тормышының яхшылануына дә зур ярдәм булганга, без, социалистлар, халыкның һәрьяктан рәхәтен, тынычлыгын, байлыгын теләүчеләр, уку эшенә, табигый, бик зур әһәмият бирәмез, табигый, укыту мәсьәләсен фәкыйрь халыкка файдалы иттереп ясамакчы буламыз» [1: 43].

Исхакый Россия күләмендә татар уку-укыту системасына реформа ясау ягында тора һәм аның программасы бүген дә актуаль яңгырый. Ул татар балаларына түләүсез мәҗбүри белем алу мөмкинлеге тудыруны бик кыю рәвештә яклап чыгып, дәүләт хисабына укыту, мохтаҗларга социаль ярдәм оештыру проблемаларын көн тәртибенә куя: «Безнеңчә, уку һәркемгә мәҗбүри булырга тиеш һәм дә уку-укыту казна хисабыннан тотылырга тиеш. Уку яшьләрендә балалар, укымаенча надан калмасын өчен, заводлар, фабрикалар вә башка эшләргә алынмаска тиеш. Фәкыйрь балаларга уку-язу кирәкләре һәм өст-башлары, ашау-эчүләре казна хисабыннан булырга тиеш» [1: 59].

Билгеле булганча, Г. Исхакый, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта башлый. Бертуган Хөсәеновлар тарафыннан төзелгән «Хөсәения» мәдрәсәсе ул вакытта татарның алдынгы уку йортларыннан саналган. Ул анда киеренке мөгаллимлек эше белән бергә, мәдрәсәнең җәмәгать тормышында актив катнаша. Андагы ашханәдә, йокы бүлмәләрендә тәртип урнаштыра. Шәкертләрнең аң-белемен арттыру максатында, яңа фәннәр укытуны кертә, атна саен әдәби кичәләр үткәрә.

Туры сүзле һәм яңалыкка омтылучы яңа мөгаллимнәре йогынтысында шәкертләр дә мәдрәсәдәге хәлләргә аеграк карый башлыйлар, чын дөресен сөйләргә өйрәнәләр. Уку-укыту программаларын үзгәртү, белем бирү дәрәҗәсен күтәрү, шәкертләрнең яшәү шартларын яхшырту һ.б. проблемаларны күтәргән Исхакый мәдрәсә җитәкчелегендә яклау тапмый һәм аннан китәргә мәҗбүр була. «Мәдрәсәдәге күнегелгән тәртип буенча үз җайларына гына яшәргә күнеккән мөгаллимнәргә Исхакыйның мәдрәсә тормышын болай болгатып җибәрүе, аларның тынычлыгын алуы ошамый, әлбәттә. Һәм алар үзе дә тынгысыз, башкаларга да тынгылык бирмәгән бу «ала карга» мөгаллимнән тизрәк котылу ягын карыйлар. Һәм бераздан Гаяз мәдрәсәдән чыгарыла, кабат эшсез кала» [3: 27].

Г. Исхакыйның бу тема гәүдәләнгән мәкаләләрендә мәдрәсә мөгаллимнәренең белем дәрәҗәсе проблемасы да яктыртыла. «Мәктәп-мәдрәсәләр» (1906) язмасында автор, үз стиленә туры калып, уку йортына гомуми бәя бирүдән башлый: «Хөсәенов мәдрәсәсе – безнең татар мәдрәсәләре арасында тышкы низам вә интизам җәһәтеннән беренче мәдрәсәдер. Анда, шәкертләр парталарда утырган кебек, мөгаллимнәр дә вазифалар алып укыталар. Дөрес,

программаларына караганда, бик күп фәннәр укыла. Ләкин 15 еллык дәвамында бу мәдрәсә халкымыз өчен бик аз хезмәт итте, халкымызның авыруына бик аз ярдәм итте» [1: 59]. Һәм аның сәбәпләрен мөгаллим исемен күтәргән шәхесләрнең белем дәрәҗәсе түбән булу белән китереп бәйли: «Шәкертләрнең белүләре мөгаллимнәр аша һәм китап уку аша буладыр. Мондагы мөгаллимнәр шәкертләргә кирәкле нәрсәләрдән, кеше булыр өчен тиешле фәннәрдән шәкертләрнең үзләре кадәр дә белмиләр» [1: 59]. Мәкалә авторы бу ноктада гына калмыйча, аны яхшырту юллары һәм чаралары хакында уйлана. Исхакый түбән белемле мөгаллимнәрне эштән җибәреп, укымышлы һәм зыялы укытучылар алу юлын тәкъдим итә: «Мәдрәсәне яхшыртыр өчен иң радикальный, иң тугры юл – шул надан мөгаллим вә мөдәррисләрне чыгарып, мәдрәсә тәрбия кылуны белә торган, укыган, белгән, мөгаллимлекне филхакыйкать ярата торган мөгаллимнәр куюдыр» [1: 65]. Шәкертләргә мөнәсәбәтне яхшырту, дөньяви фәннәр укыту, китапханәләр ачу, рус китаплары, газет-журналлар укуда иркенлек булдыру да бу масксатны якынайту чаралары буларак ассызыклана.

Г. Исхакый публицистикасында татар матбугаты, сүз иреге, аерым газеталарның иҗтимагый-сәяси мәсләге мәсьәләләре дә гәүдәләнеш ала. Бу проблемаларга да ул революцион-сыйнфый позициядән якын килә. Беренче мәртәбә ул 1905 елда ике генә саны чыгып калган «Хөррият» газетасы битләрендә чагылып кала.Ул «татарлар арасында сәяси фикерләрне таратыр өчен вә аларны революциягә хәзерләр өчен махсус татарлар арасында гына хезмәт» [4: 47] итәчәк «Хөррият» җәмгыятенең органы буларак оештырыла. Ә инде Гали Путиляков наширлегендә чыккан «Таң йолдызы» газетасында бу мәсләк тагын да ныгытыла. Татар социалист-революционерлары органы булган бу газета, табигый ки, шушы иҗтимагый кавемнең карашларын чагылдыра. «Сүз монда заман тормышын сыйнфый позициядән торып бәяләү һәм аны бары революцион юл белән генә үзгәртү мөмкинлегенә инану турында бара» [3: 37].

Г. Исхакый матбугат битләрендә үзенең иҗтимагый һәм сәяси омтылышларын чагылдыра. Алар газетаның программасында ачык чагыла: «Мондый куркыныч, чуалчык вә бик мөһим бер вакытта без дә эшче һәм үзе эшләп көн күрә торган авыл халкының файда вә сәгадәтләрен күзәтеп, <...> без эшче һәм авыл халыкларына караңгы төндә, кара урманда таң йолдызы булмакчы буламыз. Гәзитәмезнең авыл халкы өчен лозунгысы «Бөтен йир, бөтен ирек»тер. <...> сәяси вә экономный праволарыңызны алырга теләгән һәр кеше «Таң йолдызы» мәркәзенә җыелып берләшеңез дә берләшеп тырышыңыз, чөнки тартышуда гына табарсыз сез үзеңезнең хакыңызны» [1: 343].

«Эшчеләр мәсьәләсе (Үткән номерымызда...)» (1906), «Эшчеләр мәсьәләсе (Шул көннәрдә Алафузов...)» (1906) мәкаләләрендә газета программасында әйтелгәнчә, авыл халкы һәм эшчеләр мәнфәгатьләре яктыртылып калмыйча, өстәмә табыш, капитал туплануның асылы ачыла. 1906 елларда Идел буенда көчле ачлык булу сәбәпле, авыл халкы тамагын туйдырыр өчен шәһәргә килеп тулып, очсыз эш куллары сафын арттыра. Завод һәм фабрика хуҗалары, мондый форсаттан файдаланып, үз байлыкларын арттырып калырга тырышалар. Алафузов заводында эшчеләрне кыскартып, ярты хакка гына алар урынына авылдан килүчеләрне алалар, нәтиҗәдә эшчеләр урамга чыгарылып, ач калу куркынычы астына куелалар [1: 91].

Исхакый мондый хәлдән чыгу юллары хакында да уйлана һәм бүген дә актуаль булган фикерләр белән чыгыш ясый. Мәсәлән, ул налогларны зурлыгы, крестьяннарга җир бирү, социаль иүзгә каршы көрәшү, капитал алдында тез чүгү һ. б. «Шуның өчен иң әүвәл авыл халкын, эшчеләрне андый зур налоглардан коткарып, бөтен Россиядәге налогларны файдага гына салдырырга

тиештер. Икенче, авыл халкына бөтен йирләрне биреп, аны андый-мондый вак-төяк ачлыкларда ул кадәр фәкыйрьләнүдән алып калырга кирәктер» [1: 92]. Шул рәвешле автор тарафыннан социалистларның шушы юнәлештә хәрәкәт итәргә тиешлеге раслана. Икенче мәкаләдә эшчеләрне кыскарту аша завод-фабрика хуҗаларының капитал туплаулары ассызыкланып, «капитал берлән көчнең (труд)» тартышуы хакында нәтиҗә ясала. Моны булдырмас өчен, Исхакый эшчеләрне, тупланып, бердәм хәрәкәт итәргә чакыра.

Күзәтүләр Г. Исхакыйның XX гасыр башы татар публицистикасын тематик яктан баетуын, жанр ягыннан төрлеләндерүен күрсәтә. Аның 1917 елга кадәрге публицистик мирасында аерым бер баскыч булып аерылып торган 1905–1910 еллар эшчәнлеге инкыйлаби һәм сыйнфый көрәш идеяләре калку гәүдәләнү белән характерлана. Иҗтимагый гаделлек, милли тигезлек һәм азатлык, татарлар һәм инкыйлаби хәрәкәт, революцион вакыйгаларда көрәш тактикасы проблемалары Россия иҗтимагый-сәяси контекстында ячтыртыла. Моннан тыш ул, татар җәмгыятенең, милли яшәебезнең, милли мәгариф, матбугат, милли тел, тарих, диннең бүген дә актуальлеген югалтмаган мөһим проблемаларына җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтеп, үз мөнәсбәтен белдерә. Эзләнүләр Г. Исхакый публицистик мирасының киң колачлы һәм масштаблы өлкә булуын күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ


1. Исхакый. Г. Әсәрләр: 15 томда. 6 том: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 447 б.

2. Миннегулов Х. Литературно-публицистическая деятельность Гаяза Исхаки в эмиграции (1919–1954) // Записи разных лет (татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казан: Идел-Пресс, 2010. С. 240–247.

3. Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 189 б.

4. Низамов И. Хөррият (Татар матбугатының онытылган бер сәхифәсе) // Мирас. 1994. № 10. Б. 46–48.

5. Нуруллин И.З. Гаяз Исхакый (Әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача бер күзәтү) // Исхакый Г. Зиндан: сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 5–18.

6. Хәсәнов М.Х. Татар Ренессансының бөек каһарманы // Гаяз Исхакый. Әсәрләр: 15 томда. 1 том: Повестьлар, хикәяләр (1899–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 5–30.

7. Зарипов М., Әмирханов Р. Гаяз Исхакый // Татар зыялылары: тарихи штрихлар: укытучылар һәм югары сыйныф укучылары өчен мәкаләләр җыентыгы / төз. Р. Мөхәммәтшин; русчадан Ә.М. Камалов тәрҗ. Казан: Мәгариф, 2003. Б. 175–182.

8. Gilazov T.Sh, Karabulatova I.S., Sayfulina F.S., Kurakova Ch.M. and Talipova G.M. Between the East and the West: Phenomenon of Tartar Literary Criticism in the Lingvo-Cultural Aspect // Mediterranean Journal of Social Science. 2015. Vol 6, No 3, S2, May 2015. P. 508–517. Doi:10.5901/mjss.2015.v6n3s2p508.


## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕН АНАЛИЗЛАУДА КАРТОГРАММА ТӨЗҮ АЛЫМЫН ФАЙДАЛАНУ


***Гыйлаҗева А.Ф.*** *(Арча)*



Г. Исхаки деятель татарского национального движения, писатель, публицист, издатель и политик. С целью изучения жизни и творчества, сохранение и пропаганды наследия Гаяза Исхаки, мы на уроках татарской литературы использовали метод составления картограммы. Метод составления картограмм на уроках литературы – это инновационный подход в организации деятельности учащихся при изучении художественных произведений. Важно отметить, что структура такого занятия выстроена в режиме саморазвития обучаемого, что позволяет развивать как его исследовательские, так и творческие способности. Все это позволяет ребятам лучше усваивать учебный материал, проявлять творческую активность и самостоятельность при изучении художественных произведений на уроках литературы.

**Ключевые слова:** метод составления картограммы, входные данные, читатель, выходные данные, ассоциации, функции произведения.

G. Ishaki is an activist of the tatar national movement, writer, publicist, publisher and politician. In order to study life and work, to preserve and promote the heritage of Gayaz Ishaki, we used the method of drawing up a cartogram in the lessons of tatar literature. The method of drawing up cartograms in literature lessons is an innovative approach in the organization of students ' activities in the study of works of art. It is important to note that the structure of this lesson is built in the mode of self-development of the student, which allows to develop both his research and creative abilities. All this allows children to better assimilate the educational material, to show creative activity and independence in the study of works of art in literature lessons.

**Key words:** method of compiling cartograms, the input reader, the output of the Association function works.

Гаяз Исхакый – татарның сирәк очрый торган бөек таланты, милли әдәбиятның классигы һәм горурлыгы.Ул татар дөньясында Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Курсави һәм Габдулла Тукай, Фатих Әмирханнар, Галимҗан Ибраһимовлар белән бергә, татар халкын, аның милли-мәдәни рухиятен яңа баскычка күтәргән, олы талант, ә аның әдәби мирасы – халыкның милли хәзинәсе, рухи байлыгы.

Г. Исхакый – иҗатының башлангыч чорыннан ук, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен үзәккә куеп яктыртып килгән язучы. Ул, гомумкешелек проблемаларын хатын-кызның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге ролен кутәреп, чын гуманистларча сурәтләгән. Халыкның рухи тормышының нигезендә яткан гаилә корылышын, хатын-кыз азатлыгы, мәгърифәтле һәм алдынгы карашлы булу, байлыктан дөрес файдалану кебек мәсьәләләрне яңа фикри бөеклектә хәл иткән.

Татар әдәбияты дәресләрендә Г. Исхакыйның тормыш һәм иҗат юлын яшь буынга өйрәтү һәм пропагандалауда яңа алымнар эзләү бурычы куелды. Шул максаттан, без укучылар белән Г. Исхакыйның әсәрләре буенча картограммалар төзү алымын файдаландык.

Әдәбият дәресләрендә картограмма төзү – матур әдәбият әсәрләрен өйрәнгәндә укучылар эшчәнлеген билгеләүдә инновацион алым булып тора. Шунысын билгеләп үтү мөһим: мондый структуралы дәресләрдә укучыларда эзләнү сәләте белән бергә иҗади сәләт тә үстерелә. Тәкъдим ителгән материал барлык кешегә дә аңлашыла торган формада языла, өстәмә рәвештә иллюстрацияләр дә китерергә мөмкин. Болар барысы да укучыларда әдәбият дәресләрендә иҗади активлык һәм мөстәкыйльлек тәрбияли, Г. Исхакый иҗатына кызыксыну уята, әдәби әсәр төрле күзлектән чыгып анализлана.Яңа материалны, ягъни әдәби әсәрне тирәнтен аңларга ярдәм итә.

Әдәбият дәресләрендә картограмма төзү методының максаты: әдәби әсәрнеңербөтен система итеп карау.

Бурычлары:

1. Конкрет әдәби әсәргә картограмма шаблоны әзерләү;

2. Төп дәрәҗәләрне аеру (әсәр турында мәгълүматлар, әсәрдән чыга торган мәгълүматлар).

3. Картограмманың модулен ясау (биредә төп вакыйгалар, геройларның монологы һәм диалогы, ачкыч сүзләр, детальләр һ.б. чагылыш табачак)

4. Укучыга тәэсир итүче төп функцияләрне ачыклау.

5. Әдәбият дәресләрендә әлеге методны кулланунның әһәмиятен формалаштыру.

Әдәбият дәресләрендә без Г. Исхакыйның «Остазбикә» әсәренә картограмма төзедек. Картограмма төзү безгә әсәрне автор позициясе, төп геройлар, укучы күзлегеннән чыгып анализларга мөмкинлек бирә. Картограмма төзегәндә,

проблемалы сораулар һәм ситуацияләр куела, ачкыч образлар һәм детальләр билгеләнә. Әсәргә картограмма төзегәч, әсәр безгә уч төбендәге кебек ачыла.

«Остазбикә» әсәре буенча төзелгән картограммага тукталып китик. Г. Исхакыйның «Остазбикә» картограммасын төзү барышында, иң беренче эш итеп, әсәр турында мәгълүмат китерелә: басылу тарихы, жанры, темасы, геройлар, хронотоп. «Остазбикә» әсәре беренче тапкыр Мәскәүдә «М.О. Аттой и Ко» типографиясендә басылып чыга. Тышлыкта язылу вакыты «28 декабрь [1914] – 24 нче гыйнвар, 1915 сәнә, Мәскәү» дип күрсәтелгән. Жанры – повесть, 13 бүлектән тора. Тема: Сәгыйдә белән Вахидның 12 ел бәхетле тормыш кичерүләре, ләкин балалары булмау сәбәпле Сәгыйдәнең үзен корбан итеп, үз өстенә көндәш алуы тасвирлана. Геройлар: Сәгыйдә-остазбикә, Вахид мулла; Сәгыйдәнең әти-әнисе, Хәйретдин мулла, Шакир мәэзин, Рәхим мулла һәм аның хатыны, Галимә, Үлмәс абыстай, Сәгыйдәнең тутасы, Әхмәт, Вагыйз, Зөлфия абыстай, мәхәллә халкы, кыз балалар, ир балалар. Хронотоп: Сәгыйдәләр өендә, Вахид мулла авылында, Сәгыйдәләр өендә, Рәхим мулла өендә, Сәгыйдә белән мулла өендә, Сәгыйдә белән Вахидның өендә, шәһәрдә (Казанда), өйләрендә, Зөлфия абыстайларда.

Алга таба әсәрдән чыга торган билгеләрне билгелибез: ИТД (идея-тематик дәрәҗә), СКД (сюжет-композиция дәрәҗәсе), АД (ассоциатив дәрәҗә), РИД (ритмик-интонацион дәрәҗә) дәрәҗәләрне билгелибез. Мисаллар карап китик: идея-тематик дәрәҗәгә әсәрдән мондый юлларны керттек: *«Абзый кеше! Шунысын әйтәм: берүк ул йортка килен булып чыдар өчен кызыңыз шәйтан тиресе киеп килсен!»* Сюжет-композиция дәрәҗәсенә Сәгыйдәнең каенанасын күреп күңеле төшүе, гаҗизләнүе, үзенең балачак тормышы, каенана-каенаталары белән ничек яшәрмен дип уйланулары һ.б. керттек. Ассоциатив дәрәҗәгә геройларның охшашлыгын һәм каршылыгын билгеләдек. Сәгыйдә белән Вахидның охшашлыгы, Сәгыйдә белән Галимәнең охшашлыгы һәм каршылыгы һ.б.

Картограмма эшләгәндә, иң кызыгы тексттан ачкыч сүзләрне, ачкыч фразаларны, символларны, текст эчендәге ассоциацияләрне билгеләү булды. Ачкыч сүзләр: *әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, көндәш, остазбикә.* Ачкыч фразалар: *беткән баш беткән, бик матур төш күрдем, бәхетемне ким кылма, ирнең үгие юк, хатынның үгие бар, баласыз тормыш – хәят түгел ул, алла бирмәде дә бирмәде, әй угылым булса иде!..*

Символлардан төш (юраучы), кояш (җылытучы, яктылык символы), мөселман тормышы символлары (Коръән, бөти, намазлык, ястү, ахшам, мәдрәсә, ясин, кыйраәт, гошер, гарәфә көне, кыямәт көне һ.б.), авыл тормышы символлары (чебешләр, тавыклар, чуар бозау, яңа салам исе), татар тормышы символлары (коймак, пәрәмәч, сумса, кабак исе, шалкан исе, яңа икмәк, катлама исе), ярык (татар тормышы символы).

Текст эчендәге ассоциация: авылы – кара як, капка – актык өмет, каенанасы – убыр карчыгы, Сәгыйдә – асрау, Галимә – җария, канизәк. Текст тышындагы ассоциация З. Биишева «Кимсетелгәннәр», Г. Исхакый «Мөгаллимә», М. Галәү «Мөһаҗирләр», М. Акъегет «Хисаметдин менла», Г. Исхакый «Өч хатын белән тормыш».

Әсәр укучыга ничек тәэсир итә, нинди функцияләр үти – без бу сорауларга да җавап табырга тырыштык. «Остазбикә» повесте – прогнозлау, танып белү, агарту, хакыйкатьне эзләү функцияләрен үти. Укучылар белән шулай ук төп геройлар булган Сәгыйдә белән Вахид образларын ача торган сыйфатлар уйлап яздык. Шулай итеп, Сәгыйдә образына *остазбикә, ирен бик ярата, эшчән, табигате йомшак, баласыз, «ахмак», бакышы – падишаһлар бакышы, йөре-*

*ше – баһадирлар йөреше, карт мулланың кадерле кызы, кызлар укыта, көндәш, асрау* дигән сыйфатлар уйлап яздык. Вахидка – *Сәгыйдәне бик ярата, үткен генә кара күзле, җиңел генә кыяфәтле, саф тавышлы, хәзрәт, мулла, Казан шәкерте* дигән сыйфатлар китердек.

Текст эченнән һәм текст тышыннан чыккан мәгълүматлар нигезендә, иң соңыннан нәтиҗә ясала. Нәтиҗә: Г. Исхакыйның «Остазбикә» әсәренең жанры – повесть. Безнең картограммада ал төс – хакыйкатьне эзләү функциясе өстенлек алды. Чыннан да, автор монда бик авыр сорау куя. Сәгыйдә белән Вахид бер-берсен үлеп яраталар. Ләкин унике ел бергә бәхетле торуларына карамастан, аларның балалары юк. Һәм менә монда Сәгыйдә алдына сорау килеп баса. Нишләргә? Үзеңне бәхетсез итеп көндәш алып, балалы булыргамы, әллә инде ире белән икәү, ләкин баласыз гомер кичерергәме? Менә шул сорауны Сәгыйдә чишә. Үзен корбан итеп, бәхетле тормышына киртә куеп, үз өстенә көндәш ала. Ул әсәр буе хакыйкать эзли. Ахырдан инде «баласыз тормыш – хәят түгел ул» дигән фикергә килә.

«Остазбикә» повестенда Гаяз Исхакый шәхеснең эчке дөньясын тагын да тирәнрәк итеп ачарга омтылып яза. Повестьта остазбикәнең бала булмаудан өзгәләнүләре, башка хатыннан туачак балаларны тәрбияләүгә әзер торуы, яраткан иренә үз укучысы Галимәне димләве, аның шул вакыйгаларга хәзерлек барганда туган каршылыклы кичерешләре, үзе сайлаган язмыш фаҗигасен күтәрергә көч табуы шундый итеп бирелә ки, Сәгыйдәне илаһи образ буларак кабул итмәү мөмкин түгел. Ләкин шунысын да әйтергә кирәк: минемчә, әсәрдәге иң бәхетсез герой – Галимә. Иң бәхетсез язмыш – Галимә язмышы. Гаяз Исхакый үзе дә әйтә: «Ул шунда канизәкме, җарияме шунда», – ди.

Эшебезне йомгаклап шуны әйтәсе килә: әдипнең әсәрләре буенча картограмма төзү укучыларга бик ошады. Балалар эзләнделәр, кайберләренең иҗади ягы да ачыкланды, Г. Исхакый әсәрләренә кызыксыну артты. Картограммаларны без плакат формасында, төрле төсләр кулланып, әсәр эченнән сүзләр, фразаларны, символларны алып яздык. Картограмманы шулай ук презентация формасында да эшләргә була. Иң мөһиме: укучылар үзләре Г. Исхакый әсәрләре тәрбияви яктан да, психологик яктан да бик әһәмиятле икән дип, нәтиҗә ясадылар.

ӘДӘБИЯТ

1. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

2. Хәсәнов М.Х., Зәкиев М.З. Гайнанова Л.Р., Әхмәдуллин А.Г., Әюпов Х.Г. Гаяз Исхакый. Әсәрләр: 15 томда. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр. 2003. 496 б.

## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИК СИНОНИМИЯ

***Э.Н. Денмөхәммәтова*** *(Казан)*

В статье рассматриваются особенности умелого использования фразеологических единиц в своих произведениях Г. Исхаки. Исследуются устойчивые выражения на предмет синонимичности между словом и фразеологизмом, между разно компонентными фразеологизмами и фразеологическая вариативность. Приводятся интересные примеры из произведений Г. Исхаки, где через авторские устойчивые выражения передается тонкость татарского языка. Работа выполнена в сравнительном аспекте. Примеры из произведений Г. Исхаки анализируются в сравнении с современным татарским литературным языком. Работа актуальна для исследователей в области фразеологии, лексикологии и синонимии не только татарского языка, но и остальных тюркских языков.

**Ключевые слова:** синонимия, фразеология, татарский язык, Г. Исхаки, вариативность, мастерство автора.

The article deals with the peculiarities of skilful use of phraseological units in his works by G. Ishaki. Researched expressions on the subject of synonymical between word and idiom between the different component phraseological units and phraseological variation. Points out interesting examples from the works of G. Ishaki, where in a more stable expression is passed to the subtlety of the Tatar language. The work is performed in a comparative aspect. Examples of G. Ishaki's works are analyzed in comparison with the modern Tatar literary language. The work is relevant for researchers in the field of phraseology, lexicology and synonymy of not only the Tatar language, but also the rest of the Turkic languages.
**Key words:** synonymy, phraseology, Tatar language, G. Ishaki, variability, mastery of the author.

Г. Исхакый – татар халкының бөек улы, язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче буларак танылган бөек шәхес. Аның күпкырлы эшчәнлеге һәм әдәби мирасы туган илендә бик соң бәяләнә башласа да, тиз арада популярлык казанды. Фикер үткенлеге, батырлыгы, халкын яратуын әдип күпсанлы чәчмә һәм сәхнә әсәрләрендә, публицистик язмаларында һәрдаим дәлилләп килә. Аны татар милләте, татар халкы, ил һәм тел азатлыгы, халык язмышы һ.б. шундый чиксез күп, әмма беренче карашка бик гади булып күренгән, асылда киләчәкне, яшәеше тәэмин иткән сораулар бочый. Әдип алар турында уйлана, әсәрләре аша уйлары белән бүлешә, чишелеш юлларын эзли.

Г. Исхакый, тирә-якта абруйлы мулла нәселе вәкиле, укымышлы, чын интеллигент шәхес буларак, чит телләр өйрәнү белән беррәттән, туган телен – татар телен камил белә, аны зурлый, хөрмәтли. Үзенең язма һәм телдән сөйләмендә (моны соңгы елларда Россиягә кайтып ирешкән әдипнең аудиоязмада сакланып калган тере тавышы дәлилли) телнең һәр берәмлеген яратып, ихтирам белән һәр нечкәлекләрен белеп файдалана. Г. Исхакый гомеренең яртысын чит илләрдә үткәрсә дә, татар теленә гомере буе тугрылыклы калып, туган телендә иҗат итә.

Г. Исхакый мирасы туган илгә әйләнеп кайтканнан соң, аның белән кызыксынучылар, әдипнең тормыш юлын һәм әсәрләрен, публицистик эшчәнлеген фәнни яктан өйрәнүчеләр күп булды. Совет чорында «кара исемлеккә эләгеп», әсәрләре тыелып, исеме онытгырылган әдип 90 нчы елларда кабат туган иленә «кайтты». И. Нуруллин, Х. Мәхмүтов, А. Әхмәдуллин, Л. Гайнанова, Ә. Кәримуллин, М. Хәсәнов, Ф. Мусин, Ә. Сәхәпов, Р. Ганиева, Х. Миннегулов, Т. Галиуллин, В. Хаков, Ф. Сафиуллина, И. Бәширова, Г. Гобәйдуллина, З. Рәмиев, Г. Зиннәтуллина, А. Кәримова, Г. Шакирова һ.б. галимнәрнең монографияләре, фәнни мәкаләләре, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре аша Г. Исхакый татар халкына таныла башлады. Әсәрләре яратылып укылып кына калмыйча, анализландылар һәм бүгенге көндә дә фәнни тикшеренү объекты булуларын дәвам итәләр. Әдипнең язу теле, стиле нәкъ менә әсәрнең асылын кабул итәргә, әсәр эченә кереп китеп, үзеңнең дә әлеге вакыйгалар үзәгендә катнашуыңны тою мөмкинлеген ача. Һәр язучы стилен аның үзенә генә хас булган сурәтләү чаралары билгели, шунлыктан әдипләр төрле очракта төрле чаралар кулланалар. Укучыга эмоциональ-экспрессив яктан тәэсир итәргә теләп, образлылыкны көчәйтү нисбәтеннән, мәсәлән, фразеологизмнар кулланылырга мөмкин.

Г. Исхакыйның татар телен яхшы белүен аның халык телендәге тотрыклы сүзтезмәләрне оста файлануы да дәлилли. Шуны әйтергә кирәк: фразеологизмнарны һәр автор үзенчә куллана: гомуми сөйләм телендәгеләреннән үзгәреш файдаланырга да, стилистик төсмерен үзгәртеп, башка мәгънәдә кулланылырга мөмкин. Тотрыклы сүзтезмәләрне төрлечә үзгәртү, аларның санын-исәбен арттыра, фразеологик синонимлыкка да китерә.

Мәгълүм булганча, фразеологизм һәм аны белдергән сүз арасында уртак мәгънә булудан тыш, тотрыклы тезмәләр үзара да синонимик рәт хасил итәләр.

Ә синонимлык исә тел байлыгын чагылдыра торган иң мөһим күренеш булып исәпләнә. Мәгънәдәш сүзләрне куллану нәтиҗәсендә фикер төгәл җиткерелә, сөйләм матур яңгырашлы, күренеш-төшенчәләр һәм аларның билгеләре төрле-төрле мәгънә төсмерләре һәм стилистик бизәкләр белән аңлатылып, тасвирлану мөмкинлегенә ия булалар.

Г. Исхакыйның көчле образлылык, экспрессивлыкка ия булган, психологизм белән сугарылган әсәрләрендә фрезеологик гыйбарәләр еш күзәтелә. Бу тотрыклы берәмлекләр үз чиратында синонимик рәтләр хасил итәләр. Шунлыктан, Г. Исхакый әсәрләрендә урын алган фразеологик синонимия күренешен тикшерү әлеге хезмәтнең максатын билгели. Аңа ирешү өчен, әдипнең әдәби әсәрләрендә семантик, стилистик, семантик-стилистик һәм абсолют синонимнарны күзәтү; фразеологизмнар үзара синоним булган очракларны тикшерү; синонимик вариантлылык тудырган берәмлекләрне ачыклау бурычы куела.

Г. Исхакый әсәрләре ттеленең индивидуаль фразеологик формаларын өйрәнү, аларны гомумхалык чаралары белән чагыштырып, әлеге ике төркемнең үзара йогынтысын ачыклау әдип теленең уникаль һәм универсаль сыйфатларын билгеләргә ярдәм итә.

Эш барышында лингвистик метод һәм алымнар комплекслы рәвештә файдаланылды: тасвирлау, чагыштыру, функциональ-стилистик, структур, статистик метод һәм алымнар кулланылды.

Г. Исхакыйның тотрыклы гыйбарәләрдән оста файдалана белүе – отышлы һәм уңышлы ягы. Фразеологик әйтелмәләр язучыга геройның портретын тасвирлауда, эчке дөньясын ачуда, вакыйга-күренешләрне чагылдырырга ярдәм итә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә. Үз әсәрләрендә әдәби телдә дә мәгънәдәш сүзләр буларак йөргән берәмлекләрдән иркен файдалана. Мәсәлән, *тормыш кору* (С.б.) – *төпләнеп калу* (О.) – *тамыр җибәрү; җен чыгу* (Т.г.) – *ачу кабар* (Т. г.) – *ачу килү* (М.җ.); *җан асрау* – *көн күрү* (О.) – *очны-очка ялгау* (Т.б.) һ.б.

Мәсәлән, *«Анда барганда муллаларның өе яныннан үтеп, йорт-җирләрен, тормыш-килешләрен өстеннән генә* ***күздән үткәрде»*** [3: 275]. *«Түбән очтагы ат сатарга тели торган яшь егет тә мөәзин абзыйны* ***күзе аша уздырып****, бик тиз танып алды»* [3: 275];

*«Мин аның* ***тасма телен*** *яратмыйм, алла сакласын, Галиягә әлләниләр сөйләр»* [3: 387]. *«Шуның анасын яратмадым, үзен яратмыйм,* ***татлы телен*** *яратмыйм»* [3: 387].

Г. Исхакый әсәрләрендә семантик-стилистик синонимнар төренә караган, фикергә эмоциональлек бирү өчен кулланылган мәгънәдәш сүзләр дә шактый очрый. Мәсәлән, ***баш әйләнү*** фразеологизмы (үзеңне) *начар хис итү* мәгънәсендә килергә мөмкин. Шул ук вакытта бу тотрыклы гыйбарә әдәби стильдә ***ми кайнау*** берәмлеге белән синонимик мөнәсәбәттә дә була ала. Ул тәэсирлеге ягыннан көчлерәк һәм гади-көнкүреш стилена карый. Әлеге тотрыклы гыйбарәләр әдип әсәрләрендә түбәндәгечә урын алалар:

*«Ул көне-төне шул уй астында изелде,* ***башы әйләнде,*** *ләкин бәладән котылу юлын таба алмйча* ***миләре кайнады****, тормышының шул тулмаган ягыны тутырырга җай була алмады»* [3: 164].

*«Баш әйләнү»* һәм *«ми кайнату»* гыйбарәләре бер җөмлә эчендә кулланылып, автор фикеренең үсә бару дәрәҗәсен күрсәтәләр. Г. Исхакый шул рәвешле ситуациянең кискенлегенә басым ясый, хис-тойгының үсүен ассызыклый.

Фразеологизмнарда синонимия хасил итүнең бер төре буларак, **синонимик вариантлар** күренешен дә аерып чыгаралар. Фразеологизмнарда вариант дип структур үзгәрешкә очраган, ләкин семантик һәм стилистик яктан

бернинди дә аермасы булмаган сүзләре уртак фразеологик берәмлекләрне атыйлар. Фразеологик синонимнар фразеологик вариантлардан лексик составларының тулысынча яңартылулары, бер үк төшенчәнең төсмерләрен төрле образлар аша чагылдыру белән аерылалар [5: 85]. М. Мөхәммәдиев фикеренчә, «фразеологик вариантларның лексик составларындагы өлешчә үзгәреш аларның образлылык структурасына да, мәгънә, эмоциональ һәм стилистик төсмерләренә дә фразеологик синонимнардагы кебек ачык үзгәлек кертә алмый. Ләкин бу – фразеологик вариантларның стилистик кулланылыш сфералары тар, алар тулы канлы сурәтләү чаралары була алмыйлар дигән сүз түгел» [4: 180].

Телдәге вариантлык – тел үсешенең һәр чорына хас күренеш, телдә яңа лексик һәм фразеологик берәмлекләрнең туу, үсү һәм юкка чыгу процессларының чагылышы. Ул телдә я аерым фразеологик берәмлекләрнең синоним кулланудан вариантка күчүе һәм шуннан соң югалуы, яки, киресенчә, вариантның дифферениция нигезендә синонимлашуы, аннан аерым берәмлекләр туу кебек процессларның бер баскычы буларак яши.

Г. Исхакый әсәрләрендә түбәндәге синонимик вариантларны күрергә була: *зат исеме күтәрү* (З.) – *дан күтәрү* (З.); *күз сирпеп кую* (Б.б.) – *күз төшерү* (К.б.); *тап булу – тап килү – туры килү* (Б.б.); *ришвәт бирү – сыйлык бирү* (М.җ.) – *әҗер бирү* (О.); *коткы салу – коткы тарату* (М.җ.), *коры куык* (О.) – *җил куык* (Т.б.); *кот очу – кот чыгу – кот калмау* (Б.б.) – *котсыз калу* (О.) – *коты алыну* (М.җ.) һ.б.

Синонимик вариантларның структур яктан нинди үзгәреш кичерүенә бәйле рәвештә, Ш. Ханбикованың «Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр» хезмәтенә таянып, өч төркемдә карала алалар.

1. Компонентларның бәйләнеш формасында аерма булган фразеологизмнар.

*«– Әти, эш әйбәт туры килеп,* ***акча төшерә алсак****, миңа да кәләпүш алырбызмы? – дип сорап куйды» (*А.б.); *«Зариф үзенең алдагы эшләре: ничек итеп* ***акча төшерү****, атлы булу, алты почмаклап өй салдыру турында уйланып барды»* (М.җ.).

Әлеге ике җөмләдә ***«акча төшерә алу»*** һәм ***«акча төшерү»*** дигән фразеологизмнар кулланылган. Бу тотрыклы тезмәнең беренче компоненты ике очракта да баш килештә (эшнең туры объектын билгесезлек төсмере белән белдерү), икенче компонеты исә төрле формада: икенче җөмләдә синтетик исем фигыль формасында килсә, беренче җөмләдә шарт фигыль формасында һәм аналитик юл ярдәмендә мөмикинлек модальлеген белдереп килгән. Күрүебезчә, бер үк мәгънәне тәшкил иткән тотрыклы гыйбарәләр, бәйләнеш формасында аерма кичереп, үзара синонимик вариантлылык хасил итәләр.

Синонимик вариантларның әлеге төренә түбәндәге җөмләләр дә мисал булып тора:

*«****Олугъ башыңны кече итеп килүең*** *өчен аллаһы тәгалә җиде оҗмахының ишеген ачык кылсын!* (С.б.) – *«****Олугъ башың кече иткәнсең*** *икән, сәбәпләре зурдандыр, шәт»* (О.);

*«– Мулла абзый, болар белән* ***торыр хәл юк****. Иртәдән-кичкә кадәр эшлим, мулла абзый, йорт булсын дип эшлим, өстемә сорамыйм, алыштырырлык күлмәгем юк,* ***торырга хәлем юк, калмады****»* (С.б.).

2. **Факультатив компонент өстәлү яки кыскару юлы белән үзгәргән фразеологизмнар.** Бу төр вариантлылык нәкъ менә авторның тотрыклы тезмәне ничек кулланырга теләве һәм бу төр фразеологизмга тәэсир итү көче ягынан нинди вазыйфа йөкләве белән бәйле. Бу төрне рус галимнәре автор фразеологизмнары дип тә атыйлар. Мәсәлән:

*Хәер, һәрберсе үзенчә терекөмеш булып тәгәрәүче малайлар шәкертнең ул сүзләренә* ***колак та салмады*** (Ш.а.);

*Әйе, шәкертнең яңа хәбәренә малайлар, ичмасам,* ***колак читләрен дә салмадылар****, хәер ул үзе дә аптырап калмады* (Ш.а.).

Әлеге ике җөмләдәге фразеологизмнар нигезендә ***«колак та салмау»*** дигән тотрыклы тезмә ята. ***«Колак та салмау»***, аңлашылганча, *ишетергә теләмәү, игътибар итмәү* мәгънәсендә бирелгән. Икенче җөмләдәге ***«колак читләрен дә салмау»*** дигән синонимик вариант түбәндәге үзенчәлекләргә ия:

1) ***колак*** сүзенә ***чит*** сүзен өстәп, нindидер дәрәҗәдә беренче компонентның чиге билгеләнә һәм аның тартым һәм төшем килеш кушымчалары белән бирелүе гыйбарәне конкретлаштыра;

2) бу чикне төгәл билгеләү, үз чиратында, фразеологизмның образлылыгын көчәйтә, эмоциональ-экспрессив ягын арттыра.

Татар телендә әлеге ике тотрыклы берәмлекләрне эмоциональлек һәм кулланылыш даирәсе ягыннан чагыштырып үтик.

***«Колак та салмау»*** дигән фразеологизм безнең телебездә бик еш кулланыла, ягъни бик актив. Безнеңчә, күбесе инде аның тотрыклылыгына игътибар да итми, гади бер берәмлек буларак кына кабул итәләр.

***«Колак читләрен дә салмау»*** дигән фразеологизмы тел остасы тарафынан иҗат ителгән тотрыклы тезмә икәнлеге күренеп тора. Бу гыйбарәгә Г. Исхакый аерым мәгънә керткән, ягъни ишетмәүләренең ни дәрәҗәдә көчле булуын ассызыклап, образларны характерлаучы сыйфатны ачып бирә алган. Безнең карашка, бу фразеологизм ярдәмендә тел остасы эмоциональ-экспрессив яктан тәэсир итүгә ирешеп, укучыда тагын да күбрәк кызыксыну уята алган һәм автор фразеологизмы образлылыгы ягыннан көчлерәк һәм бик урынлы кулланылган.

Алдагы җөмләләр дә әлеге төргә мисал була ала:

*«Сорур ни булганын уйлап бетерә алмады, Зарифның кулы тию берлә аның теге, баягы* ***хисләре*** *аны* ***бөтенләй биләп алды****»* (М.ж.); *«Уйланмаган бу эшкә Зариф элгәре исе китсә дә, уйлап торырга вакыт юкка, шул* ***хисләр*** *аны да* ***биләп алганга****, ул да җавапсыз калмады»* (М.җ.).

3. **Бер компоненты мәгънә төсмере белән аерылмый торган синоним сүздән торган фразеологизмнар**, ягъни тотрыклы тезмәнең бер компоненты һәрвакыт бер үк калырга тиеш булган фразеологизмнар. Бу төр, гомумән, сөйләмә, әдәби телләрдә иң еш кулланыла торган фразеологизмнарны тәшкил итә. Мәсәлән, ***«күңел йомшару»*** һәм ***«күңел эрү»*** дигән фразеологизмнарның бары тик икенче компонентлары төрле, ә беренче өлеше тәңгәл килә. Түбәндәге мисаллар игътибарга лаек:

*Шушы хәлдә калуы аркасында бу дога, башка бөтен догалардан үзгәрәк булып, Сорурның* ***күңелен йомшарта****, елыйсын китерә иде* (М.ж.); *Гомумән, әлеге истәлеге белән бәйләнешле булган бөтен нәрсә аның* ***күңелен эретә*** *иде* (Т.б.).

народа в XX веке не только в России, но и за рубежом. Татарский литературовед Хатип Миннегулов, исследовавший в основном жизнь и творчество Г. Исхаки в эмиграции, изучив татарскую литературу и публицистику за рубежом, отметил, что во второй и третьей четверти прошлого столетия в Финляндии, Китае, Японии, Турции, Германии и во многих других странах периодическая печать и литература была напечатана в основном усилиями Гаяза Исхаки [3: 5]. Кроме того, как пишет ученый-востоковед Л. Усманова, известная исследованиями деятельности Гаяза Исхаки на Дальнем Востоке, он сыграл «выдающуюся роль в объединении тюрко-татарской эмиграции на Дальнем Востоке, в признании ее Японской империей, что намного облегчило жизнь эмигрантов и их адаптацию вдали от родины» [4: 354].

В Стамбуле в издательстве Boğaziçi Üniversity Press в 2001 году вышла монография японского тюрколога Акиры Матсунаги «Аяз Исхаки и тюрко-татары на Дальнем Востоке» на трех языках – турецком, английском и русском языках. Через три года в 2004 году данная монографию была переиздана в Баку в издательстве «Сабах» (редактор и переводчик Рехбер Бешироглу, 104 с.). Автор – тюрколог Акира Матсунага – родился в 1960 году в Токио и после окончания исторического факультета университета KEİO прошел специальный курс при Министерстве Иностранных дел Японии и в 1990–1994 годах работал советником по культуре, образованию и журналистике в посольстве в Анкаре. Защитив в 1995 году докторскую диссертацию по теме «Япония и тюркский мир», стал доктором исторических и филологически наук, профессором. А. Матсунага – автор нескольких монографий и более 100 научных и публицистических статей. В то же время он является директором программ Фонда Мира Сасакава по регионам Центральной Азии и Кавказа [6: 102].

Данная статья будет опираться на бакинское издание монографии, подаренной нам самим автором. В предисловии, написанной членом Национальной Академии наук Азербайджана, профессором Низами Джафаровым, говорится о том, что монография посвящена актуальной теме – периоду царской России и положению тюркологии на фоне молодой Советской власти, и преследует три цели: 1. Деятельность тюркологов на Дальнем Востоке-Японии в нач. XX века; 2. Первые научные труды по тюркологии в Японии; и 3. Зарождение основ тюркологии как науки. Азербайджанский ученый также отмечает, что Акира Матсунага, предоставляя информацию о деятельности и научном творчестве таких первых тюрков в Японии, как Мухаммед Абдулла Курбан Али, Юсуф Акчура, Аяз Исхаки и другие, серьезно изучил и японскую периодическую печать, научные журналы той эпохи и документы, хранящиеся в Министерстве Иностранных дел и архивах Японии [5: 3].

Во введении к монографии автором дается краткая информация истории поселения тюрков-татар в Японии. Так, А. Матсунага отмечает, что общины тюрков-татар, проживающих в Японии с 1953 года как турецкие граждане, «существовали в таких японских городах, как Токио, Нагойя, Кобе и Кумамото до 1950-х годов.» Однако на Дальнем Востоке больше нет турецко-татарских общин, они эмигрировали в Турцию, Австралию и Америку по различным причинам в 1950-х годах. Далее А. Матсунага высказывается о цели своей монографии – описать краткую историю тюрко-татарских общин и визит Гаяза Исхаки на Дальний Восток. К сведению, ученый дает имя и фамилию Гаяза Исхаки как «Аяз Исаки». После довольно подробной биографии и политической деятельности «известного активиста Идил-Уральских тюрко-татарских движений и турецкого националиста», А. Матсунага во введении останавливается и на его публицистическом и литературном творчестве, назвав Г. Исхаки «блестя-

щим журналистом, одаренным писателем и драматургом». Далее ученый дает общие сведения о его политической и публицистической деятельности после отъезда на чужбину и сожалеет, что Гаяз Исхаки «не был так же известен в Турции, как турецкий националист Юсуф Акчура» [6: 64–66]. А. Матсунага не забыл упомянуть и о том, что «после Горбачевской перестройки Исаки был заново оценен тюрко-татарами в Татарстане» и за последние годы татарские ученые написали множество статей о его жизни и творчестве [6: 66].

Первая глава монографии названа «Тюрко-татарские общины на Дальнем Востоке». Здесь дается краткая история волны тюрко-татарской эмиграции в XIX в. и после революции 1917 года в Маньчжурию. А. Матсунага дает подробную информацию, в каких городах тюрко-татары расселились, какие общины они организовали и на каких работах были задействованы. Исследовал Матсунага и миграцию тюрко-татар в 1920 году в Корею и Японию. Особенно подробно он останавливается в монографии на истории эмиграции в Японию «лидера тюрко-татарской общины в Токио»Мухаммед Абдулхай Курбан-Али (1892-1972), основавшего в 1928 году Токийское Мусульманское общество, полными членами которого были 150 тюрко-татар. Описывая его деятельность в Японии, А. Матсунага упоминает, что именно он основал здесь тюрко-татарскую школу Мектеб-и Исламийе и типографию в Токио Матбаа-и Исламий, а также опубликовал тюрко-татарские издания, отправленные почтой в исламские страны («Йанга Йапон Мухбири») и татарские учебники для татарских учеников. В то же время А. Матсунага объективно подчеркивает нелегкий характер активиста тюрко-татарской общины Курбан-Али и пишет, что «некоторые тюрко-татары в Токио были враждебно настроены по отношению к нему» и другие тюрко-татарские общины в таких городах Японии, как Кобе, Кумамото и Нагое «абсолютно не поддерживали Курбан-Али» [6: 67–69]. И только визит такого популярного татарского писателя и националиста как Гаяз Исхаки, по мнению Акиры Матсунаги, должен был изменить положение тюрко-татар на Дальнем Востоке. Ведь именно Гаяз Исхаки привлек тюрко-татар на Дальний Восток. Как заметил А. Матсунага, «Офис дипломатических записей (Японское Министерство Иностранных Дел) в Токио хранит аривные материалы, касающиеся визита Аяза Исаки в Японию» [6: 69]. Таким образом, ученый в данной монографии представляет и некоторые из японских архивных материалов, касающиеся приезда Исхаки в Японию и Маньчжурию. В главе «Визит Аяза Исхаки в Японию» А. Матсунага пишет, что Г. Исхаки, принявший участие в движении Прометея в Польше вместе с «сосланными турецкого происхождения, покинувших Советский Союз», пропагандировал компании против Советского Союза и коммунизма через турецкие публикации и Советский Союз признал его опасной персоной – пан-тюркистом». По мнению ученого, Гаяз Исхаки, «имевший сведения о менявшейся политической ситуации на Дальнем Востоке и основании Манчукуо (Маньчжурии), возможно, думал, что это хорошая воможность для исправления тяжелого положения тюрко-татар на Дальнем Востоке» и «решил посетить Японию и Маньчжурию с целью объединения и организации тюрко-татарских беженцев на Дальнем Востоке» [6: 70–71]. В данной главе подробно описывается и второй визит Гаяза Исхаки в 1933 году в Кобе, в ходе которого он посетил тюрко-татарские общины и прочитал лекции о положении в Советском Союзе. Делая акцент на цели визита Г. Исхаки, Матсунага отмечает, что «его отношение и замечания полны симпатии и дружбы к японскому правительсиву и Манчукуо» и его визит в Японию благоприятно повлиял на тюрко-татар, проживавших здесь и изъявивших желание сотрудничать с ним в различных областях в Японии [6: 71–72].

В следующей главе монографии «Конфликт между Исаки и Курбан-Али в Изимибаши» А. Матсунага описывает состояние тюрко-татарской общины до приезда Исхаки в Японию и конфликт между группой, поддерживавшей Исхаки, и группой, поддерживающей Курбан-Али, опираясь на документы, хранящиеся в Офисе дипломатических записей.

В главе «Основание Идил-Уральской тюрко-татарской культурной организации» даны сведения о Независимом комитете Идил-Уральских тюрко-татар – Идил-Уральском движении, основанном Гаязом Исхаки в 1928 году в Берлине, о цели данного движения и Идил-Уральской тюрко-татарской культурной организации, которую Исхаки основал в Токио в 1934 году. А также даны сведения о филиалах данной организации. Дана и подробная информация о Первом Курултае в Кобе с участием 41 тюрко-татара. А. Матсунага останавливается и на том, что об этом Курултае была написана Гаязом Исхаки статья, которую он отправил в египетскую газету Аль-Балаг. Далее ученый приводит описание резолюции.

В главе «Визит Аяза Исаки в Маньчжурию» А. Матсунага описывает приезд Исхаки в Маньчжурию и прочтение им тюрко-татарам серий лекций по следующим темам: «О положении тюрко-татар в Европе», «О положении тюрко-татар в Советской России» и «Идил-Уральское движение». Японский ученый приводит текст информирования японского Министра иностранных дел о визите Гаяза Исхаки Японским консульством в Хайларе.

В следующей главе монографии, которая называется «Первый Курултай на Дальнем Востоке и Милли Байрак», дана информация о 1-ом Курултае Идил-Уральской тюрко-татарской организации на Дальнем Востоке, который был проведен с 4-го по 14-ое февраля 1935 года в Восточной гостинице Мукдена. А. Матсунага приводит список членов исполнительного комитета Курултая и называет цели, которые преследовал Курултай. Также дается информация о еженедельной тюрко-татарской газете «Милли Байрак», которая издавалась на арабском языке в Мукдене. По мнению ученого, «Японские военные наблюдали за движениями Идил-Уральской тюрко-татарской культурной организации» [6: 84]. А. Матсунага останавливается и на тех статьях, которые написал в газете «Милли Байрак» Гаяз Исхаки во время пребывания на Дальнем Востоке, и в которых поддерживал независимость Манчукуо. По мнению Акиры Матсунага, Исхаки, возможно, «писал дружеские статьи для правительств Японии и Манчукуо для того, чтобы улучшить положение тюрко-татар и их жизненный уровень на Дальнем Востоке» [6: 85].

В последней главе монографии «Возвращение Аяза Исаки в Европу», говорится о том, что Г. Исхаки своей активной деятельностью «добился результатов и определенной доли успеха на Дальнем Востоке» [6: 86]. Далее ученый говорит о возвращении Исхаки в Европу и продолжении своей активной деятельности в Европе. А также А. Матсунага пишет и о его побеге из Польши в Турцию, где «Исаки продолжал поддерживать и организовывать зарубежных тюрко-татар до своей смерти в 1954 году» и, что «он также беспокоился о тюрко-татарах на Дальнем Востоке» [6: 86].

В «Заключении» монографии японский тюрколог подводит итоги пребывания Г. Исхаки на Дальнем Востоке. Здест приведены тексты телеграмм, в которых сообщалось о Гаязе Исхаки. По мнению А. Матсунаги, «японские власти приняли деятельность Аяза Исаки в Маньчжурии за действия Советского агента, и, что японские офицеры негативно оценивали его по информации, предоставляемой Курбан-Али, у которого были личные связи с Генеральным Штатным Офисом и организацией правого крыла «Организация Черного Дракона» [6: 88].

А. Матсунага затрагивает здесь и политическую ситуацию на Дальнем Востоке после Второй мировой войны, когда положение тюрко-татар серьезно ухудшилось. По предоставленной А. Матсунагой информации, Гаяз Исхаки ходатайствовал о защите и спасении тюрко-татар на Дальнем Востоке в качестве «Президента Идил-Уральских тюрко-татар на Дальнем Востоке». Данное ходатайство, по сведению А. Матсунага, хранится в Общественном бюро записей в Лондоне. А. Матсунага с сожалением пишет, что японцы не знали имени Гаяза Исхаки и о его визите в Японию, так как большинство тюрко-татар после Второй мировой войны эмигрировало в Турцию, Австралию и Америку. Ученый, несмотря на исчезновение тюрко-татарских общин на Дальнем Востоке, призывает помнить историю отношений между тюрко-татарами и японцами на Дальнем Востоке.

Широко известно, что Г. Исхаки в эмиграции был уважаемой личностью и его идеи, взгляды, литературные и публицистические произведения оказали огромное влияние на жизнь татарского народа и на родине, и за рубежом [2: 127]. В незаконченной автобиографической повести Эмрулла Агиев писал следующие строки: «Мы, молодежь, хорошо знали Гаяза Исхаки, его большой портрет висел в зале общины с портретами ученого и просветителя Исмаила Гаспринского, великого поэта Габдуллы Тукая, историка-реформатора Шигабетдина Марджани, создателя первого тюрко-татарского театра Галиаскара Камала, а также других знаменитостей. <…> Несмотря на нашу малочисленность на Дальнем Востоке, он приехал сюда, созвал съезд, помог образованию Центрального правления общин (Меркез), начал издание газеты «Милли Байрак». Он объединил в сплоченную семью тюрко-татар Японии, Китая и Кореи. Его признавали правительства эти стран» [1: 74–75; 114–115]. Деятельность Г. Исхаки исследовалась и освещалась как при его жизни, так и после его смерти не только на родине, но и за рубежом. Поэтому каждое новое исследование, особенно зарубежных ученых, проживающих втех странах, где он разворачивал свою деятельность, радует по-особому. Монография японского тюрколога Акиры Матсунага «Аяз Исхаки и тюрко-татары на Дальнем Востоке», пропагандирующая деятельность Гаяза Исхаки за рубежом, является одним из таких значимых научных исследований.Надеемся, что она послужит дополнительной научной литературой для ученых, работающих по теме деятельности Гаяза Исхаки на Дальнем Востоке. То, что монография издана на трех языках (турецком, английском и русском), дает возможность использовать ее и ссылаться на нее широкому научному кругу не только в России, но и за рубежом.

ЛИТЕРАТУРА

1. Агиев Э. Жизнь одного человека // Э. Аги. Казань: Магариф, 2003.

2. Мансуров И.С. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге татар дөньясына йогынтысы. Гаяз Исхакый Иҗаты: хәзерге караш // Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Б. 125–131.

3. Миңнегулов Х.Й. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.

4. Усманова Л.Р. Роль Гаяза Исхаки в организации тюрко-татарской эмиграции на Дальнем Востоке // Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. С. 348–354.

5. Cəfərov Nizami. Yapon alimi prof. Akira Matsunaqanın «Ayaz İshaki və Uzaq Şərqdəki Tatar türkləri» əsəri haqqında // Matsunaga Akira. Ayaz İshaki və Uzaq Şərqdəki Tatar Türkləri. Bakı: Sabah, 2004. S. 3–4.

6. Matsunaga Akira. Ayaz İshaki və Uzaq Şərqdəki Tatar Türkləri. Bakı: Sabah, 2004. 104 s.

# ТАНЫЛГАН ТЮРКОЛОГ ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫ АКЛАУ ҺӘМ ХЕЗМӘТЛӘР ҖЫЕНТЫГЫН ӘЗЕРЛӘП ЧЫГАРУ

*М.З. Зәкиев*

В статье речь идет о процессе реабилитации Гаяза Исхаки на расширенном заседании Комиссии «Наследие», о подготовке 15-томника его произведений сотрудниками Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, а также Турецком фонде Менгер, президентом которого была дочь Турецкого миллионера Ахметвали Менгер доктор (кандидат) философии Сафия Имре.
**Ключевые слова:** реабилитация, комиссия по наследию, пятнадцать томов, ИЯЛИ АН РТ, архив Исхаки, Турецкий фонд Менгер.

The report deals with the process of Gayaz Iskhaki's rehabilitation at the enlarged meeting of the «Heritage» Commission, on the preparation of the 15-volumes of his works by the employees of the Language, Literature and Art Institute named after G. Ibrahimov, as well as the Turkish Menger Foundation, whose president was the daughter of the Turkish millionaire Akhmetvali Menger, the Doctor (candidate) of Philosophy Safia Imre.
**Key words**: rehabilitation, Heritage Commission, fifteen volumes, Iskhaki archive, Turkish Menger Foundation.

Совет чорында халык дошманы дип танылган Гаяз Исхакый, акланганнан соң, язучы, публицист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе дип рәсми рәвештә танылды. Ләкин аның танылган тарихчы галим-тюрколог та булуына җитәрлек игътибар биргәнебез юк әле.

Бүгенге конференциядә без үзебезнең бу җитешсезлегебезне танырга һәм төзәтергә тиешбез, аның танылган тюрколог булуын әйтергә һәм җыйнак кына итеп күрсәтеп бирергә дә тиешбез.

Гаяз Исхакыйны тюрколог-галим итеп таныта торган төп хезмәте – «Идел-Урал». Бу хезмәт беренче мәртәбә 1933 елда Берлинда татарча нәшер ителә. Аннан соң шул ук елда Франциядә французча һәм русча, 1934 елда Токиода – японча, 1938 елда Варшавада – полякча, шул ук елда Лондонда – русча басылып чыга.

1987 елда Гаяз Исхакыйны аклаганнан соң, аның хезмәтләрен җентекләп өйрәнү башлана, иң элек аның милли мәсьәләне хәл итүгә багышланган тюркологик хезмәте «Идел-Урал» өйрәнелә, 1991 елда аерым брошюра хәлендә бастырылып чыгарыла. Биредә Рафаэль Хәкимнең кереш һәм йомгаклау мәкаләләре урнаштырылган, алар Гаяз Исхакый хезмәтләрен анализлаган беренче мәкаләләр саналалар. «Идел-Урал»ның татарчасы 1992 елда шулай ук аерым брошюра рәвешендә басып чыгарылды [1: 64; 2: 48]. Менә шул басмалардан соң һәм унбиш томлыкның чыгу барышында һәм чыккач, Гаяз Исхакыйның хезмәтләрен гыйлми өйрәнү юлга салынды.

Мин хәзер, Гаяз Исхакыйны аклау һәм аның 15 томлыгын әзерләү эшләрен оештыручы буларак, менә шул эшләр турында сөйләмәкче булдым.

Быел 2018 елда халкыбызның атаклы язучысы, журналисты,сәячәтчесе, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, төрки тарихы галиме Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулды. Шул уңайдан бөек эшлеклебезне аклау һәм аның әсәрләре җыентыгын әзерәп чыгару турында мәгълүмәт бирү укучыларны да кызыксындырыр дип уйлыйм.

Гаяз Исхакый Сталин чорындагы милли сәясәтнең иң зур дошманы санала иде. Шуңа күрә ул үз иленә кайта алмыйча, чит илдә вафат булды. Аны аклау (реабилитацияләү) шома гына бармады, Татарстан Өлкә комитетында, район партия оешмаларында эшли торган яки эшләгән интеллигенция вәкилләре Гаяз Исхакыйны аклауга каршы киләләр иде. Шуңадыр партиянең Өлкә комитеты да Гаяз Исхакыйны аклауны турыдан-туры үзе эшләмәде, аның Үзәк Комитет-

ка бу аклау халык инициативасы белән башкарыла диярлек юлларын эзләде. Бу фикергә мин түбәндәге сөйләшүләрдән соң килдем.

Татарстан Өлкә комитетында пропаганда юнәлешен алып баручы Әдип Сәхип улы Миндубаев, мине – Тел, әдәбият һәм тарих институты директорын үзенә чакырып алгач, безнең арада шундый сүз булды:

– Мирфатыйх Зәкиевич, син үзең күреп торасың, Өдкә комитеты электән гаепләнгән бик күп эшлеклеләребезне аклады. Болар барысы да Өлкә комитеты инициативасы белән генә башкарыла икән дигән сүз булмасын өчен, төрле оешмаларның да инициативасын күрәсе килә иде. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның реабилитациясен кайсы оешма күтәреп чыкса әйбәт булар иде икән, язучылар оешмасымы, әллә син җитәкли торган ИЯЛИме?

Мин бу сорауга шунда ук түбәндәге җавапны бирдем:

– Ике уйлап торасы юк, моны безнең институт кына башкарырга тиеш, аның хезмәтләр җыентыгын да бары безнең институт кына әзерләп чыгара алачак.

Шушы сөйләшүдән соң мин Гаяз Исхакыйның хезмәтләрен, ИЯЛИнең бу яңа юнәлешкә әзерлеген, мөмкинлекләрен өйрәнеп чыктым. 1987 елның 10 нчы ноябрендә институт каршында 18 кешелек Рухи мирас комиссиясен төзү турында приказга кул куйдым. Комиссия әгъзалары Өлкә комитетта, Министрлар Советында да каралды. Комиссиянең рәисе итеп филология фәннәре докторы, професср Флюн Мусинны билгеләдем.

Комиссия әгъзалары, изге гамәл кылабыз дип, дәртләнеп эшкә керештеләр. Аларның барысына да Гаяз Исхакый әсәрләренең библиографиясе бирелде. Бу библиографияне ИЯЛИнең өлкән фәнни хезмәткәре Һәнүз Мәхмүтов планнан тыш төзегән булып чыкты. Ул планга кертмичә генә, «Гаяз Исхакыйның драматургиясе» дигән темага монография яза башлаган. «Гаяз Исхакыйны кайчан да булса акларлар дип ышанып яшәдем» дип аңлатты ул үзенең бу теманы алуын.

Рухи мирас комиссиясенең беренче зур эше итеп, 1989 елның 1 нче мартында Гаяз Исхакыйны реабилитацияләү турында шәһәр күләмендә киңәйтелгән җыелыш үткәрдек. Сөйләшү зур каршылыклар белән кискен тонда барды. Шулай да Гаяз Исхакыйны аклау һәм аның әсәрләренең тулы басмасын әзерләп чыгару кирәклеге турында уңай фикер күпчелек тавышны алды. «Мирас» журналын чыгару турындагы карарга да шушында нигез салынды.

Рухи мирас комиссиясенең бу утырышы институт гыйльми эшенең төп юнәлешен дә үзгәртте: Гаяз Исхакый әсәрләренең тулы җыентыгын төзеп чыгару әдәбият бүлеге хезмәткәрләренең мактаулы бурычына әйләнде. Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакыйның хезмәтләре төрле илләрдә басылган. Ул язмаларны эзләү, табып алып кайту өчен, күп кенә чит ил командировкалары оештырырга туры килде.

Шул эшләр белән шөгыльләнү чорында, Истанбулдагы Халыкара фәнни конференциягә килгәнемне белеп, мине Төркиядәге татар миллионеры Әхмәтвәли Мәнгәрнең кызы Сафия Имре үзенең офисына чакырды. Конференция утырышы тәмамлануга, мине Сафия ханымның ярдәмчесе Мәхмүт Әлүкәй Мәнгәрләр офисына алып килде. Мин Сафия ханымны электән күргәне юк иде. Ул татар хатыннары кебек матур итеп киенгән, минем белән дөп-дөрес итеп татарча сөйләшә башлады. Әзерләп куелган чәй өстәле янына утыргач, төрекчәгә күчте.

– Мин сезне үземнең киңәшчем булырга риза булмассызмы дип белергә чакырдым. Мин сезне хәтсездән беләм, сез чын эш кешесе, ә шулай да сез директор бит, вакытыгыз җитәрме?

– Вакытым җитәр, мин сезнең киңәшчегез булырга әзермен, ләкин мин сезгә бер яңа эш тәкдим итмәкче булам.

– Сезнең эшегез турында да сөйләшербез. Аңа кадәр мин сезне Мәңгәр вакыфы белән таныштырмакчы булам.

– Әтием Әхмәтвәли, сәламәтлеге какшагыч, миңа шундый киңәш бирде: – Минем капиталым сезгә һәм сезнең балаларыгызга да җитәрлек. Аннан туган халкыма – татарларга өлеш чыгарырга тырыш, – диде.

– Әтием вафат булгач, мин аның васыятен үтәргә керештем. Алманиядәге үзебезнең бер бик бай имениене саттым һәм аның акчасына, татарларга ярдәм итәр өчен, Әхмәтвәли Мәңгәр ширкәтен төзедем. Мин ул ширкәтнең президенты, ә сезне бирегә алып килгән Мәхмүт Әлүкәй – безнең гаилә табибыбыз – минем ярдәмчем. Без Мәңгәр мәркәзе хисабына Казанга җибәрәсе китапларны әзерлибез, Төркиядә укып йөрүче татар студентларына акчалата ярдәм күрсәтәбез. Минем янда сез командировкага җибәргән Лена Гайнанова ике мәртәбә булды. Мин аңа үземнең хезмәткәрләр ярдәме белән Гаяз Исхакыйның берничә мәкаләсен табып бирдем. Моның өчен ул бик шатланды.

– София ханым, минем сезгә кушасы эшем дә менә шул Гаяз Исхакый әсәрләрен бөтен җир шарыннан эзләп табу һәм безнең институтка кайтару белән бәйле.

– Мин Гаяз Исхакый әсәрләре җыентыгы өчен аның архивын төзү һәм аны үз иленә кайтаруны Мәңгәр мәркәзе планына кертүне башлаган идем инде. Сезнең үтенечегез дә шушы мәсьәлә белән бәйле булгач, мин бу проблеманы үземнең төп эшем дип санячакмын.

Бу сөйләшүдән соң миңа Мәңгәр вакыфында еш булырга туры килде, бигерәк тә Исхакый архивын туплау һәм материалларны тәртипкә китерү мәсьәләләре буенча.

Гаяз Исхакыйның архивы әзер булгач, мин архивны төзүдә катнашкан кешеләрне Казанга чакырдым, алар Гаяз Исхакый архивын да алып килергә тиешләр иде.

1997 елның 5 нче июнендә София ханымны, аның ире Иззәт Имрене, Мәхмүт Әлүкәй һәм аның хатыны Зөһрә Әлүкәйне Казан аэропортында каршы алдык. Казан белән таныштыргач, кунакларны София ханым әтисенең бабасы туган Мәңгәр авылына, әнисенең ерак туганнары яшәгән Саба якларына алып бардык.

Мин алдан ук президентыбыз Минтимер Шәриф улы белән сөйләшеп куйган идем. Шул сөйләшү буенча, 9 нчы июньдә София ханым китергән архивны президентыбызга тапшыру тантанасы булды.

Төркиягә кайткач, София ханым, минем һәм Илбарис Нәдировның (икенче киңәшченең) соравын үтәп, архивны туплау турында махсус хат язып җибәрде. Хатның эчтәлеге белән укучыларны да таныштырыйк.

**София Имре хаты:**

«Сәгадәт Чагатай (Г. Исхакыйның кызы) вафатыннан соң, Гаяз Исхакыйның Әнкарадагы архивы Мәхмүт Таһир кулына керә. Белгечлеге буенча инженер булса да, Мәхмүт Таһир Төркиядәге төрки-татарлар арасында әдәбимәдәни гамәлләре белән танылган кеше иде. Сәгадәт Чагатай мәрхүм әтисенең мирасын барлауны, саклауны үзе исән вакытта ук аңа ышанып тапшырган иде. Кызганыч ки, Мәхмүт әфәнде Таһир да озакламый вафат итте (1991. декабрь). Моннан соң язучының М. Таһирда саклanучы архивы Әнкарада яшәүче журналист вә китап белгече Саидә Арсланбәк кулына күчте. 1995 ел башында Ә. Мәңгәр вакыфы корылгач, мин Арсланбәкне фәнни хезмәткәр сыйфатында вакыфка эшкә алдым. Безнең беренче эшебез Гаяз Исхакый архивын кыйммәтле бер мирас буларак Әнкарадагы бүлегебезнең сейфына урнаштыру булды.

– Гаяз Исхакыйның Ташкентта яшәүче Сөембикә исемле ерак туганы барлыгын 1996 ел башында гына белдем. Ул чыннан да Гаяз бәйнең хәзерге көндә төп варисы икән. Шуңа күрә Гаяз Исхакый архивын аңа тапшыру яисә аннан сатып алу мәсьәләсе көн тәртибенә басты. Сөембикә ханым Шәрипованың ул архивны Ташкент шәһәренә алып китү ихтималы да күз алдыннан үткәрелде. Һәр ихтималга каршы бөтен архивның берәр фотокүчермәсе әзерләнде.

1996 елда май аеның соңгы атнасында Сөембикә ханым Төркиядә булып китте. Истанбулга килгәч, аны хәл кадәрле кунак иттек. Шул арада аңа Ә. Мәнгәр вакыфының Гаяз Исхакый архивын сатып алырга әзер икәнлеген әйттек. Сөембикә ханым, иң югары дәрәҗәдә галиҗәнаплек күрсәтеп, әдип архивын төп ватаны булган Казанга кайтару шарты белән, вакыфка бернинди бәя, хак куймыйча бүләк итеп тапшырачагын белдерде.

Язмыш тарафыннан шулай язылган булгандыр, без Ә. Мәнгәр вакыфының икенче рәисе Мәхмүт Әлүкәй, шулай ук ирем Иззәт Имре белән 1997 елның июнь башында Казанга килгәч, Гаяз Исхакый архивындагы 89 документның оригиналларын Татарстан милли архивына тапшырдык. Ул архивны Татарстан Президенты Минтимер әфәнде Шәймиев үз кулы белән кабул итеп, бу бүләк өчен безнең вакыфка һәм Сөембикә ханым Шәриповага зур рәхмәт белдерде.

Бу архивның тагын бер данәдәге фотокопиясе Төркия дәүләт архивына да бүләк ителде.

Гаяз Исхакыйның безнең вакыф аша үткән архивы турында Сезгә ирештерәсе мәгълүматларым менә шулардан гыйбарәт.

Ихтирам илә, Сафия Имре»

Сафия Имре китергән архив һәм берничә кыйммәтле шәхси әйбере турында матбугатта, радио-телевидениедән җентекле итеп хәбәр бирелде, килгән документларның тулы исемлеге «Гасырлар авазы» журналында дөнья күрде (1997, 3–4 саннарда).

Гаяз Исхакый материалларын туплап тапшыруы һәм Татарстан китапханәләренә ярдәме өчен, 1998 елда 13 сентябрь Указы белән Сафия Имрегә «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Бу дәүләт бүләген 1999 елның 1 октябрендә мин Истанбулга алып барып тантаналы рәвештә Сафия Имрегә тапшырдым.

Гаяз Исхакыйның Төркиядән килгән һәм институт галимнәре туплаган әсәрләрен бергә туплап гомуми күләмен өйрәнгәч, төркем җитәкчесе Лена Гайнанова барлык әсәрләр 15 томлык булачак дигән фикер әйтте. Башка төрле фикер әйтүчеләрнең тәкъдимнәрен дә исәпкә алып фикер йөрткәннән соң да 15 томлык чыгару фикере өстен чыкты.

Мин институт директорлыгыннан пенсиягә киткәнче, Гаяз Исхакый әсәрләренең беренче һәм икенче томнары басылып та чыкты. Сигезенче томы нәшрияткә тапшырылды.

Калган башка томнарын әзерләп бастырып чыгару эше белән җитәкчелек итү эшен ИЯЛИнең яңа директоры Нурмөхәммәт Хисамов, соңрак бу вазифага билгеләнгән Ким Миңнуллин башкардылар.

Барлык 15 томны бастырып чыгару 2014 елда тәмамланды. Аларны әзерләп чыгаруда катнашкан галимнәрдән Лена Гайнанова, Зөфәр Мөхәммәтшин һәм Зөфәр Рәмиев 1917 елда Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә лаек булдылар.

ӘДӘБИЯТ

1. Гаяз Исхаки. Идель-Урал / автор предисловия и послесловия кандидат философских наук Рафаэль Хаким. 1991: Татар. кн. изд-во. 64 с.

2. Гаяз Исхакый. Идел-Урал / редакторы В. Имамов.1992. Яр Чаллы. 48 б.

# ӘДӘБИ РЕЦЕПЦИЯНЕҢ ИКЕ ТӨРЕ: XIX ЙӨЗ РУС ЯЗУЧЫЛАРЫ Г. ИСХАКЫЙНЫҢ МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТӘНКЫЙТЬ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ

***М.И. Ибраһимов*** *(Казан)*

В статье рассматриваются вопросы рецепции Гаяза Исхаки в период эмиграции творчества русских писателей XIX века. Устанавливается соотношение эстетических и внеэстетических критериев критической оценки, определяется роль публицистического дискурса в суждениях о русских писателях.

**Ключевые слова**: Гаяз Исхаки, русские писатели XIX века, рецепция, татарская литература, русская литература, публицистика.

Tatar writer, critic and public figure G. Iskhaki's opinion on personality and creativity of Russian writers of XIX century was studied in this article. The relation of aesthetic evaluation criteria and extra-aesthetic evaluation criteria was established and role of journalistic discourse in critical judgments was evaluated.

**Key words**: Gayaz Iskhaki, Tatar literature, Russian literature, publicism, reception.

Безнең әдәбият белеме фәнендә рус һәм татар әдипләренең иҗатын чагыштыру – озак еллар аерым бер юнәлеш булып яши. Бу юнәлештә ике төр хезмәтне аерырга мөмкин. Беренчесендә әдәби багланышлар тикшерелә, икенчесендә исә – типологик охшашлыклар. Рус һәм татар әдәбиятлары арасындагы багланышларны өйрәнү, күп очракта, рус әдипләренең татар язучыларына тәэсир итү мәсьәләсе белән бәйле. Нигездә, андый хезмәтләрдә, татар әдипләре тарафыннан рус язучылары әсәрләрен һәм, гомумән, иҗатларын кабул итү һәм аларга иярү турында сүз бара. Алай итеп мәсьәләне кую очраклы түгел: беренчедән, XX йөз татар язучылары үз әсәрләрендә һәм чыгышларында рус әдипләренең тәэсире турында кайвакыт турыдан-туры язалар; икенчедән, әдәбият белемендә өйрәнчек милли әдәбиятлар прогрессив рус әдәбиятының йогынтысы аша үсәләр, дигән фикер озак еллар яшәп барды.

Чагыштырма әдәбият белеме теориясендә әдәби бәйләнешләрнең ике формасы булуы турында, кайбер галимнәр тарафыннан инде күптән әйтелеп барыла. Словакия галиме Д. Дюришин бу формаларны интеграль һәм дифференциаль контактлар дип билгеләп, беренчесенә чит әдәбияттагы күренешләрне якын күрү, алар белән тиңдәшлекне ассызыклау, икенчесенә, киресенчә, бүтән әдәбиятның күренешләреннән читләшү, аның белән аерманы күрсәтү хас булуын яза [2: 149].

Татар һәм рус әдәбиятлары арасында да, интеграль бәйләнешләр белән янәшә, дифференциаль бәйләнешләр дә бар, ләкин аларга тиешле игътибар бирелми, гәрчә аларның әһәмияте беренче төр бәйләнешләрдән ким булмаса да. Киресенчә, нәкъ дифференциаль бәйләнешләр аша безгә, күп очракларда, әдәбиятларның миллилеге ачыла.

Г. Исхакыйның 1929 елда мөһаҗирлектә язылган «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» дип аталган мәкаләсе шундый хезмәтләрнең мисалы. «Милли юл» журналында (8 нче санда) басылган бу мәкалә СССРдагы Л. Толстойның тууына 100 еллык юбилей чараларын уздыруга һәм шул сәбәпле «Безнең юл» журналында Х. Вәлинең «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» дип исемләнгән мәкаләсе чыгуга нисбәтле язылган.

Г. Исхакый, Толстойның татар әдәбиятына тәэсир итүе турында язган һәм революциягә кадәр Толстойга ияреп иҗат иткән язучылар исемлегенә Г. Исхакыйны дә керткән [1] Х. Вәли белән бәхәскә кереп, үз мәкаләсендә үзен толстойчылар рәтенә кертүен ялгыш дип саный. *«Толстой миңа һәрвакыт ят булып килде, – дип яза Г. Исхакый, – аның чуалчык фәлсәфәсе, аның мәдәният-*

*не инкарь итеп маташуы, аның ишан булып кылануы... табигатьтән бирелгән минем туп-туры иттереп торган башым вә нәселдән килгән төркчә сизүем, хис итүем берлә һичбер вакыт үзләшә, берләшә алмады. Толстойны хөрмәт итсәм, әдип уларак хөрмәт иттем. Толстойчы булмадым»* [3: 328].

Мондый сүзләрне әдипнең егерме ел алдан «Казан мөхбире» гәҗитәсендә (1908 елның 31 март санында) «Граф Толстой» исеме белән чыккан мәкаләсе белән чагыштырганда, татар әдибенең һәм публицистының бөек рус язучысына карата булган фикеренең кискен үзгәрүе турында уйларга мөмкин. Чынлап та, Толстойның 80 яшьлек юбилеена багышлап язылган мәкаләсендә Г. Исхакый аның иҗатын, карашларын югары бәяләп, Толстой турында татар дөньясында мәгълүмәтнең һәм татарчага тәрҗемәләрнең аз булуын тәнкыйтьләп чыга [4].

Егерме елдан соң Толстойга карата татар әдибенең мөнәсәбәте үзгәрүе, аның эстетик карашларына нигезләнмәгән. Игътибар итик: китерелгән өзектә Г. Исхакый Толстойны «әдип уларак» хөрмәт итүен ассызыклый. Димәк, әдипнең «толстойчылыктан» баш тартуы бүтән төрле сәбәпләр белән бәйле.

Мөһәҗирлектә яшәсә дә, Г. Исхакый СССРдагы большевиклар тарафыннан милли мәдәниятләргә карата сәясәтне һаман күзаллап һәм тәнкыйтьләп барган. Әдип большевиклар дәүләтендә милли әдәбиятларга, телләргә тиешле игътибар булмавы турында яза, милли мәдәниятләрнең яшәвен тик рус мәдәниятенә иярүгә бәйләгән тарихчыларга каршы чыга: *«Ләкин, мәгаттәәсеф (үкенеч ки), безнең тикшерүчеләремезнең иң күбесе шул тугры юлдан адашып, русларның мәшһүр Иловайскилары тарафыннан мәйданга атылган: татарның бер нәрсәсе булмаган, бер нәрсәсе дә булачак түгел... үз бакчамызда үскән, үз малларымызның нәселене, төбе-тамырыны табыр өчен күрше рус авылының түтәе бакчасында... танытып бетерәләр»* [3: 330].

Шул ук фикерләрне без Г. Исхакыйның 1937 елда, СССРда А.С. Пушкинның вафатына 100 ел тулу уңаена уздырылган бәйрәмгә (һәм шуңа бәйле милли республикаларда тантаналы чаралар үткәрүенә) нисбәтле язылган, «Әдәбият пәрдәсе астында русчылык» мәкаләсендә күрәбез («Яңа милли юл», 1937. № 3).

Г. Исхакый А.С. Пушкинның бөек шагыйрь булуына, әлбәттә, шикләнми. Милләтпәрвәр буларак, әдип СССРда Тукайга һәм башка төрки язучыларга тиешле игътибар булмавын ассызыклый һәм шул ук вакытта большевикларның икейөзлеген күрсәтә: дворян булган Пушкинны халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәреп, большевиклар хөкүмәте үз илендә күп санлы әдипләрне кыру процессын алып баралар, ди [5].

Г. Исхакыйның Толстойга багышланган мәкаләсендә тагын бер мәсьәлә игътибарга лаек: публицист XIX йөз рус классикларына үз мөнәсәбәтен белдерә: *«Минем рухыма иң якын рус язучылары, иң сөйгәннәремнең берсе әле дә Тургенев, икенчесе – Чехов вә өченчесе – Гогольдер. Беренчесең Европа мәдәнияте берлә сугарылган татар рухында мин үземне-үзем таныйм. Икенчесенең һичбер төрле славянча ялганы, риякәрлеге (икейөзлелеге) берлә пычранмаган рухында үземнең тугрылык сөюемә азык табам. Өченчесенең юморында бабамыз Хуҗа Насретдиннан килгән юморчылыкта мөштәрәк (уртак) ноктaлар табам»* [4: 329]; *«Мин аның (Достоевскийның. – М.И.) китабы эченә кереп киткәч, үземне-үзем әллә нинди һавасыз бер бина эчендә кебек хис итәм. Аның славянча иттереп душа, душа... дип, грех дип кылануларыннан чиркәнәм... Мин һичбер вакыт үземне көчләмәенчә, аның бер әсәрен укып чыкканымны хәтерләмим»* [3: 328–329].

Күрәбез ки, аерым рус язучыларын (Тургенев, Чехов, Гогольне) якын күреп, кайберәүләрен (Достоевскийны) Г. Исхаки үзенә ят итеп билгели. Мондый

бәяләү сәнгати нигезләргә корылмаган: биредә без Г. Исхакыйны әдәбият тәнкыйтьчесе буларак түгел, беренче чиратта, публицист буларак күрәбез. Татар әдибе Достоевскийның славянофил булуын кабул итми, чөнки славянофиллыкта ул төрки халыкларны кимсетүне күрә.

Шулай итеп, мөһаҗирлектә язылган бу ике мәкаләдә әдәбият тәнкыйте дискурсы түгел, бәлки, публицистик дискурс өстенлек ала. Г. Исхакый үз мәкаләләрендә татар әдәбиятының миллилеген яклап чыга. Аның үткен (бәлки, кайвакыт, дорфа итеп тә яңгыраган) сүзләре рус әдипләренең абруен төшерү өчен түгел, ә 1920–1930 елларда большевикларның милли әдәбиятларга һәм мәдәниятләргә карата алып барылган сәясәтенә нисбәтле һәм шул ук вакытта татар һәм бүтән төрки халыкларның әдәбиятлары рус әдәбияты тәэсире аркасында гына үсеш алган дип фикер йөртүчеләргә каршы әйтелгән.

ӘДӘБИЯТ


1. Вали Х. Толстойның татар әдәбиятына тәэсире // Безнең юл. 1928. № 8.

2. Дюришин Д. Теория сравнительного изучения литературы. М.: Прогресс, 1979. 319 с.

3. Исхакый Г. Толстойның татар әдәбиятына тәэсире// Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһәжирлектәге иҗаты. Казан, 2004. Б. 325–340.

4. Исхакый Г. Граф Толстой // Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 6 т. Казан, 2005. С. 135–139.

5. Исхакый Г. Әдәбият пәрдәсе астында русчылык // Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһәжирлектәге иҗаты. Казан, 2004. С. 259–262.


## ӘМИРХАН ЕНИКИ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ


***Р.Р. Идрисов** (Уфа)*



Классик татарской литертуры Г. Исхаки оказал огромное влияние на развитие татарской литературы XX века. Его наследие было под запретом в советские годы. Несмотря на это его традиции были достойно продолжены А. Еники и его современниками. Это касалось всех сторон поисков в творчестве, начиная от проблем, жанра, творческого метода и стиля. Таким образом обеспечивалась преемственность в развитии национальной литературы.


**Ключевые слова:** начало XX века, татарский ренессанс, традиции, писатель-наставник, Г. Исхаки, А. Еники.



The classic of Tatar Literature Gayaz Iskhaki greatly influenced the development of Tatar Literature of the 20th century. His heritage was prohibited during the Soviet period. In spite of it his traditions were proudly followed by A. Eniki and his contemporaries. It touched all sides of searches in the creation beginning with the problems, genre, creative methods and style. Thus the succession in the development of national literature was performed.


**Key words:** beginning of the 20th century, Tatar Renaissance, traditions, a writer-tutor, G. Iskhaki, A. Eniki.


Бөек татар әдибе Әмирхан Еникинең публицистикасында – мәкалә, эссе, иҗат портретлары, рецензияләре һәм истәлекләрендә зыялы, мәдәниятле шәхес төп урыннарның берсен били. Әдип әледән-әле бу мәсьәләгә әйләнеп кайта. Үзенең шәхес һәм әдип булып формалашуындагы шундый шәхесләрнең йогынтысы хакында уйлана. Һәм күңел түрендә йөрткәннәрнең кешелек сыйфатларын барлый һәм шуларның үзендә дә табарга омтыла. Шул сыйфатларны үзендә күреп, ул сөенечле мизгелләр кичерә, яшәргә көч һәм юаныч ала.

Әдип үзенең «Соңгы китап» әсәренең «Бабайлар эзеннән» дип аталган бүлегендә татар халкының төмәннәр дип аталган этнографик төркеменең генезисы хакында фикер йөртә, катлаулы тарих битләрендә татар элитасы – морзаларның язмышын барлый. Кенәз-морзалардан килгән интеллект,

гражданлык хисләре, тарихи сагышын тикшереп, ул татар халкы мәдәнияте тамырларының еракка китүенә игътибарын юнәлтә. Бернәрсәнең дә юктан бар булмавын һәм бернәрсәнең дә юкка чыкмавы хакында кызыклы, дәлилле нәтиҗәләр ясый.

Нәселенең таза тамырларын ул төмәннәрдә сакланып калган шәҗәрәләргә дә нигезләнеп исбат итәргә омтыла. Табигый сайланыш һәм конкуренция шартларында физик һәм акыл көче белән җәмгыятьтә лидер булып алга чыккан нәселләрнең, рухи-әхлаки җегәр туплап, тарих мәйданына килүен ул гадәти бер хәл итеп карый. Бу бик борынгыдан килгән яшәү рәвеше, яңаданяңа этәргечләр алып, XX гасыр башында татарның мәшһүр ренессансына килеп кушыла.

Мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек идеологиясе гасырлардан гасырларга тупланып килгән рухи нигезне уятып җибәрә һәм тизләнешле үсешне тәэмин итә. Егерменче йөз башы синтезы нәтиҗәсендә мәйданга милли зыялыинтеллигентлар катламы килә, һәм алар шул яңарышның байракчылары булып китәләр. Милли-мәдәни үсеш моңарчы күрелмәгән биеклекләр яулый һәм халык, үз йөзен саклап, дөнья цивилизациясе юлыннан ышанычлы адымнар ясый. Милләтне үстерү һәм аны бәхетле итүне шәхси бәхет итеп караган зыялылар катламы барлыкка килә һәм бар кеше өчен мәдәни үрнәк дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әмирхан Еникинең иҗат дөньясы формалашуда хәлиткеч рольне нәкъ шул XX йөз башы татар әдәбияты традицияләре уйный. Татар ренессансының бәрәкәтле тәэсире әдәби әсәрләр, гәзит-журнал мәкаләләре һәм язучыларының шәхси үрнәге мисалында күренә. Булачак әдипнең рухи-мәдәни үсеше XX йөз башы татар дөньясының иҗтимагый-тарихи һәм әхлакый эстетик эзләнүләре яктысында да бара.

Ул чор татар тарихында бик үзенчәлекле дәвер булды. Күп гасырлар буена тупланып килгән рухи потенциал мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек идеяләре рәвешендә яшәешнең бар өлкәләренә дә ташкын булып бәреп керде, публицистика, тарих һәм әдәбиятның төп үсеш юнәлешләрен билгеләде. Җәдитчеләр милләтне алга җибәрү, аны һәръяклап тәрәккый иттерү юлларын эзләделәр [9: 131].

Татар тормышында барган катлаулы үзгәрешләр, искелек белән яңалык көрәше, мәйданга яңа заман каһарманы килү матур әдәбиятта да чагылыш тапты. Яңарышны әйдәүче титаннар – талантлы әдипләр сафы пәйда булды. Аларның идеалы алга киткән бәхетле милләт булды. Мәгърифәтчелек идеалларында мәйданга килгән сүз сәнгате әһелләре: «Шәхес милләтне тәрәккый иттерү (чәчәк аттыру) юлы белән генә бәхетле була ала, дип җавап бирделәр» [10: 344]. Һәм шуңа да милләткә, халыкка хезмәт итү милли идея дәрәҗәсенә күтәрелде һәм зыялыларның яшәү мәсләгенә әверелде.

Нәселе бик борынгы татар морзаларына барып тоташкан [1: 155], халык мәнфәгатьләрен кайгырту һәм аның өчен фидакарь хезмәт итүне яшәү рәвеше итеп кабул иткән Еникиләрнең бер вәкиле булган яшь Әмирхан өчен бу максатлар бик якын була. Шуңа да ул, бик иртә шул идеяләр белән рухланып яши башлый һәм хаклык һәм гаделлекне әдәби иҗат белән раслауны иң нәтиҗәле юл итеп таба [6: 498].

«Тукайчы» булып әдәбиятка килгән Ә. Еники милли прозаның реалистик традицияләрен иҗатында үрнәк итеп саный. 1962 елда язылган «Безне ул өйрәтте» исемле мәкаләсендә Ә. Еники: «Бишенче елдан соң әдәбиятка бер үк вакытта диярлек Фатих Әмирхан белән Галимҗан Ибраһимов килеп керделәр… Бу ике олы талант аркасында безнең проза әдәбияты яңа биеклеккә күтәрелде, өр-яңа сыйфатларга баеды, ул инде чынлап та рус һәм Европа

прозасына охшаш бер кыяфәткә керде. Без чын мәгънәсендә роман һәм хикәяләр укый башладык…

Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов безнең проза әдәбиятыбызда хикәяләүнең үрнәк булырлык гүзәл бер тел-стилен тудырды», – дип язды [2: 9]. Мәкаләнең йомгаклау өлешендә Ә. Еники болай ди: «…аңардан соң әдәбиятка килгән язучылар, барысы да диярлек аның көчле йогынтысына бирелеп, теге яки бу дәрәҗәдә Галимҗан стиле белән яза башладылар… Әлбәттә, алар иярүчеләр генә булып калмадылар, чын талантка ия булганнары телебезне баетуда, әдәби осталыкны үстерүдә үзләреннән дә зур өлеш керттеләр, ләкин барыбер аларның һәркайсы «Галимҗан мәктәбе» аша узды» [2: 9].

«Җепшеклек» чорының шифалы йогынтысында язылса да, бу вакытта Ә. Еники Гаяз Исхакыйның исемен телгә ала алмый әле. Шулай да бу исемлекне тулыландырып, бу өч классик әдипең татар реалистик прозасына нигез салуы хакында – үзенчәлекле синтез хакында сүз алып барып булыр иде. Моңа ышанычлы дәлилләр бар. Революциядән соң, исеме тыелып, иҗаты әдәбият тарихыннан алып ташлануына карамастан, Г. Исхакыйның бәрәкәтле традицияләре әдәбиятны тукландыруын дәвам итте. Бу – Ә. Еникинең иҗатчы буларак формалашуында да күренә. Мәсәлән, үзенең «Дуслар белән сөйләшү» дип аталган мәкаләсендә (1979) ул: «Ундүрт-унбиш яшьләремдә инде мин ул чактагы татар әдәбиятының билгеле әсәрләрен (мәсәлән, Г. Ибраһимовның барлык әдәби китапларын) укып чыктым дияргә ярый)» [2: 35].

Эзоп теленә мөрәҗәгать иткән Еникинең «билгеле әсәрләр» гыйбарәсендә Г. Исхакыйның әсәрләрен күз алдында тотуын чамалавы кыен түгел. 17 елдан соң язылган «Шәхес» дип исемләнгән мәкаләсендә ул ачыктан-ачык бу хакта язу мөмкинлеге ала: «Мин дә Г. Исхакый дигән әдипне ишетеп кенә түгел, бик яшьтән үк укып та белә идем. Бездә аның кайбер әсәрләре бар иде – егерменче елларның башларында ук миңа шуларны укырга да туры килде... (Соңыннан иң хәтәр елларда да мин аларны үземдә сакладым)», – ди ул [4: 3].

Ә. Еникинең Исхакый әсәрләрен күз карасыдай сакларга омтылуының сәбәбе бик гади, әлбәттә. Ул – бөек остазыннан өйрәнгән, һәм, безнеңчә, барыннан да элек Г. Исхакый иҗатының идея-әхлакый пафосы язучыны әсир иткән булырга тиеш. Әдипнең «Ике йөз елдан инкыйраз» әсәре белән Ә. Еникинең XX йөз уртасында «Әдәбият үсешенең яңа дәверен ачкан» (Ә. Тенишев) «Әйтелмәгән васыять» повесте арасындагы идеяләр күчемлеге XX гасырда халык яшәешенең төп үзенчәлеген билгели. Бу яктан Еники остазының лаеклы дәвамчысы булган.

Әдип өчен Г. Исхакый остаз язучы гына булмаган, аның иҗтимагый эшчәнлеге һәм публицистикасы да Еникинең күңелен арбап торган. Үзенең замандаш дусты Бакый Урманчега багышланган мәкаләсендә бу хакта да язып китүне кирәк дип саный: «...Гаяз Исхакый барысыннан да элек бөек әдип – менә шунсы Бакый абзыйны беренче нәүбәттә әсир иткән булырга тиеш...» [4: 301].

Яшь Әмирнең яшәү кыйбласын Г. Исхакый кебек маяклардан эзләве табигый хәл, чөнки «... 20 йөз башы татар рухи тормышын Г. Исхакыйдан башка күз алдына да китереп булмый» [8: 3].

Ә. Еники, һичшиксез, исхакыйчы булып, әдәбият дөньясына аяк баса. Бу – аның иҗатының төп мәсләгенә туры килә. Ул – инкыйразны кисәтү, хакыйкать һәм гаделлек сакчысы булу, XX йөз башы мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек идеяләрен ялкынлы яклау, иҗатта тирән психологизм, әхлакый сафлык һәм миллилекне раслау Гаяз Исхакыйны әдәбият тарихындагы урынын анык күз алдына китерү аның иҗатын әдәбиятка кайтару хәстәрлегендә дә күренә.

Мәшһүр җырчы Фәридә Кудашева истәлекләренә караганда, 60 нчы елларда Нәкый Исәнбәтләрдәге бер дусларча мәҗлестә шул хакта сүз кузгатылган. Анда теләктәш әдипләр Ә. Еники, Г. Бәширов, Б. Урманче, Х. Туфаннар булган [6: 31]. Шулай ук өлкә комитеты секретаре Ф. Табиев алдында 1964 елда Г. Исхакый мирасын әдәбиятка кайтару фикерен җиткерүчеләр арасында була ул. Ә. Еники: «...хәтта бик хәтәр Г. Исхакый мәсьәләсен дә телгә алдык. Аны Нәкый абзый кузгатты... ләкин Табиев Исхакый турында сөйләшүне катгый рәвештә кире какты...» – ди ул [4: 218].

70 ел буена иҗаты һәм исеме тыелса да, күрүебезчә, Ә. Еникигә классик әдипнең йогынтысы гаять зур була. Бу уртаклык һәм тәэсирләр хакында әдип 90 елларда чәчәк аткан публицистикасында тулысынча әйтү мөмкинлеге алды.

1990 елда басылган «Татар мәсьәләсе» мәкаләсенең Г. Исхакыйның «Инкыйраз...»ыннан үсеп чыкканын күрми мөмкин түгел. Шулай ук әдипнең шул еллардагы күпкырлы публицистикасы остазының мәкалә-чыгышлары белән аваздаш. Сәясәт, мәдәният, мәгариф, тел мәсьәләләрен ике әдип тә күтәреп чыга һәм охшаш чишелеш тәкъдим итә. Мәсәлән, Ә. Еникинең «Татар баласына урысча белмәү куркынычы янамый» дигән мәкаләсендәге (1998) фикерләр Г. Исхакыйның «Мәдрәсә вә мулла»мәкаләсендәге карашлар белән аваздаш: «...мәдрәсәләрдә иске вә яңа төрек төрек-татар әдәбияты, төрек вә татар теле дәресләре тәрбиянең нигезләреннән берсе булырга тиешләр», – диелә анда [7: 306].

Гаяз Исхакыйның «Мәдрәсә вә мулла», «Мөфти», «Мөфтилек», «Аракы бәласы» кебек мәкаләләре шул ук гамь белән сугарылган. Еникинең дингә һәм динчеләргә карата булган мөнәсәбәте дә Исхакыйныкы белән аваздаш. Гомеренең соңгы атналарында дусты Фуат Маннаповка болай ди: «Динне сәясәттән аерырга кирәк. Дин сәясәткә хезмәт итәргә тиеш түгел, аның эше тәрбия, югары әхлак, яхшылыкка өндәү... Мәчет тирәсендә дә яхшы кешеләр бар...» [5: 4].

Гомумән, ике әдипнең яшәү мәсләге һәм уртак кыйбласы мәкалә, карашмөнәсәбәттә генә түгел, бар иҗатта чагылыш таба.Татар әдәбиятында XX гасырны башлаучы Г. Исхакый шул гасырны төгәлләүче икенче мәшһүр әдип Ә. Еникинең иҗатына гаять зур йогынты ясый. Бу шифалы йогынты, идея-әхлакый тәэсирдән башлап, жанр, проблема, иҗат методы һәм стиль үзенчәлекләренә кадәр үтеп керә. Совет чоры цензурасы шартларында Ә. Еники остазы традицияләрен үзенчәлекле әдәби юнәлеш – милли реализм тарафдары буларак дәвам итә. Ә инде 90 нчы еллардагы үзгәрешләр чорында ул, нәкъ Г. Исхакый кебек, публицистика жанрында әйдәүче әдипкә, халкының вөҗдан һәм намус үлчәменә әверелә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006. 320 с.
2. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәим истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 224 б.
3. Еники Ә. Соңгы китап: Истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 504 б.
4. Ә. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. 5 т.: Публицистик язмалар, мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 479 б.
5. Идрисов Р. Без китәбез, сез каласыз // Өмет. 2000. 25 март.
6. Идрисова В.А., Идрисов Р.Р. Сагынуларым биниһая: Очерклар, иҗади портретлар, интервьюлар. Уфа: Китап, 2015. 114 б.
7. Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 6 том: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 447 б.
8. Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр.. 2004. 367 б.
9. Очерки истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 407 б.
10. Яхин А.Г. Әдәбият: 9 нчы сыйныф өчен дәреслек-хрестоматия. Тулыландырган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2001. 191 б.

# Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА КАРАЛТЫ-КУРА АТАМАЛАРЫНЫҢ СЕМАНТИКАСЫ

***Д.М. Кадирова, Э.Х. Кадирова*** *(Казан)*

Наши дома – хранители традиций, быта. Дом отражает характер той семьи, которая живёт в нём. Мир творчества Гаяза Исхаки населен множеством персонажей, и все они окружены вещами, которые усиливают зримость изображаемого мира, характеризуют его обладателей. В статье рассматриваются особенности употребления слов, обозначающих жилые и хозяйственные постройки в творчестве Г. Исхаки. Среди них гораздо больше таких слов, которые являются местными названиями для жилых и надворных построек.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, слово, семантика, диалектизм, названия построек.

Our houses are the keepers of traditions and life. The house reflects the character of the family that lives in it. The world of the works of Gayaz Iskhaki is inhabited by a multitude of characters, and all of them are surrounded by things that enhance the visibility of the depicted world, characterize its owners. In the article features of the use of words, which call residential and household buildings in the works of G. Iskhaki, are considered. Among them, there are many more such words that are local names for residential and outbuildings.
**Key words***:* Gayaz Iskhaky, word, semantics, dialectism, names of buildings.

Шагыйрь, прозаик яки драматург никадәр образлы фикер йөртсә, ул тудырган әдәби әсәр укучы яки тыңлаучы күңеленә шулкадәр ныграк тәэсир итә, камилрәк һәм матуррак тоела, тудырган дөнья – чынбарлыкка, геройлар тере кешеләргә охшаш була. Алар ышандыра, дулкынландыра, елата, шатландыра.

Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәрендәге Сөннәтче бабай белән аның өен янәшә куеп сурәтләгән юлларны укыгач та шул фикергә киләсең: «Ул Сөннәтче бабайның өе иде. Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде. Авыл тарихыны белми торган вакытта такта берлән ябылган түбәсе, вакыт үтә-үтә каралып бетеп, анда-монда кәкрәеп торулары берлән Сөннәтче бабайның битенә бөтенләй охшый иде. Түбәсенең кырыйларына солы, борай, алабута катышыннан үскән үләннәр дә берсе анда таба, берсе монда таба карап, Сөннәтче бабайның рәтләп тарамаган сакалыны хәтергә китерә иде. Өйнең сулга да, уңга да таба кәкрәйгән диварлары Сөннәтче бабайның төрле тарафка таба бөрәйгән аркасыны искә төшерә иде [2: 199]. Бу чагыштыру текстның тәэсир көчен бермә бер арттыра, сурәтләнә торган күренеш-халәтне укучы күз алдына төгәл китереп бастыру өчен ярдәм итә: Гади генә каралты-кура исемнәре чын сурәт ясауда катнаша. Мондый атамалар Гаяз Исхакый иҗатында еш очрый.

*Өй* һәм *йорт* сүзләре язучы әсәрләрендә ‘яшәү-тору өчен салынган корылма’ мәгънәсендә файдаланыла: Кунаклар киткәч, *өйләр* ташландык йорт кеби буп-буш калды [2: 84]; *Өй* түбәсенә шыбыр-шыбыр яуган ягмур тавышлары йокы арасына кереп, әллә нинди төшләр күрсәтteләр [2: 84]; Теге фикеремне авылның тышында калдырып, иске генә, моң гына бер *йортның* капкасыны ачтым [2: 87]; Авылның бөтен урамыннан, *өйләреннән*, бакчаларыннан, ындырларыннын, кырларыннан көйгән ис килеп тора [2: 112]. Бу ике лексеманы татар әдәби телендә дә мәгънәгә карап аеру кыен.

Йорт һәм өй лексемалары тиңдәш мәгънәләрдә килеп, бер җөмләдә кабатлаудан котылу өчен дә бирелә: <...> күрше Мәхмүтнең йортында халык өчен, Шакирә әбинең өендә муллалар өчен аш-су хәзерләнергә булынды [4: 388]; Авылның кырыеннан сан буенча исәпләнә торган Сөннәтче бабайның йорты да, дөрестене әйткәндә, өе дә, үзе кеби, бөтен авылның өйләреннән аерым иде [2: 199] мисалында автор күпмәгънәле йорт сүзенең мәгънәсенә синонимы аша ачыклык кертә.

Татар телендә йорт лексемасы махус билгеләнгән корылма мәгънәсендә дә кулланыла:... чагыла: *Мәчет йортына* әллә никадәр халык җыелган [2: 308];

<...> безнең этиләрнең *мал-туар йорты* иде [2: 188]. Мисалларда торакның нинди максаттан файдаланылуы күздә тотыла. *Кияү өенә* чыгарга Хәдичә бер дә каршы килмәде [2: 112] очрагында *кияү өе* – кыз йортында кияү белән кызны үзләрен генә калдыру өчен әзерләнгән урын Татарларда кияүгә чыгуның бер йоласына туры килә. Шулай ук авторның әсәрләрендә *аш өе* [3: 229], *җыен өе* [3: 228], *хезмәтче өе* [2: 140] вариантлары да очрый.

Гаяз Исхакый көнбатыш диалект вәкиле буларак, аның иҗатында күп очракта *йорт* сүзендә ‘ишегалды’ күзаллана: Ул мунчаның идәнене юып кайтышлый йорт уртасында, яшел чирәм өстендә, ялан аяк көенчә чиләкләр, савытлар юа иде [2: 82]. Гаяз Исхакыйда аерым очракларда *өй* һәм *йорт* лексемаларының төрле төшенчәләрне аңлатуы мисалларда да ачык күренә: <...> миләшкә су сибү, *йортны* себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Онытканмын икән әле, *өй* җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде [2: 203].

Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәрендәге түбәндәге мисалда *йорт* лексемасы ашлык, яшелчә үстерә торган, печәнлеге булган урынны да аңлата: Аның өенең артында канау берлән әйләндереп алган суга кадәр сузылган *йорты* бар иде. Читтән караганда никадәр кечкенә генә күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлык кыры, суга якын җире печәнлеккә бүленгәнгә, башка урта җире шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрене дә эченә ала алган иде [2: 201–202]. Автор яшелчәләр үскән урынны бакча лексемасы аша аңлаткан очракка да мисаллар бар: Җизниләр бакчасында айбагар бар, сезгә дә бирермен [2: 264]. Язучының төбәк лексикасына еш мөрәҗәгать итүе *айбагар* сүзендә дә (*айбагар* блт., каз.ар.-крш., т.кам.-крш, нгб.-крш., брб.д., *айбагар* миш.д. көнбагыш [7: 26]) чагыла.

‘Бер хуҗалык булып яшәүче кешеләр, гаилә’ мәгънәсенә дә Г. Исхакый иҗатында мисал бар: Унсигез *йорт* коры туфракка басып алды. Унсигез *йорт* өстендәге киеме берлә тышта калды [4: 197–198].

Берничә урында ‘йорты һәм җире булган шәхси хуҗалык’ мәгънәсендә *йорт-җир* парлы сүзе очрады: Балалар күбәйде. *Йорт-җир* бала белән тулды [2: 285]; Вахидның дәүләтен, мал-туарын, *йорт-жирен* дә калдырырга угылы юк [2: 313].

*Йорт* сүзе күплек санда җыйма мәгънәдә килә: Сәгыйдәгә: «Абыстай! *Йортларымызны* карарга кайткан идем. Ирем авырды дип хат алдым. Балаларымыз, аллага шөкер, җитәрлек. Шул угылымызны тәрбиягә алсаңыз ла. Үзе гакыллы, үзе үткен. Теләсәңез, бөтенләй сезгә бирермез», – диде [2: 293].

*Ындыр* сүзенә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә ‘урылган ашлыкны саклау, киптерү, сугу һәм җилгәрү өчен түбәле махсус җайланган урын, корылма’ дигән аңлатма бирелгән [6: 546]. Татар сөйләшләрендә ул ‘авылда, гомумән, бәрәңге һәм башка төр бакча үсемлекләре өчен бүленгән җир кишәрлеге, бәрәңге бакчасы’ мәгънәсендә дә йөри (лмбр., трбс., чст., чпр., стрл., мәл.) [7: 798]. Гаяз Исхакый иҗатында да бу лексема төп мәгънәдә актив лексика составында: Мин, хәзрәт, менә шул *ындыр* тулы икмәкләремез, йорт тулы малымыз-туарымызның кирәген белмим [2: 340]; Ләкин аның суы бик суыктыр кеби күренгәнгә, арт капкадан җиңгинең сәнәкләр, тырмалар, көрәкләр күтәреп *ындырга* киткәнене күреп, аның артыннан киттем [2: 197]; *Ындырлар* да, үзләренең кечкенә, ак, чалыш-чолыш куелган чүмәләләре берлә кеше күзенә күренергә оялган кеби, моң гына торалар [2: 113]; Мин *ындырга* барып кайттым. Андагы үләннәр дә бик матураеп үсәргә хәзерләнеп торалар [2: 102]; Хатыннар, кызлар *ындырга* кайттылар. Алар кояшта пешкән, кызарган битләреннән тирләр агызып, уҗым өчен орлыклар суга башладылар [2: 102].

Мисалларда ындыр лексемасының эчтәлеге, табигате ачык чагыла. *Ындыр табагы* гыйбарәсе да бу чорда ук телебездә урын алган: Күрше ындырда Шакирның ике кызы *ындыр табагы* ябып маташалар иде [2: 80].

*Абзар* сүзе хәзерге татар әдәби телендә һәм кайбер сөйләшләрдә ‘терлек һәм кош-корт яба яки асрый торган каралты’ [6: 15] дигәнне аңлата. Язучы әсәрләрендә *абзар* варианты чикле дәрәҗәдә генә очрый: Теге өйгә дә кермәенчә абзарга чыктым [2: 196]. Гаяз Исхакый иҗатында бу лексеманың *азбар* варианты кулланыла: Бишенче елда *азбарлар* мал-туар белән, йорт кош-корт белән, ындыр ашлык, печән белән тула [2: 286]; <...> теге егетне чакырып, келәт янына казыклар кагып, азбар ясый башлады [4: 389]. Хайваннар яңа ясалган азбарга ябылды, капчыклар келәткә бушатылды [4: 390].

*Азбар* – әдәби *абзар* сүзенең диалекталь тәңгәле. Н.Б. Борһанова билгеләвенчә, татар теле территориясендә бу лексик берәмлек *абзар/азбар/арбаз* формаларында билгеле. *Абзар* нигездә урта диалект (каз.арт., т. я., минз.) сөйләшләренә хас. Әдәби телгә дә ул шушы сөйләшләрдән кергән; *азбар* формасы киңрәк территориягә тарала: ул, гомумән, мишәр диалекты өчен характерлы. Урта диалектның да кайбер сөйләшләрендә (кас., нкр., перм., нрл., трх.) ешрак *азбар* формасы кулланыла [1: 60–61]. Мишәр диалекты сөйләшләрендә *азбар* сүзе тагын ‘ишегалды’ (рус. двор) мәгънәсен дә бирә ала. «Бу күренеш бигрәк тә сергач, темников, кузнецк һәм касыйм сөйләшләрендә күзәтелә», – дип билгели Н.Б. Борһанова [1: 61].

Язучының әсәрләрендә башка каралты-кура атамаларына да мисаллар табарга була. Әдәби әсәрләрдә *лапас* сүзе үзенең активлыгы белән аерылып тора һәм ул мал-туар абзары булу белән берлектә, хуҗалык эшләрен алып бару өчен төзелгән каралтыларның атамасы. Татар әдәби телендә лапас ‘мал-туар, арба-чана, эш кораллары, утын һ.б.ш. нәрсәләрне кояштан, явым-төшемнән ышыклау өчен, баганаларга утыртылган, авыш итеп ябылган түбәле, бер яки ике ягы да ачык булган корылма (абзар белән рәттән дә, аерым да булырга мөмкин)’ [6: 341] мәгънәсендә килсә, Татар теленең зур диалектологик сүзлегендә аның ‘өсте ябулы ишегалды’ мәгънәсе теркәлгән [7: 454]. Лексеманың сүзлектә норлат сөйләше белән генә чикләнгән бу мәгънәсе Г. Исхакый иҗатында да күзәтелә: Шулай уйланып, моңланып йөргәндә *лапас астында* аз гына ялтырый торган хезмәтче өенең утына күзем төште [2: 140]; Шуннан ул лапас астына кермәсме дип, шунда керсә, өстенә керергә уйлый башладым [2: 83]; Шуны эшләп бетергәч, ишекне бикләп чыгып, күршеләрнең лапаслары артына басып, мәдрәсә яна башлаганны күтәргә тотындылар [4: 222].

Г. Исхакый иҗатында традицион-язма тел янәшәсендә гомумхалык вариантлы да атлый. Каралты-кура атамаларын бирүдә дә язучы бик теләп үз төбәге җәүһәрләрен файдалана.

ӘДӘБИЯТ

1. Борһанова Н.Б. Татар телендә авыл төзелешенә караган лексик-семантик төркемнәре // История диалектологических исследований татарского языка. Казан, 1982. Б. 50–64.

2. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.

4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 448 б.

5. Садыкова З.Р. Названия хозяйственных построек и инвентаря в татарском языке. Казань: Печатный двор, 2003. 212 с.

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

7. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

# AYAZ İSHAKÎ PİYESLERİNDE MİLLİYETÇİLİK

***A.M. Kamalieva*** *(Bartın, Türkiye)*

Гаяз Исхаки – одна из самых влиятельных фигур как в татарской литературе, так и во всем тюркском мире, благодаря своим произведениям и идеям, транслируемым через свои произведения. Считается, что писатель, на раннем этапе своего творчества был под влиянием идей большевиков. Однако со временем он стал пламенным сторонником идеи «тюркского единства», что стало причиной появления некоторых споров вокруг его произведений. Жанр пьесы самый ёмкий, простой и живой путь передачи мыслей и идеологии, которые хочет напрямую донести писатель дочитателя. Исхаки в своих пьесах с самого раннего этапа сохранил и донес идею тюркской националистической мысли. Его пьесы периода раннего творчества – «Ад», «Общество», «Жан Баевич», «Жизнь с тремя женами» направлены в первую очередь на просвещение народа и пробуждения национального самосознания. На более позднем этапе писатель говорит о равноправии для всех тюркских мусульман, проживающих на территории России и рассказывает о борьбе в решении данного вопроса. В пьесах «Среди волн», «Зулейха», «Учитель», «Учительница» выражаются взгляды автора на национальную идею. В поздний период творчества Гаяз Исхаки сконцентрирован на идее «тюркского единства». Драмы «Борьба» и «Олуг/Великий Мухаммед» пронизаны этой мыслью. В драме «Олуг/Великий Мухаммед» особенно свободно и открыто выражается тема нацинальной идеи автора.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, национальная идея, татарская пьеса.

Ayaz Ishaki is one of the names that has influenced all Turkish world as much as Tatar literary circles with his works and ideas he has put forward in these works. In the beginning, the writer thought to be influenced by the Bolshevik thoughts in the course of time that he became an ardent advocate of the «Turkish Union» ideal and this brought some arguments. The play is a field in which thoughts and ideology are presented in the easiest and most vivid way and directly transferred to the viewer / reader. İshaki, in his plays, has developed Tatar / Turkish nationalism from the earliest times by protecting his line of thought. Among his early works, «Doomsday», «Society», «Can Bayeviç» and «Life with Three Women» are the works aimed at raising the public awareness in national issues, especially in education. In the second period plays, the author ask for equal rights for all Muslim Turks living in Russia and tells about the struggles for realizing this. «Inside the Wave», «Züleyha», «Muallim», «Muallime» plays are his works that prioritize these considerations. In his recent works, Ayaz İshakî has adopted the ideology of «Turkish Union» and gave works with this point of view. «Debate» and «Great Muhammad» are the palys that have been written with this thought. In particular, the Ulu Muhammad (Great Muhammad) is the work that he gave at a time when he could express his thoughts freely and could easily reveal the nationalist discourse.
**Key Words:** Ayaz Ishaki, Nationalism, Tatar Play.

## Giriş

Tatar düşünce ve edebiyat dünyasının önemli kilometre taşlarından olan, gerek fikirleri gerekse bu fikirleri uğruna verdiği mücadeleler ile kalıcı izler bıraktığı bugün artık herkes tarafından kabul edilen Ayaz İshakî'nin fikir ve düşünce serüveni hem yaşadığı dönemde hem de daha sonrasında araştırmacılar tarafından tartışma konusu yapılagelmiştir.

Onun iyi bir sosyalist olduğunu, milliyetçi söylemini sadece bu düşünceye hizmet için bir araç olarak kullandığı görüşünü savunan araştırmacılar olduğu kadar, Ayaz İshakî'nin hayatının tüm dönemlerinde gerçek bir milliyetçi olarak mücadele ettiği tezini savunanlar da vardır.

Ancak, Ayaz İshakî'nin gençlik yıllarından son dönemlerine kadar yaşam süreci, mücadeleleri ve verdiği eserler top yekûn nazara alındığı zaman onun gerçek anlamda bir Tatar-Türk milliyetçisi olduğu, «Türk birliği ülküsü» için bütün yaşamı boyunca mücadeleler verdiği net bir şekilde ortaya çıkmaktadır.

Konunun diğer boyutlarını bu çalışmanın dışında tutarak sadece onun piyeslerindeki milliyetçi vurgularını burada sunmaya çalışacağız.

Bu arada piyesleri diğer edebî türlerden ayıran bazı farklı özelliklerine dikkat çekmek gerekirse; bilindiği gibi piyesler sadece okunmak için yazılmaz. Piyesler canlandırılmak üzere kaleme alınan eserlerdir. Yani piyes, roman, hikâye ya da şiir gibi edebî türlerin aksine gösterim (Show) amacıyla kaleme alınır. Bunun için de etkileme gücü diğer türlere nazaran daha yüksektir. Sahnedeki sanatçının içine girebildiği ölçüde bu etki gücü artar. Bir de bu eserlerin verildiği dönemleri düşünürsek, sinema ve televizyon gibi görsel kitle iletişim araçlarının çok yaygın olmadığı ortadadır. Bu sebeple topluma verilecek mesajı olan yazarlar, diğer edebî türler kadar tiyatro türüne de önem vermişler, topluma mesajlarını piyesler üzerinden vermeyi tercih etmişlerdir.

Ayaz İshakî, sanatı sanat için değil de sanatı toplum için kullanan bir yazardır, aynı zamanda düşünce adamı ve aktivisttir. Dolayısıyla o, piyeslerini yazarken, toplumu, bu edebiyat ortamında eğitmeyi de hedeflemiş, «eğlendirirken eğitmeyi» düşünerek eserler kaleme almıştır.

Bu bakış açısı ile kaleme alınan piyeslerde Ayaz İshakî'nin milliyetçilik anlayışı ile ilgili gözlemlerimizi aktarmaya çalışalım[1].

## Ayaz İshakî'nin Milliyetçilik Anlayışı

Ayaz İshakî, yüzyıllar boyu Hristiyan yapılmak için türlü türlü baskı ve zorlamalara maruz bırakılmış, Rus hegemonyası altında ulusal kimliklerini kaybetmeye zorlanmış, tüm bu baskılara rağmen kendi öz benliğini ve varlığını korumayı başarmış Tatar toplumunda yetişmiş bir aydındır. O, bir taraftan ulusal değerlerini korumaya çalışırken diğer taraftan Fransız Devrimi ile birlikte Batı'da başlayan aydınlanma hareketlerini yakından takip eden, okuyan, düşünen ve yorumlayan bir yazardır.

Ayaz İshakî'nin piyeslerinde milliyetçilik konusunu incelerken önce onun nasıl bir milliyetçilik anlayışına sahip olduğuna bakmamız gerekir. Onun milliyetçilik anlayışını anlayabilmemiz için de öncelikle fikir temellerine inerek nasıl bir tefekkür altyapısına sahip olduğunu bilmemiz doğru olacaktır. Ayaz İshaki'nin fikir temellerini oluşturan en önemli iki unsuru şöyle tespit edebiliriz: Birincisi, o, kendi tarih, din, kültür, gelenek ve görenekleri ile ailesinin ve aldığı geleneksel eğitimin birikimi ile iç dünyasında milli kültürünü iyice yoğurmuş ve hazmetmiş bir yazardır. Yani kendi köklerini iyi bilen, benimseyen ve bunlara sahip çıkan bir şahsiyettir. İkincisi de yaşadığı dönemin aydınları üzerinde az veya çok etkiler bırakan, Batı kökenli, modern düşünce arayışlarıdır ki; İshakî'yi bir dönem Bolşevik düşüncenin etkisinde bırakan temel sebep de budur. Okuyan, araştıran ve düşünen bir beyne sahip olan İshakî, «Bolşevizm» ile kendi düşünce iklimine çok daha uygun görünen Batı kökenli «nasyonal sosyalizm» ideolojisi arasında kendi yolunu oluşturuncaya kadar gelgitler yaşamış bir yazardır. Bu sürecin sonunda ise başlangıç ve arayış yıllarından sonra fikrî olgunluğa ulaştığı dönemlerde onu tam bir «Pantürkist» olarak görürüz.

## Piyeslerdeki Milliyetçilik Anlayışı

Ayaz İshakî'nin piyeslerinde nasıl bir milliyetçilik anlayışını savunduğuna genel olarak baktığımızda; yazarın piyeslerinde, ulusal değerler konusunda hassasiyet taşıdığını, Tatar kimliğinin ateşli bir savunucusu olduğunu görürüz.Ona göre milli kimliğin korunması büyük ve kutsal bir ülküdür. Bu ülkünün korunması ve savunulması yolunda hiçbir fedakârlıktan çekinilmemesi gerekir. Tüm Tatarlar önce, ellerinden gasp edilmiş millî haklarının geri alınması için mücadele etmelidir. Ayaz İshakî'de ilk dönemde bu temelle başlayan milliyetçilik anlayışının daha sonraları gelişerek tüm Türk kavimlerinin ortak zeminlerde buluşmasını hedefleyen «Pantürkizm» ya da «Turancılık» ülküsüne doğru evrildiğini görürüz.

---

[1] Bildiri hazırlanırken, «Romantik Milliyetçi Ayaz İshaki» adlı kitaptanda yararlanılmıştır.

## «Ulu Muhammed» Piyesinde Milliyetçilik

Ayaz İshakî'nin 1944 yılında yazımına başlayıp 1947 yılında tamamladığı «Ulu Muhammed» piyesi yazarın son eserlerindendir. İstanbul'da,özgür bir ortamda kaleme aldığı bu eserinde yazar, milliyetçilik konusundaki düşüncelerini de serbestçe dile getirme fırsatını bulmuştur. Bu sebeple basım sırasına göre değil de»Ulu Muhammed» piyesini önceleyerek onun piyeslerindeki milliyetçilik düşüncesini değerlendirmek daha doğru olacaktır.

«Ulu Muhammed» piyesinde Tatar tarihinin en önemli dönemlerinden olan Kazan Hanlığı'nın kuruluşu dramatize edilmektedir. Kazan Hanlığı'nın kurucusu olan Ulu Muhammed'in hayatı ve kahramanlığının konu edildiği piyeste, ana karakter etrafında canlandırılan olaylarla Tatar milli kimliği ve kahramanlık motifleri piyeste etraflıca yer bulmaktadır.

Eserdeki milliyetçi unsurları birkaç ana başlıkta toparlamak gerekirse:

– Tatarların, geçmişte büyük devletler kurarak özgür iradesi ile bölgede hâkimiyet sağlaması vurgulanarak Tatarların tarihine sahip çıkması ve geçmişleriyle gurur duymaları gerektiği vurgulanmaktadır.

– Tarihte bu kadar başarılı olmuş bir milletin kendi öz değerlerine sahip çıkması halinde neler yapabileceği anlatılmak suretiyle Tatarların kendi öz benliklerine dönmesi ve kendi değerlerine sahip çıkması gerektiği düşüncesi savunulmaktadır.

– Özgür bir düşünce ortamında kaleme aldığı bu piyesinde Ayaz İshakî, gayet net bir şekilde Türk Birliği idealine olan inancını açıkça ortaya koymakta ve kahramanların hem tavır hem de sözlü olarak bu düşünceyi savunmalarını sağlamaktadır. Meselâ,piyeste, özellikle Kazan, Altınordu ve Bulgar Türkleri arasındaki sıkı ilişki, karşılıklı dayanışma ve birbirlerine destek olma durumuna vurgu yapılarak «bugün de Türk kavimlerinin birbirleriyle omuz omuza vermesi gerektiği» düşüncesi oluşturulmaya çalışılmaktadır.

– Bilindiği gibi,Tatarlar, Türk soylu uluslar içerisinde Ruslarla gerek coğrafî gerekse kültürel olarak en yakın ve en uzun süreli ilişki kurmak durumunda olan topluluktur. Yazar, bu piyesinde Tatar-Rus ilişkilerine de gönderme yaparak bu ilişkinin tarihte nasıl olduğundan hareketle bugün ve gelecekte nasıl olması gerektiği konusunda öngörüde bulunmaktadır. Bu başlığı biraz açmak gerekirse, eserde, Kazan Hanı Ulu Muhammed'in hâkimiyeti döneminde Rus Knezliği de büyüme gayreti içerisindedir. Bu amaçla Ruslar çevrelerindeki diğer Türk unsurlara saldırılar düzenlemekte ve onlarla savaşmaktadır. Ulu Muhammed bu duruma kayıtsız kalamaz ve müdahale etmeye karar verir. Rus Knezi Vasili'ye elçi gönderir. Ondan bir takım sözler alır. Ancak Vasili bu sözlerinde durmayınca bir ordu kurarak başına kendi oğlunu geçirir ve Rusların üzerine gönderir. Rus knezini esir alır. Ancak Rusların sözlerine durmamalarına karşılık Vasili'ye gayet iyi davranmak suretiyle asil bir duruş sergiler. Esir aldığı Vasili'ye herkesin önünde yemin ettirerek tekrar Rusların başına geçirmesi ise; geçmişte Tatarların Rusların üzerindeki hâkimiyetinedikkat çekmektedir. Ayrıca bu yaklaşım ile Tatarların kaba kuvvetten ziyade akıl, mantık ve siyasî manevralar ile de yetenekli bir millet olduğuna vurgu yapılmaktadır. Tatar-Rus ilişkileri konusunda, eserdeki temel yaklaşım,»Tatarların kendi milli kimliklerini korumak kaydıyla Ruslara karşı hep dostça bir yaklaşım içerisinde oldukları, ancak çoğu zaman buna olumlu karşılık göremedikleri» şeklinde özetlenebilir.

– Eserde, kendi ulusal kimliğine sahip çıkmakla birlikte, başta Türk soylu milletler olmak üzere herkesle dostça ve kardeşçe yaşama isteğide dile getirilmektedir ki; bu durum Ulu Muhammed'in Kazan'a girdiği sırada karşılaşacağı tablo ile ilgili duyduğu endişeler içerisinde dile getirilir. Ulu Muhammed, Kazan'ı fethedipgirdiğinde özellikle Türk soylu kabilelerin nasıl davranacağı konusunda endişe içerisindedir. Ancak onların kendiliğinden gelerek ona tabi olmaları Muhammed'i rahatlatır.

– Eserde ulusal sembollere bağlılık ve saygı konusunda da motifler işlenerek millet ve milliyetçilik şuuru benimsetilmeye çalışılmaktadır. Yazıldığı döneme göre, dile getirilmesi bile sakıncalı olabilecek olan ulusal değerlerden birisi olan «bayrak» konusunda eserde yapılan göndermeler yazarın bu değerlere bağlılığı konusundaki en açık göstergelerden bir tanesidir [2: 31].Yazar bu semboller etrafında içten içe bağımsızlık ve ulusal birlik konusundaki özlemini de ifade etmektedir.

– «Ulu Muhammed» piyesindeki milliyetçi söylemler ile ilgili en önemli tespitlerimizden birisi de şudur ki; yazarın salt ırk kökeninde birliktelik arayan bir milliyetçilik kavramının ötesinde kültürel unsurları da değerlendiren ve «kültür birliği» söylemine dayanan bir milliyetçilik anlayışının peşinde olduğudur. Bu noktada onu, özellikle dinî motiflere ve dinî değerlere sahip çıkan bir yaklaşım içerisinde görürüz. Piyesin başkahramanı «Ulu Muhammed» aynı zamanda dindar bir karakter olarak verilir. O, ülkesini İslam dininin güzellikleri, hak ve adalet anlayışına göre yönetmeye çalışan bir karakterdir. Ogünkü Tatar toplumu da dinî değerlerine gönülden bağlı insanlardır. Mesela, devletin başına itaat etmeyi dinî bir vecibe olarak görür ve ona göre hareket ederler. Yine aynı şekilde vatanı düşman işgalinden korumak aynı zamanda dinî bir sorumluluk ve kutsal bir vecibedir. İshakî, bu benzeri dinî motifleri milliyetçi bir bakış açısı ile «Ulu Muhammed» piyesinde işlemiştir [2: 45].

«Ulu Muhammed» piyesinde milliyetçilik ile ilgili bu ana tespitlerimizin dışında ulusal değerler için mücadele etmeyi telkin eden, gerektiği zaman düşmanla savaşmaya hazır olmayı tavsiye eden, ülkenin, devletin ve milletin korunması için gerektiği zaman canını tehlikeye atmanın gerekliliğini savunan söylemlere sıkça rastlamak mümkündür.Bu durum da eserde milliyetçi bakış açısını açıkça göstermektedir [2: 54].

Eserde, Tatarların atalarının Bulgarlar, onların da atalarının Türkler olduğu fikrine de yer verilmektedir.

### «Züleyha» Piyesinde Milliyetçilik

Ayaz İshakî'nin milliyetçi söylemine geniş yer verdiği ikinci önemli eseri ise «Züleyha» piyesidir. Bu piyeste yazar, uzun zamandan beri Tatarlar üzerinde bilinçli bir şekilde uygulanmakta olan zorla Hristiyanlaştırma ve Ruslaştırma politikalarını eleştirir. Bu eserde öne çıkan milliyetçi unsurları şöyle özetleyebiliriz:

– Züleyha, okuma yazması olmadığı halde zengin bir kültürel birikime sahiptir. Bu yönüyle Tatar toplumunun zengin kültür mirasına göndermeler yapılmaktadır.

– Hristiyanlaştırma ve Ruslaştırma baskılarına karşı cahilliğine rağmen ciddi bir direnç göstermektedir. Bu yönüyle milliyetçi bir duruşa sahiptir.

– Züleyha, tüm Tatar kadınlarında olduğu gibi fedakâr, zeki, çalışkan ve sabırlıdır. Bu gibi üstün özellikler Züleyha'nın şahsında toplu olarak verilmek suretiyle eserde Tatar kadını yüceltilmektedir.

– «Züleyha» piyesinde dinî motifler de ön plandadır. Eser bu yönüyle de ulusal birliğin en önemli unsurlardan birisinin dinî değerler olduğu tezini işlemektedir.

– Eserde Rus baskı ve zulmüne direnen başkahraman Züleyha ve Selimcan başta olmak üzere diğer kahramanlar yüceltilerek verilmektedir. Bu durum eserin baştan sona milliyetçi duygular içinde kaleme alındığının en açık göstergesidir.

– «Züleyha» piyesi ile ilgili en önemli tespitlerimizden birisi de, yazarın Rus baskı ve zulmünü anlatırken, hiçbir zaman Rus milletini kötüleyici ve aşağılayıcı bir üslup içine girmediğidir. Ona göre kötü olan Rus halkı değil, o günün Rus yönetimidir. O, hiçbir milleti kendi ulusundan daha aşağı görmeyen pozitif bir milliyetçilik anlayışına sahiptir [3: 542].

### «Tartışma» Piyesinde Milliyetçilik

«Tartışma» piyesi, gerek olay kurgusu gerekse içerik açısından yazarın diğer piyeslerinden farklıdır. Ayaz İshakî bu piyeste aslında kendisini anlatır. Bu piyesi,

yazarın en çok Bolşevik düşüncenin etkisinde kalarak yazdığı eseri olarak da değerlendirmek mümkündür. Çünkü «Tartışma», adından da anlaşılacağı üzere, mevcut yaşam düzeninin tartışıldığı yerine yeni bir düzenin kurulması gerektiği düşüncesini irdeleyen bir piyestir. Piyesin kahramanı Zakir mevcut düzenden memnun değildir. Düzenin baskıcı ve zorba bir yönetim tarzı olduğunu düşünmektedir. Tabii ki burada kastedilen rejim Çarlık yönetimidir. Zakir, arkadaşlarıyla birlikte gizlice siyasî bir örgüt kurarak rejimi değiştirmeyi amaçlar. Yeni kurmayı düşündükleri rejim Bolşevik bir rejim olacaktır. Burada bizi ilgilendiren en önemli husus, yazarın bu düşünceyi savunurken «milliyetçi» bir söylemden asla vazgeçmemiş olmasıdır. O, Bolşevik rejimin gelmesi halinde Tatar milletinin özgürlük ve refahının artacağını, Ruslarla kardeşçe ve eşit şartlarda bir yaşam düzeninin kurulacağını varsaymakta ve Bolşevik düşünceye bu amaçla sarılmaktadır. Piyeste Zakir ve arkadaşları istedikleri devrimi gerçekleştirirler. Ancak bu devrimin sonuçları hiç de istedikleri gibi olmamıştır. Daha fazla özgürlük beklerlerken, daha baskıcı ve katı bir rejimle karşı karşıya kalırlar. Zakir ve arkadaşları hayal kırıklığı yaşarlar. Yeni bir dünya düzeni için arayışlara girerler.

«Tartışma» piyesi, Ayaz İshakî'nin kendi fikir gelişimini sorguladığı ve olgunlaştırdığı piyesidir ve bu yönüyle onun fikir ve sanat yaşamındaki önemli dönüm noktasını oluşturur. Gençlik rüzgârlarının etkisiyle içine girdiği hayallerin etkisiyle verdiği mücadelenin boşa gitmesi onu daha «ulusçu» bir çizgiye doğru taşımıştır.

**«Muallime» Piyesinde Milliyetçilik**

Ayaz İshakî'nin milliyetçi duygular içerisinde kaleme aldığı bir başka önemli piyesi «Muallime»dir. Bu piyeste yazar bir «kültür milliyetçisi» olarak karşımıza çıkar. Bu piyeste Tatar milli kültürünü, örf ve ananelerini, Tatar millî şuurunu benimseyen ve bu değerleri Tatar çocuklarına aktarmak suretiyle gelecek kuşakları kendi milli benliğine bağlı olarak yetiştirmeyi amaçlayan bir Tatar kızının öğretmenlik serüveni anlatılır. Bu idealleri yürekten benimseyen Fatma öğretmen, hayallerini gerçekleştirmek için cesur bir şekilde Sibirya'da görev alır. Burada tanıştığı Abdullah öğretmen de benzer düşünceler taşımaktadır. İki genç ve milliyetçi karakter Tatar halkının geleceğinin, gelecek kuşakların iyi yetiştirilmesiyle sağlanacağına inanırlar. Bunun için de millî şuura sahip, kültürlü, aydın gençler yetiştirmeye yönelmişlerdir.

**Diğer Piyeslerinde Milliyetçilik**

Konuları ve işlediği temalar farklı olsa bile, milliyetçi motifleri Ayaz İshakî'nin tüm piyeslerinde görmek mümkündür. Meselâ, «Can Bayeviç» piyesinin ana kahramanı seçilen ve piyese adını veren Can Bayeviç, sürekli kendisini Ruslara benzetmeye çalışan özentili bir karakterdir. Bu yaklaşımıyla da sürekli komik durumlara düşer ve alay konusu olur. Karısı Sahipcemal ise kendi öz benliğine ve kültürüne sahip çıktığı için tüm piyes boyunca yüceltilir ve takdir edilir. Sahipcemal kocasının içine düştüğü bu durumdan da sürekli rahatsızlık duymaktadır. Piyeste yer bulan üçüncü ana karakter olan Rus kadını Marca, «kötü bir kadın» olarak tanımlanır ve olumsuz bir karakter olarak verilir.

Ayaz İshakî'nin «Kıyamet» ve «Cemiyet» piyesleri aslında birbirine benzer. Eski-yeni çatışmasının işlendiği ve «yeninin savunulduğu» bu iki piyes de aynı milliyetçi bakış açısıyla kaleme alınmıştır. Yazar her iki piyeste, Tatar toplumunun geçmişten getirdiği bir takım yanlış davranışlarını göz önüne sermekle beraber, esasen «Tatar toplumunun nasıl daha iyi bir geleceğe ulaşacağı» konusunda kafa yormaktadır. Bu eserlerde modernleşme ve yenileşmenin Tatar toplumunun geleceği için önemi vurgulanmakta, özellikle eğitimin büyük önem taşıdığı anlatılmaktadır. Her iki eser de bu yönleriyle yazarın milliyetçi yaklaşımının ürünüdür.

## Sonuç

Ayaz İshakî, sanatı sanat için değil sanatı toplum için kullanmayı hedefleyen bir anlayışla piyeslerini kaleme almıştır. O, piyeslerinde Tatar kültürünü, Tatar gelenek ve göreneklerini, Tatar milli değerlerini ve nihayet Türk birliği mefkûresini halka anlatmak ve benimsetmek amacını taşımıştır. İshakî, yaşamı boyunca Tatar toplumunun bağımsız, özgür ve müreffeh bir toplum olması için mücadele etmiş, bunu eserlerine yansıtmış bir mücadeleci, aydın ve yazardır. Bütün piyeslerine yansıyan temel düşünce budur.

Ayaz İshakî, baştan beri milliyetçilik ideolojisini savunmuş bir yazardır. Fakat özellikle devrim yıllarında Batılı karşılığı «nasyonal sosyalizm» olan milliyetçi bir sosyalizmi benimsemiş, daha sonraları bu düşüncesini olgunlaştırarak, fikir babalığını İsmail Gaspıralı, Yusuf Akçura ve Zeki Velidi Togan gibi Tatar aydınlarının yaptığı modern anlamda Türk milliyetçiliği ideolojisini benimsemiş bir aydın-yazardır.

O, piyeslerinin tamamında milliyetçilik düşüncesini işlemekle birlikte, ilk dönem eserlerinde, milliyetçiliği eğitim yoluyla halka benimsetmeye çalışmıştır. «Kıyamet», «Cemiyet», «Can Bayeviç» ve «Üç Kadın ile Hayat» piyesleri bu dönemde kaleme alınmış ve halkı, eğitim başta olmak üzere millî konularda bilinçlendirmeyi hedef alan eserlerdir. Yazar, ikinci dönem piyeslerinde, Rusya'da yaşayan bütün Müslüman Türkler için eşit haklar sağlanmasını isteyen ve bunun için verilen mücadeleleri anlatan ve yine mücadeleye devam edilmesini telkin ve tavsiye eder. «Dalga İçinde», «Züleyha», «Muallim», «Muallime» piyesleri bu kategoride değerlendirilebilir. Son dönem eserlerinde ise Ayaz İshakî'yi tamamen «Türk Birliği» ideolojisini net bir şekilde savunurken görürüz, yazar bu dönem eserlerinde İdil-Ural Türklerinin müstakil bir devlet kurmaları gerektiği fikrini savunur. Bu dönem eserlerinde Tatar halkının bağımsızlık ve özgürlük düşüncesini açık bir şekilde savunmayı da sürdürür. «Tartışma» ve «Ulu Muhammed» bu düşünceyle kaleme alınmış piyeslerdir.

KAYNAKÇA

1. Akış Ali. Gayaz İshakıy: «Milli Azatlık Hereketinin Büyük Yulbaşçısı» // Kazan Utları. Sayı 2. 1994. Sayfa 152.

2. Исхакый Гаяз. Олуг Мөхәммәд. Тарихи драма (Кереш суз) // Мирас. 1991. № 1.

3. Исхакый Гаяз. Зарыгып көткән мирас. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

4. Kamalieva Alsu M. Romantik Milliyetçi Ayaz İshaki. Ankara: Grafiker, 2009. S. 248.

5. Мусин Ф.М. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛИ ҺӘМ СӘЯСИ МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

***Г.Ф. Каюмова*** *(Казан)*

Практически во всех своих произведениях Гаяз Исхаки отражает свою веру в ислам, описывая самые красивые образы религиозных деятелей того периода. Писатель борется за права и национальное достоинство татарского народа, он подчеркивает равноправие татарского народа среди сообщества других народов и национальностей.
**Ключевые слова:** Г. Исхакий, нация, татары, произведения, религия, обычаи.

In almost all of his works, Gayaz Iskhaki reflects his faith in Islam, describing the most beautiful images of religious figures of that period. The writer fights for the rights and national dignity of the Tatar people, dedicated to the struggle for freedom and their rights. The author emphasizes the equality of the Tatar people among the community of other peoples and nationalities.
**Key words:** G. Iskhaki, the nation, the Tatars, works, religion, customs.

Халыкны халык итә торган шушы әхлак, дин, әдәп кебек иң мөһим мәсьәләләр барлык галимнәрне, дин әһелләрен, сәясәтчеләрне һәм, гомумән, бөтен кешелек җәмгыятен һәрчак борчыган, борчый һәм борчыячак. Бөтен гомерен патша заманында Татарстаннан, совет чорында хәтта Рәсәйдән дә еракта, чит мәмләкәтләрдә үткәрергә мәҗбүр булган Гаяз Исхакый да үзен татар халкының бәхете, милли азатлыгы өчен көрәшүгә багышлый. «Милләте өчен аның шикелле җан атып тырышкауган халкы мәнфәгатен барлык нәрсәдән дә өстен куйган фидакарь шәхесләргә тоталитар режим беркайчан да миһербанлы булмады» [8: 13]. Шундый авыр шартларда да Гаяз Исхакый, төшенкелеккә бирешмичә, Аллаһның барлык сынауларын да горур үтеп, милли бәйсезлек, дини азатлык өчен сәяси һәм иҗтимагый эшләрдә катнашып та, үзенең үткен һәм туры каләме белән дә дин өчен, милләт өчен, әхлак өчен көрәшә. Г. Исхакый үзенең язмасында: «Халкыбызның өсте-башы бөтен, ашы-суы иркен, йөзе-күзе күркәм, көе-җыры көчле, сүзе-сазы татлы, кыланышы-килеше җайлы, йөрешебарышы тугъры булыр дип күңелем төшми, дәртем кайтмый, ышанычым бетми» [8: 19]. Шушы сүзләренә ул гомере буена тугрылыклы кала.

Изге китап Коръәннең «Әл-Бәкара» сүрәсендәге 148 нче аятендә ошбу сүзләр язылган: «һәр милләтнең үз кыйбласы бар, һәрберсе үз кыйбласына юнәлер. Ләкин мөшрикләрнең кыйблалары батыл (ялган). Әмма мөселманнарның кыйбласы хак кыйбладыр. Сез, мөселманнар, яхшы эштә ярышыгыз һәм алга чыгыгыз! Кайда гына булсагыз да, Аллаһ барыгызны да хөкем итәр өчен, бер урынга җыяр, әлбәттә, Аллаһуның һәрнәрсәгә көче җитәдер» [2: 148.] Г. Исхакый, Алланың шул әмерен үтәргә теләп, татар халкының кыйбласын – бәхеткә илтүче юлын дөрес билгеләп, гомере буе шул юлыннан тайпылмыйча, халыкны да шул юлга өндәгән. «Шунысы гыйбрәтле: Гаяз Исхакыйны милли-азатлык көрәшеннән зиндан-сөргеннәр дә, эмиграция дә, төрле эзәрлекләүләр, ялалар да – берсе дә туктата алмады, ул үз идеалына тугры калды, үз халкына бәйсезлек киләсенә инанган килеш вафат булды» [6: 203]. Язучының әсәрләрен укып әхлагыбызны үстерәбез, белемнәребезне баетабыз, иманыбызны ныгытабыз.

Барлык әсәрләрендә дә диярлек ислам диненең хак дин булуын исбатлаган, дин әһелләренең иң матур үрнәкләрен күрсәткән: «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Зөләйха», «Локман Хәким», «Олугъ Мөхәммәд», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һ. б., шул ук вакытта гаделлеккә каршы чыгып, халык бәхетенә аяк чалучы, ислам дине кануннарын бары үз мәнфәгатьләре өчен куллanучы, үзләрен чын мөселман дип атаучы имансыз, надан дин әһелләрен фаш итеп, чын йөзләрен ачып биргән: «Җан Баевич», «Алдым-бирдем», «Тартышу», «Җәмгыять» һ.б. Г. Исхакыйның әсәрләре бүген дә бик актуаль. Язучының һәр әсәре татар халкының бай, кыйммәтле ядкяре булып тора. Бу әсәрләр чал тарихыбызны дөрес итеп сурәтләп бирә, гореф-гадәтләребезне, милли үзенчәлекләрне чагылдыра, үткәннәргә таянып, киләчәк турында уйланырга мәҗбүр итә, Алладан ярдәм сорап, бәхет өчен бары үзебезгә көрәшергә өнди. Һич кичекмәстән, Г. Исхакыйның фикере белән тулысынча килешергә мөмкин: «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!» [7: 3]. Г. Исхакый татар халкының укымышлы, максатына ирешүчән, горур табигатьле милләт булуы белән, башка халыклар арасында да тигез хокуклы булып яшәргә тиеш булуын ассызыклый [1: 50]. Моның өчен ислам диненнән, гореф-гадәтләрдән, тарихи хәтеребездән читләшмәскә кирәклегенә басым ясый. Г. Исхакый искәрткәнчә, милләтебезне, әхлагыбызны саклап калу өчен, рухи кыйммәтләребезне баету өчен, халыкка хезмәт итү юлына баскан һәркем нык иманлы, саф күңелле, алдынгы карашлы, максатчан кеше булырга, барлык киртәләрне җиңеп чыга

белергә тиеш. «Аракы бәласе» исемле мәкаләсендә автор татар дөньясына бу афәтнең татар милләте өчен гаять куркыныч булуы хакында фикер йөртә, милләт булып яшәү өчен, иң элек мәдәниятне, мәгариф системасын, матбугатны, сәнгатьне үстерергә һәм иң мөһиме – аек булырга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Аның фикеренчә, дөньяга аек караш кына милләтне үстерә. Язучы, милләтне инкыйраз авыруыннан саклап калу максатында, аның игътибарын халыкның милли яшәешенә, күркәм гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, нәселнәсәбенә, борынгы тамырларына юнәлтә. Әдипнең шул максатны күздә тотып язылган «Солдат» (1908), «Очрашу яки Гөлгазар» (1902) повестьлары, «Кияү» (1911), «Шәкерт абый» (1911), «Сөннәтче бабай» (1910–1911), «Татар гакылы» (1910), «Мәдрәсә җимеше» (1910), «Башкорт бәхете» (1910), «Көтелгән бикәч» (1910), «Мансур» (1909), «Кәҗүл читек» (1912), «Борынгы шәкертләр» (1909), «Күк капусы» (1909), «Корсак» (1909), «Хәлимә туташ» (1908), «Корбан гаете» (1908), «Калуш» (1909) хикәяләре татар тормышының төрле якларын һәм халыкның милли үзенчәлекләрен, проблемаларын яктырта.

Бу нисбәттән Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» повесте аерым игътибарга лаек. Әсәрдә нәселе Мөхәммәд галәйһис-сәламнең үзенә барып тоташкан карт дөнья куя. Дөньядан иртә китүенең сәбәпчесе пычрак, ялкау һәм затсыз бер карчык булса да, Сөннәтче бабайның үлеме милли хәтер, тарихи хәтернең үлеменә, югалуына, юкка чыгуына тиң булган иҗтимагый-сәяси фаҗига төсмерен ала һәм аерым бер кешенең физик яктан яшәүдән туктау чикләреннән узып китә. Ягъни, Сөннәтче бабайның вафаты гади генә түгел, ул буыннар бәйләнешенең өзелеп юкка чыгуы дигән сүз дә. Сөннәтче бабай үзе үлсә дә, ул изге эшен хәзрәтнең улына васыять итеп тапшырып калдыра: димәк, эле сөннәтләү йоласының дәвам итүенә зур ышаныч бар, чөнки хәзрәтнең улы мәхдүм – дини гаиләдә тәрбияләнгән акыллы, зирәк бала. Сөннәтче бабай йортындагы тормыш иң югары дәрәҗәдәге ислам дине кануннары, әхлагы белән сугарылган. Сөннәтче бабай һәм аның карчыгы Гөлйөзем әбинең авызыннан Алла сүзе өзелми, алар бөтен җаны-тәне белән Алланы сөяләр, Аңа гына буйсыналар, Аңа гына шөкер итәләр. Аларның шул ихласлылыгы әсәр укучыга да уңай тәэсир итә, күңелләрне эретә, мәңгелек турында җитди уйланырга мәҗбүр итә.

Гаяз Исхакый әсәрләрендә гаилә тормышын сурәтләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Җәмгыятьнең бер күзәнәге буларак, гаилә-җәмгыятькә файда китерерлек кешеләрне тәрбияләүдә иң зур роль уйнаучы фактор. Бала тәрбиянең, аң-белемнең нигезен гаиләдә алырга тиеш. Шәхес формалашуда төп рольне уйнаучы гаиләнең балага уңай яки тискәре йогынтыларын күрсәтеп, әсәр укучыларны бу проблемаларга җитдирәк карарга этәрә. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, Гаяз Исхакыйның үзенә дә гаилә тәрбиясе бик зур йогынты ясаган: ул татарның мәгърифәтле, мәдәни гаиләсендә туа, эти-әнисенең җылы кочагында тәрбияләнә, сабый чагында ук авыл җиренең шифалы һавасы, бай матур табигате – урман-кырлары, елга-күлләре тәэсирендә, туган халкының гореф-гадәтләре, милли традицияләре белән рухи азыкланып үсә.... Билгеле инде, иманы зәгыйфь булган җәмгыятьтә әдәпсезлек, берәүләрнең рәхимсез изелүе нәтиҗәсендә икенче берәүләрнең шартлап баюы, исереклек, фахишәлек, җинаять һәм башка бик күп проблемалар хөкем сөрә башлый. Ә болар, үз чиратында, төрле куркыныч авыруларга, балалар ятимьлегенә, гаиләләр таркалуга, бөтен бер халыкның әкренләп юкка чыгуына китерә. Бу коточкыч проблемаларны Гаяз Исхакый йөз ел элек үк күтәреп чыга: «Иң кайгылысы шул иде: халкымыз әхлак җәһәтеннән бик бозылган иде. Казан халкы бөтенләй этлеккә салынган иде. Көндезләрен вак-төяк сату иткән булып маташалар да, кичәләрендә гостиницалар, пивной вә фәхеш урыннарында кичләр үткәреләр иде, исереклек шул дәрәҗә тәрәкъ-

кый иткән иде!!. Әйтеп бетерерлек түгел. Зина, фәхеш тә иң кабахәт дәрәҗәдә патшалык сөрүдә иде. Һәр йердә башы ачык ислам кызлары, мөселман хатыннары күзгә күренә иде, бу эшләрнең бу кадәр артуына сәбәп тә халкымыз арасында эчү вә исереклекнең артуы иде. Ирләремез көне-төне кәсеп иткән акчаларын хатыннарына, балаларына алып кайтыр урынында фахешханәләрдә яки мәйханәләрдә вакытларын үткәрдекләреннән, хатыннары теләр-теләмәс, тамак туйдырыр өчен булса да, фахеш юлына кереп китәләр иде» [3: 175–176].

Шунысы үкенечле: әдип йөз ел элек күтәреп чыккан милләтебез проблемалары бүгенгәчә яшәп килә. Әлеге упкыннан чыгу юлы бер генә: Аллаһ боерган юл – исламның асыл кануннары белән яшәү. «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендә аң-белемле ата-ананың төпле тәрбиясе балага уңай тәэсир иткәнлеге сурәтләнсә, «Бай углы»нда исә, киресенчә, Үзләре дә ныклы белем һәм тәрбия алмаган Фатыйх бай белән хатыны Сәгыйдә бердәнбер уллары Кәримне аздыруга, һәлакәткә китерүгә төп сәбәпче булалар. Әсәрдә үзләрен чын мөселман дип күрсәтүче, ә чынлыкта мәҗүсилек белән шөгыльләнүче имче-томчы, багучы карчыклар, надан остазлар фаш ителә. «Мәдрәсә җимеше» хикәясендә бу проблемага ныграк басым ясала. Авылга яңа указлы яшь мулла Хәйдәр киләчәген белгәч, барлык кызлар остазбикә булырга хыялланалар. Хәйдәр, байлыкның бар нәрсәдән дә өстен булуына ышанып, авылның иң бай кәләше Сорурга өйләнә. Бөтен кеше Сорурга көнләшеп карый. Ләкин үзен иң бәхетле итеп тойган Сорур Хәйдәрнең мәдрәсәдә укыганда ирлек сыйфатыннан мәхрүм калганын белгәч, тирән кайгыга бата. Аның уй-кичерешләре каршылыклы була. Бер яктан, ул гомер буе ирле кыз булып гомер кичерү куркынычы алдында кала. Икенче яктан, Хәйдәрдән аерылса, ул зур мәшәкать белән бирелгән остазбикәлек урыныннан мәхрүм калырга тиеш була. Әлбәттә, байлыкка, дан-шөһрәткә омтылган Сорур остазбикәлектән ваз кичәргә теләми. Ләкин шул ике теләген дә тормышка ашырырга омтылуы аны зур гөнаһ кылуга этәрә: ул үзләрендә хезмәтче булып эшләгән таза егет Зариф белән үзенең хатын-кызлык теләкләрен канәгатьләндерә башлый. Бу хәлне Хәйдәр дә белеп ала, ләкин моңа каршы чыга алмый. Бераздан бу гаиләдә бер-бер артлы балалар туа. Алар үсеп җиткәч, «бер хатынга ике ир, бер балага ике ата багышланган тормышка бер кияүгә ике бала, бер кодага ике кода багышларга гына калды» дип, автор үз әсәрен юмористик рухта төгәлли [4: 126].

«Башкорт бәхете» һәм «Көтелгән бикәч» хикәяләрендә яшьләрне алдан бер-берсен күрми һәм белми өйләндерү гадәтенең аянычлы нәтиҗәләргә китерүе турында сөйләнә. «Башкорт бәхете» хикәясендә солдаттан кайткан башкорт егетенең фаҗигасе сурәтләнә. Әнисе аны моңа кадәр күрмәгән, белмәгән башкорт кызына өйләндерә. Тик кәләш әле хисләре һәм теләкләре дә тумаган ун-унөч яшьлек кечкенә буйлы кыз булып чыга. «Көтелгән бикәч» хикәясендә, шундый ук юл белән өйләнеп, Вәли бәхетсезлеккә дучар була. Ул кечкенә чагында үзенә ярәшеп куелган хәзрәт кызы Ләлә белән очрашуга ныклап әзерләнә. Булачак кәләшенең моннан дүрт йөз чакрымдагы шәһәрдә яшәве сәбәпле, егет аны өйләнешкәнчегә кадәр күрә алмый. Ул күңелендә шушы кызның илаһи образын тудыра. Шундый кызга тиң булыр өчен, бик тырышып укый, Корьәнне яттан өйрәнә, Гарәбстанга да китеп укый. Туган иленә кайткач, озын чәчле, зифа буйлы, чибәр Ләлә белән очрашуын сабырсызланып көтә башлый. Туй көне килеп җиткәч, ул Габдрахман хәзрәт өенә килә һәм чын Ләйлә белән очраша. Кәләше турында булган барлык хыялларының җимерелүе Вәлинең йөрәге ярылып үлүенә китерә.

Гаяз Исхакый, татарларның күркәм гореф-гадәтләрен, тормыш рәвешләрен сурәтләү белән бергә алрның кимчелекләрен дә фаш итә, инкыйразга китерүче

төп сәбәпләрне «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902) хыялый-публицистик повестенда аеруча тулы яктырта. Әдип милләтнең алга китүен тоткарлаучы биш төп сәбәпне билгели: иске карашлы руханиларның, ишаннарның яңалыкка каршы булулары, динне үз мәнфәгатьләре өчен генә куллланулары; мәдрәсәләрнең, мәктәпләрнең юклыгы, булганнарында да эшкә яраксыз фәннәр укытылуы; милләткә хезмәт итәрдәй кешеләрнең, бик фәкыйрь сыйныфтан чыгып, вакытларын, көчләрен тамак туйдыруга сарыф итүләре; халыкның бик надан булуы, рус мәктәпләрендә укытыла торган дөньяви фәннәрнең мәктәп-мәдрәсәләрдә урын алмавы; кылган гамәлләрнең дәвамсыз, нигезсез булуы.

Әдип күп кенә дин әһелләренең, ишаннарның надан, әхлаксыз булуларыннан, ислам тәгълиматына җиңелчә генә карауларыннан ачы итеп көлә: «Әхлак җәһәтеннән Казан халкы тагы артка калдылар. Бик күп кешеләр тәһзибе әхлак (әхлак төзәтү) өчен дип, төрле тарикатьләргә (ишанлык юлы, дини юнәлеш) керсәләр дә, әхлак көннән-көн бетүдә иде, моның да сәбәбе «һәр начарлык намаз укыгач бетә, ишаннар – оҗмах юлын күрсәтүчеләр», мәсьәләләренә бик каты ышанып, ишанга кергән кеше никадәр начарлыклар кылсалар да, кыямәт көнендә котыладыр игътикады урынлаштыгыннан, һәр кеше оҗмах юлын үзем беләм дигән кебек, теләсә ни кылуыннан иде» [3: 182–183].

Чыннан да, үзләрен бик белдекле, саф күңелле итеп күрсәтүче надан, бозык ишаннар, руханилар һәм башка кайбер дин әһелләре тынычлык, тигезлек, татулык, гаделлек, югары әхлак кебек күркәм сыйфатларны гына хуп күргән ислам динен үз мәнфәгатьләре өчен генә кулланалар. «Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә» [3: 221].

Кызганычка каршы, бүгенге җәмгыятебездә дә андыйлар бик күп, алар ислам мораленең, әхлакый сыйфатларның үсүен тоткарлыйлар, массакүләм чараларның мөселманнар турында, шул рәвешле ислам дине турында да ялган фикерләр таратуына этәрәләр. Хәм бу урында Г. Исхакыйның фикере белән килешәбез дә: «Ике йөз елдан соң иңкыйраз» әсәрендә әлеге әхлакый мәсьәләләргә тап буласын.

ӘДӘБИЯТ

1. Габидуллина Ф.И. Проблемы изучения жанровой природы татарского романа // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. Ч. I. № 7 (25). 2013. С. 49–51.
2. Исхакый Г. Аракы бәласе // Мирас. 1988. № 12. Б. 25–28.
3. Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз. Повесть // Исхакый Гаяз. Әсәрләр: 15 томда. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 332 б.
4. Исхакый Г. Мәдрәсә җимеше. Хикәя // Исхакый Гаяз. Әсәрләр: 15 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 243 б.
5. Коръән Кәрим китабы (тәфсире һәм укылышы белән). Казан: Иман, 2009.
6. Миңнегулов Х. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. 302 б.
7. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан, Татар. кит. нәшр., 1998. 215 б.
8. Нуруллина Р. Г. Исхакый // Заман – Татарстан. 1998. 20 фев., № 8. Б. 13–19.

## İDİL-URALLI BİLİM ADAMLARININ TÜRKİYE'DE TARİHÇİLİĞİN GELİŞİMİNE KATKISI

***İlyas Kemaloğlu*** *(İstanbul, Türkiye)*

Тюрки Поволжья и Урала много раз в истории были вынуждены эмигрировать на турецкие земли. Среди тюрков Поволжья и Урала, эмигрировавших сначала в Османскую империю, потом в Турцию, было много ученых. Так, часть ученых благодаря специальному государственному приглашению или в результате личных усилий обосновалась в Турции. Юсуф Акчура, Садри Максуди Арсал, Хамит Зубеир Кошай, Рашит Рахмети Арат, Муса Акъегетзадэ, Ахмет Темир, Заки Валиди Тоган, Акдэс

Нимэт Курат, Гаяз Исхаки – главная часть из ряда этих ученых. Несомненно, кроме этих можно было бы перечислить еще много имен. В данной статье будут рассматриваться ведущие ученые – выходцы из Поволжья и Урала, создавшие труды по истории и внесшие свой вклад в создание научных учреждений в Турции; оцениваться роль, которую они сыграли в развитии исторической науки в Турции.
**Ключевые слова**: тюрки Поволжья и Урала, Турция, Гаяз Исхаки, Юсуф Акчура.

Idil Ural Turks have had to emigrate many times today's Turkey throughout history. There were a great number of scholars among those Idil Ural Turks arriving to the Ottoman Empire and the subsequent Turkey. Besides, some of them have come to live in Turkey with exclusive invitation or in individual effort. The prominent ones are Yusuf Akçura, Sadri Maksudi Arsal, Hamit Zübeyr Koşay, Reşit Rahmeti Arat, Musa Akyiğitzade, Ahmet Temir, Zeki Velidi Togan, Akdes Nimet Kurat and Ayaz İshakî. There are still surely numerous figures to regard apart from them. In this report, it will be discussed the leading Idil Ural-born scholars who have given works in the field of history and contributed to the establishment of scientific institutions in Turkey, and further, the roles those of who have played for the development in the science of history in Turkey will be evaluated.
**Key words:** Idil Ural Turks, Turkey, Ayaz Ishaki, Yusuf Akçura.

Özellikle XIX. yüzyıldan itibaren İdil Ural Türkleri gerek toplu gerekse de bireysel olarak Anadolu topraklarına göç etmeye başladılar. Kazan ile Astrahan hanlıklarının ele geçirilmesinden sonra Rusların bölgede başlattıkları Hristiyanlaştırma ve Ruslaştırma politikasının devam etmesi; dinî ve sosyo-ekonomik alanlardaki baskı; 1890'da Rusya Dışişleri Bakanlığı'nın Rusya Müslümanlarının dinî nedenlerden dolayı yurtdışına göç edebileceklerini ilan etmesi, 1891'de yaşanan kıtlık; 1892'de II. Abdülhamit'in Rusya'dan birkaç bin Müslümanın Osmanlı topraklarına göç etmelerine izin vermesi; amacının Hristiyanlaştırma ve Ruslaştırma olduğu düşünülen 1897 tarihindeki nüfus sayımı gibi sebepler İdil Uralllı Müslümanların Osmanlı topraklarına göç etmelerine neden oldu. Tatarların Anadolu'ya göçleri XX. yüzyılda da devam etti. İdil-Ural Türklerine yönelik siyasî ve dinî baskının devam etmesi, 1917 İhtilâli ve SSCB'nin kurulmasından sonra söz konusu baskının artması, Türkiye'deki Tatarların Anadolu'daki akrabalarıyla yazışmaları ve akrabalarının Anadolu'da sürdükleri hayattan övgüyle bahsetmeleri, bu dönemdeki göçlerin başlıca sebepleriydi[1]. 1950 ve 1960'lı yılların başlarında ise Türkiye, Tatarların yeni göçüyle karşılaştı. Bu tarihte Türkiye'ye gelen göçmenler Çin'deki Tatarlar'dır. Çin'de Komünistlerin iş başına geçmeleriyle birlikte Müslümanlara karşı baskı uygulanmaya başlandı. Bu da Tatarların Türkiye'ye göç etmelerine neden oldu.

Göçler sırasında, özellikle de ikinci dalgayla çok sayıda Tatar aydını Türkiye'ye geldi. İdil Uralllı bilim adamlarının bir kısmı ilmî müesseselerin kuruluşunda önemli rol alırken, bir kısmı da kaleme aldıkları eserlerle ön plana çıkmaktadırlar. Örneğin 2016'da doğumunun 140. yılını kutladığımız Yusuf Akçura 1931'de Mustafa Kemal Atatürk tarafından *Türk Tarihi Tetkik Cemiyeti*'nin (daha sonra *Türk Tarih Kurumu* adını aldı) kuruluş çalışmalarında görevlendirildi, 1932'de de cemiyetin başkanlığına seçildi [2: 150; 7: 32–36; 13: 2–7; 19: 283–286].[2] Yine Sadri Maksudi Arsal da *Türk Tarih Kurumu*'nun kuruluşunda yer aldı. Hatta 1930 kurultayında *Tarih Heyeti*'nin kuruluşunu bizzat kendisi teklif etmişti [2: 151]. Yine Akçura 1908'de *Türk Derneği* ve 1912'de *Türk Ocağı*'nın kuruluşunda aktif rol oynadı, *Türk Yurdu*'nun başyazarı ve editörü oldu ve dergiyi başarılı bir şekilde 17 yıl boyunca idare etti. Bu faaliyetlerinin yanı sıra Akçura çok sayıda eser kaleme aldı.

Benzer faaliyetlerde İdil Uralllı arkeolog ve etnolog Hamit Zübeyr Koşay (1897–1984) da bulundu. *Türk Tarih Kurumu* ile kardeş kurum olan *Türk Dil*

[1] Bu göçler ile ilgili daha ayrıntılı bilgi için bkz. [10: 50; 12: 896–905; 15: 69–145; 18: 23–29].
[2] Yusuf Akçura'nın Türkiye'deki faaliyetleri için ayrıca bkz [14].

В 90-ые годы XX столетия начинается масштабное изучение возвращенного духовного наследия писателя-эмигранта, публициста Гаяза Исхаки (1878–1954). Не остаются в стороне и поэты, идущие со временем, чутко прислушивающиеся к духу времени, которые в своих произведениях обратились к творчеству и личности Гаяза Исхаки. Автором статьи проанализировано изображение образа Г. Исхаки как в творчестве поэтов старшего и среднего поколения: А. Рашита, Ф. Тархановой, Л. Шакирзяновой, А. Халима, так и молодых поэтов нового времени: Р. Салахова, Ф. Гилязова и Р. Мухамметшина. К сожалению, литературное перевоплощение образа Г. Исхаки еще не нашло своего отражения в более ёмких поэтических произведениях – в поэмах, в эпических и драматических видах литературы. Однако, при дальнейшем глубоком изучении жизни и творчества личности Г. Исхаки, вопрос об увековечении писателя в литературных памятниках, надеемся, будет решен.
**Ключевые слова**: эмиграция, национальное самосознание, пророчество, исчезновение, нравственные ценности, философия жизни.

In the 90-ies of the twentieth century, a large-scale study of the returned spiritual heritage of the emigre writer and publicist Gayaz Iskhaki (1887–1954) begins. Do not stay away and the poets, who come with time, are sensitive to the spirit of the times, who in their works turned to the creativity and personality of Gayaz Iskhaki. The author of the article analyzes the image of the image of G. Ishaki as in the works of poets of the senior and middle generation: A. Rashit, F. Tarkhanova, L. Shakirzyanova, A. Khalim, and young poets of modern times: R. Salakhov, F. Gilyazov and R. Muhammetshin.
Unfortunately, the literary reincarnation of the image of Gayaz Iskhaki has not yet found its reflection in the more capacious poetic works – in poems, in epic and dramatic kinds of literature. However, with further deep study of the life and work of the personality of G. Ishaki, the question of perpetuating the writer in literary monuments, we hope, will be resolved.
**Key words:** emigration, national self-consciousness, prophecy, disappearance, moral values, philosophy of life.

Халкыбыз азатлыгыбыз өчен көрәшкә чыккан, гасырлардан килгән дәүләтчелекне торгызу, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрне саклау юлында зур сынаулар, рәхимсез кимсетүләр аша узып, мөһәҗирлектә яшәргә мәҗбүр булган мәшһүр әдип, публицист, сәясәтче Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулды.

Билгеле, XX йөз ахырының туксанынчы елларында бу олуг шәхеснең исеме Ватанга кайтарылгач, иҗаты һәм эшчәнлеген өйрәнү буенча зур эш җәелдерелде.

Гаяз Исхакый шәхесе галимнәребездән тыш шагыйрьләребезнең дә игътибар үзәгенә алынды. Заман сулышын тоеп яшәгән татар поэзиясе гасыр ахырындагы милли азатлык идеалларын үзендә актив җанландырып җибәргән әдәби төр булды.

XX йөз башында ук Г. Тукаебыз, пәйгамбәрләрчә, Исхакыйга карата «Кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!» (Мөхәрриргә, 1913) дип, аның Казанга кайтуын көтә. Әмма Чистай төрмәсендә утырган, полиция тарафыннан даими эзәрлекләнеп торган (1906–1913), аннары Архангель губернасында

сөргендә (1913) иза чиккән әдипкә шигъриятебез йолдызы Тукай белән очрашу мөмкин булмый, мәркәзебезгә кайтканда, ул инде бакыйлыкка күчкән була.

Бернинди режим белән дә килешә алмаган Г. Исхакый тиздән илдән сөрелә һәм 1918 елның 13 гыйнварыннан алып – 1954 июленә кадәр гомерен чит җирләрдә үткәрергә мәҗбүр була. Ул Берлинда, Варшавада, Парижда, Токиода, Харбинда, Истанбулда, Әнкарада яши. Биредә татар мәктәпләре, мәчетләр ача, читтән торып милләтебезгә ярдәм итә.

Могтәбәр шәхесебезнең исеме акланып, халыкка кайтуы вафатыннан соң, XX гасыр ахырында, милләтебезнең суверенитет яулаган, милли яңарыш, рухи-мәдәни кыйммәтләр яңартылган чорга туры килә. Мәгълүм булганча, милләтебезнең мөстәкыйльлек даулаган, хөрлек һәм азатлык юлында үзенә идеал шәхес, барыр кыйбла эзләгән 1991 нче елны, зинданнардан кайтарылып, Гаяз Исхакыйның «Зиндан» китабы дөнья күрү – татар дөньясында зур вакыйга була.

Бу уңайдан шагыйрь һәм публицист, Г. Исхакый премиясе лауреаты Әхмәт Рәшит «Гаяз Исхакый китабы чыккач» (1991) исемле шигырен иҗат итә. Автор Г. Исхакыйның кайту көнен халкыбызның үзенең иң кадерле һәм газиз кешесенә мөнбәр даулавы белән чагыштыра һәм җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеккә барыр озын юлында, Исхакыйның «пәйгамбәрчә сүзен» халыкның үзенә «дога итеп ятларына ышана» [4: 36]. Халкыбызның Г. Исхакыйны иленә кайтуы белән бәйле күтәренке кәефе, милли уянуны күтәренке пафос белән күрсәтелгән: «И шатланды милләт, көлеп, елап / Үзен ул көн кеше итеп тойды. / Күпләп-күпләп алдык киталарны – / Кабат тыярлар, дип, Исхакыйны» [4: 36]. Шатлык-сөенеч вакыт-вакыт төшенкелек белән дә алышына. Илдән рәнҗеп киткән Г. Исхакыйга мөнәсәбәттә Ә. Рәшит татар халкы язмышындагы шомлы, гөнаһлы үткәнгә борылып карый, тарихи чынбарлыкны үз җаны аша үткәргәндә, *кызыл кан, таш байрак, шомлы шәүлә* кебек аллегорик образларны куллана. Әдипнең илгә кайту көненең үткәннәргә тәүбә көне икәнен дә искәртә әдип. Халык поэзиясендә сары сагыш, аерылу символы булып килгән *киек каз* образы әсәрдә ике тапкыр очрый: беренче юлларда – илгә кайткан казларның каңгылдауларының күккә эленеп калып, офыкларга сары сагыш кунуында, парә-парә бәгырь теленүендә без ул язларда Гаяз Исхакыйга иленә юл ябылуын шәрехләсәк, соңгы өлештә – язларның чор капкасын кагуында, илгә киек казларның кайту тантанасында әдип мирасының, ниһаять, Ватанына кайтып төшүне күрәбез [4: 36].

Г. Исхакыйның авылдашы, шагыйрә һәм тәрҗемәче Флера Тарханова бөек якташын үзе яшәгән XX йөз башы рухи яңарыш, милли үзаң, милләт зыялылары формалашкан чор тирәлеге яссылыгында яктырта: «Хәлләремнән килсә / мин кайтарыр идем / Исхакыйлар, Тукай заманын, / Милли горурлыкның / Көчле ташкыныннан / Кайнап торган шәһри Казанын» («Мин кайтарыр идем...», 2003) [6: 18]. Шигырьдә автор, хыялында йөргән Исхакыйлар, Тукайлар чоры Казанын, гасырлар томанында калган милли әхлаклылыкны, борынгыдан килгән әдәпне, зыялылыкны кайтарырга теләвен һәм җирдән телне, милләтне каралтучы барча гадәтләрне сөрергә кирәклеген ишарәли һәм үзенең бары шул үткән чорда гына күңел тынычлыгы, рухына канәгатьләнү табачагын белдерә [6: 18]. «Хәлләремнән килсә, / Мин кайтарыр идем» юлларының кабатланып килүе шигырьнең укучыга тәсирен генә арттырып калмый, бәлки лирик геройның эчке халәтен тагы да тирәнәйтә.

Композиторыбыз Луиза Батыр-Болгари тарафыннан көйгә дә салынган «Исхакый» (2003) шигырендә [6: 51]. Ф. Тарханова Исхакый язмышын сөйгән халкы язмышы белән тоташ итеп сурәтләгән. Аны бәйсез дәүләт яклар өчен

көрәшләргә, хәтта давылларга керергә әзер, «Милләт» дигән тирән ярасыннан әле дә булса моңы саркып торучы милли каһарманыбыз итеп гәүдәләндерә [6: 51]. Тархانованың лирик герое – тел сафлыгы өчен җан атучы, милләт азатлыгы өчен йөрәк-бәгырьләрен канатучы. Әлеге шигырь Г. Исхакый мирасы илгә кайтып, тәнкыйтьче галимнәребез тарафыннан азмы-күпме өйрәнелгәч язылса да, шагыйрә Исхакый рухының илгә бөтенләе белән кайтып җитәчәгенә зур өметен белдерә: «...чит туфрактан рухы күтәрелеп, / Көтә аның килер сәгатен / Көтә һаман килер сәгатен» [6: 51]. Шигыренең эчке катламында автор милләт азатлыгы, тел сафлыгы өчен көрәшү юлында милләтебезнең Гаяз Исхакый рухлы көчле шәхесләргә мохтаҗ булуын искәртә. Халык традицияләре нигезендә, авылына мәдхия рәвешендә язылган «Яуширмә» (2001) шигырендә исә мәшһүр Г. Исхакый авыл данын күтәрүче, халык күңелендә саклаучы яугир егет итеп бирелә [6: 5].

Язучы, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимнең «Исхакый каурые» шигырендә лирик герой – дүрт яшьлек сабый. Ул шыксыз, салкын өйдә берүзе һәм янында очып йөрүче фәрештәгә яныннан китмәвен ялвара. Җавап итеп, фәрештә ул баланы ташламавын, аңа Исхакыйның каурый җибәрүен хәбәр итә [7: 291]. Г. Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты А. Хәлимнең тәрҗемәи хәле дә, игътибар итсәк, үз героеныкына охшаш: ул да дүрт яшеннән ятим калган, тормышның күп ачысын татыган.

Мәгълүм булганча, каурый – әдәби иҗатка өндәүче символ. Борынгы бабаларыбыз каурый яки камыш каләм белән язганнар. Элек-электән каләм иясенә хөрмәт зур булган, каурый каләм – рухи көч-куәтне аңлаткан. Милләтнең бәхете һәм киләчәге шундадыр дип, каләмгә зур өмет баглаганнар. Ятим калган, ачлыктан үлем белән тартышкан кечкенә Айдарга фәрештәнең: «Бисмилла, сабый, сөен: Исхакый үзе сиңа дип / Җибәрде каурыен...» [7: 291], дип, каурый бүләк ителү – булачак әдипнең милли азатлык юлында Исхакый эшен дәвам итүен, аның иҗатына булган зур ихтирамын белдерә.

2001 елның 31 июнендә Г. Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә Гаяз Исхакый укулары була һәм шул уңайдан әдипнең авылына сәяхәт оештырыла. Ошбу сәфәре турында Л. Шагыйрьҗан «Гаяз Исхакый юлыннан» шигырендә түбәндәгечә яза: Эч пошканнан түгел бу сәяхәт, – / Эч янганнан, йөрәк янганнан. / Без үтәсе юллар әллә кайчан / Исхакыйга барып ялганган...[8: 7]. Ул шул маякны югалтмаска, изге хыялларга, киләчәккә, якты өметкә, алдан барган яңарыш язы – Гаязга атларга өнди [8: 7]. «Яуширмәнең серле чишмәсе» (2001) шигырендә шагыйрә Яуширмә суының татлылыгы, шифалыгының серен Гаяз рухын саклавында күрә. Исхакый куәтләгән хөрлек утын сүндермичә, дөрләтеп, татарлыгыбызны саклап калырга, җаннан коллыкны алып ташларга өнди: Ул рух сүнсә / бетәр татар да.../ Дөрләтегез саклап шул утны, / Чыгарыгыз йолкып теге укны – / Кубарыгыз җаннан коллыкны!.. [8 : 9].

Яңа буын шагыйрьләре Рифат Сәлах, Рүзәл Мөхәммәшин, Фәнил Гыйләҗевлар да иҗатларында Г. Исхакый образына мөрәҗәгать итәләр.

Нәмык Кемал исемендәге премия лауреаты шагыйрь, тәрҗемәче Рифат Сәлах Исхакый образын милләт образы белән тыгыз мөнәсәбәттә күрсәтә: «Милләтебез!»диеп янып-көеп, / Без яшәргә тиеш, без – бакый! / Дөрес юлны күрсәткәнең өчен, / Мең рәхмәтләр сиңа, Исхакый!» [5: 11]. Р. Сәлах шигырендә ул Яуширмәдән килеп, халыкны ике гасыр алдан инкыйраз турында кисәткән, Казан урамнарына, йортларына «Азатлык» авазы сеңдергән, шул эшләре өчен үз Ватанында изелгән милләтче буларак күзаллана. Шагыйрь, Г. Исхакыйның мөһаҗирлеккә китүенең сәбәбен дә аңлата кебек: «Башың ию хаҗәт микән илгә, / Ватаныңда үзең изелсәң!» [5: 11] – ди. Сәлах фикеренчә,

XX йөз башыннан алып хәзерге чоргача милләтебезнең күге бер карала, бер аяза. Бүген, сикәлтәле һәм катлаулы дәверләр кичереп тә исән калуыбызга Г. Исхакыйга рәхмәтле булуыбызны һәм киләчәгебезне дә аның белән үтәргә хаклы икәнебезне раслаган: «Без атларга тиеш ялгышмыйча, / Туры юлда синең эз балкый! / Син яшәсәң, яшәр милләтебез, / Ышан безгә, ышан, Исхакый!» [5: 11], дип, ялкынлы юллар белән тәмамлый автор шигырен. Шулай итеп, Р. Сәлах иҗатында Г. Исхакый мәңге тере, безне күзәтеп, милләтебезне дөрес юлга күндерүче образ буларак сурәтләнә. Дөрестән дә, язучының иҗатын өйрәнәләр, китапларын укыйлар икән, ул исән. XX гасырның 90 елларында Исхакый иҗат мирасын барлау киң колач белән башкарылса да, бу өлкәдә эшлиселәр күп әле. ТР Язучылар берлеге һәм Төрексой оешмасы аша Төркиядә укып, төрек-татар әдәби бәйләнешләрен яңартучы, Г. Исхакый эзләре буйлап сәяхәт кылган бүгенге буын шагыйре Р. Сәлах үз иҗатында Исхакый мирасының илгә кайтарылуының дәвамлы эш икәнен дә искәртә: «Чит илләрдән торып әле һаман / Милләтеңә хатлар язасың...» [5: 11].

Шагыйрь, журналист, халыкара төрки яшьләр корылтае (2014), төрки дөньяның яшь язучылары җыены делегаты (2017), «Азатлык» активисты һәм, гомумән, милләтпәрвәр шагыйрь Фәнил Гыйләҗевның «Төркия дәфтәреннән» циклында Гаяз Исхакыйга багышланган «Кайтмадылар» (2015) [2: 8] шигыре дә игътибарга лаек. Әсәр Г. Исхакый шәхесен күздә тотса да, ул милләт образы булып, гомумиләштерелә төшә: күз алдында татар халкының сәяси һәм идеологик үткәнендәге кимсетүләрен, авыр һәм гыйбрәтле язмышы яңартыла. Әйе, Советлар дәүләте өчен иң явыз дошман ул – милләтче. 1917 нче елдан башлап илдә урнашкан тоталитар режим шартларында күпме халык һәлак булган, кыйнап-рәнҗетелеп, рухи яктан сындырылган, репрессияләнгән. Милли азатлык хәрәкәтендә чыныгу алган күп әдипләр, мәсәлән, С. Максуди, Г. Баттал, Ф. Туктаровлар белән Г. Исхакый да, Октябрь революциясен кабул итмичә, мөһаҗирлектә яшәргә мәҗбүр булалар.

«Кайтмадылар» шигырендә Ф. Гыйләҗев тарихка бәйле, өч ата образын гәүдәләндерә: милләт атасы – Гаяз Исхакый; репрессия корбаны булып, «мәсләкләре өчен диварларга терәп атылган ата-бабаларыбыз»; өченчесе, тарихыбызның иң кырыс, рәхимсез юлбашчысы, халыклар атасы – Иосиф Сталин.

Милләт аталарын бәяләгәндә, автор, аларның чит җирләргә качып котылуларын чарасызлыктан, баш хакына булуын искәртә. «Хөр Ватанга кайтам!» дип, аларның гомер буе җирсеп, «җан атуларын, акыл куюларын», туганнарын, нәселләренең җуюларын аерым бер трагизм белән сурәтли: Кайтмадылар... Кендек каны тамган / Туфрак җәсәдләрен күммәде. / Милләт кенә түгел, ятим калды / Милләт атасының теләге [2: 80 ].

Икенче ата – тарихи үткәнендә корбан булган аталарыбызга төшкән авыр сынаулы үткәнне күрсәтә: аларны диварларга терәп аттыралар, ГУЛАГларга ябып череттерәләр, бер гаепсез «дошман» исемнәре тагалар, гомумән, аның кыен күсәген күп кимерүче, үксез милләт балаласы булуы ассызыклана.

Сталин образындагы атаны характерлаганда ул «Ата берәү иде һәм ул ата / Кызганмады һичбер баласын», ди [2: 80]. Шагыйрь Сталинның большевистик-фашистик режимының бер милләтне дә аямаганлыгын, милләтне ятимләндерүен, азатлыкка булган теләк-максатларны фаш итүен күрсәтә.

Г. Исхакыйга иленә кайту насыйп булмаса да, халыкка бу атаның сүзе, иҗат мирасы кайта. Ф. Гыйләҗев та алдагы шагыйрьләр кебек Г. Исхакый кебек аталар ярдәме белән генә милләтне саклап булуына өметләнә: «...Ата сүзе кайтты чорлар аша / Бер әманәт булып Ватанга: / Милләт рухы өчен аталарны / Кайтарырга вакыт татарга!» [2: 80].

Яңа буын шагыйрьләреннән М. Җәлил премиясе лауреаты Рүзәл Мөхәммәтшинның Исхакыйга мөнәсәбәтле «Инкыйраз» 2006–2007 [3:50] шигырендә милләткә булган әрнүле авазын, ялваруын ишетәбез. Билгеле булганча, Г. Исхакыйның «Инкыйраз» әсәре 1902 елда языла, аның исәпләвенчә, милләт ике гасырдан соң, 2100 елларда юкка чыгачак. Хәзер ул әйткән дәвернең яртысыннан артыгы үтелгән... Р. Мөхәммәтшинны әнә шул хакыйкать уйландыра, гамьләндерә, сызландыра: «Минем кабат бире / Кайтуым икеле, / Һәм минсез дә тормыш / Тиешенчә үтә. / Без төптә, ә милләт / Сулый соң сулышын... [3: 50]. Яшь әдип инкыйразга баруны милләтнең берләшә алмавында, көнләшеп, сугышып,үз ишеңә янаудан күрә. Ул халыкка сүнмәскә, көленнән булса да янып китәргә, шул рәвешле, инкыйраз чикләрен күчерергә чакыра. Шигырь тукымасында Исхакый образы турыдан-туры гәүдәләнмәсә дә, эпиграфта искә алынуы һәм шигырьнең пессимистик исеменә мөнәсәбәттә ул милли инкыйраз турында кисәтүче даһи буларак күзаллана. Р. Мөхәммәтшин Г. Исхакый юраган инкыйраз хакында яшәеш фәлсәфәсе, мәңгелек мәсьәләләр, лирик героеның үтә дә хисси-эмоциональ дөньясы аша фикер йөртә.

Күзәтүләребез шуны күрсәтте: Г. Исхакый образына хәзерге шигърияттә төрле буын шагыйрьләре мөрәҗәгать иткән. Өлкән һәм урта буын иҗатында ул күп очракта үзләре катнашкан һәм күргән билгеле бер вакыйга уңаеннан сурәтләнгән, әйтик, суверенлык алу, «Исхакый укулары», Яуширмә авылына сәфәр, әдипнең мирасын халыкка кайтару, ватанында тәүге китабы басылу һ.б. Яшь буын шагыйрьләре иҗатында киң урын алуының алшартлары булып, бер яктан – Төркия-Татарстан арасындагы сәяси-иҗтимагый, әдәби бәйләнешларның ныгуы, яшьләрнең Төркиягә сәяхәте, язучы эзләре буйлап йөрү, Истанбулдагы каберен зиярат кылу тәэсире булса, икенче яктан, XXI гасыр башы милли азатлык, әхлакый кыйммәтләр яңарышы мәсьәләләренә бәйле рәвештә, милләтне саклап калу юлында рухи идеал эзләү нисбәтеннән гәүдәләнә. Һәр буын шагыйрьләре дә Исхакый образын милләт хадиме дәрәҗәсендә үстереп, халкыбызның үткәне, бүгенгесен, киләчәге белән якын мөнәсәбәттә, милләтнең коткаручысы, юл күрсәтүчесе сыйфатында күрәләр һәм мирасының тулаем илгә кайтуына зур өметләр баглыйлар.

Билгеле, бу олуг шәхес турында күләмлерәк шигъри әсәрләр – поэмалар, хикәя, повесть, романнар, драмалар әле язылмаган. Әлеге мәсьәлә киләчәктә, иҗаты, тормышы буенча тагы да яңа эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, уңай якка хәл ителер һәм Гаяз Исхакыйның якты истәлеген әдәби һәйкәлләр дә мәңгеләштерер дигән теләктә калыйк.

## ӘДӘБИЯТ


1. Габидуллина Ф. Просветительские традиции в творчестве Г. Исхаки // Проблемное обучение в современном мире: сборник статей VI Международных Махмутовских чтений. Елабуга: Изд-во КФУ г .Елабуга, 2016. С. 99–103.

2. Гыйләҗев Ф. «Уян, милләт!» диеп көйли татар: шигырьләр // Казан утлары. 2015. № 4. Б. 79–81.

3. Мөхәммәтшин Р.Ф. Бүре мин: шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 159 б.

4. Рәшит Ә. Таң илчесе: шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 287 б.

5. Сәлах, Р.Г. Ак фәрештә: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 143 б.

6. Тарханова Ф. Яшьлек эзем калган сукмаклар: шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 223 б.

7. Хәлим А. Исхакый каурые // Татар шигърияте: 1980–2000 еллар. Казан: Мәгариф, 2003. 352 б.

8. Шагыйрьҗан Л. Сагынмаклык: Истәлекләр, багышламалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 303 б.

# Г. ИСХАКЫЙ ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ФАҖИГАЛЕЛЕК
## («Зөләйха», «Дулкын эчендә», «Олуг Мөхәммәд» әсәрләре мисалында)

***Ф.Х. Миңнуллина** (Казан)*

В статье рассмотрена драмы Г. Исхаки с позиций теории трагического. В пьесах проблема противостояния героев трагическим обстоятельствам в безвыходной ситуации является основополагающей.
**Ключевые слова:** драма, Г. Исхаки, пьеса, конфликт, трагическое, драма.

The article is considered from the perspective of the theory of the tragic in the dramas of G. Iskhaki. In the tragedy, the problem of opposing heroes to tragic circumstances in a desperate situation is fundamental.
**Key words:** drama, G. Iskhaki, play, conflict, tragic, drama.

Татар классик язучысы, журналист һәм публицист, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый (1878–1954) – халкыбыз тормышында һәм мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган шәхес. «Гаяз Исхакыйнын драматург буларак ижатын ике чорга бүлеп карау мәслихәт булыр. Беренче чор – 1906–1923 еллар. Татар театр сәнгатенен туу көннәреннән алып, Гаяз әфәнде эмиграциягә киткәч, анын әсәре буенча куелган ин соңгы спектакль уйналу еллары бу. Исхакыйның шул вакытта татар сәхнәсенә күтәрелгән иң соңгы әсәре – «Салих хаҗи балалары» («Юлсызлар») 1923 елның 9 ноябрендә уйнала. Икенче чор – Гаяз Исхакый мирасы халкыбызга кире кайту чоры. Театр сәнгатендә ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1992 елның 19 декабрендә «Зөләйха» трагедиясен сәхнәләштерү белән башланды» [1: 173].

XX гасыр ахырында ил тормышында башланнып киткән үзгәрешләр чорында, әдипнең тоткынлыкта яткан зур иҗади мирасы халкыбызга кире кайтарыла башлады. Татар сәхнәсенә иң беренче булып яңадан «Зөләйха» трагедиясе күтәрелде. Празат Исәнбәт Г. Камал исемендәге театр сәхнәсенә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» (1992), «Алдым-бирдем» (1994), «Җан Баевич» (1995) әсәрләрен сәхнәләштерде. Уфадагы «Нур» театрында яшь режиссерлар Б. Ибраһимов белән Ф. Бикчәнтәев Г. Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясен һәм «Көз» повестен киң җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим иттеләр. Билгеле булганча: «Гасырның беренче унъеллыгында Г. Камал, Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, И. Богданов, С. Рәмиев иҗатлары белән сәхнә әдәбияты тема һәм жанр төрлелегенә ирешеп, чынбарлыкка нисбәтле вакыйгаларны сурәтләү аша реализм юнәлешен үзләштерә, акрынлык белән синкретизмнан арына барып, сурәт чараларының бай төсмерләрен бирә, үз чорының үзенчәлекле образларын тудыра. Ә инде гасырның икенче унъеллыгы сан һәм сыйфат үзгәрешләре белән характерлана. Инкыйлабтан соңгы реакция, Беренче бөтендөнья сугышы авырлыкларына карамастан, татар җәмгыяте Яңарыш рухы белән яши» [7: 33]. XX йөз каләм осталары тулысынча милләт язмышын алгы планга куя, милли азатлык идеясе әдәбиятның нигезенә салына. Г. Исхакый әсәрләрнең үзәгендә шәхес язмышы, халык һәм милләт язмышы тора [4: 50]. Аның «Алдым-бирдем», «Тартышу», «Җәмгыять», «Мөгаллимә», «Зөләйха» һәм башка пьесалары шундыйлардан. Аны кайчандыр тарихи казанышларга ирешкән татар халкының киләчәге, тәрәккъыят юлына аяк баса алмавы борчый. Бер төркем әсәрләрендә ул, милләтне инкыйраздан саклап калу максатында, игътибарын халыкның милли яшәешенә, гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, шул ук вакытта фаҗигале язмышына юнәлтә. Мәгълүм ки, татар халкының тормышы, тарихы фаҗигаләр белән тулы. 1552 елда Явыз Иванның Казан ханлыгын яулап алуы – шуларның берсе. Г. Исхакыйның мөселман халыкларын,

беренче чиратта, татарларны көчләп чукындыру вакыйгалары тасвирланган «Зөләйха» (1912) – иң беренче татар трагедиясенең нигезендә – нәкъ менә шул фаҗига ята. Автор Зөләйханы гаиләсеннән аерып, рус кешесенә кияүгә бирүне һәм көчләп чукындыруны милләт тормышында зур фаҗига дип бәяли. Әдип әсәрнең жанрын драма дип билгели. Трагик хатаның булмавына карамастан, әсәрне татар әдәбиятында трагедия жанры тудыруның беренче адымы, тәҗрибәсе дип әйтергә була. Фаҗиганең төп мотивы трагик хатадан гына тормый. Герой фаҗигасен тудыручы сәбәпләр трагик вакыйгалар белән дә бәйле. Трагедиянең төп герое тирәсендәге башка персонажлар, аларның аянычлы хәлләре, гасырдан-гасырга күчеп килә торган милли каршылык белән бәйле. Бу әсәр куелган мәсьәләнең чишелеше, фаҗигале вакыйгаларны бирү, тәэсир итү көче ягыннан татар әдәбиятында беренче трагедия жанрына мисал.

Трагедияләрдә төп геройның хәл итеп булмаслык каршылык эченә кереп, киеренке көрәш нәтиҗәсендә котылгысыз рәвештә һәлакәткә юлыгуы, әлеге жанрның иң мөһим үзенчәлеге. Зөләйха да, үзенең һәлакәткә баруын белгән хәлдә, үз идеяләренә гомеренең соңгы көненә кадәр тугры кала. Биредә шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. Ә. Закирҗанов билгеләгәнчә, ул бер генә адәм дә күтәрә һәм түзә алмаслык авырлыклар йогынтысында интегә, җәфалана, җәбер-золым, кайгы-хәсрәт күрә, ләкин үз диненнән, теленнән язмый, трагедия ахырында, мөэмин-мөселман, татар булып, фани дөньядан китә. Әлеге әсәре белән Г. Исхакый, татар әдәбиятында беренче булып, үз милләтенә, үз диненә, үз кыйбла-мәсләгенә, үз гаиләсенә, әби-бабадан калган гореф-гадәтләренә, үзенең ана булу сыйфатларына тугры калган бөек татар хатын-кызы образын гәүдәләндерә [6: 138]. Ул трагик герой, көчле шәхес буларак ачыла, авырлыкларга баш имәү, горурлык, икенче яктан, каршылыкны җиңеп чыгарга көче җитмәү аны зур газаплануга һәм, үлемгә китерә. Рухи һәм физик изелү кичерүгә карамастан Зөләйха динен, рухи ныклыгын саклап кала. Христиан динендә тәрбия алган Әхмәтне дә үз диненә кайтаруга ирешә. «Ислам диненең халыкны берләштерүдәге ролен күрсәтүне драматург башка диннәрне түбәнсетү исәбенә эшләми. Һәр халыкның үз диненә ышанычы көчле, аның моңа хакы бар, дип куя ул мәсьәләне» [3: 41]. Әлеге фикер, автор тарафыннан «Олуг Мөхәммәд» драмасында да күтәрелә.

Мәгълүм ки, Г. Исхакый Октябрь инкыйлабын кабул итә алмыйча чит илгә китәргә мәҗбүр була. Мөһаҗирлектә дә ул милли рух белән сугарылган әсәрләренең үзәгенә милләт язмышы мәсьәләсен куеп, әлеге проблеманы төрле яссыллыкта чишә. «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд», «Хәят юлында», «Дулкыннар арасында» кебек сәхнә әсәрләре шуларның матур бер үрнәге. Р.К. Ганиева билгеләгәнчә, ул большевиклар сәясәте, кызыл террор мәсьәләләрен тасвирлаган «Дулкын эчендә», «Катлаулы рус һәм татар сәяси мөнәсәбәтләрен, христиан һәм ислам диннәренең рус һәм татар тарихындагы урынын, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребезнең, казан татарларының ниндиерәк варислары булу мәсьәләсен, тарихи барышта ирешкән уңышларыбыз һәм җибәргән хаталарыбыз турындагы уйлануларны, гореф-гадәтләребезне «Олуг Мөхәммәд» драмасында чагылдырды» [5: 147]. Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасында автор яшьли тол калган Разыя абыстай белән аның бердәнбер кызы Бану язмышы мисалында халык язмышы, фаҗигасе хакында сүз алып бара. Драмада яшьли тол калган Разыяны ике балалы Хәйрулла яучылый. Ләкин, Разыя кызы хакына аңардан баш тарта. Кызы Бану кияүгә чыгып Кырымга киткәч, ул бу адымының хата булуын аңлый. «Мин гаепле... Мин сине балам өчен корбан иттем. Сине генә түгел, үземне дә корбан иттем...Анда үлсәң, син анда кан эчендә буылып, балаларыңны күрергә тилмереп үлсәң, мин

монда ялгызлыкта, ятимлектә буылам...» [8: 280]. Шул рәвешле әсәргә үз-үзен ялгызлыкка дучар иткән кеше фаҗигасе килеп керә. Автор фикеренчә, шәхси бәхетнең кешенең үзеннән дә торуын күрсәтә. Шуңа күрә дә Разыя үзе кебек яшь бала белән тол калган кызына яңадан гаилә корырга киңәш бирә. «Бер кайгыны ялгыз күтәргәнче, икәү бүлешерсез» [8: 293], – ди ул.

Гражданнар сугышын, Беренче бөтендөнья сугышын кичергән гаиләнең язмышы большевиклар властька килгәч тагы да катлаулана, фаҗигале төс ала. Кызыллар Разыяның бер гаебе булмаган киявен атып үтерәләр, үзен,буржуйлыкта гаепләп, булмаган акчаларын бирүне таләп итәләр. Нәтиҗәдә, Разыяның өйдәге бар әйберен алып чыгып китәләр. Бу авырлыкларга түзә алмаган хатын якты дөньядан китеп бара. Шул рәвешле, әдип сәясәттән ерак торган бер гаилә мисалында яңа заманның кырыс җилләре, яңа хакимият вәкилләренең рәхимсезлеген ассызыклый. Әлеге күренешләр ананың бала алдындагы бурычының шәхси мәнфәгатьләр белән каршылыкка керү кебек мәсьәләләр тирәсендә яктыртыла.

Г. Исхакыйның тарихи пьеса буларак тәкъдим ителгән «Олуг Мөхәммәд» пьесасында совет авторлары күтәрә алмаган икенче тема – татар халкының үткән тарихын бирү. «Олуг Мөхәммәд» драмасында татар милләтенең әйдәүчесе булган беренче хан – Казан ханы сурәтләнә. Әсәрдә Олуг Мөхәммәд зирәк, алдан күреп эш итүче идарәче буларак ачыла. «Без таралган илемезне берләштерергә тырышамыз.... Дәүләт корыр өчен белем кирәк, бер-береңә ышаныч кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк...» [8: 455]. «Зөләйха» трагедиясендәге кебек, биредә дә әдип һәр халыкның үз диненә хаклыгы булу мәсьәләсен күтәрә. Драманың ахыры да тирән мәгънәгә ия. «Бу сәгатьтән башлап, Мәскәү князьлеге берлә Казан ханлыгы арасында сугыш бетте, килешү булды... Халыкка белдереңез..., халык өч көн, өч кич бәйрәм итсен...» [8: 517], – ди хан. Олуг Мөхәммәд кан коюны бетерергә, дуслык урнаштырырга, халыкны тынычлыкта яшәтергә уйлый. Автор Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары хакында сүз алып барып, татар халкының үз вакытында дәүләтле булуын билгели.

Г. Нуриев фикеренчә: «Жанры буенча да ул – тарихи трагедия. «Олуг Мөхәммәд» трагедиясендә ул тарихи вакыйгаларга тугры калып, хронологик тәртипкә, сәнгать әсәренең фабуласына яраклы рәвештә үзгәреш керткән, татар халкы тарихындагы мөһим борылышларны, үз чоры каршылыкларын да исәпләп, объектив бәяләгән» [8: 90]. Мәкалә авторы шунда ук, трагедиянең төп конфликты – халыкның гомум үзаңы үсү һәм үзбилгеләнүгә ирешү омтылышына комачау тудыра торган көчләрнең бәрелешүендә булуын ачыклый. Билгеле булганча, трагедия жанрында язылган әсәрләр капма-каршы көчләрнең килешүе мөмкин булмаган көчле конфликтка корыла һәм уңай идеаллар алып килүче герой тигезсез көрәштә һәлак була. Трагедиядә һәрвакытта да кешелек яшәешенең азатлык, характер һәм язмыш, гаеп һәм гафу ителү кебек мәсьәләләре күтәрелә. Ул персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән һәм гадәттә фаҗига белән тәмамлана торган драматик жанр. Әсәр, чыннан да, фаҗигале сюжетка корылган. Чөнки трагедиянең аерым элементлары бүтән жанрларда ук чагылуын күрергә мөмкин. Бу жанрда язылган әсәрләрдә, тулаем алганда, ике арадагы катлаулы мөнәсәбәтләр трагедия язу өчен бик уңышлы һәм бай материал булып торса да, автор аны трагедия дәрәҗәсенә күтәрмәгән. Әсәрнең финалы да шул хакта. Г. Исхакыйның бу әсәрендә фаҗигалелек мотивлары, элементлары бар. Олуг Мөхәммәднең рус дәүләте белән көрәше, шул юлда пьесада персонажлар сөйләмендә телгә алынган хан киявенең үлеме шулар. Димәк, ул трагик ситуацияләрне эченә алган катлаулы тарихи драмалар төренә керергә лаеклы бер әсәр булып тора.

Гомумиләштереп әйткәндә, Г. Исхакыйның мөһаҗирлектә язылган драма әсәрләрендә татар милләте язмышына мөнәсәбәтле мәсьәләләр күтәрелә.

Г. Исхакый татар әдәбиятында заман проблемаларын, ил язмышы, халык язмышы турындагы уйлануларын, көчле характерлар, кызыклы вакыйгалар аша тасвирлый алган күренекле каләм иясе.

ӘДӘБИЯТ

1. Арсланов Г.М. Гаяз Исхакый һәм татар театры // Казан утлары. 1999. № 9. Б. 172–178.

2. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007..

3. Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 239 б.

4. Габидуллина Ф.И. Проблемы изучения жанровой природы татарского романа Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. Ч. I. №7 (25). 2013. С. 49–51.

5. Ганиева Р. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

6. Закирҗанов Ә. Татар трагедиясе // Казан утлары. 2010. № 3. Б. 138–144.

7. Закирҗанов Ә.М. XX гасырның I чирегендә татар драматургиясе үсешенә нисбәтле Кәрим Тинчурин иҗаты // Фәнни татарстан. 2017. № 3. Б. 32–41.

8. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 5 том: Хикәяләр, повестьлар, пьесалар (1920–1947). Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 559 б.

9. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

10. Нуриев Г.С. Г. Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» тарихи трагедиясе поэтикасы // Г. Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). Казан, 2008. 376 б.

## «МИЛЛИ БАЙРАК» ГАЗЕТАСЫНДА МӘГАРИФ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Л.Р. Мортазина*** *(Казан)*

Общественно-политическая газета «Милли байрак», издававшаяся в городе Мукдене в 1935–1945 годах, является одним из ценных и малоизученных источников о жизни, быте, культуре и образовании тюрко-татарских эмигрантов Дальнего Востока. Особый интерес представляют статьи, посвященные национальному образованию и воспитанию, среди которых много публикаций о состоянии школьного дела у татар Дальнего Востока, о проблемах в области образования, также материалы о татарских педагогах и деятелях просвещения.
**Ключевые слова:** «Милли байрак», мухаджиры (эмигранты), образование, национальные школы, религиозное воспитание, национальное воспитание.

The socio-political newspaper «Milli Bairak» («Banner of the Nation»), which was published in the city of Mukden in 1935–1945, is one of the valuable sources about the life, way of life, culture and education of the Turkic-Tatar emigrants of the Far East. Articles on national education and upbringing are of interest. Among them there are a lot of publications about the state of schooling among the Tatars of the Far East, about problems in the field of education, as well as materials about Tatar educators and educators.
**Key words:** «Milli Bairak», muhajirs (emigrants), education, national schools, religious education, national education.

«Милли байрак» – Ерак Көнчыгышта яшәүче төрки-татар мөселманнарының 1935–1945 елларда Кытайның Мукден шәһәрендә дөнья күргән иҗтимагый-сәяси газетасы, «Ерак Көнчыгыш төрки-татар мөселманнарының Идел-Урал милли-дини комитеты» органы [14: 161]. Татар телендә басылучы әлеге газетаның басыла башлавытанылган язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый исеме белән бәйле. Г. Исхакый – газетаны оештыручы һәм аның беренче мөхәррире була.

Бүгенге көндә «Милли байрак» газетасы чит илләрдә яшәгән милләттәшләребезнең тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, мәгарифен, иҗтимагый

тормышын өйрәнүдә кыйммәтле чыганакларның берсе булып тора. Шунысы куанычлы: Япониянең Симанэ университеты архивында саклаанган әлеге газетаның электрон копиясе (бүген билгеле булган иң тулы комплектларның берсе) 2015 елда ТР галимнәре карамагына тапшырылды [13: 5]. Бүгенге көндә «Милли байрак» газетасының библиографик күрсәткече [7] басылып чыгу моңарчы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән татар басмасының, андагы материалларның фәнни күзлектән чыгып өйрәнелүенә, фәнни әйләнешкә кертелүенә юл ачачак, татар тарихының, аерым алганда, мөһаҗирлектәге татар тормышының төрле аспектларын өйрәнүгә зур өлеш кертәчәк.

«Милли байрак»ның барлыкка килүе иң беренче чиратта Ерак Көнчыгышта яшәгән төрки-татарларның милли бердәмлеген һәм мәдәниятен саклау теләге белән бәйле була. Татар телендә матбугат чарасы булдыру омтылышлары 1917 елга кадәр дә булса да, татар җәмгыятенең аз санлы булуы сәбәпле, әлеге теләк тормышка аша алмый. Бары тик революциядән соң гына Харбин шәһәренең имамы Гыйниятулла Сәлиәхмәт Ерак Көнчыгышта татар телле нәшрият ачуга ирешә, бирердә 1920–1924 елларда «Ерак Шәрык» исемле журнал басылып килә [16: 60]. Татар мөһаҗирләренең тормышын, ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларны туплау максатына җавап бирерлек даими басма бары тик 30 нчы еллар уртасында гына барлыкка килә. Ерак Көнчыгышка килгән Гаяз Исхакый 1935 елның 16 октябрендә Япония хөкүмәтеннән Мукден шәһәрендә татарча газета чыгаруга рөхсәт ала [4: 404] һәм үзенең фикердәшләре – Рокыя Мөхәммәдиш[1] һәм Ибраһим Дәүләт-Килде[2] (Төркиядә яшәүче танылган татар галиме Надир Дәүләтнең әти-әнисе [6: 11]) белән берлектә аны чыгаруга керешә.

«Милли байрак» Япония, Корея, Кытайда яшәүче төрки-татарлар арасында тарала. Аны шулай ук Финляндия, Германия, Польша, Һиндыстан, Төркия кебек илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә алдырган, Сүрия, Пакыстан кебек илләрдән язышучылар булган. СССРда газета таралмаган [16: 61]. 1936 елда Г. Исхакый Европага китә һәм Европа илләре һәм андагы сәясәт, мөселман дөньясы, милли мабугат, татар милләте һәм аның мәдәнияте, мөстәкыйльлеге һ.б. темаларга багышланган мәкаләләрен шуннан җибәреп тора.

Гомумән алганда, газета төрки-татарларны туплау, телне, милли горурлыкны, традицияләрне, гореф-гадәтләрне, дини йолаларны саклау, милли хәрәкәт, дәүләтчелекне торгызу һ.б.ш. милли идеяләрне тормышка ашыруны, төрле илләрдә яшәүче татар җәмгыятьләре арасында элемтә урнаштыруны максат итә, татар мөһаҗирләренең җәмәгать эшчәнлеген, әдәбиятын, икътисадый хәлен яктырта. Анда Кытай һәм Корея белән беррәттән, Япониянең Токио, Кобе, Нагоя һәм Комамото шәһәрләрендә яшәүче татарларга зур игътибар бирелә, Төркиядәге мөһаҗирләр, Россиядәге татарлар турындагы мәкаләләр басыла [5: 80, 81]. Ерак Көнчыгышта яшәгән татарларның тормышын яктыртуга багышлан-

[1] Рокыя Сабирҗан кызы Мөхәммәдиш (1908–1989) – педагог һәм публицист, тумышы белән Казан губернасы Тәтеш өязе Үтәмеш авылыннан. 1916–1917 елларда Ерак Көнчыгышта Благовещенск шәһәрендәге татар мәктәбендә укый, 1925 елдан Кытайның Харбин, 1927 елдан Япониянең Токио шәһәрендә яши. Г. Исхакый Европага киткәннән соң, «Милли байрак»тагы баш мәкаләләрнең күбесе аның тарафыннан языла (Гаяз Исхакый. Әсәрләр. 15 томда. Т. 12. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 405).

[2] Ибраһим Котлымөхәммәд улы Дәүләткилде (1901–1967) – журналист, Ерак Көнчыгышта төрек-татар милли хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе, чыгышы белән Казахстанның Кызылъяр шәһәреннән. 1919 елда Владивостокта радио курсларына укырга керә, Харбинда мөһаҗир русларның реальное училищесында белем ала. 1922 елдан Япониядә. 1935 елдан соңгы тормышы Ерак Көнчыгыш төрек-татар җәмгыяте һәм «Милли байрак» газетасы белән бәйле (Гаяз Исхакый. Әсәрләр. 15 томда. Т. 12. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 405).

ган мәкаләләр арасында мәктәп-мәгариф һәм милли тәрбиягә багышланган материаллар аеруча күп. Бу Япония татарлары өчен мәгариф өлкәсенең зур әһәмияткә ия булуы турында сөйли [5: 82]. Гали Акыш билгеләп үткәнчә, «Милли байрак» «мөһаҗирлектә яшәгән татар яшьләрен милли рухта тәрбияләү эшенә зур өлеш кертте» [2: 137].

Мәгариф мәсьәләләренә багышланган мәкаләләргә килгәндә, биредә Ерак Көнчыгыштагы төрек-татар мәктәпләренең эшчәнлеге, дәреслекләр мәсьәләсе, милли мәгариф һәм аның бурычлары, туган телне саклау һәм укыту, татар тарихын өйрәтү, милли тәрбия, ислам тәрбиясе, укытучылар әзерләү һ.б. проблемаларны аерып күрсәтү мөмкин.

Газетада иң күп яктыртылган мәсьәлә, мөгаен, Ерак Көнчыгышта төрек-татар мәктәпләренең эшчәнлегедер. Бу төр мәкаләләрдә аерым мәктәпләрдә укыту һәм тәрбия эше, аның эчтәлеге, яңа мәктәп биналары ачылу, аларда белем бирүче укытучылар, имтихан нәтиҗәләре һ.б. турында сөйләнә. Мәктәпләрдә укуларның башлануы, тәмамлануы турындагы белдерүләрне дә шушы төркемгә кертеп карарга кирәктер. Бу мәкаләләрдән Ерак Көнчыгыш илләрендә татарлар арасында мәктәп-мәгариф эшенең куелышы, торышы турында гына түгел, анда эшләгән педагоглар, мәктәп эшчәнлегенә ярдәм күрсәткән шәхесләр (ата-аналар, һәйят (комитет) әгъзалары, иганәчеләр һ.б.) турында да мәгълүмат алырга мөмкин.

Кайбер мәкаләләргә тукталып китик.

Нагояның Идел-Урал төрек-татар мөселманнары мәдәни җәмгыять идарәсе тарафыннан язылган «Нагоя мәсҗид-мәктәп бинасының ачылу мәрасиме» мәкаләсендә Япониянең әлеге шәһәрендә 1936 елның 18 августында Идел-Урал төрек-татар мөселманнары өчен ачылган мәчет-мәктәп турында сөйләнә, аны салуда ярдәм күрсәткән кешеләр – Гыйсмәтулла хаҗи Әгерҗи (матди яктан), Мәркәз диния шөгъбәсе рәисе Мәдъяр хәзрәт Шәмгуни (мәгънәви), мәктәп ачылышында нотык тоткан шәхесләр – Дәүләтшаһ Сөзгән, мәчет-мәктәп салу һәйятенең рәисе Тимербай Хәмидулла, мөгаллим Гыймадетдин Баймөхәммәди, Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте рәисе һәм имамы Гали Дашки һ.б. искә алына [12]. Мәкаләдән әлеге бинаны салуда Кобе шәһәрендә яшәүче татарлар, һинд, гарәп мөселманнарының да матди ярдәм күрсәтүләре аңлашыла. Төрек-татарлар тормышында гаять әһәмиятле булган әлеге вакыйганың Япония җәмгыятендә дә зур кызыксыну уятуын күрергә мөмкин. Бу хакта мәҗлестә япон вәкилләренең катнашуы, бар чыгышларның да япон теленә тәрҗемә ителеп барылуы, япон телендәге котлау телеграммалары укылу, япон газеталарында («Осака осахи», «Нагоя симбун») бу чара турында мәкаләләр, рәсемнәр басылып чыгу сөйли.

«Мукден төрек-татар мәктәбендә» дип исемләнгән мәкаләдә мәктәптә язгы имтиханнар тәмамлану уңаеннан 1937 елның 4 июнендә үткәрелгән дога мәҗлесе һәм шәкертләргә шәһадәтнамәләр бирү мәрасиме шактый тәфсилле тасвирлана [11]. Анда шулай ук төрек-татар мәктәпләрендә мәктәп эшенең оештырылуы, аерым алганда, имтихан алу тәртибе турында да кызыклы мәгълүматлар алырга мөмкин. Мәсәлән, укучылардан имтихан алу өчен махсус һәйят төзелгән, имтиханда шулай ук җәмгыять кятибе, Мәркәз мәгариф шөгъбәсе[1] рәисе урынбасары Рокыя Мөхәммәдиш катнашкан; ибтидаи алты сыйныфны тәмамлаучы укучылар исемлеге тәкъдим ителгән (Рәшидә Яуш һәм Габбас Уразбәхет). Шәһадәтнамәләр тапшырылып, Мәгариф идарәсе,

[1] Милли мәгариф системасын саклау, мәктәпләр ачу, туган телне һәм тарихны укыту мәсьәләләрен хәл итү өчен төзелгән махсус оешма, мәгариф департаменты.

мөгаллимә (Разия Дәүләткилде), ата-аналар һәм мәктәпне тәмамлаучылар тарафыннан тәбрикләү һәм рәхмәт сүзләре әйтелгәннән соң, дога мәҗлесе уздырылган, милли көйләр җырлап бәйрәм дәвам ителгән. Шулай итеп, әлеге язмалар аша без чит илләрдә татар мәгарифен оештыруның үзенчәлекләре турында мәгълүмат ала алабыз.

«Харбин мәктәбе» дигән язмада ата-аналар һәйяте сайлау һәм аның нәтиҗәләре, «Киҗу мәктәбендә» мәкаләсендә Идел-Урал төрек-татар мәктәбендә укулар башлану, мөгаллим билгеләнү турында хәбәр ителә [17; 8]. Мондый төрдәге язмалар «Милли байрак» газетасында шактый күп.

Газета битләрендә мәгариф өлкәсендә татарларны борчыган тагын бер проблема – татар урта мәктәбенең булмавы мәсьәләсе чагылыш таба. Билгеле булганча, Маньчжуриядә урта татар мәктәбе булмый. 4–6 сыйныфны татар мәктәбендә тәмамлаганнан соң, татар баласы укуын кытай, рус яки француз мәктәбендә генә дәвам итә алган. Шулай итеп, кайбер балалар өчен укуны алга таба дәвам итү мөмкин булмаган [18: 84].

Газетада басылган язмаларның зур күпчелеген милли һәм дини тәрбиягә багышланган мәкаләләр алып тора. Аларда «чит илләрдә, ят мәдәният эчендә яшәргә мәҗбүр булган авыр мөһаҗирәт дәверендә яшәгән милләтебезнең үз балалары итеп җитештерү» мәсьәләсе күтәрелә. Бу күрәштә, газета фикеренчә, беренче урынны гаилә һәм милли башлангыч мәктәпләр биләсә, икенче, шулай ук иң зур өлеш матбугат өстенә төшә. «Утырып җитмәгән яшь күңелгә <...> укый торган матбугаты, әдәбилек көчле тәэсир итә» [9]. Шул сәбәпле, газета хезмәткәрләре фикеренчә, милләтебезнең киләчәге булган яшь буынны тәрбияләүдә милли рух белән сугарылган, ана телендә чыга торган матбугатның да роле биниһая зур.

Милли тәрбиягә килгәндә, аның иң беренче бурычы – «милли эшләребезгә хадимләр» әзерләү, ягъни үзебездән соң милләткә хезмәт итәрлек яшьләр тәрбияләп калдыру [1]. Мәкалә авторы заман яшьләрендә милли рухның түбән булуын, шуңа күрә нәкъ менә бала вакыттан ук милли тәрбия бирүгә зур игътибар итәргә кирәклекне ассызыклый. «Балалар дөньясы» дигән язмада автор үзе уйлавынча татарларга хас дип санаган бер мисал китерелә. Әгәр баласы тыңламый икән, ди автор, энисе аны: «Әгәр тыңламасаң, этиең киләсе елга мәктәпкә илтер», – дип куркыта; шул рәвешчә татар баласы мәктәпне куркыныч бер урын буларак кабул итә. Автор бала тәрбиясендә куркытуны түгел, ә шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, хәлгә керү кебек уңай сыйфатларга таянырга киңәш итә. Ә бу уңай сыйфатларны тәрбияләүдә, әлбәттә, беренче урын эниләргә бирелергә тиеш. Хатын-кызларның гаиләдә иң төп бурычы – бала тәрбиясе, димәк милләтнең киләчәге дә – аналар кулында [10].

Газетадагы тәрбия турындагы мәкаләләр арасында революциягә кадәр татар матбугатында дөнья күргән язмалар да очрый. Аеруча әһәмиятле дип санаган мәкаләләрне редакция хезмәткәрләре кабат күчереп бастыруны кирәк санаганнар. Шундыйларның берсе – «Тәрбия вә тәгълим» мәкаләсе [15]. Әдәп, әдәп тәрбияләү, әдәп кагыйдәләре (тырышлык, исраф итмәү һ.б.) булдыруның әһәмиятен ассызыклаган әлеге мәкалә заманында «Шура» журналында басылган була. Димәк, татар дөньясында гасыр башында актуаль булган проблемалар читтә яшәүче милләттәшләребез өчен милли тәрбия бирүдә әһәмиятләрен югалтмаган.

Газетада дини тәрбиягә багышланган язмалар да шактый. «Дин дәресләре», «Ислам шәригате буенча ни өчен укырга кирәк?» һ.б. мәкаләләр шундыйлар. Бу чит илләрдә яшәүче татарлар өчен туган тел, милли тәрбия белән беррәттән, милләтне саклап калуда диннең дә зур урын тотуы турында сөйли.

«Милли байрак»та татар мәгарифе тарихына багышланган мәкаләләр дә урын алган. Аларда гасырлар дәвамында татар мәгарифенең үсеш үзенчәлекләре, Россиядәге руслаштыру сәясәтенең мәгарифкә йогынтысы, атаклы татар мәдрәсәләре һ.б. темалар чагылыш таба [3].

Гомумән алганда, «Милли байрак» газетасында дөнья күргән шушы берничә генә мәкаләгә нигезләнеп тә, Ерак Көнчыгыштагы милләттәшләребез өчен мәктәп-мәгариф эшенең никадәр әһәмиятле булганын күз алдына китерергә мөмкин.

ӘДӘБИЯТ


1. Айслан. Балалар дөньясы // Милли байрак. 1936. 15 декабрь.
2. Акыш Г. Гаяз Исхакый – Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы // Гаяз Исхакый. Әсәрләр. 15 томда. Т. 15. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 129–144.
3. Бикбай К. Бу кем? Милли мәгариф аланында // Милли байрак. 1937. 7 май.
4. Гаяз Исхакый. Әсәрләр: 15 томда. Т. 12. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 471 б.
5. Гибадуллина Л. Газета «Милли байрак» как источник информации о жизни татар в Японии // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро. Казань: Институт Истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 80–82.
6. Гибатдинов М., Усманова Д., Усманова Л. Изучение тюрко-татарских материалов в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро.Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 9–19.
7. Ерак Көнчыгыштагы төрки-татар мөһаҗирләренең мирасы («Милли байрак» газетасының библиографик күрсәткече). Казан: Тарих институты, 2015. 284 б.
8. Кижү мәктәбе // Милли байрак. 1936. 6 ноябрь.
9. Мәркәз мәгариф шөгъбәсеннән // Милли байрак. 1936. 6 ноябрь.
10. Милләтнең кыйммәтле барлыгы – балалар вә аналык бурычы // Милли байрак. 1944. 1 октябрь.
11. Мукден төрек-татар мәктәбендә // Милли байрак. 1937. 11 июнь.
12. Нагоя мәсҗид-мәктәп бинасының ачылу мәрасиме// Милли байрак. 1937. 21 февраль.
13. Об архиве Урало-Алтайских языков профессора Хаттори Сиро // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро. Казань: Институт Истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 3–8.
14. Татарская энциклопедия: В 6 томах. Т. 4. Казань: ИТЭ, 2008. 768 с.
15. Тәрбия вә тәгълим // Милли байрак. 1937. 7 май.
16. Усманова Л. Газета «Милли байрак» – «энциклопедия» татарской эмиграции // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро. Казань: Институт Истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 60–65.
17. Харбин мәктәбе // Милли байрак. 1936. 6 ноябрь.
18. Хафизов З. Вопросы педагогики в одной из статей газеты «Милли байрак» // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. С. 83–87.


# Г. ИСХАКЫЙНЫҢ 1910–1920 ЕЛЛАР ИҖАТЫНДА «ГАИЛӘ БӨТЕНЛЕГЕ» МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Ә.Р. Мотыйгуллина*** *(Казан)*

В многогранной творческой деятельности Г. Исхаки особо подчеркивается проблемы семьи. Писателя с начала творчества заинтересовали проблемы семейных ценностей, взаимотношения между членами семьи. В статье раскрывается идейно-тематическая сторона творчества писателя 1910–1920 годов на примере рассказов «Наставница», «Башкирское счастье», «Долгожданная невеста», повести «Он еще не был женатым». Только в рассказе «Наставница» встречаемся с моделью идеальной семьи, а в остальных произведениях автора изображаются разногласия в семье.
**Ключевые слова:** татарская литература, рассказ, семейные ценности, проблема, творческий процесс, модель семьи.

In the multifaceted tvorcheskoy activity G. Ishaky especially stresses the problems of the family. From the very beginning of his career, the writer was interested in the problems of family values, the relationship between family members. The article reveals the ideological

and thematic side of the writer's work of 1910–1920 on the example of the stories «Mentor», «Bashkirskoe schatye», «The long-awaited bride», the story «He was not yet married». Only in the story «Mentor» we meet with the model of an ideal family, and in the remaining works the author shows disagreements in the family.
**Key words:** Tatar literature, story, family values, problem, creative process, family model.

Күренекле татар әдибе Г. Исхакыйның иҗаты күпкырлы. Шуңа күрә әдип табышларын чорларга бүлеп (мәгърифәтчелек чоры, таңчылык чоры, милләтчелек чоры, мөһаҗирлек чоры) өйрәнү кабул ителгән. Әмма әдип иҗатын тематик нисбәттән өйрәнү барышында әлеге бүленеш кысаларына гына сыеп бетми. Язучы гомере буе җәмгыятьне үзгәртү юлларын эзләгән. Аның фикеренчә, дәүләтнең нигезен гаилә тәшкил итә. Шуңа күрә гомере буе җәмгыятьтә тормыш-яшәеш моделен өйрәнгән. Ул гаилә тотрыклылыгы, бөтенлеге мәсьәләсен берничә яссылыкта яктырта [5]. Иҗатында катнаш никах мәсьәләләре, татар халкына хас күп хатынлыкның аяныч нәтиҗәсе, хатын-кыз бәхете, хатын-кыз иреге, шәхси мәнфәгатьләрен яктырту кебек тормыш-көнкүреш мөнәсәбәтләре «Сөннәтче бабай», «Кияү», «Көтелгән бикәч», «Башкорт бәхете», «Остазбикә», «Ул икеләнә иде», «Ул әле өйләнмәгән иде», һ.б. әсәрләрендә ачык чагыла. Шулай ук әдип гаилә кору, шул ук вакытта ир-хатын мөнәсәбәтләренең җимерелүенә китерүче сәбәпләрне тормышчан мисаллар белән дәлилли [4].

Әдип әсәрдән-әсәргә күчеп, идеаль гаилә моделен эзли. Гаиләдәге татулык, бер-берсен аңлашып яшәү, үзара хөрмәткә лаек гаилә үрнәген «Остазбикә» (1915) әсәрендә бирә.

Повестьта камил гаилә үрнәген, аның бөтенлеген саклап калу өчен көрәшүче, бер-берсен аңлаган ир белән хатын тормышын күрәбез. Әсәрдә татар авылы хатын-кызы бәхете мәсьәләсе үзәктә тора. Башка бик күпләрнеке кебек, инде җитлеккән кыз Сәгыйдәнең дә иң зур хыялы рәтлерәк кешегә кияүгә чыгу. Кияүгә чыгу яшенә җиткәч, мулла кызы Сәгыйдәне дә хатынлыкка соратып килә башлыйлар. Әтисе Хәйретдин хәзрәт шуларның берсенә – ерактагы бер авылның яңа указ алган яшь мулласына тукталырга була. Башта гадәт буенча, әлеге мулланың бөтен хәл-әхвәле, аның әтисе – «надан Рәхим мулла», аның хатыны, бала-чагасы, мәхәлә халкы, мәхәлләнең яшь муллага карашы, тирә-юнь муллаланың яшь муллага баглаган өметләре хакында тулы мәгълүмат җыю өчен әлеге авылга югалган затны эзләү сылтавы белән үзенә дә икенче хатын эзләп йөргән Шакир мөәзинне җибәрәләр. Шундый зур эшне Шакирның ничек башкарып кайтуын юмор белән тасвирлаганнан соң, автор туйга әзерләнүне шулай ук традицион йолалары белән һәм юмор да катыштырып сурәтли. Монда инде Сәгыйдәнең үз-үзен тотышы, уй-кичерешләре алгы планга чыгарыла. Иң әүвәл аңарда булачак каенанасы белән очрашуның бик авыр тәэсир калдыруы җентекләп сурәтләнә. Караңгы чырайлы каенанасын күргәч, Сәгыйдәгә бәхетсезлегеннән караңгы бүлмәгә кереп еларга гына кала. Моннан соң кызны туганнары булачак кияүнең ата-анасына охшамаган булуы белән тынычландыра башлыйлар. Шуннан түземсезлек белән вәгъдә ителгән кияүне көтү башлана. Тәрәзәдән «яңа гына мыек чыгып килә торган таза яшь йөз, йөзендәге үткен генә кара күзләре, җиңел генә хәрәкәтле сабыр гына кыяфәт»не күргәч кенә, Сәгыйдәнең җилкәсеннән зур бер йөк төшкән кебек була [3: 280]. Шунда ук аның котын алган кода белән кодагый онытыла, кызның күңелендә җылы өмет туа. Һәм Сәгыйдә үзенең кияү мулласын күңеленнән яратканнан ярата бара һәм аннан башка тора алмас хәлгә килә. Шушы бәхетеннән ул үзенең, тирә-юньдә мәртәбәле хәзрәт кызының, каената йортында «хезмәтчеләр ашата торган, сарыклар карый торган, сыерлар сава торган, карт белән карчыкның комганнарыннан җылы суны бушатмый тота торган асрау»га әверелүен дә

сизми кала [3: 281]. Әмма әтисе затлы нәселдән булган бердәнбер кызының мондый түбәнлеккә төшүен, кара мужик хатыны төсен алуын күтәрә алмый һәм үзе килеп авылда мужиклардан яшь муллага йорт саттырып алдыра һәм кияве белән кызын әлеге йортка күчерә. Моннан соң автор бу гаиләнең Вахид мулланың күзге көннәрнең берсендә ниндидер эш белән күрше авылга китеп, шунда тоткарлануы сәбәпче була. Мулла кайтмый торгач: «Төне нинди? Аты, килеп, күпер астына төшеп батып үлсә... Үлсә?!» – дигән уй Сәгыйдәнең «бөтен җанын-тәнен өшетеп» җибәрә, «әллә нинди кырык куллы, йөз тырнаклы, мең тешле булып, авызыннан ут чәчә торган зобани сурәтенә кереп» аның алдына баса [3: 288]. Моңа кадәр Вахид муллага мөкиббән китеп, аңардан башка беркем турында уйламый яшәгән Сәгыйдәнең күңеленә хәзер: «Әй бер углым булса иде!» – дигән уй яшендәй үтеп керә һәм аңарда «моңача һичбер булмаган бер куәт белән балалы буласы килү – үзенең угылын күрәсе килү дәртен» тудыра [3: 289]. Алга таба автор Сәгыйдәнең моннан соң авыл кешеләренә дә, үзләренең мал-туарына да яраткан баласына карагандай карый башлавын шундый тасвир ярдәмендә күрсәтә. Ә инде кемнәрднер кунакка килсә, ул «бөтен гомерен шуларның баласы артыннан йөрергә сарыф итте: ул үзе йоклатты, үзе коендырды, үзе уйнатты, сөяргә тотынса, баланы елатмаеча туктамады» [3: 318]. Героинясының кинәт кенә хасил булган бала сөю хисен шундый тормышчан детальләр ярдәмендә ачу белән бергә, автор алга таба Сәгыйдәнең үз баласын булдыру теләген тормышка ашырырга омтылуларын да тасвирлый. Хатын үзе бала таба алмавын белгәч, угыллы булуның башка юлларын эзли башлый: хәзрәткә бер хатын алып бирсәм?... аның баласы бит хәзрәт баласы була. Хәзрәт баласы минем балам...» – дигән уйга бирелә. Баланың нәселне дәвам итүче булуын аңлый. Әмма Сәгыйдәнең ирен икенче хатынга өйләндерү теләге җитди каршылыкка очрый. Аның:

«– Хәзрәт, син җигәрендә әле, сиңа әле, Аллага шөкер, өмет бетмәгән... Шул өйләр, шул дәүләтләр, шул мәчет, мәдрәсәгә хуҗа, үзеңә дә, миңа да догачы калдыру өмете бетмәгән... Хәзрәт, сиңа өйләнергә кирәк!» – дигән сүзләрен Вахид мулла башта ишетергә дә теләми. «Сәгыйдәдән башка хатын юк», – фикере белән яшәвен дәвам итә [3: 310]. Ләкин нәсел эшен дәвам итәрлек баласы юклыкны аңлау, җиде буыннан килгән михрабның яңа иясен булдыру теләге геройны ахыр чиктә сөйгән остазбикәсенең тәкъдимен кабул итәргә этәрә. Хатыны сайлаган Галимәгә өйләнә. Икенче хатынның баласы тугач та, Сәгыйдәнең йортта төп хуҗабикә һәм яшь хатын тудырган балаларның төп анасы булып калуын рухи бөеклектә күрсәтә. Гаилә нигезен, киләчәк буынны саклап калу өчен Сәгыйдә үз хыялына, йөрәк әрнүе, көнләшү хисләренә карамыйча ирешә. Әсәргә чор тәнкыйте дә битараф калмый. Әсәр героеның кылган гамәлләренә бәя биреп, монда адәмнең йөрәгендәге тойгылар, бу халәтнең процессы үзе кебек үк табигый, – дип бәяләнә [2: 236]. Нәтиҗәдә гаилә учагы тагын да ныгый, ир белән хатын мөнәсәбәтләре тагын да җанлана, яңа сулыш ала.

Г. Исхакыйның 1910 елларда язылган әсәрләре арасында гаилә бөтенлеген саклауны үзәккә алган, бер-берсен аңлап яшәүнең капма-каршысы, ягъни антитнезасын да очратабыз. Әдипнең гаиләнең җимерелү сәбәпләрен ассызыклаган фикерләре «Башкорт бәхете» (1910) һәм «Көтелгән бикәч» (1910) хикәяләрендә чагылыш таба.

«Башкорт бәхете» ндә солдаттан кайткан башкорт егетенең гаилә кору драмасы яктыртыла. Әлеге гадәт буенча әнисе аны моңа кадәр күрмәгән, белмәгән бер башкорт кызына өйләндерергә була. Туй үткәрер вакыт җитеп, җирле йола буенча булачак кәләшен урманга киткән кызлар арасыннан табып алгач, ул бөтенләй диярлек күз алдына китермәгән кешегә тап була. Кәләш дигәнебез

ун-унөч яшьтәге балалыктан чыкмаган кечкенә буйлы кызчык була. Аңарда әле хатын-кызлык хисләре һәм теләкләре дә тумаган икән. Шунлыктан ул иренең төннәрен аны сөяргә теләвен «марҗалар берлә әллә нинди оят эшләргә солдаттан өйрәнеп кайткан», дип кире кага [3: 177]. Һәм әсәр герое менә дүрт ел инде шушы «бала-хатын» белән үзенең ирлек теләкләрен канәгатьләндерә алмыйча, ягъни гаилә тормышыннан бернинди ямь һәм тәм тапмыйча гомер уздырып ята икән.

«Көтелгән бикәч» хикәясендә шундый ук юл белән өйләнүнең әсәр героена никадәр авыр тәэсир иткәнен ачыграк гәүдәләндерү өчен башта Вәли мәхдүмнең башта малай чакта үзенә ярәшеп куелган Габдерахман хәзрәт кызы Ләлә белән очрашуга ничек әзерләнүен яктыртуга зур урын бирелә. Булачак кәләшнең моннан дүрт йөз чакрымдагы шәһәрдә яшәве сәбәпле, герой аны өйләнешкәнчегә кадәр күрә алмый. Һәм хыялый зат буларак күңелендә кызның илаһи образын тудыра. Шундый кызга тиң булыр өчен ул бик тырышып укып мәдрәсә тәмамлый, Коръәнне яттан өйрәнә, «Тәфсир» белән «Хәдис»не укырга өйрәнү нияте белән Гарәбстанга китә. Шушы дәвамлы сәяхәте вакытында ул төрле халыкларның бик чибәр кызларын, әйтик яһүд, грузин, төрек, гарәп, француз чибәрлеген күрә, әмма үзенең хыялындагы Ләләсен алардан да сылурак итеп күз алдына китерә. Ахыр чиктә Вәли мәхдүм булачак кәләшен «озын сачле, зифа буйлы, матур йөзле, энҗе теше, зур күләр күзле, нурлы керфекле» итеп күзаллый башлый [3: 184].

Шулай күзаллаган Ләләнең «сәгадәте өчен башына “Коръән”, “Тәфсил”, “Хәдис”, әллә никадәр фикъһе (ислам дине хокуклары турында белем), ысул мәсьәләләре тутырып этисе янына имамлыкка тамга да алып» туган иленә кайткач, Вәли мәхдүм түземсезлек белән очрашуны көтә башлый. Шул көн килеп җиткәч, ул дүрт йөз чакрым араны кыз турынгы уйланудан вакыт узганын да сизми үтеп, Габдерахман хәзрәт өенә килә һәм анда реаль Ләлә белән, ягъни «зур табак битле, калын куе кашлы, кечкенә күзле, утын кеби зур куллы, чүмәлә кеби зур тәнле бер хатын» белән очраша [3: 185]. Моңа кадәр бөтен тырышканнарының шушы хатын өчен булганлыгын аңлауның геройга никадәр авыр тәэсир иткәнен күрсәтү өчен автор үтемле деталь таба. Ягъни хыялдагы Ләләне күргәч, Вәли мәхдүмнең җан авазы яңгырый: «Менә шуның өчен Коръән хафиз кылдың, шуның өчен мәдрәсәдә изелдең, шуның өчен Гарәбстанда өч ел тордың, шуның өчен әллә ничә мәртәбә тугъры килгәндә файдалана алмаенча, гыйффәтеңне сакладың! – диде» [3: 186].

Шул рәвешле, Вәли мәхдүмнең ялган идеалга ышанып яшәве фаҗигале язмышка китерә. Алда карап кителгән мисаллардан күренгәнчә, Г. Исхакый гаиләнең таркалу сәбәпләрен милли йолаларга таянып яшәүдән күрә. Хиссез мәхәббәткә корылган гаиләнең азагы бик аянычлы булуын бәян итә..

Г. Исхакый иҗатында әзер гаилә модельләре белән генә эш итми. Төрле шартларда яшәгән татар халкы вәкилләренең томыш-яшәешен тасвирлый. Татарлар яши торган төбәктән аерылган Шәмси язмышы Г. Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» (1915) повестендә сурәтләнә.

Повестьнең үзәк герое Шәмси гаилә кору турында уйлый гына әле. Бу мәсьәләне хәл итүаның өчен шактый катлаулы һәм каршылыклы төс ала. Автор теманы ачканда егетнең яшәү рәвешен үзгәртеп, характер сыйфатларын, татар милләтенә хас үзенчәлекләрне ача. Авыл егетен әдип шәһәрнең рус цивилизациясенә «күчереп» рухи дөньясының катлаулануын күрсәтә. Шәһәр тормышы, сәнгать белән кызыксыну Шәмсине үз милләтеннән булмаган Анна белән очраштыра. Бу кыз белән очрашу, аралашу татар кызына өйләнү хыялы белән яшәгән Шәмсинең тормышын үзгәртеп җибәрә. Ул агым уңаена йөзә

башлый. Хәзер кәләшнең татар кызы булуын, әмма Аннага охшаган булуын тели башлый. Аңа хәзер Анна кебек дус була белә торган, Анна кебек үз хисабын йөртми торган, Анна кебек гомерендә бер каты сүз сөйләми торган, Анна кебек тормышның һәр борылышыннан тәм таба белүче татар кызына өйләнергә кирәк. Әлбәттә, герой андый кызны таба алмый. Анна Шәмсинең хатын-кызлары турындагы барлык уңай сыйфатларын үзендә туплаучы идеалга әверелә. Ир кешене кадерләп тору, өс-киемнәрен юу, авырган чакта тәрбияләү, тәмледән-тәмле ризыклар белән тулы мул өстәл әзерләү, иртән назлап уяту, өйне чисталыкта, аклыкта, сафлыкта тоту аңлап, ярдәм итеп тору, авыр чакта дәшми калу кебек күренешләрнең барысы да Анна Васиьевнада тупланган.

Әмма Шәмси уйларындагы гаилә кору мәсьәләсе бала туу турындагы хәбәрне ишеткәч, үзгәреш тә кичерә. Иң башлап бу хәбәр үзе геройга аяз көндә яшен суккандай тәэсир итә: аның «бөтен әгъзаларыннан суыклы-әчеле бер агым үтте, кисәктән башына сугылган кеше кебек иләс-миләс булды да калды. ... Албасты пәрие баскан кебек басты» [3: 357]. Бер яктан, Шәмси хәзер «татар баласы булгач, татар гаиләсе ясап, татар балалары тудырыр, үстерер өчен» татар кызына өйләнергә кирәклеген тагын да ныграк аңлый. Икенче яктан, туачак Васяның яки Яшаның балалык хакын аяк астына салып таптарга ул үзендә көч таба алмый. Алга таба реаль тормыш барыбер үзенекен итә. Бераздан Аннаның үзен «йомшак, матур, җылы, тулы тормыш белән» чолгап алуы нәтиҗәсендә Шәмси тынычлана, балага да карашын үзгәртә [3: 359]. Хатынның моннан соң бер-бер артлы туган балаларын чиркәүгә алып барып чукындырганын белгәч, кызып китеп, тагын бер аның белән араны өзәргә һәм, ниһаять, татар кызына өйләнергә ниятләп авылына кайтып китсә дә, Шәмси анда авыл кызына өйләнеп, Аннадан башка яши алмавын аңлап, туйга әзерләнгән җирдән кабат шәһәргә әйләнеп кайта. Аны мөселманлык белән бәйләүче бер юанычы гына кала, ягъни ул балаларын кайчан да булса Истанбулга илтеп, мөселман тәрбиясе бирү турында хыялланган хәлдә әсәр тәмамлана.

Шулай итеп, повестьта башка милли мохиткә эләгүнең татар кешесен үзеннән-үзе милли җирлектән һәм яшәү рәвешеннән аеруы һәм аның нәсел тамырлары коруга китерәчәге күрсәтелә. Әдип бу хәлнең ахыр чиктә милләт язмышына кире тәэсир итәчәгенә, гаиләнең тотрыксыз булуына ишарә ясый.

Шул рәвешле, Г. Исхакыйның 1910–1920 елларда иҗат иткән проза әсәрләре арасында гаилә бөтенлеген саклауга багышланганнары аерым игътибарга лаек икән. Әдипнең бу чор иҗатында татар халкының яшәү рәвешен чагылдыру, үрнәк гаилә моделен күрсәтү омтылышы ясала. Әмма гаилә кору аеручa дини кануннар белән кушылып киткән очракта зур гына каршылыклар да тудыра икән. Ислам дине кануннары нигезендә яшәгән Сәгыйдә үзе дә тирә-юньдәгеләрнең дә бәхетле тормышын тәэмин итә ала. Әмма «Башкорт бәхете»ндәге хатын-бала, «Көтелгән бикәч»тәге Ләлә, «Ул әле өйләнмәгән иде»дәге Анна Васильевна Г. Исхакый тудырган хатын-кызлар галереясында милләтнең киләчәген күз алдына китерү мөмкинлеге бирмиләр. Андый гаиләдә үзара дустанә мөнәсәбәт, киләчәккә якты өметләр баглау күзәтелә алмый.

## ӘДӘБИЯТ


1. Гайнанова Л. Сикәлтәләр аша: Г. Исхакый әсәрләре эзләреннән // Шәһри Казан. 1991. 30 январь.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 8 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 447 б.
3. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авторлары И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.
4. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.
5. Сәмитова С.Г. Гаяз Исхакый иҗаты (1914–1917). Казан: Казан ун-ты нәшр., 2005. 125 б.

# МИЛЛӘТ МӘҖЛЕСЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КАРАШЫ

***З.Г. Мөхәммәтшин*** *(Казан)*

В статье рассматривается отношение и анализ работы заседаний Миллят Маджлеси (Национального собрания) выдающегося татарского писателя и одного из основателей политического движения у татар Гаяза Исхаки. Г. Исхаки в своей статье старается анализировать политическую обстановку в России и национальном движении, в том числе политические решения о путях создания государственности татар на путях стоительства «Штата Идель-Урал». И он дает оценку спорным вопросам, не решенным проблемам. В статье также отражается борьба между разными политическими течениями татарской общественности, которые влияли на особо важные политические решения в ходе заседания.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, Уфа, Учредительное собрание, Казань, Москва, Первый и Второй Всероссийкий съезд мусульман, «Штат Идель-Урал».

The article examines the relationship and analysis for the work of the Milli Majlisi meetings (the national assembly) by the outstanding Tatar writer and one of the founders of the polytheche movement in the Tatars of Gayaz Iskhaki. G. Iskhaki in the articles strives to analyze the political situation in Russia and the national movement, including in the first history of the Tatars on the creation of the political statehood decision «State of Idel-Ural» by ways of assessing disputed issues and unsolved problems. The articles also reflect the struggle between different trends of the Tatar public, which influences particularly important political decisions during the meeting.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, Ufa, Constituent Assembly, Kazan, Moscow, First and Second All-Russian Congress, «State of Idel-Ural».

XX гасыр башында татар иҗтимагый хәрәкәте һәм әдәбиятында башланган уңай үзгәрешләр милләтнең төрле социаль катламнарын төрле сәяси һәм фәлсәфи карашлар, төркемнәргә бүлә. XX гасыр башында ук татарның талантлы әдибе буларак танылган Г. Исхакый да бу хәрәкәттән читтә калмый. Аның беренче чыгышлары һәм язган публицистик мәкаләләре рус эсерлары фиркасы идеясендә формалаша, соңрак, 1913 елда сөргеннән кайкач, рус кадетлары фиркасы нигезендә барлыкка килгән «Мөселман иттифакы»ның милли-дини идеяләренә өстенлек бирүне кулайрак саный. 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң Мәскәүдә 1–11 май көннәрендә эшләгән Беренче Бөтенрусия мөселманнарының корылтаенда гомумтөрки фикерне алга сөреп, Россиянең киләчәген унитар дәүләттә күрә, татар милләтен фәкать Россия составындагы халык итеп кенә күз алдына китерә. 1917 елның июль-август айларында Россиядә сәяси вазгыятьнең кискенләшүе сәбәпле, 1917 елның 21–31 июль көннәрендә Казанда эшләгән Икенче Бөтенрусия мөселманнары корылтаеның 22 июль утырышында кабул ителгән Милли-мәдәни мохтарият идеясенә кушыла. Аның фикеренчә,татарның беренче милли-мәдәни мохтарияте дә Россия дәүләте идарәсендә кануни нигездә формалашкан оешма булырга тиеш. Шунысы мәгълүм: 1917 елның 4 декабре 1918 елның 24 гыйнвар көннәрендә Уфада җирләшкән Милләт Мәҗлесе утырышларында Г. Исхакый әле милли бәйсезлек идеяләренә кушылып китә алмый. Шуңа карамастан, ул XX гасыр башы татар иҗтмагый хәрәкәте, аның сәяси көрәш тарихында күренекле эз калдырган, гомеренең күп өлешен сәясәткә багышланган шәхес. Бу чыгыш-язмада, әдипнең турыдан-туры катнашлыгында узган Милләт Мәҗлесе утырышларында милли сәясәттә төп игътибар итәргә тиешле мәсьәләләр, кайбер вакыйгаларга аның мөнәсәбәтенә, фаҗигале татар тарихында беренче тапкыр милли бәйсезлек идеясе күтәрелгән Милләт Мәҗелесе эшчәнлегенә тукталу кирәк табылды.

Бу тема хакында сүз алып баруга ихтыяҗ бар да кебек. Беренчедән, Милләт Мәҗлесе утырышлары тәмамлануга 2018 елның гыйнвар аенда 100 ел

тулды, икенчедән, Милләт Мәҗлесе мөнбәрендә яңгыраган татар халкы өчен мөһим стратегик һәм тактик мәсьәләләр, андагы каршылыклар, аларга китергән бәхәсләр һәм Милләт Мәҗлесен юк итүгә китергән сәбәпләр, хаталар, инде озак еллар узуга кармастан, XX гасырның 80 еллар уртасында башланган җәмгыятьтәге үзгәрешләр тәэсирендә 1988 елда төзелгән Татар иҗтимагый үзәгенең милли көрәш тарихында да кабатлана һәм аңа быел 30 ел тула. Милләт Мәҗлесендәге кискен каршылыклар берничә еллык сәяси көрәш тәҗрибәсе булган милләтнең XX гасыр башында татар халкының әле сәяси мәсьәләләр хәл итәргә әзер түгеллеген, аның стратегик планнары, гомум милли идеясенең юклыгын раслый, бу җитешсезлекләр Г. Исхакый катнашлыгында узган вә егерме елдан соң Милләт Мәҗлесе турында «Яңа милли юл» журналы, «Милли байрак» газетасында басылган мәкаләләрендә чагылыш тапкан фикерләренә кабат тукталуны таләп итә. Кызганыч, Г. Исхакый мәкаләләрендә яңгыраган фикерләр, сәяси хаталар XX гасырның ахыры – XXI гасыр башында да шул ук кала.

Мәгълүм ки, XX гасыр башы милли хәрәкәте татар тарихчылары – Р. Вәлиев [1], И. Таһировларның хезмәтләрендә шактый өйрәнелгән [7: 6–31], соңгы вакытларда Төркиядә яшәп иҗат итүче Н. Дәүләтнең дә Милләт Мәҗлесе тарихын тикшергән, аның уңышлары һәм уңышсызларын дәлилләгән монографик хезмәте басылды. Н. Дәүләт үзенең хезмәтендә Милләт Мәҗлесенең оештырылуы, эш процессы, анда катнашкан шәхесләрне һәрберсен искә алып, Милләт Мәҗлесенең ничек эшләвен, нинди карарлар чыгаруын җентекләп тасвирлаган [2: 189–278]. Бу язмада, фәкать Г. Исхакыйның Милләт Мәҗлесенә биргән бәясе, анда искә алынган кайбер вакыйгалар уңае белән туган аерым фикерләргә генә игътибар юнәлтү урынлы булыр кебек.

Г. Исхакыйның Милләт Мәҗлесенең тарихына багышланган язмалары «Яңа милли юл» журналының 1937 елгы 12 нче һәм 1938 елның 1 нче саны һәм шул ук елның 3 нче санында «Милләт мәҗелесенең егерме еллыгы», «6 февральдә Милләт Мәҗлесенең егерме еллыгы унае берлә Гаяз әфәнде Исхакыйның Варшау радиосы аркылы сөйләгән сүзе» исеме белән һәм «Милли байрак» газетасының 1937 елның 3 декабрендә «Милләт Мәҗлесенең егерме еллыгы (1917, 4 декабрь – 1918, 24 гыйнвар)» баш астында нәшер ителгән.

Милләт Мәҗлесе 1917 елның Октябрь инкыйлабыннан соң татар халкының кыйбласыз калган көннәрендә җыела. Ул бу көннәрдә, беренчедән, милли мохтарият идеясен тормышка ашачагына ышана, икенчедән, 1918 гыйнварында Петрогродта җыелачак Дәүләт Учредительное собраниесендә яңа Россиянең федераль дәүләт буларак формалашуын көтә. Өченчедән, сәяси вазгыятьнең көнләп түгел, сәгатьләп үзгәреп торган илдә, шул исәптән милли сәясәтчеләр арасында еш алышынган сәяси карашларның кискенлеге Милләт Мәҗлесендә көн тәртипләренең бер-бер артлы үзгәреп торуларына китерә, аның эшчәнлегендә һәрдаим төзәтмәләр ясарга этәрә, фикер каршылыкларына сәбәп бирә. Г. Исхакый үзенең мәкаләләрендә, бигрәк тә «Яңа милли юл» журналының 1937 елгы 12 нче һәм 1938 елгы 1 нче санында басылган язмасында аларга җентекле тукталып, Милләт Мәҗлесенең нинди шартларда эшләвен күз алдына китереп бастыра. Әдип-публицист Милләт Мәҗлесендә килеп туган киеренке мәсьәләләргә киңрәк тукталуы, шул проблемаларга игътибарны күбрәк юнәлтүе урынлы да кебек. Мәкаләдән аңлашылганча, Милләт Мәҗелесендә фикер каршылыклары нәтиҗәсендә барлыкка килгән төп ике фракция – «төрекче»ләр һәм «тупракчы»ларның сәяси көрәшләре һәм бәхәсләре, аларны хәл итүдәге проблемаларны тасвирлап, әдип-публицист һәрбер мәсьәләгә үз мөнәсәбәтен белдерә. Шуны да ассызыклап үтү кирәк: Милләт Мәҗлесендә

формалашкан «төрекче»ләр фракциясен XX гасыр башын иҗтимагый хәрәкәтендә актив катнашкан, сәяси яктан азмы-күпме тәҗрибә туплаган татар зыялылары, сәүдәгәрләр тәшкил итсә, «тупракчы»ларда исә европа һәм рус мәдәнияте тәрбиясен алган, чагыштырмача яшь буын зыялылары туплана һәм алар милли хәрәкәткә шактый радикаль юнәлеш бирергә телиләр. Г. Исхакый искәрткәнчә, әлеге фракциягә «җиде-сигез большевик фиркасенең әгъзалары» да кушыла. Шул рәвешле «төрекче»ләр фракциясендә илледән арыграк әгъза булса, «тупракчы»ларда утыз биш – утыз алтыдан артмый. Язма раслаганча, Милләт Мәҗлесендә милләт мәнфәгатен кайгырткан, аеруча мөһим мәсьәләләр ике фракция әгъзалары арасында кискен каршылыклар нигезендә авырлыклар белән хәл ителә. Алар берничә. Беренчесе, Милләт Мәҗлесе ачылган көнне «тупракчы»лар фракциясенә кергән татар большевиклары Совет хөкүмәтенә Милләт Мәҗлесенең ачылуын белдереп телеграмма сугу фикерен күтәрәләр. Бу мәсьәлә шактый бәхәсләр тудыра, шуңа карамастан, күпчелек «без үзебезнең милли-мәдәни мохтариятыбызны игълан иткән халыкның вәкилләре, үзебезне үзебез фәкать милләтебез алдында гына мәсъүл тотабыз *(җаваплы тотабыз).* Вә һичбер төрле рус хөкүмәтенең безнең эчке эшләребезгә катышырга хакын танымыйбыз, без үз милләтебезнең генә садыйк тәбәгасебез *(тугрылыклы гражданнары),* диделәр. Телеграмм тәклифен рәд иттеләр *(тәкъдимен кире кактылар)»*, – дип [3: 197], яңа идарәгә килгән большевик хөкүмәтен таныган телергамма җибәрүдән баш тарта. Ике фракция арасындагы каршылык Милләтләр эшләре комиссары Й. Сталинның телеграммасына җавап бирү-бирмәүдә дә бәхәсләр китереп чыгара, нигездә күпчелекнең каршы булуы белән әлеге мәсьәлә дә уңай чишелеш таба. Икенчесе, һәм Милләт Мәҗелесе өчен генә түгел, татар һәм башкортны каршы куйган катлаулы мәсьәләләрнең берсе – Зәки Вәлиди һәм Шәриф Манатовларның Оренбургта башкорт корылтае җыеп, Милләт Мәҗлесенә каршы хәрәкәт итүе. Бу мәсьәлә гаять тә четеркле һәм милли хисләргә бәйле. Г. Исхакый искәрткәнчә, Милләт Мәҗлесе вәкилләренең катнашлыгы белән бу проблема да өлешчә уңай якка үзгәрә. Әдип-публицист бу хакта: «Нәтиҗәдә, Оренбургтагы «башкорт корылтае», без кардәшләребез татарлар, мишәрләр, нугайлар, типтәрләрдән аерылырга теләгебез юк, безне алдап китерделәр, дип, зур тавыш күтәреп, Зәки Вәлиди, Шәриф Манатовларның үзләрен генә калдырып, мәҗлесләрен калдырып ташлап чыктылар», – дип яза [3: 198–199]. Г. Исхакый Милләт Мәҗлесендә милләтнең гомум исемен билгеләүне төп бурыч икәнен ассызыклый.

1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр татар милләте төрле исемнәр – болгар, төрек, татар исемнәре белән атап йөртелә. Милләт Мәҗлесе бу проблемага да нокта куя – киләчәктә «Идел-Урал төрек-татар» исеме белән йөртeләчәген искәртә. Мәкаләдән күренгәнчә, исем сайлау да каршылыксыз узмаган, аеруча «күршеләрнең» күңелләренә хуш килерлек исем табу хәлне тагын да катлауландыра.

Бу болгавыр заманда гайре рус булмаган милләтләргә каршы большевикларның милли сәясәтләре Идел буе халыкларын да уйланырга мәҗбүр итә. Алар, Г. Исхакый язганча, кызыл рус тәэсирендә калып юкка чыгу куркынычын тоялар. Россиянең үзәк өлешендә бердәнбер алдынгы карашлы һәм беренчеләрдән булып сәяси кыйбласын билгеләүгә йөз тоткан татар халкының тәүге оешкан Милләт Мәҗлесенә Идел буеның мари вәкилләре үзләренең мөрәҗәгатьләре белән чыга. Марилар: «Без татар халкы берлә бергә меңләрчә еллар буе дуст яшәдек. Бүгенге большевик татар тартышында да без сезнең берлә бергәбез», – дип белдерәләр [3: 198]. Әдип-публицист искәрткәнчә, хәтта рус агымнары, православный дине оешмалары да Милләт Мәҗлесеннән

яклау эзли. Марилар турында сүз кузгалтуның төп сәбәбе: бу милләт татар халкы белән дус яшәү генә түгел, тарихтан мәгълүм булганча, татар халкының бердәнбер дәүләте саналган Казан ханлыгын Иван Грозный кан белән яулап алганда да ханлык гаскәрләре арасында мари милләте вәкилләре күпләп катнашкан. Әлеге тарихи бергәлек мари һәм татарның гомерлек юлдашы булган. Г. Исхакый искә алган рус агымнары һәм православный дине әһелләренең Милләт Мәҗлесенә тартылу тарих беләнраслана кебек. Беренчедән, рус дәүләте мөстәкыйльлеген югалту куркынчы янаган, тарихка «гаугалы заман» буларак кереп калган 1600–1613 елларда, төгәлрәге 1612–1613 елларда, Казанда рус боярлары, воеводалары Мәскәүдән аерылган бәйсез Казан дәүләтен төзү теләге белән фетнә күтәрәләр. Ләкин Мәскәү гаскәренең оешканлыгы һәм күпкә көчле булуы Казан дәүләтен торгызуга комачаулый. Икенчедән, православныйлар да очраклы рәвештә генә Милләт Мәҗлесенә тартылмый. Тарихка күз салсак, рус дәүләте, рус патшалыгында бөек реформатор буларак танылган Петр I идарәсенә кадәр мәмләкәт, нигездә православный чиркәве идарәсендә була. Петр I властька килү белән православный чиркәвен дәүләт идарәсеннән читләштерә. Ул фәкать үз хакимлегенә, Петр I вафатыннан соң, XVIII гасырның икенче яртысында гына ирешә ала. Россиядә диннән читләштерүнең икенче адымы 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң кабат күтәрелә. Әлеге мәсьәлә мөселманннар арасында да куера, алар да динне дәүләттән аеру кирәклегенә басым ясыйлар. Һәр ике дини идеологиянең үз максатлары бар, әлбәттә. Бу урында, иң беренче, мөселман оешмаларының динне дәүләттән аеру теләгенә ачыклык кертү мөһим дип саныйм. Әлеге адым рус православный диненә иярүдән бигрәк, мөселман дини ошмалары финанс ягын үзләре карамагына алып, акча белән мөстәкыйль идарә итәргә тели. Милләт Мәҗлесендә төп каршылык шуңа бәйле карала. Г. Исхакый мәкаләсендә проблемага тулы аңлатма бирелгән. Өзеккә игътибар итү комачау итмәс кебек. Анда түбәндәге юллар бар: «Шулар арасындагы мөһимнәренең берсе дә – милли тәшкиләтебездә *(оешмабызда)* динне милләттән аеру-аермау мәсьәләсе – аерым урын тоткан иде. Безнең Идел-Урал төрек-татарларының милли үзлеген, барлыгын саклауда динебез исламиятнең руслардан башка булуы иске заманнарда бик зур роль уйнаганы кеби, безнең милли мәдәниятебезнең гәүдәләнүендә дә бик тирән эз калдырып, зур тәэсир ясаган вә киләчәктәге барышыбызда да үзенең ролен бетермәгән иде. Шуңарга милләтчеләребезнең күпчелеге милли мөәссәсәләребезне *(оешмаларыбызны)* дини мөәссәсәләребез берлә бергә йөртү, милли мәдәниятне динебез берлә бергә алып бару тарафында иделәр. Шул нигездән чыгып, мохтарият һәйәте Диния нәзарияте янында Уфага йирләшкән, вә Милләт Мәҗелесе дә шул сәбәптән Уфага чакырылган <…>. Безнең динебез, дин әһелебез һәрвакыт рус хөкүмәтеннән золым-җәбер күреп килгәнгә,үзенең көчене, куәтене халкыннан гына алганга, бездә милләтне диннән аеруның сәбәпчесе юк иде. Ләкин безнең ул вакыттагы кайбер яшьләребез русларда булган, булуы матлуб *(соралган)* нәрсәләрне тәнкыйтьсез һәммәсен үз халкына кертүне фазыйләт *(яхшы эш, яңалык)* дип йөргәнгә, яшьләр арасында динне милләтән аеру да бер мөһим мәсьәлә кеби йирләшкән иде. Татар большевиклары моны программаның башына ук язып куйганнар, һәрбер йирдә шул хакта сөйлиләр, пропаганда ясыйлар иде» [3: 199]. Тәкъдим ителгән өзек Милләт Мәҗлесендә, диннең милләтне ничек саклавы, аның әһәмияте югалмавын ачык күрсәткән. Православныйларның Милләт Мәҗлесеннән яклау эзләүләре хакында да ачыклык кертү кирәктер. Милләтне, аның мәдәниятен саклауда мөселман диненең алдан күреп, динне дәүләттән аермауны беренче планга куйган Милләт Мәҗлесе карарларын православный дине әһелләре дә үз күрә, икенчедән,

җирле православный һәм рус милләтенең аерым агымнары, форсаттан файдаланып, үзәк идарә системасына буйсынудан качып, Милләт Мәҗлесенең «Идел-Урал дәүләте» идеясенә тартылулары итеп карарга да кирәктер. Әлеге сәбәпләр, рус православный диненең аерым төркемнәрен татар халкының милли оешмасы саналган Милләт Мәҗлесенә мөрәҗәгать итәргә этәргеч тә биргән, күрәсең.

XX гасырның иҗтимагый хәрәкәте алгарышлары татар халкының милли үзаңы уянуга зур этәргеч бирә. Татар халкы XX гасыр башына кадәр рус дәүләтенең милли изүе, аның басымы астында яшәп, милли-мәдәни, дини тәрбияне үзенчә хәл итә алудан мәхрүм иде. 1905–1907 елгы инкыйлаб тәэсирендә татар иҗтимагый хәрәкәте, милли-мәдәни һәм дин тормышында җанлану, вакытлы татар матбугаты туугa, милли мәгарифен үстерүгә азмы-күпме юл ача. Инкыйлаб дулкыны белән милли мәгариф системасын булдыру, уку-укытуда реформалар, татар исеменә бәйле һәм дини мәсьәләләр, рус сәяси фиркалары тәэсирендә хәрәкәт иткән татар зыялыларының киләчәктә татар халкының милли һәм дини яшәеше нинди юл белән китәчәге һәм башка проблемалар иҗтимагый тормышта чагылыш таба, милли матбугатта һәрдаим яктыртыла, бәхәсләр ута, ниндидер чишелешләр дә була. Татар милләте шул ук мәсьәләләр белән 1917 елгы Октябрь инкыйлабына килеп җитә. Милләт Мәҗлесе дә бу мәсьәләләрне кабат күтәрә һәм бәхәсләргә юл ача. Г. Исхакый мәкаләсендә дә моңа игътибар бирелә. Нигездә, проблемалар никадәр мөһим булмасын, язмадан һәм тарихтан күренгәчә, алар гасыр башында нинди бәхәсләр уятмасын, Милләт Мәҗлесендә камил эшләнгән карарлар кабул ителмәсен, Россиянең идарәсе большевиклар кулына көчү белән юкка чыгарыла. Нәтиҗә күз алдында.

1917 елда бер-бер артлы узган Беренче һәм Икенче Бөтенрусия мөселманнары корылтаеннан аермалы буларак Милләт Мәҗелесе утырышларында вазгыять таләбе булган сәяси темалар да чагылыш таба. Әдип-публицист әлеге мәсьәләләргә киң тукталa. Бу чорда татар халкының киләчәк язмышын билгели торган милләтнең дәүләти төзелеше, аны саклаучылык гаскәри көчен, идарәсен ныгыту иде. Мәкаләдән, татар халкының үткән тарихыннан аңлашылганча, Милләт Мәҗлесе бу мәсьәләләрдә төпле карарга килә алмый һәм аның күп төрле сәбәпләре дә бар, сәяси яктан чыныккан, тәҗрибә туплаган Г. Исхакый да Милләт Мәҗлесе утырышларында үз хаталарын җибәрә. Хәер, милли бәйсезлек идеясен яклау, милли көрәш идеологиясе, принциплары, юнәлешләрен билгеләнмәгән халык мөстәкыйльлек фикерен байрак итәрлек шәхесләр ул чорда булу ихтималы да шикелле. Г. Исхакый да шулар рәтендә.

Югарыда аның кайбер сәяси һәм фәлсәфи фикерләренең үсүе һәм үзгәрүе хакында сүз булган иде инде. Бу урында киңрәк тукталу кирәктер, мөгаен. Әдип-публицист 1905–1907 еллардагы инкыйлаб дулкынында кадетлар фиркасенең сәяси программасын юнәлеш итеп алган, төрек-татарның беренче сәяси фиркасе «Мөселман иттифакы» корылтайлары күтәргән милли проблемаларны, патша Россиясендә яшәүче башка милләтләр белән янәшәдә, төрек-татарның тигез хокуклыгын тануга каршы чыга. Хәтта ки фирка эшчәнлеген тәнкыйтьләгән Г. Исхакый 1913–1917 елларда «Мөселман иттифакы» фиркасенең программасында гәүдәләнгән мөһим идеяләрнең, милли сәясәтнең нигезе итеп ала, шуны алга сөрә. Милли-мәдәни һәм дини мәсьәләләрнең кайсы гына тармагын мәкаләләрендә яктыртмасын, тормышның ачысын-төчесен татыган, аның кануннарын тирәнрәк аңлый башлаган, тәҗрибә туплаган әдип-публицист үтә дә кызыл социалистлыктан ягъни эсерлар идеясеннән, акрынлап ваз кичкән Г. Исхакыйны хәтерләтә. Гомумтөрек сәяси программаларда исә ул төрекче булып кала. Кызганыч ки, бай тәҗрибәле күп кенә төрек-татар зыялы-

лары кебек, 1917 елның катлаулы сәяси вазгыятендә ул да татар халкының тулы мөстәкыйлеген яклый алмый, хәтта мәкаләләрендә һәм чыгышларында бу хакта өметле фикер дә күренми. Г. Исхакый мөстәкыйльлек идеясендә пассивлык күрсәтсә дә, Милләт Мәҗелесендә 1917 елның Февраль инкыйлабына зур өметләр баглаган, милли сәясәттә аеруча кискен адымнарга әзер булган чагыштырмача яшь буын «тупракчы»лар фракциясе Мәҗлеснең гомуми җыелышында «Идел-Урал штаты» проектының ике вариантын тәкъдим итә. Проект хакында, аның авторы Галимҗан Шәрәф дәлилле чыгыш ясый. Ул: «...XII гасырда зур фөтухаты белән *(яулап алу, басып алу)* мәшһүр Чыңгыз вә аның яланнары *(балалары)* безнең бабайларымыз булганлыгы яки хәзер дә милләтемез яши торган җирләрдә бабаларыбыз тарафыннан Болгар ханлыгын яки Казан ханлыгын тәшкил иткәнлеге өчен түгел, бәлки киләчәктә безнең дә яшәргә хакыбыз булганы өчен үзебезгә аерым дәүләт төзү фикерен алга сөрәбез. Ата-бабаларыбыздан калган тарихи әсәрләр һәм исемнәр исебезгә төшкәндә, кайсыбыз гына «кайчан без мөстәкыйль ил төзү уңышына ирешербез соң?» дип уйламый», – дип чыгыш ясый [4]. Милли бәйсезлеген югалткан татар халкы тарихында беренче тапкыр сәяси юл белән мөстәкыйль дәүләт төзү идеясе югары мөнбәрдә яңгырый. Шуңа карамастан, Г. Исхакый үзенең чыгышында проект авторларын яңа корылачак дәүләтнең төп халкы аерым күрсәтелмәгән өчен тәнкыйтьли. Милли-мәдәни мохтарият идеясенә тугры калган әдип-публицист милли мохтариятләр үзләрен яклый алсын өчен төзелә, илдә яшәүче бөтен кавемләр үзара иттифак кора, шул вакытта төп милләт без булачакбыз дигән фикерне ассызыклый. Шуңа өстәп Россиянең федератив дәүләт булачагына һәм аңа керүче дәүләтләрне төзегәндә төп рольне икътисад уйнаячагына ышануын әйтә [5]. Милләт Мәҗлесендә озак фикер алышулар, бәхәсләрдән соң Идел-Урал дәүләте түгел, ә, бәлки, федератив Россиядә шул исемдәге өлкә төзү хакында карар кабул ителә. Гомумән алганда, татар халкы мөстәкыйль Идел-Урал дәүләте төзү идеясенә әзер идеме соң? Г. Исхакый мөһаҗирлектә I Бөтенрусия мөселманнарының корылтайлары һәм Милләт Мәҗлесе оешуга егерме еллыгы уңаеннан язылган мәкаләләрендә Россиядә гомер сөрүче бер генә милләт тә, поляк һәм финнардан кала, тулы бәйсезлек фикерен күтәреп чыгуга әзер булмавын искәртә. Ул моның сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: «...яңа милләтләрнең милли хокукларын танып, яңа бер Русия мәйданга китерү вә аның идарәсен уртак көчләргә бирү өчен Учредительное собрание туплпу хәрәкәте эшләнә иде. Вә һәрбер киләчәк дәүләт корылышы эшләре шул мөәссәсәдә чыгачак дип, милләтләргнең хокуклары, вазыйфалары кануни юлга корылачак дип көтелә вә большевикларга мәүкыйт *(вакытлы)* килгән бер идарә генә итеп карала иде. Бу вакыйгаларда ләһләр *(поляклар),* финнарга башка ачыктан истикъляль *(бәйсезлек)* байрагын күтәргән әле бер милләт тә юк иде. Барысы да рус демократиясенә ышану нигезендә хәрәкәт итеп, киң мохтарият белән хәрәкәт итеп, киң мохтарият белән канәгатьләнү фикерендә иделәр» [3: 208]. Мөһаҗирлектә яшәгән Г. Исхакый шуның белән үзен аклый да. Чынлыкта, мәкаләдән алынган өзек Идел-Урал дәүләте идеясенең пыскып юкка чыгу сәбәбен төгәл аңлаткан. Әлеге юлларның авторы Г. Исхакый һәм аның көрәштәшләре инанган Идел-Урал дәүләте идеясенең тормышка ашмавына киңрәк туктала. Ул: «Чыннан да, беренче карашка, гомер бакый акыл белән аңлау кыен булган Россиядә, нинди дәүләт корылышы, нинди сәяси һәм икътисадый юлны сайлаячагы, идеологик нигезе нинди юнәлеш алачагы билгеле булмаган дәүләттә, төрек-татарлар күтәргән милли-мәдәни мохтарият һәм Идел-Урал дәүләте идеясе бер утопия генә икәненә ышанасың. Чын дөресе, әлегә бик сирәк милләтләр генә үзләренең мөстәкыйль дәүләтләрен цивилизацияле,

парламент юлы белән хәл итә алды яисә ала, чынлыкта исә күп очракларда милләтнең бәйсезлеге зур корбаннар, кан коюлар бәрабәренә яулап алына. Бу – хакыйкать. Россия гасырлар дәвамында көчләп буйсындырылган милләтләрне юк итүгә корылган дәүләт төзелеше, халыкларны ассимиляцияләү өчен көчләп чукындыру, русларны бердәм, берегеп яшәүче милләтләргә якынрак утырту һәм башка ысуллар бер генә аерым милләттә дә мөстәкыйль идарә системасы булдырырга мөмкинлек бирми иде шул. Төрек-татар зыялысы моның төп сәяси нигезләрен аңлый, төрле төркемнәрдәге фикер каршылыклары да шуңа бәйле. Шуңа күрә Г. Исхакый инанган милли-мәдәни мохтарият һәм Г. Шәрәф тәкъдим иткән Идел-Урал дәүләте идеясе Октябрь инкыйлабыннан соң башланган катлаулы сәяси вазгыятьтә пыскып сүнә», – дип яза, [6: 20–21] ул вакытта да, бүген дә төрек-татарның милли мөстәкыйльлеге өчен Россиянең имприячел сәясәте шартларында алшартлар булмаган, булмаячагын искәртә. Шул рәвешле большевик хөкүмәтенең халыкка алтын таулары вәгъдә иткән сәяси программалары да нәтиҗә биргәндер, ул Россиянең дәүләт структураларын тиз вакыт эчендә кулга төшерә, милли-мәдәни мохтарият яисә Идел-Урал дәүләте булдыруга хыялланган, шуңа зур өметләр баглаган татар халкының Милләт Мәҗлесен дә Идел-Урал мөстәкыйль дәүләте һәм төрек-татар халкының милли гаскәриләренең беренче яралгылары булган Гаскәри Шураны 1918 елның март-апрель айларында ук куып тарата һәм җитәкчелеге кулга алына. Г. Исхакый Милләт Мәҗлесенең кечкенә тарихын искә төшергәндә төрек-татар милли хәрәкәте, шул исәптән, Милләт Мәҗлесенең большевиклар басымы астында уңышсызлыкларын күрсәтү белән янәшәдә, аның фаҗигасен, милли хәрәкәтнең соңгы көннәрен җентекләп яза, аны күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә. Әдип-публицист 1919 елдан мөһаҗирлектә яшәп, егерме ел вакыт узуга кармастан, төрек-татарның бердәмлеге, аның якты киләчәге хакында яза. Г. Исхакыйның милли темаларны яктырткан һәрбер язмасы югары нотада, лозунг рәвешендә тәмамлана. Аның Милләт Мәҗлесенең егерме еллыгы уңаеннан язылган мәкаләсе моңа дәлил була ала. Ул: «Идел-Урал җөмһүрияте һәйәтенең эше йиренә большевиклар аерым Татарстан, аерым Башкортстан, аерым Чувашстан игълан итеп, безнең тупрак ил берлегебезне кырырга, ватарга тырыштылар. Ләкин большевикларның унҗиде-унсигез еллык бу шәйтани планнардан һичбер нәтиҗә чыкмаганын күзебез берлә күреп торабыз. Большевиклар никадәр бүлсәләр дә, халкыбыз бердер, бардыр, берлеген саклап киләдер. Шул берлене вөҗүдкә чыгарып, илебезне, йортыбызны үз кулына алырга форсат кына көтәдер. Мөһаҗирәтебездә милли юлыбызга садыйк калгандыр. Мөһаҗирәттәге бөтен милли оешмаларыбыз Милләт Мәҗлесенең юлыннан барадыр. Милли истикъляллен кыйбла итеп хәрәкәт итәдер», – дип яза [3: 206], туган җиреннән ихтыяри-мәҗбүри аерылган, мөһаҗирәттә яшәгән татар халкына хыялда гына булса да иленә кайтырга өмет уята, үзе дә шул өмет белән яши, шуңа ышана.

Татар халкының милли хәрәкәте, аның дәүләтчәнлек идеясе салынган Милләт Мәҗлесе тарихы татар тарихчылары тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә тикшерелсә дә, Г. Исхакыйның Милләт Мәҗлесенең тарихы, аның эш процессы, заманы өчен мөһим мәсьәләләргә үз мөнәсәбәтен белдерүе тарихи күзлектән караганда игътибарга лаек. Әдип-публицист, Милләт Мәҗлесеннең эшчәнлегендә турыдан-туры катнашкан шәхес буларак һәрбер проблеманың нигезен, ул мәсьәләгә карата туган бәхәсләргә мөмкин кадәр объектив якын киләргә тырыша. Шунысы ачык: Милләт Мәҗлесе татар иҗтимагый хәрәкәтендә тәүге тапкыр милли мөстәкыйльлек идеясенең тууы белән дә тарихи әһәмияте зур. Милләт Мәҗелесе 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң да, татар иҗтима-

гый хәрәкәтендә искелек һәм яңалык, сәяси көрәштә буыннары нык, тәҗрибәле татар зыялылары һәм европа, рус уку йортларында белем алган, радикаль фикерләргә бай яшь буын арасында мөһим сәяси вакыйгалар яисә темалар чишелешендә фикер каршылыкларының булуын, яшәячәген ачык дәлилли алган. Г. Исхакыйның мәкаләләренә күзәтү ясаганда кызыл җеп булып сызылып барган төп фикерләр шулар.

ӘДӘБИЯТ


1. Вәлиев Р. Өзелгән дога. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 270 б.

2. Дәүләт Н. 1917 Октябрь инкыйлабы вә төрк-татар Милләт Мәҗелесе (Эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗелесе. 1917–1919). Казан: Җыен; Милли китап, 2008. 384 б.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 12 том. Публицистика / [томны төз., иск. һәм аңлат. әзерл. Зөфәр Мөхәммәтшин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 471 б.

4. Милләт Мәҗелесе. 3 гыйнвар утырышы // Тормыш. 1918. 5 гыйнвар. 779 нчы сан.

5. Милләт Мәҗелесенең мөһим карарлары // Тормыш. 1918. 14 гыйнвар. 784 нче сан.

6. Мөхәммәтшин З. Гаяз Исхакый шәхес, әдип, милли рәһбәр // Гаяз Исхакый: тарихи документаль җыентык / төз.-авт.: С.Рәхимов, З. Мөхәммәтшин, А. Заһидуллин. Казан: Җыен, 2011. 964 б.

7. Тагиров И. Татарстан: тарих сәхифәләре. XX гасыр – XXI гасыр башы. Казан: Җыен, 2016. 376 б.


## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «ӨЙГӘ ТАБА» ПОВЕСТЕНДА ХРОНОТОП БИРЕЛЕШЕ


***Г.Н. Мөхәрләмова** (Казан)*



В статье рассматривается роль хронотопа дороги в пространственно-временной организации повести Г. Исхаки «Дорога домой». Хронотоп дороги, неся особую смысловую нагрузку в произведении, выполняет функцию понимания его основной идеи. Хронотоп дороги соответствует жизненному пути полковника Тимергалиева и представляет собой пересечение горизонтальной и вертикальной проекций. Вертикальная проекция понимается как путь вверх – как возвращение героя к своей сущности. Эти две проекции, входя в противоречие, приводят к трагедии – смерти героя.


**Ключевые слова:** художественное время, художественное пространство, хронотоп дороги, горизонтальная проекция, вертикальная проекция.



This article examines the role of chronotope of the road in the time-space organization of «The Way Home» novel by G. Iskhaki. Bearing a special semantic load in the work, the chronotope of the road fulfills the function of understanding its main idea. The chronotope of the road corresponds to Colonel Timergaliev`s path of life and represents the intersection of horizontal and vertical projections. Vertical projection is understood as a way up, when the hero's return to his essence. As these two projections enter into a contradiction, it leads to a tragedy – the death of the hero.


**Key words:** rtistic time, artistic space, chronotope of the road, horizontal projections, vertical projections.


Г. Исхакыйның «Өйгә таба» исемле тарихи повесте заманында төрле бәхәсләр, каршылыклы фикерләр уяткан әсәр. Билгеле булганча, ул Берлинда 1922 елда языла һәм 1938 елда шул ук Берлинда «Милли юл» нәшриятында басылып чыга. Әлеге әсәрдә язучы татар полковнигы М. Тимергалиев язмышы мисалында милли тигезсезлек проблемасын ача.

Повестьта сурәтләнгән вакыйгалар Беренче бөтендөнья сугышы белән бәйле булып, әсәрдәге әдәби урын һәм вакыт турында сүз йөрткәндә, беренче чиратта, шул фактны исәпкә алырга кирәк.

Әдәби урын һәм вакыт, ягъни хронотоп – әдәбиятта чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау; урын һәм вакыт – әдәби әсәрдә сурәтләнгән дөньяның әһәмиятле өлешләре. М.М. Бахтин хронотопны «аңланган

һәм конкрет бөтендә урын һәм вакыт билгеләренең кушылуын» барлыкка китерә торган «әдәбиятның формаль-эчтәлекле категориясе» [1: 235] буларак аңлый. «Өйгә таба» повестендагы хронотоп тарихи вакыйгалар белән бәйле, һәм аны тарихи урын һәм вакыт дип атый алабыз. Әсәрдә Г. Исхакый тарихи урынны Төркия җирләре белән чикләп ала.

Әсәрнең төп герое – Мирхәйдәр Тимергалиевның тормыш юлы, утыз ел дәвамында патша гаскәрендә хезмәт да үз эченә алып, төрле сугышларны, күп батырлыклар үз эченә алган юл. М. Бахтин фикеренчә дә, юл хронотобы кешедә шәхси язмыш юлы буларак аңлашыла.

Әдәбиятта юл хронотобының әһәмияте бик зур, чөнки бик сирәк әсәрләр генә юл мотивын кертүдән башка төзелә, күпчелеге исә юл хронотобына, аның төрле вариацияләренә нигезләнә. Бу исә юл хронотобының киң күләмле күренеш буларак, урын-вакыт берлеген төгәл һәм ачык чагылдыруын билгели. Әсәрдә Тимергалиевның реаль юлы нигезендә үзен аңлауга таба юл буларак аңлашыла. Әдәбиятчы-галим И.И. Меркулова фикере буенча, юл «тормышның мәгънәсен, язмыш сукмаклары буенча хәрәкәтен һәм аерымлануын ача торган үзаңның тотрыклы образларының берсе» [4: 98]. Г. Исхакыйның «Өйгә таба» повестенда да геройның тормыш юлы аның биографик вакытына тәңгәлләшә, вакытлар үтү белән геройның характерын да, язмышын да үзгәртә.

Әсәрдә юл герой гомеренең бер аралыгында горизонталь проекциясен билгели: Тимергалиев төрле җыелышларга, очрашуларга йөри, театрларга бара, офицерлар, генераллар белән очраша. Шул ук вакытта юлының вертикаль проекциясен аның уйлары, хис-кичерешләре хасил итә. Икенче төрле әйткәндә, Тимергалиевның гадәти, объектив хронотобы аның үсештәге субъектив хронотобына каршы куела, геройның каршылыклы уйлары, хисләре аның яңа тормыш алдында торуына ишарәли. Шул рәвешле, биредә герой атлап чыгарга тиешле тупса хронотобы билгеләнә. Автор героен мондый адым ясауга ашыктырмый: Тимергалиевның юлы алга таба бармый, ул гел бер җирдә таптанып торырга мәҗбүр, аның уйлары да бер ноктада әйләнеп торып, ябык түгәрәк хасил итә: «уй аның балалар тегермәне кебек шылтырады» [2: 22]. Эш белән шөгыльләнү дә аны тирән, борчулы уйларыннан арындыра алмый. Күңеленең тынычсызлыгын «күз алдыннан бик озакка кадәр кызының сыны, аның хатынының бер киселгән кулы берлә күккә таба карап дога кылуы» [2: 23] югалмавы билгеләп тора. Ул уйланып озак вакыт йокыга китә алмый газаплана: «ул әйләнде, әйләнде, таң алдында гына акрын гына йокыга талды» [2: 23]. Йокыга киткәч тә авыр төшләр күреп, саташа: «Менә аның күз алдына үзенең зәгыйфь кенә кызы килеп баса. Аның якында аның күптән түгел генә сугыш мәйданында каһарманча үлгән бердәнбер угылы килеп урынлаша. Алар артында күптән инде вафат иткән аның хатыны моңлы гына күзе берлә ялынган кебек, ялварган кебек кулын суза: аның бер кулы кырт итеп киселгән, манара киселгән кебек киселгән... Аның догага күтәргән ике кулы йирендә бер кул, бер җиң генә селкенә. Бер кулы юк. Нәфисәнең бер кулы киселгән!» Саташуы дәвам итә, ул хатынына дәшә: «Нәфисә син? Әйе, Нәфисә!... Шулай, Нәфисә, шулай!.. Синең шул бер кулың киселгәндер... Сугышта киселдеме?.. Кем кисте, дошманмы? Безнекеләреме? Дошман кем?» [2: 21] дип ул саташуларында да туры юлны сайлый алмый интегә. Ул сискәнеп уянып китә, шул уйларыннан арынмакчы була, ләкин «кара уй» аны ташларга уйламый да. Шул рәвешле, әсәрдәге перцептуаль хронотопгеройның эчке халәтен билгели, күңеленең тынычсызлыгын сәбәбен аңларга ярдәм итә.

Шушы уйларының авырлыгын ачык тәрәзәдән күренеп торган коточкыч манзара билгели: «Айның нурына коенган мәчетнең туп берлә тишелгән

михраб урыны сукыр кешенең күзе кебек полковникка карады. Аның яртылай өзелеп төшкән манарасы, кулы киселгән кешенең кулсыз җиңе кебек селкенә, саллана кебек, моңа йодрык күрсәтә кебек булды. Аның артындагы җимерек, ватык төрек өйләре, төрек йортлары шул җәрәхәтләрдән егылый, сыкрый кебек тоелды» [2: 20]. Шул күренешләр аңа тынычлык бирми, күңелен әрнетә. Бервдә ачык тәрәзә хронотобы тирән уйларга чумдыра һәм шул ук вакытта геройга дөньяга, вакыйгаларга күзен ачарга да ярдәм итә.

Геройны әсәр буена өен табарга ашкынуы, өен эзләвен күзәтәбез. Тимергалиевне адвокат кунакка чакыргач, үзен үз өендәге кебек итеп хис итә, шул тәэсирләрдән рәхәтлек хисе кичерә: «Аш башланды. Казан ысулында пешерелгән пилмән күптән бирле гаскәр ашына өйрәнгән полковникка үткән гомерен хәтерләтте, аның артыннан килгән пылау, аның артыннан бирелгән шурпалы Казан бәлеше аның тәмамән гаскәрлеген, полковниклыгын оныттырды. Үзенең гаилә тормышы, Оренбургта вакытта хатыны, әбисе берлә бергә торулары хәтеренә китерде» [2: 29]. Тимергалиев шул гаиләнең әгъзасы кебек хис итә башлый үзен. Ул шул гаилә пространствосына үтеп кереп, аны үзенеке итә: «Бу музыка Тимергали берлә бу гаилә арасындагы бөтен пәрдәләрне ачып, арадагы бөтен ятлыкларны бетерде» [2: 31]. Шул рәвешле, Үзеңнеке/Читнеке оппозициясе тәгаенләнә.

Әле яшәгән өе исә геройга тар булып тоела, аңа монда һава җитми, сулышы тарая. Тарлык/Киңлек, шул рәвешле оппозициясе геройның эчке, психологик халәтен билгели. Әлеге оппозиция әсәрнең берничә өлешендә урын ала. Мондый уйларның чуалуына, төпле бер фикергә килә алмавына шулай ук шәһәр пространствосы да куәт биреп тора: «Урамның һәр почмагында исерек эфисәр очрады. Урам буенча өзелмәенчә атларда, автомобильләрдә маржалар төяп кәеф-сафа чиккән эфисәр кәрваны өзелмәде... Ресторанның ачылып киткән ишегеннән тулып чыккан музыка, исерек тавышы дөньяны тутырды...» [2: 39]. Шул рәвешле, язучы шәһәр хронотобын геройның буталчык уйфикерләрен, авыр хисләрен чагылдыру өчен куллана.

Шушы ябык түгәрәк эченнән чыгып китү өчен аңа нинди дә булса бер дөрес фикер, карарга килү кирәк, ул исә шушы фикерне таба алмый азаплана: «Ләкин безнекеләр кем соң? Дошман кем соң? – дигән сөаль килеп басты. Тагы башын чуалтты. «Чын, без кем, дошман кем, мин, полковник Тимергалиев кем?!!» [2: 21]. Шул рәвешле, язучы героен алдагы юлын сайлау алдына куя: «Тимералиевтә, гүя, ике “мин” көрәшә башлый. Берсе аның – үз хезмәтен төгәл башкаручы, сугышта каһарманлыкларга әзер булган, хәрби антына тугрылыклы кырыс җитәкче. Икенчесе – бу сугышта чын дошманының кем икәнлеген ачышларга, дөрес юлны табарга омтылучы шәхес» [5: 168].

Тимергалиев үзендә бу тупсаны атлап чыгарга көч таба, нәкъ менә бу аңа дөрес карарны кабул итүдә ярдәм итә: «Җитте! Үткәннәр үтте, кичәгәннәр кичте, бүген Мирхәйдәр Тимергалиевның тормышында бер тыныш куелды, аның юлы борылды. Моңгачага кадәр барганның тәмам тискәренә борылды. Ул үзенең урынын кая икәнлеген бүген ачык белде, үзенең юлын тапты» [3: 65]. Тимергалиевның барыр юлы югарыга менү кебек аңлашыла. Горизонталь һәм вертикаль проекцияләренең каршылыгы фаҗигале конфликтка китерә. Нәтиҗәдә – геройның үлеме. Шушы юлда ул югары идеаллар өчен үзен корбан итә, батырларча һәлак була.

Шулай итеп, геройның «өйгә таба»юнәлгән юлы аның шактый еллар ялгыш юллардан йөреп, урау юллар аша үзенә, үз асылына кайту, рухи яктан үсү-үзгәрү юлы буларак аңлашыла.

ӘДӘБИЯТ

1. Бахтин М.М. Формы времени и хронотопа в романе // Вопросы литературы и эстетики. М., 1975. С. 234–235.

2. Исхакый Г. Өйгә таба // Әсәрләр: 15 томда. 5 том. Казан, 2009. 559 б.

3. Исхакый Г. Өйгә таба // Мирас. 1992. № 2. С. 45–66.

4. Меркулова И.И. Хронотоп дороги в русской прозе 1830–1840-х годов: дис. ... канд. филол. наук. Саранск, 2007. 221 с.

5. Мөхәммәтвалиева Г. Г. Исхакыйның «Өйгә таба» повесте // Казан утлары. 1999. № 8. С. 166–170.

# ЯПОНИЯДӘ ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

***Н.Ш. Насибуллина*** *(Казан)*

В статье освещаются исторические условия формирования татарской эмиграции, культурная жизнь татарских общин Японии. Исследуются вопросы развития татарской эмигрантской периодической печати, татарской литературы зарубежья, творчества и общественной деятельности Г. Исхаки как одного из ее представителей.
**Ключевые слова:** татары в эмиграции, литературное наследие татар, культурная жизнь татарских общин, эмигрантская печать, Г. Исхаки.

The article highlights the historical conditions for the formation of the Tatar emigration, the cultural life of the Tatar communities of Japan. In this article issues of the Tatar emigre periodical press development, the Tatar literature in foreign countries, creativity and social activity of G. Iskhaki as one of its representatives are studied.
**Key words:** The tatars in emigration, literary heritage of the Tatars, cultural life of the Tatar communities, emigrant press, G. Iskhaki.

XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында эмигрантлык хәрәкәтләренең колачы киңәю Беренче бөтендөнья сугышы, 1905 елгы февраль һәм 1917 елгы октябрь инкыйлаблары, гражданнар сугышы, Сталин репрессияләре белән бәйле. Бу сәбәпләр татарларны, исән калу максаты белән, үзләренең тарихи ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә алар Кытай, Япония, Корея, Австралия, Финляндия, Швеция, Германия, Польша, Румыния, АКШ, Канада, Төркиядә, Норвегия җирләрендә яшәү урыны табалар. Анда татарларның милли җәмгыяте оеша, төрле түгәрәкләр, хатын-кызлар клублары һәм татар китапханәләре эшли. Татарлар җәмгыятьләре үз милләттәшләре арасында мәгърифәтчелек эшен киң җәелдерәләр.

1934 елда Япониянең Кобэ шәһәрендә татарларның беренче корылтае оештырыла. Корылтайда татар диаспорасы мәктәпләре, вакытлы матбугат һәм китап басу эше проблемалары, чит җирләрдә яшәүче татарларның матди хәлен яхшырту юллары, милли үзаң тәрбияләү ысуллары, татарларны ассимиляцияләшүдән саклап калу чаралары хакында фикер алышалар. Шушы ук съездда типография оештыру һәм газета чыгару хакында уртак нәтиҗә ясала. Шул ук елда Япониягә татар милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Гаяз Исхакый килә. Аның татарларның мәдәни проблемаларын хәл итү максатыннан башлаган эшләре җирле хакимиятнең игътибарын җәлеп итә. Гаяз Исхакый, Япония җәмәгатьчелеген татарларның тарихи язмышы белән таныштыру өчен, япон галимнәре һәм иҗтимагый эшлеклеләре белән үзара элемтәгә керә. 1934 елның декабрендә япон телендә үзенең «Маньчжуриядә яшәүче төрек-татарларының азатлык өчен көрәше» дигән мәкаләсен һәм «Идел–Урал» монографиясен бастырып чыгара. Бу фактор Япониядәге татарларның алдагы тормышына уңай йогынты ясый.

Татар мөһаҗирләрең милли-мәдәни тормышын фәнни яссылыкта тикшереп, З. Гарипова Россиядән килгән мөселманнар саны Япониядә 1920 еллардагы 400–500 кеше булса, 1930 еллар азагына 5–6 меңгә җитә. Алар Токио, Иокогама, Осака, Киото, Кобе, Нагоя, Кавасаки шәһәрләрендә яшиләр. Бу шәһәрләрнең һәркайсында «Исламия» җәмгыятенең бүлекчәсе эшли («Исламия Токио», «Исламия Кобэ» һ.б.), – дип яза [2: 106].

«Исламия» җәмгыяте активистлары тырышлыгы белән Нагоя һәм Кобэ шәһәрләрендәге мәчетләр каршында мәдрәсәләр төзелә. Татарлар Япониядә «Япония мөселманнарының рухи идарәсе»н оештыралар. Арада иң эресе булып 1924 елда рәсми төстә оешкан «Исламия Токио» бүлекчәсе санала. Анда имамнар булып Габделхәй Корбангали (1924–1938), Ибраһим Габделрәшит кади (1938–1944), Мөхәммәтәмин Ислами (1944–1951), Шәрифулла Мифтахетдин (1951–1967), Гайнан Сафа (1967–1984) хезмәт итәләр. Мәхәлләнең юридик зат хокукына ия булуы дәүләт оешмаларына рәсми мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Токио, Кобе, Нагоя шәһәрләрендә мәчет-мәдрәсәләр төзү һәм зират өчен җир кишәрлекләре тиешле дәрәҗәдә рәсмиләштереп бирелгән. Япониянең Диния нәзарәте дә оештырыла.

Императорның белем бирү турындагы 1937 ел, 5 декабрь законы таләпләре нигезендә Токиодагы «Исламия» мәдрәсәсе Япониянең дәүләт мәктәпләре исемлегенә кертелә һәм ул дәүләт мәктәпләренә бирелгән барлык хокуклардан файдалана башлый. «Исламия» мәхәлләсе Япониянең күп кенә күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең киң яклавы астына алына [1: 76].

1938 елны ачылган Токио мәчете 48 ел буе халыкка хезмәт итә. 1985 елгы җир тетрәү вакытында мәчет диварлары ишелеп, аның хәрабәләрен 1986 елны юк итәләр. Токиода яшәүче Тәмимдар хаҗи үзенең 2000 елда язган хатында болай ди: «..1986 елның башында мәсҗид бинасын ватып яңа мәсҗид салырга карар бирелде, вә Япониядә булган мөселман пасоллары кирәкле акчаны бирергә сүз бирделәр. Мәсҗидне салу вакыты килгәндә, Ислам мәмләкәтләренең экономияләре бозылганга күрә биргән сүзләрендә тора алмадылар вә 1996 елда Төркиянең Баш Баканы Сөләйман Дәмирәл эфәнде Япониягә рәсми зияртәндә[1] җөмһүриятебезнең риҗасыны[2] кабул итте вә 1998 март аенда имарәткә[3] башланып, 2000 елның 30 июнендә ачылыш мәрәсиме эшләнде» [1: 10].

1939–1945 еллардагы сугыш һәм аның нәтиҗәләре татарларны төрле илләр буйлап тарата. Әмма бергәлекнең, кечкенә генә булса да, бер өлеше сакланып кала. Токиода татарлар һәм башкортлар Төрки ассоциациягә берләшәләр. Тәмимдар Мөхит һәм Әнвәр Апанай төрле вакытларда аның рәисе булып торалар.

Татар мөһаҗирләренең иң зур казанышы – аларның әдәби мирасы. 1920–1940 елларда Ерак Көнчыгыш регионында татар телендә «Ерак Шәрык» (Харбин, 1920–1923), «Азат шәрык» (1923), «Ялкын» (Харбин, 1923–1924), «Шәкертләр таңы» (Мукден, 1934–1935), «Игланыл хакыйкать» (Токио, 1932), «Яңа япон мөхбире» (Токио, 1931–1945) (1931–1932 елларда ул «Япон мөхбире» исеме белән чыга), «Рәсемләр мәҗмугасы» (Токио, 1937) журналлары, «Мең ел» (Харбин, 1922), «Ерак Шәрык» (Харбин, 1924–1925), «Бәйрәм нуры» (Харбин, 1934), «Чаткы» (Харбин, 1932–1933), «Тәммуз» (Харбин, 1934), «Милли байрак» (Мукден, 1934–1945), «Йолдыз» (Тянцзинь, 1928) газеталар нәшер ителә [4: 189; 3:36].

[1] Зиярәтендә – визитында.
[2] Риҗасыны – үтенечен.
[3] Имарәткә – төзелешкә.

Бу иҗтимагый-сәяси һәм фәнни әдәби басмалар мөһаҗирләр әдәби хәрәкәтләрендә зур роль уйный. Бигрәк тә 1931–1945 елларда татар телендә Япониядә айга бер чыгарылган «Яңа япон мөхбире» журналы да зур әһәмияткә ия.

Т. Насыйров мәгълүматлары буенча, 1905 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәр чит илләрдә татар телендә типографик һәм башка ысуллар белән 66 исемдә газета һәм журналлар нәшер ителгән. Аларның күбесе Германиягә туры килә. Анда 18 исемдә газета һәм журнал басылган. Кытайда – 16, Төркиядә – 14, Финляндиядә – 8, Япониядә – 5, Румыниядә – 6, Венгрия, Швеция һәм АКШта берәр исемдәге вакытлы басма дөнья күргән [5: 127].

Мөһаҗирлек матбугаты үсешендә Г. Исхакый, С. Максуди, Х. Габдүш, Р. Рәхмәти, Ф. Туктаров, Г. Салиәхмәт, Г. Корбангали, Ә. Мәңгәр, Р. Мөхәмәдиш, И. Дәүләткилде, Х. Хәмидуллин, Наилә Бинарк, Р. Мөхтәсин һ.б. актив эш җәелдерәләр.

Татар мөһаҗирләре, газета һәм журналлар чыгару белән генә чикләнмичә, әдәбият үсешенә дә зур игътибар бирәләр. Шуңа күрә газета яки журнал редакцияләрендә эшләүчеләрнең күп өлеше әдәби иҗат белән дә шөгыльләнәләр, һәм аларның әсәрләре шул ук газета-журналларда басылып чыга.

Милләттәшләребез чит илләрдә татарча китаплар да бастырып чыгаралар. Хөсәен Габдүшнең «Дүрт хикәя» се китабы Токио шәһәрендә 1931 елда нәшер ителә. Күпчелеге гарәп шрифтында басылган китаплар нигездә әдәби, фәнни, педагогик, дини, музыкаль юнәлешләрдән гыйбарәт була. Дәреслекләр, сүзлекләр, календарьлар, географик карталар, сирәк кенә булса да җырлар җыентыклары да дөнья күрә. Ерак Көнчыгышта аларның саны 40 лап исәпләнә. Алар нигездә Токиодагы «Матбагаи исламия» нәшриятында дөнья күрә. Әйтик, «Кызларга махсус милли шигырьләр» дигән китап анда 1936 елда бастырыла. Шигырьнең эчтәлегендә Аллаһны олылау, белемгә-мәгърифәткә өндәү, әти-әнине хөрмәт итәргә, үз милләтең өчен көрәшергә чакырулар яңгырый.

Эмиграциядәге язучылар иҗаты үзенә бер аерым шартларда бара. Алар үз юлларын, үз юнәлешләрен эзлиләр, туган телләрен, көнкүрештәге милли үзенчәлекләрен киләчәк буынга саклауны бурычлары итеп саныйлар. Аларның татар халкы тарихы, милләт язмышы, рухи халәтләре турындагы уйланулары, табигый ки, чәчмә әсәрләрендә, шигърияттә, публицистикада чагылыш таба.

Эмиграциядәге татарлар Муса Акъегетзадә, Гаяз Исхакый, Рәшит Рәхмәти Арат, Тамурбәк Дәүләтшин, Садри Максуди, Әхмәт Тимер, Наилә Бинарк, Ләбиб Каран, Гали Акыш, Хөсәен Габдүш, Надир Дәүләт, Мәхмүт Таһир һ.б. гомумтатар мәдәниятенең мөстәкыйль өлешен тәшкил итәләр.

Япониядә яшәүче татарларның тарихын барлау бүгенге көндә дә дәвам итә. Усманова Лариса Рафаэл кызы инглиз телендә «The Turk-Tatar Diaspora in Northeast Asia. Transformation of Consciousness: A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950s» («Төньяк-Көнчыгыш Азиядәге төрки-татар диаспорасы. 1898 һәм егерменче гасыр уртасына кадәр булган чордагы тарихи һәм иҗтимагый вәзгыяттә фикерләр сөреше буенча») исемле китабын бастырды. Япония, Корея, Маньчжуриядә яшәгән татарларга бәйле чыганаклар, документларны өйрәнеп язылган хезмәт җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителде. Фәнни эзләнү барышында Төркиядә, Америкада яшәүче татарлар да үз өлешләрен кертәләр. Аларның әти-әниләре, әби-бабалары Япониядә булган төрки мәктәпләр ачуга да сәбәпче булган. Татарлар белән бергә бу якка ислам дине дә килгән. Л. Усманова татарлар тормышын махсус өйрәнер өчен Япониядәге Симанэ төбәге университетында докторлык эшенә алына. Анда татарлар белән дус булган Хотори Сиро атлы тел галименең шактый бай архивында «Милли байрак» газетасы тупланмасы булуын ачык-

лый. Безгә мәгълүм булуынча, Америка галимәсе Айшә Рорлих тарафыннан китерелгән «Милли байрак» газетасының берничә нөсхәсе Татарстан милли китапханәсендә дә саклана.

Исламны таратучы Габдеррәшит Ибраһимов «пан-исламист» булган, СССРда мөселманнар мохтариятен кору турында хыялланган, тик совет хөкүмәтеннән качкан татарлардан зур яклау ала алмаган. Икенче лидер, урысларның ак армиясе вәкиле – Габделхәй Корбангалиев. Корбангалиев өченче юлбашчы булган, ул Япония башкаласы Токиода мәхәллә кора алган. Кадими кеше булса да, ул да татар-башкорт өчен дәүләт кору турында хыялланган. Җәдитче Гаяз Исхакый соңарак килгән. Алар өчесе дә Япониянең ислам сәясәте кысаларында дәүләт белән хезмәттәшлек иткәннәр.

Исхакый фикерләренә таянып утызынчы елларда оешкан «Мәркәз» оешмасына 27 мәхәллә керә. Аларда яшьләр яки хатын-кызлар комиссияләре дә эшли, мәктәпләре дә була. Гомумән Коба, Нагоя, Харбин, Сеул, Токио кебек шәһәрләрдә асылы «пенза»лы булган милләттәшләр мәчетләр корып та тарихка кергән. Аннары аларның күпчелеге Төркиягә күченгән. Алар үзләрен «төркитатар» дип атаган.

Татар мөһаҗирләре иҗтимагый тормышында зур урын биләгән Гаяз Исхакый да гомеренең соңгы елларын Төркиядә уздыра. Кайсы илдә яшәвенә карамастан, ул илдәге сәяси, әдәби-мәдәни процессларга зур йогынты ясый, татарларның рухи һәм социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, милли җәмәгать оешмалары төзеп, милләттәшләребезне берләштерүче, туплаучы көч буларак чыгыш ясый. Токиога, Кобэ, Харбин, Хайлар, Мукденга, Мисырга, Сүриягә, Фәләстыйнга һәм башка юнәлешләргә юл тотканда, Гаяз Исхакый, урыннардагы җәмәгатьчелек белән очрашып, алар алдында Россиядәге татарларның тарихына, әдәбиятына туктала, аларның үзбилгеләнү хокукына хакы барлыгын аңлата. Гаяз Исхакый мөһаҗирлектә татар милли-азатлык хәрәкәтенең танылган әйдәүчесе һәм идеологы булып таныла.

ӘДӘБИЯТ


1. Адутов Р. Япониядәге кардәшләребез // Татаро-башкирская эмиграция в Японии. Яр Чаллы, 2001.

2. Гарипова З. Татарларның милли-мәдәни тормышы // Фәнни Татарстан. 2015. № 2. Б. 106.

3. Мансуров И.С. Татарская литература зарубежья и творчество Гаяза Исхаки периода эмиграции: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005.

4. Миңнегулов Т. Чит илләрдә татар вакытлы матбугаты // Казан утлары. 1990. № 10.

5. Насыров Т. Татарская эмигрантская пресса // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2004. № 2.

6. Усманова Л.Р. О тюрко-татарах в Маньчжурии и Японии. Интервью Бим-радио. Режим доступа http://www.bimru.ru/article/1084/14/свободный.

7. Usmanova Larisa. The Turk-Tatar Diaspora in Northeast Asia. Transformation of Consciousness: Historical and Sociological Account between 1898 and the 1950s. Tokyo: Rakudasha, 2007.


## Г. ИСХАКЫЙ ҺӘМ РИФӘ РАХМАН ӘСӘРЛӘРЕ АРАСЫНДА ИНТЕРТЕКСТУАЛЬ ДИАЛОГ


***Г.Р. Насибуллова*** *(Казан)*



В статье изучается интертекстуальная связь между произведениями Г. Исхаки и Р. Рахман. На примере произведений этих двух авторов доказывается, что интертекстуальность как художественный прием обогащает, расширяет и углубляет идейно-тематические, смысловые границы литературного произведения.



**Ключевые слова:** рассказ, идея, герой, интертекстуалность, диалог, связь



The article considers the intertextual connection between the works of G. Ishaki and R. Rahman. On the example of these two works, the author proves that intertextuality as an

artistic expedient enriches, expands and deepens the ideological-thematic, semantic boundaries of a literary work.
**Key words:** story, concept, character, intertextual connection, dialogue

Һәр халыкның әдәбияты үзеннән алда килгән әдәбият белән бәйләнештә үсә. Яңа әдәби әсәр, әдәби эволюция процессына кушылып, аны баета, тулыландыра. Һәр язучы әдәбият тарихына мөрәҗәгать итә, остазларының тәҗрибәсенә таяна. Бу бәйләнешнең бик үзенчәлекле төре интертекстуальлек дип атала. Интертекстуальлек – ул теге яки бу әсәр поэтикасын башка әсәр структурасында куллану. Ул ачыктан-ачык яки яшертен булырга мөмкин. Язучы, үзенең шәхси әдәби максатларыннан чыгып, башка әсәр поэтикасына мөрәҗәгать итә. Интертекстуальлек чаралары булып төрле цитаталар куллану, реминисценция, аллюзия, центоннар тора. Әлеге терминны француз филологы һәм постструктуралистик юнәлеш теоретигы Ю. Кристева әйләнешкә кертә. Ул М. Бахтинның карашларына, аерым алганда, аның «Эчтәлек, материал һәм форма проблемасы» хезмәтендә чагылыш тапкан, әдипнең, чынбарлыктан тыш, үзенә кадәр язылган һәм заман әдәбияты белән бәйләнештә булуы, автор тарафыннан яшәп килүче әдәби формалар белән көрәшү кебек аңланылучы «әңгәмә» коруы хакындагы фикеренә таяна.

Интертекстуальлек һәм интертекст төшенчәләренә кануный билгеләмәне Р. Барт бирә: «Һәр текст бер үк вакытта интертекст булып тора; башка текстлар анда төрле дәрәҗәләрдә һәм күпмедер танылa торган формада катнаша: узган мәдәниятләр текстлары һәм әйләндереп алган мәдәният текстлары. Һәр текст иске цитаталардан тукылган тукыма хасил итә. Мәдәни кодлар, формулалар, ритмик структуралар, иҗтимагый идиомалар һәм башкалардан өземтәләр – барысы да текст тарафыннан йотыла һәм анда үзара уралышып бетә, чөнки текст тирәсендә сөйләм бар. Теләсә нинди текст өчен мәҗбүри шарт булган интертекстуальлек чыганаклар һәм йогынтылар проблемасына гына барып тоташмый; ул килеп чыгышын ачыклау мөмкин булмаган, аңнан тыш яки автоматик цитаталар рәвешендәге аноним формулаларның гомуми кырын хасил итә» [1: 47]. Р. Барт фикеренчә, «яңа текст бары тик текстара мөнәсәбәтләр, интертекстуальлек аркасында гына яши» [1: 48].

Башка текстларны яки аларның элементларын кушу интертекстуальлек категориясе чагылышының төп ысулы булып тора. Интертекстуальлек призмасы аша дөнья моңа кадәр барысы да әйтелгән зур бер текст буларак күзаллана, ә яңасы билгеле элементларны бутау (смешение) нәтиҗәсендә генә туарга мөмкин. «Һәрбер текст интертекст булып килә, аңа кадәр булган мәдәният текстлары яки аны әйләндереп алган мәдәният текстлары (тексты окружающей культуры). анда төрле дәрәҗәдә очрый. Һәрбер текст иске цитаталардан тукылган тукыманы хәтерләтә» [3: 218].

Болардан чыгып, теләсә нинди текстта башка тексттан цитаталар кулланылырга, ягъни интертекстуальлек мөмкин. Әмма ул төрле жанрларда төрлечә кулланыла. Бөтен кешелек мәдәнияты бердәм текст буларак карала. Бу очракта барлык яңа текстлар бер яктан бердәм үзләреннән алда килгән текстка (предтекст), мәдәни контекстка, әдәби традициягә нигезләнә, ә икенче яктан үз чиратларында мәдәният күренешенә әйләнгәнгә күрә интертекст булып торалар. В. Топоров фикеренчә, «бөек текст» – «урын һәм вакыт чикләрен үтүче, ирекнең иң югары ноктасын яулаучы буларак бөтен җирдә һәм мәңге яши» [4: 284].

Интертекстуальлек татар әдәбияты өчен ят күренеш түгел. XX гасыр башында Г. Рәхим, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан әлеге ысулга мөрәҗәгать итә. Язучылар халык авыз иҗаты әсәрләре нигезендә яңа риваять-легендалар тудыра-

лар, әсәрләрендә моңа кадәр таныш булган образ, вакыйгаларны кулланалар. Хәзерге язучылар да әлеге ысулга еш мөрәҗәгать итәләр.

Рифә Рахманның «Сөннәтче әби» – бүгенге әдәбиятта интертекстуальлек чагылышының ачык мисалы. Р. Рахман «Сөннәтче әби» хикәясен әсәр ахырында үзе үк Г. Исхакый белән интертекстуаль диалог дип атый. Ике әсәр арасында бәйләнеш берничә яссылыкта бар. Иң беренче чиратта ул исемдә чагылыш таба. Ике әсәрнең дә исеме һәм төп герое бер-берсенә бик якын. Ике әсәр арасында сюжет-композицион параллельләр дә бар. Әсәрләрдә милли гореф-гадәтләрне саклаучы кешеләрнең тормышы һәм аларның үлеме сурәтләнә.

Р. Рахманның «Сөннәтче әби» хикәясе Г. Исхакый әсәре белән идея-тематик яссылыкта да «әңгәмә алып бара». Язучы әлеге хикәядә Г. Исхакый тарафыннан билгеләнгән кыйммәтләрнең югалмавын, ә дәвам итүен күрсәтә. Әсәрнең үзендә турыдан-туры «Сөннәтче бабай» повестен телгә алу юк. Р. Рахман гасыр башында язылган әсәргә мөрәҗәгать итеп, аның идея-тематикасын дәвам иттерә. Билгеле булганча, Г. Исхакый повестенда сөннәтчелек кебек изге эшне ир-ат башкара. Р. Рахманда исә әлеге вазифа Мәфрузага йөкләнгән. Автор вакыйгалар агымы аша хатынның бу эшкә алыну тарихын сөйли. Сөннәтче картка исә бу эш нәселдән күчкән.

Г. Исхакый «Сөннәтче бабай» әсәре нигезендә милләтнең киләчәге өчен борчылу ята. Язучы бик матур тасвирламалар аша халкыбызның яшәешен, гореф-гадәтләрен тасвирлый. Р. Рахман образлар системасы, символлар аша Г. Исхакый әсәре белән «әңгәмә алып бара». Г. Исхакыйның төп герое Сөннәтче бабай – үзе үк символик образ. Аның исемен дә, яшен дә берәү дә белми, барысы да Сөннәтче бабай дип атап йөртә. Ул бераз бөкрерәк, өстендә тузган казаки. Казаки – хезмәт итү билгесе, бабай гомере буе сөннәт йоласына хезмәт итә, шуңа күрә киеменең алды тузган.

Р. Рахманның Сөннәтче әбисе Мәфруза исемле, аңа туксан яшь. Бу һөнәр Мәфруза карчыкка нәселдән килмәгән, ул бу эшкә йоланы үтәүче булмаганга керешә. Язучы Сөннәтче әбинең авылда ихтирамга лаек кеше булуын күрсәтә: «ул урамнан үткәндә, сугышып яткан балалар да шып кала, тәмәке тартканы тәмәкесен чалбар кесәсенә яшерә, бер-бер сәрхушы тизрәк кайда да булса шылу ягын карый» [5: 19].

Г. Исхакый повестендә Сөннәтче бабайның карчыгы Гөлйөзем әби дә татар халкының традицияләрен саклаучы, ирен хөрмәт итүче, татар хатын-кызының үрнәге буларак тасвирлана. Бу яктан Р. Рахман герое Мәфруза да аңа аваздаш. Ике әсәрдә дә уртак күренеш – хатыннарның ирләренә юынырга ярдәм итүе, су салып торуы аларның чиксез хөрмәтен, гаиләдә ир белән хатын мөнәсәбәтләренең идиллиясен күрсәтә.

Г. Исхакый төрле символик образлар аша милләтнең яшәешен тасвирлый. Сөннәтче бабайның өй алдында миләш агачы үсә. Татар халкы каралты-курасы янына һәрвакыт шундый җимешле куаклар утырткан. Бу үзенә күрә традиция. Повестьтә бабай агачны бик кадерләп карый, аның белән сөйләшә. Миләш агачы милләт язмышы буларак гәүдәләндерелә. Р. Рахман хикәясендә әлеге рольне нарат башкара. Өйләнгәч, Галләм, барлык авыл халкын шаккатырып, йорт каршыларына пар нарат утырта. Татар халкы өчен йорт янына ылыслы агач утырту табигый түгел. Әсәрдә сурәтләнгән ирләр башкара торган сөннәт эшенә хатын-кызның да алынуы хас түгел. Әлеге күренешне милләтне сакларлык, аның йолаларын, гореф-гадәтләрен киләчәк буынга тапшырырлык ирләр калмавына ишарә буларак кабул итәргә мөмкин. Хикәядә Мәфрузаның нарат күркә утында кайнаган чәй эчүен Р. Рахман йола дәрәҗәсенә күтәрә. Авылда бары тик Мәфрузаның гына самавырын нарат күркәсе утында кайнатуы йолаларның онытылуы, юкка

чыга баруын раслый. Р. Рахманның «Сөннәтче әби» хикәясендә дә нарат агачы символик мәгънәгә ия. Ул халыкның хәтерен гәүдәләндерә. Сөннәтче әби үлгәч, кодагые Хариса нарат кәүсәсенә килеп бәрелә һәм тирә-юньдәге күркәләрне җыярга була, сөннәт пәкесенең үзләрендә бүрәнә ярыгына кыстырылып торуын исенә төшерә, сөннәт эшенә өйрәнергә, аны дәвам итәргә карар кыла.

Г. Исхакый милләтнең киләчәге укымышлы кешеләр кулында булуын күрсәтергә тели. Шуңа күрә бабай пәкесен мәхдүмгә тапшырып калдыра. Р. Рахман хикәясендә Мәфруза карчык төрле ырымнарга да ышана. Бабасыннан ишеткән туксан тугыз баладан артык сөннәткә утыртырга ярамый, йөзенче бала үлә икән дигән сүздән соң ул йоланы башкарудан туктый. Биредә дә пәке Г. Исхакый әсәрендә кебек изге әйбер санала. Аны әйбәтләп төреп сандык төбендә саклыйлар. Авылда туган йөзенче баланың хорафатлардан көлә торган, сөннәт белән шөгыльләнүе өчен Мәфруза карчыкны күп рәнҗеткән күмхуҗ рәисе Мотыйк малае булуы да символик мәгънәгә ия. Бу йөзенче малайның Байрак исемле, киләчәктә аның авылда мулла булуы да символик мәгънәгә ия. Күпме генә ярдәм итәргә теләсә дә, Мәфруза ярамый дигән ышануын җиңә алмый. Язучы милләтеннән, аның тарихыннан, гореф-гадәтләреннән ваз кичкән кешеләр дә алардан башка яши алмавын күрсәтә. Совет рухында тормыш алып баручы Мотыйкның да улын сөннәт кенә коткарып кала ала. Мәфруза пәкесен Мотыйкның үзенә тоттыра. Ләкин Мотыйк мондый җаваплы эшкә әзер түгел.

Шул рәвешле Р. Рахман Г. Исхакый әсәре белән эчке диалог аша милләтнең киләчәге өчен борчылуын, гореф-гадәтләрнең, традицияләрнең әһәмиятлеген күрсәтә. Хикәядә кулланылган интертекстуаль чаралар автор тарафыннан билгеләнгән идея-сәнгати бурычларга ирешүгә хезмәт итеп кенә калмый, алар хикәянең мәгънә чикләрен киңәйтәләр, кыска әсәр мәйданында әйтеп, тасвирлап бетерә алмаганны укучыга җиткерүдә ярдәм итәләр.

ӘДӘБИЯТ


1. Барт Р. Избранные работы. Семиотика. Поэтика. М.: Прогресс, 1994. 616 с.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 том: Повестьлар һәм хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр. 1999. 248 б.
3. Современная русская литература (1990-е гг. – начало XXI в.): учебное пособие для студентов филологического факультета высших учебных заведений / С.И. Тимина, В.Е. Васильев, О.Ю. Воронина и др. М.: Академия, 2005. 348 с.
4. Топоров В. Пространство и текст // Текст: семантика и структура. М.: Наука, 1983. С. 227–284.
5. Харрасова Р.Ф. Онытырмын димә... Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 239 б.


## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ГЕНДЕР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН ЧАГЫЛДЫРГАН СТЕРЕОТИПЛАР


***Г.Ә. Нәбиуллина, Ә.Ш. Юсупова, Г.Н. Галимова*** *(Казан)*



В статье рассматриваются гендерные стереотипы в произведениях татарского писателя Гаяза Исхаки. На конкретном материале определяются их функции в тексте и роль в описании характеров главных героев.



**Ключевые слова:** гендерный стереотип, татарский язык, литература, Гаяз Исхаки, произведения.



The author of the article discusses gender stereotypes of the works Tatar writer Ayaz Ishaki and determines theirfunctions in the text as well as their role in characterising the main heroes.



**Key words:** Gender stereotype, tatar language, literature, Ayaz Ishaki, works of Ayaz Ishaki.

Дөнья күләмендә танылган язучы Г. Исхакый иҗаты татар әдәбияты тарихының зур бер өлешен тәшкил итә. Иҗатының байлыгы, күтәргән проблемаларының киңлеге, гәүдәләндергән геройларының төрлелеге белән Г. Исхакый – киң колачлы язучы. Ул үзенең роман һәм повестьларенда, хикәя һәм сәхнә әсәрләрендә татар тормышын, аның яшәешен, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, тормышның матур һәм караңгы якларын оста итеп сурәтли. Шушы сурәтләүләр аша Г. Исхакый – иҗатының башлангыч чорыннан ук хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен үзәккә куеп яктыртып килгән язучы. Ул – үз әсәрләрендә хатын-кызны яклаучы, аңа теләктәшлек итүче, аның хәлен җиңеләйтергә тырышучы. Бер очракта ул аларны яшәү шартларына бәйле рәвештә бик түбән төшереп калдырып («Кәләпүшче кыз»), икенче очракта шул түбәнлекләрдән чыгу юлларын табып тасвирлый («Теләнче кызы»). Күпчелек очракта ул хатын-кызны алдынгы фикерле, булдыклы, кыю, ирләргә яки егетләргә караганда да активрак фигура итеп сурәтли («Ике гашыйк», «Мөгаллимә», «Көз») [3: 659].

Г. Исхакыйның күп кенә әсәрләрендә шәкерт һәм хәлфәләр, мулла һәм хәзрәтләр, ханым-туташлар һәм абыстайлар тормышы үзәккә куела, шушы образлар аша ир-ат һәм хатын-кызга хас гендерлык үзенчәлекләре яктыртыла. Бу җәһәттән язучының хатын-кыз һәм ир-ат геройларның тормышын, җәмгыятьтә тоткан урыннарын, характерлы сыйфатларын, эш-гамәлләрен, уй-фикерләрен, аларның үз-үзләрен тотышларын сурәтләүгә корылган гендерлык стереотиплары игътибарга лаек. Шуны истә тотып, әлеге фәнни мәкаләдә Г. Исхакыйның проза әсәрләрендә, аерым алганда, «Сөннәтче бабай» һәм «Остазбикә» повестьларында урын алган гендерлык стереотипларын тикшерү үзәккә куелды.

Тикшерү объекты итеп алынган «Сөннәтче бабай» һәм «Остазбикә» әсәрләре татар әдәбиятының бер казанышын тәшкил итәләр. Бу ике әсәр дә – нечкә психологик тасвирлауларга бай һәм әхлакый, тәрбияви яктан да көчле әсәрләр. «Остазбикә» повестенда унике ел бергә гомер кичергән Вахид хәзрәт белән остазбикә Сәгыйдә тормышы тасвирлана. Биредә без төп герой Сәгыйдә образы аша хатын-кызны килен, ир хатыны, ана, шәхес буларак ачкан гендер стереотипларын билгели алабыз. Иң беренче чиратта, Сәгыйдә *«остазбикәдә бер дә артыклык-кимлек юк иде. Ул гади генә авыл остазбикәсе иде»* [3: 273]; *«бер карт мулланың кадерле кызы», «бер яшь мулланың сөйгән остазбикә хатыны»* [3: 281] буларак характерлана. Күренгәнчә, татар хатын-кызы кадер-хөрмәттә һәм һәрвакыт ир-ат кайгыртуында яши. Гомумән, исламда хатын-кыз һәрвакыт кемнең дә булса канаты астында яши. Яшь чагында аны әти-әнисе тәрбияләп үстерә, кияүдә чагында аны ире саклый, картайган көнендә хатын-кызны балалары тәрбияли.

Сәгыйдәне килен буларак характерлаучы стеротипларны үз эченә алган өзекләр китерик: *«Бәлки шулай итеп, Сәгыйдә гомергә килен булып калыр иде, бәлки гомергә дә ул шул хезмәтчеләр ашата торган, сыеклар карый торган, сыерлар сава торган, карт белән карчыкның комганнарыныннна җылы суны бушатмый торган асрау булып калыр иде»* [3: 281]; *«Карт хәзрәт кызын, үзенең сөекле кызын, өстендә дублы мужик туны, кулында ярты аршинлы баригалы, башында ирләрдән калган мескен бүрекле, аягында тула оек өстенә юкәдән үреп ясаган башмаклы иттереп күрү хәйран калдырды»* [3: 282]. Әлеге өзекләрдән күренгәнчә, Сәгыйдә кайнана-кайната йортында эшчән, тырыш, мескен кыяфәтле, баш иеп хезмәт итүче, күндәм холыклы килен буларак күз алдына килеп баса.

Хатын-кызның гаиләдә үз-үзен тотышы, иргә булган мөнәсәбәте, хатын, ана буларак характерлы сыйфатларын тасвирлаган стереотиплар әсәрдә башыннан ахырына кадәр кулланыла. Сәгыйдәнең иренә булган мөнәсәбәтен түбәндәге

юлларда ачык чагылдырылган: *«Бәлки аның иренә мәхәббәте, шундагы бөтен авырлыклар, бөтен хурлыкларны онытып, аңарга тормышның бөтен әчесен төче иттереп күрсәтер иде»* [3: 281]; *«Өйдә аны һәр көнне бертөсле ачык, һәр көнне бертөсле көтеп, Сәгыйдә каршы ала. ...аны Вахид һәрвакыт кайнаган самовар янында көтә торган, яна торган мич алдында табасын кыздыра торган итеп таба»* [3: 285]. Бу юллар Сәгыйдә образы аша хатын-кызның гаиләдәге урының, ана, ир хатыны буларак ролен, вазифасын аңларга ярдәм итә. Сәгыйдәнең иренә булган мөнәсәбәте, ихтирамы аша татар хатыны ирен хөрмәт итүче, яратучы, гаилә җылысын, гаилә учагын саклаучы буларак күзаллана.

Г. Исхакый тасвирлавында хатын-кыз күндәм, иренә буйсынучан, йомшак холыклы, нечкә күңелле, тыйнак, күркәм холыклы зат буларак күз алдына килеп баса. Шул ук вакытта хатын-кызның берникадәр кырыс, таләпчән булуы билгеләнә: *«Аның табигате йомшарды, изрәде. Ул сабак белмәгән кызларны чаж-чаж чыбык белән пешерә торган абыстай, бөтен кызларга "Ай, гакыллым, кызым" дип эндәшә торган булды...»* [3: 291].

Хатын кыз гаилә өчен генә яратылмаган, аның җәмгыятьтә үз урыны, җәмәгатьчелек арасында абруе, дәрәҗәсе дә бар. Әсәрдән өзек китерик: *«Сәгыйдә остазбикә атаклы остазбикә булып, бөтен авыл хатынының киңәшчесе, мәслихәтчесе, гакыл бирүчесе, дин-диянәт өйрәтүчесе була»* [3: 287].

Повестьта Остазбикәнең бала булмаудан өзгәләнүләре, башка хатыннан туачак балаларны тәрбияләргә әзер булуы, яратып, хөрмәт итеп яшәгән ирен үзе өйләндерергә карар кылуы каршылыклы кичерешләр аша сурәтләнә: *«хәзрәт, аның хәзрәте, менә шул матур минутларны, матур сүзләрне, йомшак сөюләрне Галимәгә багышлармы?..»* [3: 306]; *«Хәзрәт минеке, хәзрәт минеке. Бирмим. Бирмим...»* [3: 307]; *«Сәгыйдә кара сыманрак күлмәк киеп, кара өстендә ак бизәкле яулык бәйләгән. Йөзе балавыздан ясаган кебек ап-ак. .. Балкышы – падишаһлар балкышы. Йөреше – баһадирлар йөреше...»* [3: 318]; *«Шул көндәшкә каршы, падишаһ кебек олугъ, фәрештә кебек шәфкатьле көндәшкә каршы Галимә дә дошманлык, көндәшлек хисе били алмады. Аның дошманлыгы Сәгыйдәнең йомшаклыгына, аның балага йомшаклыгы кебек шәфкатенә бәрелеп, эреп киткән кебек булды. Аның көндәшлеге Сәгыйдәнең олугълыгына, биеклегенә, падишаһ кебек биеклегенә бәрелеп югалып киткән кебек булды»* [3: 319]. Мисаллардан күренгәнчә, Сәгыйдә образында хатын-кыз өчен гаиләнең әһәмияте, хатын-кызның ана булу, ирен ата буларак күрергә теләү, нәсел дәвамчысы калдыру теләге ачык чагыла. Биредә без хатын-кызның төп вазифасы нәкъ менә ана булу стереотибын күрәбез. Төп геройның үз балалары булмаса да, ул – көндәше һәм газиз иреннән туган балаларына чын ана. Тапкан ана түгел, баккан ана дигән халык мәкале нәкъ менә Сәгыйдә остазбикәгә туры килә: *«Галимә аналыкка чыгып бала тудыргач та, хәзрәткә дә, Галимәгә дә чын ана Сәгыйдә булып урынлашты. Ул гына да түгел, балалар үсә башлап, беренче сүзне әйткәндә дә, иң беренче "әннә, әннә" дигәнне Сәгыйдәгә эндәште»* [3: 319].

Әсәрдә Вахид мулла образы аша ир-ат, аның характерлы үзенчәлекләре, үз-үзен тотышы, җәмгыятьтә тоткан урынын, гаиләдә ир, ата буларак вазыйфаларын билгеләүче стереотиплар күп кулланыла. Иң беренче чиратта, төп герой Вахид мулла – гыйлемле, тирә-якта абруйлы, укымышлы, ислам кануннары буенча яшәгән, белем, мәгърифәт таратучы хәзрәт: *«Гыйлеме бар. Ир вазифасын белә»* [3: 283]; *«Өч-дүрт ел эчендә Вахид мулла тирә-юньдә игътибарлы муллга әверелә»* [3: 287]; *«Хәзрәт! Авылымызны яктырткан идең, мәчетемез, мәдрәсәмезгә нур керткән идең...»* [3: 313].

Вахид образында ир-ат гаиләсен саклаучы, аны кайгыртучы, аягында нык басып торган ир буларак күрсәтелә: *«хәзрәт бик яхшы, дәүләтемез*

*бар...»* [3: 306]. Ир һәм хатын мөнәсәбәтен чагылдырган стеоретиплар әсәрдә зур урын ала: *«Хәзрәт абыстайдан башка ашый-эчә алса да, өйрәнмәгәнгәме, тәме булмагангамы, ансыз ашка утырмый»* [3: 286]; *«Вахид хәзрәт чәйне ясагач та, Сәгыйдә остазбикә йә пәрәмәч, йә коймак, йә сумса күтәреп килеп утыра һәм дә һәрвакыт: "Җә, хәзрәт! Исәнме?" – дип тагы бер дәшә. Икесе дә бер-берсенә карашалар да исәнлекне, түгеллекне аңлашалар»* [3: 286]; *«Абыстай, хәзрәттән башка бер эш эшләми, берни капмый»* [3: 286]. Икенче хатынга өйләнсә дә, беренче мәхәббәтенә тугры калган изге җан да ул Вахид мулла: *«...Хәзрәт үз кулы белән метрикә дәфтәренә исемен "атасы Вахид, анасы Галимә" дип язып торса да, ул үзен-үзе һаман бер хатынлы иттереп хис итте, бер хатынлы иттереп уйлады, бер хатынлы иттереп торды»* [3: 319].

Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» повесте да кеше характерын тирән һәм нечкә психологик сурәтләү осталыгы ягыннан игътибарга лаек әсәр. Биредә сөннәткә утырту кебек йола аша авылның, халыкның тарихын, гореф-гадәтләре тасвирлана. Исеме дә күптән онытылган Сөннәтче бабайның кичерешләре, уй-гамәлләре, аның холкына җайлашкан, аны хөрмәт итеп яшәгән карчыгы Гөлйөзем әби язучы тарафыннан аерым бер җылылык белән сурәтләнә. Гомумән, Г. Исхакый «вакыйгаларны тәфсилләп, нечкәләп, әллә нинди һич өзелмичә тезелеп торган сүзләр табып, халыкта кулланыла торган төшенчәләр, әйләнмәләр кертеп, төбенә төшеп сурәтли» [3: 659].

Сөннәтче бабай образы аша шулай ук ир-атның җәмгыятьтә тоткан урыны, вазифалары, гаиләдәге урынын билгеләүче стереотипларны күзалларга мөмкин. Иң беренче чиратта, аның турыда *«Сөннәтче бабай – сөннәтче бабай иде»* [3: 198] дип бирелә. Авыл халкы арасында сөннәтче картның *«яше югалган кеби, исеме дә югалган иде»* [3: 199] булса да, ул билгеле нәселдән, дәрәҗәсе, абруе зур, тирә-юньдә хөрмәт казанып яши: *«Аның исеме бар иде. Исеме генә түгел, аның бөтен нәселене язган аның бабаларыны, бабаларының бабаларыны язган "Сөннәтче шәҗәрәсе" бар иде. Ул шул шәҗәрәсе берлән, үзенең сөннәт кисәргә мирас тарикы берлән хакы барлыгыны читтә килгән һәрбер шарлатан алдында исбат итә алырлык булса да, авыл халкы аның үткен чалгы пәкесе берлән сап-сары агач черегенә шәҗәрәсеннән дә нык ышанганга, шәҗәрәнең кирәге дә юк иде»* [3: 199].

Сөннәтче бабай образында хуҗалыклы, эшчән, тырыш, йорт җанлы, хезмәт яратучы, ир-ат стереотиплары гәүдәләнә. Ул, иң беренче чиратта – гаилә башлыгы. Сөннәтче бабайның йорттагы вазыйфалары *«миләшкә су сибү, йортны себерү», канауларны төзәтү»* [3: 203] белән генә чикләнми: *«Читтән караганда никадәр кечкенә генә күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлык кыры, суга якын җире печәнлеккә бүленгәнгә, башка урта җире шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрене дә үз эченә ала иде»* [3: 202]; *«Җәйнең һәр вакытында аның шул бакчасы ямьяшел тора, илдәге корылык аның арышыны саргайтмый, җәйге эсселек аның кара бодаены көйдерми иде»* [3: 202].

Сөннәтче бабай карчыгы Гөлйөзем әби белән «*илле, алтмыш, җитмеш ел*» [3: 217] тигез картлыкта көн күреп, бер-берсен ярты сүздән, бер караштан аңлап, бәхетле гомер итәләр: *«Бонларның төсләрендә, йөзләрендә, кылынышларында, табигатьләрендә дә һичбер аерма юк иде. Дөресте генә, бонлар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде»* [3: 202]. Бер җан, бер тән булып яшәгән кадерле карчыгын югалткач, Сөннәтче бабай ятим кала. Гөлйөзем әби үлгәч, *«түшәк, ястык аңар ят күренде, ул урын каты тоелды. Өе, шул Сөннәтче бабай өйләнгәннән бирле торган өе, үзенеке түгел, кешенеке*

*кебек тоелды»* [3: 218]. Шул рәвешле ир-ат, нинди генә көчле зат булса да, хатын-кыз тәрбиясеннән, мәхәбәтеннән башка яши алмый дигән нәтиҗә ясала.

Сөннәтче бабай образында ир-ат хатынын хөрмәтләүче, гаиләнең матди ягын кайгыртучан, алдан хәстәрле, ышанычлы терәк итеп күрсәтелә: «*Иң актык сөннәт беткәч, Сөннәтче бабай зиярәт өстенә барып, Коръән укый, хәзрәткә кереп сәдакә бирә, остазбикәгә дип җимеш илтә иде. Шуннан соң, күршедән ат алып, сөннәт булган йортлардан сөннәт ашлыгы җыеп йөри, капчык-капчык карабодай, борай, арыш, солы төяп өйгә кайта, өй алдының бөтен өсәкләрене ашлык, он берлән тутыра иде. Җыелган икмәкне сатып, карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк ыштан, рамазан никадәр ерак булса да, "санауды көн үтәр" дип, мәсҗедтә авыз ачтырырга дип, ике кадак хөрмә алып, мөэзингә бирә иде»* [3: 211].

Сөннәтче бабайның карчыгы Гөлйөзем әбине, ислам шәригате буенча яшәгән хатын кыз буларак, ирен тәрбияләп торучы, аны һәрвакыт *«кайнаган самовар, яккан мич берлән көтә торган»* [3: 207], кайгыртучан хатын-кыз итеп күзаллыйбыз. Шул ук вакытта ире ышыгында, ире канаты астында, гаилә җылысын саклап, шул ук вакытта җәмгыятьтә иренең дәрәҗәсен булдырып яши ул. Гөлйөзем әби үрнәгендә, кияүдәге хатын-кыз беренче чиратта үзен иргә багышлаучы, ирен тәрбия кылучы, гаилә җылысын саклаучы зат буларак аңлашыла. Бу стереотип Гөлйөзем әби вафатыннан соң үзенә яучылыкка килгән Миңлесафа сүзләрендә дә ачык чагыла: *«Угылым, кызым җиткән; ир тәрбия кылырлык хәлем юк, – диде»* [3: 221].

Гомумән, Г. Исхакый тасвирлавында Гөлйөзем әби образы аша тыйнак, нәфис зат, саф, күркәм холыклы, уңган, чиста-пөхтә, тырыш һ.б. шундый күркәм сыйфатларга ия хатын-кыз күз алдына килеп баса: *«Гөлйөзем әби көне буе эштән бушамый иде. Ул кай вакытлар мич ягып, күмәч сала, кыстыбый пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде»* [3: 203]; *«Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрен юа, самоварны тагы көзге кеби иттереп ачып куя»* [3: 206]; *«...кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самовар кую – Гөлйөзем әбинең эше»* [3: 203]; *«өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде»* [3: 203]; *«аның бүрекле тавыгы, кызыл әтәче – "Гөлйөзем әби тавыгы", "Гөлйөзем әбинең әтәче" дип йөртелә, аның зур җилемле, һавалы мөгезле, көтүнең артыннан килә торган кәҗәсе дә "Гөлйөзем әби кәҗәсе" дип йөртелә иде»* [3: 202].

Бер яктан, без карап киткән стереотиплар субъектив. Икенче яктан караганда, Вахид мулла, Сөннәтче бабай, Сәгыйдә остазбикә, Гөлйөзем әби, образлары шул чор өчен хатын-кыз һәм ир-атның гаиләдә, җәмгыятьтә тоткан урыннарын күзалларга ярдәм итәләр. Г. Исхакый әсәрләрендә, гомумән, хатын-кызлар бик хөрмәтләнә, югары урында тора. Язучы сурәтләвендә хатын-кыз илаһи образ итеп бирелә, үзенчәлекле чагыштырулар, эпитетлар ярдәмендә тасвирлана. Мәсәлән, Сәгыйдә остазбикә, падишаһ белән чагыштырыла, Гөлйөзем әби *«оҗмаһ әһеленнән»* [3: 219] буларак тасвирлана. Моңа охшаш чагыштыруларны Г. Исхакыйның башка әсәрләрендә дә табарга мөмкин. Мәсәлән, «Көтелгән бикәч» әсәрендә төп герой *«оҗмахтагы хур кызы кеби, аннан да матур», «оҗмах хурыннан матур Ләлә»* [3: 183] буларак гәүдәләнә. Без карап китән әсәрләр мисалында исә ир-атлар хатынын хөрмәтләүче, ышанычлы терәк, гаиләсен кайгыртучан ир, гыйлемле, абруйлы, хөрмәтле, күренекле шәхес итеп күрсәтелә.

ӘДӘБИЯТ

1. Бухаева Р.В. Этнокультурные стереотипы речевого общения (на материале бурятского языка): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Улан-Удэ, 2015. 56 с.

2. Замалетдинов Р.Р. Татарская культура в языковом отражении. М.: ВЛАДОС; Казань: Магариф, 2004. 239 с.
3. Исхаки Гаяз. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авторлары И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.
4. Уфимцева Н.В. Этнические и культурные стереотипы: кросскультурное исследование // РАН ИАН. Сер. Литература и язык. Т. 54, № 3. 1995. С. 52–73.

# ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ РОЛЬ ТЕАТРА И ДРАМАТУРГИИ ЧЕРЕЗ ПРИЗМУ ТВОРЧЕСТВА АХМЕТА МИДХАТА И ГАЯЗА ИСХАКИ

***А.М. Нигматуллина*** *(Казань)*

Заслуга татарских и турецких драматургов, чье творчество, прежде всего, служило интересам просвещения и воспитания народа неоценима. В данной статье рассматривается роль театра и драматургии как просветительского этапа в развитии татаро-турецкий связей. Спектакли, где шла критика таких пороков, как многоженство, неравенство в браке, были востребованы зрителем и служили идеям гуманизма и свободы.
**Ключевые слова**: театр, драматургия, просветительство, театральная критика.

The merit of the Tatar and Turkish playwrights, whose work, first of all, served the interests of enlightenment and education of the people is invaluable. This article discusses the role of theatre and drama as an educational stage in the development of Tatar-Turkish relations. Performances that criticized such vices as polygamy and inequality in marriage were in demand by the audience and served the ideas of humanism and freedom.
**Key words**: theatre, drama, education, and theatrical criticism.

Театр и драматургию по праву можно считать ярким и характерным культурным достижением эпохи Просвещения. Будучи одним из популярных видов искусства, театр, по мнению Шиллера: «был важнейшим орудием в деле воспитания и образования народа» [2: 95].

Для мусульманского Востока театр стал своеобразным центром, который способствовал развитию национальной культуры, воспитывал художественно-этические вкусы, двигал нацию к прогрессу.

Почти все крупнейшие представители турецкого и татарского просветительства пробовали свои силы в драматургии. Они использовали эту возможность как эффективное средство пропаганды просветительских идей. Высоко оценив значение театра для подъема культурного уровня народа, просветители настойчиво призывали к созданию национальной драматургии и театра.

Подчеркивая огромную морально-очистительную и воспитательную силу театра, профессиональный татарский критик Г. Карам утверждал, что: «Наличие национального театра – свидетельство культуры данного народа, показатель степени его социального прогресса» [9: 164].

Мысль о том, что через театр и драматургию, возможно то, к чему долгие годы стремился турецкий писатель-просветитель Ахмет Мидхат, побудило его писать для театра и о театре.

Обеспокоенный низким культурным уровнем своего народа в статье «Изгнание» он продолжал: «Театр для любой культурной страны является одной из самых важных сторон ее жизни; тем более он совершенно необходим в нашей отсталой стране, где на три тысячи человек приходится менее одного грамотного. Если мы серьезно хотим просвещать народ, то нам следует в нашей литературе уделять больше внимания драматургии» [6: 39].

Несмотря на огромное количество написанных им книг, статей в журналах и газетах, он горячо был убежден в том, что для повышения культурного уровня народа нельзя ограничиваться только изданием книг. «На сегодняшний день, – писал А. Мидхат, – даже самая популярная книга издается в Турции тиражом тысяча пятьсот – две тысячи пятьсот экземпляров. Если они и будут проданы, то это произойдет в течение пяти лет. Для стотысячного народа от этого пользы мало. Если мы серьезно хотим просветить народ, не умеющий читать и писать, то с помощью театральных зрелищ назидательного характера мы добьемся гораздо больших результатов. Потому как, если каждый раз при условии, что семьсот, восемьсот человек будут посещать театр, то, разыгрывая представление по десять, пятнадцать раз, его увидят десять, пятнадцать тысяч зрителей» [16: 3].

Итак, с зарождением драматического театрального искусства, появилась еще одна возможность воздействия передовых идей современности и действительности на умы людей. И с этой точки зрения, вполне справедливо замечание театрального критика Г. Карама, который утверждал, что: «…смысловое и воспитательное воздействие театра на эпоху и народ было чрезвычайно велико» [7: 49].

Известно, что национальная драматургия в Турции возникла гораздо позже профессионального турецкого театра. В зарождении последнего, огромную роль сыграла переводческая деятельность писателей-просветителей. Находясь под сильным влиянием западной, в первую очередь французской литературы, в целях создания сценического репертуара, писатели приступают к переводам западной драматургии.

А. Мидхат своеобразно относился к вопросу литературного заимствования у иностранных авторов. «Он не считал зазорным «присвоить» сюжет какого-нибудь европейского писателя. Однако А. Мидхат был отрицательно, даже враждебно настроен к тем положениям и идеям, которые противоречили его моральным, религиозным и политическим воззрениям. Поэтому литературные заимствования у него имели определенные пределы» [13: 138].

Татарский театральный критик Г. Карам, который высоко ценил классиков восточной и западноевропейской литературы утверждал, что: «Ни одна литература не может развиваться в узко национальных рамках, а тем более татарская, находящаяся в стадии бурного развития и изменений. Нужно бережно относиться к национальной самобытности. Татарское искусство должно развиваться по своим законам, иметь свои неповторимые особенности. На пути приобщения к достижениям мировой цивилизации недопустимо слепо копировать чужие образы, нужно бережно сохранять черты национального своеобразия, традиции, сложившиеся веками» [11: 15].

Исследования дооктябрьских турецко-татарских драматических связей показывают, что театральные традиции этих народов имеют много общего. Объяснение этому может послужить и тот факт, что «в годы борьбы за создание профессионального татарского театра среди его основных покровителей немало было людей, получивших образование в Стамбуле и Каире. Среди них просветители отец и сын Мотыйгулла и Камил Тухватуллины, ученый и педагог Зия Камали, писатель и журналист Фатих Карими один из самых зрелых театральных критиков, выпускник Стамбульского университета Г. Карам» 12 29].

Именно Г. Карам вместе с драматургом Г. Камалом впервые знакомят татарского зрителя с турецкой драматургией. Они переводят на татарский язык драму «Несчастное дитя» («Кызганыч бала», Г. Камал) и комедию «Горе от любви» («Гыйшык бәласе», Г. Карам), написанных прогрессивным турецким писателем-просветителем Намыком Кемалем.

В своих воспоминаниях о знакомстве с творчеством турецких писателей Г. Камал писал: «Одновременно с изучением русского языка я начал знакомиться с турецкой литературой. Книги турецких писателей попали мне в руки через И. Ахметзянова, служившего приказчиком у братьев Каримовых. Однажды он, сопровождая некоего старца во время хаджа, на одном из Стамбульских книжных базаров приобрел книги турецких писателей и привез домой. Я окунулся с головой в их чтение. Среди них я нашел драму Н. Кемаля «Заваллы чужук». Какое богатство! Я уже неплохо освоил турецкий язык и, читая драму по несколько раз, начал понимать. Как раз в это время в голове стала созревать тема. Книга Н. Кемаля подтолкнула меня на сочинение драмы «Несчастный юноша». Показав сочинение своему учителю Миргаязу Иманаеву, я получил его одобрение. Пьеса тут же была отослана в Петербург для цензуры, а я, не дожидаясь ее возвращения, приступил к переводу драмы Н. Кемаля «Заваллы чужук». Продав перевод, я получил гонорар в размере пяти рублей. На эти деньги накупил книг. Теперь турецкий язык я освоил хорошо и читал книги с удовольствием» [5: 305].

Турецкая литература, вступившая несколько раньше на путь просветительского реализма, в дальнейшем развитии и становлении татарской литературы сыграла не последнюю роль. Благодаря близости языков, интерес к ней среди татарской молодежи к концу XIX века заметно возрос.

Фатых Амирхан, будучи одним из ярких представителей прогрессивной татарской молодежи, в письме, датированном 20-ым февраля 1904 года, писал: «В начале прошлого года вместе со студентами и гимназистами мы поставили два спектакля на татарском языке. Первый: «Несчастное дитя», второй: «Горе от любви». Я играл Халила в пьесе «Несчастное дитя» и в «Горе от любви» Габдесамат эфенди. Народ нас принял хорошо» [8: 46].

В становлении национального театра татарская молодежь принимала самое активное участие. Например: «В деревне Камали в 1900 году шакирдами была поставлена трехактная комедия Айтуганова “Дядя Халит” (“Халит агай”). Играли ее также в медресе деревни Ижбуби. В Уфимском медресе “Усмания” 27 января 1901 года шакирды поставили пьесу собственного сочинения “Опозориться” (“Ризолят”) в четырех актах. Спектакли шакирдов не носили организованного характера, однако из этих примеров мы видим, что уже в начале нынешнего столетия прогрессивная татарская молодежь сделала на пути создания национального театра свои первые шаги» [3: 13].

Вот еще пример, где герои пьесы Г. Исхаки «Тартышу» («Борьба», 1907–1908 годы), ставят драму турецкого писателя Н. Кемаля:

«Шакира: Я прочитала все книги, которые вы мне назвали. Годных для театра очень мало. Перевод с русского очень плох. Нужно ставить пьесу “Несчастное дитя”. Да и женских ролей там не так много.

Насыйр: Ребята, ну что будем делать?

Сабир: Давайте будем играть “Несчастное дитя”» [14: 455].

«Обращение к сценическим произведениям турецких и азербайджанских авторов сыграло заметную роль в деле становления татарской драматургии. Эти переводы знакомили татарских читателей и зрителей с иной жизнью, а лучшие из них воспитывали критическое отношение к окружающей среде, привычному укладу жизни» [1: 15].

Кроме того, именно пьесы Н. Кемаля «Несчастное дитя» и «Горе от любви» поставленные 22 декабря 1906 года, связывают с датой рождения профессионального татарского театра. Хотя более поздние исследования называют дату 21 апреля 1906 года, когда в городе Уфе была поставлена пьеса

татарского драматурга Г. Исхаки «Жизнь с тремя женами» («Өч хатын берлән тормыш»).

В отличие от турецкой национальной драматургии татарская драматургия зародилась гораздо раньше профессионального татарского театра. В 80-е годы XIX века появляются первые драматические произведения на татарском языке: «Бичара кыз» («Несчастная девушка», 1887 г.) Г. Ильяси и «Рядде бичара кыз» («Противоположное несчастной девушке», 1888 г.), написанная Ф. Халиди.

Однако, как утверждает Х. Губайдуллин: «Исследователи истории татарской литературы и драматургии почему-то обходят молчанием третью по счету пьесу «Дедушка Хасат» («Хасат баба») Фаика, изданную в Казани в 1893 году. Лишь писатель Садри Джалял более или менее подробно останавливается на данной комедии в статье «Первая комедия на татарском языке» [3: 10].

Об этой комедии упоминает М.В. Гайнутдинов в предисловии к книге Ф. Карими «Дочь мурзы», а также в своей монографии Н.Г. Ханзафаров, где пишет: «Повышенный интерес татарских просветителей к проблеме комедийной драматургии привел к тому, что в 90-х годах начали публиковаться комедийные пьесы «Дед Хасат», 1893 год; «Комедия в Чистополе», 1895 год. Эти пьесы послужили заметным достижением татарской драматургии в ее жанровом обогащении» [12: 45].

«Судя по надписи на обложке: «События развертываются в 1872 году в городе Измире». Комедия «Хасат баба» была переведена с турецкого языка» [3: 11].

Свои драматургические произведения А. Мидхат начал писать в период, когда театральная жизнь Стамбула переживала свой расцвет. Появление в 1860 году комедии «Женитьба поэта» Ибрагима Шинаси, положившей начало возникновению письменной драматургии в турецкой литературе, дала возможность многим писателям-просветителям выразить через национальную драматургию свои просветительские взгляды.

Театральные произведения А. Мидхата появились раньше написанных им романов. Быстро оценив преимущество театра в деле пропаганды просветительских идей, он приступает к созданию и постановке своих драматургических произведений.

А. Мидхат известен как автор семи пьес. «Айвах» («О, горе!») так называлась первая пьеса А. Мидхата. Она вышла в сборнике «Забавные истории» в 1871 году и впервые была сыграна 30 марта 1873 года.

Пьеса имела большой успех у зрителей и была одной из любимых А. Мидхата. Сюжет пьесы очень прост. Молодой служащий Мефтун бей живя в доме свекра имел двух жен, которые и не подозревали о существовании друг друга. Первая жена Сабира ханум была ревнивой женщиной и не допускала мысли о втором браке мужа. Это обстоятельство вынуждало Мефтун бея лгать. Одну половину недели он проводил с Сабирой ханум, другую у второй жены – Лейлы ханум. Свое отсутствие он объяснял загруженностью на работе. Обе женщины, любящие Мефтун бея, стали сетовать на его работу и, будучи верны ему, требовать ежедневного присутствия дома. Не желая расставаться ни с одной из них, Мефтун бей некоторое время изощрялся и продолжал обманывать. Тогда отец Сабиры ханум, Рифат бей, узнав о похождениях зятя, решает положить этому конец. Однако Сабира ханум, сама раскрывшая тайну Мефтун бея, в последние часы жизни выносит ему свой приговор.

Проблема полигамии, поднятая А. Мидхатом в пьесе, была одной из злободневных для стран мусульманского Востока. Традиции и обычаи, разрешавшие многоженство, только усугубляли и без того бесправное положение жен-

щин. «Трагические судьбы таких семей не могли не коснуться общества, так как семейные отношения в какой-то мере определяли степень прогресса страны. Если женщина обречена на бесправие, это значит, что система воспитания в таком обществе порочна» [6: 42].

Тема бесправного положения женщин волновала не только турецких, но и татарских писателей – просветителей. Это хорошо видно на примере творчества Г. Исхаки, который уже в своих ранних произведениях обратился к теме трагической судьбы татарской женщины.

Его первый шаг в драматургии начался с драмы «Жизнь с тремя женами» («Өч хатын берлән тормыш», 1900 г.). Хотя проблема многоженства в татарском обществе не стояла так остро, Г. Исхаки счел необходимым затронуть ее, так как она имела место.

«Сюжетом для своей пьесы Г. Исхаки взял истинное происшествие. С бытом и настроением женщин он был знаком с детства. У его матери была «названная сестра», которая хаживала к ним в дом и жаловалась на свою судьбу. Как жена имама мать Исхаки пользовалась в деревне почетом и в их доме всегда бывали женщины советовавшиеся с ней о своих делах. И вот, когда они за чаем беседовали, мальчик, пристроившись за самоваром, внимательно слушал их разговоры» [4: 4]. В отличие от А. Мидхата, чей герой, раскаявшись, оплакивал свое одиночество, Г. Исхаки жестоко наказывает своего героя.

Трижды женившись, Карим бай превращает свою семейную жизнь в сущий ад. Будучи безнравственным и невежественным, он не смог оценить достоинство и порядочность своей первой жены Асмы. Именно ей пришлось ощутить всю тяжесть деяний Карим бая.

Познавшая с детства боль и утрату родителей, Асма стремилась создать счастливую семью. Однако безответственность и жестокость Карим бая разрушили ее мечты. Ведя распутный образ жизни, Карим бай женится на другой женщине – Марьям. Ее скверный характер, неуживчивость и тяга к легкой наживе довели Карим бая до банкротства.

Судьба третьей жены Сорур – яркий пример тому, что женщина в мусульманском обществе занимала бесправное положение и довольно часто была предметом купли-продажи.

Автор пьесы не оставил своего героя безнаказанным. Неизлечимая болезнь, а затем смерть стали расплатой Карим баю за его деяния. Умирая, он, раскаявшись, стал просить прощения у первой жены Асмы:

«Карим: Асма! Как же мне вымолить у тебя прощения за то, что ты пережила со мной. Мои ухаживания, женитьба, наша совместная жизнь, то, как я привел в дом еще одну жену, боже! Даже язык не поворачивается произнести это слово… Прости меня грешного, бесстыдника, прости меня! Не отпускай меня с таким камнем на сердце к Господу! Мне и других грехов хватает!.. О, сердечный друг мой, жена моя! Умираю, умираю! Прости дорогая, прости!..» [15: 94].

«Известный ученый, мыслитель Фараби, которого называли вторым Аристотелем Востока говорил, что человека делают счастливым его духовные навыки и качества его характера. Причины же, делающие человека несчастным, это его злые деяния и способствующие последним плохие качества характера и навыков» [10: 8].

Семейные отношения Мефтун бея, героя пьесы А. Мидхата, изначально строились на лжи, что и привело к трагедии в финале. Осуждая героя, автор показал его трусость и низменные чувства, объяснения которым видел в недостаточном воспитании в семье.

Еще более гнусным и безжалостным оказался герой драмы Г. Исхаки Карим бай. Ссылаясь на законы шариата, позволявшие иметь до четырех жен, он, женившись в очередной раз, не задумывался над тем, что каждую из жен делал несчастной.

Невоспитанность, невежество, ложь и многие другие дурные пороки людей драматурги объясняли недостатком просвещения в обществе. Их призывы и стремления к укреплению хороших традиций в семье, во взаимоотношениях между людьми звучали в каждом драматическом произведении. В них отражалась реальная действительность. Именно поэтому, первые драматические произведения, были востребованы как зрителями, так и читателями.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия. М.: Наука, 1983. 263 с.
2. Видман В. Театр и революция. М. – П., 1923. 103 с.
3. Губайдуллин Х.Х. Татарский театр дооктябрьского периода истории: дис. ... канд. искусствоведения. Казань, 1964. 337 с.
4. Исхакый Г. Загородное гуляние шакирдов. М., 1914. 17 с.
5. Камал Г. Сочинения в трех томах. Т. 3. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 415 с.
6. Кямилев Х. У истоков современной турецкой литературы. М.: Наука, 1967. 132 с.
7. Мухамадеев Р.С. Проблемы формирования татарской литературной критики (1905–1917 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 144 с.
8. Нуруллин И.З. Прометей из новотатарской слободы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 269 с.
9. Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в. / отв. ред. доктор филол. наук В.Ф. Пустарнаков. М.: Наука, 1990. 198 с.
10. Саади А. Педагогические мысли Востока. Казань: Изд-во Тат. научно-педагогического общества при АН Академическом центре Татнаркомпроса, 1927. 31 с.
11. Салихова А.Р. Литературно-критическое наследие Г. Карама: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 20 с.
12. Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия. Казань: Фэн, 1996. 267 с.
13. Яковлева Н.С. А. Мидхат – один из зачинателей турецкого рассказа // Ученые записки ЛГУ. 1990. № 426, серия Востоковедческих наук. Вып. 32. С. 132–140.
14. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 672 б.
15. Исхакый Г. Өч хатын берлән тормыш // Мирас. 1996. № 7–8.
16. Inci Enginün. Ahmet Midhat efendinin tiyatroları. Istanbul, 1990. 302 s.

## XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ МИЛЛИ РИЗЫК ЛЕКСИКАСЫ (Г. Исхакый әсәрләре материалында)

***Р.С. Нурмөхәммәтова*** *(Казан)*

Статья посвящается изучению языка произведений Г. Исхаки, в частности употребляемой в них лексики пищи. Материалом послужили повести и рассказы, написанные писателем в период 1912–1916 гг., а именно «Сөннәтче бабай» (Исполнитель обряда), «Кияү» (Зять), «Ул икеләнә иде» (Он еще сомневался), «Остазбикә» (Жена муллы) и др. Творчество классика татарской литературы является богатой площадкой для исследования повседневного быта татар начала XX века. Описанные в ярких примерах особенности культуры питания, национального обыденного и праздничного стола татар не оставляют равнодушным читателя и дают богатый достоверный материал для лингвокультурых изысканий.
**Ключевые слова:** татарский язык, лексика, XX век, названия пищи, национальные блюда.

The article is devoted to the study of GayazIskhaki’s workslanguage, especially the food vocabulary used in them. The material was novels and stories written by the writer in the

period 1912–1916, namely «Sunnetchebabay» (Performer of rites), «Kiyew» (son inlaw), «Ul ikelene ide» (He doubted), «Ostazbike» (Mulla's wife) etc. The work of the Tatar literature classic writer is a rich space for the study of everyday life of the Tatars of the early twentieth century. The features of the culture of nutrition, the national ordinary and festive table of Tatars described in vivid examples do not leave indifferent the reader and give a rich reliable material for linguocultural research.
**Key words:** Tatar language, vocabular, XX century, food names, national dishes.

Классик язучыларның иҗаты, әсәрләренең теле төрле яклап, төрле максатларда фәнни тикшеренүләргә җәлеп ителә. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки нәкъ менә шул әсәрләр билгеле бер чор теленең үзенчәлекләре турында дәлилле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Бу хезмәттә Гаяз Исхакыйның XX гасыр башында иҗат иткән әсәрләренең теле нигезендә татар теленең «Ризык» лексик-семантик төркеменә караган сүзләр арасыннан «милли ризык» сегментын барлау максаты куела. Әлеге мәкаләдә тупланган материаллар татар матди мәдәнияте лексикасы формалашу тарихына берникадәр ачыклык кертәчәк дип уйлыйбыз.

Гадәттә, классик язучылар, аларның әсәрләрендәге персонажлар бары рухи проблемаларны гына кайгырткannar, шул мәсьәләләрне хәл итү турында гына уйлаганнар дигән караш яши. Бу, бер яктан, дөреслеккә туры килсә дә, икенче яктан, бик өстән генә фикер йөртү. Җентекләбрәк караганда, әдәби әсәр нинди генә чорда пәйда булмасын, язучы кайсы гына жанрда, юнәлештә иҗат итмәсен, алар (димәк, алар иҗат иткән геройлар да) ризык рәтен белгәннәр һәм алар моны яшермәгәннәр дә, дигән нәтиҗә туа.

Әдәби әсәрләрдә ризык – гадәти ризык кына түгел. Ул, өй эчендәге җиһаз, геройларның тышкы кыяфәте, киемнәре, табигать күренешләре кебек үк, әсәрдә барган вакыйгалар сурәтләнгән әйләнә-тирәнең бер өлеше. Шуңа күрә барлык язучыларның иҗатында да ашау вакыты, ризыклар, төрле бәйрәмнәрнең аерылгысыз компоненты буларак табын һ.б. шактый җентекле сурәтләнә.

Америкалы Дина Фрайд үзенчәлекле бер проект эшләгән, ул анда танылган әдәби әсәрләрдә искә алынган ризыкларны үзе әзерләп фотога төшергән һәм блогына урнаштырган, шуның белән персонажлар ашаган ризыкларның китапның үзе кебек үк кызыклы булуын исбат итәргә теләгән [2].

Безнең татар язучылары иҗаты материаллары да мондый блогларда лаеклы урын ала алырлар иде. Чыннан да, рухи азык чыганагы булган әдәби әсәрләрдә «тән азыгы» турында искә алуларбик урынлы тоела. Ә инде алар талантлы язучылар каләме белән дә тасвирланса, тәэсир көче бермә-бер арта.

Кайчандыр, бик борынгы заманнарда, ризыкка мөнәсәбәт тә башкача булган, гадәти ризыклар бәйрәм ризыкларыннан аерылган, зур тантаналарда, кунаклар килгәндә генә табынга куела торган затлы ашамлыклар һәм аларны әзерли белүче оста пешекчеләр яшәгән. Барыннан да бигрәк, шул чорны, шул эпизодларны «авыздан сулар килерлек» итеп тасвирлап язучылар булган. Бәлки үз вакытында ул язучыларның иҗатындагы әлеге өлешләр тәнкыйть утына да алынгандыр, әмма гади укучы әсәрдәге бу урыннарны тын да алмый укыгандыр.

Дөресен әйткәндә, ризык турында оста итеп язучылар алай ук күп түгел. Чөнки моның өчен аерым талант, фантазия һәм хыяллана белү дә кирәктер. Татар әдәбиятында ризык темасы берникадәр «рәнҗетелеп, кимсетелеп», хәтта аерым очракларда «нәфрәт» белән яктыртыла. Ни генә булмасын, татар милли ризыкларының тарихын торгызганда, матди мәдәният лексикасының формалашу үзенчәлекләрен ачыклаганда теләсә нинди мәгълүмат урынлы һәм файдалы.

Бу мәкаләдә фактик материал Г. Исхакыйның «Сөннәтче бабай» (1912), «Кияү» (1912), «Ул икеләнә иде» (1914), «Остазбикә» (1915), «Кәҗүл читек» (1916) әсәрләреннән тупланды һәм шулар нигезендә XX гасыр башы татар милли ризыклары турында мәгълүматлар базасы тулыландырылды. Мисалларның күчелеге яңа булмаса да, алар бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән татар ризыкларының саллы тарихы турында бәян итә, ни дисәң дә, әлеге әсәрләр язылганнан соң бер гасырдан артык вакыт үтеп киткән. Бу хәл хәзерге укучыга таныш ризыкларның шул гомер (бәлки аннан да күбрәк) актив кулланылышта булуын, әле дә әһәмияте югалмавы хакында сөйли.

Татар милли ашлары арасында камыр ризыклары өстенлек итүе турында күп языла, бу үзенчәлек инде дөньядагы башка халыкларга да мәгълүм. Бу урында әлеге күренешнең сәбәпләрен ачыклап тормыйча гына, шуны әйтүне урынлы саныйбыз: тикшерелгән әсәрләрдән күренгәнчә, татар милли камыр ризыклары көндәлек ашлардан саналмаган, аларны сирәк кенә, бер-бер сәбәп белән, мәсәлән, кунаклар килгәндә яки төрле мәҗлесләргә пешергәннәр. Һәрхәлдә, гади халык шулай яшәгән, хәллерәкләрнең табыны, әлбәттә, баерак булган.

Камыр ризыкларыннан **икмәк** – әче камырдан мичтә пешерелгән азык; ипи [5: 178] татар ризыклары арасында төп урынны алып торган, гадәттә аны арыш оныннан пешергәннәр, бодай оныннан пешерелгәне затлырак саналган, аны кунаклар, бәйрәм табыннары өчен тотканнар. Г. Исхакый әсәрләрендә (алга таба әсәр исемнәре кыскартып биреләчәк: «Сөннәтче бабай» – СБ, «Кияү» – К, «Ул икеләнә иде» – УИИ, «Остазбикә» – О, «Кәҗүл читек» – КЧ) *икмәк,* көндәлек ризык булу белән беррәттән:

– хәер итеп тә бирелгән: Дүшәмбе көнне авылның төрле очыннан табак-табак оннар, *икмәк*ләр, итләр күтәреп килгән кыз балаларны, кызы Сәгыйдә абыстай «бисмилла» әйтеп әлиф-бигә төшендергәнне, күңел сабагына «Әлхәмде» сүрәсен биреп йибәргәнне күреп, Хәйретдин хәзрәт тынычлап өенә кайтып китте (О);

– бер-бер изге, зур эшнең әҗере дә булып торган: Иртәгесен иртүк чыгып китә, көн буе дүрт-биш йирдә сөннәт кисеп, биш-алты *икмәк* күтәреп кайта иде (СБ);

– төрле ырым, сихер гамәлләре белән бәйле кулланылган: Чуваш хатыныннан килгән әллә нинди ырымлы *икмәк*не бисмилласыз ашады (О).

***Күмәч*** – май, йомырка, шикәр кушып, камыр басып пешерелгән ашамлык; ак оннан пешерелгән икмәк [5: 331]: Ул кайвакытлар мич ягып *күмәч* сала (СБ). Остазбикәнең тәмле чәе, һәйбәт *ачы күмәче*, балы аңар тагы карчыгыны исенә төшерде (СБ) һ.б.

***Калач*** – ак күмәч [5: 224]: <…> ире ак саплы пәке берлән зур бер *калач*ны күкрәккә терәп кисә бирә (УИИ). Шәһәрдә исә аны башка форма биреп тә пешергәннәр булса кирәк: Әнисе, Әхмәдулланың *саплы калач*ын бир әле (КЧ).

Т.Х. Хәйретдинова тикшеренүләреннән күренгәнчә, татарлар өй шартларында пешерелгән түгәрәк ак икмәкне – *күмәч*, ә шәһәрдән алып кайтканын яки кибеттән сатып алганын *калач* дип атаган [7: 17].

Г. Исхакыйның «Кияү» әсәрендә таныш булмаган ризык атамасы очрады: <…> кодагыйга дип, зур-зур күмәчләр, һәйбәт бәлешләр, пешкән **оча**лар бирелде [3: 193]. Бу берәмлек гамәлдә йөргән сүзлекләрдән әсәрдәге фонетик формада табылмады. «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә ризык мәгънәсендә «оч» сүзе теркәлгән: «ачы камырдан озынча формада пешерелгән кабартма» һәм аның темников сөйләшендә очравы билгеләнгән [6: 508], шушы

ук аңлатма Т.Х. Хәйретдинова хезмәтендә дә бирелә [7: 25]. Безнең фикеребезчә, **оча – оч** бер ризык атамасы булырга мөмкин.

XX гасыр башында татарлар камыр ризыкларыннан **пәрәмәч, коймак, сумса, чәкчәк, катлама, белен, кыстыбый, бәлеш, юка, кош теле, кактөш** һ.б. пешергәннәр: Вахид хәзрәт чәйне ясагач та, Сәгыйдә остазбикә йә *пәрәмәч*, йә *коймак*, йә *сумса* күтәреп килеп утыра (О). Хушбуй исле *сумса, пәрәмәч* тәме чыккан өй каршы алды (КЧ). Җомга көнне иртә белән ул *пәрәмәч* китерерме?.. (УИИ). Шул бүлмәдә тора алмаячагын, иртәгә барып шул комедияне, майлы *пәрәмәч, коймаклар*, пәрдәләр кушып дәвам иттерә алмавын хис итте...(УИИ). Гадәттә, абыстай, Гөлйөзем әби янында калдык-постык *пәрәмәчләр, коймаклар,* бәлешләрдән тагын бераз авыз итә иде (СБ). Ул кайвакытлар <…> бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына *коймак* хәзерләп куя иде (СБ). Былтыр карт муллаларда иртәнге чәйдә ашаган кеби *вак пәрәмәч* ясасаң, аны серкә белән бирсәң шәп булыр иде дә, әлеге килен! (К) һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, бүгенге көндә гадәти ризык булган ***пәрәмәч, коймак, сумса, коймак*** һ.б. я ирләрнең мәчеттән кайтышына, я мәҗлесләргә,я кунак-төшем килгәндә әзерләнгән.

Иртәгә *борчак белене* бирермен (КЧ). Миңа синең борчак беленең кирәкми, безнең әни *коймак* пешерә (КЧ). – ***Белен***не төрле оннардан пешергәннәр булса кирәк, ә борчак бик гади культура саналган, оны да арзанрак йөргән һәм аннан «яхшы сыйфатлы» ризыклар әзерләп булмаган. Ике мисалны чагыштырып караганда, ***коймак***ның, чыннан да, ул чорда затлырак ризык саналуы күренә.

Безнең әни *кыстыбый* ясый (КЧ). Ул кайвакытлар <…> *кыстыбый* пешерә (СБ) һ.б. – Галимнәр фикеренчә, ***кыстыбый*** борынгы ризык булса да, тикшерелгән әсәрләрнең материалы аның да көн саен пешерелмәвен күрсәтә.

Борынының әллә кайбер йире кечкенә генә хушбуй исе сизенгән кебек булды, бер йире яңа пешкән икмәкме, *бәлеш*ме исе тойган кебек булды (УИИ). Ул бетәргә өлгерә алмый, каз аягы-бүтәкәсеннән пешкән, чыгыр-чыгыр кайнап тора торган *шурпалы бәлеш* ашъяулыкка куела иде (СБ).Үрдәктән соң Гөлйөзем әби <…> *йомырка бәлеше* чыгара иде (СБ). Ак кына кулын моңлы йөзенең бер ягына куйган да, майлы *бәлеш*ле, коймаклы ис чыга торган өйдә йоклый... (УИИ). Килен иртәдән бирле чәй эчмәсә дә, ул бик тиз генә мичне җыеп, берсе *дөгедән*, берсе *тавыктан*, берсе кич өчен ике-өч *бәлеш* ясап тыкты (К). Чәй янына Мәрфуга абыстай, лимун, әфлисунга башка, кичә пешергән *алма бәлеше*не <…> керттерде (К) һ.б. – ***Бәлеш*** – татар табынының иң күркәм ризыгы, аны төрле эчлек белән, төрле зурлыкта ясаганнар. Г. Исхакый тасвирлаган ***каз-аяк бәлеше***н көз көне каз өмәләре вакытында пешергәннәр.

Ул тулып, авылны аңкытып тормый, гает көнендә муллалар өендә гатырша мае исе кебек, туйлы йортта *чәкчәк, катлама* исе кебек бөтен исләрне басып та тормый (О). Ике якта, ике тәрилкәдә катырылган *как-төш* (УИИ). Икешәр тәрилкәдә *кош телләре*. Озын бер тәрилкәдә *юка*лар (УИИ). Хәмитнең алдында *чәкчәк* торса да <…> (УИИ).Тагы, мулла-мөәззин белән булышкач башкача: ширбәте, катламасы гына җитми, *как-төш* тә кирәк (К). Өч-дүрт йомыркага гына булса да *кош теле, юка* пешереп алыйм (К) һ.б.

Бу төркемдә бүгенге көн укучысына аңлаешсыз булган атамалардан ***как-төш*** – чәкчәк [5: 224]. Бу чорда аның«чәкчәк» сүзе белән янәшә йөргәне күренә, ә хәзер кайбер төбәкләрдә генә сакланып калган диалекталь берәмлек санала. Каюм Насыйри да бу татлы ризык турында искә ала: «Янә бер төрле аш бар – как-төш дип әйтәләр. Ул как-төш дигәннәре шул: әүвәл камырны басалар йомырка белән, сөт белән, май белән катыштырып. Ул камырны вак итеп

әнәчә ясыйлар. Аны пычак белән вак итеп кисәләр, эрбет чикләвегеннән артык зур булмый, аны казанда кайнаган майга салып алалар. Май эчендә пешкәч, бик яхшы була; моны бавырсак дип әйтәләр. Шул бавырсакны бер подноска өеп катыралар бал белән, өстенә конфет сибәләр; бик яхшы нәрсә була. Аны чәй янына куялар» [4: 241]. Ф. Баязитова ризыкның исеменә төгәллек кертә: «Табынга биргәндә төш өстенә, гадәттә, как ябып чыгара торган булганнар, шуннан *someone* атамасы калган булса кирәк», ди [1: 272]. ***Юка*** – камырны юка гына итеп җәеп пешерелгән тәбикмәк [5: 719] шулай ук әдәби телдә югалган ризык атамасы, җирле төбәкләрдә *йока, җука* формалары очрый [1: 253].

**Ит** – төрки халыклар туклануында төп ризык. Татарлар да иттән күптөрле ашамлыклар әзерләргә өйрәнгән, аны шулпага салып та пешергәннәр, тозлаганнар, каклаганнар, кош итеннән күп төрле затлы ризыклар әзерләгәннәр: Карчык, күңелгә бик үк тулып бетмәсә дә, *ит* юкта *үпкә* тансык дигәнчә, бабай разый булды (СБ). Хатыны кыска гына, тулы куллары берлән бер төеннән төрле кәгазьгә төргән *тутырма*лар <…> чыгара бирә (УИИ). Яшь тәкәнең *тутырма*сыны каймак, дөге, *бавыр* атлап үзе тутырды (К). Балык артыннан *кыздырылган ит* килде. Аннан соң, дөге бәлешенннән соң *чапкан кәтлит*, аннан соң *каз ите*, <…> мәйданга чыкты... (УИИ). Шуның артыннан *тавык ите*ндә пешкән шурпа китерә иде (СБ). <…> *пешкән үрдәк* чыгара иде (СБ). Менә *тутырган тавык* <…> (СБ). Ит аз калып китсә, хатыннар мәҗлесенә берәр *тутырган тавык* та бирермез (К). Юкка өченче көн ике пар *тозлы каз*ны Сафа хатынына саттым (К). Андагы каймаклар, майларны, *тозлы ит, тозлы каз*ларны күздән кичерде (К) һ.б.

Сөт ризыклары атамаларыннан тикшерелгән әсәрләрдә **каймак, катык, май, сары май, корт** һ.б. урын алган. Анасының сыер савып *сөт* бирүене көтә-көтә ач көенчә йоклап киткән угылыны урынга салды (К). Әби, сыерны куып алып кайтма, *каймагы* чәйпәлә, ди...(КЧ).Үзе базга төшеп, *каймаклы катык* алып чыгып, бабайның алдына куйды (СБ). Беркөн муллалар мәҗлесенә бит ашка *катык* катып чыгарган! (К). Быел *катык-сөт* әлхәмделиллаһ (К). Каралуны белми торган ашъяулыкны алып селкеп, подносны куйды, тәрилкә белән *май*ны, булкины читкә төртте...(УИИ). Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрен юа, самавырны тагы көзге кеби иттереп ачып куя, шул көнгә дип җәйли җыйган *каймагы*ннан гөбе яза иде. Ул чәене эчәр-эчмәс, хаҗ шәрифтән килгән, балалар авызландырырга тотыла торган хөрмәне алып, кечкенә генә савытка *пешкән каймак* салып, хәл белергә китте (СБ). Яңадан *пешкән каймак* кайнатты (К). Мулла кияү, бәлки, туң майны яратмый торгандыр, аңа коймак, сумсаны *сары май*дан пешерербез (К). Менә муллалардагы кеби катырган *корт* ясасаң иде (К). Хатыны <...> *майлар, пәйнирләр* чыгара бирә (УИИ) һ.б.

Әсәрләрдә ике төрле каймак атамасы очрый: ***каймак*** һәм ***пешкән каймак***. Беренче төре сыерны савып, сөтне бераз салкында торганнан соң сөт өстеннән җыелып алынган; икенчесен ясау өчен сөтне чүлмәк белән мичкә тыкканнар һәм әледән-әле чүлмәк өстенә утырган каймакны җыеп алганнар.

***Сары май*** – эретеп, туртасы чыгарылган сыер мае [5: 464].

***Пәйнир*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «пинер» дип теркәлгән *сыр* булырга тиеш [5: 416].

Шул рәвешчә, Г. Исхакый әсәрләрендә «милли ризык» сегментына караган сүзләр шактый күп кулланылган. Әлбәттә, Гаяз Исхакый кебек зур иҗади мирас калдырган язучыларның телен, хәтта аерым аспектта гына да, тулаем, җентекләп тасвирлау мөмкин түгел. Без дә әлеге эштә бу теманы фрагментар рәвештә генә яктырта алдык дип уйлыйбыз. Киләчәктә бу юнәлештә тикшеренүләр дәвам итәр, татар классик язучылары әсәрләренең теле төрле лексик-

семантик төркем лексикасын, безнең очракта ризык атамаларын барлауда уңышлы файдаланыр дигән фикерне җиткерәбез. Чөнки бу берәмлекләр милли лингвомәдәниятнең аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр, әлеге тотрыклы лексик-семантик төркем «Ризык» концептына бәйле милли дөнья күренешен барлыкка китерә. Ә моны ачыклауда төрле язма чыганакларның роле гаять зур.

ӘДӘБИЯТ

1. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. Казан: Дом печати, 2007. 480 б.

2. Блюда из знаменитых литературных произведений. Режим доступа: https://www.officeplankton.com.ua/int/blyuda-iz-znamenityx-literaturnyx-proizvedenij.html.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 том: Повестьлар һәм хикәяләр (1909-–1918). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.

4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 384 б.

5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

6. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

7. Хайрутдинова Т.Х. Названия пищи в татарском языке. Казань, 1993. 142 с.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН

***З.З. Рәмиев*** *(Казан)*

В статье рассматриваются письма классика татарской литературы Гаяза Исхаки (1878–1954) к писателю, драматургу, публицисту Фатиху Амирхану (1886–1926), написанные в 1912 году по поводу подготовки к изданию «Сборника татарской литературы» по инициативе М. Горького. Освещена также острая полемика, возникшая на страницах татарских газет «Йолдыз», «Сүз» и «Кояш» во время проведения десятилетнего юбилея татарской периодической печати, где Ф. Амирхан выступает в защиту доброго имени Г. Исхаки, писателя и общественного деятеля.

**Ключевые слова:** Татарская литература, Гаяз Исхаки, Фатих Амирхан, Хади Максуди, Максим Горький.

The article study the letters of the classic of the Tatar literature [G]Ayaz Ishaki (1878–1954) to the writer, playwright, publicist FatihAmirkhan (1886–1926), written in 1912 on the preparation for publication of the Collection of Tatar Literature on the initiative of M. Gorky. In the study, the acute polemic that arose on the pages of the Tatar newspapers «Yoldyz», «Susa» and «Koyash» during the tenth anniversary of the Tatar periodicals where F. Amirhan defends the good name G. Ishaki, a writer and public figure, is also reviewed.

**Key words:** Tatar Literature, Ayaz Ishaki, Fatih Amirkhan, Hadi Maksudi, Maxim Gorky.

Кайсы гына атаклы татар әдибенең нәфис әдәбиятыбыз, мәдәниятыбыз тарихында биләп торган урынын, сәнгати казанышларын тикшерүгә алынмыйк, аның чордаш каләмдәшләре белән шәхси мөнәсәбәтләре һәм, иң мөһиме, гаять катлаулы һәм үзенчәлекле иҗат мәйданында төрле-төрле бәйләнешләре турында да сүз алып барырга тиеш булабыз. Холык-фигыльләре белән берсеннән нык аерылып торган шәхесләр буларак та танылган, XX гасыр башында татар әдәбиятының яңарышына гаять зур өлеш керткән классикларыбыз Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов, Тукай һәм Фатих Әмирхан, Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев, Галимҗан Ибраһимов һәм Фатих Әмирханнар арасындагы мөнәсәбәтләр тугрысында объектив фикер әйтү теләге белән сугарылган тикшеренүләрдә һәрберсенең мин-минлегенә (хөббе нәфесенә) һәм каләм белән эш итүләренә хас үзенчәлекле якларныачуга омтылышлар ясала, аларның сәнгатьчә фикерләү рәвешендә охшашлыклар да, аерымлыклар да, кайчакларда кискен каршылыклар да булганлыгы күренә. Совет чорында исеме дә, күпкырлы иҗат мирасы да халкыбыздан, әдәбият тарихыннан читләштерелгән Гаяз Исхакый

турында соңгы утыз елда язылган хезмәтләрдә дә аның чордаш әдипләре белән интертекстуаль һәм башка төр бәйләнешләренә ачыклык кертелә башланды. Бу урында исә безнең сүз бер үк заманнарда үзләрен гаять талантлы язучы, шул ук вакытта матбугат дөньясында публицист, җәмәгать эшлеклесе, милләтпәрвәр итеп танытксн Гаяз Исхакый белән Фатих Әмирханнарның бер-берсенә мөнәсәбәтләре хакында барыр.

Башта ук аларның тәрҗемәи хәлләренә караган берничә мәгълүматны искә төшерик. Гаяз Исхакый (мишәр) Чистай өязендәге Яуширмә авылында 1878 елда туган, Фатих Әмирхан исә Казанның Яңа Бистәсендә 1886 елда дөньяга килгән («әтисе ягыннан мишәргә <...> барып тоташа» [10: 7]). Шунысы да бар: Г. Исхакыйның әнисе Камәрия Чистай тарафында танылган Морат мулла улларыннан Мөслимвәли кызы булган, «Морат мулла <...> Әмирханнар нәселендә дә мөһим урын тоткан» [7: 10]. Хәер, ике әдип тә бу кызыклы тарихтан хәбәрдар булганнар дип әйтеп булмый.

Яшьләре ягыннан караганда, Гаяз белән Фатихның аралары сигез елдан гыйбарәт. Бу исә аларның очрашкан, аралашкан чакларында теге яки бу рәвештә үзен сиздереп торырга мөмкин иде. Әмма әлегә безгә мәгълүм булган чыганакларда мондый хәлнең булуына ишарәле торган фактлар очрамады (кызганыч ки, алар иҗатын, Тукай язганча, «инәсеннән җебенә кадәр тикшереп» язылган хезмәтләр юк әле, иң мөһиме, әсәрләренең академик басмалары төзелмәгән).

Истәлекләрдә аларның 1897–1898 елларда йөзгә-йөз очрашу ихтималы турында бер сүз дә әйтелми. Ләкин шунысы бар: Ф. Әмирхан унбер яшьләрдә (1895) Казанның мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә йөреп укый башлый. Тиздән (1897 елда) Яңа Бистәгә күчеп килгән Гаяз Исхакый исә Фатихның әтисе Зариф хәзрәт яңа гына ачкан «Әмирхан» мәдрәсәсенә хәлфә булып урнаша [4: 406] (Татар укытучылар мәктәбенә керергә омтылса да, авыруы аркасында, кымызга китеп дәваланып соңара, кабул ителми). Менә шушы вакытларда 20 яшьлек Г. Исхакыйның унике яшьләрендәге Фатихны күрмәве, таныш булмавы ышандырмый. Атаклы «Фәтхулла хәзрәт» исемле повестеның (1911) тексты алдыннан басылган «Минем тәрҗемәи халем»ендә Ф. Әмирхан «Бу елларда [Мөхәммәдия»дә укыган чакларда] мин гарәп вә төрек әдәбияты белән шөгыльләнә һәм һәрбер яңа чыккан татар китапларыны укып чыга башладым», – дип яза. 1904 елда ул Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан инкыйраз» хыялый әсәре белән дә танышмый калмаган, билгеле. Бу соңрак язылган «“Йолдыз” һәм Гаяз Исхаков» исемле мәкаләсендәге «Минем әле дә хәтеремдә, әүвәл мәртәбә “Инкыйраз”ны укып чыккан сәгатьләрем, яшьлегемнең башы, рухымның һәрбер самими вә ялкынлы нәрсәгә ачык вакыты иде әле» дигән юлларда раслана; русча язган автобиографиясендә дә: «Ул миңа бик тә көчле тәэсир ясады», – ди [8: 8].

Әйтергә кирәк, Мәскәүдә «Тәрбияи этфаль» журналының сәркятибе булып эшләгәндә (чынында, редактор) анда бары тик бер генә татар әдибе турында язма бирелгән. «Гаяз» дип исемләнгән бу текст (авторы үзе икәнлеген Р. Алушига язган хатында әйтелә), «халык корбаны булган мөхәррир вә әдибе мәшһүр Гаяз әфәнде Исхаков» турында Ф. Әмирханның вакытлы матбугат битләрендә беренче мәртәбә фикер әйтүе белән әһәмиятле. Балаларга гына адреслануга карамастан, бу язмада, Г. Исхакыйның ике әсәре («Өч хатын берлән тормыш», «Инкыйраз...») мисалында гына даул чор татар баласына әдиплекнең асыл мәгънәсе нидән гыйбарәт икәнлеген ача алган: «Әдип дип бары язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгата, күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирә вә мәгыйшәтнең начар вә яхшы якларыны ачык күрсәтә торган мөхәррирләргә генә әйтеләдер»[1].

Г. Исхакый әсәрләре турындагы уй-фикерләрен Ф. Әмирхан моннан соң да әледән-әле вакытлы матбугат битләрендә укучыларга җиткерә тора. Мәсәлән, шул ук 1907 елда ул (автор – «Дамелла»), Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасы (2 көн элек кенә басылган китап) кулга керүгә, «Әл-ислах» газетасында (19 ноябрь) бәяләмә язып урнаштыра. Әле яңа гына – авторы эсерлар партиясендә булуда һәм крестьяннар арасында җинаятьчел агитация алып баруда Россия империясе Эчке эшләр министрының 20 октябрьдәге карары белән гаепләнеп, Архангель губернасына сөргенгә җибәрелүенә карамастан да ул сүз ала, әсәрдәге образларны башлыча типлар[2] сыйфатында бәяли. Аерым алганда, хатын-кызлар типларының «ирләр кыйсеменә караганда да мөкәммәл була» дип саный. Ф. Әмирхан пьесада җитди кимчелекләр (ноксаннар) да таба: берсе – мәхәббәт аз тасвир ителү. Аның фикеренчә, пьесада «Гаяз әфәнде романтизмда саранлык иткән». Г. Исхакыйның «Солдат» исемле повесте да Ф. Әмирханның («Дамелла»ның) игътибарын җәлеп иткән. Әмма бәяләмәсе [5] бик кыска, ниндидер, авторның үзеннән тормаган сәбәпләр аркасында (реакция еллары) «мөхәрриренең тел очында әйтелми калдырылган сүзләрене әйтергә, язарга» тыелырга мәҗбүр булган. Хәер, повесть тулысынча басылмаган да була. Ф. Әмирхан киләчәктә «яз кояшы» чыкса тәнкыйтен язарга вәгъдә бирә.

Г. Исхакый бу елларда Ф. Әмирханның әдәби, тәнкыйди, публицистик һәм иҗтимагый эшчәнлегенә кагылышлы нинди дә булса фикер-бәя әйткәнме, язып чыкканмы соң? Бу сорауга уңай җавап биреп булмастыр. Моның ике сәбәбе бар шикелле. Беренчесе – Ф. Әмирханның әле 1907 ел башында «Тәрбияи әтфаль»да гына эшләве, әле олылар матбугатына ныклап аяк басмаган булуы[3]. «Әл-ислах»та 1907 ел ахырында чыккан мәкаләләре исә башлыча Дәүләт Думасы эшчәнлегенә бәйле проблемаларны эченә ала. Икенче сәбәп – бу вакытларда исә Г. Исхакый үзе дә әдәби иҗат мәйданыннан читтәрәк эш итә, 1905–1907 елгы инкыйлабый вакыйгалар тәэсирендә сәясәт мәйданына барып керә, өч мәртәбә кулга алына, төрмәләрдә утыра, качакларда качып та йөри, Петербургта яши, Төркиягә дә барып чыга, ахыр чиктә ерак Архангель губернасына сөрелә. Шунлыктан аңа татар вакытлы матбугатындагы хәл-әхвәлләргә, Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури кебек күренекле иҗатчыларга үзенең мөнәсәбәтен белдереп торырга туры килмәгән кебек. Әмма бу замандаш татар язучы һәм шагыйрьләре иҗатыннан Г. Исхакый бөтенләй хәбәрдар булмаган икән дигән сүз түгел.

Моны без аның Фатих Әмирханга язган хатларын укыганда күрәбез. 1910–1912 елларда Г. Исхакый Максим Горький белән дә хат алыша. XX гасыр ахырында И. Нуруллин, бу рус язучысының татар әдибенә юллаган тугыз хатын табып алып, аларны «Татарстан» журналында (1992. 7–8 нче сан; 1993, 2 нче сан) бастырып чыгарды (соңрак аларның тексты Исхакый «Әсәрләр»енең 14 нче томына кертелделәр[4]). Шунысы мөһим: хатларының берсендә М. Горький Г. Исхакыйны рус телендә «“Татар мәҗмугаи әдәбиясе” исемендә бер китап басдырырга» димли. Г. Исхакый, бу тәкъдимне кабул итеп, башта ук дүрт татар мөхәрриренең әсәрләрен сайлап алып кертү мөмкинлеге турында уйлана. Алар – Исхакый үзе, Тукай, С. Рәмиев һәм Фатих Әмирхан. Бу турыдагы фикерләре белән нәкъ менә Фатих Әмирханга хат аша мөрәҗәгать итүендә («Син үзең – яза торган дәвернең чын баласы, шул дәвернең психологиясен иң белә торган мөхәррире») аның язучы иҗатыннан яхшы хәбәрдар булуы күренә. Мәсәлән, ул, «Татар кызы»н, күптәннән укыганлыгын искәртеп, «зур бер әсәрнең конспекты» кебек күргәнлеген, «Хәят» повестеның «Урталыкта» романыннан «тормышлы»рак булуын әйтә, «Хәят»не тизрәк язып бетерергә дә куша. Тагын шунысы да игътибар лаек: ул, үзенең беркадәр татар әдәби мохитеннән аерылыбрак яшәвен танып («Казандан беркемдән дә хат алмыйм»), Фатих Әмирханнан бу җыентыкның

эчтәлегендә урын аласы текстларның характеры турында да киңәшләр дә сорый. «Мин, син, Габдулла, Сәгыйдкә башка рус галәменә күрсәтерлек әсәр юк дип уйлыйм» дип әйтсә дә, шунда ук Ф. Әмирханнан «Син ни фикердә? Бәлки, мин белми торган, мин читдә торып күрми калган берәр мөхәррир, шагыйрь бардыр. Булса, шул кем?» дип киңәш тә сорый; сүзен дәвам итеп, шагыйрьләрдән Тукай белән С. Рәмине генә алуы башка шагыйрьләр каршында җинаять булып күренүенә шикләнеп тә куя. Аныңча, «бөтен әсәрләрдән <…> татар исе, татар тормышы аңкып торырга тиеш». Сорауларына Ф. Әмирханның җавабын алгач, Г. Исхакый тагын аңа хат яза. Күрәсең, Ф. Әмирхан үзенең хатында әлеге җыентыкка Г. Ибраһимов, Ш. Камал әсәрләреннән дә үрнәкләр кертү турында сүз кузгаткандыр. Г. Исхакый Г. Ибраһимовның «Диңгез» хикәясен[6] укымаганын әйтеп, «Сөю – сәгадәт»ен җыентыкка кертергә хаксызрак таба, Ш. Камал иҗатында «елавык»[7] руслардан кергән өмидсезлекне зарарлы буяу дип таба. Күрәсең, Ф. Әмирхан хатында аның «Урталыкта» романы турындагы фикерләре белән килешеп бетмәгәнлеген язганын укып, Г. Исхакый бу әсәр турында элекке хатында әйтеп узган тәнкыйди фикереннән кайтырга туры килгәнлеген белдерә. Шул ук вакытта ул укучылар әсәрне автор теләгәнчә аңлаячакларына шикләнеп тә куя. Исхакый «Тормышмы бу?» әсәре, «Фамилия сәгадәте» җыентыгы турында Ф. Әмирхан хатында әйтелгән тәнкыйди фикерләр белән дә өлешчә килешкән. Ул, «Татар мәҗмугаи әдәбиясе»ндә татар әдәбияты турында кыска гына бер мәкалә урнаштыруны мәслихәт табып (дөресрәге, бу – М. Горький тәкъдиме), материал сорап, шул ук Ф. Әмирханга мөрәҗәгать иткән була. Шунысы кызганыч, бу ике әдипнең, хатлардан күренгәнчә, бер-берсе тулы аңлашып эшләүләренең нәтиҗәле ахыры дөнья күрми: җыентык чыкмый кала.

1914–1915 елларда да ике әдип арасындагы мөнәсәбәтнең теге яки бу рәвеш үзгәреш кичерүенә дәлил булырлык фактлар юк. Ф. Әмирхан, татар әдәбияты һәм вакытлы матбугаты мәйданында 1913 елда булып торган вакыйгаларны күзәтү форматында язылган Яңа ел (аныңча, «бәрәкәтсез ел») мәкаләсендә [5] күп кенә күңелсез хәлләрне (Тукай үлеме, Г. Камал авыруы, С. Рәмиевнең язмавы, И. Бикчурин, Я. Байбуриннарның үз ихтыярлары белән дөньядан китүләре, донослар һ.б.) санап киткәндә: «Гаязымыз сөргеннән азат ителсә дә, бер җирдә тыныч торалмый торган булып азат ителде. Ул быел бик аз язды», – дип, үкенечен белдерә, һәм шунда ук әдипнең Петербургта Г. Исхакый наширлегендә һәм редакторлыгында «Ил» газетасы чыга башлавына, аның тиз арада үзенә игътибар җәлеп итүенә, гомумән, 1913 елда татар вакытлы матбугатының тәрәккъкыять юлында булуына шатлануын да изһар итә. Г. Исхакыйның «Мөгаллим» исемле биш пәрдәле драмасының «Шәрекъ» клубында сәхнәгә куелышына язылган бәяләмәсендә дә Ф. Әмирхан, спектакльгә уңай бәя бирә, бишенче пәрдәнең уйналмавын хуплый (аны ул бик йомшак дип таба). Спектакльдә «татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы <…> авыр, фаҗигале вә өмидсез булып торадыр», «моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә, рухани трагедиягә әйләнә», дип яза ул, Г. Исхакыйны «зур талант, зур мөхәррир» дип атый.

Мәгълүм ки, 1905–1907 елгы инкыйлабый вакыйгалар тәэсирендә туган татар вакытлы матбугаты кыска гына вакыт эчендә шактый зур үсешкә ирешә. Төрле-төрле мәсләк тоткан газеталар барлыкка килде. Кызганыч ки, күбесе озын гомерле булмады, бары берничәсе генә ун-унике ел яшәп, большевиклар революциясеннән соң гына тукталырга мәҗбүр булдылар. Болардан икесе исә – «Йолдыз» һәм «Вакыт» хәтта ки 1916 елда үзләренең ошбу дөньяда яши башлауларының унъеллыгын билгеләп үтәргә дә хаклы иделәр. Шулай булып чыкты да. Татар вакытлы матбугатының унъеллыгы мәсьәләсе башлыча

«Йолдыз» газетасының унъеллыгы төсендә, әмма көтелмәгәнрәк эчтәлектә чагылыш тапты.

Шунысы беркадәр гаҗәп, әлеге юбилей турында беренче сүз Казанда чыгып килгән ике газетаның бер үк көнге – 1916 елгы 5 гыйнвар саннарында кузгатыла: «Йолдыз»ның «Матбугате мувәкъкатенең ун елы» рубрикасы астында «Идарә»нең (16 юллы гына) әүвәл башлап бирелгән искәрмәсендә һәм аннан соңгы Г. Баттал язмасында һәм «Сүз» газетасында исә Г. Исхакыйның «Милли матбугат бәйрәме» мәкаләсендә. «Йолдыз»ның «Идарә»се сүзендә шималь татарлары телендә газета чыгуга 1905 елның сентябрь-октябрендә ун ел тулып узуы[8], сугыш аркасында «тантаналы милли бәйрәм»нең кечектерелүе, ниһаять, «Казандагы бер җәмгыять» аны 5 гыйнварда уздырырга карар бирүе искәртелә. Г. Баттал мәкаләсендә исә татар халкының тарихына күз салына, рус дәүләтенең көчәюе аркасында төрки-татарларның көнбатыш мәгарифе һәм мәдәниятеннән аерылып калуы, гафләт йокысында булып, XIX гасыр ахырында гына уяна башлавы турында бара; Казандагы «Көтебханәи исламия» нең унъелыгы мәҗлесендә (2 гыйнварда) цензура комитеты рәисе Пинегинның татар газеталары чыга башлауның да ун ел тулуын әйтеп, аларның сепаратизм-фәләнгә хезмәт итмәүләрен сөйләгәнлеге дә языла. Газетада Ш. Әхмәдиевнең «Ун ел» исемле мәкаләсе матбугатының унъеллыгына багышланган.

Г. Исхакый «Сүз»дәге (5 гыйнвар) мәкаләсен исә истәлек рәвешендәрәк башлый. 1905 елның октябре көннәрендә Казанда бер төркем татар зыялылар мәҗлесендә[9] яңа гына чыгарырга рөхсәт алынган «Казан мөхбире» газетасын «ничек кую, шул эшне ничек алып бару» мәсьәләсе турында сүз барган була. Исхакый әлеге газетаның бара-тора Сәйдәшевкә тапшырылып, «аңгырыйшыңгырый авырып» үлүен, «Йолдыз» газетасының аерылып чыгуын, Ф. Туктаров белән «Таң йолдыз»н гамәлгә куюларын, гомумән, татар матбугатының бик кыен шартларда яшәвен, хәзер инде «сөннәт туе»на – «ун миллионлы Идел буе мөселманы үзенең чын баласының шул дини дә туена» әзерләнгәнен билгеләп үтеп, «Ителгән хезмәтләр тәкъдир ителерме?» дигән сорау куя, матбугат бу имтихан көнендә үзенә бәяне лаек дәрәҗәдә алыр дигән ышаныч белдерә.

«Йолдыз»ның тулысынча диярлек унъеллык мәсьәләсенә караган материалларны эченә алган 15 гыйнвар санында Г. Исхакый куйган сорауга җавап бирелә кебек. Анда имзасыз һәм дә исемсез баш мәкалә (авторы Һ. Максуди булырга тиешле) газета тоткан мәсләкне аңлатуга корылган. Иң мөһиме: 1905–1907 елларда газетаның «мода» булган суллыкка иярмәвенә, хөррият вә мөсавәткә (тигезлеккә) караган эшләрдә генә суллыкны кабул итүенә, милләткә караган эшләрдә исә һич тә сулланмавына басым ясала. Икенче мөһим шәрех – газетада татар телен (шивәсен һәм имласын) заманга яраклаштырып эшкәртеп куллану. Газетада шулай ук Һ. Максудиның «“Йолдыз”ның тарихы», энесе Садри, Х. Мәхмүдов, мөгаллим Ф. Сәйфи, Ш. Әхмәдиев мәкаләләре, газетага каләмләре белән катнашкан затлар исемлеге бирелгән, берничә кешенең газетаны тәбрикләре китерелгән. Ш. Әхмәдиев фикеренчә, «Йолдыз» «чын милли аң, милли идея нигезенә корылып чыккан җәридәләрнең берсе һәм аның яшәп килүе дә башында торучының (мөхәррир Һ. Максудиның) чын фидаилеге аркасында». Аннан соң да автор мөхәррирне мактау сүзләрен бик мул куллана. 17 гыйнварда чыккан «Кояш»тагы репортажсыман язмасында исә билгесез автор, 15 январьда Казанда Һ. Максуди ханәсендә булган шөкран (рәхмәт белдергән) мәҗлес турында сүз алып бара, анда нотыклар сөйләнүен, бүләкләр бирелүен, телеграмнар килгәнлеген әйтә. Матбугат эшләре комитеты рәисе (цензор) М.Н. Пинегин матбугат дәүләт мәнфәгатен күзәтергә тиешлегенә, киләчәктә дә «Йолдыз» бу юлда уртача мәсләк тотачагына басым ясаган.

Газетаның бу (15 гыйнвар) саны белән танышу Г. Исхакыйда яхшы тәэсир калдырмаган [3]. Юбилей белән котлау-тәбрикләр җибәрүчеләр берничә генә, «татарның милли хезмәтләрен тәкъдир итә белүче аңлылардан» («Вакыт» белән «Тәрҗеманнан башка) беркем дә юк, котлаучылар арасында гыйльми, әдәби затлар да, газеталар редакторлары да күренми ич. Ул бу «суыклык»ның сәбәбен ачарга тырыша: мәсләктәшләрен җыя алмау, мәсләксезлекне мәсләк итү, Һ. Максудиның «мәдрәсә шәкерте генә булса да, «базар»ны аңлап, күзне халыкның «донос ясаша торган» иң кара бүлекләренә (катлавына) боруы, газетаның куркаклыгы, икейөзлелеге... Озак та тормый Һ. Максуди, «Йолдызчы» (псевдоним), Ш. Әхмәдиевләр «контр һөҗүм»гә күчеп [6], Исхакыйны (1906 елда «таңчы» булуын да истә тотып) төрле-төрле гаепләрдә «фаш итәләр». Аларның кайберләре: 1906 елларда «таңчы»лар «Йолдыз»га милли дип бәйләнә иделәр» («корсак мәҗбүр итәдер» – ирония), әдәпсезләр, газетаны («Йолдыз»ны) бернинди дәлилсез «вак интрига вә вак донослар белән мәшгуль бул»уда гаепләүләр; фикер үзгәртү (1906 елда сүгенеп язулары; хәзер исә, күрегез, Исхакый «буржазиягә залимнәр, кан эчүчеләр дип кычкырмый»); бернинди нигезсез «Йолдыз»га «доносчы, хулиганлык таратучы, хөкүмәттән субсидия алучы» кебек пычраклар ыргыта һ.б... Исхакый бу чыгышларга да мөнәсәбәтен белдерми калдырмый: «Йолдыз»га соңгы җаваб»ын яза[10]. «Йолдыз» юбилее темасына караган соңгы мәкалә Фатих Әмирханныкы булса кирәк. Һ. Максуди белән дә, хат аша Исхакый белән дә аралашкан (үзе әйтмешли, «буржуази тынычлык сөя торган табигать» иясе) Әмирхан Һ. Максудиның Исхакыйга ташлаган гаепләүләрендә дәлилсезлек таба, атаклы әдипнең «милләтчелеге бер битлектән гыйбарәт»диюе белән һич тә килешми, таңчылыгында да, шул вакытта милләтчеләрне тәнкыйтендә дә милләтче булып кала дип саный, аның иң мөһим сүзе: «Гаяз халыкчы иде, ләкин ул һичбер вакытта руслашитыручы булганы юк». Минемчә, Ф. Әмирханның бу мәкаләсе – минемчә, бу чор татар вакытлы матбугатында Исхакыйның намуслы исемен яклап яңгыраган иң дәлилле сүз. Каләмдәшенең әдәби иҗатына, иҗтимагый эшчәнлегенә иҗаби (уңай), хәерхаһлы мөнәсәбәте аеруча 1917 елгы Февраль инкыйлабы көннәрендә чагылыш тапты. Ул, Исхакыйның басылып та өлгермәгән «Зөләйха» трагедиясен сәхнәдә Г. Кариев бенефисында күреп, пьесаның әдәби җәһәтеннән башкалардан бик өстен торуын, «урыны-урын белән гүзәллекнең югары дәрәҗәләргә ирешүен язып чыга. Ф. Әмирхан 7 апрельдә Казанда Г. Исхакый шәрәфенә ясалган банкетта (язучының 160 дусты, җөмләдән 40 ханым вә туташ катнашкан) рәис итеп сайлана. Бу турыда үзе үк язган репортажсыман мәкаләсендә [9] Г. Исхакыйның әүвәлге чыгышы белән үк «мәҗлескә эш җыелышы төсе» бирүен искәртеп, ул укучыны аның соңрак, җавап рәвешендә сөйләгән нотыгының мөфһүме (эчтәлеге) белән дә таныштыра (стенография ысулы гамәлгә куелмаганлына офтанып куя). Исхакыйның төп фикерләреннән берсе: «Бу көндә бөтен милләт бербөтен буларак, кулга – кул тотышып хәрәкәт итәргә тиеш <…> милли бөтенлек байрагы астында сәхнәгә басарга тиеш».

Бу ике атаклы әдипнең, иҗади шәхесләрнең теге яки бу ситуациядә аралашу, фикерләшүләрендә, күренә ки, бервакытта да кискен каршы килүләр, бер-берсенә рәнҗешле, кимсетүле сүз көрәштерүләр булмаган, аңлашып яшәгәннәр. Үрнәк итеп сөйләрлек.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Журналның 1907 елгы 1 нче (1 гыйнвар) санының «Бу көннәрдә улган вакыйга» бүлегендә имзасыз гына басылган.

2. Астөшермәдә автор «“Тип” дип, мәгыйшәттән алып ясалган вә тасвир ителә торган мәгыйшәтнең халыклары арасында махсус бер фиркагә тугъры килә торган сурәте әдәбиягә әйтәләр» дигән искәрмәсе дә бар.

3. Беренче җитди әдәби әсәре – «Гарәфә көн төшемдә» хикәясе «Әл-ислах» газетасының 1907 елгы 25 октябрь санында гына басыла.

4. Томны төзүче, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче – Фәния Фәйзуллина.

5. 4 нче томда өч хаты китерелә. Алар 1912 елның 13 июнендә, 5 августында, 18 сентябрендә язылган.

6. Г. Ибраһимовта: «Диңгездә».

7. Г. Исхакыйның «Елавык Хәйрулла» исемле хикәясе дә бар, «Аң» журналының 1913 елгы 9 нчы санында басылган.

8. «Нур» 1905 елның 16 сентябрендә (Петербургта), «Казан мөхбире» 29 октябрендә чыга башлый.

9. Анда Һади Максуди да булган.

10. Сүз. 1916. 2 март. Г. Исхакый «Әсәрләр»енең 7 томы искәрмәләрендә «Йолдыз» белән Исхакый арасында килеп чыккан бу бәхәс турында тулырак язылды.

ӘДӘБИЯТ

1. Әл-ислах. 1908. 26 октябрь.
2. Гаяз. «Йолдыз»га соңгы җавап // Сүз. 1916. 2 март.
3. Исхаков Г. «Йолдыз»ның юбилейсы // Сүз. 1916. 20 гыйнвар.
4. Исхакый Г. Тәрҗемәи хәлем (Икенче вариант // Әсәрләр: 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр. 2013. 479 б.
5. Кояш. 1914. 1 январь.
6. Максуди Һ. «Таңчы»га җавап // Йолдыз. 1916. 26 гыйнвар; Әхмәдиев Ш. Шәкерт абый // Шунда ук. 1916. 28 гыйнвар; «Йолдызчы». «Таңчы» тагын сүгенә башлады // Шунда ук. 1916. 31 гыйнвар; «Таңчы»га икенче җавап // Шунда ук. 1916. 10 февраль.
7. Мусин Ф. Гаяз Исхакый. Казан: Татар. кит. нәшр. 1998. 191 б.
8. Нуруллин И. Гаяз Исхакый // Исхакый Г. Зиндан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.
9. Ф. (псевдоним). Гаяз әфәнде шәрәфенә // Кояш. 1916. 27 март.
10. Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

# ЭВОЛЮЦИЯ ЭТНИЧЕСКОГО СОЗНАНИЯ ЧУВАШСКОЙ ТВОРЧЕСКОЙ ИНТЕЛЛИГЕНЦИИ В НАЧАЛЕ XX ВЕКА

***В.Г. Родионов*** *(Чебоксары)*

Самоидентификация чувашской интеллигенции в начале XX в. эволюционировала в тесной связи с реальной жизнью общества. В 1903 г. ученики школы И. Яковлева дружно выступили за демократизацию образования, против ее миссионерской и русификаторской деятельности. Их недовольство было направлено и против врагов чувашского языка и культуры. В защиту родного языка стали выступать не только интеллигенция, но и национальное духовенство, простые крестьяне. Начало XX в. следует считать периодом резкого подъема национального самосознания и активного поиска путей дальнейшего развития чувашского народа. В авангарде рядом с политической элитой стояла национальная творческая интеллигенция.

**Ключевые слова:** этническая идентификация, чувашская интеллигенция, начало XX века.

In the early 20th century self-identification of the Chuvash intellectuals evolved in a close connection with the real life of society. In 1903 the pupils of I. Yakovlev's school supported the democratization of education and against its missionary and russification activities. Their discontent was directed against the enemies of the Chuvash language and culture. Not only intellectuals, but also national clergy, ordinary peasants began to speak in defense of the native language. The beginning of the 20th century should be considered as a period of rapid rise of national consciousness and of the active search of ways of Chuvash people's further development. The national creative intellectuals were in the vanguard next to the political elite.

**Key words:** ethnic identification, Chuvash intellectuals, the early 20th century.

Проблема самоидентификации чувашской интеллигенции в начале XX в. автором статьи затронута в ряде работ: [4: 12–69; 5: 237–253; 6: 43–47] и др.

Как известно, после издания произведения Г. Исхаки «Исчезновение через двести лет» (1904) в татарском обществе резко актуализировалась проблема выработки национальной идеологии, направленной против *инкыйраз*. В указанных трудах утверждается, что подобную необходимость осознавала и чувашская интеллигенция, которая занималась анализом и критикой действительности в аспекте общественно-национального обустройства, выработки национальной идеи [5: 223]. Целью данной статьи является изучение изменения этнического сознания чувашских писателей и поэтов в первое десятилетие XX в., которые в определенной степени отражены в созданных ими художественных произведениях, а также в их дневниках и мемуарах.

В 1901 г. в творчестве Я. Турхана впервые появляется тема родного языка и его значения в жизни чуваша. В стихотворении «Каçхи чан çапни» (Вечерний звон, 1901) лирический субъект переживает за судьбы чувашского языка, песни и традиционной культуры. Он выступает против официальной русификаторской политики: «Если чувашский язык исчезнет/ То какая благодать будет чувашу? / Чувашская песня если исчезнет / То что останется ему петь? / Если обрусится чуваш, / Русские же скажут: / "Был бы чуваш умным, / Он бы [никогда] не русел". / Неблагодарный русский радовался бы, / Этим свое сердце успокоил бы». Далее мысль лирического героя конкретизируется: если чуваш забудет свою песню, то в чем он найдет утешение? Песня, исполняемая чувашом, выражает его ум и душу, наводит на воспоминания о минувшем и заставляет ему горестно рыдать.

Данное стихотворение отражает настроения чувашской интеллигенции общенационально-центристского направления, к которому принадлежали Н. Никольский и целая плеяда его единомышленников. Борьба за родной язык и народную культуру привела их к противодействию политике просветителей-обрусителей XIX в. (Н. Ильминского, частично и И. Яковлева), хотя они против названных деятелей публично никогда не выступали, как не выступали и против чувашей левого крыла (кроме оценок в личных письмах).

Через год поэт обратился и к социальному концепту *çитмен пурăнăç* (жизнь бедственная), который достаточно глубоко разработан М. Федоровым еще в 80-е гг. XIX в. (поэма «Леший». 1884). Лирический герой стихотворения «Тырăакакан» (Сеятель, 1902) глубоко переживает за мальцов, которые могут остаться без своего кормильца. Язык обывателей очень зол, они не поймут душу отца, заботящегося о благополучии своих детей. Сеятель вздыхает непроизвольно возникшим возгласом: «Ах, пурнăçăн çитменни!» (Ах, жизнь бедственная!). Данный социальный мотив сближает Я. Турхана с поэтами левого крыла. Но, как известно, социальные проблемы не были чужды и поэтам с центристскими взглядами.

Итак, в поэзии Я. Турхана усиливается интерес к социальной проблематике. Если в переводах он раньше старался избегать этой темы, то в 1902 г. посвятил ей ряд произведений, тем самым показав свою возросшую общественную активность.

«Пииты» Симбирской чувашской учительской школы (СЧУШ) шли к чувашской письменной поэзии через открывание себя, через восприятие богатого наследия русской поэтической классики. Хотя многие их стихотворения были в той или иной степени ученическими, но они точно уловили насущные потребности чувашского общества той эпохи. В феврале 1902 г., Г. Комиссаров (Вандер) в свой дневник вносит такую запись: «Наши чуваши во многом изменились. Прежде, как-будто, они не имели чувства достоинства в прямом смысле: чувашин был бесмолвен при оскорблениях сос стороны русских; а теперь

нам оскорбительно, когда кто-нибудь из другой нации ударит нас, мы изъявляем свои права. И ученики, вместо того, чтобы кротко переносить все нападки учителей, как бывало прежде, теперь не переносят этого, а сейчас предъявляют свободу и оставляют школьные скамейки» [2: 457]. Главной и объединяющей чертой поэзии «пиитов» данного периода является их недовольство школой и учителями из СЧУШ. Например, однокашник Г. Комиссарова Р. Иванов выступил в «Казанской газете» со статьей против яковлевского литературного языка, тем самым желая расшатать авторитет инспектора СЧУШ. По воспоминаниям первого, 21 апреля 1903 г. их класс написал сочинение на тему «Что дала мне СЧУШ?». Выпускник И. Карапулов написал свою творческую работу в форме негодующей сатиры на преподавателей истории, географии и сельского хозяйства И. Карапулова хотели исключить из школы В. Никифоров и Турченко, но за него заступились законоучитель Лебяжьев и молодые учителя [2: 467].

«Сегодняшняя тема заставила меня заняться анализом своего образования в Чувашской школе, – занес в свой дневник Г. Комиссаров (Вандер) впечатления, полученные от выпускного письменного экзамена по русскому языку. – Но можно ли это воспитание назвать благородным и добросовестным? Вообще, школа не сделала для нас того, что должна и могла сделать. Напротив, на каждом шагу почти встречаешь сопротивление свободному развитию. Всеобщая история, логика и педагогика с бесполезным зубрением много повредило развитию… Кто, например, старался о развитии стремления к поэзии и вообще к идеалам? Вздумали представлять «Женитьбу» [Гоголя], встретили отпор и только с большим трудом получили разрешение. Но будет довольно и этого. Досадно то, что ты хочешь любить школу, а у тебя отнимают эту любовь. Да, грустно жить на этом свете!» [2: 469].

Недовольство учеников-выпускников школой и некоторыми консервативными учителями заставило Г. Коренькова написать в довольно саркастическом духе стихотворение «Ĕмĕр сана манасçук…» (Ввек тебя не забыть, 1903). Датировку стихотворения позволяют уточнить следующие строки Г. Комиссарова (Вандера): «Он еще писал одно довольно большое стихотворение, посвященное инспектору школы Ивану Яковлевичу» [2: 377]. В воспоминаниях эмигранта С. Николаева читаем: «Когда я был во втором классе, мне пришлось испытать на своих ушах цепкость и силу пальцев нашего инспектора. В пылу гнева и раздражения … он не раз пускал в ход свою тросточку, и бывали случаи полома ее об спину потерпевшего» [4: 73]. В нем поэт описывает факты избиения инспектором его и других озорников СЧУШ. А когда грозный «воевода» школы поскользнулся на льду и упал, никто из учеников не поспешил на помощь. Читаем дальше: «Как же тебя забыть, / Как из памяти выбросить! / Денег надо накопить, / Себе на мясные щи, / А для нашего желудка / Гнилых огурцов поискать, / «Хороших» педагогов/ Приводил ты [в школу], // Старых дьячков / Приглашал пить вино. / Там Калӳсĕ и Илявар, / Плешивый и Свиновар, / И «Солнышко», и Кучер, / И «Турецкий» тоже там». (Из дневника Г. Комиссарова можно вычислить следующих преподавателей, которыми были недовольны ученики СЧУШ: В. Никифоров, Турченко, Д. Кочуров. Первый имел прозвище «Мамай», второй «Скотинин» и «Свиновар», а третий «Кучер» и «Извозчик».) Лирический герой жалуется на учителей, которые не дали ученикам «ума ни на копейку». Здесь выражено желание выпускников получить более глубокое образование, чем получали его в СЧУШ.

В свой дневник Г. Комиссаров (Вандер) 20 апреля 1903 г. внес такую запись: «Наши сочинения взяты к Кочурову, сочинения оканчивающих курс подвергаются поправке того, который сам знает гораздо меньше воспитанников, и

который слывет за человека-эгоиста, преследующего только свои цели и старающего уронить С.Я. Князева в глазах Ивана Яковлевича» [2: 467].

Далее выпускник погружается в общее размышление: «Ну, может ли человеческое чувство, человеческая душа снести такое тиранство, такие насмешки насильников, которые считаются воспитателями, педагогами, желают, чтобы воспитанники любили их школу, а между тем думают играть на воспитанниках, как на флейтах, подавляют все благородные чувства и стремления и тираническими действиями выводят их из терпения».

Итак, «пииты» дружно выступили против порядков СЧУШ и ее миссионерской и русификаторской деятельности. Требования «пиитов» и их сокурсников демократизировать школьное образование сводились к следующим пунктам: 1. Родной язык в школе должен оставаться главным орудием развития учащихся. 2. Из букваря следует убрать излишние слова и выражения религиозного и монархического содержания. 3. Обогатить литературный язык богатством других диалектов (верхового и средненизового). 4. В школах разучивать лучшие чувашские и русские народные песни.

Следующей общей темой и проблемой «пиитов» была борьба против отрицателей чувашской культуры, когда, открывая полемику в «Казанской газете», шовинист Н. Мельников вызывающе заявил, что-де «чувашской культуры не бывало и не будет» (13 апреля, № 15). А Г. Комиссаров (Вандер), будто предвидя подобные заявления, еще в начале 1903 г. сочинил стихотворение «Чăваш» (Чуваш), в котором имеются такие строки: «Я верю: чуваш / Умом выдвинется вперед, Совершенствуя мастерство, / Догонит он других». В стихотворении показаны положительные качества народа: трудолюбие и оптимизм, стремлениям к знанию, умения и мастерство. Лирический герой выражает надежду на улучшение жизни чувашей, что позволит им догнать в плане культуры развитые народы.

1905–1906 гг. вошли в историю чувашской общественной мысли прежде всего двумя значительными событиями: изданием первой чувашской газеты («Хыпар») и созданием общенациональной общественной организации «Союз чувашских учителей (СЧУ). Хотя идея основания чувашской периодической печати была мечта передовой молодежи еще в конце XIX в. (И. Юркин пытался издать национальную газету «Пулхăр» (Булгар. 1899 г.), она воплотилась в жизнь лишь после оглашения царского манифеста от 17 октября 1905 г. Все хлопоты по организации и изданию еженедельной газеты «Хыпар» (Вести) взял на себя Н. Никольский, молодой лидер национальной интеллигенции начала XX в. Его идея создания новой национальной культуры на основе этнических концептов и констант, а также наличие целого комплекса научного инструментария ученого, направленного на аргументацию в пользу использования в церквах и школах чувашского языка, способствовали формированию новых конструктов чувашского сознания. Иными словами, научные мысли В. Магницкого и его достойного ученика постепенно становились национальными ценностями и легли в основу нового общественного сознания чувашского народа. Так зарождалось общенациональное движение за сохранение и развитие чувашской этнокультурной нации. В нем периодическая печать выполняла объединяющую роль центра и имела большие центростремительные силы. Газета являлась более оперативной и демократичной формой управления общенациональным движением, чем авторитарная должность инспектора чувашских школ. Недовольство чувашских пассионариев порядками в СЧУШ и поведением ее инспектора частично было погашено и направлено против врагов чувашского языка и культуры. В защиту родного языка стали выступать не только интеллигенция и церковнослужители, но и, что весьма показательно, представители чувашского крестьянства.

Главной целью редактора являлось, как он вспоминал потом, объединение разновекторных сил народа для создания и развития единой общенациональной культуры на базе чувашского языка и синтеза в ней традиционного и православно-христианского начал. Программа редактора была поддержана братьями Турханами, тройкой «пиитов», И. Юркиным и другими творческими деятелями.

Раскол в редакции «Хыпара» произошел в мае 1906 г., когда сотрудники из бывших учеников СЧУШ, исключенных из школы за революционную деятельность, пытались изменить курс газеты путем публикации материалов по политическим и социально-экономическим проблемам. Вскоре на съезде чувашской интеллигенции было принято решение о передаче «Хыпара» в ведение СЧУ, о назначении нового редактора (С. Игнатьева). Началась вторая жизнь газеты, которая постепенно затухла к концу мая 1907 г.

Итак, 1905 – 1906 гг. для чувашской творческой интеллигенции были не только временем богатым общественно-политическими событиями, но и периодом размежевания по отдельным группам и выбора писателями своих жизненных позиций. Так, основная часть чувашских поэтов, в том числе и «пииты», поддерживала программу «Хыпара» Н. Никольского и активно сотрудничала с его редакцией. Цели братьев Турханов, просветителя и священника Д. Филимонова и др. были схожими объединение молодой интеллигенции, в том числе и членов СЧУ, с чувашскими священниками в пользу общенационального развития. Такую политику вел и Н. Никольский, новоявленный лидер интеллигенции. Но большинство членов СЧУ, в том числе редактор газеты «Хыпар» С. Игнатьев, одновременно выступали против политических устоев в России (с позиции эсеров) и критиковали чувашских священников как приспешников власти и церкви. Борьба «на два фронта» оказалась для них непосильным трудом: газета закрылась из-за финансовых затруднений и ареста сотрудников редакции. И так, к 1906 г. для чувашских писателей идея сохранения чувашского этноса, развития его многофункционального языка и культуры стала общенациональной. Чувашская общественная мысль двигалась в том же направлении и темпе, что и общественное сознание татарской нации начала XX в.

В творчестве «пиитов» своеобразно разрабатывается концепт «свой – чужой», главным образом, созданием образа народа-соперника, каким для чувашей в начале XX в. были татарский и русский этносы. В поэме-сказке «Чăваш па тутар» (Чуваш и татарин, 1905) Г. Кореньков в шутливой форме передает содержание общенациональной присказки: «Кто насмехается над чувашом, к тому самому пристанет» (*Чăвашран кулаканнин хăйĕн кутне çыпăçнă тет*). Смекалистый чуваш постоянно одерживает верх над своим приятелем татарином. Вывод автора таков: чуваш на первый взгляд вроде смирный, но тем, кто над ним захочет потешаться, маху не даст.

В ноябре 1905 г., когда был создан Союз учителей Ядринского уезда на правах филиала Всероссийского союза учителей, Г. Комиссаров (Вандер) сочинил «Учительскую марсельезу» с таким припевом: «Вставай, поднимайся, учитель, / Иди на борьбу за рабочий народ! / Пусть сдается народу мучитель! / Вперед, вперед, вперед, вперед, вперед!». Из дневниковых записей поэта можно узнать, что учителя в те дни выступали против жесткого контроля инспекторов, а также против сельских священников и жандармов как преданных властям сыщиков и фискалей. Лирический герой стихотворения рассуждает так же: «Опекает нас всякий, кто может: / И инспектор, и поп, и жандарм. / Через нас воспитать барин хочет / Обитателей серых казарм». Поэт призывает мужиков собраться под красным стягом: «И увидят враги исполина. / Затрепещут тогда их сердца. / И сразится с ним рать властелина, / Но кто сможет сломить силача!..»

Итак, в 1905–1906 гг. Г. Кореньков и Г. Комиссаров (Вандер) активнее стали развивать мотивы свободы и социальной борьбы, прославлять народ и защищать его интересы. В стихотворении «Товарищу» (1906) последний открыто заявляет, что «счастье – в служенье народу, в борьбе, в правде». В то же время Р. Иванов окончательно отходит от первых двух «пиитов» в сторону «черносотенцев», а также от О. Романова, который не принимал чувашскую народную культуру. Даже Т. Кириллов отстранился от них, был ближе к центру (он понимал значение родного языка и традиционной культуры в новой чувашской жизни). «Хыпар» Н. Никольского объединял и тех, кто стоял левее от О. Романова, и радикальных хыпаровцев СЧУ (М. Акимова, Т. Тайыра и др.). В данный период произошло ускоренное смещение основных концептов, мотивов и тем в стихотворных произведениях в сторону социального и национального содержания. При этом татарская поэзия в лице Г. Тукая активно разрабатывала общенациональную проблематику, чувашская же поэзия оказалась подверженной общероссийским социально-политическим настроениям в ущерб общечувашскому движению. Все это сказалось на динамике и специфике развития национальных литератур последующих периодов.

Главными этническими концептами и мотивами в поэзии становятся родной язык (как основа новой культуры, печати), поэт (как лидер, певец и защитник нации), образы народов-соперников и др. Новые переводы радикально-левых поэтов способствовали созданию революционных образов и символов, а также частичному утверждению чувашской силлабо-тоники. Переводы умеренно-левых поэтов осуществлялись главным образом на основе традиционной (силлабической) метрики. Синтетическое мышление национальных творцов значительно сократило время их становления, оно усиленно направляло поэтов по пути национального своеобразия и творческой уникальности, а также высокого художественного мастерства.

К 1907 г. в «Хыпаре» выделились два основных течения: общенационально-центристское и радикально левое. В составе первого находились и умеренно левые поэты, которые никогда не забывали о насущных проблемах родной нации. Вторые мыслили категориями социально-классовых учений и не признавали общенациональных интересов. Данная особенность наглядно отразилась и при переводе «Крестьянской марсельезы» на чувашский язык, который Т. Тайыр значительно изменил (усилил и конкретизировал его в духе программы эсеров): «За землю, свободу, за насущный хлеб/ Пойдем все сражаться с врагом. / За то, что издеваются над нами, / Соберемся с ними воевать». Здесь обнаруживается чисто классовый подход переводчика.

«Крестьянскую марсельезу» переводил и ученик 1 класса СЧУШ К. Иванов (Кашкыр), когда их класс готовился выступить с протестом против преподавателя-шовиниста Д.И. Кочурова Исследователи полагают, что перевод был сделан не ранее 10 и не позднее 25 октября 1906 г. [1: 364]. В его переводе социально-классовый призыв заменен национально-этническим: «Вставайте, подымайтесь, чувашские люди [т.е. народ]! / Начинай воевать, люд голодный! / Народ пусть обиду свою превратит в ярость! / Вперед, вперед, вперед!»

Радикально-левые хыпаровцы открыто писали, что черный люд (*хура халăх*) не спасет ни царь, ни сам Бог (*патша та, Турă та çăлăнăçкӳмĕ*). Т. Тайыр призывал крестьян к смертельной схватке: «Давайте, родные, без страха / За землю свою постоим, / За нее в бою погибнем». Оправдали ли себя обращения поэтов к мирным крестьянам с призывами брать в руки оружие? Тем более в 1907 г., когда кровавая реакция уже торжествовала и добивала последних свободолюбивых революционеров? Прав был Д. Филимонов, ко-

торый просил молодых чувашских социалистов не экспериментировать свои революционные учения на таком малочисленном народе, как чувашский, и не подталкивать его к кровавой катастрофе. Фактически предсказание последовательного ученика И. Яковлева сбылось: вскоре редакцию газеты разгромили, а радикально-левых сотрудников, в том числе и Т. Тайыра, отправили в Сибирь.

Существует и другая правда. Она заключается в том, что накопленный опыт и практика национально-политической самоорганизации чувашской революционной интеллигенции 1905–1907 гг. были успешно применены в 1917–1918 гг., что придало чувашскому национально-освободительному движению невиданную до того времени динамику и весьма высокую сплоченность и организованность. Создание Н. Никольским в 1917 г. «Общества мелких народностей Поволжья» и развитая разветвленная сеть филиалов «Чувашского национального общества», участие в выборах в Учредительное собрание отдельным списком придали чувашскому национальному движению роль третьей (наряду с русскими и татарами) силы, притягивающей к себе прежде всего «другие малые нации – мари, удмуртов, мордву [3: 371].

Следующим событием, несомненно повлиявшим на творчество К. Иванова (Кашкыра), является его активное участие в петиции, поданной учащимися I класса инспектору СЧУШ 10 января 1907 г. Воспитанники-чуваши данного класса потребовали от инспектора увольнения учителя русского языка и заведующего столярной мастерской Д.И. Кочурова по причине «презренного отношения к чувашам» и «неаккуратного отношения к урокам» [1: 322–323]. 3(16) марта 1907 г. поэт принимает активное участие в волнениях: ученики СЧУШ отказались от занятий, пели революционные песни, а некоторые из них пытались вывесить на здание школы красный флаг. Через два дня они подали вторую петицию с объявлением бойкота учителю-шовинисту, под ней подписались и воспитанники русского происхождения. 8 марта 1907 г. весь первый класс был отчислен из СЧУШ, и К. Иванов возвращается в отчий дом.

Так завершился кратковременный национально-политический порыв воспитанников СЧУШ. Не случайно он совпал с периодом издания газеты Союза чувашских учителей и активного действия чувашских социалистов-революционеров. Личностные качества К. Иванова (Кашкыра), как и его однокашника-поэта Н. Шубоссинни, сформировались именно в пору подъема и резкого слома чувашского национального и общественно-политического движения и в дальнейшем определяли творческое кредо и художественные установки этих поэтов.

Итак, чувашская литература в начале XX в., как и татарская (Г. Исхаки, Г. Тукай, Г. Ибрагимов и др.), интенсивно разрабатывала этнически значимые концепты, составляющие константную основу этнокультурной нации. К числу важнейших факторов динамичного изменения этнической идентификации необходимо включать политическую реальность, высокоразвитую народную культуру, профессиональные искусства и самобытную литературу. Их функциональная значимость определялся наивысшей целью чувашского этноса – обеспечение его полнокровной жизнедеятельности. Первое десятилетие XX в. является периодом резкого подъема национального самосознания и активного поиска путей дальнейшего развития чувашского народа. В авангарде рядом с политической элитой стояла национальная творческая интеллигенция, в первую очередь поэты.

ЛИТЕРАТУРА

1. Иванов К. Собр. соч. Второе, доп. изд. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1990. 56 с.

2. Комиссаров Г.И. О чувашах. Исследования. Воспоминания. Дневники, письма / сост. и примеч. В.Г. Родионова. Чебоксары: Изд-во Чуваш.ун-та, 2003. 528 с.

3. Леонтьев А.П. «Хыпар»: минувшее и настоящее. Факты. События. Судьбы. Чебоксары: Хыпар, 2011. 640 с.

4. Родионов В.Г., Федоров Г.И., Мышкина А.Ф. и др. История чувашской литературы XX века. Часть 1 (1900–1955 годы): коллективная монография. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 2015. 431 с.

5. Родионов В.Г. Чувашский этнос: исследования по этнологии и мифопоэтике. Чебоксары: ЧГИГН, 2017. 324 с.

6. Родионов В.Г. Чувашское и сравнительное литературоведение: теория и практика. Чебоксары: ЧГИГН, 2017. 92 с.

# АССОЦИАТИВНО-СМЫСЛОВОЕ СОДЕРЖАНИЕ МОРАЛЬНО-ЭТИЧЕСКИХ КАТЕГОРИЙ В ИНДИВИДУАЛЬНО-АВТОРСКОЙ КАРТИНЕ МИРА Г. ИСХАКИ (на примере прозаического произведения «Теләнче кызы»)

***Ф.К. Сагдеева*** *(Казан)*

Предметом рассмотрения в данной статье является смысловое содержание морально-этических категорий яхшылык, яманлык, вөҗдан и др., воссоздаваемые на основе лексической экспликации. Объектом исследования послужило прозаическое произведение Г. Исхаки. Фактором, повлиявшим на выбор объекта исследования является то, что в «Теләнче кызы» многообразно представлен материал для выявления морально-этических категорий как фрагмента индивидуально-авторской картины мира.
**Ключевые слова:** морально-этические категории, индивидуально-авторская картина мира, слово, лексема, добро-зло, яхшылык, яманлык, совесть, вөҗдан.

The subject of consideration in this article is the semantic content of the moral and ethical categories of yashylyk, yamanlyk, vejdan, etc., recreated on the basis of lexical explication. The object of the study was G. Iskhaki' sprose. The factor that influenced the choice of the object of research is that the material in the «Telenze gizi» is multifaceted for the identification of moral and ethical categories as a fragment of the individual author's picture of the world.
**Key words:** moral and ethical categories, individual author's picture of the world, word, lexeme, good-evil, yashylyk, yamanlyk, conscience, vejdan.

Понятие картины мира относится к числу фундаментальных проблем теории языка. Интерес к этой проблеме имеет давнюю историю, у истоков которой стоит идея о языке как деятельности народного духа и о различиях языка с точки зрения их мировидения. В последние десятилетия произошел переход от лингвистики «имманентной», ориентированной на изучение языка «в самом себе и для себя», к лингвистике антропологической, «имеющей своей целью изучение языка в тесной связи с человеком, его сознанием, мышлением, духовно-практической деятельностью» [2: 5].

Исследователи, изучающие различные области картины мира признают, что в слове на различных языковых уровнях содержится информация о жизненных ценностях, проявляются особенности действительности.

Раскрытие внутреннего мира человека является основной задачей художественного творчества. Именно в этой сфере возникает потребность в разработке языковых средств и способов сообщений об этой внутренней, психической жизни.

На основе установления иерархии смыслов и ценностей для отдельной языковой личности возможно структурирование завершенной картины мира.

Морально-этические категории соотносятся с одной из основных областей духовной жизни человека и общества – нравственностью. Добро и зло, жизнь и смерть, любовь, справедливость, совесть, стыд, вина и др. задают исходные

ориентиры, на основе которых строится художественная картина мира Г. Исхаки. Данный тезис позволяет определить проблемы анализа художественного произведения, связанные с аспектом восприятия и отражения в творчестве автора морально-нравственных отношений, с умением и способами использования языка морально-этического моделирования для раскрытия художественного характера. Данные категории, являясь формально-содержательными, значительно определяют образ человека в художественном тексте.

В основе семантики морально-этической лексики лежит бинарная оппозиция *добро-зло.*

Каждый художник слова находит свое языковое решение проблем, связанных с противопоставлением противоположностей. У Г. Исхаки добро и зло познаются в единстве.

Добро, к примеру, ассоциируется с доверием и свободой: *Ул тәмам кызына ышанганга аңарга ирек бирде* <...>; любовью: <...> *бер Аллаһе Тәгаләдән бирелә торган «гыйшык» дигән бернәрсә* <...> *һәмма кешедә була дип тә ышана иде*; уважительным отношением к родителям: *Ул атасын, анасын бик зур күрә иде. Аларга хезмәт итү, аларны ризаландыруны беренче кирәкле эшләреннән саный иде* [4: 12 ]. Зло разрушает последнюю надежду и порождает неверие в высшую справедливость. Данное представление находит свое выражение в следующих языковых единицах*: актык өмете өзелде, яхшылык, начарлыкка бер-бер гадел Алланың булуына ышануын тәмам алды.* Представление о справедливости непосредственно связано с ролевым противопоставлением: *бай – фәкыйрь*. Ролевые полюса справедливости характеризуются полярностью и в плане синтагматической сочетаемости слов: *никадәр золым кылган – зур гөнаһ эшләмәгән* : *Моңарга никадәр золым кылган, бүген дә тагы моның төсле бер кызны шулай итә торган бер бай малаена бирелгән дәүләтне, шулкадәр яхшы, тугры, гомерендә, шәт, бер мәртәбә зур гөнаһ эшләмәгән гәрәнкәче бабайның шул дәрәҗә фәкыйрьләге аның хәзерге үлчәве буенча һич гадәләткә сыймый иде* [4: 73].

В языке автора нашло отражение то, что в структуре лексики морально-этической сферы в качестве основообразующих выступают понятия *грех* и *добродетель*. Так, например, в случае оценки ситуации как несправедливой, человек резко меняется, перестает быть добродетельным, начинает испытывать враждебность: *һәрнәрсәгә бер дошманлык, һәркемгә бер ачу берлән карап.* Это чувство в свою очередь порождает зло, агрессию. Осмысление несправедливости жизни передается при помощи слов и сочетаний, имеющих в своей семантике отрицательную коннотацию: *начарлык кылырга хәзер,золым, гөнаһ, җәбер* и др.: *Ул хәзер һәрбер начарлыкны кылырга хәзер, һичберсендә гөнаһ, кешегә җәбер кебек нәрсәләр күрми иде* [4: 73]. В данном случае обнаруживается переход абстрактных существительных *гөнаһ, җәбер* в лексико-грамматический разряд конкретных существительных по модели «абстрактное понятие → конкретный предмет, вещь» в сочетании с глаголом конкретного физического действия *күрми.*

Совесть играет основную роль в нравственной жизни человека. «Самоговорящий язык считает совесть «вторым я» человека, обладающим внятным голосом. Этот голос должен звучать немолчно, непреклонно, неотступно, ясно, но от человека зависит, будет ли он к этому голосу прислушиваться или же заглушит его, подавит, заставит замолчать», – пишут Е.М. Верещагин и В.Г. Костомаров [3: 388 ].

У Г. Исхаки наиболее часто употребительным словом в значении совесть является татарское слово *вөҗдан*, однокоренные с ним слова, фразеологические единицы, связанные с лексемой *вөҗдан.*

В индивидуально-авторской картине мира автора совесть представлена в форме эмоционального переживания. Пока не заглушена совесть человека испытывает мучения: *вөҗдан газабы*.

Совесть – это моральный регулятор поведения человека. В языке ведет себя подобно человеку постоянно гложет (*вөҗданың ашый букв. разъедает совесть*): *Сәгадәтнең исеме Габдулланың вөжданың ашый торган әллә нинди бер авыруга әйләнде* [4: 108–109].

Внутренний конфликт между стремлением к удовлетворению влечений и сдерживающими их предписаниями совести является той основой, когда мучения, угрызения совести усиливаются: *Аның вөҗдан газабыны зурайтуы йтмәгән кебек, теге маржа, теге кабинет күз алдына килде* [4: 164 ].

Совесть может проснуться. Угрызения проснувшейся совести (*уянган вөҗданының газабы*) описываются при помощи сочетаний слов*: бик авыр йөк, бик авыр хәтирәләр, бик ишанычсыз, тайгак, зур җинаят, зур гөнаһ* и др.: *Бу бүлмәдә Габдулла үзенең уянган вөҗданының газабы берлә үзенең баскан урыының бик ышанычсыз идекен, үзенең бара торган юлы бик ышанычсыз, тайгак идекен, үзенең киләчәк өчен хәзерләгән эшләре киләчәк өчен бик авыр йөк булачагын, бик ямьсез хатирәләр калдырачагын, үзенең Сәгадәткә иткән җинаятенең дә ни дәрәҗәдә зур гөнаһ идекен бик яхшы аңлаган кебек, үзенең шул зур җинаятен сатып алыр өчен әллә никадәр корбан кылу дәрәҗәсенә килеп җиткән иде* [4: 82]. В тексте как средство описания внутреннего состояния героя используется наречие *бик* и прилагательное *зур*, что придает большую экспрессивность и эмоциональность повествованию. Совершенный героем аморальный поступок – это нравственное преступление, грех. Искупление греха требует совершения жертвоприношения. Данная мысль реализуется при помощи сложного глагола *корбан кылу*: *<...> үзенең шул зур җинаятен сатып алыр өчен әллә никадәр корбан кылу дәрәҗәсенә килеп җиткән иде* [4: 82]. Угрызения совести, раскаяние в содеянном, осознание ответственности за совершенный поступок, противоречащий моральным принципам, дает возможность вновь стать совестливым (*вөҗданлы*), человечным (*кешелекле*): *Үзенең бөтен гайрәтен-көчен кушып шул былчырак, кабахәт Габдулла Әмирхановичтан яны, вөҗданлы, кешелекле Габдулла әфәндене тудырмакчы була иде* [4: 82].

В языковой картине мира совесть – нравственный тормоз, блокирующий реализацию аморальных желаний и побуждений [1: 353]. Она мыслится как некое существо внутри человека, поэтому человек отвечает перед своей совестью, как перед судией. Основной характеристикой совести как внутреннего судии является ее беспристрастность: всем людям она диктует справедливое решение. У Г. Исхаки, герой, осознав свой поступок, клянется перед своей совестью: *Үзенең киләчәктә ничек итеп әхлак даирәсеннән чыкмаеча гомер итүләрне уйлап, үзенә-үзе вәгъдәсендә торырга сүз бирә, үзенең вөҗданы кашында ант итә иде* [4: 83].

Укоры совести порождают чувство вины, которое является действующей причиной, определяющей каузальность: *Габдуллаүзенең җинаятенең зурлыгын тагы бер мәртәбә хис итте. Күңелендә Сәгадәтне күрсә дә: «Мин сәбәп булдым, мин!» – дигән фикер тагы аның алдында килеп басты* [4: 109].

Осмысление виноватой совести ассоциируется с освобождением из тюрьмы своей совести (*үзенең вөҗданының төрмәсеннән котылып*) [4: 83], грязью, которую необходимо срочно удалить: *Ул вөҗданындагы шул керне тизрәк бетерер өчен <...>* [4: 163].

Из вышесказанного следует, что понимание совести исходит из признания ее двойственности. С одной стороны, совесть выступает в качестве

добродетельного начала в герое, способствующего его моральному самоконтролю и нравственной самооценке. А с другой стороны, порождает неприязненные чувства – это мука совести, угрызения совести, укоры совести, чувство вины.

ЛИТЕРАТУРА

1. Апресян Ю.Д. Новый объяснительный словарь синонимов. М., 1995.
2. Вендина Т.И. Русская языковая картина мира сквозь призму словообразования (макрокосм). М., 1998.
3. Верещагин Е.М., В.Г. Костомаров. Язык и культура. М.: Индрик, 2005. 1040 с.
4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 448 б.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «СӨННӘТЧЕ БАБАЙ» ӘСӘРЕНДӘ МИЛЛИ ҺӘМ ДИНИ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР

***А.Х. Садыйкова*** *(Казан)*

В произведениях Гаяза Исхаки отражены татарские национальные поверья, обычаи. С особенным лиризмом он пишет о жизни двух стариков в рассказе «Сөннәтче бабай» (1911). Дед занимается нужным для детей, мальчиков-мусульман делом, их обрезанием. Он считает, что его ножик был передан еще в древние времена соратником пророка Салманом Фарси (историческая личность). Он считает свое дело священным. Его в деревне уважают. Они мирно и счатливо живут со своей старухой, исполняя все обычаи, подчеркивается их гостеприимство.
**Ключевые слова:** татарские поверья; обычаи; традиции, идущие с древности; обрезание.

He well-known Tatar writer G. Iskhaky in his works highlights tatar national beliefs, customs. With special lyricism, he writes about the life of two old people in the story «Sunnutche Babai» (1911). The grandfather is engaged in the deed necessary for the children, the Muslim boys, their circumcision. He believes that his knife was transferred back in ancient times to the ally of the prophet Salman Farsi (Historical Personality). He considers his work sacred. He is respected in the countryside. They peacefully and happily live with their old woman, complying with all customs, emphasizes their hospitality.
**Key words:** tatar beliefs; mores; traditions, traditions dating back to antiquity; circumcision.

Ибраһим Нуруллин бу әсәргә мондый бәя бирә: «Сөннәтче бабай, – чын мәгънәсендә милли һәм халыкчан әсәр. Ул татар авылының үзенә хас фикерләү рәвеше, хис-тойгы, гореф-гадәтләрен белеп чагыштырган» [3: 14], – ди.Чыннан да Гаяз Исхакыйның күп кенә әсәрләрендә фольклор, гореф-гадәтләр тасвирлана.

«Зөләйха», «Мулла бабай», «Остазбикә», «Кияү», «Сөннәтче бабай» дигән әсәрләрендә гореф-гадәтләр калку булып күзаллана.

Мәсәлән, «Кияү» дигән хикәясендә ул укучыны этнографик дөньяга алып керә. Муллалар кодагые булырга хыялланган Мәрфүга абыстай кызын бик тырышып Мәзингә кияүгә бирергә тырыша. Ул әзерләгән туй ашлары, бирнәләр, кияүне сыйлау гаиләне бөлгенлеккә төшерә. Әсәрдә Мәрфүга абыстайның бу тырышлыгыннан көлү сизелә.

Ә шул ук 1911 елда чыккан «Сөннәтче бабай» дигән хикәядә татар-мөселман халкына хас булган бер гореф-гадәтне язучы лирик планда тасвирлый. Ул әсәр турында Г. Ишнияров дигән журналист болай яза: «...“Сөннәтче бабай”да берсеннән-берсе матур һәм тормышыбыздан алынып язылганга укылганда, эчтә булган әллә нинди яшерен серләрне күз алдына китереп куялар» [3: 107, 409]. Әсәрне чыннан да лиризм белән сугарылган дип әйтергә була.

Авылда «Сөннәтче бабай» дип аталып, гади генә карт гомер итә. Гаяз Исхакый борынгы милли йолаларны, гореф-гадәтләрне шушы тыйнак кына көн итүче карт гамәлләре аша күрсәтә. Авылда аны барысы да Сөннәтче бабай дип кенә беләләр. Ул әкияти бер персонажга әйләнгән, яше күпме икәнен белмиләр, исеме дә онытылган. Шулай да бабайның горурлыгы Салман Фарсиның бабалары икәнен белү. Биредә язучы әсәргә тарихи шәхесне кертә. Ул ислам тарихында билгеле шәхес [1: 162–163]. Мөселманнар армиясе Мәдинәне алу өчен юл тотканда бер фарсы Салман фарси (фарс та диләр) ул элек кол булып, исламны кабул иткән пәйгамбәрнең тарафдары. Ул гарәпләргә билгеле булмаган бер фарсы хәйләсен кулланырга тәкъдим итә.

Мөселманнар шәһәрнең ачык төньягына канау (хандак) казырга һәм шуның артына ныгырга тиеш булалар. Канауны казыйлар, пәйгамбәр үзе дә казый. Пәйгамбәр могъҗиза күрсәтә. Бик күп кешене бер кәрзин хөрмә ашатып туендыра. Шуннан ул тимер таягы белән суга, аннан утлар чыгып бөтен Йеменны, Гарәбстанны, хәтта Константинопольны ялт итте [4: 46]. Шәһәр янына җиткәч, мәҗүсиләр канауны күреп аптырыйлар, атыш башлана. Мөселманнар җиңә. Салман фәрси шулай тарихка керә, фарсылар таҗиклар аның каберен күрсәткәннәр, изге саналган.

Сөннәтче бабай сөннәтчелеккә хакы барын исбат иткән шәҗәрәсен, анналары чалгы пәкесен, сөннәткә сибә торган шешәгә тутырган череген бик кадерләп саклый.

Язучы бу ядкарьләрне елмаебрак тәфсилләп, яратып яза. Нindидер кунак-фәләнгә шәҗәрәнең бер җиренә төртеп күрсәтә дә (укый белмәсә дә): Менә монысы Салман фәрси Аллаһы ганһе, бусы мин. Бабай бу сүзләрне әйткәндә һафаланып киткәндәй була. Бабайга сөннәтәтчелек этисеннән мирас булып калган.

Әмма яшь булгач, сөннәтче дип санамыйлар, Корбаколый дип йөриләр. Авыл хәзрәте аңа Түнтәр ишанга барып, рөхсәт ал, ди. Ул чак әле яшь, нык, 12 көн юлда бара.

Анда Түнтәр ишан аңа сораулар бирә. Ул җавап бирә. Шуннан рөхсәт алып, шәҗәрәгә исемен яздырып ала һәм 16 көндә өенә кайта. Авылында өйләнә. Алар Гөлйөзем әби белән тыйнак кына яшиләр. Кечкенә генә, әмма уңыш бирә торган бакчалары да бар. Бакчаны бабай карый, өй җыештыру Гөлйөземәби өстендә: ул самаварын һәр атнакич көне беләнсап-сары итеп ача, әллә ничә тапкыр идәнен себерә, кыстыбый, коймак пешерә.

Көннәр салкыная башлагач Сөннәтче бабай, намаздан соң хәзрәткә барып, «безгә фатиха биреп чык», – дипү тенә. Хәзрәт вәгъдә бирә. Кунак каршы алуны, өстәлләрнең муллылыгын язучы үз әсәрендә һәрвакыт бик матур итеп тасвирлый. Ул татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын бик белеп яза. Биредә дә кунак каршы алу бик матур булып күз алдына килеп баса. Хәзрәт фатыйха бирергә абыстае белән килә. Картларга чирек чәй бүләк итә, абыстай күкрәкчә бирә. Өч самавыр чәй эчкәч, хәзрәт дога кыла, аңа садака бирәләр. Шуннан Гөлйөзем әби тавык итендә пешкән шурпа китерә, аннан каз-аяк бүтәкәсеннән пешкән, кайнап торган шурпалы бәлеш килә. Сөннәтче бабай сосла алып керә. Бәлешнең төбеннән дә берәр кисәк ашыйлар. Шуннан пешкән үрдәк чыга, ул да ашалып беткәч, әби йомырка бәлеше чыгара, ул да ашалып бетә. Бабай азактан зур карбыз күтәреп керә, аны да мактый-мактый ашыйлар. Ахыры, хәзрәт сөннәткә чыгарга фатыйха бирә. Шул көнне өйләдән соң сөннәтче бабай эшкә чыгып китә. Татар авылының сый-хөрмәте мул булуын, ашау культурасын, аш-су осталыгын язучы яратып, тәфсилләп күрсәтә. Сөннәткә йөрү гамәлен дә тасвирлый. Бабай малайларга алма биреп, чыбыркы

ишәргә вәгъдә итеп, аларны кызыл ыштан үлчәргә күндерә. «Бисмилла» дип кисеп алгач, малайның җәрәхәтенә череген куя. Аннан чәй эчү була, бабай садакага бер ипиен алып, өенә кайта. Икенче тапкыр балаларның яраларын тикшерә, тагын ипи ала. Ә көзен инде аңа ата-аналар уңышларыннан өлеш чыгаралар. Сөннәтче бабайны һәм Гөлйөзем әбине аның изге кәсебе яшәтә, ашата, киендерә. Аның тормышын автор «җәйге җилсез көнне ашьяулык кеби тип-тигез ага торган Идел кеби», – дип чагыштыра. Бу әсәрдә тагын ул заманнар өчен хас булган бер гадәт күрсәтелә. Бабай, көнен, вакытын санап, сөйләшеп хәзрәткә бара, кан алырга. Бисмилла әйтеп, хәзрәтнең арт чигәсенә йомшак кына пәке очы белән чигә, аннан мөгезне утырта, аннан икенче чигәгә чигә, ике-өч чүмеч хәтле кан агызалар кайвакыт. Аннан тамырны бәйлиләр. Бабай шул эш арасында элекке риваятьләрне, кан алдыруны сөйли. Хәзрәт рәхмәт әйтеп, аңа бүләк бирә. Бабай табип гамәлләрен үти, хәзрәт сафланып китә. Сөннәтче бабайның бу бәйрәме дә үтеп китә. Тормыш һаман талгын гына ага кебек.

Әсәрнең беренче яртысы әкияти рухта, ул легенда (шәҗәрә, пәке, Салман фәрси исеме) ярдәмендә, мифологик төсмерләр белән өртелгән. Г. Исхакыйның фольклорны, гореф-гадәтләрне куллануы үзенчәлекле. Ул әсәрнең икенче өлешендә бу хыялый дөньядан кинәт реаль дөньяга күчә, һәм сөннәтче бабайның тормышы кискен үзгәрә, ул әкияти талгынлыгын югалта. Аның карчыгы Гөлйөзем әби вафат була. Бабайның тормышы челпәрәмә килә, өенең яме, рәте китә. Ялгызлыгы авыр булгач, ул өйләнергә тели. Авылындагы, тирә-юньдәге барлык карчыкларга сүз салып карый. Әмма риза булучы табылмый, шулай да берсе риза була.

Бәхетсезлеккә каршы, ул уңмаган, тупас карчык булып чыга. Сөннәтче бабайның өе, ризыклары, кош-кортлары кадерсезләнә. Карт өеннән ваз кичә, я мәчеттә, я урамда көн уздыра. Соңгы чик тиз килеп җитә. Инде карт, ялгышын аңлап, Гөлйөзем әби кабере янында үзенә кабер казый башлый. Бер көн өенә кайтса, карчык түр башында хәзрәт Сәлман Фарси пәкесе белән бәрәңге әрчеп утыра. «Хәзрәти Аксак Тимердән калган» һәм җитмеш мең мөселманны сөннәткә утырткан пәкенең мәсхәрәләнүенә юаш сөннәтче бабай түзә алмый. Ул гомердә булмаганча тузына, карчыкка әйберләр ата, аңа «талак» дип өч тапкыр кычкырып, куып чыгара. Бабайның ярсыган күзенә бу тупас карчык халык риваятьләрендәге «пәри ташландыгы» булып күренә. Бабай аны тагын «иблис сидеге, шәйтан, Дәҗҗал» дип тә атый. Яүҗүҗ-мәүҗүҗ колы, ди. Соңгы сүзләр бабайның ислам мифологиясеннән мәгълүматлы булуын күрсәтә. Дәҗҗал (гар.) – алдакчы, ялганчы дигән мәгънәне аңлата. Яүҗүҗ-Мәүҗүҗ – төрле әшәкелекләр, явызлык таратучылар, кешеләрнең явыз дошманнары. Ахырзаман җиткәч тимер диварны җимереп, дөньяны үзләренә буйсындырачаклар. Шулчак Дәҗҗал, зур ишәккә атланып, дөнья буйлап китәчәк. Ул коточкыч, гәүдәсе кызыл, маңгаенда бер күзе бар. Ул мәчетләрне җимерә, мөселманнарны куа, 40 көн шулай барачак, диелә [2: 7–8, 105–106].

Ярсыган Сөннәтче бабай бер юньсез әбине шундый коточкыч явыз итеп күзаллый. Бу хәлдән соң бабай һуштан яза һәм үлеп китә. Бабайны тиешенчә хөрмәтләп, Гөлйөзем әби янына, үзе казыган кабергә күмәләр. Ләкин зиратта алар өстенә бабай утырткан ямь-яшел яфраклы ике яшь каен үсте, дип тәмамлый язучы үзенең бу мәхәббәт тарихын. Көнчыгыш дастаннарында урын алган, Низами тарафыннан язылган «Ләйлә һәм Мәҗнүн» дастаны, аның вариантлары татар халкында борынгыдан билгеле булган. Гашыйкларның мәхәббәте фаҗигале тәмамланып, үлгәч, аларны янәшә күмәләр. Алар каберенә роза куаклары үсеп, бер-берсенә уралалар. Менә каеннар тавышсыз-тынсыз картлар

кабере өстендә кешеләр аңламый торган тормыш берлән яши башлады, дип яза Исхакый [2: 154–184].

ӘДӘБИЯТ


1. Ирвинг В. Жизнь Магомета. М., 1949. 312 б.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда. 2 том. Казан, 1999. 417 б.
3. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда. 8 том. Казан, 2011. 447 б.
4. Исхакый Г. Зиндан. Казан, 1991. 669 б.
5. Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышы. Казан: Иман, 1993. 103 б.


# XX ЙӨЗ БАШЫ МИЛЛИ ЯҢАРЫШ ХӘРӘКӘТЕНДӘ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ЗАМАНДАШЫ ИБРАҺИМ БИККОЛОВ


***Ф.С. Сайфулина*** *(Казан)*



В данной статье анализируется общественно-журналистская деятельность Ибрагима Биккулова (1884(86)–1938), чье доброе имя было незаслуженно забыто в сложные годы репрессий и в последнее десятилетие возвращено родному народу. Ибрагим – младший брат более известного татарскому читателю религиозного деятеля, просветителя, писателя начала XX века, автора книг для чтения – Касима Биккулова. Родившись в семье известных богословов Биккуловых в конце XIX столетия, Ибрагим, как и многие талантливые личности, проходит сложную, но яркую жизнь, посвященную делу служения своему народу. В его публицистических статьях прослеживается общественно-культурное и политическое состояние татарского общества начала нового века.


**Ключевые слова:** татарская литература, Ибрагим Биккулов, публицистика начала XX в., журналистская деятельность.



In this article, Ibrahim Bikkulov (1884(86)–1938) public-journalistic activity is analyzed, whose good name was undeservedly forgotten during difficult years of repression and returned to the native people in the last decade.Ibrahim is the younger brother of a religious figure, educator, writer of the early 20th century, more known to the Tatar reader, the author of books for reading – Kasim Bikkulov. Born in the family of famous Bikkulov theologians at the end of the nineteenth century, Ibrahim, like many talented individuals, goes through a complex but vivid life dedicated to the service of his people. In his journalistic articles, the socio-cultural and political state of the Tatar society of the beginning of the new century can be traced.


**Key words:** Tatar literature, Ibragim Bikkulov, journalism of the beginning of the 20th century, journalistic activity.


XX гасыр башы татар халкының милли һәм рухи үсешендә, мәдәни яңарышында әһәмиятле урын тоткан чор буларак билгеле. Әлеге вакыт татар әдәбиятының киң колачлы, масштаблы үсеше белән билгеләнә. Нәкъ шушы вакытта милли әдәбият белеменә һәм әдәби тәнкыйть фәненә нигез салына, вакытлы матбугат үсеш ала. Шуның белән бергә татарларны һәм башка төрки халыкларны мәгърифәтле итергә омтылган яңа буын язучылар, нәширләр, тәрҗемәчеләр формалаша. Бу – искелекне җимереп, татар тормышының бөтен өлкәсендә дә яңарыш хәрәкәте башланган чор [1: 3].

И. Бикколов та әлеге хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган яңа заман яшьләренең берсе. Ибраһим Җамаледдин улы Бикколов (1884–1938) репрессия еллары корбаны булган һәм исеме соңгы еллардагы эзләнүләр нәтиҗәсендә халкыбызга кире кайтарылган, милләтебезнең бик күп талантлы улларының берсе, җәмәгать эшлеклесе, педагог, XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып барган журналист, тәрҗемәче. «Татар халкы тарихында, яңарыш чоры татар тормышында, туган җирләре – Яңа Тинчәле авылының ике гасыр арасы хәятендә бу олуг шәхесләр һәм, гомумән, Бикколовлар нәселе кылган

изге гамәлләр, калдырган мәдәни мирас киңкырлы. Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган этиләре Җамаледдиннең дә, Казан мәдрәсәләренең берсендә укыган мәгърифәтче, дин белгече, шагыйрь, язучы Касыймның, атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, гомерен укытучылык эшенә багышлаган, публицист булып танылган Ибраһимның да туган авыллары халкын, гомумән, төрле төбәкләрдә таралып яшәгән татар кавемен белем-мәгърифәтле итү юлындагы хезмәтләре бәһәләп бетергесез» [2: 9].

Әлеге шәхес хакында аерым мәгълүматлар XX гасыр ахырында Ф. Ибрагимова язмасында урын алган [3: 188]. Биографиясеннән аерым мәгълүматлар «Шәхесләребез» сериясендә басылган «Бертуган Бикколовлар» китабында тәкъдим ителә [2: 12–35].

Замана әдәбият белеменең бер юнәлешен сәяси-идеологик сәбәпләр аркасында галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән шәхесләрнең эшчәнлеген өйрәнү тәшкил итә. Әлеге мәкалә И. Бикколовның замана башындагы публицистик эшчәнлеген өйрәнүгә багышлана.

И. Бикколовның публицистик эшчәнлеге шактый киңкырлы. Үз вакытында ук Галимҗан Ибраһимов аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә югары бәя бирә [4: 29 апр.]. XX йөз башынада аныңүз чорының актуаль мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре «Шура», «Кояш», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында һәм «әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» кебек гәзитәләрендә басыла. Бу яктан караганда Россия тарихына катлаулы сәяси вакыйгалары белән кереп калган ел буларак 2014 ел И. Бикколов эшчәнлегендә аерым активлык белән сыйфатлана. Бу җәһәттән аның 1914 елгы эшчәнлеген күрсәтергә мөмкин. «Петербургта мөселман съезды», «Гомумауропа сугыш алдында», «Бөтен дөнья сугыш алдында» [5] мәкаләләрендә авторның шушы вакыйгаларга мөнәсәбәте чагылыш таба, әлеге аналитик характердагы мәкаләләр аны киң карашлы, тирән белемле, хз фикерен ачык, төгән әйтеп бирерлек журналист буларак формалашуын күрсәтә. «Үткән 1914 ел» [6: 19–24] дип аталган аналитик мәкаләсе И. Бикколовның татар дөньясы, яки Русия вакыйгаларыннан гына түгел, ә гомумтөрки һәм Аурупа илләрендәге сәяси вакыйгалардан да хәбәрдар булуын, аларны бер яссылыкка куеп, бәяли алуын күрсәтә. Мәкалә 1914 елның башында Төркия-Юнан илләре арасында низагка бәядән башланып, аны китереп чыгарган сәбәпләр турында фикер йөртүдән, моңа Аурупа илләренең, аеруча Германиянең мөнәсәбәтен чагылдырудан башлана; бу вакыйгаларга Русия, Әрмәнстанның тартылу сәбәпләре ачыклана.

Алга таба автор әлеге мәкаләсендә Германия матбугатында Русиягә каршы каты һөҗүмнәр һәм аның нәтиҗәләре хакында фикерләрне күзәтә, Албаниянең үз эчендәге кузгалышлар, Франция – Россия – Румыния – Ливадия мөнәсәбәтләрен сыйфатлый, Англия – Ирландия бәйләнышларына да күзәтү ясый. Франциядәге хөкүмәтендәге эчке каршылыклар хакында хәбәр бирә. Гарби (көнбатыш) Яурупаның башка бөек вә кечкенә дәүләтләрендә Балкан дәүләтләре арасындагы хәлләр, Болгариядә партия низаглары, Икенче Балкан сугышының эче нәтиҗәләре хакында эш башында торучыларның бер-берләрен гаеп итешүләре кебек мәгълүматлар; болардан тыш, Сербия вә Каратау (Черногория), Юнанистан (Греция) вә Румыния дәүләтләрендәге хәлләре бәян итә. Япония, Кытай дәүләтләре, Кытай вә Манголия, Манголия вә Русия арасындагы зур вакыйгалар хакында фикер йөртә.

Мәкаләдә Русиянең эчке эшләре вә вакыйгаларына, илнең беренче Бөтендөнья сугышы алдынан булган халәтенә бәя бирелә. Государственный Думада Төркестанга мөнәсәбәтле карарлары, Русия эшчеләренең хәрәкәте зур-зур

шау-шуларга сәбәп булуы, кадетлар, октябрист вә милләтчеләрнең съездлары, Русиядә беренче буларак һавада очу эше съезды да булып үтүе хәбәр ителә.

Мәкаләнең аерым бер өлеше Русия мөселманнары тормышына багышланган. Бакуда «Сафа җәмгыяте», Одессада, Варшавада җәмгыяте хәйрияләр, Ростов-Донда «Нәшре мәгариф» җәмгыяте, Мәскәүдә вә башка байтак җирләрдә көтебханәләр, Кавказда төрле мөселман җәмгыятьләре тарафыннан авылларда мәктәпләр ачылуы хакындагы хәбәрләр замана укучысында аерым кызыксыну уята. Шулай ук Идел буе мөселманнары арасында рус-татар школаларының тизлек берлә арта башлаганлыгы, Кырым мөселманнары Дарелмөгаллимин ачар өчен акча җыюлары, Минзәләдә имамнар курсы ачылуы, мөгаллимәләр курслары, Төркестан әтрафында да яңа тәртип мәктәпләре күзгә күренерлек рәвештә артуы һ.б. хәбәрләр дә XX йөз башы татар-мөселман җәмгыяте хакында мәгълүмат бирә.

И. Бикколов заманаһың игътибарга лаек булган зур мәсьәләләреннән Петроградта булып үткән ике мөселман съездлары һәм Кавказдагы мөселман мөгаллимнәре съездларын билгеләп үтә һәм аларның әһәммиятләре турында фикер йөртә.

Болардан тыш мәкаләдә дини бәйрәмнән, сату-алу эше, вакытлы матбугат эше, Театр вә музыка һ.б. күп мәсҗәләләр күтәрелә.

Ахыр якта «Үткән елда бөтен ислам галәме» дигән баш астында Мөселман мәмләкәтләреннән Хива вә Бохара, Кытай, Һиндстан мөселманнарында, Әфганстанда, Иранда, Мисыр мөселманнары тормышында, Төркиядә булган яңалыклар белән дә таныштыра.

Мәкалә «Тунис, Әлҗәзаир (Алҗир), Фәс (Морокко) һәм Җава (Ява) атаулары мөселманнарының хәятләреннән кирәк кадәр мәгълүмат безгә бик аз ирешдекеннән, алар хакында катгый бер нәрсә язарга мөмкин булмады. Ләкин, һәрхәлдә, гомум ислам галәме үткән 1914 нче елны яхшы ук тыныч, искечә, алга атларга бик ашыкмыйча гына үткәргәннәр» дигән фикер белән тәмамлана. И. Бикколовның икенче алда да «Үткән 1915 ел» [7: 51–54] мәкаләсе белән чыгуы, авторның үз фикерләрендә һәм эшчәнлегендә шактый өзлекле булуын күрсәтә. Әлеге характердагы мәкаләләре аны җитди сәяси журналист итеп таныта.

И. Бикколов тарафыннан язылган мәкаләләр арасында заманының атаклы шәхесләренә багышланганнары да шактый. Шундыйлардан берсе татар Яңарыш хәрәтәтенең башында торучы – И. Гаспралының вафатына бәйле язылган. «Беренче мөгаллим» [8: 14 сентябрь] исеме белән бирелгән мәкалә түбәндәге юллар белән башлана: «Үткән гасырда үзенең Мәрҗаниләре, Насыйри вә Курсавиләренең тәрбиясе саясендә шималь төрекләре уку яшенә җиткән иделәр. Фәкать ... заманча укытыр өчен бер мөгаллим кирәк иде. Менә шушы мөгаллим Кырым ярымодасының (ярымутравының) бер почмагыннан чыкты. Шималь (төньяк) төрекләренең бу беренче мөгаллимнәре мөкәммәл Аурупа образованиесен алган, чын тәрбия вә гыйлем сахибе, чын мәгънәсе илә Аурупалы бер зыялы иде».

И. Бикколов И. Гаспралының эшчәнлегенә, татар милләте өчен кылган гамәлләренә югары бәя бирә, аеруча «Тәрҗеман» гәзитен чыгаруының төркитатар халкының тәрәккыятендә аеруча зур игътибарга лаеклы, авыр, ләкин бик кирәкле эш булуын күрсәтә. Мәкалә авторы «Мөгаллим»нең төп фикере – төрки халыкларның бер тел, бер дин һәм бер идеалларга хезмәт итү аша бердәм булуын алга сөрү дип тәгаенли, шуның аша Аурупа мәдәнияте югарылыгына күтәрелүгә ирешү мөмкинлеген таный. И. Гаспралы ирешкәннәргә бәя биреп, И. Бикколов, «...хәзер ул мөхтәрәм карт остаз үзен чын-чын ата, чын-чын остаз иттереп, без шималь төрекләренең үзләренә генә түгел, бәлки

бөтен галәме исламга таныткан, ... бөтен галәме исламнан үзен ихтирам иттерә алган иде. ...хәзер инде аны бөтен Аурупа ихтирам итә, аның мөселманнар хакындагы сүзләре илә бөтен Аурупа голәмәсе хисаплаша, аның хакында немец, инглиз, француз, рус телләрендә әсаслы китаплар языла башлаган иде» – дип яза, төрки дөнья өчен аның хезмәтләре русларның Бөек Петр I ләре, немецларның Пистолоцилары дәрәҗәсендә булуын раслый. Мөгаллимнең вафаты бөтен ислам дөньясы өчен зур бәхетсезлек дәрәҗәсендә югалту булуын автор нечкә тоемлы публицист буларак тасвир итә. Мәкалә авторының теле камил, тәэсирле, образлы булуы, үзенең замана вакыйгаларыннан хәбәрдар, тирән белемле булуы шик тудырмый. Мәкалә ахырында беренче мөгаллим эшен аның шәкертләре дәвам иттерәчәк, аның исеме һәр кешенең йөрәгендә сакланачак дигән фикер яңгырый.

И. Бикколовның мөхтәрәм Ш. Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу уңаеннан үткәреләчәк чараларга әзерлек алып бару хакында язылган мәкаләсе [9: 18 сентябрь] дә шушы характерда язылган. Мәкалә башында ук автор бу эшнең асыл максатын ачыклый: «Милләтнең бөек адәмнәренең озак гомер итүләре, озак хезмәт итүләре, туган көннәре мөнәсәбәтләре илә бөек бәйрәмнәр ясауның халыкта милли аңны тәрәкъкый иттерү вә милли хисне үстерү юлындагы файдалары булдыкыны, уйлыймын ки, озын-озак исбат итеп торуга да хаҗәт юк. ... Шуңа күрә мондый вакыйгалар мөнәсәбәте илә булган форсатларны ганимәт (уңыш, бәхет) дип белеп, мондый вакыйгалардан киңерәк рәвештә файдаланып калырга тырышырга кирәк». Автор Мәрҗани хәзрәтләренең йөз ел тулу мөнәсәбәте илә ясалачак бәйрәмне халык өчен файдалы итеп үткәрелергә тиешле бер чара буларак белгели. И. Бикколов Ш. Мәрҗани шәхесенең руханилар арасында үз заманында иң мәгълүм Һәм бөек ихтирам казанган булуына басым ясый һәм «аның бәйрәмен халык бәйрәме иттерер өчен иң беренче юл була алыр иде» дигән фикерне яза. Ш. Мәрҗанинең эшчәнлегенең асылын мәкалә авторы Исмәгыйль Гаспринский кебек бөек даһиларыбызга «мәдәният вә мәгариф орлыгын чәчәр өчен җирлек – әсас хәзерләп калдыруда» дип бик төгәл билгели һәм руханигалимнең юбилее уңаеннан үткәреләчәк бәйрәм гомумхалык бәйрәме булырга тиеш һәм ул шуңа лаек дигән фикерне үткәрә.

И. Бикколовның бу мәсьәләләрдә шактый эзлекле булуы – Мәрҗани юбилее белән бәйле икенче мәкаләсендә чагылыш таба. «Шималь төрекләренең каһарман [10: 19 гыйнвар] – алда каралган мәкаләдә күтәрелгән мәсьәләнең нәтиҗәсе буларак язылган. Монда автор, шулай ук, юбилее уңаеннан Ш. Мәрҗани шәхесен ачу, аның исемен кабат искә алу, милләт өчен башкарган эшләренә югары бәя бирү юнәлешендә фикер йөртә. Мәкалә авторы Ш. Мәрҗанине яңарыш хәрәкәте башында торган галим буларак бәяли һәм «шушы вакыттан башлап, тик вә тыныч кына яткан шималь төрекләре дөньясы хәрәкәткә килә һәм шушы хәрәкәт насыйры Гаспринский, Баруди вә Бигиләргә нигез хәзерлидер» дип яза. Мәкалә герое итеп алынган шәхес монда Бохарага күз тотып эш иткән татар дөньясын Мисыр, Истанбул тарафларына һәм Рус мәдәнияты вә әдәбиятына юнәлтүче буларак бәяләнә. Ул шималь төрекләре арасындагы фикри вә иҗтимагый инкыйлабны башлап калдыручы кешеләрдәндер. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарларда милли аң, милли әдәбият, милли тел, милли хыяллар белән яшәүче яшьләр җитеште дигән фикер – әлеге мәкаләнең асыл эчтәлеген тәшкил итә. Мәкалә гомерен халкына хезмәт итеп, милли үсеш юлларын билгеләгән хөр фикерле галимнең иң бөек хезмәте – татар тарихына хезмәт итү дип билгеләнә. Фикерен йомгаклап, И. Бикколов: «...шушы бөек шәхеснең туганыннан йөз ел тулган көненең шундый уңайсыз вакытка туры килеп,

кирәгенчә олуглана алмавына соң дәрәҗәдә тәәссеф (кайгыру, ачыну) иттегемне әйтеп үтәмен. Моны шундый бөек адәмнәре булган бәхетле милләтнең иң бөек бәхетсезлеге» дип кабул ителергә хаклыгын билгеләп үтә.

И. Бикколовның үз заманы әдәби барышына багышлап язылган мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Аның 1916 елда «Аң» журналында [11] татар вакытлы матбугатының тууына 10 ел тулу уңае белән дөнья күргән мәкаләләре бу өлкәдәге унъеллык тәҗрибәгә нәтиҗә ясау, йомгаклау рухындагы язмалар. Әлеге мәкаләләрдә автор үткән дистә ел эчендә татар телендә чыга торган һәм чыгудан тукталган газета-журналларга күзәтү ясый, белешмә бирә. Бу факт И. Бикколовның актив хәбәрче, вакытлы матбугат үсешен күзәтеп баручы, нәтиҗәләр ясый алырлык аналитик фикер йөртүче публицист буларак танылу алган булуы хакында сөйли.

Шушы заман татар әдәбиятының йөзен билгеләүчеләрдән Г. Тукайга мөнәсәбәтле мәкаләләре шундыйлардан. «Тукай “Әлислах” идарәсендә» [12: 2 апрель] дигән истәлегендә аның белән 1908 елның беренче яртысында танышуы хакында яза: «Тукай белән «Әл-ислах» идарәсендә таныштым һәм аның белән бик тиз дуслаштык, бергә эшли, бергә яза торган идек». И. Бикколовның Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан караганда шул заманда Томск каласында нәшер ителә башлаган «Сибирия» гәзитендә дөнья күргән «Габдулла әфәнде Тукаев» [13: 7 апрель] мәкаләсе игътибарга лаеклы. Берничә ел Себер якларында мөгаллимлек иткән татар интеллигенты, журналист, әлеге мәкаләдә Тукай үлеме белән бергә татар әдәбиятының зур югалтуы хакында яза: «Хәзер безгә Габдулла әфәнденең Толстой хакында әйтдеке «Тәсбих өзелде» сүзләрен тәкърарлап, Гаяз, Әмирхан, Сәгыйтьләр вә Гафурилар кебек мөхтәрәм затларыбыздан төзелгән тәсбих өзелде, шушы тәсбихнең иң кыйммәтле бер төймәсе дә җиргә төшеп югалды, мәңге табылмаска югалды, диеп тәкъдирнең бу каты золымына баш кына ияргә калды».

Якын дусты, фикердәше Ф. Әмирхан иҗаты, әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге хакында И. Бикколовның берничә мәкаләсе билгеле. «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» [14: 12 март] мәкаләсе гомумиләштерү характерында булуы белән аерылып тора һәм Ф. Әмирханны мәдрәсә елларыннан ук актив җәмәгать эшлеклесе, шәкертләрнең, соңрак татар интеллигенциясенең лидеры буларак таныта. И. Бикколовның 1915 елда «Кояш»та басылган «Татарча театр» [14: 11 февраль] дип аталган мәкаләсе Ф. Әмирханның яңа пьесасы – «Тигезсезләр»нең беренче тапкыр сәхнәдә куелуына мөнәсәбәтле языла. Мәкалә, бер яктан, әсәргә идея-эстетик кыйммәте ягыннан бәя бирергә омтылыш, икенче яктан бу фикернең сәхнәдә актерлар уены аша тормышка ашырылу дәрәҗәсен бәяләү ягыннан якын килгән булуы белән игъибарга лаеклы.

Шул рәвешле, ике гасыр арасы кебек катлаулы чорда үз юлын укытучы эшеннән тыш, журналист, публицист буларак билгеле, шушы юнәлештә шактый күләмле хезмәтләр калдырган Ибраһим Бикколовның XX гасыр башы татар милли хәрәкәтендә, иҗтимагый тормышында, вакытлы матбугат үсешендә тоткан урыны гаять зур, әһәмиятле. Исеме үз заманы татар җәмәгатьчелегенә шактый киң мәгълүм булган укытучы, шул заман әдәби барышының асылын тәшкил иткән әдипләр белән бергә кулына каләм алган, соңрак шәхес культы корбаны булган И. Бикколовның әлеге чор вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күргән публицистик мирасын барлау, аны замана әдәби торышы кысаларында тәфсилләп өйрәнү, һичшиксез, дәвам иттерелергә тиеш.

## ӘДӘБИЯТ

1. Гилазов З.З. Татарская литература начала XX века (в книжных изданиях): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казан, 2003. 24 с.

2. Бертуган Бикколовлар. Әдәби-биографик җыентык / төзүче-авт. Ф. Сәйфуллина, И. Гомәров һ.б. Казан: Җыен, 2016. 448 с.
3. Ибраһимова Ф. Тарих сәхифәләрендә – татар шәхесләре. Ибраһим Бикколов // Казан утлары. 1994. № 6. Б. 188.
4. Ибраһимов Г. Яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. 1915. 29 апрель.
5. Бикколов И. Петербургта мөселман съезды // Аң. 1914. № 13. Б. 250–252; Гомумауропа сугыш алдында // Аң. 1914. № 14. Б. 267–268; Бөтен дөнья сугыш алдында // Аң. 1914. № 15. Б. 285–286.
6. Бикколов И. Үткән 1914 ел // Аң. 1915. № 1. Б. 19–24.
7. Бикколов И. Үткән 1915 ел // Аң. 1916. № 3. Б. 51–54.
8. Бикколов И. Беренче мөгаллим // Кояш. 1914. № 509. 14 сентябрь.
9. Бикколов И. Мәрҗани юбилее мөнәсәбәте илә // Кояш. 1914. № 513. 18 сентябрь.
10. Шималь төрекләренең каһарманы // Кояш. 1915. № 521. 9 гыйнвар.
11. Бикколов И. Вакытлы матбугатымызның әүвәлге ун елы // Аң. 1916. № 1. Б. 1; Русиядә мөселман матбугат мувәкъкате // Аң. 1916. № 1. Б. 14–17.
12. Бикколов И. Тукай «Әл-Ислах» идарәсендә // Ак юл. 1914. 2 апрель (№ 24).
13. Бикколов И. Габдулла әфәнде Тукаев // Сибирия. 1913. 7 апрель (№ 96).
14. Бикколов И. Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан // Кызыл Татарстан. 1926. 12 март (59).
15. Татарча театр // Кояш. 1915. № 627. 11 февраль.

# «ЗУЛЕЙХА» Г. ИСХАКИ НА СЦЕНЕ ТЕАТРА ИМ. Г. КАМАЛА

***А.Р. Салихова*** *(Казань)*

В статье рассматривается спектакль театра им. Г. Камала «Зулейха». Анализируется режиссерское решение. Уделяется внимание актерским работам и музыкальному оформлению.
**Ключевые слова:** театр, музыка, спектакль, Г. Исхаки.

In the article the author considers of performance «Zulaikha» on the scene of G. Kamal Theater. The paper analyzes the director's decision. Author pays attension actor's game and musical accompaniment.
**Key words:** theatre, music, play, G. Ishaki

Начавшиеся в конце 1980-х годов демократические процессы коренным образом изменили культурную ситуацию в обществе. Возрождение интереса к своим истокам, поиски объективности, стремление к восстановлению исторической справедливости характерны для всего советского искусства времен перестройки, в том числе и театра. Возвращались народу забытые имена, запрещенные произведения. Возрос интерес к национальной истории, люди заново открывали для себя многих выдающихся деятелей культуры, их творческое наследие.

После долгого забвения вернулись на подмостки произведения Гаяза Исхаки. Огромная заслуга в этом принадлежит Празату Исанбету. Не побоявшись реальных трудностей, как политического, так и эстетического характера, режиссер одну за другой ставит несколько его пьес: «Зулейха» (1993), «Брачный контракт» (1994), «Жан Баевич» (1995). Наибольший резонанс, безусловно, получила «Зулейха».

Эта пьеса занимает особое место в национальной истории. Ее можно назвать первой татарской трагедией, исторической драмой. Она уникальна своей проблематикой. Пожалуй, ни в одной другой пьесе не поднимаются с такой остротой вопросы национального и религиозного самоопределения. Г. Исхаки начал писать ее в 1907 году в Чистопольской тюрьме, где оказался за участие в революционно-демократическом движении, продолжил уже в Стамбуле,

а завершил в Петербурге в 1912 году. Однако, столкнувшись с цензурой, драма не смогла выйти в свет раньше 1918 года.

Сценическая судьба этого произведения была трудной, короткой и ослепительно яркой. Поставленная в марте 1917 года Г. Кариевым она стала значительным историческим и общественно-политическим событием. Семичасовой спектакль, в котором участвовали около 60 человек, первый в истории татарского театра, для которого специально была написана музыка, никого не оставил равнодушным. За короткое время он был повторен трижды и шел с неизменным успехом. Почти все журналы и газеты Казани откликнулись на данную постановку пространными рецензиями. Мнение было единодушным: «Зулейха» – выдающееся явление художественной жизни татарского народа.

«Зулейха» была поставлена и в Москве, где также заслужила восторженные рецензии не только татарской, но и русской прессы. К сожалению, очень скоро она стала трактоваться как «националистическая», «антирусская», «проповедующая религиозный фанатизм» пьеса и исчезла из театрального репертуара. Последняя ее постановка в нашей стране датируется 1919 годом (режиссер З. Султанов осуществил ее на сцене Астраханского театра). Но и за эти короткие два года «Зулейха» успела стать легендой. Идеи, заложенные в драме, ее глубоко гуманистический пафос оставили в сердцах зрителей глубокий след. Нет народов великих и малых, все народы равны и имеют одинаковое право на счастье и процветание, верность своим святыням и памяти предков. Не насилие, не рознь и вражда должны править миром, а гуманность, добрососедство и взаимоуважение. Не против русских и христианства направлена драма «Зулейха», а против физического и духовного гнета, неравенства, несправедливости.

Возвращение «Зулейхи» на сцену татарского театра ожидалось общественностью в течение нескольких лет и с большим нетерпением. Мало кто отдавал себе отчет в трудности, почти неразрешимости этой задачи. Огромная эстетическая и мировоззренческая пропасть отделяла постсоветского зрителя от пьесы Г. Исхаки. Кроме того, пятиактная хроникальная историческая драма со множеством действующих лиц, массовыми сценами необычайно сложна для сценического воплощения. Откровенная публицистичность, обилие длинных монологов, эпичность и масштабность драмы, где через судьбу отдельной конкретной женщины раскрывается трагедия целого народа, делают это произведение громоздким, предназначенным более для чтения, чем для сцены. Вероятно, этим объяснялся тот факт, что долгое время не находилось режиссера, готового взяться за этот нелегкий материал. Нужно отдать должное мужеству Празата Исанбета, решившегося на постановку, отметив при этом, что и ему не удалось избежать компромисса.

Драма была сокращена почти наполовину, причем в спектакль не вошла самая яркая, насыщенная и важная для автора сцена, несомненно, являвшаяся кульминацией произведения – фантастическая картина явления умирающей Зулейхе ангелов. Глубоко религиозная идея искупления и вознаграждения за страдание и праведность, находившая горячий отклик у мусульман начала века, совершенно не укладывалась в рамки советского театрального и зрительского опыта. Видимо, поэтому она и не попала в спектакль. Для постановочной группы было важным сделать спектакль доступным и понятным. И она достигла этой своей цели, правда, лишив при этом «Зулейху» ее своеобразия и необычности. «Зулейха» в постановке П.Исанбета была максимально приближена к традиционной эстетике татарского театра. Особенно это ощущалось в актерских трактовках.

Прежде всего, в образе главной героини – Зулейхи. Это имя выбрано не случайно. С древнейших времен в исламской поэзии имя Зулейхи является символом незапятнанной чистоты, самоотверженности, духовной красоты. Воспетая многими поэтами, в том числе и великим Кул Гали, для миллионов мусульман она являлась образцом мужества и стойкости, вселяла надежду на божью справедливость и милосердие. Героиня Исхаки, так же как ее прообраз из древней и любимой народом поэмы перенесла нечеловеческие мучения, но искалеченная и обезображенная страданиями сохранила в своей душе свет любви и веры, за что и была вознаграждена. Путь Зулейхи – тяжелый и кровавый путь к истине, путь к единственно возможному, трудному, заслуженному счастью.

Этот во многом символический образ требовал условного, обобщенного решения. Однако, исполнительница Ф. Хайруллина основной акцент делала на бытовой, конкретной стороне роли, создавая яркий, реалистический характер полуграмотной, глубоко религиозной татарки. В результате снижалась высокая патетика образа-символа. Спектакль приобретал некоторый мелодраматический оттенок, а Зулейха порой выглядела забитой деревенской женщиной, которую впору было пожалеть, как жертву собственного невежества и предрассудков.

То же можно сказать и о старике Гимади. Все мы знаем Х. Залялова, замечательного комедийного и жанрового актера, как мастера сочных и остроумных характеристик, знаем тщательность и добросовестность с которой он подходит к любой, даже маленькой роли. Однако на этот раз стремление к правдоподобию, желание реалистически передать одновременно возраст героя, его физическую немощь и душевные страдания неожиданно привели к не совсем неуместному в данном случае комическому эффекту. Думается, что глубоко трагичный по мусульманским понятиям образ святого мученика за веру требовал не столько конкретики; сколько обобщенности и возвышенности.

Традиционно и далеко не в авторском ключе был решен образ попа (исполнитель И. Масгудов). Олицетворяющий черную силу, духовный гнет и насилие над личностью, он должен вызывать ужас своей беспощадностью и всемогуществом. Страшная фигура деспота и мракобеса, облеченного властью отнять у детей мать, у мужа жену, у родителей дочь, обрекающего сотни людей на смерть и пытки, была показана карикатурно, с нарочитой комичностью. Конечно же, в этом проявились определенные советские штампы.

Наиболее близок к эстетике, мироощущению Г. Исхаки был Салимжан в исполнении Г. Каюмова. Нужно отметить, что если Зулейха в результате деформации драмы многое потеряла и в плане развития характера, и в философском содержании, то Салимжан, за счет этого, выдвинулся на первый план, стал проводником авторской концепции. Он проходит тот же путь, что предназначался Зулейхе. От тихого семейного счастья через каторгу и пытки к прощению и блаженству. Сцена гибели Салимжана одна из самых сильных в спектакле. Фантастическая картина явления ангелов Зулейхе, не вошедшая в спектакль, ее высокий гуманистический пафос, звучащая в ней вера в торжество добра и справедливости, неярким, но живым отблеском отразилась в предсмертном монологе Салимжана. Перенесший в жизни нечеловеческие страдания, Салимжан умирает в покое и умиротворении, словно уходя в неведомый прекрасный мир. Авторская идея победы праведности над грехом, тема искупления и вознаграждения нашла свое воплощение в этом коротком эпизоде.

Были обобщено решены и обретали особую значимость два второстепенных персонажа. Это Доносчик (Р. Шамкаев) и Старый мужик (Н. Дунаев). Режиссер и исполнители подчеркнули, выделили заложенную в пьесе идею

достоинства личности независимо от национальности и вероисповедания. Подлость и шкурничество доносчика, который, предавая своих единоверцев в руки попа и жандармов, не стесняется громко именовать себя «истинным мусульманином», противопоставлялись великодушию много повидавшего русского крестьянина. Если Р. Шамкаев не жалел для своего героя сочных сатирических красок, то Н. Дунаев сумел в крошечной роли передать величие простого, нравственного человека, олицетворяющего здравый народный ум, мудрость, терпимость. В его устах убедительно прозвучали слова о том, что нельзя насильно сделать татарина русским, а русского татарином, что каждый должен быть свободен в выборе веры. В этом же ключе играл роль Габдуллы Н. Аюпов, создавая с Н. Дунаевым крупные, почти эпические, народные характеры.

В основном, коллективу театра удалось создать спектакль высокого эмоционального накала, волнующий и одухотворенный. Особенно сильное впечатление производили кульминационные сцены (столкновения крестьян с попом и жандармами, возвращение Зулейхи с помощью Габдуллы в лоно ислама, финал). Именно в эти моменты звучала музыка, приподнимающая действие над обыденностью и бренностью земной жизни, воспринимающаяся как гимн силе и стойкости человеческого духа.

Композитор театра Ф. Абубакиров проделал огромную и кропотливую работу по расшифровке и оркестровке архивных материалов, и зрители услышали оригинальную музыку Султана Габаши, написанную к первой постановке «Зулейхи» в 1916 году. Он проявил незаурядный талант, мастерство и вдумчивость при обработке черновых нотных записей, свыше 70 лет пылившихся в архивах, сумел придать им современное звучание, подчеркнуть драматизм. Торжественная и печальная, затрагивающая потаенные струны души, строгая, величественная мелодия «Кичке Азана» стала лейтмотивом спектакля, во многом определившим его смысл. Пьеса, постановка которой в тогдашней нестабильной ситуации вызывала немало опасений, прозвучала не укором, не обвинением, а поминальной молитвой, данью памяти и благодарности предкам, вопреки жесточайшим преследованиям сумевшим защитить самобытность культуры, веры, и языка, сохраниться как нация.

Спектакль «Зулейха» Татарского государственного академического театра им. Г. Камала вызвал большой общественный резонанс. Он стал важной вехой на пути возвращения татарскому народу его культурного наследия.

ЛИТЕРАТУРА

1. Музыкага салынган пьеса // Аң. 1917. № 2 (15 март).
2. Карам Г. Габдулла Кариев бенефисы // Аң. 1917. № 3–4 (20 апрель).
3. Тюменов Р. «Зөләйха» – Мәскәүдә // Ил.1917. № 20 (10 май).
4. Габяши А.Р. «Зулейха» вернулась? // Известия Татарстана. 1993. 2 февраля.
5. Габяши А.Р. Татарский мир на татарской сцене // Татарский мир. 2002. Сентябрь.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА ДИНИ ЛЕКСИКА

***М.Р. Саттарова, Ф.Х. Габдрахманова*** *(Казан)*

В современном языкознании изучение лексики в целях выяснения ментальных особенностей, специфики культуры носителей языка является одним из актуальных направлений. Внимание исследователей привлекает то, что язык, будучи важнейшим инструментом человеческой деятельности, выполняет аккумулятивную функцию, тем самым является источником информации о культурной деятельности человека. Язык создается и совершенствуется в течение многих веков. Это не только средство общения, но и память народа, его культура и опыт познавательной деятельности, ми-

ровоззрение и психология. Изучая лексический фонд языка, принято распределять его в семантическом аспекте на различные группы. В данной статье анализируются одна из таких групп – лексика духовной культуры татарского языка, зафиксированная в творчестве Гаяза Исхаки.
**Ключевые слова:** татарский язык, духовная культура, Гаяз Исхаки, национальный менталитет, религиозная лексика.

In modern linguistics, the study of vocabulary is one of the modern trends, which makes it possible to explore the mental characteristics, the specifics of the native culture of speakers. The attention of researchers is attracted by the fact that language, being the most important tool of human activity, fulfills the accumulative function, so it is a source of information about the cultural activity of a person. Language is created and improved for many centuries. This is not only a means of communication, but also the memory of the people, its culture and experience of cognitive activity, worldview and psychology. Studying the lexical fund of language, it is customary to distribute it to different semantic groups. In this article, one of these groups is analyzed. It is the vocabulary of the spiritual culture of the Tatar language, recorded in the work of Gayaz Iskhaki.
**Key words:** Tatar language, spiritual culture, Gayaz Ishaki, national mentality, religious vocabulary.

Халыкның милли менталитеты, мәдәнияте үзенчәлекләренең тел материалында чагылышын ачыклау максатыннан телнең сүзлек байлыгын өйрәнү хәзерге лингвистиканың актуаль мәсьәләләреннән санала. Телнең аралашу чарасы булып кына калмыйча, кешенең рухи һәм матди мәдәнияте белән бәйле эшчәнлеге турында күзаллаулар һәм тәҗрибәсе туплана торган мәгълүмат чыганагы булу галимнәрнең игътибарын җәеп итә. Тел гасырлар дәвамында формалаша һәм камилләшә торган күренеш. Тел – аралашу чарасы гына түгел, ул халык хәтере, аның мәдәнияте, танып белү эшчәнлеге һәм психологиясен чагылдыра торган күренеш. Телнең сүзлек байлыгын төрле тематик төркемнәргә бүлеп өйрәнү кабул ителгән. Әлеге мәкаләдә шундый трөкемнәрнең берсе – татар халкының рухи мәдәнияте белән бәйле лексиканың Гаяз Исхакый иҗатында кулланылышы тасвирлана.

Рухи мәдәният дигән вакытта рухи иҗат һәм шул иҗат нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән кыйммәтләр – кагыйдәләр, кануннар, символлар, мифлар, гореф-гадәтләр, дин, әхлак һ.б. күз алдында тотыла [4: 166]. Рухи мәдәният кебек, аны белдергән төшенчәләр дә бик киң кырлы. Рухи мәдәният лексикасын өйрәнү аша халыкның фикерләү, дөньяга карашы үзенчәлеген ачыклыйбыз. Хәзерге заманда фәнни, иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи күзаллау белән беррәттән дини күзаллау да аерып карала. Җәмгыять һәм кеше үсешенә йогынты ясый торган күренеш буларак, дини күзаллауның дөньяны танып белүдә үз урыны бар.

Г. Исхакый XIX–XX гасырлар чигендә яшәп иҗат иткән мәгърифәтче әдип иҗатында еш кына рухи мәдәният белән бәйле мәсьәләләргә мөрәҗәгать итә. Аның игътибары мәгърифәтлелек, хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны һ.б. кебек җитди сорауларга юнәлдерелгән. Замандашлары арасында Г. Исхакый үз иҗатында дини тәрбиягә зур игътибар бирүе белән аерылып тора. Автор әсәрләрен дини тәрбия яссылыгыннан анализлау татар халкының шул чордагы дини яшәешен күзалларга мөмкинлек бирә.

Г. Исхакыйның «Остазбикә» (1910), «Тормышмы бу?» (1911), «Кияү» (1912), «Зөләйха» (1912) һ.б. әсәрләрендә йөздән артык дини эчтәлекле лексика кулланылган. Әлеге әсәрләрдән тасвирлана торган тематик төркемгә караган сүзләр мәгънәгә бәйле турыдан-туры сайлап алынды. Билгеле булганча, дини күзаллаулар нигезендә тормыш икегә бүленә: бу дөньядагы һәм теге дөньядагы тормыш. Әлеге күзаллауларны истә тоткан хәлдә, автор иҗатында кулланылган дини эчтәлеккә ия сүзләр түбәндәге тематик төркемнәргә берләштерелде:

1. Теге дөнья белән бәйле төшенчәләр:

1) Аллаһ Тәгаләне белдерә торган сүзләр: *Алла, Раббе, Ходай*. Мәсәлән, ***Алла*** *һәр эшне күрә...* («Зөләйха», 541 б.). ***Ярабби****, үзең ярлыка!* («Алдым-бирдем», 349 б.). *Безгә дә* ***Ходай*** *анларныкыча тәкъдир иткән булсачы!* («Тормышмы бу?», 50 б.);

2) Аллаһ Тәгалә булдырган төрле көчләр: *Әҗәл (үлем, вафат булу, үлем фәрештәсе мәгънәсендә кулланыла), Газраил, Җәбраил, иблис, пәри, фәрештә, шайтан* һ.б. *Мәсәлән,* ***Әҗәлгә*** *сабырлык бир...* («Зөләйха», 562 б.). *...****Газраилга*** *сабырлык бир, диеп ялварам* («Зөләйха», 523 б.). *...****Җәбраил*** *фәрештә белән...* («Зөләйха», 570 с.) һ.б.;

3) теге дөнья күренешләрен белдергән сүзләр: *ахирәт, җәннәт, җәһәннәм, кыямәт, оҗмах, тәмуг, фирдәүс*. Мәсәлән, ***Ахирәт*** *мәңгелек* («Зөләйха», 526 б.). *...күңелеңдә* ***җәһәннәм*** *утыннан кызу кайгылар булса да...* («Зиндан», 64б.). *Алай гына ярамый бит,* ***кыямәт*** *бар* («Тормышмы бу?», 37 б.);

4) дини тәгълимат белән бәйле төп төшенчәләр: *амин, Аллага шөкер, бисмилла, гөнаһ, дин, җомга (җомга көн, җомга намазы), иман, иншалла, тәкъдир, тәүбә* һ.б. Мәсәлән, *Ни уйласаң да, кызлар берлә уйнау бит* ***гөнаһ*** *инде!* («Тормышмы бу?», 38 б.). *...****тәүбә*** *кылып бетерергә юл күрсәт!* («Зөләйха», 569 б.).

2. Дини йолалар, бәйрәмнәр атамалары:

1) намаз, дога, гыйбадәтне белдергә сүзләр: *ахшам, вәгазь, дога, икенде, намаз, өйлә намазы, ният, ураза* һ.б. Мәсәлән, *Эш юктан, ичмасам,* ***намаз****га барып килим.* («Тормышмы бу?», 36 б.);

2) дини гореф-гадәтләрне белдергән сүзләр: *авыз ачу, җеназа, никах, сөннәт* һ.б. Мәсәлән*, Иртәгесен Сәлим хаҗи килеп* ***никях*** *та укыткannar* («Алдым-бирдем», 317 б.);

3) календарь белән бәйле атамалар: *рамазан (ай календаре белән тугызынчы ай), рәҗәп (ай календаре белән җиденче ай), шәгъбан (ай календаре белән сигезенче ай)* һ.б. Мәсәлән, *Өч ел рәҗәб,* ***шәгъбан рузасы****н тотарга вәгъдә бирде* («Остазбикә», 290 б.);

4) бәйрәм атамалары: *гарәфә көн (Корбан гаете алдындагы көн, Гарәфә тавында басып тора торган көн буларак та атала), Кадер киче, Корбан гаете*. Мәсәлән, ***Корбан гаете*** *җитәр алдыннан без начальниктан гает өчен мәчеткә чыгарырга сорадык* («Зиндан», 55 б.).

3. Дингә мөнәсәбәте булган кешеләрне, төрле предметларны белдергән төшенчәләр:

1) кешеләр: *абыстай (хәзрәтнең хатыны, кызлар укытучысы), имам, ишан, мәзин, мөселман, мулла, пәйгамбәр, сөннәтче, хаҗи (хаҗга барган кеше), хәзрәт* һ.б. Мәсәлән, *Шәрифә* ***абыстай****лар берлә чәй эчтем* («Тормышмы бу?» 37 б.). *Сөешү* ***пәйгамбәрләр****дән калган!* («Алдым-бирдем», 384 б.);

2) дини китап, текстларны белдергән сүзләр: *аять, догалык, Коръән, Фатиха (Коръән сурәсе), хәдис, Ясин (Коръән сурәсе)* һ.б. Мәсәлән, *...Мулламорад бабайның чишмәсеннән алып кайткан су белән тәһарәтләнеп* ***Коръән чыктылар*** («Остазбикә», 292 б.);

3) дингә мөнәсәбәтле булган корылма, урыннарны белдергән сүзләр: *мәдрәсә, мәхәллә, мәчет, михраб* һ.б. Мәсәлән, *Мин* ***мәдрәсә****дә укыганда ул зур шәкерт иде* («Остазбикә», 315 б.);

4) дини ритуаллар, гореф-гадәтләргә бәйле кулланыла торган предмет, кием һ.б. атамалары: *гүр садакасы (мәрхүмнең гөнаһларын кичерелүне сорап бирелә торган садака), зәкят (керемнең кырыктан бер өлешен тәшкил итә торган садака), кәләпүш, комган, намазлык, тәсбих, чалма* һ.б. Мәсәлән, *Абыс-*

*тай: «**Зәкят** бирергә кирәк иде», – ди* («Алдым-бирдем», 318 б.). *...баш кодага* ***намазлык**, каен анага намазлык, ...* («Кияү», 236 б.).

Тасвирланган материаллардан аңлашылганча, Гаяз Исхакый мөселман татарларның яшәү мохитен белеп, бөтен нечкәлекләре белән тасвирлаган. Аның мөһаҗирлеккә кадәрге чор иҗаты бу күзлектән караганда аеруча бай һәм кызыклы. Арада иң еш кулланылган берәмлекләр булып *Аллаһ, намаз, дога, Коръән* сүзләре тора. Бу исә үз чиратында әлеге төшенчәләрнең татарлар өчен гадәти, көндәлек булуын раслый. Моңа дәлил итеп шул сүзләрнең *Ходай, Тәңре, өйлә намазы, икенде* һ.б. кебек синонимнарының да актив кулланылуын әйтергә кирәк. Гомумән алганда, Гаяз Исхакый әсәрләре үрнәгендә татар классик әдәбиятында теркәлгән дини эчтәлекле лексика халыкның рухи мәдәнияте торышы турында фикер йөртергә, аның әһәмиятен аңларга, хәзерге көн белән чагыштырганда телнең лексик байлыгы үсешен күзалларга ярдәм итә.

ӘДӘБИЯТ


1. Исхакый Гаяз. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.
2. Исхакый Гаяз. Сайланма әсәрләр: 15 томда. 5 том. Казан: Хәтер, 2002. 480 б.
3. Исхакый Гаяз. Әсәрләр: 15 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.
4. Нурмухаметова Р.С. Лексика материальной и духовной культуры татарского языка // Вестник ТГГПУ. 2011. № 1 (23). С. 165–169.


## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫШТЫРУЛАР


***Э.И. Сафина*** *(Казан)*



Статья посвящена описанию предмета сравнения в прозе Гаяза Исхаки. Анализ исследуемого материала показал разнообразие сравнительных оборотов в его творчестве. Их использование позволяет писателю изобразить мир в различных его проявлениях, донести читателю настроение героя, обстановку, в которой он находится. Использование тропов характеризует выразительность творчества писателя. Сравнение используется Г. Исхаки в описании окружающего мира, в речи героев, сравниваются лица, внешность, предметы, действия и ситуации.


**Ключевые слова:** сравнение, троп, образ сравнения, модель, сравнительная конструкция, контекст, ассоциативный признак.



The article is devoted to the description of comparison in the prose of GhayazIshaki. The analysis of the language material showed a variety of comparative constructions in his literary works. Their use lets the writer portray the world in its various manifestations, convey to the reader the mood of the hero, the environment he belongs to The use of tropes characterizes the expressiveness of the writer’s works. Comparison is used by G. Ishaki in the description of the world, in the speech of the characters, while comparing the faces, looks, objects, actions and situations.


**Key words:** comparison, trope, the image of comparison, model, comparative construction, context, associative feature.


Гаяз Исхакый әсәрләре иң элек кызыклы, үзенчәлекле чагыштырулары белән игътибарны җәлеп итә. *Чагыштыру* тропларның иң гади һәм иң таралган төрләренең берсе буларак, нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы [1: 191]. Алар автор сурәтләгән предметны, хәрәкәтне, билгене, халәтне күз алдына җанлырак, тагын да калкурак һәм игътибарны үзенә тартып тора торган итеп китереп бастыра. Язучы чагыштырулар аркылы тирә-юньгә, җәмгыятьтәге күренешләргә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Шул ук вакытта, чагыштырулар язучының стилен баета, образлы, җанлы картина тудыруга булышлык итә. Уңышлы чагыштыруның

мөһим билгеләреннән берсе булып яңалык элементы тора. Бу язучының фантазиясе, уйлап табу осталыгы белән бәйле.

Г. Исхакый чагыштыруларны бик яратып һәм күп кулланган. *Гөл чәчәге төсле бит, фәрештә кебек кыз, тулган ай кеби, оҗмахтагы кебек, җәһәннәмдәге кебек* һ.б.ш. башка авторлар тарафыннан да еш кулланыла торган чагыштырулардан тыш, авторның үзенә генә хас образлы сурәтләре дә бик күп. Мисал өчен: *«Менә тутырган тавык: ул, туп эченә тутырып, дошман гаскәренә атып, аның крепостене ватарга ясаган кеби катырылган; киселгәч, йомыркалар беләү кеби ялтырап торалар; тозлылыгыннан авызга кабарлык түгел»; ...«Английский пыяла»дан ясалган кеби ялтырый торган тәрилкәләр уңмаган хатынның алъяпкычы төсенә керде. Әби заманасыннан йөзендә аллы-гөлле кояш уйный торган самовыры казан төбе кеби катты. Чынаякларның тоткалары, чәйнекнең капкачлары маңка малайның борыны төсле булды»* («Сөннәтче бабай»); *«Зур урамга чыга торган урамнардан чиләктән актарылган бәрәңге кебек, төрле төстәге, төрле киемдәге кешеләр агып торганга, зур урамның йөрүчеләре күбәйгәннән-күбәя бара»* («Солдат»). Оригиналь чагыштырулар куллану, билгеле инде, язучыдан күп эзләнү, предмет, вакыйга, күренешләрнең серен, үзенчәлекләрен, гомумән, дөньяны яхшы белүне сорый.

Г. Исхакый әсәрләрендә чагыштырулар түбәндәге очракларда актив кулланыла:

**1. Кешеләрнең тышкы кыяфәтен, буй-сынын, йөзен һ.б. сурәтләгәндә.** Мәсәлән, *«Ул аның озын керфекләренең күзене нурландырып торуыны, битенең уртасының аз гына эчкә таба уелып керүене, калфак астында чем-кара саченең кара урмандагы җансыз күл кеби томрап торуыны карарга тотынды»* («Кӧтелгән бикәч»); *«Йөзе балавыздан ясалган кебек ап-ак»* («Остазбикә»); *«энҗе кебек ялтырап торган теш»* («Тәгаллемдә сәгадәт...»), *«гөл чәчәге төсле битләр»* («Бай угълы») һ.б.

**2. Кешеләрнең халәтен, хис-кичерешләрен сурәтләгәндә:** *«Ул, үзенең суга батып үлә торган баласын судан тартып чыгарган кеше кебек шатланып, кагазь савыт берлә сабынны карарга тотынды»* («Солдат»); *«Ул, бер күрше малаенда күргән уенчыкны аталарыннан таптыра торган тирес бала кеби, шул уе берлән бөтенләй томаланды»* («Сөннәтче бабай»); *«Ул, аяк баскан йире тайган кеше кеби булып, аптырап калды»* («Кияү»); *«Садыйк та, авырлыгыннан башын күтәрә алмаган кебек, башын иеп кенә өйгә керде»* («Солдат»); *«Хәлим, кыз катына барган егет кеби, рәтләп чәй дә эчә алмады»* («Мулла бабай»); *«Ул, үзенең дошманын җиңгән солдат кебек елмаеп, аның тишекләреннән аккан судан, аның эчендә шылтырый торган былчырактан көлә башлады»* («Калуш»).

**3. Төрле предметларны сурәтләгәндә:** *«Аның саурысы синең апаңның намазлык чигә торган үрнәге кебек чәчәкле була»* («Кәҗүл читек»); *«...өстәл чаклы берничә зур китапны ачып куеп, китап карый торган Галиәкбәр хәлфә анларның күз алдыларына килеп басты»* («Мулла бабай»); *«тегермән кеби мендәрләр»* («Мулла бабай»); *«энҗе кебек гөлләр»* («Тәгаллемдә сәгадәт»).

**4. Төрле күренешләрне, вакыйгаларны, вакытны һ.б. сурәтләгәндә:** *«Чебен уты кебек кенә яктылык»* («Солдат»); *«кырмыска оясы кеби кеше кайный торган Печән базары»* («Мулла бабай»); *«Татар тормышы өстендә аллы-кызыллы кояш уйнаганчыга кадәр, татарның тупас, дорфа тормышы гөлле чәчәкләр, бизәкләр берлән бизәлгәнгә кадәр, татар тормышы эчендә кайный торган әчетке кабарып йитеп, татар тормышы савытының бөтен тирәсеннән ташып чыгып, Идел буйлап агып киткәнче, Урал тауларыны үтеп китеп, Кашгар чикләренә барып йиткәнчегә кадәр язам»* («Бер тоткарның саташуы»).

**5. Тирә-юньне, табигатьне сурәтләгәндә:** *«Таза егет кебек билен бөкмәенчә тора торган нараты, суыктан куркудан йирдән башлап ук боталарга чормалган чыршысы, кып-кызыл миләш тамчылары берлән бизәнеп, кырык итәкле күлмәк кигән авыл кызы кебек, тармаклары берлән дөньяга җәелгән миләше...»* («Ул әле өйләнмәгән иде»); *«Аның өенең алдында, юкә агачлар берлән бастырып тоттырган кечкенә бакча да, бер караганда, һаваланганнан күкрәгене чыгарып, кукраеп тора кеби, бер караганда, картайганнан арып, билене тота алмаенча, бөкрәеп тора торган кеби күренә торган миләш агачы да бар иде»* («Сөннәтче бабай»); *«Ник соң ул бүлмәсенә Анна Васильевна кебек ун тәңкә түгел, унсигезне түләсә дә, эт абзары кебек күренә»* («Ул әле өйләнмәгән иде»).

**6. Хәрәкәтне, тизлекне сурәтләгәндә**: *«Яшьләрне дә мәдрәсәнең өметсезлегеннән әрчегән, пакьләгән кебек булды, һәммәсе куян балалары кеби сикерешергә, этешергә тотындылар»* («Мулла бабай»); *«...Хәлим, яңадан уянган кеби бөтен үткән вакыйгаларны күз алдына китереп, яшен уты кеби, сәндерәдән сикереп төште»* («Мулла бабай»); *«Үзе акыртын гына торып китеп, зур таз алдында һаваланып кына, иренеп кенә, ашап туйгач юына торган үрдәк кеби генә, йылы су белән юынырга, тәһарәт алырга тотынды»* («Мулла бабай»).

Чагыштыру – ул бер күренешне икенче предметка яки нәрсәгәдер охшатып сурәтләү, дидек. Тиңләү өчен гадәттә үтә таныш, барлык укучыларга да билгеле әйбер алына. Г. Исхакый предметларны тышкы билгесе, эчке халәте, хәрәкәте буенча чагыштырганда күбрәк форма һәм тышкы охшашлыкка мөрәҗәгать итә. Ә чагыштыру объекты буларак ул гадәттә хайваннарны, үсемлекләрне, төрле предметларны, күренешләрне һ.б. кулланган. Аларны берничә төркемгә аерып карарга була. Мисал өчен:

**1. Чагыштыру объекты сыйфатында үсемлекләр**: *«Бәхетсез кызның гөл чәчәге төсле битләреннән мөлдер-мөлдер яшь ага иде»* («Бай угълы»); *«эт эчәгесе кеби Хәлимне урап алган тормышның ваклыклары»* («Мулла бабай»); *«Зур урамга чыга торган урамнардан чиләктән актарган бәрәңге кебек, төрле төстәге, төрле киемдәге кешеләр агып торганга, зур урамның йөрүчеләре күбәйгәннән-күбәя бара»* («Солдат») һ.б.

**2. Хайваннар дөньясы:** *«Ул бер-бер әйбер алыр өчен селкендеме, аның артындагы озын чәч такмасы, аларга тагылган зур чулпылар, кыңгыраулы тайлар җыелган кебек, шылдырау тавышлары чыгаралар»* («Остазбикә»); *«Җәй буе Урал буенда эт туе кебек халык арасында гомерен үткәрде»* («Кәләпүшче кыз»); *«Хәерчене урынтын тешләргә теләгән эт кеби, үзе Шәрәфигә каты сүз әйтергә, каты мөгаләмә кылырга хәзерләнә башлады»* («Кияү»); *«Ул, оясыны былчыраткан каз кеби, иртәдән кичкә кадәр өенә керергә курыккан кеби, өе тирәсендә әйләнә башлады»* («Сөннәтче бабай»); *«Тәне җылан тәне кеби бер җыелырга, бер сузылырга башлады»* («Мулла бабай»).

**3. Табигать күренешләре:** *«Мәдрәсә язгы җылыда ягъмурдан соң кычкыра торган бакалы күлгә, яисә көтүче яллый торган җыен өенә әверелде»* («Мулла бабай»); *«Шәкертләр, язгы кар кеби, әллә кая эри башладылар»* («Мулла бабай»); *«уйларым, диңгез дулкыны кеби, берсенә-берсе кушылды»* («Очрашу яки Гөлгыйзар»); *«буасын ерып киткән су кеби»* («Мулла бабай»).

4. **Тормыш-көнкүреш предметлары:** *«Кулларының саргайган тиреләре өстендә берсеннән-берсе киң, әллә ничәшәр беләзекләр аның кулларын сынганнан калайланган чәйнек борыны кебек иттереп күрсәтәләр»* («Остазбикә»); *«Ике атна вакыт үтмәде, Гөлйөзем әбинең тарихы онытылган көннән бирле керткән тәртипләре бозылды. Аның заманасында сары гәрәбә кеби ялтырый торган идәннәр мәдрәсә әчелеге хәлене алды»* («Сөннәтче бабай»); *«Саҗидә,*

*почта юлаучы атларының кыңгыравы кадәр зур чулпысыны чылтыратып, исле сабын белән кул юарга чыгып китте»* («Кияү»).

5. **Күк җисемнәре:** Халкыбыз элек-электән хатын-кызларның матурлыгын сурәтләгәндә ай, кояш, йолдыз сүзләрен яратып куллана. Г. Исхакыйда, мәсәлән, *«яңа туган ай төсле каш»* («Теләнче кызы»); *«төскә-башка тулган ай кеби»*(«Мулла бабай»); *«Озак үтмәде, ай кеби ялтырап, минем каршыма Гөлгыйзар килеп чыкты»* («Очрашу яки Гөлгыйзар») һ.б.

6. **Тавышка охшатып чагыштыру:** *«Бик нечкә тавыш белән җылаган балалар кеби көмеш телле кубызлар иске көйләрне җырлый башлады»* («Мулла бабай»); *«Кунаклар, аларның балалары берлә шау итеп, куәтле умарта кеби гөрләп тора торган өй тынланды, моңланды»* («Тормышмы бу?»); *«тегермәннең картлар ыңгырашуы кеби чыгырдавы»* («Мулла бабай»).

7. **Дин белән бәйләнешле чагыштырулар**: *«Оҗмах ишеге ачылган кеби, кая барасыны белмәде»* («Мулла бабай»); *«мәдрәсә аның күз алдында оҗмах кеби күренә башлады»* («Мулла бабай»); *«Әҗәл тагарагы кеби көймәләр»* («Очрашу яки Гөлгыйзар»); *«фәрештә төсле пакь ятимә бала»* («Кәләпүшче кыз»); *«фәрештә төсле матур Зөһрә»* («Мулла бабай»); *«Аның аягы үзен оҗмахта кебек хис итте»; «Аягы үзен җәһәннәмдә кебек күрде»* («Калуш»); *«Анларны, әллә нинди, мәдрәсәгә бер дә охшамаган, шатлыклы, кәефле оҗмах кеби хыял дөньясына алып китте»* («Мулла бабай»).

Мисаллардан күренгәнчә, чагыштыруларда автор чынбарлыкны үз күзлегеннән чыгып чагылдыра. Чөнки һәрбер язучы яки шагыйрь, аерым шәхес буларак, үзенчә фикер йөртә, дөньяны үзенчә күзаллый.

Сурәтләү чараларының ясалышына игътибар итсәк, Г. Исхакый прозасында кулланылган чагыштыруларның бәйлекләр ярдәмендә ясалуы (*«ай төсле каш»; «төскә-башка тулган ай кеби»*) күренә. Моннан тыш, чагыштыру үзе бер иярчен җөмлә булып килергә дә мөмкин. Бу очракта да ул баш җөмләгә чагыштыру бәйлеге (*кеби, төсле, кебек, кадәр* һ.б.) ярдәмендә бәйләнә. Мисал өчен:

– *кеби, кебек* бәйлеге белән ясалган чагыштырулар: *«Садыйк та, авырлыгыннан башын күтәрә алмаган кеше кебек, башын иеп кенә өйгә керде»* («Солдат»);

– *төсле* бәйлеге белән ясалган чагыштырулар: *«Камәр кебек матур кызны, фәрештә төсле пакь гыйффәтле ятимә баланы, алдап-йолдап әрәм итеп ташларга теләү»* («Кәләпүшче кыз»);

– *кадәр* бәйлеге белән ясалган чагыштырулар: *«тау кадәр хәсрәтләр»* («Кәләпүшче кыз»).

Бер сурәтләү объектын ачыклап-сыйфатлап килгән чагыштырулар *гади* (*ай кеби*, *фәрештә кебек*), чагыштырыла торган күренешләрнең мөстәкыйль образлар аша сыйфатлануына корылган чагыштырулар *җәенке (киңәйтелгән)* [1: 192] дип атала (*«Ул тәмам китәргә уйлап бетергәндә, тормыш аны ныграк бәйләргә тырышкан кеби, аның хәзерге шул икеләнүне белеп, аны урынлаштыру өчен зуррак якорене салган кеби, Зөһрәне балага авыртты»* «Мулла бабай»).

Чагыштырулардан тыш, Г. Исхакый әсәрләрен образлы итүдә эпитет (*шәфкатьсез ягъмур, көлемсерәп торган кояш* һ.б.) һәм метафораларның (*кояш йылысы үпте, кочты, сөйде* һ.б.), фразеологик әйтелмәләрнең (*җанны кыйнау, исеме-чабы китү, су кебек эчү*) дә әһәмияте зур. Авторның метафораларында да хис-тойгы, эмоциональлек өстенлек итә. Мисал өчен, *«таш йөрәк түгел»* («Очрашу яки Гөлгыйзар»), *«йөрәк яну»* («Кәләпүшче кыз»), *«баш вату»* («Солдат»), *«тормыш тупасланды»* («Мулла бабай»), *«күз яшен буу»* («Солдат») һ.б. Урынлы кулланылган мәкаль-әйтемнәр Г. Исхакый әсәрләренең халыкчанлыгын арттыра, сурәтләрне тагын да камилрәк итә: *«Бер тиен куян,*

*ун тиен зыян», «Ашыккан ашка батар», «Анасына карап кызын ал»* («Мулла бабай»); *«Эзләгән эз табар», «Ятып калганчы атып кал», «Яхшылыкка каршы яхшылык»* («Бай угълы»).

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: бик көчле стилистик чара буларак, Г. Исхакый әсәрләрендә чагыштырулар аерым урын алып тора. Язучы чагыштыруларга табигать күренешләрен, вакыйгаларны, кешеләрнең йөз-кыяфәтен, рухи дөньясын сурәтләгәндә мөрәҗәгать итә. Текстта чагыштырулар төрле эпитетлар белән баетылып, эмоциональ фонны тагын да көчәйтәләр, язучының стилен баеталар һәм әсәрләренең образлылыгын арттыралар.

ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.
2. Губайдуллина Г.Ф. Языковые и стилистические особенности ранней художественной прозы Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук.Казань, 2008. 26 с.
3. Исмагилова Г.К. Лексика романов Гаяза Исхаки «Нищенка», «Мулла бабай»: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 23 с.
4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.
6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 448 б.
7. Сафиуллина Ф.С. Исхакыйның хикәяләү осталыгы // Г. Исхакый һәм татар дөньясы. Казан: Фикер. 2000. Б. 229–256.
8. Татар лексикологиясе: Өч томда. 1 том / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. 352 б.


## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ *-ЛЫ/-ЛЕ* ҺӘМ *-СЫЗ/-СЕЗ* КУШЫМЧАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ


***Р.К. Сәгъдиева, Д.Х. Хөснетдинов*** *(Казан)*



В произведениях Гаяза Исхаки поднимаются проблемы актуальные даже по сей день. Его творчество, особенности произведений вызывают особый интерес среди ученых. Творчество писателя анализируются с разных сторон. Изучение стилистически-языковых особенностей автора помогает сделать интересные выводы. В этой статье идет речь об употреблении Гаязом Исхаки аффиксов *-лы/-ле, -сыз/-сез.*



**Ключевые слова:** аффиксы, смысловые отношения, словосочетания, прилагательное, имя существительное, татарский язык.



The works of Gayaz Iskhaki raise problems of topicality even to this day. His work, features of the works are of special interest among scientists. Creativity of the writer is analyzed from different sides. Studying the stylistic-linguistic features of the author helps to draw interesting conclusions. In this article we are talking about the use of the affixes by Gayz Iskhaki *-le, -sez.*



**Key words:** affixes, semantic relations, word-combinations, adjective, noun, Tatar language.


*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары үзара антоним булып торалар. *-лы/-ле* кушымчасы нәрсәнеңдер кайда да булса булуын белдерә: *рәсемле китап*, *паласлы идән*, *көчле егет*... *-сыз/-сез* кушымчасы нәрсәнеңдер кайда да булса булмавын аңлата: *рәсемсез китап*, *палассыз идән*, *көчсез егет*.

*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары рус теленә сыйфат формасы белән генә түгел, ә сүзләрне бәйли торган чара буларак та (предлог белән) тәрҗемә ителә. Аларның сыйфат формасы белән тәрҗемә ителә алулары, әлеге кушымчалы сүзләрнең җөмләдә аергыч булып килүләре *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез*кушымчаларын сыйфат ясагыч кушымча дип тануга нигез булган. Һәм, гомумән алганда, тел белемендә, иң беренче чиратта, *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчаларының сүз ясагыч функциясенә игътибар бирелә. Ләкин алар сүз төрләндергеч

функциясенә дә ия. Чөнки, беренчедән, ул кушымчалар күп очракта сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртмиләр. Икенчедән, алар, башка сүз төрләндергеч формалар кебек үк, теләсә нинди исемгә ялгана алалар. Өченчедән, *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалы сүзләр сөйләмгә әзер лексик берәмлек буларак үтеп кермиләр. Сүзләр бу кушымчаларны сөйләм процессында башка сүзләр белән бәйләнешкә керү өчен алалар. Шулай итеп, *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары сүз төрләндергеч чараларга тулысынча җавап бирә.

*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары күп кенә телчеләр тарафыннан да сүзләрне бәйләүче чара буларак танылганнар. Мәсәлән, Г. Фәезханов, Һ. Максуди, Г. Чыгтай. А.Н. Баскаков та әлеге фикердә тора. Ул аларны исемнәрнең аергыч формасы итеп карый. И. Гиганов, А. Троянский, М. Мәхмүтов, К. Насыйри, Ш. Иманаев кебек авторлар *-сыз/-сез* кушымчасын, үзенең антоним парыннан башка гына, бәйлек буларак кабул итәләр [5: 71].

Проф. В.М. Насилов, *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчаларының сүз ясагыч та, сүз төрләндергеч тә булуларын танып, аларны тоташтыру кушымчалары («аффиксы включения») дип атый [4: 32–35].

Г.И. Рамстедт, М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, Р.Ф. Зарипов, Л.С. Левитская кебек галимнәр *-лы/-ле* кушымчасын барлык килеше формасы дип, *-сыз/-сез* кушымчасын юклык килеше күрсәткече икәнен искәртәләр [5: 72].

Хәзерге татар тел белемендә телчеләр *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчаларының грамматик мәгънәләренә, ягъни исемнәрне һәм исем белән фигыльне бәйләүләренә, әйберне бәяләү, эш-хәрәкәтнең үтәлү коралын, вакытын кебек төсмерләрне белдерүләренә зур игътибар итәләр. Г.Х. Ахунҗанов, әлеге кушымчаларны өйрәнеп, аларның мәгънә төсмерләрен җентекләп ачыклап чыккан [1: 3–29]. М.З. Зәкиев *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчасы ярдәмендә башка сүз төркемнәре: исемнәр, шулай ук исем фигыль яисә сыйфат белән исем арасында да сүзтезмә оешуын мисаллар белән дәлилләп уза [6: 122–144].

*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары, бер яктан, сүз ясагыч кушымча буларак, исемнәр яки сыйфатлар ясыйлар, икенче яктан, грамматик мәгънә белдереп, сүзләрне башка лексик-грамматик берәмлекләргә бәйлиләр. «Бу ике функция арасында кискен чик куярга ярамый, кушымчаларның берьюлы ике төрле функция башкара алуын да танырга кирәк. Кайвакыт бу ике функция берләшә ала» [3: 27].

*-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчаларының кулланылышында өч төрле очрак бар:

1. Беренче очракта алар сүз ясагыч функциясен генә үтиләр һәм бәйләүче чара да, килеш кушымчасы да булмыйлар, алар ярдәмендә бары исемнәр яки сыйфатлар ясала. Мәсәлән, Г. Исхакый *ташкентлы* дигән исемне кулланган: *Китапта бер **ташкентлы мулла** Габбас дигән кешенең кырык газизләр зиярәтене эзләп йөреп, Испаниягә барып чыгып, минем теге Әндәлес тарихында укыган гарәпләрнең калдыкларыннан гизле бер атауда яшәүче мөселман гарәпләргә барып очравыны һәм дә аларның хәзерге тормышларының ничек икәнлегене тасвир иткән* [2: 94]. ***Ташкентлы мулла*** – исемле исем сүзтезмә, иярүче исем ияртүче исемгә лексик мәгънә аша ияргән. Бу очракта *-лы* кушымчасы бәйләүче чара вазифасын башкармый.

Сүзнең нигезе бүгенге көндә инде кулланылмаса, сыйфатлар барлыкка килә: *комсыз*, *сөекле*, *өзлексез*, *ваемсыз*, *җентекле*. Андый төр мисалларны Г. Исхакый әсәрләрендә шактый очратырга мөмкин: *Шуның өчен мин озакламаенча пальтәмне киеп салкын идәнгә яттым һәм дә **татлы-тытлы йокыга** киттем* [2: 33]. *Тагы безгә кичәге **юньсез урыс** кереп кәгазенә өчле цифр куеп чыкты* [2: 53]. *Кыскасы гына, төрмә хәзер элгәреге бертуктамаенча кабәхәт*

*сүзләр ишетелеп тора торган төрле каракларның, кеше үтерүчеләрнең җыелган җирләреннән битәр бер мәктәпнең пансионына яисә студентларның тора торган* ***ярлы номерларына*** *охшый башлады* [2: 70]. *Ләкин төрмә яратылганнан бирле хисаплаганда, төрмәдә ятудан туеп бер кергән кеше, икенче ятудан куркып, үзенең эшли торган эшләреннән тәүбә кылганы, үзенең* ***сөекле хезмәтеннән*** *баш тартканы бер дә юктыр, булса да, бик аздыр* [2: 76]. *Анда бездәге кеби мелт-мелт итеп,* ***ярлы кешене*** *сүнәм-сүнәм дип куркытып торган табагач лампалар урынына һәр өйдә, һәр бүлмәдә әллә нинди матур, пөхтә электрик лампалар төнне кичтән аермаслык иттереп яктырталар* [2: 94]. Бу очракта тогәлләүле мөнәсәбәт сыйфат белән исем арасында барлыкка килә. Монда да иярүче белән ияртүче сүзне бәйләүче чара булып *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары түгел, ә лексик мәгънә була.

2. Икенче очракта бу кушымчалар сүз ясагыч һәм бәйләү функциясен берьюлы үтиләр. Алар, иң элек сүз ясагыч функциясен башкарып, шул ук вакытта бәйләү сәләтләрен дә югалтмаганнар. Мондый мисалларны бер функциядән икенче функциягә күчеш очрагы дип билгеләргә кирәктер. Г. Исхакый әсәрләрендә нәкъ шундый төр, ягъни сыйфат белән исем арасындагы төгәлләүле мөнәсәбәткә мисаллар шактый табып була: *Көнделә әллә нинди* ***ямьсез фикерләр****, караңгы уйлар йөри иде* [2: 33]. *Мин картның шулкадәр* ***гакыллы сүзенә*** *исем китте* [2: 49]. *Вакыйган: бу* ***ике төрле халык*** *арасында никадәр аерма: <...>* [2: 50]. *Аның төрле тарафыннан* ***төрле тавышлар*** *чыга иде* [2: 53]. *Төрмәдә буш камералар булса да, боларны, мичкәгә төягән* ***тозлы кыяр*** *кебек, берсе өстенә берсен төяп, сасыда эштән чыгаралар иде* [2: 54]. *Аларның аны* ***гакылсыз бала*** *кебек итеп, юк сүзләр берлән юаткан булып маташулары аңарга мыскыл иткән кебек тоела иде* [2: 68]. *Хәзер элгәреге* ***мәгънәсез җырлар*** *урынына башка җырларын җырлый башладылар* [2: 70]. *<...> аллы-гөлле төстәге күбәләкләрнең хәтфә кеби йомшак канатлары берлә шул саф һаваны* ***яшелле****,* ***сарылы****,* ***кызыллы****,* ***аллы йолдызлар*** *берлә бизәкләүләре; төрле бал кортларының матур тавыш берлә кызуланып, бер чәчәктән икенче чәчәккә күчеп бал җыюлары – һәммәсе бу көнгә бик зур бәйрәм төсе бирә* [2: 85]. *Хуш, авылның* ***майлы бәлешләре****,* ***тәмле итләре****!* [2: 104]. *Аның хәзер* ***шәфкатьле нуры*** *мәрхәмәтле* [2: 106]. Моннан тыш сыйфат үз формасы аша фигыльләргә дә ияреп килеп, төгәлләүле мөнәсәсәбәт хасил итә: *Боларның әйберләре һәммәсе дә тупас,* ***җансыз****,* ***рухсыз күренәләр иде*** [2: 26]. *<...>* ***тавышсыз*** *гына өч-дүрт малай гына* ***уйнашып маташалар*** [2: 112]. *Аларның ватык-ватык тәрәзәләреннән чыга торган яңа икмәк, май, ит исләре, аларның эчләреннән ишетелә торган* ***куәтле*** *умарта* ***гөрләве*** *кеби көчлелек тавышлары һәммәсе дә беткән* [2: 112]. Мисаллардан күренгәнчә, сыйфатлы исем һәм сыйфатлы фигыль сүзтезмәләре оеша. Бу вакытта бәйләүче чара вазифасын *-лы/-ле*, *-сыз/-сез* кушымчалары үти.

3. Өченче очракта бу кушымчалар, конкрет исемнәргә ялганып, берәр нәрсәгә ия булуны белдерсәләр, бары тик исемнәрне башка сүзләр белән бәйлиләр һәм сүзнең предметлык мәгънәсен үзгәртмиләр. Бу очракта алар нәкъ менә барлык һәм юклык килешләре кушымчалары, бәйләү функциясен үтиләр, ә сыйфат ясамыйлар. Г. Исхакый әсәрләрендә исемле исем сүзтезмәләр дә кулланылган. Автор исемне икенче бер исемгә *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары аша бәйли һәм предметны яисә затны булу-булмау билгесе ягыннан сыйфатлый: *Бу шактый гына зур, ике* ***тәрәзәле*** *бер* ***бүлмә*** *иде* [2: 40]. *Болар арасында унбиш яшьлек малай булган кебек, кырык берлә илле арасындагы* ***йортлы-җирле****,* ***бала-чагалы кешеләр*** *дә бар иде* [2: 54]. *Киленнәр, эшләр беткәч, <...> курыккан кеби генә җылыта торган көзге җылы* ***кояшлы көннәрдә*** *яшел*

*ужым араларыннан үтә торган юллардан <...> дуст-ишкә ашка барып йөрүне уйлыйлар иде* [2: 102].

Г. Исхакый әсәрләрендә *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалары ярдәмендә ясалган катлаулы сүзтезмәләрне дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, бер төркем катлаулы сүзтезмәләр беренче компоненты ялгызлык исем, ә икенчесе *атлы* кебек сүз белән белдерелгән: *Шуның өчен урядниклар баягы **Шәйхи атлы куштанга** килеп, мине бөтенләй каравыллап тора башладылар* [2: 41]. Икенче бер төркем катлаулы сүзтезмәләр сан ярдәмендә барлыкка килгән: *Төрмәнең бинасы соңгы капкадан 10–15 сажин ераклыгында **өч катлы**, акка буялган таш **өйдер*** [2: 51]. *Америка дигән җирдә **егерме җидешәр катлы өйләр** салалар икән* [2: 107].

Телдә катлаулы сүзтезмәләр белән бергә аларга охшаган, ләкин бөтенләй башка тел берәмлеге булган күренешләр дә очрый. *Сары чәчле*, *ак йөзле*, *озын буйлы* кебек берәмлекләр бер сүз итеп каралырга тиеш. Алар – кушма сыйфатлар. Г. Исхакый әсәрләрендә дә бу төр төгәлләүле мөнәсәбәткә кызыклы мисаллар күзгә ташлана: *Үзе ап-ак сакаллы, **киң маңгайлы**, Толстой кыяфәтле җитмеш биш яшьлек бер **карт** иде* [2: 48]. *Чөнки Фуадның авылында бик зур сакаллы, бик **кечкенә башлы** бер **татар** Фуадны сайлатмаенча, үзе сайланасы килгәнгә, халык аны сайламый Фуадны сайлаганга, теге мужик куштаны бик хурланып Фуад өстеннән жалоба биргән* [2: 58]. Әлеге мисалларда сыйфатлы исем сүзтезмәләр *-лы* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән. Бер караганда өч мөстәкыйль мәгънәле сүздән оешкан кебек күренсә дә, алар ике генә компоненттан торалар һәм гади сүзтезмәләр рәтендә тикшерелергә тиешләр.

ӘДӘБИЯТ


1. Ахунзянов Г.Х. Регулярнообразуемые имена прилагательные на -лы // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. Казань, 1988. С. 3–29.

2. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.

3. Кашапов М.Х. Татар теле синтаксисыннан лекцияләр. Казан: Gumanitarya, 2003. 168 б.

4. Насилов В.М. Аффиксы включения // Вопросы языка и литературы стран Востока. М.: Изд-во ИМО, 1958. С. 31–50.

5. Сагдиева Р.К. Аффиксы как средства выражения конкретизирующих отношений в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 164 с.

6. Татарская грамматика: в трех томах. III том. Закиев М.З. Синтаксис. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 576 с.


## Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА КЕШЕНЕҢ ЭЧКЕ КОНФЛИКТЫ


***С.Г. Сәмитова (Казан)***



Г. Исхаки, используя психоанализ, затрагивая глубинные слои человеческой души, умело раскрывает эмоциональные переживания своих героев в произведениях «Ул икеләнә иде» һәм «Ул әле өйләнмәгән иде». Внутренний конфликт, который создает героям невыносимые переживания, построен на борьбе сознания и подсознания, Персоны и Тени, в установлении Самости.



**Ключевые слова:** Творчество Исхаки; внутренний конфликт, сознание, эмоциональные переживания, никах.



G. Iskhaki, using psychoanalysis, and thereby touching the inner layers of the human soul, skillfully reveals the emotional experiences of his characters in his works of “Ul ikelene ide” and “Ul ele ilenmegen ide”. The internal conflict, which creates unbearable emotions for the characters, is built on the struggle of consciousness and subconsciousness, a Person and his Shadow, in the establishment of the Self.



**Key words:** Creativity Ishaki; internal conflict; consciousness; emotional experience; engagement.

Г. Исхакый – рухы белән туган халкына бәйләнгән әдип. Ул үз милләтенең башка халыклар арасында югары дәрәҗәле, хөрмәткә ия халык булуы турында хыяллана. Әдипнең җәмгыять, мәгърифәт, мәдәният, матбугат, әдәбият өлкәсендәге эшчәлеге шул максатка хезмәт итә.

Милләт үсешенең нигезендә гаиләдәге тәрбия ятканлыгын аңлаган әдип, үз вакытында үзенең иҗатында бу мәсьәләгә зур урын бирә. Гаиләнең токкасы хатын-кыз булуын ассызыклап, иҗтимагый тормышта хатын-кызның ролен алгы планга чыгарып, «Ул икеләнә иде» (1915) һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) повестьларын иҗат итә. Хатын-кыз иренең хатыны гына түгел, бәлки милләт язмышын хәл итүче зыялыларны тәрбияләп үстерүче дә. Милләтнең телен, традицияләрен алдагы буыннарга җиткерүчеләр дә алар. Юкка гына татар халкы туган телен «Ана теле» дип атамый. Бу телне, димәк гаиләне дә саклауда ана кешенең төп рольне уйнавын күрсәтә.

Г. Исхакый, алдарак телгә алынган повестьларында, өйләнү төшенчәсенә тирән мәгънә салып, бу әсәрләрдә гаилә, гаиләдә хатын-кызның урыны, катнаш никах мәсьәләләрен күтәрә. Гаилә, дәүләтнең мөстәкыйль бер өлеше буларак, милләт үсешендә хәлиткеч көчкә ия. Кеше бәхетен гаилә бөтенлеге белән бәйләп, ул бу проблеманың шәһәр мохитендә ничек хәл ителүен күрсәтә. Биредә инде кеше милли мохиттә генә калмый, бәлки башка халыкларның яшәү рәвешләре белән очраша, заман цивилизациясе йогынтысына бирелә. Рус культурасының зур шәһәрләрдә көчле булуы башка халыкларның гаилә кору традицияләренә дә йогынтысы ясый. Шунлыктан, катнаш гаилә мәсьәләсе көн тәртибенә куела. Бу мәсьәләгә, әлбәттә, татар зыялылары битараф кала алмый. Г. Баттал татарлар арасында катнаш гаиләләр күбәюне тарихка бәйләп: «Русия инкыйлабыннан соң байтак зыялыларымыз мөселман кызлары арасында үзләренә тиң кызлар тапмадыкларыннан рус, поляк, француз йә яһуди кызлары илә өйләнмәккә башладылар», дип искәрмә биреп үтә [2]. Бу хәлдән котылуның бердәнбер чарасы итеп кызларны да егетләр кебек укытып, белем белән нурландырып, дөнья көтәрлек дәрәҗәгә күтәрүне күрсәтә.

Әсәрләрнең төп каһарманнары Шәмси белән Хәмит рус мәктәпләрендә белем алган, рус мохитендә тәрбияләнгән, абыстай да гына белем алган татар туташларын тиң күрмәгән, тик шулай да үз тамырлырыннан тулысынча өзелмәгән, киләчәктә зыялы ягымлы татар кызы табып өйләнү хакында хыялланучы татар егетләре. Алар икесе дә рус мәдәнияте йогынтысында тәрбияләнгәннәр. Егетләрнең дөньяга карашлары да шул рус җирлегендә, ягъни Петроград шәһәрендә формалаша. Икенче әсәр беренчесенең дәвамы итеп язылa. «Ул икеләнә иде» әсәренең каһарманы Хәмит, укымышлы татар кызына өйләнә алмагач, элеккеге дус кызы Мария Ивановнага өйләнеп, гаилә кору турында хыяллана. Дуслары киңәшен тотып, ул өйләнергә ниятләгәч, башта чибәр генә укымышлы бер татар кызына өйләнмәкче була: «Мәсәлән, ул шул шәһәрнең Фатыйманы алса? Әйе, Фатыйма бунын хатыны булса?,.. Төсе-буе.. Зарарсыз... Әллә Хәдичәме? Хәдичә моның хатыны булып, шулай менә бүген Габдрахманнарда булган кебек, хуҗа булып, кунаклар каршы алырмы?... Бер-бер нәрсә йитмәсә, моның колагына гына әйтеп, акча алып, ябык кибетне ачтырып китерергә асрауны йибәрерме?» [3: 321]. Хәмит дә, ике баласы туганның соңында да, үзен өйләнмәгән итеп хис итеп, һаман да алдагы көндә зирәк татар кызына өйләнү турында өметләнә. Хәмит, шул максаттан чыгып, Сәгыйть дусты сүзенә колак салып, «кием-салым йөртә белүче, йорт тотарга өйрәнгән, уңган, матур» [3: 322] бай кызын карап, танышу йөзеннән шәһәргә китә. Хәмитне үзен зыялы, тәрәккъый санаган, бөтен гомерен мал туплауга багышлаган Садыйк бай бик шатланып каршы ала, хәтта кунакның ни эш белән йөрүен сорап

та тормыйча, кунак итә. Герой бераз югалып кала, сөйләшер сүз таба алмый изалана. Аның күңелендә йөрткән зирәк, укымышлы кыз портреты, Садыйк бай кызы белән аралаша башлауга ук, юкка чыга.

Әлеге әсәрләрендә Г. Исхакый үз чоры татар кызлары белән рус кызлары арасында параллель үткәрә. Әдип ирекле мәхәббәт мәсьәләсенә кагылып үтә, һәм бу күренешнең тумыштан сабыр, инсафлы, итагатьле татар кызларына үтеп кермәгәнлегенә шатлана. Әмма бу артык «тәрбиялелек» белән генә Хәмитнең күңелен яулап булмаганлыкны да ассызыклый. Әдип, дөнья әдәбиятын белгән, билгеле бер мәдәниятле мохиттә тәрбияләнгән рус кызларын, абыстай белеме белән генә чикләнгән татар кызларына капма-каршы куя. Тукайның кем икәнен дә белми торган милли туташлар, әлбәттә рус мәдәнияте, рус мохите тәрбияләгән бу егетнең игътибарына лаек була алмый.

Г. Исхакый, әдәби әсәрләрендә генә түгел, иҗтимагый-сәяси фикерләре, гамәли эшчәнлегендә дә хатын-кыз язмышы мәсьәләсенә үтә игътибарлы. 1917 елның маенда эшләгән Бөтенроссия мөселманнарның беренче корылтаенда Г. Исхакый хатын-кыз мәсьәләсен күтәреп чыга. Ул публицистик эшчәнлегендә дә бу теманы читләтеп үтми: «Хатын-кыз язмышы» [4] исемле мәкалә яза. Татар кызларына исә күптән ирләр белән тигез хокуклы итеп, нигезле белем бирергә кирәк. Алар хәзер Аурупа, рус мәдәниятебелән танышып, төрле кичәләргә йөреп, махсус уку йортларында тәрбияләнә башларга тиеш. Г. Исхакый белемле чибәр рус кызлары белән янәшә куярлык милли туташлар әзерләүнең халык мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүен күрсәтә.

Шулай да XX йөз башында татар әдәбиятында милләт кызларын югары зәвыклы, тәрбияле итеп сурәтләгән әсәрләр юк түгел. Мисалга Ф. Әмирханның «Петербург дарелфөнүненең хокук шөгъбәсен беренче дәрәҗә диплом белән тәмам иткән, Аурупа телләреннән бер-икесендә укый-яза һәм сөйләшә торган Зөләйханы» һәм алдынгы фикерле рус егете Михаилның гыйшкын яулаган зифа буйлы, чибәр, тәрбияле татар кызы Хәятне һәм күрсәтергә мөмкин [1: 344].

Повесть геройларының мөселман туташларына карата шундый ике яклы фикерләр тууының икенче бер сәбәбе – татар хатын-кызларының киенүләре, ата-ана сүзеннән чыкмау, итагатьлек һәм сафлыкны саклап җенси мөнәсәбәтләрне кабул итмәү, ирекле мәхәббәткә каршы булу. Шундый туташларга каршы һәрвакыт матур киенгән, чәчләре ясалган, нәзәкатьле, якын мөнәсәтләргә әзер рус кызлары тора. Шул рәвешле егетләрне, нинди генә кыз белән очрашып карамастан, яшерен «татлы җимеш» тарта. Башта моны: «Мин өйләнмәгән бер егет, ул хөр бер хатын», – дип кабул ителә; бу вакытлыча бер рәхәт кичерү генә, дип өстән генә фикер йөртелә. Хәмит бу хакта: «ул өйләнде ди. Дуст-ише аны тәбрикләп килә. Килмәсә? Бу бит руска өйләнү... Кардәш-кабилә туйга җыела... Нинди туй? Рус белән туй буламыни? Тагы алар берсе дә килмәсә? Килмәсә генә түгел, моның өйләнүене өйләнү дип карамаенча, тик рус белән тору гына, тәүфыйксызлыктан килгән бер бәхетсезлек кенә дип караса?» [3: 320] – дип шөбһәләнә. Шул ук вакытта үз-үзенә каршы килеп: «Аларның алай карарга ни хакы бар! Сөю, мәхәббәт милләтне белми. Аңарга байлык, ярлылык киртә-кальга була алмаган кебек, милләт, дин аермасы да аны тотып кала алмый. Мин сөйгәч, кемнең хакы бар?»

Әлеге юллардан күренгән халәтне психанализга мөрәҗәгать итеп аңлатма биреп карыйк. Әсәрнең атамасына чыккан «Икеләнү» шактый тирән мәгънәгә ия. Икеләнү хисе геройны әсәрнең азагынача ташламый вождан газабы утларында көйдерә. Шәхес мөһим проблема алдында таптала, аны чишү юлларын таба алмый. Мондый уйлар, гадәттә, проблеманың берничә чишелеше булган-

да туа, әмма аларнын һәммәсе дә кешедә эчке курку, шөбһә хисе уята. Кеше куңелендә туган эчке конфликт шәхес өчен бар төр конфликтларга караганда да авыррак. Нилектән шулай булып чыга соң? Икеләнү – ул кеше психиканың сакчысы, бу хис кешене узеннән саклый, һәм ахыр чиктә тиешле, үзе дөрес дип тапкан карарга этәрә. Шул ук вакытта, икеләнү, максатларга ирешү юлында тоткарлап, шәхесне бернигә яраксыз, буш адәм ясый.

Кешенең шулай икеләнүе беренче чиратта аңда ачыкланып җитмәгән томанлы яки инстинктив фикерләр (подсознание) белән бәйле. Инстинктив фикерләр кешегә табигатьтән салына. Әлеге томанлы фикерләрдә дөнья яралганнан бирле яшәп киткән кешелекнең тәҗрибәсе саклана һәм алар уйланылмаган шөгыльләрдән баш тартырттыру өчен аңны уята. Бер сүз белән әйткәндә, бу фикерләр кешегә ярдәм итә, яшәтә.

Хәмит тә, Шәмси дә татарның алдынгы яшьләре, алда әйтеп үткәнчә, чорына күрә укымышлы, зыялы, рус мохитендә яшәүгә карамастан, татар дөньясы белән дә тыгыз бәйләнештә торалар, алдагы көндә татар кызына өйләнеп, акыллы матур балалар табып, аларны милли рухта тәрбияләү утында яналар. Геройларның төрле милли кичәләргә, театрларга, дини бәйрәмнәргә йөрүе, нәсел-нәсәбе белән дә хисаплашуы монын ачык мисалы.

Хәзер исә бу күренешнең асылында ни ятканын ачыкларга тырышып карыйк. К.Г. Юнг теориясе буенча, томанлы аңсызлык яссылыгында ике архетип Персона һәм Тень (күләгә) ята. Персона – ул җәмгыять һәм социаль мохит тәрбияләгән образ, күләгә исә кешенең табигый инстинктлары, коллектив аңсызлык катламында яшеренгән ата-ана, әби-баба, гомумән, милли билгеләр җыелмасы. Социаль яшәеш егетләрдән Тукай белән янәшә Лермонтовны, Толстойларны белгән, театр-концертларга йөргән алдынгы фикерле, укымышлы, алар күрергә теләгәнчә киенә белүче, әңгәмәне алып бара ала торган, әдәпле, шул ук вакытта ир-атларда теләк тудыра ала торган нәзәкатьле ымсындыргыч хатын-кыз аралашу, гаилә коруны сорый, ә шәригать, дини кануннар, милли традицияләр беренче карашка калкып тормасалар да, Хәмит белән Шәмсидә икеләнү хисләрен уяталар. Алар шәхескә инстиктив аңлылыктагы Күләгә архетипы аша ирешәләр.

Күләгә архетипынын әледән-әле аңлылыкка үтеп керүен исбатлаучы мисаллар әсәрдә байтак. Мәсәлән, төш алымы. Аларны язучылар алхәбәр урынына символик образ буларак кулланалар; психология фәне исә төшләрне шәхеснең томанлы узаңы, кешедә барган психик халәтне билгеләүдә инстинктив аңсызлыкны тану чарасы итеп файдалана. Геройларның төшләре бу хаҗәттән игътибарга лаек.

Г. Исхакый геройларның эчке халәтен, дөньясын, җанында кузгалган көчле давылны чагылдыру өчен, төрле мифик образлардан актив файдалана: «Минем өстемә албасты пәрие килеп ятты. Әнә шул үзенең авыр йөге белән акыртын гына өстемә ята, аның резинка кебек йомшак, сыгыла-бөгелә торган тәне әгъзаларның бөгелгән, борылган һәммә йерләрен тутырып баса бара. Аның очлы ике борыны минем борынның тишекләренә тыгыла, аның кайнар сулышы авызга таба менә. Тукта, ул бит кяфер шәйтан шулай итеп үтермәкче була. Буып, иман әйтергә ирек бирмәенчә җанны алмакчы була. Тиз-тиз авызга килгәнчә бисмилла әйтим, ул бит, кяфер пәрие, бисмилладан курка... Тагы сул аякның баш бармагын селкетим, ай, ул баскан, үләм, тыным бетә. Әнә үзенең карабодай саламы яккан авыл миченнән килә торган эссесе белән бөтен йөзне киптерә, яндыра» [3: 322]. Шушы ук образ «Ул әле өйләнмәгән иде» повестенда да бар. Албастының әсәрләргә килеп керүе юкка түгелдер. Бу әсәргә символик мәгънә алып керә. Уйлап карасаң, әле китерелгән күренеш-төш әсәрнең нигезенә салынган – руслаштыру сәясәтенә тәңгәл килә. Мифик персонажның

кыз образына туры килүе ачык күренә. Ул башта акрын гына геройларның йөрәген били, аңын җуйдыра. Соңыннан тулаем «басып», үзенә буйсындыра; бүгенгечә иттереп әйтсәк, толерант мөнәсәбәтләр урнаша. Ягъни бөтенләй аларда татарның хисен, туган халкын, гореф-гадәтләрен, йолаларын оныттыра. Автор әсәр башыннан яратып сурәтләгән Анна һәм Мария образларын әсәрләренә керткән җен-пәри образлары аша чын йөзен ачып сала.

Мифлар сүзлегендә Албастыга түбәндәге аңлатма бирелә: «Албасты – төрки халыкларында очрый торган мифик образ. Ул күп очракта ямьсез кыяфәтле, озын тузган сары чәчле, шундый ук озын күкрәкле (кайчагында албасты аларның аркасына сала) хатын-кыз. Ул хайваннарга һәм җансыз предметка әйләнә ала. Аңа хас атрибутлар – тылсымлы китап, тарак, тәңкә.

Албасты кешеләргә, бигрәк тә, бала тапкан хатыннарга, яңа туган сабыйларга төрле авырулар һәм төнге саташулар җибәрә ала» [6: 58] (тәрҗ. С.С.). Күренгәнчә, сүзлектәге кулланма белән Г. Исхакыйның трансформациясе бер-берсеннән аерылмый. Бу образны бирүдә әдип милләтнең бетүен күздә тотканлыктан, аның мәгънәсен киңәйтә, тирәнәйтә һәм әдипнең кеше күңелен бөтен нечкәлекләрен белү дәрәҗәсен исбатлаудан тыш, төш юрау осталыгына да ия булуын ассызыклый. К.Г. Юнг сүзләре белән әйткәндә: «Синең карашың бары үз йөрәгеңдәге күрә алсаң гына ачылыр. Кем әйләнә-тирәгә генә карый, ул төшләр генә күрер» («Твое видение станет ясным, только если ты сможешь заглянуть в свое сердце. Кто смотрит наружу – видит лишь сны» – тәрҗ. С.С.) К.Г. Юнгның «төш күрү концепциясендә» төшләрнең реаль тормышта булмаган хисләрне кичерү, билгеле яки билгесез сәбәпләр аркасында тыелган эмоциональ киеренкелекне киметү, бетерү, аңлылык-аңлаучанлыкның чикләрен киңәйтү, психик функцияләрнең үсешен тәэмин итә. Төштә мифик образларның урын алуы томанлы аңлылыктагы киеренкелекне тудыра торган уй-фикерләрнең чагылышы. Тормышта рус мәдәниятенә ярарга тырышып яшәгән егетләрнең асылы дин Ислам дине, милли йолалар, нәсел җебе белән нык бәйләнгән булуына ишарә, һәм бу символлар төштә шәхеснең асылын тәшкил итә торган Үз (Самость) архетипының чагылышы. Мондый төшләр, К.Г. Юнг фикеренчә, «үз үзен табарга, башка кешеләрдән аерырга булыша торган мөһим (важные) төшләр».

Бу очсыз-кырыйсыз өзгәләнүне Г. Исхакый үзенә хас тирәнлек белән геройның психологик нюансларына кагылып нечкә штрихлар ярдәмендә тасвирлый. Автор да бу газаптан котылу чарасын бөек көчкә – Аллаһы Тәгалә язмышына тапшыра. «...Күңеленең әллә кай бер җире ышанып җитмәгәнгә, кай вакытларны кайгыртучан булды. Вә ярдәмчесе, киңәшчесе булмаганга, елап-елап намаз укучан, алладан сораучан булды».

Биредә «әллә кай бер җире» дигән сүзгә салынган эстетик мәгънә кабат-кабат уйлануны таләп итә. Сүз художнигының көче, кодрәте, иҗади колачы да, ул шәхеснең эчке дөньясын бөтен барлыгын, өметен, шикләнүен, юануын, борчылуын билгесез язмыш кочагында кайнавын күз алдына китерә. Ләкин билгеле бер нәтиҗә ясарга ашыкмый. Әдипнең әлеге әсәрләре өстендә эшләгәндә, язучының кеше психологиясен никадәр тирән чагылдыруы, гаҗәп бер нечкәлек белән бирелүенә игътибар итик. Биредә сүз рәссамы конкрет художество образларының хисләре, кичерешләре, дулкынлануы, тетрәнүе аркылы татар голямасында үскән кешеләрнең җанын рус мохитендәге реаль тормыш, яшәеш никадәр газаплаганын сурәтләп бирә. Әсәрдәге геройлар гына түгел, барлык әйләнә-тирә, табигатьнең күренешләре Шәмси белән Хәмитнең кичерешләренә органик кушылып сыкрыйлар, алар яшь кешенең, аның хисләренең, җәмгыятьнең кыргый законнары басымы астында изелгәнлегенә сыкрыйлар, шул ук вакытта мәхәббәт хисләрен хуплыйлар, аларга теләктәшлек итәләр.

Шул ук вакытта, әдип бу мөнәсәбәтләрнең бәхетле мөнәсәбәт була алмавын да ачык күрсәтә. Ике мохиттә үсеп тәрбияләнгән ике дөнья кешесе, ничек тә бәхетле була алмый. Аларны гел үз тормышы тарта. Шәмси дә бит алдагы көндә урыс балаларын милли рухта тәрбияләү утында яна. Ул янган арада, Анна Васильевна үз хыялларын тормышка ашыра бара. Бер гаилә эчендә яшәгән ике конфессия вәкиле никахны гомерлек итә алмый. Дини һәм милли каршылыкларга нигезләнгән гаилә мәсьәләсен яктыртып, әдип проблеманың ижтимагый-сәяси һәм рухи асылын ачыклап бирә әлеге күренеш фаҗигагә илтә. Г. Исхакый үзенең бу ике повесте аша руслаштыру мондый күренешнең «милләтнең генофондын хәлсезләндерүгә алып баруын, табигать кануннарына каршы килүен кисәтеп үтә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, күңел диалектикасын ачуга корылган психологик анализ татар әдәбиятында тәүге тапкыр Г. Исхакый иҗатында чагыла. Әдипнең «Ул икеләнә иде» һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрләре бер яктан милләт мәсьәләсе, аның киләчәге турында уйлануларга нигезләнгән. Шул ук вакытта, бу повестьлар кешенең эчке кичерешләрен ачу ягыннан да укучыга гаять кызыклы.

ӘДӘБИЯТ


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. 2 том. Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 478 б.
2. Баттал Г. «Мөгаллим» китабы вә өйләнү мәсьәләсе // Вакыт. 1909. 27 июль.
3. Исхакый Гаяз. Әсәрләр: 15 тода. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 464 б.
4. Исхакый Г. Хатын-кыз мәсьәләсе // Ил. 1914. 18 гыйнвар. № 11.
5. Миңнегулов Х. Әдәбиятчылар алдында эшләр күп // Ватаным Татарстан. 1994. 27 февраль.
6. Мифы народов мира. Энциклопедия. 1 том. М.: Советская энциклопедия, 1991. 671 с.
7. Сәхапов Ә. Исхакый иҗаты: монография. Казан: Мирас, 1997. 369 б.
8. Фәхретдинов Р. Болгар һәм Казан торекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 287 б.
9. Юнг К. Сновидения. Структура психики и архетипы. М.: Академический проект, 2015. 328 с.


## ЗАТНЫ ТАСВИРЛЫЙ ТОРГАН ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕ ТАТАР ТЕЛЕННӘН РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### (Г. Исхакыйның «Теләнче кызы» һәм «Нищенка» әсәрләре материалында)


***Ф.Р. Сибгаева*** *(Казан)*



Данная статья посвящена исследованию особенностей перевода оценочной лексики. В статье рассматриваются способы использования оценочной лексики, выявляются основные тенденции и способы ее перевода, анализируется степень точности и адекватности перевода оценочных определений в литературных текстах Г. Исхаки в переводе с татарского языка на русский язык. Лексическое значение слова – реализация понятия языковой системой и дополнительная характеристика, которая отражает сопутствующие понятию представления, а также эмоциональная и стилистическая окраска слова. Лексическое значение определяется сложностью взаимоотношений значения и понятия. В эмоционально-оценочных словах также присутствует соотношение значения и понятия.


**Ключевые слова:** оценочная лексика, литературный произведения, Г. Исхаки, перевод, рациональная оценка.



This article is devoted to the study of the peculiarities of translation of evaluation vocabulary. The article discusses the ways of using valuation vocabulary, reveals the main trends and ways of its translation, analyzes the degree of accuracy and adequacy of translation of appraisal definitions in the literary texts of G. Iskhaki in translation from Tatar into Russian. The lexical meaning of the word is the realization of the concept by the language

system and an additional characteristic that reflects the concepts accompanying the concept, as well as the emotional and stylistic coloring of the word. Lexical meaning is determined by the complexity of the relationship between meaning and concept. In emotionally-appraising words, there is also a relation between meaning and concept.
**Key words:** estimated vocabulary, literary work, G. Iskhaki, translation, rational evaluation.

Гаяз Исхакый татар хатын-кызының эчке һәм тышкы матурлыгы аның сафлыгына, тырышлыгына, хезмәт сөючәнлегенә, милләт өчен көрәшүче булуына, белемгә, мәгърифәткә омтылуына, аның гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урынына бәйле ди. «Теләнче кызы» романында әлеге принципларның барысы да урын алган. Әсәрнең рус теленә тәрҗемәсенең аннотациясендә болай диелә: «Роман "Нищенка" – это воплощение мечты Гаяза Исхаки об идеальной татарской женщине, свободной и прекрасной» [1: 3].

Лексик сурәтләү чараларына фразеологик әйтелмәләр, метафоралар, чагыштырулар, эпетитлар һ.б. керә. Әдәбият белемендә аларны поэтик чаралар яки стилистик фигуралар дип атыйлар. Бу чаралар матур әдәбиятның образлылык системасын тәшкил итә. Төрле телләр өчен сүзләрнең фразеологик бәйләнешендә, образлылык системасында уртак һәм үзенчәлекле яклар бар. Халыкларның тормыш-көнкүрешендә, яшәешендә, хисләрендә, сәнгатьчә фикерләвендә, табигать, җәмгыять күренешләрен күзаллау, үзләштерү характерында уртак һәм аермалы яклар бар. Бертөрле фәлсәфи караш, сәнгатьчә фикерләү нәтиҗәсе буларак ике телдә дә мәгънәләре һәм образлары бертөрле булган сурәтләү чаралары бар. Шуңа бәйле рәвештә, әдәби тәрҗемә процессында андый чараларны төгәл яки турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкинлеге килеп туа. Шул ук вакытта һәр телнең үзенә генә хас образлы чаралары бар, ләкин тәрҗемәче бер үк вакытта төп нөсхәнең милли колоритын, үзенчәлеген, авторның индивидуаль стилен (идеалектын) сакларга тиеш.

Лексик сурәтләү чараларын тәрҗемә иткәндә, дүрт ысул файдаланыла: а) төгәл яки сүзгә-сүз тәрҗемә; ә) аерым компонентларын үзгәртеп тәрҗемә итү; б) тәрҗемә телендәге әзер сурәтләү чарасы белән алмаштыру; в) компенсация ысулы белән тәрҗемә итү. Чагыштырулар, метафора, эпитетлар – лексик сурәтләү чаралары, икенче төрле аларны әдәбият белемендә троплар дип тә атыйлар. Фразеологизмнар да дүрт ысул нигезендә тәрҗемә ителә. Иң актив ысулларның берсе – сүзгә-сүз, ягъни калькалаштырып тәрҗемә итү һәм компонентларның берсен үзгәртеп тәрҗемә итү. Тропларның образлылыгын саклап тәрҗемә итү – оригиналның мәгънәви һәм сәнгатьлелек әһәмиятен тулы итеп бирүдә әһәмиятле роль уйный. Аерым очракларда оригиналдагы троплар тәрҗемә теленең әзер троплары белән алмаштырылып тәрҗемә ителә. Мондый образларга корылган сурәтләү чаралары тәрҗемә иткәндә үзгәреш кичерә. «Тропларны алмаштыру юлы белән тәрҗемә иткәндә, тәрҗемә теленең реалияләре катнашмаска тиеш. Югыйсә бу тарихи чынбарлыкны бозуга китерә», дип саный Р.А. Юсупов [2: 15]. Тропларны нейтральләштереп тәрҗемә итү әдәби тәрҗемәдә сирәк очрый. Бу ысул тәрҗемә телендә оригиналдагы сурәтләү чарасына күчерелмә мәгънәсе һәм образлылыгы белән туры килерлек чара табылмаганда, кулланыла.

Матур әдәбиятта гомумпоэтик троплар белән беррәттән язучы теленә генә хас индивидуаль троплар да урын ала. Бу берәмлекләр язучының индивидуальлеген, стилен булдыруда катнашалар. Аларны тәрҗемә итү тагын да игътибарлылык сорый. Автор тарафыннан уйлап табылган яңа метафоралар, чагыштырулар, эпитетлар оригинал тел ияләре өчен дә гадәти булмыйлар. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, индивидуаль тропларның контексттагы күчерелмә мәгъ-

нәләрен, эмоциональ дәрәҗәсен аңларга кирәк. Тәрҗемә принциплары язучының индивидуаль тропларын максималь дәрәҗәдә саклануны күздә тота. Индивидуаль тропларны тәрҗемә телендәге әзер троплар белән алмаштыру үзен акламаска мөмкин, шуңа күрә автор иҗат иткән сурәтләү чарасын, тел бизәген тәрҗемәдә дә автор кулланган кебек саклау әһәмиятле. Тәрҗемәче аны, туган тел нормасын бозмыйча, төгәл тәрҗемә итәргә тиеш. Мондый тәрҗемәләр, әлбәттә, язучының индивидуаль стилен булдыруда катнашалар.

Г. Исхакыйның иҗатында хатын-кыз темасы – иң бай традицияле һәм иң күренекле темаларның берсе. Аң-белем һәм тәрбия ярдәмендә милләтне инкыйраздан коткару һәм үстерү турында сүз алып барганда, Г. Исхакый хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирүгә аеруча игътибар бирә. «Әгәр ана кеше тәрбияле булса, ул, билгеле, баласын ашату-эчертү турында гына кайгыртмаячак, ә бәлки аның холкының яхшы булуы, рухының сәламәтлеге, белемлелеге өчен дә тырышачак», – ди автор.

Г. Исхакыйның «Теләнче кызы» романында хатын-кыз язмышы һәм образының яктыртылуы аеруча үзенчәлекле. Монда ата-анасы бик иртә үлеп, бөтенләй ятим калган, әмма тормышның төбенә төшсә дә, үзенең күңел сафлыгын һәм иманын югалтмаган Сәгадәтнең, тормыш баткаклыгыннан котылып һәм аң-белем алып, күркәм зыялы затка әверелүе сурәтләнә. Ул кешелекле, юмарт, милләтпәрвәр бер ханым булып үсеп җитә.

Төп геройның исеме *Сәгадәт* рус телендә *Сагадат* дип транслитерация ысулын кулланып бирелә: *«Сәгадәт – өч ел моннан элек туган авыл хәзрәтенең кызының исеме булганга, Хөсниҗамал абыстай да, кызының исеме мулла кызыныкы төсле булсын дип, Сәгадәт куйдырган иде». / «Трёхлетняя дочка муллы звали Сагадат. Хусниджамал-абыстай решила дать своей новорождённой малышке то же имя, ведь слово "сагадат" означает "счастье"».* Әлеге өзекнең рус теленә тәрҗемәсендә *Сәгадәт* исеменең аңлатмасы бирелә, гәрчә оригиналда ул булмаса да. Ялгызлык исемнәрне биргән вакытта лексик трансформациянең (лексик-семантик алмаштыру) модуляцияләү ысулын тәрҗемәче уңышлы куллана.

Хатын-кызның белемле, динле, тырыш, хезмәт сөючән булуын Г. Исхакый түбәндәгечә тасвирлый: *«Сәгадәт яз булгач та барган кыз берлән бергә зәрдәгә йөрергә тотына иде. Аннан вакыты берлә балтырганга да бара иде». / «Ранней весной Сагадат собирала с подружками сныть, чуть позже – борщевик».*

Гади җөмләләрне берләштерү алымы да очрый, чөнки оригиналда җөмлә хәзерге татар әдәби калыпларына туры килеп бетми, ә тәрҗемәдә исә рус теленең синтаксик үзенчәлегенә туры китерелгән: *«Җанын фида кылып»* гиперболасы йомшартылып: *«верой и правдой»* дип кенә бирелгән: *«Аңарга бу хатыннар һәммәсе дә бик яхшы төсле күренә иде, һәммәсен дә әллә нинди бүләкләр белән бүләклисе килә иде. Һәммәсе өчен дә киләчәктә җанын фида кылып хезмәт итәргә күңеленнән вәгъдә кыла иде». / «Она с благодарностью смотрела на женщин, все они казались ей сегодня очень хорошими, хотелось сделать им какой-нибудь подарок, она давала в душе зарок всю жизнь служить каждой их них верой и правдой».*

Алдагы *«Аларны бик ләззәт белән бөтен китапның эченә кереп укый иде». / «Книги она читала с упоением, забыв обо всём на свете»* мисалында *«Китапның эченә кереп укый иде»* лексик сурәтләү чарасы тәрҗемә телендәге әзер гыйбарә белән алмаштырылган – *«забыв обо всём на свете».*

*«Җәй үтеп киткәндә безнең Сәгадәт шактый гына мәгълүмат җыя алган, үзенең иске фикеренең күбесен ташлап, аларны яңа берлән сипли алган иде.» / «К концу лета Сагадат накопила немало знаний, отказалась от многих*

*прежних своих представлений».* Тәрҗемәче лексик-грамматик трансформациянең үзенчәлекле очрагын – антонимик тәрҗемә кулланган: *«шактый гына мәгълүмат җыя алган» – «накопила немало знаний».* Җөмләнең икенче өлешендә исә героиняның яңа фикерләр туплавы турында оригиналда бирелгәнчә өстәп әйтелми, төшереп калдырыла. *«Мөгаллимәнең көндез биргән дәресен кич бетереп, кичкесен төнлә хәзерләп, мөгаллимәсенең исен китәрде.» / «Задание, полученное днём, она выполняла вечером, то, что получала вечером, выполняла ночью. Учительница поражалась её трудоспособности».* Грамматик трансформациянең җөмләне таркату ысулы. Шулай ук тәрҗемәче русча текстта «поражалась её трудоспособности» дип модуляцияләү алымы ярдәмендә мәгънәне логик яктан көчәйтә.

Хатын-кызның Аллаһка ышануы, дингә мөнәсәбәте дә тәрҗемәдә үзенчәлекле бирелә: *«Сәгадәт бик ихлас берлән моның намаз укуын тыңлап торды. Бу бабайның тавышын ишеткән саен Сәгадәткә бабай якынлаша бара иде». / «Девушка с удовольствием прислушивалась к молитве. И чем дольше слышала она этот голос, тем ближе становился ей пожилой незнакомец».* «*Ихлас»* сүзен *«удовольствие»* дип тәрҗемә итү генә җитми, безнеңчә, чөнки монда нәкъ ихласлык, ягъни *«искренность»* күздә тотыла. *«Авыз эченнән генә Аллаһе Тәгаләдән әтисен ярлакавын, әнисенең сәламәтлеген, үзенең... бәхетле булуын сорарга тотынды». / «Мысленно просила Аллаха простить отцу все его грехи, послать матери здоровье, а для себя...просила счастья».* «*Авыз эченнән»* сүзтезмәсе тәрҗемәдә *«мысленно»* берәмлеге белән бирелә – бу экспликация алымы. Бу очракта тәрҗемәче аны уңышлы кулланган. Алга таба тәрҗемәче яңадән модуляцияләү алымын кулланып, *«әтисен ярлакавын»* берәмлеген *«простить отцу все его грехи»* дип бирә.

«Теләнче кызы» романында хатын-кызны, аның эшчәнлеген тасвирлый торган лексик берәмлекләрне тәрҗемә итү процессында тәрҗемәче Азалия Исмәгыйль кызы Бадюгина трансформацияләрнең лексик, грамматик һәм катнаш типларын кулланып шактый гына уңышлы тәрҗемә тәкъдим итә. Лексик трансформацияләрдән төп игътибар лексик-семантик алмаштыру, конкретлаштыру, генерализацияләү һәм модуляцияләү ысуллары белән бирелә. Грамматик трансформацияләрдән иң еш очраганнары җөмләләрне таркату, берләштерү һәм, сүз тәртибе үзгәрү алымнары. Тәрҗемә өлкәсендә грамматик трансформацияне куллану авыр ысулларның берсе. Тәрҗемәче бу ысулны кулланган вакытта да, тел нормаларын бозмас өчен, аеруча сак эш итә.

ЛИТЕРАТУРА

1. Исхаки Г.Г. Нищенка. Мулла-бабай: романы / [пер. с татар. А.И. Килеевой-Бадюгиной]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 352 с.

2. Юсупов Р.А. Вопросы перевода, сопоставительной типологии и культуры речи. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 383 с.

## MARTİN HARTMANN’A GÖRE AYAZ İSHAKÎ

***Dr. Ayşegün Soysal Akyos*** *(İstanbul, Türkiye)*

Гаяз Исхаки в период II Конституционной монархии находится в числе прибывшей в Стамбул татарской интеллигенции. Исхаки, участвовавший в культурной и политической жизни Стамбула, знакомится с находившимся в то время в городе немецким востоковедом Мартином Хартманном. В данной работе будут затронуты сведения, которые дает Мартин Хартманн о Гаязе Исхаки, будет сравниваться мнение Гаяза Исхаки о турках и политических изменениях в османском государстве с его письмами, написанными из Стамбула в Казань.

**Ключевые слова**: Гаяз Исхаки, Мартин Хартманн, казанские татары, Стамбул, османские турки.

Ayaz Ishaki was one of the Kazan Tatar intellectuals who came to Istanbul in Second Constitutional period. He played an important role in cultural and political life in Istanbul. He met with a German Orientalist, Martin Hartmann, in Istanbul. In this paper Hartmann's views and information he gave about Ayaz Ishaki will be discussed and compared with his articles sent to Kazan periodicals. Through this information we can learn the first impression and thoughts of Ayaz Ishaki about the Ottoman Turks and the developments in Istanbul.
**Key words:** Ayaz Ishaki, Martin Hartmann, Kazan Tatars, Istanbul, Ottoman Turks.

Ayaz İshakî, edebiyat, basın, siyaset alanlarında faaliyet göstermiş önemli bir Kazan Tatar aydınıdır. Ayaz İshaki bir ulema ailesinde yetişmiş, klasik din eğitimi alarak bir imam-öğretmen olarak çalışmaya başlamıştır. Ancak 20. yüzyıl başında Rusya ve Osmanlı imparatorluğundaki siyasi ve toplumsal değişimlerden ve Avrupa'nın düşünsel gelişiminden etkilenmiştir. Ayaz İshaki'nin düşünce ve eylem adamı olarak kimliği zaman zaman çelişebilen bu etkilerle biçimlenmiştir. 1908'de II. Meşrutiyetin ilanından sonra birkaç kez Türkiye'ye gelen Ayaz İshaki kısa sürelerle de olsa 1908–1911 arasında İstanbul'da yaşamıştır. Yazarlık faaliyetini sürdürdüğü bu dönemde İttihat ve Terakki Partisinin ileri gelenleriyle bağlantı kurduğunu, Türkçülük fikrinin yayın organı bir dergi çıkarmak amacıyla Enver Paşa ile de görüştüğünü hatıralarında anlatmıştır. Ayaz İshakî anılarında Petersburg'da Alman şarkiyatçı Martin Hartmann (1851–1918) ile tanıştığını da anlatır ve Hartmann'ın onun verdiği bilgilere dayanarak ve ismini anarak Rusya Müslümanları hakkında yazdığı yazının Rus siyasi polisi tarafından bulunmasını kolaylaştırdığını ekler. Biz bu tanışmanın İstanbul'da gerçekleştiğini düşünüyoruz, bu çalışmada da Hartmann'ın 1910 yılında yayımlanan «Türkiye'den Siyasi Olmayan Mektuplar» kitabında Ayaz İshaki'nin nasıl değerlendirildiği üzerinde duracağız.

Teoloji ve Doğu dilleri eğitimi alan Martin Hartmann kısa bir süre Edirne ve İstanbul'da görev yaptıktan sonra 1876–1887 yılları arasında Beyrut'da Alman konsolosluğunda tercümen ve danışman olarak çalışmıştır. Daha sonra 1918'deki ölümüne kadar Berlin'de Arapça eğitimi veren Hartmann Almanya'daki sosyal demokrat çevrelerce önem verilen bir şarkiyatçı olmuştur [1].

Martin Hartmann 1909 sonbaharında İstanbul'da 40 gün kalmış, çeşitli temaslarda bulunmuş ve bu görüşmelere dayanarak «Türkiye'den Siyasi Olmayan Mektuplar» kitabını yazmıştır. Kitabında Ayaz İshaki'yle tanışmasına ve Ayaz İshaki'nin düşüncelerine önemli yer vermiştir. Bu kitaba dayanarak bu tanışmalarının 1909 eylülünde İstanbul'da gerçekleştiğini düşünüyoruz. Kitapta Ayaz İshaki'den Ayaz olarak bahsetmiş, düşüncelerini çoğunlukla doğrudan onun ağzından çıktığı şekilde aktarmış ya da en azından kitaptan o izlenim edinilmektedir.

Hartmann'ın Ayaz İshaki ile konuşmaları hakkında yazdıklarına genel olarak baktığımızda ilk dikkati çeken İshaki'nin İstanbul'da olduğu sırada yazdıklarıyla, yaptığı konuşmalarla örtüşmesidir. Dilde sadeleşme, kadın özgürlüğü, Osmanlı Türkleri eleştirileri, Tatarların Osmanlı Türklerinden üstünlüğü gibi konular öne çıkmaktadır. Bir fark olarak sınıf vurgusunun, Ayaz İshaki'nin halkçı, sol hassasiyetlerinin öne çıkmaması olduğu söylenebilir ki bu Hartmann'ın tercihi de olabilir. Tatarların Ruslardan üstünlüğü de yine sadece bu konuşmalarda vurgulanan bir konudur. Adlandırmalara bakılacak olunursa, Osmanlı Türkleri, Rusya Müslümanları, Tatarlar, Nogaylar terimleri kullanılmıştır. Kitaptan yaptığımız aktarmalarda metindeki tanımlara sadık kaldık.

Hartmann İstanbul'da bulunduğu dönemde hem Türk Derneği'ndeki dilde sadeleşme tartışmalarını izler hem de Ayaz İshaki'yle tanışır. 12 Eylül 1909 tarihli

mektubunda Hartmann dil tartışmaları hakkında 9 Eylül 1909'da *İttihad* gazetesinin 107. sayısında yayımlanan Mehmed Nizami imzalı «Lisan Kavgası» makalesinin geniş bir özetini verir. Bu makalede Kazanlı edebiyatçı Ayaz'ın yazdıklarının edebi açıdan değersiz olduğunun belirtildiğini aktaran Hartmann bunun nedeninin de nefret olduğuna dikkat çeker. Bahsi geçen *İttihad* gazetesi ve yazar Mehmed Nizami hakkında bir bilgiye ulaşamadık ancak Hartmann'ın dil tartışmalarını başlatan Süleyman Nazif ve Ali Nusret'in makalelerinden çok bu yazıya yer vermesi dikkat çekicidir. Hartmann'ın aktardığına göre Mehmed Nizami yazısında Osmanlıda da halk için bir edebiyatın gerekliliğini kabul eder ancak Osmanlı edebiyatını bu nedenle Kaşgar Türkçesi düzeyine indirmenin ya da Kazan'ın Tatarca dil anlayışına uydurmanın imkânsız olduğunu belirtir. Hartmann yazarın cemiyet kelimesini bilen hiçbir Osmanlının dernek kelimesine ihtiyaç duymadığını, zaten kendi üyelerinin de dergilerinde bu kelimeyi kullanmadığını vurgulayarak dikkat çekilen bazı çelişkilere kendisi de kısmen hak verir [5: 49]. Mehmed Nizami'nin Tatarcaya atıfta bulunmasının kuvvetle muhtemeldir ki nedeni Ayaz İshaki'nin *Sırat-ı Müstakim*'de yayımlanan dilin sadeleşmesi hakkındaki yazılarıdır.

Martin Hartmann 26 Eylül 1909 tarihli mektubunda Türk Derneğinin o günkü oturumuyla ilgili daha olumlu bir izlenime sahip olduğunu aktarır. Oturum başkanının Kazanlı Ayaz'a bir konuşma yapması için ısrar ettiğini ancak ülkeden ayrılacağını belirttiğini yazar. Hartmann Ayaz'ın dikkat çekici bir şahsiyet olduğunu, sert, Türkten ziyade Slava benzeyen bir tipi olduğunu, hareketlerinde ve davranışlarında sakarlık bulunsa da konuştuğu zaman düşünen ve düşündüğünü açıkça söyleme cesaretine sahip biriyle karşı karşıya olunduğunun görüldüğünü belirtir. Ayaz İshaki Osmanlıları çok yeteneksiz oldukları, diğer Türk halkları hakkında hiçbir şey bilmedikleri, çok düşündükleri ancak eğitim, edebiyat ve ahlaki nitelikler açısından çok geri olduklarını söyleyerek topa tutmuştur. Hartmann kendisine Ayaz'ın oturumun başlangıcında İstanbul'a doğru, dürüst bir Türk halkı bulacağı düşüncesiyle geldiğini ama bir yalancılar çetesi bulduğunu ve «yalan söylemekten başka bir şey yapamazsınız, sizde sözünde durmak yok» dediğinin aktarıldığını belirtir. Hartmann ilk konuşmayı kimin yapacağıyla ilgili tartışmada herkes, yanlış yapmamak için layıkıyla hazırlanması gerektiğini söyleyerek kaytarınca Ayaz'ın sert bir ironiyle «Arapça bir atasözü vardır; hiçbir şey yapmayan hata yapmaz. Burada da olan bu, yanlış yapmayacaksınız ama hiçbir şey de yapılmayacak» dediğini kendi kulaklarıyla duyduğunu ekler.

Hartmann kitabında bu toplantıda konuşulan konular, ilgili kişi ve yayınlarla ilgili dağınık bilgiler verir. Bu bağlamda «Rus Ayaz»ın toplantıda olumlu bakılan *Sırat-ı Müstakim*'e makaleler verdiğini de ekledikten sonra Yunus Emre hakkındaki konuşmalara geçer [5: 123]. Kitap içinde Hartmann Ayaz İshaki için yukarıdaki gibi «Rus» tanımı dışında çoğunlukla «Nogay» tanımını kullanmıştır.

Hartmann derneğin toplantısında halkın çektiği sıkıntıların açıkça tartışıldığını, Osmanlıların temel şanssızlığının yönetime duydukları güven olduğu konusunda fikir birliğine varıldığını hatta devrimin bile yönetimin korumasında gerçekleştiğine dikkat çekildiğini anlatır. Hartmann Ayaz'ın Rusyalı Türklerin bu açıdan daha iyi durumda olduğu tespitini doğru bulur. Ayaz Rusyalı Türklerin yönetimden hiç bir şey beklemediklerini, her şeylerini kendilerinin kazanmak zorunda olduğunu belirterek İstanbul'da Türkler arasında bir milyoner bile bulunmadığını oysa Rusyalı Türkler arasında bir düzineden fazla olduğunu ekler.

Ayaz İshaki'nin Osmanlı Türklerine yönelik olumsuz düşünceleri Martin Hartmann tarafından da paylaşılır. Ayaz'ın milli konulardaki görüşlerine de değinerek onun Rusya'da Türkler için «milli» kavramının olmadığını, elbette amaçlarının Türklüğü güçlendirmek olduğunu, aynı zamanda hoşgörülü olduklarını örneğin

Odessa'da Rusların Yahudileri öldürmesini engellediklerini; kadın sorununu çözdüklerini, kız çocuklarının Rus okullarına devam ettiklerini; ahlaki olarak da dindar İstanbul'dan daha kötü durumda olunmadığını ekler. Yazar bu defa Nogay olarak tanımladığı Ayaz'la yaptığı özel görüşmeden bu insanların dini çekincelerden tamamen kurtulduğunda inandığını belirterek onlarda dinin milli düşünceden sonra geldiğini, İslamiyetin, diyanetin önemsiz olduğunu belirtir [5: 126].

Martin Hartmann 28 Eylül 1909 tarihli mektubunda Kazan'dan Ayaz'ın kendisini ziyaret ettiğini sevinerek haber verir. Dış görünüş itibariyle neredeyse korkutucu olduğunu ama derin düşünce ve gerçek duygularını belli eden yaradılışıyla kendisini daha da sevdiğini ekler. Konuşkan olduğunu, güzel ve kapsamlı konuştuğunu belirtir. Ayaz'ın Rusya'daki pek çok saygın insan gibi sürgün olduğunu ancak artık sürgünde yaşamadığını büyük, medeni bir Rus şehrinde yaşadığını da ekler. Kanunların anlamsızlığı ve bürokrasinin aptal gaddarlığının zamanında ve usulünce verilecek rublelerle yumuşatılabildiği bu kutsal ülkede her şeyin mümkün olduğunu belirterek Ayaz İshaki'nin sürgün yerinden rüşvet vererek çıktığına işaret etmektedir muhtemelen. Hartmann devamla Ayaz'ın bölge hakkında çok güzel hikâyeler anlattığını yazar. Ayaz'ın Rus yönetimi hakkındaki değerlendirmesinin kendisinin *Der Islam* dergisinin 1907 ve 1908 yıllarında yayımlanan sayılarında yer almış yazılarını desteklediği için özellikle değerli olduğunu ayrıca eklediği sevindirici yeni hususları da aşağıdaki gibi özetler:

«Nogay»ların Rusya Türkistan'ında yerleşmelerine, toprak almalarına izin vermeyen yasalar pratikte uygulanmamaktadır. İdil Tatarları doğuştan sağlamlık ve akıllılıklarıyla bu baskıyı yendiler. Bunda Rus çinovniklerin rüşvet almalarının rolü de azımsanmamalıdır. Gün geçtikçe daha fazla Nogay Türkistan'da yerleşiyor ve böyle giderse bu durum bölgedeki Rus hâkimiyeti için ciddi bir tehlike oluşturacak. Yozlaşmış, ikiyüzlü, tembel ve entrikacı Rusların soğukkanlı, bilinçle amacına hizmet eden Tatar unsurundan daha aşağı olduğu ne kadar söylense azdır. Güçsüz ve yetersiz Sart halkı yeterince Nogay unsuruyla karışırsa Rus devletini ekonomik olarak ilerlettikleri gibi sonunda bu muhteşem topraklar da Rus kamçısını beklemek yerine başka bir kültür düzeyine erişir. Bunun tek şartı Nogayların Ruslaşmaya – yani sahte kültür - şimdiye kadar gösterdikleri katı direnci korumalarıdır. Bu konuda yalnızdırlar. Rusya Müslümanlarının kültürle, yani tek erişebildikleri Rus kültürüyle temasa geçtikleri zaman dejenere olmaları üzücü bir durumdur: bu kültürün kötü yanlarını alıyorlar ve hemen ilerlemelerine engel bir uyku haline girip enerji kaybediyorlar. Sartlar dışında Dağ Kırgızları ve Kara Kırgızlardan farklı olarak özellikle Kazak Kırgızların bu etkilere maruz kaldıkları söylenebilir. Nogaylar sadece Rus zehrine karşı ilerleme ve kendini savunmaya özellikle ihtiyaç duyan ova halklarının değil büyük çoğunluğunu dağ Kırgızlarının oluşturduğu Türkistan'ın dağ halklarının da arasına karışıyor. Rus yönetimi Nogayların bu göçebe kavimler arasına yerleşmesine karşı katı bir kanun çıkardı, sadece bu yüzden Kırgızlar arasında faaliyet göstermek isteyen ki öğretmen olarak tercih ediliyorlar, genç Nogaylar, buraya çoban olarak gelip elbette yalnızca bir Rus casus tehlikesi varsa görünüşte bu işle uğraşıyorlar.

Hartmann Ayaz'ın Nogaylar arasındaki gelişmelerle ilgili değerlendirmelerini çok açıklayıcı bulur: Genç kuşaklar bütün hayatın köklü reformunun iki noktadan çıkması gerektiğinin farkındadır. Birincisi dil ve edebiyatın gelişmesi, ikincisi ise kadının durumunda radikal bir değişim. Birincisini halletmek çok zor değil: yetenekler var ve gençlerin uğraşılarına Kerimof gibi eski kuşak kitapçıların direnci gençlerle yürüyen yeni yayıncıların ortaya çıkmasıyla kırılacaktır. Ayaz nitelikli edebi eserlerin maddi başarısını teyit ederek kendi eserlerinin ilk baskıda 5000 nüsha basıldığını çoğunda yakında ikinci baskıya gerek olacağını belirtmiştir. İstanbul'da çok okunan eserlerin en çok 2.000 adet basıldığını Hartmann ekler. Ayaz'ın hareketin

zamanlaması konusunda yeni düşünce hayatının başlangıcı olarak tam bir kesinlikle 1893 yılını, edebiyat ve basın faaliyetlerinin başlangıcı olarak da 1896 yılını verdiğini belirtir. Bu dönemde dilin yabancı unsurlardan temizlenmesi kuşkusuz özellikle önemli bir andır. Birçok defa dikkat çektiği tuhaf durumun yani Kazan'da basılan kitaplarda nispeten çok Osmanlıca kelime bulunmasının da açıklığa kavuştuğunu kaydeder. Ayaz, Yazıcıoğlu'nun *Muhammediye*'si ve *Altıparmak* olarak bilinen Peygamberler Tarihi gibi eski Osmanlıca eserlerin Nogaylar tarafından çok okunduğunu, hatta tuhaf bir şekilde kendilerine tamamen yabancı bir dil olmasına rağmen kadınlar tarafından bazı bölümlerinin ezberlenerek mekanik bir şekilde tekrarlandığını belirtir. Böylece neden kolaylıkla Osmanlıcanın Kazan Türkçesine nüfuz ettiği izlenimine kapılındığını da anlamıştır.

İkinci eğilim daha büyük bir tepkiyle karşılandı: kadınların kurtuluşu. Bütün din adamları böyle dinsizliklere büyük bir öfkeyle karşı çıktılar, kapitalistler ve toplumun itibarlı kesimleri de şimdilik fanatiklerin yanında duruyor. Ama gençler pes etmediler. Korkmadan kızlarını Rus kız okullarına, karılarını peçesiz sokağa gönderdiler. En etkili müttefikleri Rus polisi oldu, böyle zırva bir olaydan sonra hemen çağrılmalarına rağmen karışmadılar. Bugün neredeyse bütün İdil bölgesinin en azından kentlerdeki bütün Müslüman kadınları peçesiz gezebiliyor, Türk kadınları kocalarıyla tiyatroya gidebiliyor, hatta tiyatro gösterilerine katılabiliyor. Hartmann Ayaz için olağanüstü adam diyerek onun Türk İstanbul'a hakim olan ikiyüzlülük ve ahlaksızlığı keskin ve yerinde bir şekilde tespit etmesini ve bizzat örtünmenin ahlaksızlığa neden olduğunu kanıtlamasını çok öğretici bulur. Osmanlı Türklerinin bunu anlaması mümkün değildir. Anlattığına göre adliye nazırı Ayaz'a örtünme ve kapalı yaşam nedeniyle Türklerin yaşadığı bölgelerde işlenen suçların en büyük bölümünün ırza tecavüz olduğunu söylemek zorunda kalmıştır. Hartmann bu bakanın adını vermez ancak bu kişi muhtemelen 31 Mart olayından sonra adliye nazırı olan Necmettin Molla'dır (Kocataş). Buradan da Ayaz İshaki'nin İstanbul'da bulunduğu süre zarfında özellikle İttihatçı çevrelerle ve sorumlu mevkilerdeki kişilerle görüştüğünün bir örneğini daha görüyoruz.

Osmanlı Türklerinin durumunun iyileşmesine, halkın başat özellikleri olarak gördüğü ve kadının yüzlerce yıllık köleliğini büyüten kıskançlık ve güvensizliğin engel olduğunu ekler. Bu aptallar kadınlarını sürekli gözaltında tutmazlarsa aldatılacakları korkusuyla yaşıyorlar ve tam da bu yüzden İstanbul hayatını tanıyanları bileceği gibi kolaylıkla da aldatılıyorlar diyerek Pierre Loti'nin «Les Desenchantees»deki kahramanının eğlenceli kaçamaklarını örnek gösterir. Daha kötüsü de akılsızlıklarını gösteren zihniyetlerini dinle örtmeleridir Ayaz'a göre. Ama Nogayların bunu aşmasını ve on yılı geçmeyen bir sürede bu karanlık kâbustan kurtulmalarını takdire şayan bulur.

Nogayların bilimsel itibarı Avrupa'da son yıllarda zarar gören ama aslında bu topluma hizmet etmiş olan bir kişiye teşekkür borçlu olmaları gereğine dikkat çekiyor. Berlin doğumlu ünlü Türkolog Radloff sayesinde Kazan'da nitelikli öğretmenler yetiştiren *darülmuallimin*'in (1876 Kazan Muallim Mektebi) kurulduğunu hatırlatır. Hartmann burada Ayaz'ın Rus dostu olmadığını, Radloff'a müteşekkir olmak için kişisel bir nedeni olmadığını ekleyerek sözlerinin genel anlayışıyla çeliştiğini belirtir [5: 133].

Bu noktada Hartmann'ın Ayaz İshaki'nin hayatı, eğitimiyle ilgili bilgi sahibi olmadığını anlıyoruz. Dinle ilgili yorumlarında da Ayaz İshaki'nin din eğitimi aldığına ihtimal vermediği fark ediliyor. Mektubunun bu son cümlesinden de Ayaz İshaki'nin Muallim Mektebinde okuduğunu bilmediği anlaşılıyor, çünkü tam da Hartmann'ın yazdığı gibi kurduğu okulda okuduğu için Radloff'a müteşekkir olabilirdi İshaki [5: 130–133].

Hartmann 30 Eylül 1909 tarihli mektubunda hayatla ölüm arasındaki mücadelenin İstanbul'da sürekli bir kriz ortamı yarattığını tespit ederek hayatın 23 Temmuz 1908'de yani II. Meşrutiyet ilan edildiğinde kazandığını ama 31 Mart olaylarını kast ederek 13 Nisan 1909'da tehdit edildiğini ekler. Burada Meşrutiyetin Abdülhamid tarafından resmen ilan edildiği 24 Temmuzun değil İttihat ve Terakki Cemiyetinin ilanı gününün benimsenmiş olması da dikkat çekicidir.

Aynı mektupta Gayret kitapçısı Garbis Fikri'nin dükkânı ve müşterileri hakkında bilgi verir. Fikri'nin Rusya'dan en yeni kitapları getiren tek kişi olduğunu, sık sık dükkâna gelen Ayaz'ın «Tilençi kız»ını burada bulduğunu, en son eseri «Aldım berdem» piyesinin çevirisinin de yapılacağı haberini de yine Fikri'nin verdiğini belirtir [5: 134].

Hartmann daha sonra Tanin gazetesiyle *Servet-i Fünun* ve *Sırat-ı Müstakim* dergilerini ziyaretini anlatır. *Sırat-ı Müstakim*'in din konusundaki olumlu tavrına örnek olarak 53. Sayıda Ayaz'ın Rusya Müslümanlarının okul sistemi hakkındaki makalesine yer verilmesini gösterir [5: 138]. Tarihçi Volker Adam ise Ayaz İshaki'nin bu dergide yazmasını Hartmann'ın dergiyle iyi ilişkilerine bağlar [2: 48].

Ayaz İshaki'nin Hartmann'la konuşmalarına ve İstanbul'daki yayınlarda çıkan makalelerinde öne çıkan konular Rusya'daki dergilere yazdığı yazılarınkinden farklıdır. İstanbul'da yaptığı konuşmalar, yazdığı yazılar daha çok Kazan Tatar toplumunu tanıtmaya yöneliktir. Ayaz İshaki'nin 31 Mart olayları sonrasında İstanbul basınındaki dil tartışmalarına katıldığı yukarıda belirtilmişti. Ayaz İshaki 1911'de tekrar İstanbul'dadır ve yaz aylarında Türk Derneği'nde Necip Asri'nin kitabına aldığı «Tatar edebiyatı tarihçesi» konulu bir konferans verir, bu konuşma derneğin aynı adlı dergisinde de yayımlanmıştır.

İstanbul'dan *Yoldız* gazetesine yolladığı mektubunda ise İstanbul'daki gelişmeler hakkında yazmaz. İstanbul'da yazılacak çok şey olduğunu bunları önem sırasına koymanın zorluğunu belirterek İstanbul'daki Tatar öğrencilerin durumları hakkında yazmayı uygun bulur. İstanbul'da bulunduğu dönemlerde şehrin entelektüel ve siyasi yaşamına katıldığı gibi Tatar öğrencilerin durumuyla ilgilenmeye de önem vermiştir. 1909'da *Yuldız*, 1911'de *İdel* gazetesine yolladığı mektuplarda daha çok İstanbul'daki Tatarlar, özellikle de öğrenciler hakkında bilgiler vermiştir. Volker Adam'ın belirttiğine göre Ayaz İshaki de 1911'de *İdel* gazetesine yolladığı «Türk tatar meselesi» başlıklı yazıda İstanbul'da Osmanlı Türkleriyle Rusyalı Tatarların birlikte yaşayışı hakkında ilginç detaylar vermiştir [2: 133].

*İdel*'de çıkan bu yazısında yalnızca 1909'da İstanbul basınını haftalarca meşgul eden dil tartışmalarını kendisinin bitirdiğini hatırlatır [2: 372]. O zaman *Tasvir-i Efkâr*'ın basit, anlaşılır Türkçeye karşı durduğunu daha sonra da imparatorlukta yaşayanlara Türk değil Osmanlı denmesi gerektiğini savunduğunu ekleyerek şimdi de benzer bir tartışmanın Türkler ve Tatarların akrabalığı üzerine çıktığını belirtir. 1911'de Ebüzziya Tevfik'in *Yeni Tasvir-i Efkâr*'da yayımladığı bir makalede damarlarında Tatar kanı dolaştığı için Rusların Avrupalı olamayacaklarını yazması öncelikle Türk Derneği tarafından eleştirilmiş ve basında tartışma başlatmıştır. Bunun üzerine İstanbul'daki Rusyalı Müslümanlar Türk halklarının akrabalıklarının konuşulacağı bir bilimsel toplantı düzenleme kararı almışlardır. Tatar basınında da *Şura* dergisindeki Türkçülerle Tatarcılar arasındaki tartışmayla aynı zamanda yani 1911 nisan ayında düzenlenen bu konferansla ilgili haberler yayımlanmıştır.

Volker Adam Ayaz İshaki'nin İstanbul hakkında bir başka yazısına atıfta bulunur. 1913 yılı ocak ayında *Kuyaş* gazetesinde yayımlanan «İstanbul hatıraları» başlıklı makale, *İdel*'de 1911'de yayımlanan makale gibi Toplu Eserlerde yer almamaktadır, dolayısıyla okuma şansımız olmadı [2: 377].

Ayaz İshakiy 1909'da İstanbul'da bulunduğu kısa süre içinde hem İstanbul'da yayımlanan süreli yayınlara katkıda bulunmuş hem Rusya'daki yayınlara makaleler göndermiş hem de edebi eserler kaleme almıştır. Bu sırada yazdığı «Tormışmı bu?» hikâyesi 1911'de Kazan'da basılmıştır. «Sünnetçi babay» ve «Şekert abıy» hikâyelerini de yine İstanbul'da kaleme almıştır, ikisi de daha sonra 1913'de Kazan'da yayımlanmıştır. Tiyatro eseri «Züleyha»yı da daha sonra 1911'de yine İstanbul'dayken yazmış ama bu eser ancak ilk defa 1917'de Kazan'da bir dergide yayımlanmıştır.

Ayaz İshaki'nin İstanbul'da ve İstanbul'la ilgili yazdıklarının bir araya getirilerek değerlendirilmesinin 20. Yüzyıl başında Kazan Tatarları ve Osmanlı Türkleri arasındaki ilişkileri anlamak için önemli olduğunu düşünüyoruz. Son dönemlerini yaşayan iki imparatorlukta yaşayan halkların biri hakim unsurun parçası iken diğeri hakim unsurun dışındadır. Her iki toplumda çok dilli, çok dinli, çok etnik unsurlu bir yapıda yaşamalarına rağmen birbirleriyle ilişkilerinde bu durumun fazla vurgulanmadığını, her iki toplumun da homojen yapılar olarak görüldüğünü, Kazan Tatarlarının Rus toplumuyla, Müslüman Türklerin diğer Osmanlı vatandaşlarıyla ilişkilerinin iki toplumun birbirine bakışında da öne çıkmadığını düşünüyoruz. Bunun nedenlerini sorgulamak için Ayaz İshaki'nin İstanbul'da yazdığı eserler ve kurduğu ilişkilerin önemli olduğunu düşünüyoruz ve eksikleri tamamlayarak bu konuda bütünlüklü bir çalışma yapmayı umut ediyoruz.

KAYNAKÇA


1. https://de.wikipedia.org/wiki/Martin_Hartmann#Literatur.

2. Adam,Volker, *Russlandmuslime in Istanbul am Vorabend des Ersten Weltkrieges. Die Berichterstattung osmanischer Periodika über Russland und Zentralasien*. Peter Lang, Frankfurt am Main 2002.

3. Çağatay, T. vd., *Muhammed Ayaz İshakî Hayatı ve Faaliyeti: 100. Doğum Yılı Dolayısıyla*. Ankara 1979.

4. Demir, Ahmet, «Ayaz İshakî ve Türk Dilinin Sadeleşmesi Sorunu: *Yeni Lisan Hareketi* Öncesinde Kazan-İstanbul Hattında Bir Erken Entellektüel Tartışma (1909)», *Modern Türklük Araştırmaları Dergisi*, cilt 13, sayı 1, Ankara 2016, s. 7–31.

5. Hartmann, Martin, *Der islamische Orient. Berichte und Forschungen. Band III: Unpolitische Briefe aus der Türkei*. Verlag Rudolf Haupt, Leipzig 1910.

6. Kanlıdere, Ahmet, «Radikal Sosyalizmden Milliyetçiliğe: Kazanlı Ayaz İshakî 'nin (1878–1954) Fikrî Serüveni», *Türk Kültürü İncelemeleri Dergisi*, 24, İstanbul 2011, s. 63–94.

7. Kanlıdere, Ahmet, «Ayaz İshakî (1878–1954) ve Türkiye'de Türkçülük Fikrinin Evrimi», *Türk Kültürü İncelemeleri Dergisi*, 27, İstanbul 2012, s. 77–124.

8. Minullin, Zavdat S., «Fraternal and Benevolent Associations of Tatar Students in Muslim Countries at the Beginning of the 20th Century», *Muslim Culture in Russia and Central Asia from the 18th to the Early 20th Centuries. Vol. 2: Inter-Regional and Inter-Ethnic Relations.ed. by Anke von Kügelgen, Michael Kemper, Allen J. Frank*, Klaus Schwarz Verlag, Berlin 1998, s. 271–280.

*9. N. A.*, *Şimâlî Türk Ediplerinden Ayaz İshakî*. Tanin Matbaası, İstanbul 1328/1912.


## НАЗВАНИЯ ОДЕЖДЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИСХАКИ КАК ОБЪЕКТ ЛЕКСИКОЛОГИЧЕСКИХ ИЗЫСКАНИЙ


***Ф.И. Тагирова, И.И. Сабитова*** *(Казань)*



В статье на примере одной тематической группы лексики – названий одежды – анализируется потенциал лексико-фразеологических средств татарского языка. С данной точки зрения раскрываются некоторые семантические, функциональные и иные особенности данной группы лексики в некоторых художественных текстах Г. Исхаки. Корпус лексических средств, использованных в произведениях Г. Исхаки, очень разнообразен и может быть исследован во многих аспектах: функциональном, тематическом, генетическом, семантическом и т.п. В этой статье нами предпринята попытка их комплексного анализа.



**Ключевые слова:** тексты Г. Исхаки, язык писателя, лингвистические особенности, лексические средства, названия одежды.

The article gives a detailed analysis of the value of G. Iskhaki's literary texts as an object and source of lexicological research on the example of one thematic lexical set – the names of clothes. Some semantic, functional and other peculiarities of this lexical set are revealed in the works by G. Iskhaki. Lexical means used in the works by G. Iskhaki are diverse and can be analyzed in the range of aspects: functional, thematic, genetic, semantic etc. Comprehensive analysis of these lexical means was carried out in the article.

**Key words:** G. Ishaki's texts, writer's language, linguistic features, lexical means, names of clothes.

Творчество Г. Исхаки на сегодняшний день является едва ли не самым изученным среди татарских писателей – его современников. В справедливости этого утверждения можно убедиться, если учесть частоту и объемы публикаций его произведений, а также количество исследований, посвященных его творчеству. На протяжении последних нескольких десятилетий литературное наследие Г. Исхаки привлекало и привлекает самый пристальный научный интерес исследователей – как литературоведов, так и лингвистов. Даже ощущается некоторое оживление подобного интереса. Исследования, посвященные жизни, творчеству, общественной деятельности писателя, довольно многочисленны и разноаспектны. Особенно много работ литературоведческого характера, например следующих авторов: Ф.М. Мусин, Т.Н. Галиуллин, Х.Ю. Миннегулов, Р.К. Ганиева, А.Г. Ахмадуллин, Ф.Г. Галимуллин, Ф.Ф. Хасанова, Д.Ф. Загидуллина, Д.М. Абдуллина, Т.Ш. Гилязов, Ч.А. Зарипова-Четин, Р. Яруллина-Йылдырым, Ф. Габидуллина, А. Камалиева и др.

Однако было бы неверным утверждать, что они всеобъемлющи и исчерпывающи. Особенно это относится к лингвистическому аспекту исследования творчества писателя, о чем свидетельствует обзор таких работ. Они весьма разнообразны посвоему подходу к проблеме исследования, по широте охвата писательского наследия автора и по другим особенностям.Так, наибольшее количество работ представляют собой статьи. Наиболее важными, на наш взгляд, являются работы таких авторов, как В.Х. Хаков [2: 223–229], Т.Х. Хайретдинова [2], И.Б. Баширова [2: 256–268], З.Ф. Ахатова [2] и др.

Однако эти исследования осуществлены по разным методикам и по сути являются разноаспектными и разрозненными. Здесь можно выделить монографическую работу Г.С. Исмагиловой «Лексика романов Гаяза Исхаки "Нищенка", "Мулла Бабай"» [3]. Обилие подобных работ далеко не означает, что тексты произведений писателя, их языковые особенности исследованы достаточно исчерпывающе. Все исследователи солидарны только в том, что язык Г. Исхаки представляет собой богатый материал для изысканий в самых различных аспектах. Поэтому есть основания говорить, что в аспекте лексикологии тексты произведений Г. Исхаки заслуживают более последовательного и системного изучения.

Язык писателя представляет собой весь массив средств общенародного языка, которые используются писателем в его произведениях. Язык Г. Исхаки в этом плане также очень богат различными лексико-фразеологическими средствами. Так, его произведения насыщены колоритной бытовой лексикой, диалектизмами, этнографизмами, бытовой лексикой, архаизмами, заимствованной лексикой и т.д. и т.п. В выше перечисленных статьях некоторые из этих лексических пластов рассматривались. В данной работе мы рассматриваем использованные автором названия одежды. Эта область лексики в татарском языкознании являлась предметом исследований ряда специалистов, главным образом, диалектологов. Так, следует упомянуть работы Ф.С. Баязитовой [1], Р.К. Рахимовой [11], Д.Б. Рамазановой [8; 9: 43–53; 10, 121–126], Л.Ф. Тухбиевой [12: 50–57; 13] и др.

Г. Исхаки отличается внимательностью к деталям, бытовым мелочам, описанию обстановки и т.п, которая отличается особой, чуть ли не этнографической точностью. Особенно это касается его ранних текстов, где этому способствует и тематика самих произведений. В первую очередь, такая скрупулезность заметна в передаче внешности действующих лиц. Одним из средств достижения такой живости и правдивости в отражении действительности отчасти являются названия одежды. Рассмотрим эту лексику в нескольких аспектах.

Лексика одежды во всех произведениях Г. Исхаки в количественном отношении представлена очень широко. Из семи текстов нами было выбрано несколько десятков разных названий. Обилие и разнообразие лексики данной тематики может быть проиллюстрировано примерами из любого из данных произведений: *Туй өчен атап тектерелгән* ***әдрәс камзулдан, очлы башлы кәләпүштән*** *Садыйк абзый хәзрәтләрне үзе каршы алды.* (Кияү) [5]. *--- иң түргә --- бер таза кеше утырган: өстендә --- кытатмы,* ***манчестермы казаки****, башында ---* ***укалы такыя****, кулында зур гына ---* ***яулык****.* (Остазбикә) [5] и т.п.

В тематическом аспекте названия одежды можно было бы рассматривать в рамках следующих условных групп:

1) Легкая одежда: *җилән, чапан, камзул, казаки, бишмәт, күлмәк, ыштан, чалбар* и т.п. Например: *Әби әйтә: «Мондый* ***чапанны*** *бохар патшасының угылы гына киядер, – ди. – Ул саранҗы», – ди...* (Кәҗүл читек) [5].

2) Теплая верхняя одежда: *чикмән, тун, билле тун, толып* и т.п. Например: *Карт хәзрәт, --- кызын өстендә* ***дублы мужик туны****, кулында* ***ярты аршинлы баригалы****, башында ирләрдән калган* ***мескен бүрекле****, аягында* ***тула оек*** *өстендә юкәдән үреп ясалган* ***башмаклы*** *иттереп күрү хәйран калдырды.* (Остазбикә) [5].

3) Головные уборы: *кәләпүш, чалма, камалы бүрек, мескен бүрек, эшләпә, калфак, яулык* и т.п. Например: *Ул бу көнне --- алды теткәләнгән булса да, арты өр-яңа тора торган әдрәс казакины, --- чиккән* ***кәләпүшне*** *кия иде.* (Сөннәтче бабай) [5].

4) Обувь: *оек, киез итек, читек, калуш, ботинка, кәвеш, штиблет, ката, чәпелдәвек, туфли, башмак, чабата* и т.п. Например: *Шәмси фин абзыйның иске чалбарын,* ***катасын*** *киеп, чалбарларын,* ***оекларны****,* ***ботинкаларын*** *киптерергә элде.* (Ул әле өйләнмәгән иде) [5].

5) Названия тканей: *әдрәс, постау, манчестер, кытат, сәренҗе, француз, сатин, сарпинкә, хәтфә, палатна, берләнтин, кәшимир, тула* и т.д. Например: *Хатынымның өсте-башы сәләмәләнгәнене күреп, бабай унике аршин* ***француз*** *алып кайтып бирде ---.* (Кияү) [5].

6) Материалы, из которых сшиты элементы одежды: *ефәк, җон, киез, кама, данадар, тамак* и т.п. *Башындагы ак* ***данадар*** *бүреге, өстендәге шәһәрчә тегелгән постау җиләне, аякка кигән пөхтә кәвешләрен --- Сәгыйдә бердән күрде.* (Остазбикә) [5].

7) Способ обработки и украшения: *крахмаллы, дублы, укалы, чиккән, челтәрле, чуклы, камалы, каймалы, кырык итәкле, лаклы* и т.п. *Кияү күлмәк-ыштаннарымыз, --- бар:* ***чиккән*** *якалысы да,* ***челтәрле*** *якалысы да, башкан ашкан!* (Кияү) [5].

8) Детали и элементы предметов одежды и обуви: *алъяпкыч, яка, муен бавы, хәситә, сауры, олтан, балтыр, бау, битлек, куныч, балтыр чүпрәге* и др. Например: *Аның* ***саурысы*** *синең апаңның намазлык чигә торган үрнәге кебек чәчәкле була. Өр-яңа читек. Аның* ***олтаны*** *болгар* ***олтаны****, кырыеннан киселгән. Ярып ук киселгән. Үзе кып-кызыл төсле. Кура җиләге төсле кызыл*

*түгел, зияб төсле кызыл. Аның* ***балтыры*** *шадраланып тора, чем-кара.* (Кәҗүл читек) [5].

9) Собирательные названия разных предметов одежды и т.п.: *кием-салым, күлмәк-ыштан, чалма-чапан, сөлге-салфет, читек-кәвеш* и т.д. --- *яулыгы җитәрлек,* ***читеге-кәвеше*** *өр-яңа. Белмим инде, берәр калфак-фәлән генә алмасаң?* (Кияү) [5].

В генетическом аспекте основным пластом данной лексики является, несомненно, общетюркская и собственно татарская. Но и заимствованная лексика использована в значительном количестве и представляет большое разнообразие:

1) Арабизмы: *фәс, җөббә* и т.п. *Башына* ***фәс****, өстенә* ***җөббә****, муенына ак яка куйган, сары бау таккан, үзе читектән яшь кенә бер кеше килеп керә.* (Җан Баевич) [7].

2) Фарсизмы: *сәренҗе/ саранҗы, шәл, кәләпүш* и т.п. *Әби әйтә: «Мондый чапанны бохар патшасының угылы гына киядер, – ди. – Ул* ***саранҗы****», – ди...* (Кәҗүл читек) [5].

3) Русизмы: *барига* и т.п.

4) Европеизмы:

а) заимствования из французского языка: *гетр, капот, жилет, калуш, жакет, пальто, вуаль, ботинка, манжет, шинель, костюм, фрак, камзул,* и т.п. *Анна Васильевна, фин хатынының* ***капотын*** *киеп алып, бөтен эчке-тышкы киемнәрен киптерергә куйды* (Ул әле өйләнмәгән иде) [5];

б) из шведского: *кофта. Марҗаның* ***кофтасы*** *алсу җирлек өстендә җете кызыл юллы материядән иде* (Ул әле өйләнмәгән иде) [5];

в) из английского: *смокинг. Шакирҗан* ***смокинг*** *кия. Ак яка, яшел муен бавы* (Җан Баевич) [7] и т.п.

В произведениях Г. Исхаки широко представлены единицы, перешедшие в настоящее время из активного употребления в пассивный пласт лексики татарского языка и являются архаизмами. Большинство из них представляют собой историзмы, то есть слова и сочетания, означающие изчезнувшие реалии: *тәвәккәл бүрек, чабата, чикмән, казаки* и т.п., например: *Ишектән Шакирҗан керә. Ул кама тоткан туннан. Ягында киез итек, башында* ***тәвәккәл бүрек****, билендә билбау* (Җан Баевич) [7].

Автором используется в текстах произведений большое количество этнографизмов, в частности названий одежды. На наш взгляд, это не случайное, а вполне целенаправленное и продуманное решение автора. Это оправдано и как средство создания местного, деревенского, национального колорита, и как средство оживления, конкретизации, приближения персонажа к читателю.

Выбор характера лексики в каждом отдельном случае, в первую очередь, обусловлен тематикой конкретного произведения. Например, рассказ «Кияү» описывает быт зажиточного татарского крестьянина с его повседневными хлопотами, редкими праздниками, а также с неотъемлемой частью татарской культуры – обычаями и традициями. Так, особое место в рассказе занимают эпизоды подготовки к свадьбе, обмена подарками, угощения гостей и т.п. Следовательно, текст как нельзя больше насыщен соответствующей лексикой, где, наряду с названиями блюд и т.п. этнографизмами, активно использованы названия традиционной одежды. Например: *Туй өчен атап тектерелгән әдрәс* ***камзулдан****, очлы башлы* ***кәләпүштән*** *Садыйк абзый хәзрәтләрне үзе каршы алды.* Или: --- *Садыйк абзыйның кияү бүләгеннән тектерелгән* ***казаки****,* ***чалбарыны****, үзенең мәдрәсәдәге иске* ***җиләнене****, авылларындагы яшь мулладан алган кара* ***бүрекне****, Мәрфуга абыстай биргән өч тәңкәгә алынган* ***читек-кәвешене*** *киеп --- кияү мулла төште* [5]. А в пьесе «Җан Баевич» преобладают западные

заимствования. Например: *Шакирҗан утырган. Аның өстендә* ***фрак, муен бавы*** *ачык кызылдан,* ***жилеты*** *яшел төстә. Аягына ак* ***туфли*** *берлә сары* ***гетр*** *кигән* [7]. Следует отметить, что их употребление продиктовано соображениями не только тематики, но и требованиями стиля произведения, периода создания, эстетических целей автора и других факторов.

Естественно, лексика одежды, использованная автором, не ограничивается приведенными примерами. Однако проанализированный иллюстративный материал, на наш взгляд, вполне достаточен для того, чтобы отразить мастерство Г. Исхаки как мастера слова при выборе и использовании лексических средств татарского языка.

Особенности выбора лексики определенного характера обусловлены и отдельными этапами творчества. Например, известно, что для последнего периода творчества автора характерно использование турецких заимствований. В то же время язык писателя тесно связан с языковым контекстом эпохи. Так, период активного использования европеизмов и русизмов у Г. Исхаки совпадает с таким периодом у других авторов начала XX века, да и всей татарской литературы вообще.

Таким же образом можно было бы продолжить анализ языка писателя на предмет использованных лексико-фразеологических средств, в аспекте литературно-художественной традиции, требований творческого метода и т.д.

В целом, на наш взгляд, тексты произведений Г. Исхаки имеют чрезвычайно большой потенциал для лексикологических исследований, который нельзя считать в достаточной мере реализованным. Подобные исследования важны для характеристики языка Г. Исхаки как писателя, его идиостиля, так как лексический состав является частью индивидуального стиля. Кроме того, богатый лексический материал его произведений может служить основой для изысканий, направленных на изучение писателя как языковой личности.

ЛИТЕРАТУРА

1. Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы: Бирнә һәм кием-салымнар (этнолингвистик, диалектологик концептлар). Казан: ТӘһСИ, 2009. 412 б.

2. Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: Әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2000. 296 б.

3. Исмагилова Г.С. Лексика романов Гаяза Исхаки «Нищенка», «Мулла Бабай»: автореф. дис. ... канд. филол. наук / [Место защиты: Ин-т яз., лит. и искусства им. Г. Ибрагимова АН Респ. Татарстан]. Казань, 2008. 26 с.

4. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда. Т. 1: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908) / фәнни ред.: М. Хәсәнов, Р. Исламов; томны төз., текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзер. Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр. 1998. 399 б.

5. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда. Т. 2: Повестьлар һәм хикәяләр (1909–1918) / томны төз., текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзер. Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр. 1999. 462 б.

6. Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. Т. 4: Пьесалар (1900–1918) / төз. Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр. 2003. 496 б.

7. Исхакый Г. Зиндан. Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре / төзүчесе, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Л. Гайнанова, кереш һәм ахыр сүз авторлары: И. Нуруллин, Һ. Мәхмүтов, Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 671 б.

8. Рамазанова Д.Б. Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте. Казань: ИЯЛИ, 2002. 352 с.

9. Рамазанова Д.Б. Некоторые наблюдения над семантикой слова итәк в татарских говорах // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Вып. 2. Казань: ИЯЛИ, 1995. 146 с.

10. Рамазанова Д.Б. Понятие «одежда» в татарских говорах // Татар теле һәм этносы тарихы мәсьәләләре. Казан: ТӘһСИ, 2000. 176 б.

11. Рахимова Р.К. Профессиональная лексика, относящаяся к ткачеству, одежде, обуви и головным уборам (на материале Заказанья ТАССР): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1975. 32 с.

12. Тухбиева Л.Ф. История изучения названий одежды и головных уборов в тюркологии и татарском языкознании // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Вып. 6. Казань: Фикер, 2003. 158 б.

13. Тухбиева Л.Ф. Лексика одежды и головных уборов в татарском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2006. 34 с.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ПРОЗАСЫНДА ГЕРОЙ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

***И.К. Фазлетдинов** (Уфа)*

В данной статье рассматривается проблема эволюции героя в раннем творчестве Гаяза Исхаки в контексте постепенного перехода автора с позиций просветительского реализма к критическому реализму и изменений его социально-политических и общественных взглядов; анализируется концепция человеческого счастья в ранних произведениях писателя.
**Ключевые слова:** проблема, просветительский реализм, критический реализм, эволюция героя, концепция счастья, трагедия народа, произведение, свобода личности.

This article deals with the problem of the evolution of the hero in the early works of Gayaz Iskhaki in the context of the author's gradual transition from educationalist realism to critical realism and changes in his socio-political and public views; the concept of human happiness in the early works of the writer is analyzed.
**Key words:** the problem, enlightenment realism, critical realism, the evolution of the hero, the concept of happiness, the tragedy of the people, the work, the freedom of the individual.

Бөек әдибебез Гаяз Исхакыйның 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын язучының «дөньяга карашы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әдәби-эстетик зәвыгы, сәнгатьчә фикерләве, әсәрләренең идея юнәлеше, язу стиле» ягыннан фәндәөч чорга бүлеп тикшерү гадәткә кергән:

1. Мәгърифәтчелек дәвере (1897–1904);
2. «Таңчы»лык дәвере (1905–1911);
3. Милләтчелек дәвере (1912–1918) [7: 319].

Аңлашыла ки, һәр чор иҗатының үзәгендә язучының шушы дәвердәге иҗтимагый, әдәби-эстетик карашларын гәүдәләндергән үзенчәлекле герой тора. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның беренче проза әсәрләре авторның мәгърифәтчелек идеалын чагылдырган герой һәм аны борчыган мәсьәләләр тирәсендә формалаша. Шуны әйтергә кирәк, бу герой статик фигура түгел. Әдипнең карашлары үскән саен, ул да сыйфат үзгәрешләре кичерә, аның фикер офыклары киңәя, чынбарлыкка мөнәсәбәте катлаулана. Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897), «Кәләпүшче кыз» (1897), «Бай углы» (1899), «Өч хатын берлән тормыш» (1900), «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) кебек әсәрләре уртак иҗат ысулы – мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылсалар да, алардагы төп каһарманнар үзләренең дөньяга карашлары, күтәргән мәсьәләләренең киңлеге, җәмгыятьне камилләштерү юллары турындагы фикерләре, хәтта ки эстетик идеаллары нисбәтеннән берберсеннән шактый аерылалар.

Әдәбият галиме Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, «татар әдәбиятында мәгърифәтчелек реализмы агымы укыту ысуллары хакында бәхәсләшеп мәйданга чыкты» [1: 155]. Филология фәннәре докторы Ф.М. Хатипов исә укыту мәсьәләләрен әдәбиятта сурәтләүнең ике юнәлештә баруын ассызыклый: «беренчесе – искечә сабак бирүне, ысулы кадимне тәнкыйтьләү; икенчесе – яңача белем бирүнең, ысулы җәдитнең кирәклеген, зарурлыгын раслау»

[8: 273]. Әлеге фикерләрне Гаяз Исхакыйның беренче әсәре – «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897) хикәясенә карата да тулаем кабатларга мөмкин.

Академик М.Х. Хәсәнов күрсәтүенчә, «үзенең темасы белән дә, эчтәлеге ягыннан да бу әсәр әле алда торган сәяси тетрәнүләргә ишарә ясамый, татар тормышында булачак җитди үзгәрешләргә нигез бирми шикелле. <…>. Әсәрдә иҗтимагый тәртипләргә кизәнү дә, социаль проблемалар да, сәяси нәтиҗәләр дә юк. Башлап язучы бары тик аң-белем, тәрбия мәсьәләләрен генә күтәреп чыга» [5: 15].

Хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Хәлим, туган авылында мәдрәсә тәмамлагач, укуын Казанда дәвам итәргә тели. Әнисе Фатыйма һәм укымышлы затлар – Кәрим абзый белән Әсма абыстай ярдәмендә, ул этисе Габдерахманның каршылыгын җиңеп чыгып, аңардан гыйлем эстәргә китәргә рөхсәт ала, хәтта ки этисе улына ун сум акчасын да кызганмый.

Казан мәдрәсәсендә Хәлим яхшы укуы, тәрбиялелеге белән мөгаллимнәре арасында ихтирам казана. Беренче елны ул акча түләп белем алса, икенчесендә түләүдән азат ителәһәм тиздән үзе үк Казанның бер мәктәбенә мөгаллим булып урнаша. Мәдрәсә җитәкчесе Рәшит бай хәйләсе белән аның кызы Маһирәгә өйләнүдән баш тартып, Габдерәхим мөгаллим кызы Галия белән никахка керә һәм бәхетле гаилә кора [5: 31–49].

Шулай итеп, «әсәрнең төп мәгънәсе – кешенең гаиләдә, тормышта бәхетле булуы өчен зарурый шарт – уку, белемле, тәрбияле булу» [5: 15] дигәнгә туры килә. Д.Ф. Заһидуллина билгеләвенчә, биредә «кешенең әхлагы турыдан-туры аның белеменә бәйләп карала» [1: 155].

Хикәядә Гаяз Исхакый «бәхет» төшенчәсен шактый тар – шәхси тормыш һәм гаилә кысаларында гына карый, әлегә гомум милләт, җәмгыять дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Ләкин үзәк герой Хәлимнең, (ә димәк, авторның да), уйфикерләре шул юнәлештә үсә баруын егетнең Казанга китәр алдыннан этисе белән килеп чыккан бәхәсеннән күрергә мөмкин.

«Дөньяда килүдән мәкъсуд (теләк, омтылыш. – *И.Ф.*) – дөньяда гына ничек җитте шулай көн уздыру түгел, бәлки үземез рәхәт яшәп вә башка мөселман карендәшләремезнең дә рәхәт гомер кичерүләренә тырышып вә гайрәт кылып, ахирәт көнендә әбәди мәсгудиятләр (мәңгелек бәхет. – *И.Ф.*) ирешмәктер, болар өчен тәхсиле гыйлемнән башка бернәрсә берлә хасил була торган түгел, шуның өчен дә мәдрәсәләргә барып гыйлем өйрәнергә кирәк» [5: 32], – ди ул. Димәк, Хәлимнең максаты шәхси бәхеткә ирешү белән генә чикләнми, ул гыйлем-мәгърифәт аша барлык «мөселман карендәшләремезне» дә бәхетле итәргә тели. Ләкин, кызганычка каршы, геройның әлеге максаты аның эшгамәлләрендә берничек тә ачылмый, коры вәгазь сату булып кына кала.

Шул ук вакытта, автор Рәхимә абыстай авызыннан барлык мәдрәсәләрнең дә, барлык укыту алымнарының да бер түгеллеге, аларда дөньяви белем бирү һәм тәрбия эше бергә алып барылырга тиешлеге хакындагы фикерләре белән дә уртаклаша. «Менә монда Сәгъди хәзрәт шәкертләре бар, – ди ул. – Алар да шул ук мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кыланып бетәләр, берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең, аларны монда көтеп торалар. Ул, шәкерт булгач та, бары да әдәпле булмый, әдәп өйрәтсәләр генә әдәпле була» [5: 41]. Хәлим биредә белем һәм әхлак камиллеге аша рухи гармониягә, ә димәк, шәхси бәхеткә ирешкән идеаль герой дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин фикеренчә, «җәдитчелек шавы әдәбияты Муса Акъегет, Заһир Бигиевлардан башланса, әдәбиятта ысулы җәдит

Г. Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән башлана» [2: 211]. Галим шушы хикәядән соң язылган «Бай углы», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын берлән тормыш» әсәрләрен идея-тематика, стиль уртаклыклары ягыннан Исхакый иҗатындагы аерым этап итеп бәяли һәм аның мәшһүр «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестенә кадәр дәвам итүен күрсәтә [2: 211]. Санап үтелгән әсәрләрдә үзәк герой җәһәтеннән язучы иҗаты өчен генә түгел, ә бөтен татар мәгърифәтчелек әдәбияты өчен мөһим булган сыйфат үзгәрешләрен күрергә мөмкин. Мәсгуд Гайнетдин билгеләвенчә, «яңа реалистик проза, мәгърифәтчелек реализмына хас идеал гәүдәләнеше, заманының матур максатларына ирешү юлын күрсәтүче, әдәпле, эшчән, сөйкемле үрнәк мулла абзыйлар, сәүдәгәрләр, әдәпле егетләр, гүзәл кызлар образларын үзәккә куеп, бу «алдакчы дөньяда» аларның ничек <…> әүлиядәй саф яшәүләрен күрсәтергә дә өлгерми, Г. Исхакый тормышның интегүле язмышлы Камәрләрен («Кәләпүшче кыз») әдәбият түренә китереп кертә» [2: 212].

Чынлап та, Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» (1897) хикәясеннән соң язылган әсәрләрендәге үзәк геройлар башка мәгърифәтче язучыларның хикәя-повесть каһарманнарыннан шактый үзгә. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестындагы Хисаметдин менла, Закир Һадинең «Җиһанша хәзрәт» повестындагы Хәсән мулла, Риза Фәхретдиновның «Сәлимә яки гыйффәт», «Әсма яки гамәл вә җәза» әсәрләрендәге Сәлимә, Әсма кебек идеаллаштырылган образлардан аермалы буларак, Гаяз Исхакыйның геройлары реалистик планда сурәтләнә. Кеше язмышына белем, тәрбиянең генә түгел, ә җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый факторларның да хәлиткеч йогынтысы язучы тарафыннан татар әдәбиятында беренчеләрдән булып тасвирлана башлый. Бу сыйфат аның һәр героеның язмышына да хас диярлек.

Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» (1897) повестендә Кәримә, ире үлеп, улы Габделәхәтне мәдрәсә интернатына урнаштыргач, теккән кәләпүшләрен Сәлимовлар кибетенә илтеп тапшыру эшен яшүсмер кызы – Камәргә йөкләтеп, аны бер ялгызын ирләр янына чыгарырга мәҗбүр була. «Чыгармый хәле юк! Чыгармаса, акча юк, башка чыгарга кеше юк. Ай, фәкыйрьлекниләр күрсәтә?!» [5: 55] – дип яза автор. Димәк, үзәк геройны һәлакәткә илтүче сәбәпләрнең берсе социаль эчтәлекле, ягъни фәкыйрьлек. Нәтиҗәдә, физик яктан да, мораль-әхлак сыйфатлары да ныгып җитмәгән кыз Вафа исемле бозык приказчикның татлы сүзләренә алданып, сафлыгын югалта; Зөһрә карчык «ярдәмендә» кулданкулга китеп, фәхешханәгә килеп эләгә, яман чир эләктерә; дәваланып чыкса да, җәмгыятьтә үз урынын табалмыйча, элекке шөгыленә кайта һәм ахырда кабат-кабат җенси авырулар белән чирләп, бала тапканда вафат була. Безнең фикеребезчә, Камәрнең трагедиясен, мәгърифәтчеләргә хас булганча, бары тик ана тәрбиясе һәм белем җитмәүгә генә кайтарып калдыру хакыйкатькә туры килми. Юкса автор: «Камәрнең фатирга акчасы, расхутка акчасы юк иде, һәммәсе кирәк! Фатирга акча сорыйлар! Кибеттә кенәгә тулган! Анда акча кирәк иде. Ни эшләсен?.. Кемгә киңәш итсен?.. Кемнән гакыл сорасын – һичкем юк» [5: 68] яисә «Шулай итеп Камәр больнистан аерылды. Ләкин ничек тамак туйдырсын? Кайда торсын? Ни берлә дөньясын кичерсен? <…>. Ике тәүлек буе ашаган юк [5: 74–75]», – дип, героеның авыр матди хәленә кабат-кабат басым ясамас иде. Димәк, әлеге шәхес фаҗигасен рухи сәбәпләр белән бергә, фәкыйрьлек, акчасызлык кебек социаль факторларга таянып та аңлатып була. Кешенең бәхетбәхетсезлеген аның социаль хәле, әйләнә-тирәлек, иҗтимагый тәртипләр белән бәйләү мәгърифәтчелек әдәбияты өчен, чын мәгънәсендә, яңалык иде.

«Теләнче кыз» романының 1901–1907 елларда язылган беренче өлешендә дә үзәк геройның язмышы мәгърифәтчелек реализмына хас традицион схемага

сыешмый, вакыйгаларга янә социаль мотивлар килеп керә. Әсәрнең төп каһарманы Сәгадәт (бәхет. – *И.Ф.*) исемле. Димәк, ул дөньяга бәхетле яшәр өчен килгән. Ата-анасы ярлы гына булсалар да, кызларына тиешле тәрбия һәм белем бирәләр. Ул мулла кызы белән әхирәт була, күркәм гадәтләргәөйрәнә. Шулай итеп, мәгърифәтчелек реализмы калыплары буенча, Сәгадәтнең тормышы имин һәм бәхетле булырга тиеш кебек. Ләкин алай килеп чыкмый. 1897 елны иген уңмый һәм кызның алтмыш яшьлек әтисе Шәрип карт, ачлыктан куркып, гаиләсе белән шәһәргә күчәргә карар кыла. Тик калада аларны беркем дә көтеп тормый. Шәрип карт та, Хөсниҗамал карчык та яшәрләренә урын, тамак туйдырырга эш таба алмыйча, ачлыктан һәм авырулардан үлеп китәләр, ә уналты яшьлек Сәгадәт хәер сорашып көн күрергә мәҗбүр була. Бай углы, «потомственный почетный гражданин» Габдулла Әмирханович Сәгадәтне капкадан капкага йөргән чагында хәерчеләр төркеменнән аерып, аулакка алып керә һәм мәсхәрәли. Нәтиҗәдә, кыз фәхешханәгә килеп эләгә.

Сәгадәтнең фаҗигасен бары тик рухи сәбәпләр белән генә аңлатып булмый. Ул тиешле тәрбия алган, укыган. Ләкин заманның аяусыз чынбарлыгы, кешегә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен җәмгыятьтә шартлар тудырылмавы аркасында, кыз бәхетсезлеккә дучар була. Фәхешханәгә дә аны җан саклап калу ихтыяҗы өстерәп килә, ул анда ачтан үлмәс өчен бара. Күренүенчә, биредә шәхес трагедиясен социаль-иҗтимагый сәбәпләр белән аңлату инде, гомумән, өстенлек ала һәм бу сыйфат язучының мәгърифәтчелек реализмы кысаларын җимереп чыгып, тәнкыйди реализм позицияләренә басуын билгеләп тора. Профессор М.Җ. Сәхапов күрсәтүенчә, әлеге әсәрләрдә хатын-кыз язмышы милләт язмышы белән тәңгәл куела һәм женси тигезсезлек киләчәктә халыкның юкка чыгуының бер сәбәбе булу мөмкинлеге турында кисәтелә. «Хатын-кызны ихтирам итмәгән, аны гаилә учагын саклаучы, балаларга тәрбия бирүче шәхес итеп күрмәгән, рухи үсеше һәм камилләшүе өчен тиешле шартлар тудырмаган милләтнең киләчәге томанлы» [6: 74–75], – ди галим.

Димәк, «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән аермалы буларак, автор биредә үзәк геройларының язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерә, аларның рухи сәламәтлеге гомум милләт киләчәген билгели. Шулай итеп, «бәхет» төшенчәсе «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендәге шәхси бәхет кысаларына гына сыймыйча, гомум милләт дәрәҗәсенә күтәрелә. Язучы бары тик гомум милли бәхеткә ирешкәндә генә, ягъни халыкның һәр вәкиленә җәмгыятьтә үз урынын табарга мөмкинлекләр тудырылганда гына, аерым шәхес үзен бәхетле исәпли ала дигән карашка күчә.

Гаяз Исхакыйның мәгърифәтчелек чоры иҗатындагы герой эволюциясен югарыда анализланган әсәрләрне 1904 елда дөнья күргән атаклы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый-публицистик повесте белән чагыштырма планда тикшергәндә аеруча ачык күрергә мөмкин. Әсәр үзәгендәге каһарман язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерү биредә ярылып ята.

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны «геройсыз әсәр» дип атый [3: 161]. Чынлап та, «XXI гасырның соңгы унъеллыгын тасвирлый башлаганчы, автор сүзне гомуми рәвештә, ягъни тулаем милләт хакында алып бара. Бары тик болгарлар тәмам юкка чыгарга берничә ел калгач кына, әсәргә Җәгъфәр исемле аерым бер шәхес – тарихчы, язучы образы килеп керә» [3: 162]. Фоат Галимуллин фикеренчә, «әлеге әсәрдә Җәгъфәр чын мәгънәсендә үзәк образ түгел, бәлки ул – автор күтәргән мәсьәләләрнең олылыгын һәм әһәмиятен тагын да көчәйтү өчен хезмәт итә торган сәнгать чарасы» [3: 162].

Шулай итеп, Җәгъфәр образы повестьта милләт символы булып хезмәт итә. Ул – гомумиләштерелгән образ. «Соңгы болгар»ның Болгар хәрәбәләрендә манара астында калып һәлак булуы да очраклы түгел. Дәүләтсез халыкның киләчәге юк – бу үлемнән килеп чыккан төп нәтиҗә шул. Җәгъфәрнең борынгы Ватанында манара астында калуы да милләтнең һәлакәтенә, беренче чиратта, ул үзе сәбәпче икәнлегенә ишарәли. Хәер, автор ишарәләп кенә калмый, әсәргә керешендә бу сәбәпләрне – биш «манигы тәрәккый»ны атап үк уза. Болар исәбенә, беренчедән, тормыш тоткасының иске фикерле руханилар кулында булуы; икенчедән, мәктәп-мәдрәсәләрнең аз санлылыгы, булганнарында да уку-укыту процессының тиешле югарылыкта алып барылмавы; өченчедән, милләткә хезмәт итүчеләрнең фәкыйрь булып, тамак хакына эшләве; дүртенчедән, урыс мәктәпләрендә укымау, ә димәк, дөнья мәдәниятеннән читләшү; бишенчедән, башкарган эшләрнең нәтиҗәсезлеге, башлау-ташлау h.б. керә [5: 154–159]. Ягъни әсәрдә тасвирланган вакыйгалар язучының иҗтимагый һәм фәлсәфи карашларына иллюстрация вазыйфасын үти. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның өчтән ике өлеше патша цензурасы тарафыннан киселеп, бары тик 1990 нчы елларда гына олуг галимебез Миркасыйм Госманов тарафыннан табылып, яңадан гыйльми әйләнешкә кертелүе дә [4: 200–240] повестьның заман чынбарлыгына, милләт сагында торырга тиешле дин әһелләренә, акчаларын халык файдасына тотар урынга, «курчак туйлары» үткәреп, җилгә очырган татар байларына, Русиянең колониаль сәясәтенә гаепләү акты булып яңгыравын күрсәтә. Язучы милли инкыйразга каршы көрәшкә бар гомерен багышлады.

Шулай итеп, Гаяз Исхакый иҗатындагы мәгърифәтчелек чоры озакка сузылмаса да, андагы үзәк герой катлаулы үсеш, эволюция юлы үтә дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Башта ул «саф» мәгърифәтчеләргә хас булганча, «белем, тәрбия һәм тән камиллеге»нә ия булган идеаль шәхес сыйфатында тасвирланса, соңрак дөньяви, реалистик төс ала һәм әйләнә-тирәлек, социаль-иҗтимагый күренешләр белән бәйләнештә сурәтләнә башлый, кешенең бәхет-бәхетсезлегенең сәбәпләре итеп, аның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе генә түгел, ә җәмгыять тәртипләре дә күрсәтелә; соңга таба исә үзәк герой, гомумән, милләт символына әверелә. Болар һәммәсе дә Гаяз Исхакыйның фикер үсешен, рухи эволюциясен билгеләп тора. Чөнки әсәр – язучының күңел көзгесе ул...

## ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төзүче-авторлар: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина; фәнни редакторлар: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

2. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 319 б.

3. Галимуллин Ф. Эзләнү вакыты: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005. 247 б.

4. Госманов М. Гасырдан – гасырга. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 488 б.

5. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда / беренче томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Лена Гайнанова; фәнни редакторлар: Мансур Хәсәнов, Рамил Исламов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 1 т: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). 399 б.

6. Сахапов М. Золотая эпоха татарского ренессанса: монография. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 319 с.

7. Татар әдәбияты: теория, тарих / төзүчеләре: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.

8. Хатипов Фәрит. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

# ПОСТАНОВКИ ПРОИЗВЕДЕНИЙ Г. ИСХАКИ В ДОРЕВОЛЮЦИОННОМ ТАТАРСКОМ ТЕАТРЕ

***Д.Р. Фардеева*** *(Казан)*

В статье рассматривается процесс постановки произведений Г. Исхаки на сцене дореволюционного татарского театра. Проанализированы наиболее важные спектакли, их особая значимость для зрителя того периода.
**Ключевые слова:** драматург, пьеса, спектакль, театр, артист, комедия.

The article deals with the process of staging G. Iskhaki's works on the stage of the pre-revolutionary Tatar theater. The most important performances, their special significance for the spectator of that period, are analyzed.
**Key words:** playwright, play, performance, theater, actor, comedy.

Гаяз Исхаки – выдающийся татарский прозаик, драматург, публицист, художник и мыслитель, один из основоположников национальной драматургии. Исхаки являлся выразителем не только татарской нации, но смог подняться до уровня требований европейской культуры и мировой цивилизации.

Пьесы Г. Исхаки совершили переворот в татарском театре, дали новый поворот в его деятельности. Драматург видел предназначение театра в просвещении и воспитании народа, придавая ему большое значение. Всего Исхаки написал более 10 драматических произведений и был наиболее плодотворным и репертуарным драматургом дореволюционного татарского театра.

В своих драматических произведениях Г. Исхаки проводил основное требование – требование жизненной правды, идейности, изображение основных явлений действительности в свете тех прогрессивных и демократических идеалов, которые и определили реалистический и обличительный характер его пьес.

В дореволюционном татарском театре были поставлены такие пьесы Исхаки, как «Жизнь с тремя женами», «Брачный контракт», «Учитель», «Общество», «Двое влюбленных», «Учительница», «Зулейха», «Светопреставление».

Г. Исхаки одним из первых авторов обратил внимание на проблему многоженства. Это наглядно видно в его пьесе «Жизнь с тремя женами», написанной в 1900 году. 21 апреля 1906 года татарский театр официально открывается этим произведением. Судя по рецензиям, спектакль имел огромный успех. В спектакле были задействованы такие актеры как Г. Ахметова, Х. Килдебеков, Ш. Абызгилдин, Г. Терегулов, Х. и Р. Таначановы, Р. Канзикиева, Р. Урманцева, З. и Х. Ахметовы. В спектакле многоженство критикуется прямолинейно.

Одним из популярных сюжетов в татарской литературе конца XIX – начала XX века являлась проблема браков по расчету, когда решения за жениха и невесту принимали их родители. Конфликт обычно обострялся при помощи истории о тайном браке возлюбленных. Так, в 1907 году Исхаки пишет драму «Брачный договор», где ситуация такова: молодая девушка недовольна решением родителей. В основу произведения вложены проблемы любви, брака. Впервые эта драма была поставлена в 1908 году в Уральске труппой «Сайяр» в честь бенефиса Сахибжамал Гиззатуллиной-Волжской (Волжская играла роль главной героини Галии). Галие – Гиззатуллиной-Волжской и Ибрагиму – В. Муртазину-Иманскому приходиться пережить множество испытаний, прежде чем они смогли добиться разрешения у родителей. В финале спектакля провозглашалось торжество любви и справедливости. Рецензенты давали высокую оценку этому спектаклю [1: 3]. Следует отметить, что пьеса «Брачный договор» игралась на сцене татарского театра больше остальных пьес Г. Исхаки.

В дореволюционном татарском театре спектакли на современную тему должны были отвечать двум основным требованиям – актуальности и художественности. «Лишь органический сплав этих качеств способен обеспечить успех спектакля», – пишет театровед М. Арсланов [3: 35]. Так, наиболее удачными в этом отношении явились постановки по пьесам Исхаки «Брачный договор», «Учитель», «Общество» и «Светопреставление».

Так, в 1910 году на сцене татарского театра впервые ставится пьеса Г. Исхаки «Учитель», которую он написал в 1908 году. В основе пьесы и спектакля образ Салиха (актер В. Муртазин-Иманский), посвятившего себя просвещению народа. Но Салих – Муртазин-Иманский не смог до конца остаться преданным выбранному пути. После женитьбы, он постепенно начинает отдавать предпочтение мещанскому благополучию и утрачивает высокие идеалы, становясь бездеятельным прожигателем жизни.

Г. Исхаки изображает в своих пьесах и представителей духовенства. В комедии «Общество» (1911) драматург в сатирическом плане показывает, как старцы-кадимисты, пугающиеся всего нового, с подозрением относятся к благотворительному обществу, созданному прогрессивной молодежью с целью оказать материальную помощь детям-сиротам. В пьесе и спектакле «Общество» показано, какой вред приносит обществу вышеупомянутая часть духовенства. Премьера спектакля состоялась в 1911 году.

В том же 1911 году состоялась и премьера спектакля «Светопреставление». В этих постановках зрители уже с первого действия были погружены в самую гущу нечистых и беззаконных плутней и проделок консервативных сил татарского общества. Режиссером спектаклей являлся Г. Кариев. В спектаклях были задействованы такие артисты, как С. Гиззатуллина-Волжская, В. Муртазин-Иманский, К. Шамиль, Х. Кульмамет, Н. Сакаев, Ф. Ильская, З. Султанов, Н. Таждарова, Г. Камал.

Таким образом, в комедиях «Общество» и «Светопреставление» создатели спектакля беспощадно осмеивают тупость, надменность и безнадежную отсталость старцев-кадимистов. На конкретных примерах и деталях в данных постановках разоблачаются консервативные силы татарского общества, которые не приемлют изменений и всеми силами стараются удержать народ в некой духовной резервации. «По мнению драматурга и режиссера-постановщика, в обществе нет прогресса потому, что за народ голосуют мелкие обыватели и жулики, представляющие себя борцами за интересы нации, а, по существу, добивающиеся своих корыстных целей» [3: 36].

Театровед М. Арсланов пишет, что через произведения Г. Исхаки «национальная режиссура нащупывала «болевые» проблемы народной жизни, развенчивала феодальную отсталость, бездуховность, фетиширование материального благополучия, противопоставляла свет тьме, учение безграмотности» [3: 35].

Типизация – одна из основных для понимания художественного метода Г. Исхаки. Его образы наделены огромной типической обобщенностью, и в этом причина силы и длительности их воздействия.

Одной из наиболее популярных пьес Исхаки является трагедия «Зулейха», написанная в 1912 году. В своей трагедии «Зулейха» Исхаки изображает, какие глубокие раны оставила в душе людей государственная политика насильственной христианизации нерусских народов. Пьесу «Зулейха» Исхаки начал писать еще в 1907, а завершил в 1912 году. В этом произведении драматург касается вечно незаживающей раны татарской души. На примере судеб главных героев драмы он с поразительной точностью смог обрисовать совершенное

в отношении татарского народа злодеяние – стремление насильственно ассимилировать, переменить его веру.

Премьера состоялась 17 марта 1917 года. Семичасовой спектакль, в котором участвовало 60 человек, имел огромный успех у зрителей. В спектакле показано, как любящая своего мужа и детей Зулейха (актриса Г. Болгарская) не сгибается перед судьбой и не меняет своих воззрений. Все рецензенты откликнулись на данную постановку обширными рецензиями. Так, Ф. Амирхан писал: «Зулейха, написанная талантливым пером и чуткой душой, представляет зрителю глубокую духовную трагедию. Это не только мощный обвинительный акт против старых властей, но и показатель того, что у нашей нации есть люди, которые готовы идти на самопожертвование ради своей веры. Это документ, доказывающий благородную роль ислама в сохранении нашей целостности» [2: 3]. Что касается Г. Болгарской, то о ее исполнении писали: «Роль Зулейхи была исполнена Г. Болгарской до такой степени хорошо и мастерски, что невозможно было не удивляться огромности разнообразию ее таланта. Во втором и третьем действиях, играя с потрясающим душу реализмом, она привела всех зрителей к катарсису и оставила глубокое неизгладимое впечатление» [4: 4]. Высокую оценку получили и другие артисты – К. Тинчурин (Салимжан), Камал I (Петр), Г. Кариев (Гимади и Габдулла) и другие [4: 4]. В спектакле в образе Зулейхи была показана не только судьба отдельной татарской женщины, но и историческая трагедия всего татарского народа.

Дореволюционный татарский театр, ставя пьесы Г. Исхаки, доказывал свою четкую идейную направленность, выполняя задачи, поставленные перед ним временем и действительностью. Творчество Исхаки составляет в истории татарского театра важнейший этап, потому что он не только создал гениальные произведения, но и дал театру теоретические основы для его дальнейшего развития.

ЛИТЕРАТУРА

1. «Алдым-бирдем» // Казан мөхбире. 1908. 1 декабрь.
2. Амирхан. «Зөләйха» // Кояш. 1917. 19 март.
3. Арсланов М.Г. Татарское режиссерское искусство (1906–1941). Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 336 с.
4. Ахмадиев Ш. «Зөләйха» // Йолдыз. 1917. 22 март.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ – ПУБЛИЦИСТ

***И.Ф. Фаттахов*** *(Казан)*

В статье анализируется девять публикаций известного татарского общественно-политического деятеля, пламенного публициста Гаяза Исхаки из цикла «Будущее России». Г. Исхаки дал полную характеристику социально-экономической ситуации в СССР в 1929 году, досконально изучил «украинский вопрос», ситуацию на Северном Кавказе, историю завоевания большевиками Туркестана и Крыма, бесчинства Иван Грозного после поражения Казанского ханства и о республике Идел-Урал.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, публицист, большевик, Русия, Украина, Кавказ, Иван Грозный, Идел-Урал.

The article analyzes nine publications of the famous Tatar social and political figure, the fiery publicist Gayaz Iskhaki from the cycle «The Future of Russia». G. Ishhaki gave a full description of the socio-economic situation in the USSR in 1929, thoroughly studied the «Ukrainian question», the situation in the North Caucasus, the history of the conquest of Turkestan and the Crimea by the Bolsheviks, Ivan the Terrible's outrage after the defeat of the Kazan Khanate and the Republic of Idel-Ural.
**Key words:** Gayaz Iskhaki, publicist, Bolshevik, Rusia, Ukraine, Caucasus, Ivan the Terrible, Idel-Ural.

Гаяз Исхакыйның «Русиянең киләчәге» [1] дигән мәкаләләрен укыгач, аның тирән белемле тарихчы, кыю сүзле публицист, алдан күрүчән сизгер сәясәтче икәнлегенә тагын бер тапкыр инанасың [2; 3; 4]. Чыннан да, Г. Исхакыйның публицистик теле үткен, зәһәр, бай [5; 6; 7; 8].

«Русиянең киләчәге» тугыз мәкаләдән торган тулы бер циклны тәшкил итә. Мәсәлән, аның 1929 елда елда язылган беренче мәкаләсендә сүз СССРдагы гомуми икътисадый-сәяси вазгыять турында бара. Биредә Г. Исхакыйның, гомумән, большевизмны сөймәгәнлеге, большевикларны яратмаганлыгы, хәтта аларны күрә алмаганлыгы сизелә.

Шул ук вакытта автор 1917 елдан соң Россиядән Европага мөһаҗирлеккә киткән сәяси көчләргә шактый тулы характеристика биргән.

Аларның берсе – монархистлар икән. Иске түрәләр һәм хәрбиләр Россия императоры Николай I нең оныгы бөек князь Николай Николаевич (1856–1929) тирәсендә берләшкәннәр.

Аннары калдык-постык демократик партияләрне санап китә. Чыннан да, кадетлар партиясен оештыручы Павел Николаевич Милюков (1859–1943) һәм кадетларның лидеры Пётр Бернгардович Струве (1870–1944), октябристлар лидеры Александр Иванович Гучков (1862–1936), шулай ук трудовиклар, уң эсэрларның фиркаләре мөһаҗирлектә СССРдагы большевизмга каршы сәяси көрәш алып барганнар.

Өченче урында аз санлы социалистлар партиясе тора, ләкин аларның фиркасе өч-дүрт төркемгә бүленгән, мәсәлән, сәясәтче, публицист Виктор Михайлович Чернов (1873–1952) группасы.

Болардан соң Г. Исхакый меньшевикларны, «Евразия» агымы тарафдарларын да телгә ала.

Икенче мәкаләсендә Исхакый украиналыларның руслардан аерым бер милләт икәнлеген, нинди тарихка ия булуын язып уза, Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соң Украинадагы катлаулы вазгыятьне тасвирлый, мөһаҗирлектәге украин мөһаҗирләренең өч төрле партиясенә бәяләмә бирә. Аның бу мәкаләсе бүгенге Украинага бәйле рәвештә хәзерге заманда да актуаль яңгырый.

Г. Исхакый украиннарны Русиядә яшәгән башка милләтләрнең иң зуры дип яза. Украиналылар үзләрен 45 миллион чамасы дип әйтсәләр, большевиклар аларны 31 миллионнан артык дип хисаплаган. Исхакый украин халкының үз фикерен хакыйкатькә якын итеп саный, шуңа күрә 45 миллион санын хуплый һәм аларның Мәскәүгә кушылу тарихын сөйләп үтә. 1654 елда үз теләге белән, үзләренең милли хокукларын саклау шарты белән, ягъни гаскәр, мал-мөлкәт эшләрендә һәм гетман сайлауда мөстәкыйль булу шарты белән, Мәскәүгә кушылганнар. Ләкин ул килешүне Мәскәү тиздән оныткан һәм тора-бара Украина бер колониягә әверелгән. Бу золымга каршы украиннар берничә тапкыр баш күтәрә, мәсәлән, 1709 елда Мазепа восстаниесе. Һәр баш күтәрүдән соң украин халкы милли хокукларын югалта гына барган: 1764 елда аерым хөкүмәтен югалткан, 1775 елда үз гаскәре бетерелгән, ә 1876 елда патша Россиясе украиннарны аерым милләт итеп танымый башлаган, украин телендә мәктәп, тәрбия эше һәм китап басу тыелган.

Г. Исхакый фикеренчә, украин халкы үзенең каны, гореф-гадәте, тарихы вә теле ягыннан великорусларга охшамаган. «Этнография ягыннан төрек-татар берлә слау (*славян. – И.Ф.*) халыкларының кушылуыннан килеп чыккан бер милләттер. Мәдәният ягыннан да Аурупа мәдәниятенә поляк вә немесләр васитасы (*арадашлыгы. – И.Ф.*) берлә бәйләнгән» [1: 14], – дип яза. Телләре славян булса да, ди Исхакый, великорус теленә тәмамән башка булган аеры юлдан хәрәкәт итәдер. «Халыкның табигате, гореф-гадәте дә (халык әдәбияты,

музыкасы, җыры, көе вә биюе) великоруссларныкыннан артыграк, төрек-татарга якынрак. Боларны руска бәйләгән бер генә йеп бар – православныйлык» [1: 14].

Украин халкы үз телендә укытылмыйча руслаштырылган һәм поплар ярдәме белән миллиге югалтылган. Ләкин бу эшләр беренче карашка уңышлы күренсә дә, һичбер нәтиҗә бирмәде, ди Исхакый. Чөнки кайбер украин зыялылары руслашса да, миллилек хисе бөтенләй үлмәгән. 1917 елда Февраль революциясе булгач та, украин милләте үз хокукын даулап мәйданга чыккан, милли гаскәр оештырган, Вакытлы хөкүмәткә буйсынмый торган милли идарә төзегән, Мәскәүдә Учредительное Собрание куылгач, бәйсезлек игълан иткән. Ләкин 1920 елда, белгәнебезчә, большевиклар Петлюраны җиңгәч, милли Украинаны бөтенләй буйсындыралар.

Украина хакындагы мәкаләсен Г. Исхакый болай тәмамлый: «Обжәктив уларак (*объектив буларак. – И.Ф.*) каралса, Украина истикъляленең (*бәйсезлегенең. – И.Ф.*) бөтен кирәкле нигезләре салынган, терәкләре корылган вә яңа дәүләтнең яшәве өчен бөтен хәзерлекләр эшләнгән хәлдәдер. Шуның өчен мөстәкыйль Украинаның рәсмән яши башлавы бер вакыт вә заман мәсьәләсе генәдер. Большевикларның бу көн Украинага каршы иткән кысынкылыклары руслык ноктасыннан һичбер файда бирмиячәктер. Беренче форсатта мөстәкыйль Украина мәйданга чыгачактыр вә яшәячәктер!» [1: 17].

Автор өченче мәкаләсен Кавказ хәлләренә багышлый. «1917 ел революциясеннән соң үзләренең Русиядән аерылыгын вә үзлеген иң нык аңлаган халык, шөбһәсез, Кавказ милләтләре булгандыр» [1: 18], – дип яза Г. Исхакый. Ул иң элек Көньяк Кавказга кергән Азәрбайҗан, Гөрҗестан (Грузия) вә Әрмәнстандагы вазгыятьләрне аерым-аерым тасвир кыла. Большевикларның Азәрбайҗанны, Әрмәнстанны, Гөрҗестанны хәйлә юлы белән һәм көч кулланып басып алганнарын тәфсилләп яза.

Мәкаләсенең беренче һәм соңгы өлешләрендә Төньяк Кавказны да, аерым алганда, Дагстанны, мәшһүр Шамилне искә ала. Большевиклар Төньяк Кавказны көчсезләндерү өчен аның идарәсен Ростов-на-Дону шәһәренә күчергәннәр һәм «Төньяк Кавказ ягы» (Северокавказский край) дип атаганнар.

Г. Исхакыйның дүртенче мәкаләсе – Төркестанны русларның басып алуы, ә 1918–1919 елларда большевизм гаебе белән Төркестанда булган «искиткеч» ачлык (Г. Исхакый язганча, 2 000 000 кеше ачка үлгән!!!), большевикларның Бохара һәм Хива ханлыкларын бетерүе турында. Нәтиҗәдә борынгы төрки ханлыклар урынына Бохара Халык Җөмһүрияте төзиләр. Ләкин большевиклар хөкүмәте «Бохара Халык Җөмһүриятенең саклануын рус гаскәренә тапшырдылар. Бу вакытка кадәр исән калган Бохара мәмләкәтен баштанаяк таладылар. Җефәк чапан кимәгән рус солдаты вә ияренең астына палас салмаган рус атлысы калмады. Төркестаннан Самарага чаклы булган тимер юл буе бөтенләй Бохарадан таланган мал берлә тулды. Бохара чапаны, Бохара паласы, Бохара җефәге, Бохара көмеш келәме бөтен базарларны, талчукларны тутырды» [1: 28].

Бишенче мәкалә дүртенчесенең дәвамы. Анда сүз Госманлы дәүләтенең сәяси һәм хәрби эшлеклеләре Әнвәр (1881–1922) вә Җәмал (1872–1922) пашалар, Бакуда 1920 елда III Интернационал үткәргән һәм Григорий Зиновьев җитәкчелек иткән Көнчыгыш халыкларының I съездында катнашып, Әнвәр пашаның чыгыш ясавы, гражданнар сугышы елларында большевикларның Җәмал пашаны Тифлистә үтерүләре, Төркестанда Әнвәр пашаның басмачылар ягына чыгуы һәм үтерелүе, басмачылыкны җиңү хакында бара.

1924 елда Төркестанның тарихи исемен онытырыр өчен Төркестанны Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Таҗикстан, Каракалпакстан, Кыргызстанга аерым-аерым бүләләр һәм бу җөмһүриятләрне СССРның әгъзалары итеп кабул

итәләр. 1925 елда бу бүленеш рәсми рәвештә тәмамлана: Таҗикстан өлкә генә булып калдырыла, 7 миллион халыклы Казакъстан җөмһүрияте оештырыла, ә Каракалпак өлкә дип атала башлый. Шулай итеп, Төркестан исеме бөтенләй бетерелә, ди Исхакый.

Алтынчы мәкалә Кырымга багышланган. Исхакый Кырымның төрки дөнья өчен әһәмиятен башка төрки өлкәләрнекеннән зуррак дип санаган. VIII гасырдан башлап төркиләр кулындагы Кырым гасырлар буе төрки илләрне үзара бәйли торган күпер булып исәпләнгән. Идел елгасыннан, Хәзәр (Каспий) диңгезеннән йөзеп килгән сәүдә көймәләре Дон елгасының кичүеннән үтеп, Кырымга барганнар, аннары Кырым портларыннан Кара диңгезгә юл тотканнар. Европадан китерелгән товарлар шул ук юлны үтеп, Идел-Уралга, Себергә, Төркестанга, Кытайга кадәр барып җиткән. Чыңгыз ханның оныгы Хубилай хан (1215–1294) заманында сәүдәгәрләрнең Судактан Пекинга 40 көндә барып җитә алулары атлы юлның гаять тә тиз эшләве белән аңлатыла. Алтын Урда империясе чорында Кырым автономияле өлкә булса да, географик урыны буенча төрки дөньяның урта бер җирендә торган. Алтын Урда җимерелгәч барлыкка килгән Кырым ханлыгы Госманлы төрекләре белән Идел-Урал татарларын бер-берсенә бәйләгән. 1520 елда Шаһгали Казан тәхетенә утыргач, Кырымның олуг ханы Мөхәммәдгәрәй туганы Сәхибгәрәйне Казанны коткарырга җибәргән. Казан татарлары Сәхибгәрәйне хан итеп сайлаганнар. Кырым белән Казан берләшеп, Мәскәү кенәзлегенә һөҗүмнәр ясагач, Мәскәү кенәзләре татар ханнарына салым түләргә тагын мәҗбүр ителгән. Ул чорда Кырым госманлылар белән килешү төзегәнгә күрә, Казан да Кырым аша Госманлы дәүләтенә бәйләнгән булган. Г. Исхакый сүзләренчә, шуңа күрә Казанда Госманлы патшаларын Ислам хәлифәсе дип танып, 1520–1566 елларда Госманлы империясе солтаны булган Сөләйман Кануни заманында исемнәренә хөтбә (мактау) укый башлаганнар.

1783 елда Россия империясе Кырымны басып алгач, Казан белән Кырым арасындагы мөнәсәбәтләр яңадан дәвам итүен, элемтәләр урнашуын Г. Исхакый әйтеп үтә. Аннан соң автор XIX гасырның II яртысында Кырымда туып яшәгән, төрки дөньяда бик якты эз калдырган Исмәгыйль бәк Гаспринскийны зур хөрмәт белән искә ала.

Алга таба 1917 елдан соңгы кискен үзгәрешләрне тасвирлап уза. Кырым татары большевикны танымады, дип яза Исхакый. 1917 елның 24–26 ноябрендә уздырылган милли корылтай Кырымның мөстәкыйльлеген игълан иткән, Милли Кырым хөкүмәтен төзегән, хөкүмәтнең рәисе итеп Чәләбиҗиһан Чәләбиевне, хәрби министр итеп Җәгъфәр Сәедәхмәдне билгеләгән. Ләкин аларны танымаган Севастопольнең большевик матрослары бераз вакыт узгач, Ленин кушуы буенча 1918 елның 5 гыйнварында Кырым татар гаскәренә һөҗүм иткәннәр, ә 13 гыйнварда җиңгәннәр. Большевиклар татар офицерларын бик күп үтергәннәр, кулга алынган Чәләбиев тә Севастополь төрмәсендә 23 февральдә вәхшичә үтерелгән. 1918 елның язында немецлар Кырымны да алганнар һәм большевикларны куганнар. Төркиягә хәрби ярдәм сорарга киткән Җәгъфәр Сәедәхмәд туган иленә кире кайткач, немец гаскәре командующие аны тоттырып яптыра, бераздан чыгара һәм Кырым хөкүмәте төзергә рөхсәт бирә. Хөкүмәт рәисе итеп поляк татары генерал Мөхәммәд Сөләйман улы (Мацей Александрович) Сулькевич (1865–1920) куела.

Мәкаләдә шулай ук 1918 елның 11 ноябрендә алманнарның Кырымны ташлап китүләре, Деникинның Кырымны кулга төшерүе, берникадәр вакыттан соң аның җиңелүе, ә французларның Деникин урынына Врангельне куюлары һәм аның да җиңелеп 1921 елда Истанбулга качуы, һәм большевикларның Кырымны яулап алулары һ.б.ш. вакыйгалар бәян ителә...

1928 елда Совет хөкүмәте Кырым АССРның Үзәк Башкарма Комитеты рәисе, кырым-татар дәүләт эшлеклесе Вәли Ибраһимовны (1888–1928) кулга алдыра һәм Кырым хөкүмәтен сигез ел буе җитәкләгән большевик кешене милләтчелектә гаепләп аттыра. Мәскәү җибәргән комиссарлар Кырымның 10 меңнән артык ул-кызларына бер ел эчендә төрле җәза бирәләр, 1 меңнән артык кешене Кырымнан сөрәләр. Шул рәвешле, зур сәяси репрессия Кырым татарларын канга батыра.

Җиденче мәкаләсе «Русиянең киләчәге (Идел-Урал)» дип атала. 1391 елда Аксак Тимер (1336–1405) Алтын Урда ханы Туктамышка (1350–1406) һөҗүм иткәннән соң Алтын Урда империясе таркала. Аксак Тимер Бөек Болгарны яндыра. Алтын Урданың колонияләре саналган Бөек Мәскәү кенәзлеге һәм Бөек Литва кенәзлеге үз мөстәкыйльлекләрен кире кайтарып алалар һәм үзләренчә яши башлыйлар, ә 1480 елда Бөек Мәскәү кенәзлеге тулы мөстәкыйльлеккә ирешә.

Ханзадәләр арасында тәхет өчен көрәш башлана. Төрле татар кабиләләре арасында кабилә низагы җанлана. «Бу заманның кыска күзле балалары үзләренең шәхси файдалары өчен милли дошманнары русларга сыгынырга хәтле барып җитте» [1: 40]. Имансызлары исә рус көчен татарның эчке сәясәтенә катыштырганнар, тәхеткә утыру өчен туганнарының канын агызганнар. Нәтиҗәдә Чыңгыз хан төзеп калдырган Алтын Урда империясе Казан, Әстерхан, Кырым, Нугай, Себер ханлыкларына бүленгән.

Чыңгыз нәселеннән булган Олуг Мөхәммәд хан XV гасырның I яртысында Казан ханлыгы дигән дәүләт оештыра. Ул татарның элекке данын кайтарыр өчен Бөек Мәскәү кенәзлегенә каршы сугыша һәм Мәскәүдән тагын салым түләтә башлый. Олуг Мөхәммәд хан бөтен Идел-Урал төбәген берләштерергә уйлаган, ләкин тәхет низаглары моңа киртә булган. Милли бәйсезлекнең тәмен белгән рус кенәзләре, татарларның таркаулыгыннан файдаланып, Казанның көчәюенә таяк тыкканнар. Вакыты җитеп, җае чыккач, Иван Грозный Казанны басып ала. Артында союзнигы булмаганга күрә Казан ханлыгы җиңелә. Бербер артлы Әстерхан, Нугай, Себер ханлыклары да «русның чабатасы астына» [1: 41] авалар. Димәк, XVI гасырның II яртысында Идел-Уралда татар дәүләтләре бөтенләй бетерелә.

Аннан соң автор Иван Грозныйның Казан татарларына каршы эшләгән вәхшилекләрен язып уза, ә Екатерина II нең татар халкына карата кылган яхшылыкларын мактап телгә ала. «Әби» патша Ислам динен рәсми таный, аның указы буенча 1788 елда Оренбургта Россия империясе мөселманнарының Духовное собраниесе оеша. Данлыклы Казан, Кышкар, Эстәрле, Чистай мәдрәсәләре нәкъ менә шул чорда ачыла һәм аннары алар гаять күп мулла, мөгаллим, галим-голяма әзерләп чыгара. Татар сәүдәгәрләре Идел-Уралда, Себердә барлык юлларны тотканнар, Россия базарларында икенче урында торганнар. Казан Мәскәүдән кала бай калага әверелгән, Шәһри Казаныбыз Идел-Урал төбәгенең гыйльми, мәдәни мәркәзе булып өлгергән. Шулай итеп, XVIII йөз ахырында Идел-Урал буенда татарларның үзенә күрә бер дини мохтарияты (автономиясе) барлыкка килә.

«Русиянең киләчәге (Идел-Урал 2)» дигән сигезенче мәкаләдә сәяси публицист фикеренең асылы болай: Россия империясе патшаларының татарларга каршы үткәргән сәясәте нигездә үзгәрмәде, аларның төп максаты халкыбызның миллилеген югалтып, руслаштырып бетерү иде. Мәсәлән, Иван Грозный һәм Алексей Фёдорович татарны көчләп чукындырсалар, император Александр III халкымның барлык милли сыйфатларын бетереп, рус рухы белән сугаруда күргән. Шуңа күрә 1917 елгы революцияләрдән соң татарлар арасында иске патшалык дәверенә кайтырга теләүчеләр һич тә булмый.

«Русиянең киләчәге (Идел-Урал җөмһүрияте)» исеме астында басылган тугызынчы мәкаләсендә, автор уенча, «әлегәчә сөйләнгән сәяси гамәлләр аңфикер тәрбиясенә зур хезмәт итсәләр дә, бер дәүләт корыр өчен болар гына җитми. Бер милли дәүләт мәйданга китерү, аны яшәтер өчен берничә уңышлы шартларның бергә җыелуы кирәк» [1: 53]. Ул моның өчен өч шарт санап китә:

1) халыкның дәүләтле булырга теләге һәм аны идарә итәргә әзерлеге булу;

2) халыкның билгеле бер җирдә күпчелекне тәшкил итүе;

3) халыкның дәүләт корган җире икътисадый, сәяси яктан аерым яшәвенә ярдәм итәрлек хәлдә булуы.

Шулай итеп, мәшһүр публицист Гаяз Исхакый Идел-Урал республикасын төзергә татар халкында әлеге өч шарт та бар дигән төп нәтиҗәгә килә.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 10 том: Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 527 б.

2. Фәттахов И.Ф. Гаяз Исхакый мәкаләләрендә Русиянең киләчәге мәсьәләләре // Татар журналистикасы – халыкка хезмәттә: Фәнни мәкаләләр җыентыгы. Төрки телле мәгълүмат кырында татар журналистикасының урыны һәм роле. Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары. 20 ноябрь, 2015 ел / төзүче-мөхәррирләр: В.З. Гарифуллин, Р.Л. Зәйни. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2016. Б. 190–196.

3. Фәттахов И. Исхакый мәкаләләрендә Россия // Мәдәни җомга. 2016. 19 февраль.

4. Фәттахов И. Гаяз Исхакый мәкаләләрендә Русиянең киләчәге // Идел. 2016. № 1. Б. 35–41.

5. Гарифуллин В.З. Каләм көче (татар журналистларының текст төзү осталыгы). Беренче китап. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. 128 б.

6. Гарифуллин В.З. Милләт мәгълүматтан башлана: фәнни мәкаләләр җыентыгы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008.87 б.

7. Гарифуллин В.З., Мубаракзянова А.З. Публицистическая деятельность Гаяза Исхаки. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2014. 108 с.

8. Garifullin, V.Z., Sabirova, L.R. Publicistic creativity of Gayaz Iskhaki in emigration // Journal of Language and Literature. 2016. 7(3). P. 272–276.

# ЯЗЫКОВЫЕ ТРАНСФОРМАЦИИ В РУССКОМ ПЕРЕВОДЕ РОМАНА ГАЯЗА ИСХАКИ «МУЛЛА БАБАЙ»

***К.С. Фатхуллова*** *(Казань)*

Статья посвящена исследованию языковых трансформаций при переводе на русский язык романа известного татарского писателя Гаяза Исхаки «Мулла бабай», а также выявлению лексических и грамматических особенностей переводного художественного произведения. Каждый язык обладает своими внутренними формами, что должно быть учтено переводчиком. Проанализированный нами материал дает возможность утверждать, что в данном переводе превалируют грамматические трансформации, которые вызваны структурными отличиями в двух языках.
**Ключевые слова:** татарский язык, перевод, трансформации, художественный текст.

The article is devoted to the study of linguistic transformations in the translation into Russian of the novel of the famous Tatar writer Gayaz Iskhaki “Mulla Babaі”, as well as the identification of lexical and grammatical features of the translated artwork. Each language has its own internal forms, which must be taken into account by the translator. The material analyzed by us makes it possible to assert that in this translation grammatical transformation is prevalent, which are caused by structural differences in two languages.
**Key words:** Tatar language, translation, transformation, artistic text.

Художественный текст обладает рядом особенностей, отличающих его от других видов текста, которые при переводе претерпевают определенные изменения, т.е. лексико-грамматические трансформации. В.В. Сдобников

характеризует художественные тексты, как «опирающиеся на образное отражение мира и существующие для комплексной передачи разных видов информаций – интеллектуальной, эмоциональной, эстетической, – а также обладающих функцией эмоционального воздействия на читателя» [1: 349]. Следовательно, при работе с художественным произведением переводчику необходимо учитывать языковые и культурные особенности разных народов, их традиции и обычаи. Переводчик должен владеть в совершенстве и языком оригинала, и языком, на который переводится литературное произведение, а также уметь находить в процессе творческой деятельности необходимые лексико-грамматические соответствия. От переводчика художественного текста требуется полное понимание литературного стиля переводимого произведения, творчества автора. При литературном переводе необходим учет традиционных стилевых навыков и требований, свойственных исходному и переводимому языкам. Знакомство с переводами классика татарской литературы Гаяза Исхаки на русский язык дает возможность констатировать, что очень часто татарское слово может оказаться шире или уже, колоритнее или бледнее, экспрессивнее или холоднее, абстрактнее или конкретнее, употребительнее или реже, чем русское в семантическом плане. Лексические единицы языка оригинала обычно бывают связаны с иными смысловыми ассоциациями, так как языковая картина мира контактирующих народов имеет существенные различия. В результате мы наблюдаем, что переводное художественное произведение соединяет различные народы и является достоянием двухкультур – культуры, породившей идею, и культуры, ее принявшей. Важными в этой связи нам представляются слова С.В. Тюленева о том, что «от потерь при передаче формы оригинала страдают в основном тексты, относящиеся к тем функциональным стилям, которые тяготеют к художественному, где форма не менее важна, чем выражаемое ею содержание, а иногда полностью преобладает над ним» [2: 21].

В качестве объекта данного исследования нами был выбран роман Г. Исхаки «Мулла бабай», который был опубликован в 1910 году. Основной целью писателя при создании данного произведения было знакомство читателя с обыденной жизнью дореволюционного медресе, обсуждение проблем просвещения и воспитания молодёжи [3]. В 2015 году увидел свет русский перевод романа, выполненный А.И. Килеевой-Бадюгиной [4]. Как заметила автор перевода в предисловии к этой книге, уникальность романа заключается в том, что никто из татарских писателей не изображал жизнь медресе столь увлекательно и подробно.

Как считают многие исследователи в области перевода, трансформация заключается в изменении формальных (лексические и грамматические трансформации) или семантических (семантические трансформации) компонентов исходного текста при сохранении их формации, предназначенной для передачи [5: 63]. Основная проблема, с которой сталкивается переводчик при передаче референциальных значений, выраженных в исходном тексте, – это несовпадение круга значений, свойственных единицам исходного языка (ИЯ) и переводящего языка (ПЯ). Когда соответствие той или иной лексической единице одного языка в словарном составе другого языка полностью отсутствет, принято говорить о безэквивалентной лексике, т.е о реалиях. Независимо от того, стремится автор к этому или нет, художественный текст всегда отражает особенности того народа, представителем которого автор является и на языке которого он пишет, и того времени, в котором он живет. Кроме того, писатель может сознательно вводить в свой текст национально-культурные реалии, ассоциирующиеся к тому же с определенным временем в жизни народа. Иссле-

дователи включают в понятие реалии наименования отдельных предметов, понятий, явлений быта, культуры, истории данного народа или данной страны. Для их передачи используются разные способы. В качестве примеров на транскрипцию и транслитерацию можем привести следующие лексические единицы: *җәмәгать, мәдрәсә, мулла, мөәзиннәр, хәзрәт, намаз, Алла, абзый, Каргалар болыныннан, шәкерт, хәлфәләр, Әбүбәкер, Вәрәка, читек, җилән, сандык, комган, камәт, ясту намазы, казый, мәхдүм, кәләпүшләр, чәкчәкләр, чәйдәшләр, җәдид, сәке, кәвеш, сарыф, бәлеш, абыстай, авыл, кош телләре, юачалар* [3: 221–229]; *джамагать, медресе, мулла, муэдзины, хазрат, намаз, Аллах, абзы, с луга Каргалар, шакирд, хальфы, Абубакир, Варака, ичиги, джилян, сундучок, кумган, камат, яста, кадий, махдум, каляпуши, чак-чак, чайдаши, джадид, саке, кавуши, сарыф, балиш, абыстай, аул, кош-теле, юача* [4: 174–181] и т.д. Как видно, транскрпиция и транслитерация в этих случаях являются единственными способами передачи безэквивалентной лексической единицы татарского языка при переводе на русский язык.

Интерес вызывает также передача фразеологических единиц, так как фразеологический корпус контактирующих языков разнообразен в семантико-стилистическом и лексико-грамматическом отношениях. Основным источником фразеологии в романе являются обороты разговорно-бытового характера, которые обогащают язык оригинала. Например: *...буның котыны алды* [3: 225] – *пугали его* [4: 178]; *...күзенә яшь тыгылды* [3:230] – *слезы навернулись на глаза* [4: 183]; *...куркудан теле бәйләнде* [3:230] – *от страха язык не слушался* [4: 184]; *...кулы бик әче*[3:231] – *рука у него тяжелая* [4: 184]; *...эче пошып* [4: 232] – *его охватила тоска* [4: 186]; *...тыңлаудан күңеле кайтты* [3: 233] – *он перестал слушать* [4: 186]; *...сугыш кызды* [3: 234] – *бой кипел* [4: 187]; *...күзләренә утлар күренде* [3: 234] – *из глаз посыпались искры* [4: 187]; *...бурычта калмаенчы* [3: 237] – *не остался в долгу* [4: 190]; *...шатлыкка күмелә* [3: 238] – *светились радостью* [4: 191]; *...пылау исе борынны яра, авызга сулар агыза башлады* [3: 240] – *аромат плова ударил в нос* [4: 193]; *...дүрт күз белән көтәргә әзерләнде* [3: 241] – *он с удивлением озирался по сторонам* [4: 194]; *...бөтен шәкерт тын алмаенча тыңлый* [3: 243] – *шакирды завороженно следили* [4: 196]; *...эче тырнарга тотынды* [3: 248] – *засосало под ложечкой* [4: 200]; *...тамырларыннан салкын ага торган булды* [3: 256] – *холодом сковывало все его существо* [4: 208] и т. д. В результате сопоставительного анализа можно прийти к выводу о том, насколько неоднозначным является перевод устойчивых сочетаний одного языка на другой. Как видно из приведенных примеров, для передачи национальной, а также культурной специфики татарских фразеологических единиц, в большинстве случаев переводчик прибегает к методу подбора частичного фразеологического эквивалента.

В ходе лингвистического анализа оригинала и переводамы выявили ряд грамматическихтрансформаций, которые обусловлены различиями в словообразовательных, морфологических и других категориях татарского и русского языков. При переводе учитываются как похожие, так и отличные морфологические средства языков, более того, переводчик должен уметь правильно и адекватно передать те языковые категории, которых не существует в языке перевода. Замены части речи или одной грамматической формы на другую являются самыми распространенными видами морфологической трансформации. Подобные замены обычно вызваны различными нормами сочетаемости в татарском и русском языках. Остановимся на примерах: *Кечкенә малайларның кычкырып сөйләүләренә хәлфәләр ачуланмый, аларның башмак киеп чыгуларына да кыйнамый...*[3: 239] – *Никто не одёргивает мальчишек,*

*которые забывшись, разговаривают слишком громко, и не наказывает тех, кто забыл снять башмаки...* [4: 192]. В данном примере имена действия *сөйләүләренә* и *киеп чыгуларына* переведены на русский язык глаголами изъявительного наклонения *разговаривают, забыл снять.* Приведем еще один пример*: Җырлаучыларга һава иркенләнеп киткән кеби булды* [3: 242]. *Певцы, казалось, свободно вдохнули, вобрали в себя свежего воздуха* [4: 195]. Здесь субстантивированное причастие настоящего времени *җырлаучыларга* переведено существительным *певцы. «Бар инде, бетте» – дип чыгарып йибәрә башлыйлар* [3: 244]. *Хромой и еще один шакирд принялись разгонять мальчишек: «Всё! Конец! Спать идите!»* [4: 197]. Глагол *бетте* из текста оригинала передается в переводе существительным *конец.* В следующем примере мы видим, как глагол передается в переводе наречием: *Алай да бит, кызым, тыш яктыра* [3: 252]. *И все же, дочка, во дворе уже светло* [4: 205] и т.д.

Учитывая специфику временных форм татарского глагола, переводчик очень часто транслирует глаголы настоящего времени в форму прошедшего времени. Например: *Вакыт соңая. Күргәннәр, ишеткәннәр белән Хәлимнең башы тула. Скрипкә тавышына колак тына. Авыз ачыла, иснисе килә башлый* [3: 245]. *Время было позднее. Казалось, голова Халима распухла от всего увиденного и услышанного, от пения скрипки заложило уши. Рот то и дело широко открывался, сдержать зевоту не было сил* [4: 198]. *Шуның белән көн үтә, кич була,, кич үтә, иртә була, ләкин Зөһрә абыстай һаман үлми иде* [3: 263]. *Так прошёл день, настал вечер, потом наступил следующий день, а Зухра абыстай все еще была жива* [4: 215] и т.д.

Говоря о грамматических трансформациях,следует отметить и о способе объединения предложений, при котором синтаксическая структура в оригинале преобразуется путем соединения двух простых предложений в одно сложное, а также о методечленения предложения, при котором синтаксическая структура предложения в оригинале преобразуется в две или более предикативные структуры переводимого языка. В исследованном переводном произведении наблюдались примеры и на эти способы.

В заключение хотелось бы подчеркнуть, что главная цель перевода – достижение адекватности. Основная задача переводчика при достижении адекватности – умело произвести различные переводческие трансформации для того, чтобы текст перевода как можно более точно передавал всю информацию, заключённую в тексте оригинала при соблюдении соответствующих норм переводящего языка. В процеессе данного исследования мы пришли к выводу, что переводчику удалось сохранить всю яркость и индивидуальную особенность стиля Гаяза Исхаки, дух той исторической эпохи, которую он описал в своем романе. Переводчик полно изложил мысли автора на русском языке и проникся глубочайшим уважением к личности писателя.

ЛИТЕРАТУРА

1. Сдобников В.В. Теория перевода: учеб. для студ. лингв. вузов и фак-в ин. яз. М.: АСТ: Восток – Запад, 2007. 448 с.

2. Тюленев С.В. Теория перевода: учебное пособие. М.: Гардарики, 2004. 336 с.

3. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 3 том / төз. Л. Гайнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 448 б.

4. Исхаки Г. Нищенка. Мулла-бабай: романы [пер. с татар. А.И. Килеевой-Бадюгиной]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 352 б.

5. Миньяр-Белоручев Р.К. Теория и методы перевода. М.: ЧНУЗ Моск. Лицей, 1996. 207 с.

# М. ЮНЫС ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА МИЛЛӘТ ПРОБЛЕМАЛАРЫНЫҢ ҮСТЕРЕЛЕШЕ

***Л.Р. Фәезова*** *(Казан)*

В статье автор рассматривает особенности публицистики М. Юныса. Выявляется, что основная тема его публицистической деятельности тесно связана с проблемами национального характера, которая берет начало от публицистического наследия начала XX века. При диахроническом сопоставлении тематическая и проблемная сторона публицистики М. Юныса наиболее близка к наследию Г. Исхаки. В отличие от публицистики Г. Исхаки, М. Юныс изначально придерживается принципа историзма, в нем присутствует наряду с глубоким анализом своеобразный синкретизм, порой выходящий за рамки традиционого публицистического жанра, тем самым приближая его творчество к литературному жанру.
**Ключевые слова:** М. Юныс, Г. Исхаки, публицистика, национальная тема, синкретизм.

In the article the author considers peculiarities of journalism M. UNISA. It is revealed that the main theme of his journalistic activity is closely related to the problems of national character, which originates from the journalistic heritage of the early twentieth century. In the diachronic comparison of the thematic and problematic aspect of journalism M. Yunisa closest to the legacy of G. Ishaki. Unlike the journalism of G. Ishaki, M. Yunis initially adheres to the principle of historicism, it is present along with a deep analysis of a kind of syncretism, sometimes going beyond the traditional journalistic genre, thus bringing his work to the literary genre.
**Key words:** M. Yunis, G. Ishaki, journalism, national theme, syncretism.

Татар милли публицистик мирасының зур бер өлешен XX йөз башында татарның яңа реалистик әдәбиятына нигез салучы Гаяз Исхакый алып торса, XX гасырның 60–80 нче елларында бу юнәлешне М. Юныс каләме үстерә. Бу ике шәхес төрле заманда яшәсә дә, публицистикаларындагы тема уртаклыгы, милләт киләчәгенә йөз токан мәсләкләре аларны татар әдәбияты тарихында, диахрон ысул ярдәмендә янәшә кую мөмкинлеге бирә. Г. Исхакыйның публицистик иҗаты илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыять, самодержавие һәм совет хакимиятенең тоталитар режимы шартларында татар халкының үсеш проблемалары белән тыгыз бәйләнгән. Ул мәкаләләрендә Совет хөкүмәтенең милли сәясәт өлкәсендәге гамәлләрен тәнкыйтьли, милли мәгариф, әдәбият-сәнгать мәсьәләләре, шулай ук туган тел үсеше проблемалары турында яза [1]. Шушы ук темаларны М. Юныс публицистикасында да ассызыклап күрсәтергә була, алай гына да түгел, темалар кабатланса да, алар яңа эчтәлек белән баетыла, тарихилык принцибы нигезендә фактографик материаллар белән тулылана, дидактик-методик катламнан аналитик тирәнлеккә чыга. Кайбер фәнни хезмәтләр билгеләп үткәнчә, Исхакый публицистикасында тарихилык принцибы ул эмиграциягә киткәч барлыкка килсә [2], әлеге принцип Юныснең публицистик эшчәнлегендә башта ук төп билгеләүче фактор буларак формалаша.

Әдәби иҗатында да еш кына публицистик алымнар кулланырга яраткан М. Юныс ни өчен 90 нчы елларда публицистик жанрларга өстенлек бирә башлый соң? Язучының жанр трансформацияләре мотивларын XX гасырның 90 нчы еллардагы милли азатлык хәрәкәтенең көчәюе белән дә, шулай ук аның 1963 елда рус телендә яза башлап, әкренләп татарча язуга күчүе, тора-бара әдәби иҗатында миллилекнең тирәнәюе белән дә аңлатырга мөмкин. Равил Рахмани М. Юныснең «Альбатрос язмышы» дигән публицистик язмалар китабына кереш сүзен «Кыйблабызга тугрылык» дип атый, ул бу үзгәрешләрне сүз ирегe белән бәйләп карый: «Үзенең активлыгы белән алай бик нык аерылып тормаган бу иҗат нәкъ менә сүз ирегe туганнан соң –

1990 елларда бөтен тулылыгы белән ачылып китте. Кыска гына вакыт эчендә ул тормыш чынбарлыгының иң хәтәр ялганнарын ачып салган, дөнья сәнгатенең асылын аңларга өйрәткән, дөнья әдәбияты белән янәшәдә татар әдәби үсешенең мескенлеген һәм үсеш перспективаларын күрсәткән язма-мәкаләләр бирде» [3: 6]. Публицистика, бер үк вакытта журналистиканың бер төре буларак, заманы өчен бик тә мөһим иҗтимагый резонанска ия. Публицистика өлкәсе бүгенге көнгә юнәлеш бирүдә хәлиткеч әһәмияткә ия булган көнүзәк мәсьәләләрне үз эченә ала [4: 746].

Шулай да М. Юныс публицистикасын без күбрәк әдәби жанр кысаларында карау яклы. Автор, мәсәлән, «Альбаторос язмышы» китабындагы мәкаләләрендә фокуска нинди дә булса вакыйга яки күренешне җыймый, ә шул вакыйга яки күренеш җәһәтеннән иҗтимагый дискурс үткәрә, аңа карата субъектив анализ ясый. Үзенең тәҗрибәсеннән, фикерләү биеклегеннән торып, автор теге яки бу иҗтимагый күренешкә үз фикерен белдерә, моның өчен ул аңа гына хас булган әдәби алымнар куллана, мәсәлән, көзгеле алымнар, метафоралар аша фикерен үтемле итеп җиткерүгә ирешә. Югарыда атап кителгән китапка кергән шул ук исемдәге мәкалә, мисал өчен, Роберт Әхмәтҗановның «Хәтер елгасы» дигән шигырьләр җыентыгын анализлауга багышлана. Беренче карашка, ул гап-гади әдәби тәнкыйть мәкаләсе булып тоелырга мөмкин. Чынлыкта исә автор җыентыкка филологик анализ ясамый, китап аша Роберт Әхмәтҗанов дигән шагыйрьнең тулаем иҗатындагы образлар системасын иләк аша үткәреп, андагы кошлар образларына аерым туктала. Кошлар образы кергән һәр очракка тарихи-метафорик мәгънә салынганлыгын ачыклап, ул шагыйрь иҗатындагы кошлар татар милләтен символлаштыра, дип бәяли. Иҗади интерпретация алымына мөрәҗәгать итеп, үзенең диңгезчелек тәҗрибәсенә таянып, ул татар милләтен, аның милләт өчен көрәшүче улларын альбатрос кошлары белән чагыштыра: «Альбатрос тәкъдирен кичергән иҗат талантларын эзләп әллә кайларга барып та йөрисе юктыр. "Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым... Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш; Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым". – Шушы әрнүле, үзәкләрне өзәрлек сүзләрдә шул ук альбатрос язмышы сурәтләнмәгәнмени? Ә соңгы көннәрендә Һади Такташка суд ясап, селәгәй комсомолларның аны мыскыллаулары шул ук альбатроска һөҗүм түгелмени?» [5: 378].

«Измаил паркы», «Ирек һәм коллык турында», «Конгресс», «Колшәриф Казаны» һ.б. күпсанлы мәкаләләрендә М. Юныс милли мәсьәләләрдә һәрнәрсәнең асылына кадәр казып төшәргә яратучы, һәр фактны төрле яклап кат-кат дәлилләп баручы, детальләргә игътибарлы публицист буларак ачыла. Мәсәлән, «Исәбәт» (1990) мәкаләсендә ул мондый параллельләр китерә: «Беренче тапкыр Европа илләре белән танышкан чакта мине бер гаҗәп нәрсә тетрәндерде: без бит озак еллар дәвамында капиталистик илләр изүче һәм изелүче сыйныфлардан тора, ә бездә сыйныфлар юк, дип ышанып йөрдек. Менә шул сыйныфлы капиталистик илләрнең тимер юлларында бары тик ике төрле вагоннар йөри: беренче класс һәм икенче класс. Аларның аермасы утыргычларның бәрхет яки дермантин белән тышлануында. Ә безнең сыйныфсыз илебездә вагоннар алты төрле: гомуми, комбинированный, плацкарт, купе, люкс һәм халыкара вагоннар. Урыс совет әдәбиятына хезмәт итүче язучыларны исә, сыйныфлар революция вакытында юкка чыгарылган булса да, берничә катламга бүләргә мөмкин» [5: 32].

Шул ук вакытта бу мәкаләләрдә әдәби, фәлсәфи, психологик һәм публицистик башлангычларның кушылуы – синкретизмны да билгеләп үтәргә кирәк. Иҗтимагый әһәмияткә ия булган фактлар еш кына рефлексия аша үтә, кайчагында фәлсәфи яссылыкка да чыгарыла. Мисал өчен, М. Юныс экзистен-

циализм фәлсәфәсен нәкъ татар өчен уйлап чыгарылган кебек, дигән фикер әйтә («Альбатрос язмышы»). «Бабаларымның кабер ташларына карап» (1992) язмасында ул мистик-мифологик катламда фикер йөртә, фикер сөрешенә татар халык әкиятләренә тартым хикәяләү мотивлары килеп керә.

Үзенең тәнкыйтендә М. Юныс абстракт төшенчәләр белән эш итми, конкрет фактлар тирәсендә генә сүз куерта, аның геройлары – конкрет кешеләр. «Алдакчылыкка табынучылар» мәкаләсендә ул күренекле галим Вил Мирзаяновның әхлакый батырлыгы турында гына язып калмый, ә идеология тудырган мифларга демифологизация ясый, идеология кулланган коралларның ни дәрәҗәдә чынбарлыктан аерылган булуын фаш итә.

Без М. Юнысның публицистикасы турында тулаем миллият проблемаларын фәлсәфи ноктадан яктырту, ачык билгеләнгән гражданлык позициясе, яшәп килгән идеологиягә карата оппозициядә булуы һәм энциклопедик дәрәҗәдәге эрудиция белән аерылып тора, дип әйтә алабыз. Юнысның публицист каләменә теманы җентекле өйрәнү, детальләргә дикъкатьле булу, туган халкының чынбарлыгы турында тирән фикер йөртү хас. Хәтта коры фактларга гына тукталганда да, ул үзенең менә дигән прозаиклык сәнгатен эшкә җигә, фантазиясенә ирек бирә, олы тәҗрибәсенә таяна.

XX гасыр публицистикасы дискурсын Г. Исхакый һәм М. Юныс мисалында караганда, милләт проблемаларын тирән яктырту, татар милләтенең фикерләү рәвешен, менталитетын билгеләргә омтылу милли публицистиканың бер үзенчәлеге итеп карала.

ӘДӘБИЯТ

1. Гали Б.Т. Общественно-политическая деятельность и исторические взгляды Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. ист. наук // Режим доступа: http://www.dissercat.com/content/obshchestvenno-politicheskaya-deyatelnost-i-istoricheskie-vzglyady-gayaza-iskhaki – Дата обращения: 23.03. 2018.

2. Мубаракзянова А.З. Публицистическая деятельность Гаяза Исхаки: автореф. дис. ... канд. филол. наук // Режим доступа: http://cheloveknauka.com/publitsisticheskaya-deyatelnost-gayaza-ishaki – Дата обращения: 23.03.2018.

3. Рахмани Р. Кыйблабызга тугрылык / М. Юныс.Альбатрос язмышы: Милли публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 6 б.

4. Энциклопедический словарь. Том XXVa. СПб.: Типо-Литографія А. Ефрона, Прачешный пер., 1898. № 6. С. 746–747.

5. Юныс. М. Альбатрос язмышы: Милли публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 384 б.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАТЛАРЫНДА ЯКТЫРТЫЛГАН КАЙБЕР ӘДӘБИ ПРОБЛЕМАЛАР

***Ф.Г. Фәйзуллина** (Казан)*

Среди большого творческого наследия Гаяза Исхаки значительную роль играют его личные письма. Они представляют большую историческую ценность, поскольку в них отражены его жизненные моменты и душевные переживания. В данной статье рассматриваются литературные проблемы, которые запечатлены в его письмах, адресованных М. Горькому и Ф. Амирхану.
**Ключевые слова:** Татарская литература, текстология, эпистолярный жанр, Гаяз Исхаки, Фатих Амирхан.

Among the great creative heritage of Gayaz Iskhakiy, his personal letters play a significant role. They are of great historical value, because they reflect his life and emotional experience. This article deals with literary problems, which are embodied in his letters addressed to M. Gorky and F. Amirkhan.
**Key words:** Tatar literature, textology, epistolary genre, Gayaz Iskhakiy, Fatih Amirkhan.

Гаяз Исхакыйның безнең көннәргә килеп җиткән шәхси хатлары гаять зур әһәмияткә ия. Алар, Г. Исхакыйның көндәлек тормыш мәшәкатьләрен, теләк-омтылышларын, эзләнүләрен үзләренә туплаган кыйммәтле кульязмалар буларак, әдипнең тәрҗемәи хәленә яңа фактлар өсти, аның әдәби процесстагы урынын һәм шул чор атмосферасын ачыграк күзалларга ярдәм итә.

Г. Исхакый күпкырлы шәхес буларак, аның хатларында да төрле эчтәлектәге фикерләр урын алган. Хатларның күбесе Г. Исхакыйның сәяси-иҗтимагый эшчәнлеген чагылдырса, әдәби проблемаларны яктырткannары да шактый. Аларда Г. Исхакый үзенең иҗади планнары белән уртаклаша, аерым мәсьәләләр тирәсендә уйлана.

«Тәрҗемәи хәле»ннән күренгәнчә, Г. Исхакый әбисе Мәхфүзә остазбикә һәм атасы Гыйлаҗетдин хәзрәттән төркичә укуда тәҗрибә туплаганнан соң, дәрес буларак, гарәп һәм фарсы китапларына күчә. Әлеге әдәбиятлар тәэсирендә аңарда гарәпчәгә аеруча якынлык хасыйл була. Казан мәдрәсәсендә укыган елларында бөтен укымышлы яшьләрнең, шул ук вакытта Г. Исхакыйның да, төрек әдәбияты белән кызыксынуы аның иҗади тормышында зур роль уйный. Казандагы Татар укытучылар мәктәбенә укырга кергәннән соң исә ул рус әдәбиятына, теленә якынлык хис итә һәм аның әсәрләрендә «рус әдәбияты техникасының тәэсире» сизелә. Үзе билгеләп үткәнчә, госманлы әдәбияты аңарда әдәби әсәрләр язуга кызыксыну уята, төп этәргеч була. Шул рәвешле, балачактан ук башка халыкларның әдәбиятлары белән кызыксынган Г. Исхакый алар тәэсирендә дөньяга килгән үзенең әсәрләрен дә татар булмаган укучы аудиториясенә чыгарга тиеш, дип исәпли һәм 1910 елның азагында моңа җитәрлек нигез бар дип санап, үзенең 1908 елда басылып чыккан «Алдым-бирдем» пьесасыннан башларга уйлый. Г. Исхакый әлеге пьесаны М. Горькийга укытуларын һәм берәр җыентыкка кертүләрен үтенеп, «Знание» нәшриятына юллый, җавап ала алмагач, турыдан-туры М. Горькийның үзенә мөрәҗәгать итә: «...Мин үземнең тарафтан шуны әйтүне кирәк саныйм: әсәрнең сәхнә җәһәтеннән кимчелекләре, бәлки башка җитешсезлекләре дә бардыр, шулай булуга да карамастан ул хәзерге татар әдәбиятының нинди үсеш ноктасында булуын һәм уянып килә торган татар халкы алдында нинди бурычлар торуын аңлау нисбәтеннән рус укучыларына кызыклы булыр иде. Әгәр дә Сезгә, Европа әдәбияты нигезендә тәрбияләнгән кешегә, кайбер типлар ачылып җитмәгән, эшләнеп бетмәгән булып күренсә, бу автор гаебеннән түгел, ә татар тормышының чынбарлыгыннан килә: анда әле яңа кешеләр тәмам калыпланып җитмәгән. Тәрҗемә өчен ник бу әсәрен сайлап алдым дигәндә, ул көнкүреш вакыйгаларының сурәтләнеше ягыннан иң характерлысы...», – дип яза (Константинополь. 1910 ел, 19 декабрь) [1: 10]. М. Горький Г. Исхакыйның теләген хуплап, «Алдым-бирдем» белән бергә тагын берничә хикәясенең тәрҗемәләрен һәм берничә татар әдибенең әсәрләрен алып, «Татар мәҗмугаи әдәбиясе» исемендә бер җыентык бастырырга әйди. Г. Исхакый үз тарафыннан әлеге тәкъдимне кабул итә һәм Фатих Әмирханга бу җыентыкка кемнәр керергә тиешлеге турындагы уй-фикерләре белән мөрәҗәгать итә: «...мин, син, Габдулла, Сәгыйтьтән башка рус галәменә күрсәтерлек әсәр ияләре юк, дип уйлыйм. Шул фикеремдән мәҗмуганы дүрт кешенең әсәрләрендән генә төземәкче булам. Син ни фикердә? Бәлки мин белми торган, мин читдә торып, күрми калган берәр мөхәррир, шагыйрь бардыр. Булса, шул кем?» – ди (Мезень. 1912 ел, 13 июнь) [1: 15]. Г. Исхакый фикеренчә, әлеге җыентыкка керергә тиешле әсәрләрдән, кирәк шигырь булсын, кирәк нәсер булсын, татар исе, татар тормышы аңкып торырга тиеш. Ул, дөньялар үзгәреп китү ихтималы барлыгын истә тотып, бу эшнең мөмкин кадәр тиз баш-

карылырга тиешлеген искәртә. Г. Исхакый үзенең алдына куелган максатка ирешү юлында бу мәҗмуганың, шөпһәсез, шул юлда салынган күперләрнең иң беренчесе һәм ныгы булачагына ышана. «Бәлки максатка ирешә алмабыз. ...Ләкин без шул мәҗмуга белән русларга каршы: «Ниндиләр менә бездә бар! Без дә торырга телимез, тормакчы да буламыз. Яшәргә юллар да эзлимез. Табылганнарын аллы-гөлле маяклар утыртып, киңәйтеп, турайтып, алдагы юлга чыкмакчы буламыз», – дип кычкырырга телимез. Вә шуны ишеттерергә тырышамыз», – ди (Мезень. 1912 ел, 5 август) [1: 18].

Г. Исхакый да, Ф. Әмирхан да Г. Тукайның җыентыкка керергә тиешле әсәрләреннән «Шүрәле»не мәслихәт күрәләр һәм тагын бер-ике кыска-кыска шигырьләрен тәрҗемә итүне кирәк саныйлар. Г. Исхакый Г. Тукай иҗаты хакында: «Габдулланың арый белмәгән шигырләренең һәммәсендән яңа пешкән арыш икмәге исе чыгып тора, һәммәсендән үзенә-үзе ышану нуры балкып тора», – ди (Мезень. 1912 ел, 5 август) [1: 18].

Г. Исхакый Ф. Әмирханның үз әсәрләрен татарларның руслашкан тормышыннан алынган дип, читкә кагып, ташларга теләве белән риза түгел. Ф. Әмирханны ул үзе яза торган дәвернең чын баласы, шул дәвернең психологиясен иң белә торган мөхәррире, дип саный. Шуның өчен әсәрләренең кайсысын тәрҗемә иттерү хакында ул аерым бер фикер әйтә алмый. Ә бары: «“Урталык”ны укып чыктым. Матур башлана, ләкин “Хәят” аңардан “тормышлы”рак, аңардан куәтлерәк тел берлән язылган. “Татар кызы”н мин әллә кайчан укыганга, хәзер аның хакында бер сүз дә әйтә алмыйм», – кебек гомуми сүзләр белән генә чикләнә.

Шушы елларда язылган «Сөю-сәгадәт» хикәясеннән чыгып, Г. Исхакый Галимҗан Ибраһимовны әле татарларның беренче мәҗмугаларына керү хакын казана алмый, дип саный. Г. Ибраһимов һәм Шәриф Камал әсәрләренең үзенә иң ярамаган ягы итеп, алардан өметсезлек сизелеп торуны күрсәтә. «Менә шул “өмидсезлек” минем карашымдан татар әдәбиятына “елавык” руслардан кертелгән татар рухына аз гына да охшамый торган кирәкмәгән зарарлы буяу гына. Безнең тормышыбызда (минем күрүемчә) мескинлек, булдыксызлык хәятның үзәге түгел. Ара-тирә очрый торган бәхетсезлек кенә. Шуның өчен шул ноктага иң зур нокта итдереп торып, бөтен тормышны шундан ага торган зәһәрле буяуга буярга тырышу, минемчә, зур хата», – ди (1912 ел. 5 август, Мезень) [1: 18].

Үз әсәрләренә килгәндә, «Алдым-бирдем», «Сөннәтче бабай», «Кияү», «Шәкерт абый» һәм тагы берәр кыска хикәяне мәҗмугага кертүне күздә тота. Аларны тәрҗемә иттерү өстендә эш алып бара.

1913 елның 10 февраль хатында Г. Исхакый М. Горькийга гыйнвар ахырында Каприга аның исеменә кульязмалар җибәрүе хакында хәбәр итә. Бу тәрҗемә әсәрләрне бастырудан Г. Исхакыйның беренче максаты татар булмаган укучыларны үзенең әдәби характерын югалтмаган әсәрләр белән таныштыру булса, икенчесе: «алардан кайда басылуы мөһим түгел, Чехиядәме, Германиядәме, Франциядәме, билгеле күләмдә акча гына китерсен» [1: 24]. Әсәрләрне тәрҗемә итеп бастыру Г. Исхакый өчен авыр матди хәлдән чыгуның бер юлы булып тора. Халыкка хезмәт итүче интеллигенциянең саны аз булган чорда үзенең матди хәлен яхшырту өчен генә физик хезмәткә күчүне Г. Исхакый халык һәм мәдәният алдында җинаять булыр, дип саный. Әсәрләрен бастырудан килгән акча аның төп яшәү чыганагына әверелә.

М. Горькийга язган соңгы хатларында Г. Исхакый үзендә 30 биткә якын басылмаган татар телендәге әсәрләренең төп нөсхәләре һәм кайберләренең рус теленә тәрҗемәләре дә барлыгын әйтә. Г. Исхакыйның шул вакытта кулында булган әсәрләренең кайберләре «Көз», һәм «Өйгә таба» повестьләре, «Локман Хәким» хикәясе, «Дулкын эчендә», «Ике ут арасында» пьесалары дип,

икеләнмичә әйтергә була. Күрәсең, М. Горький ярдәме белән дә аларны бастыруы мөмкин булмаган. Чөнки, 20 нче еллар башында язылган әлеге әсәрләрнең кайберләре бары 30 нчы еллар ахырында гына дөнья күрә.

М. Горькийның 1910–1912 елларда җәмәгатьчелекне Россиядәге милли әдәбиятлар белән таныштыру өчен рус телендә җыентыклар чыгару уе да, кызганычка, тормышка ашмый, татар әдәбияты җыентыгы чыкмый кала.

Төрмәдән-төрмәгә, сөргеннән-сөргенгә җибәрелгән һәм ниһаять чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган Г. Исхакыйның, әлбәттә, татар әдәбияты белән тулысынча танышып барырга мөмкинчелеге булмый. Ул күп вакытта дуслары-фикердәшләреннән алынган мәгълүматлар белән эш итә. Яңа әсәр мәйданга чыгу белән аларны соратып алырга тырыша. «Туган җирдән читтә яшәү, котылгысыз рәвештә, әсәрләр язуга тәэсир итә, – дип яза ул үзенең М. Горькийга Константинопольдан язган 1911 елның 3 март даталы хатында, – агымнан калышасыз яки кирәгеннән артык алга йөгерәсең. Миңа, халыктан чыккан, аңлы рәвештә халыкка якын темаларга һәм халык телендә язуны, әкренләп, әмма тайпылышсыз рәвештә халыкны Европача яшәргә һәм фикерләргә әйдәүне үзенә максат итеп куйган язучыга, аннан ерак булырга ярамый. Бу халыкны үзенең яңа әдәбияты, яңа идеяләре белән бәйләүче җепне өзәргә мөмкин. Минем фикерем шундый: әгәр дә безнең яшь әдәбиятыбыз туган туфрактан даими дым алып тормаса, нигезсез йорт кебек, кырыс татар тормышына яраксыз булачак, беренче сәяси салкыннарда ук эссез юкка чыгачак» [1: 12]. Ф. Әмирханга язган 1912 елның 13 июнь хатында да әлеге фикерне куәтләп: «Татар агымының эчендә булмаганга, кая таба дулкын киткәнен, кая таба су үзәк салганын, нинди елгаларны ташлап, яңа юл алганын күрә алмыйм. Шул күрә алмау минем өчен, әлбәттә, нык авыр, бик уңайсыз», – ди [1: 15]. Г. Исхакыйның иң курыкканы – чит җирдә яшәп, үз халкыннан аерылу, халыкның аны аңлаудан туктавы. Һәм ул ялгышмый.

Г. Исхакый татар халкының көченә ышана. Ул «Русиядә руслардан кала иң зур милләт без булганга,.. Русиядә еврейләрдән кала иң тырыш милләт без булганга... безнең көчемез һәм хакымыз бар» дигән девиз белән яши. Һәм татар әдәбиятының төп үзенчәлеге итеп, аның еламавын, ныклыгын, тазалыгын, тормышның начарлыгына, зәһәрлегенә күкрәкне киереп, җырлый-җырлый каршы чыгуын күрсәтә.

Г. Исхакыйның кулъязмаларында аның башка халыклар әдәбиятына, бигрәк тә рус әдипләреннән М. Горький, И. Тургенев, Л. Толстой, А. Чеховка карата мөнәсәбәтен чагылдырган кызыклы гына фикерләр табарга мөмкин. Әлеге хатларда Г. Исхакый укучыга үз хисләре, кичерешләре, бәя-хөкемнәре, теләк-омтылышлары булган иҗат кешесе буларак ачыла.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхаков М.Г. Әсәрләр: 15 томда. 14 том: хатлар һәм автобиографик язмалар [томны төз., текст. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Ф. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 479 б.

## АЯЗ ГИЛЯЗОВ И ГАЯЗ ИСХАКИ

***М.М. Хабутдинова*** *(Казань)*

В статье систематизированы отзывы А.М. Гилязова о наследии Г. Исхаки. Сформирован блок цитат их писем и статей, где изложены взгляды классика татарской литературы на творчество известного общественного деятеля. Подробно проанализирована антиутопия Г. Исхаки «Лукман хаким» и выявлена ее роль в художественном мире романа А.М. Гилязова «Давайте помолимся!». Доказано, что автор

произведения с большим уважением относится к наследию Г. Исхаки и вносит посильный вклад в пропаганду его наследия.
**Ключевые слова:** татарская литература, Г. Исхаки, А.М. Гилязов, «Давайте помолимся!», «Лукман хаким».

The article systematizes the reviews of A.M. Gilyazov about the heritage of G. Ishaki. A block of quotations from letters and articles, which outlines the views of the classic of Tatar literature on the work of a well-known public figure, was formed. The dystopia of Iskhaki «Lukman Hakim» is analyzed in detail and its role in the artistic world of the novel «Let's pray!». It is proved that the author of the work with great respect to the heritage of Iskhaki and makes a contribution to the promotion of his heritage.
**Key words:** Tatar literature, G. Ishaki, A.M. Gilyazov, «Let us pray!», «Lukman Hakim».

А.М. Гилязов (1928–2002) относился к Г. Исхаки (1878–1954) с огромным уважением. С тех пор, как в годы перестройки имя этого великого сына татарского народа вернулось к татарам, его личность и творчество постоянно присутствует в творческом сознании А.М. Гилязова. «В общем, я не был смолоду умнее остальных, по-взрослому не рассуждал, мог и приврать, и приукрасить. Но я, по выражению Гаяза Исхаки, видимо, родился писателем. В поисках новых тайн и событий душа моя улетала на край света, металась, переживала. Богом мне были ниспосланы цепкая память и беспокойный аналитический ум. Спасибо вам, Небеса, тысячу раз спасибо» (пер. Н. Ишмухаметова), – признается художник слова в романе «Йәгез, бер дога!» («Давайте помолимся!») (1991–1993) [3: 58].

В письме к Г. Шарафетдинову от 29 августа 1988 г. он так отзывается о творчестве татарского писателя начала XX в.: «Бәлки Гаяз Исхакый татарның иң күренекле, иң калку бер буыныдыр?! Әмирхан Еники аны үзенең остазы дип саный, мин Әмирханны! Әгәр үз заманында, миңа остазлар кирәк чакта, Гаяз Исхакыйны укып, белеп, сөеп яшәсәм минем офыгым киңрәк булмас иде мени?!» – «Возможно, Гаяз Исхаки принадлежит к поколению самых известных, прославившихся татар?! Амирхан Еники считает его своим учителем, а я – Амирхана! Возможно, если бы в свое время, когда я нуждался в наставниках, в мои руки попали бы книги Исхаки, дарящие радость, превратившиеся в любимые, мой горизонт стал бы шире?!.». А.М. Гилязов отстаивал необходимость вовзвращения татарам утраченного наследия Г. Исхаки. «Без белми калган күпме бөек җаннар бардыр әле әдәбиятләрдә! Үзебезнең Гаяз Исхакыйны кайтармый тору яшьләрдән кемнеңдер юлын кисмәс мени?.. Бәлки менә Ркаил Зәйдуллинга, Г. Моратовка, Нияз Акмаловка да нәкъ ул кирәктер. Татар тарихының Мәгълүм бер чоры өчен җавап бирә алган язучылар юк икән, безнең тарихыбыз өзек-өзек, көтек һәм гарип булып калмый микән?» – «О сколько великих имен из мира литературы остались нам неизвестны! Если мы не вернем Гаяза Исхаки, не обернется ли это тем, что мы перекроем дорогу кому-нибудь из молодых?... Возможно, Ркаиль Зайдулла, Г. Муратов, Нияз Акмалов нуждаются в таком наставнике. Наша история не предстанет ли обрывочной, короткой и уродливой, если не будет писателей, которые могут дать ответы по известному периоду истории?», – высказывает свою озабоченность писатель [4: 258].

В письме к З. Зайнуллину 13.12.1988 г., размышляя о путях возрождения татар, А.М. Гилязов пишет о роли «возвращенной литературы» («Идегей», Гаяз Исхаки) в становлении национального самосознания [10].

В письме к М. Магдиеву татарский писатель делится следующим наблюдением: «Гаяз Исхакый исә татарны аякка баскан, уйлы, фикерле чын кеше, җир баласы итеп күргән, башка милләтләрдә булган барлык сыйфатларны эзләп тапкан. Дәреслекләр төзергә алынган Альберт Яхин бик кызыклы бер

фикер әйтте: “Булдыра алган кадәр Гаяз Исхакый әсәрләре белән таныштым, мәгәр берсен дә мәктәп дәреслекләренә кертә алмадым”, – диде. Мин Альбертка ышандым һәм чиксез сөендем. Дәреслекләргә кертерлек гадәти әсәрләрне җиңел табарбыз, мәктәп кысаларына сыймый торган хөр әсәрләр табу кыен! Гаяз Исхакый татарның традицион тарлыгыннан югарырак менә алган язучы, ул татарда гомумкешелек сыйфатлары тапкан... Гомумән, Г. Исхакый татарның милли вәкилләрен бер баскычка өскә күтәрә һәм сәхнәгә меңгерә» – «Гаяз Исхаки видел в татарах сынов земли, уверенных в себе людей, умных, мыслящих, ему удалось в них найти все качества, характерные для представителей других наций. Альбер Яхин, взявшийся за составление учебников, высказал интересную мысль: “По возможности я постарался познакомиться с творчеством Г. Исхаки, однако ни одно произведение нельзя включить в школьную программу”. Я поверил Альберту и обрадовался. Мы легко найдем простые произведения для школьной программы, а вот найти произведение, не вмещающееся в школьные рамки сложно! Гаяз Исхаки – писатель, сумевшийся вырваться вверх из традиционных для татар рамок, он сумел найти в татарах общечеловеческие черты... Он сумел поднять национальных представителей татар на одну ступень вверх и представить на сцене» [4: 566].

В дневниковой записи от 22.11.1991 г. А. Гилязов проницательно замечает: «Гаяз Исхакыйны да борчыган милләтнең үзәге, нигезе мәсьәләләре. Ул уйланган-уйланган да киләчәкне “Инкыйраз” дип билгеләгән». – «Г. Исхаки беспокоился о сердцевине татарской нации, ее основе. Думал-думал и будушее ее определил как “Конец света”» [11: 2].

В интервью Г. Мурату А.М. Гилязов признается, что пьеса Г. Исхаки «Зулейха» помогла ему осознать весь трагизм татарской истории: «Гаяз Исхакыйның “Зөләйха” пьесасы белән танышканчы мин чукындыруның халкыбызга ничаклы түбәнлекләр, җәбер-җәфалар китерүен аңлап бетерми идем. Империя татарга лаеш шулпасын гел ашатып торган». – «До знакомства с пьесой Г. Исхаки “Зулейха” я, оказывается, до конца не понимал через какие унижения, преследования пришлось пройти татарскому народу. Империя всегда кормила татар лаишевской похлебкой» (подстр. пер. – *М.Х.*) [2]. Эта же мысль встречается и в его статье «Нилэр күрмәде безнең башлар?» [11].

Журналның шул ук санында К. Мотыйгыйның Г. Исхакыйга язган җавабы бирелә. Нашир Г. Исхакыйга хезмәттәшлек итәргә әзер булуы өчен рәхмәтләр укып, «Әлгасрелҗәдид» журналын бастыру эшен гамәлгә кую өстендә армыйталмый эшләргә вәгъдә бирә. Рәшит Ибраһимов, Риза Фәхретдиновларның да журнал эшендә ярдәм итәргә әзер торуларын хәбәр итә. «Әлгасрелҗәдид» битләрендә Гаяз әфәнде әсәрләрен күрергә теләп: «Элегрәк «Бай углы», «Ике гыйшык», «Очрашу», «Кәләпүшче кыз» һәм «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәрләрегезне кабат-кабат укып чыккач, сездәге әдәби сәләтнең гадәттән тыш булганлыгын беләм. Журналыбызның күләме 100 зур биттән гыйбарәт булачак һәм ул айга бер чыгачак. «Теләнче кыз» исемле романыгызны җибәрсәгез, «Әлгасрелҗәдид» номерларының иң беренчесенә урнаштырылыр. [Журналда] хезмәткәр булачак билгеле затлардан кайберләре хәтта цензура бастырырга рөхсәт биргән әсәрләрен җибәрделәр. Сез дә, вакытыгыз булгач, «Теләнче кызы»н җибәрсәгез иде. Яз ахырында үз матбагабыз эшли башлаячак һәм шул вакыттан башлап идарәбез тарафыннаан хатлар кабул ителә башлаячак» дип белдерә [1: 36].

Шулай ук Г. Исхакыйга бастырган әсәрләре өчен биреләчәк гонорар хакы турында да сүз кузгата. «Теләнче» кызы» романы өчен күпме сорасагыз, шуның хәтле акча түләнер, даими рәвештә язып торсагыз, айлык эш хакытүләнер, дип хәбәр итә [1: 36].

Моңа каршы Г. Исхакый К. Мотыйгага тагын бер хат юллый, ул 1905 елның 7 феврале белән даталанган, журналның шул ук 1905 елгы 4 нче санында урын алган. Гаяз әфәнде бу хатында да, К. Мотыйгыйга тәкъдим иткән хезмәттәшлек өчен, зур рәхмәтен белдерә. Журнал һәм гомумән китап нәшер итү эшләре өчен Казан кебек зур шәһәрнең кулаерак булуын күрсәтеп: «Журна-

лыңыз булса да, булмаенча нәшрияткә тотынсаңыз да, Казанга күчү, мәркәзне Казан ясау мәслихәт түгелме? Минем өчен андый эш өчен иң мәслихәте Казан, һәм иң җиңел китап нәшер кылыр өчен, китапны иң очуз (*арзан*) төшерер өчен мәслихәт урын Казан. Үзеңез карарсыз. Монда типография тәэсис итү (*оештыру*), яисә сатып алыныр, монда хәзер сатыла торган типографияләр бар. Уральскига караганда бик җиңел булырга кирәк» дип, К. Мотыйгыйны Казанга күчеп килергә өнди [3: 37].

К. Мотыйгый үз чиратында Г. Исхакыйга тагын бер җавап хаты яза. Бу хат шул ук кулъязма «Әлгасрелҗәдид» журналының 1905 елгы 5 нче санында урын алган. Бу хатында К. Мотыйгый журнал чыгарырга рөхсәт бирмәсәләр, китап чыгару белән шөгыльләнәчәге турында хәбәр итә. Г. Исхакыйның матбугат идарәсен Казанда оештырырга кирәк дигән киңәше белән бик үк килешеп бетми. Казан, әлбәттә, Уральски белән белән чагыштырганда сәүдә ягыннан да, һөнәр, сәнагать ягыннан да өстенрәк, ди. Әмма Уральски кебек шәһәрләрнең дә Казан дәрәҗәсенә күтәрелергә тиешлеге турында яза һәм аның сәбәбләрен дә күрсәтә: «Фәкать, минемчә, Уральски кебек шәһәрләрнең дә Казан дәрәҗәсенә күтәрелүләрен теләү кешелеклелек шартларыннан берседер. Мәгълүм ки, Россиядә булган бөтен мөселман шәһәрләре Казан дәрәҗәсенә күтәрелсә, ул вакытта, әлбәттә, милләтебезнең хәле тагы да тизрәк үзгәрәчәк. Минем фикеремчә, милләт файдасын шәхси мәнфәгатьтән өстен күрәсе килгәннәр үз шәһәрләрендә хезмәт итсеннәр һәм үз шәһәрләренең халкын мөмкин кадәр мәдәнияткә иләштерү өчен көрәшсеннәр. Юкса, әдипләр сыйныфы Казанда тупланса, Казан халкы горурланыр, башкалырына исә зарар килер, соңра инкыйраз заманы 200 елдан да әүвәл булыр» ди [5: 43].

Г. Исхакый XX гасыр башы әдәби һәм сәяси процессында күренекле урын тоткан шәхесләрнең берсе. Бу чор татар тормышын Г. Исхакыйдан башка күз алдына китереп булмый, аның эшчәнлеге бу вакыттагы яшәешнең төрле өлкәләренә үтеп керә. К. Мотыйгыйның басма «Әлгасрелҗәдид» журналын бастыруга рөхсәт алырга, журналның алдагы эшләрен оештырып йөргән вакытларда, Г. Исхакый белән киңәшүе дә очраклы түгел.

ӘДӘБИЯТ


1. Әл-Мотыйгый-Төхфәтуллин К. Фазыйләтле Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый! // Әлгасрелҗәдид (кулъязма). 1905. № 4. Б. 36
2. Гайнуллин М. Татар телендәге беренче әдәби-политик журнал «Әлгасрел-җәдит» // Совет әдәбияты. 1961. № 9. Б. 146–151.
3. Исхакый Г. Камил әфәнде! // Әлгасрелҗәдид (кулъязма). 1905. № 4. Б. 37
4. Исхакый Г. Мөхәтәрәм Камил әфәнде! // Әлгасрелҗәдид (кулъязма). 1905. № 4. Б. 35.
5. М.К. Каләм аркадашым М. Гаяз әфәнде! // Әлгасрелҗәдид (кулъязма). 1905. № 5. Б. 43.
6. Яхин Ф. Кулъязма журналдан – әдәби-иҗтимагый басма сүзгә / Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш (XX йөз башы татар әдәбияты тарихыннан). Казан, 1987. 125 с.
7. Яхин Ф. Татарская литература периодической печати Уральска (1905–1907 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. С. 10–11.


# Г. ТУКАЙНЫҢ ИДЕЯ-ФӘЛСӘФИ ЭЗЛӘНҮЛӘРЕ КОНТЕКСТЫНДА Г. ИСХАКЫЙ ШӘХЕСЕ ҺӘМ ИҖАТЫ


***Р.Ф. Харрасова*** *(Казан)*



Благодаря национально-освободительному движению выдающихся татарских общественных деятелей, в начале XX века наметился духовный подъем татарского народа. Например, татарская проза, драматургия и даже поэзия развивалась под идейно-художественным воздействием творчества Г. Исхаки. Живя еще в Уральске, Г. Тукай продвигал через свои стихи смелые размышления всеми признанного народного

лидера относительно будущего своей нации. Поэзия Тукая говорит о том, что он стал его единомышленником в видении решения многих общественно-социальных проблем. Не только творчество, но и личность писателя были для юного поэта духовно-нравственным ориентиром. Он восхищался им, считая его проводником национальной идеи в массы.
**Ключевые слова:** татарская литература, Г. Исхаки, Г. Тукай, литературные взаимосвязи.

At the beginning of the 20th century, the spiritual uplift of the Tatar people was outlined thanks to the national liberation movement of outstanding Tatar public figures. For example, tatar prose, dramaturgy and even poetry developed under the ideological and artistic influence of the works of G. Iskhaki. While still living in Uralsk, G. Tuqay promoted established national leader's bold reflections regarding the future of his nation through his poems. Poetry of Tuqay says that he was his adherent in the vision of solving many social and social problems. Not only creativity, but also the writer's personality was spiritual and moral beacon for young poet. He admired him, considering him a vehicle for the national idea to the masses.
**Key words:** Tatar literature, G. Ishaki, G. Tuqay, literary interrelationships.

Беренче чиратта, прозаик, драматург, публицист һәм милли азатлык көрәшчесе буларак танылса да, Гаяз Исхакыйны чорына күрә зур галим дип тә атарга мөмкин. Тарих, сәясәт, әдәбият кебек өлкәләрдән тирән белемгә ия әдип төрле урыннарда – Рәсәйдә һәм чит илләрдә – халык игътибарына алынырлык һәм тарихка кереп калырлык чыгышлар ясый. XX гасыр башы әдәбияты, бигрәк тә шигърияте турында сүз йөрткәндә, ул Тукай исемен һәрчак читләп узмаска тырыша. 1910 елда Төркия зыялылары каршында ясаган чыгышында, мәсәлән, әдип шул чорда иң алдынгы карашлы, иң милли, иң халыкчан шагыйрь сыйфатында Габдулла Тукайны аерып куя һәм аның Яңа татар әдәбиятын нигезләүче икәнлеген билгели. Г. Исхакый каләм иясенең тирән мәгънә эчтәлегенә омтылышын югары бәяли, иҗатының кыйммәте еллар дәвамында ачылыр дип фаразлый һәм ялгышмый да. Исхакыйның Тукай шәхесенә һәм иҗатына мөнәсәбәтле фикерләрне чагылдырган мирасы шактый күләмдә. Әдипнең бу төр язмалары мәртәбәле «Ил», «Яңа милли юл», «Сүз» һәм башка газета-журналларда дөнья күргән.

Тукайның зур милли кыйммәт икәнлеген аңлаган Исхакый шагыйрь иҗатын пропагандалау юлында зур эшләр башкара, ә теге яки бу каләм иясен иң киң танытуның төп юлы – әсәрләрен мәктәп программаларына кертү. Исхакый аның белән генә дә канәгатьләнеп калмый, шагыйрь исемен онытмау максатыннан, иҗатына кагылышлы чаралар оештыра, каберенә таш куюны кайгырта, «Тукай» җәмгыятьләре төзү артыннан йөри.Талантны дөнья танысын, аның аша милләтенең хәлен дә аңласын дисәң, иҗатын тәрҗемәдә башка халыкларга җиткерү кирәк. 1912 елның 13 июнендә Мезеньнан Фатих Әмирханга юллаган хатында Исхакый болай ди:

«…Максим Горький, "Алдым-бирдем" вә башка минем берничә хикәяләремнең тәрҗемәсен җыеп, шуңарга тагы берничә татар мөхәрриренең әсәрләрен, шигырьләрен кушып, "Татарча мәҗмүгаи әдәбиясы" исемендә бер китап басдырырга димләп хат яза. Мин бу эшне үз тарафымнан кабул итеп җавап бирдем. Хәзер шуны эш итеп чыгарырга гына кала. Шуның өчен, сезнең Казандагы мөхәррирләрегездән сиңа, Габдулла Тукаевка, Әстерхан Сәгыйть Рәмиевкә мөрәҗәгать итәргә уйладым. Син шул фикерне ничек табасың?

Беренче мәсьәлә бу: мин, син, Габдулла, Сәгыйдкә башка рус галәмендә күрсәтерлек әсәр ияләре юк дип уйлыйм. Шул фикеремдән мәҗмүганы дүрт кешенең әсәрләрендән генә төземәкче булам. Син ни фикердә? Бәлки, мин белми торган, мин читдә торып күрми калган берәр мөхәррир, шагыйрь бардыр. Булса, шул кем?

<...> Минемчә, бөтен әсәрләрдән, кирәк шигырь булсын, кирәк нәсер булсын, татар исе, татар тормышы аңкып торырга тиеш» [1: 15–16]. Алга таба хат алышу дәвамында Г. Исхакыйның җыентыкта Тукайның «Шүрәле»се һәм кайбер кыска шигырьләре булуын теләве күренә. Әдип Сәгыйть Рәмиевне «ыштансыз», «аристократ шагыйрь», ә үз базарында кыйммәте Габдулла Тукайныкыннан ким түгел дип санаса да, гади халыкка, аның «өмидсез», «һавалы» әсәрләренә караганда, Тукайның «яңа пешкән арыш икмәге исе»н аңкыткан, «үзенә үзе ышану нуры балкыт»кан иҗаты XX гасыр башы вазгыятендә мөһимрәк дип саный шикелле.

Исхакый Тукайны пропагандалауның үтемле чарасы сыйфатында әдәбиятны, вакытлы матбугатны файдалана: әсәрләре сюжетына шагыйрьгә мөнәсәбәтле эпизодлар кертә, еллар узгач та, аның иҗатын, шәхесен яктырткан мәкаләләр язудан туктамый. Исхакыйның Тукайга мөнәсәбәте темасы – зур тема, материалы бай, шунлыктан тирән ачылырга тиешле. Без исә бу чыгышта әдәби-шәхси бәйләнешләр проблемасын берьяклырак яктыртырбыз, күбрәк Тукайның фикри-фәлсәфи карашлары формалашуында Исхакый роле хакында сүз алып барырбыз.

Г. Тукай әдәбият мәйданында да, халык арасында да дәрәҗәле каләмдәшенә аның кебек үк якын килә – шагыйрь өчен милли каһарманның сәяси кыйбласын күзаллау, шәхесенең кемлеген, иҗатының кемгә һәм нәрсәгә хезмәт итүен ачыклау, гомуми иҗатының һәм аерым әсәрләренең татар сүз сәнгате тарихындагы урынын билгеләү мөһим.

Гомере бик иртә өзелгән Тукай каләм иясе буларак та, шәхес сыйфатында да тиз өлгерә, һәм аның рухи үсеш-үзгәрешләренә Г. Исхакый тәэсире биниһая зур. Бу шифалы тәэсир аеруча Җаек чорында калку чагыла. Үсмер Тукай сәясәт белән нык кызыксына, кайсы партиягә күңеле ныграк тартканны ачыклау белән мәшгуль, дусларына ияреп, төрле сәяси эчтәлектәге җыелышларга да йөри. Истәлекләрдән күренгәнчә, ул 1906–1907 елларда сул партияләрнең карашларын яклый. Монда Г. Исхакый кебек зур шәхесләрнең язганнары, эш-гамәлләре дә зур роль уйный. Тукай «Бер татар шагыйренең сүзләре»ндә (беренче басма), мәсәлән, лирик мин исеменнән үзен эсерлар янәшәсенә куя һәм шәхесен аларга кыюлыкта тиңли:

Курыкмаслыкта күңлем мисле әс-әр (эсер кебек),  
Күңлем дузәх (җәһәннәм), авызымнан ут чәчрәр минем.  
Дошман бозмый фикрем, уем җәмгыятен,  
Аңар каршы керпекләрем гаскәр минем.

Дөрес, тора-бара Тукай сул партияләрдәге кешеләрнең дә бердәй түгеллеген, Гаяз кебекләрнең азлыгын аңлый. С. Рәмиев белән ике арадагы каршылыклар аркасында туган «Булмый» (1909) шигырендә инде шушы рәвешчә фикер йөртә:

Кара карга вә «бөлгән бай» юып асла бә яз булмый;  
Вәһәр бер көлтә баш чын таңчы һәм асла Гаяз булмый.

Г. Исхакый белән Г. Тукай иҗаты – иҗтимагый-сәяси көрәш кулъязмасы ул. Яшь шагыйрьне әдип, вакыйга-күренешләрнең төбенә тиз төшенеп, оператив яктырту сәләте, проблемаларның чишелешен күрсәтә алуы, алардан да бигрәк курку белмәслеге һәм туры сүзлелеге белән үзенә тарткан дыр дип уйларга кирәк. Әдәбиятка яңа гына аяк баскан Тукай, рухи остазы кебек үк, көн кадагына суккан язмалар иҗат итә, милләт язмышына мөнәсәбәтле әсәрләрендә дә, теге яки бу шәхесләр турындагыларында да шактый кыю чыгыш ясый. Әйтик, 1907елда язылган «Хөррияты»дә, шагыйрь, «дуслар һәм дошманнар хәленнән бераз хәбәр бирелә», дисә дә, чынлыкта XX гасыр башы иҗтимагый

эшлеклеләренең, алар әгъза булып торган сәяси фиркаләрнең ирек өчен көрәше ачык аңлашылырлык сурәтләнә. Тукай бу әсәрендә эсерлар партиясе алга сөргән карашларны дини әдәбият материалын кулланып ача, аларның кайбер сәяси лозунгларын сәнгати алымнар ярдәмендә чагылдыра. Белгәнебезчә, эсерлар крестьяннарга хөкүмәттән җир таләп итә, чөнки ул – аларның бердәнбер яшәү чыганагы. Шагыйрь, моның гаделлеген раслар өчен, Алла да җирне кешегә үзенә ризык табу өчен бүләк итә, дип белдерә.

Г. Исхакыйның Беренче рус инкыйлабының гади халык мәнфәгатьләрен көтелгәнчә чишмәве өчен җаны көя. Китереләчәк мисалдан күренгәнчә, Г. Тукай үзе зур өметләр баглап каршы алган ил күләм зур иҗтимагый-сәяси вакыйганың крестьян файдасына хәл ителмәвенә шулай ук борчыла: «Җир аны эшләүчеләр өчен» дию тәмам юк ителгән». Шагыйрь билгеле бер ирекләр алып килгән инкыйлабтан соңгы артка чигенешләргә ачына, иҗтимагый вазгыятьне кыяматкә тиңли, метафорик фикер йөртеп, дөреслек кояшының тотылуы хакында әйтә. Тукай да, Исхакый да башта Дәүләт Думасына зур өметләр баглыйлар, әмма ул озын гомерле булып чыкмый – 102 көн генә яши.

Тукай белән Исхакыйны иҗатка бер үк максат-проблемалар этәрә. Танылган әдип, халыкның үзаңын үстерү, чынбарлыкка күзен ачтыру, татар кешесенә үз хәлен аңлатып бирү өчен, «Инкыйраз»ны язуны үзенең әдиплек бурычы саный. Аннан бу идеяне эләктереп алган шагыйрь каләменең төп кыйбласы итә. «Хөррияте» шигырендә ул әнә шуңа күрә милләт хәлен тетрәгән куллап белән язып биргәнлеген һәм укучының зарлану сүзләренә нәсәрләнергә теләвен махсус ассызыклый да. Исхакый, татарның киләчәгеннән ал хәбәр биреп, шул киләчәкне булдырмый калу өчен көрәшкән шикелле, «Хөррияте» ахырында Тукай, милләтнең киләчәге айлы кичтән дә яктырак булсын, дип тели.

Теләсә кайсы ике иҗатның үз ара якынлыгы, беренче чиратта, төп темаларда һәм үтәли мотивларда чагылыш таба. Исхакый гомер бакый иске тип муллаларга, надан голямаларга каршы көрәшә, Тукай да инде бу тагын да калкулана төшә. Мисалга китерелгән әсәрнең соңгы юллары, мәсәлән, чалмалылар богавыннан азат итүне теләү белән тәмамлана.

Җаек төбәгендә сул партияләр иҗтимагый күтәрелеш елларында зур актив эшчәнлек алып бара, алар тарафыннан киң җәелгән хәрәкәт каләм ияләренең игътибарын һәр даим үзенә тартып тора. Бигрәк тә татар милләтпәрвәрләре дә әгъза булып торган фиркаләрнең көрәшчән рухы, шул ухның татар публицистикасына үтеп керүе журналистиканы сизелерлек үзгәртә – андагы көрәш рухын үстереп җибәрә. Тукай вакытлы матбугат өчен иҗат иткән чәчмә әсәрләрен дә үз чорының иң алдынгы иҗтимагый-мәдәни карашларын актив пропагандалау эшенә керешә. Шагыйрьнең бигрәк тә эсерларга мәхәббәтен, әлбәттә, алар партиясенең сталинизмгача революцион-демократик хәрәкәтнең үзәге, алдынгысы булып торуы һәм шуның кысаларында хәрәкәт иткән Г. Исхакый алып барган эшчәнлеккә, аның гади җир халкын яклап язганнарына симпатиясе белән бәйләп карарга кирәк. Г. Тукай Г. Исхакый үз иҗатында файдаланган («Тартышу» һ.б.) һәм эсерларның төп шигарьләрен калыплаштырган тартышу төшенчәсен, аңа охшаш мәгънәле сүзләрне поэзиясендә шактый куллана. Аның «Тавыш» газетасына мөнәсәбәтле әсәрендә мондый юллар бар: «Эшче туган! Тартыш кирәк, кирәк тартыш, / Тартышмаган эшчеләргә бик батыр теш».

Яшь Тукай һәр даим милли идеал булырлык, әдәбият мәйданында үрнәк алырлык шәхесләр турында уйлана. Бу вакытта ул кешеләрнең кемлеген мәгърифәтчелек эшчәнлеге, меценатлыгы, фикер кыюлыгы чагылдыра дигәнрәк караштa тора. Тукай халыкны томаналыкта яшәткән, пассив тормыш алып барган

һәм сорыкортлрча көн иткән ишаннарга көчле сатира уты яудыра, ә мәгърифәт-белем таратучыларны, яңа фикер әйтүчеләрне, тормышта актив хәрәкәт итүчеләрне аларгак аршы куя. Шигъри текстларында баштарак теге яки бу социаль катламнарның кара төсләрдәге портретын гомуми планда тудырса да, әкренләп аларныт әгаен шәхесләр аша да күзаллата башлый.

Шагыйрь иҗат иткән милли каһарманнарны исемнәре һәм милләт файдасына башкарган эшләре аша чагылдыруны, үз халкына да белдерүне кирәк дип саный. Тукайның уңай яссылыктагы тасвир объектлары рәтендә теге яки бу газетаны ачучы мөхәррирләр, халык файдасына башкарган эшләргә ярдәм күрсәтүче байлар, сәяси эшлекле Р. Ибраһимов, миллионнарның күзен ачкан Г. Исхакый һәм башкалар бар. Араларында Тукайны иң сокландырганы – Гаяз Исхакый дип уйларга кирәк. Әлеге шәхесләрне, гомумиләштереп, «халыкны кем туры юлга күндерүчеләр» дип атарга да булыр иде, чөнки шагыйрь көрәшче милләтчеләрне «туры юл», «туры юлга күндерүче», «чын кеше» һ.б. охшаш эчтәлектәге гыйбарәләр ярдәмендә тасвирлый.

Контрастлар остасы булган шагыйрь күңеленә якын затлар янәшәсендә һәрвакыт җаны-тәнебеләнк абул итмәгән кешеләр турында да сөйли. Аның иң күралмаган социальт өркеме, әйткәнбезчә – ишаннар. Сорыкортларча яшәгән ишаннарны Исхакый да сөйми. Биографик материалларга нигезләнгән «Мулла бабай»да аның кешеләрне бары уңай яктан бәяләргә тырышкан героена кадәр аларга тәнкыйди күз белән карамыйча булдыра алмый: «Габдрәхим хәзрәт, тирә-як муллаларның эшләренә катышмаса да, анларның гаепләрене сөйләп йөрмәсәдә, анларның хатынларының кием-салымга исрафларыны тикшермәсәдә, ул, мәхәлләсенә разый булмаенча, сату итә башлаган мулла Хәбибнең шул эшене яратып бетерми, мәхәллә эшенә карамаенча, туй-төшем йиткәчтә, атыны җигеп чыгып китеп, айлап тирә-якны кыдырып йөрүче мулла Салихны да сөйми, ишаннарга ихласы булса да, кәрамәткә ышанса да, “тәрикать дүрттер: Хуҗа Бәһаветдин Нәкышбанди, Җәләлетдин Ширвани <…>” дип, дип мәдрәсә бикләтсә дә, Әхмәтҗан мулланың, мужик карчыкларының аршын ярым туласыны алыр өчен өшкереп-пошкырып йөрүене дә яратмый иде» [2: 374].

«Мөридләр каберстаныннан бер аваз»да Тукай, ишанлык – мәҗүсилек, башлыклары таянган идеология – нигезе төпсез, мөритлек – коллык, дип белдерә һәм шул төр хәрәкәткә каршы торырлык көчләрне эзли. Бу төр сорыкортларга тәнкыйть сүзе әйтүчеләрне шагыйрь намуслызатлар, чын кешеләр дип бәяли. Шушы уңайдан, ул Г. Исхакыйның үзе хакында һәм искелекне, наданлыкны, хәрәкәтсезлекне тәнкыйтьләп чыккан «Инкыйраз»ы турында болай яза:

Дәрсе гыйбрәт вирдебезгә «Инкыйраз» нам бирәсәр;
Аһ, боны язган кеше инсан икәндер, белмәдем.

Шагыйрь «Кем ул?» (1907) шигырендә Исхакыйны милләтнең үзаңын үстергән, аны телле-фикерле иткән шәхес буларак бәяли һәм кабат инкыйраз темасына әйләнеп кайта, ягъни узган көннәребезне уйлаткан, милләтнең артка чигенешләрен исебезгә төшергән кеше – кем, дигән сорау куя. Милләтнең вәйранлыгы мотивы Тукай иҗатында бигрәк тә Дума таратылганнан соң һәм милли матбугат органнары бер-бер артлы ябыла башлагач көчәя, чөнки анда тулы ирек киләсенә өмет сүнә.

Тукай аптыраган вакытларында әйткән «Мин әле кая барам?» – аерым бер кешенең тоткан юлы, әдипнең киләчәге, кыйбласы турында гына түгел, ә милләтнең гомуми барышы хакындагы сорау да. Шушы ук сорау Гаяз Исхакыйның «Инкыйраз» әсәрендә бөтен кискенлеге белән куела, һәм әдип аңа аннан соң да әйләнеп-әйләнеп кайта.

Тиздән Тукайның Җаек чоры иҗатын ачкан махсус китапта дөнья күрәчәк мәкаләмдә язган сүзләрем монда да урынлы яңыгараш табар дип уйлыйм: «Г. Исхакый турында мәгълүматлы, әсәрләре, эшчәнлеге белән яхшы таныш Тукайның, милли юламан дәрәҗәсендәге әдип тәэсирендә дә булса кирәк, татарны ирекле итүгә омтылышы торган саен көчәя бара. Мәсәлән, "Кичке азан" әсәрендә шагыйрь халкыбызның бер-бер артлы ханлыкларын югалту, патшаларсыз калу тарихын күз алдына торгызып бастыра. Ә бит XX гасыр башы суфилары, бигрәк тә аларның хакимият белән дуслашканнары кешене узганга борылып кайгырмаска, гомумән, дөньяда булып узганнарны искә төшерүдән арынырга, милләт, ил, мөстәкыйльлек турында уйлаудан битәр, гомумдуслык, гармония турында фикер йөртергә өнди. Бу карашлар Яңарыш алдында торган татар дөньясы өчен дә, узганда ил тоткан халыкның мескенлек-коллыкта яшәвенә кайгырган Тукай өчен дә бармый. "Кичке азан"да әнә шуңа күрә ул болай дип белдерә:

Нә дәүләт калды, нә шан!
Шаннан нишан,
Калды дингә
Дошман ишан!

<…> Вакытында җир
Селкеттек,
Инде беттек,
Инде беттек!»

Тукай соңгы көннәренәчә Исхакыйны милли идеал итүдән туктамый, шулай да сабыйларча идеаллаштырудан арына. 1911 елны Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында ул болай ди: «Мин үзем дә, Казанга килмәс борын, "Гаяз Исхаков ашый-эчә микән", дигән кызык бер шөбһәле фикердә идем. Ләкин Казанга килгәч, бөтен милләтчеләрне күреп, хәлләрен аңладым» [3: 226].

Тукайның 1913 елда язылган «Мөхәрриргә» кыйтгасында, Исхакый Ватанын ташлап киткәч, татарның милләт файдасына реаль эшләрдән китүе, Беренче рус инкыйлабыннан соң узган чорда күпләрнең үзгәрүе тасвирлана. Шагыйрь моны төрле караштагы социаль катламнарны, яшь көчләрне уртак идея һәм гамәлләр тирәсендә берләштереп торырлык милли лидерның калмавы белән бәйли:

Алты ел торды чупансыз (чабансыз. – *Р.Х.*), айрылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән курка шайтаннар»,– дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя.

Тукай Исхакыйны риялыларны иманга китертерлек зур шәхес, объектив һәм пакь тасвирлар остасы, кире якка китешкә каршы торырлык бер көч сыйфатында сурәтли. Реаль чынбарлыкны үз буяуларында чагылдырган бу әсәрне кайберәүләрнең кебек романтик шигърият үрнәге дип бәяләү белән килешеп булмый.

«Мөхәрриргә»дә очраган күз карашы гыйбарәсе шушы ук елны иҗат ителгән «Даһигә»дә дә кулланыла. Беренче әсәрдә Тукай рия затлар «күз карашыңнан керер җир тапмасынчы», дип әйтсә, икенчесендә:

Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн;
Киттең эзләп син, аны яктыртмага, идеал утын, –

дип яза. Бу шигырьдә галимнәр Г. Тукай Г. Исхакыйны күздә тоткан дип фаразлый, без исә килешмибез, чөнки бер үк чорда язылган ике әсәр арасында эчтәлектә һәм яңгыраштa аерма зур. Тәгаен тасвирлы «Мөхәрриргә»нең Г. Исхакый хакында икәнлеге бәхәс уятмый. Гаяз Исхакыйның образ характеристи-

касы, аңа кагылышлы биографик моментлар, тормыш күренешләре һәм вакыйгалары да шуны сөйли. «Мөхәрриргә»дә Исхакый кыйбласын югалтмаган, читтә дә көрәшүдән туктамаган милли лидер кебек аңлашыла, нәкъ менә шуңа күрә татарларның аңа нык ихтыяҗ кичерә. Лирик мин татар киләчәген аның Ватанына әйләнеп кайтуы белән бәйли дә.

Тасвирлары үтә гомуми пландагы «Даһигә»дә исә тормышның реаль фактлары аңлашылырлык дәрәҗәдә чагылыш тапмый. Дөньяны яктыртырга алынган романтик көрәшче идеал утын алда табачагыннан өметен өзгән. Бу образ Гаяз Исхакыйны һич кенә дә чагылдыра алмый. Шагыйрь әле генә идеал утын кабызганнарның ни өчендер туктап калуын, артка чигенеш ясауларын аңлап бетермәве хакында яза, яңа көрәшләргә, алга әйди.

«Даһигә»не язуга, чынбарлык, ягъни иҗтимагый-сәяси мәйдандагы артка китешләр сәбәп булса да, шагыйрьгә теманы Лермонтовның шул исемдәге, әмма башкача эчтәлектәге әсәре «К гению» биргән булырга мөмкин. «Когда во тьме ночей мой не смыкаясь взор / Без цели бродит вкруг, прошедших дней укор / Когда зовет меня, невольно, к вспоминанью: / Какому тяжкому я предаюсь мечтанью!..», – дип башлана ул.

Тукайның мәгърифәтьчелек поэзиясе белән Исхакыйның шул төр идея эчтәлегендәге прозасы я булмаса икесенең дә XX гасыр башы татар җәмгыятен тасварилаган сатирик рухтагы әсәрләре арасында кызыклы гына янәшәлекләр уздырып булыр иде. Г. Исхакый һәм Г. Тукай иҗатында мотивлаштыру уртаклыкларын ачу да аерым бер проблема булырлык.

Теләсә кайсы сәнгать әсәренең адресаты, иясе була, һәм ул бары тик эстетик аралашуны гына күздә тотып языла. Мәгърифәтчелек, тәнкыйди реализм әдәбияты бөтен татар милләтен алга җибәрү уе теләгеннән чыгып иҗат ителсә һәм шул сәбәпле милләткә юнәлтелсә дә, тәгаен эчтәлегенә бәйле рәвештә, әлеге адресатның үзәк өлеше тараеп та китәргә мөмкин. Тукай һәм Исхакый калдырган мирас татар хатын-кызының язмышы һәм бәхете мәсьәләсе һәрвакыт төп проблемалардан икәнлекне сөйли. Каләм ияләренең бу катламның ил тормышындагы, гаиләдәге, бала тәрбиясендәге роле турындагы уйланулары аларның бөтен иҗатын сугара. Әсәрләрендәге вакыйгалар эченә хатын-кыз куелуына карамастан, Исхакыйның да, Тукайның да төп адресаты үзгәрешләр кичерә, күпчелек очракта алар икесе дә дөньяви мәсьәләләрне хәл итүне үз кулларына алган ир-атларга мөрәҗәгать итә дип уйларга кирәк.

Тукай шигъриятендә кемгә өйләнү, гаиләдә мөнәсәбәтләрне ничек кору, үзара тиңлек-тиңсезлек проблемалары сизелерлек урын алып тора. Исхакыйда бу темага игътибар тагын да зуррак. Тукайның, әйтик, «Ике хатын берлә тормыш» (1910) такмагында күпхатынлылыкка тискәре мөнәсәбәте күренә. Гаяз Исхакыйның «Өч хатын берлә тормыш» (1900) драмасы әлеге проблеманың татар тормышы өчен гаять мөһим һәм һичшиксез чишелергә тиешлеген күрсәтә. Аның «Мөкаддимә»сендә Гаяз Исхакый болай дип яза:

«Өч хатын берлән тормыш» драмам бундан тәмам тукыз ел элек (тукыз йөзенче елның җәендә) язылганга, әлбәттә, анда мин үземнең шул вакыттагы күз карашымнан шул вакыйганы тасвир вә тәфсир иткән идем. Шул вакыттагы үземнең хак дип белгән, ышанган фикеремне укучыларга да хак-дөрест дип күрсәтергә тырышкан идем. Шул вакытта ышанган әхлак кагыйдәләрен дә ригая кылып, драмамның өсасенә «һәр җинаятьнең җәзасы була» казыясен утырткан идем. Шуның өчен безнең татар тормышында бик күп очрый торган, бик ямьсез вакыйгаларга сәбәп була торган күп хатын алуны үземнең шул вакыттагы ноктаи нәзарымнан тәнкыйть кылып, шуның һәр тарафыннан караганда да өйләнүчеләр өчен дә зарарлы идекен күрсәткән идем һәм дә шул ук

китапта фамилия сәгадәтенең ничек булуын белдерер өчен, шул өч хатынлы тормышның мөхалифе – Ризаның бер хатын белән тормышын да тасвир иткән идем», – дип яза [4: 5].

Яшьтән үк усал һәм шаян телле Тукай, теге яки бу шәхесне ничек кенә сөймәсен, кагыйдәдән бер-ике чыгарма белән, тәнкыйть итмичә кала алмый. Исхакыйга да шагыйрьнең фельетоннарында «шома шаяру ташы» шактый атыла. Ул «Ачы хакыйкать» әсәрендә үзенең әдипкә иярүләренә ишарәне юмор чарасы буларак файдалана. Шунысы мөһим: әлеге язмада ул Ф. Кәрими, Г. Исхакый кебек «олуг мөхәррирләр» янәшәсендә, гадәттә, тәнкыйтеннән сакларга тырышкан Ф. Әмирханны да атый: «Аннан соң Гаяз әл-Исхакый җәнабләре дә, үзләренең төрле урыннарда чәчелеп яткан язуларын бер җиргә җыеп, «Җыентык» исемендә җыйнак кына бер китап таратты.

Болардан соң Фатих әфәнде Әмирхан җәнабләре, үзенең вак-төяк тәхрирәтеннән җыеп, «Вак-төяк» исемле әсәр бастырды.

Бәс, боларны күргәч, минем дә төрле урында чәчелеп яткан «чүп-чарым» исемә төште. Мәзкүр өч мөхәррир кеби, минем дә шул чүп-чарны бер почмакка себереп өясем килде» [5: 315].

Тукайның «Урамда» [6: 93] фельетонында шулай ук Фатих Кәрими белән Гаяз Исхакый телгә алына. Автор бер милләткә хезмәт итүче иң үткен ике әдипнең үзара сәяси-иҗтимагый гамәлләренә бәйле вакытлы матбугатта булып узган тарткалашын бала-чаганың үчекләшүенә тиңли. Һәм бик хаклы да, чөнки танылган язучылар, мәсьәләнең төбенә төшмичә, үзләре хезмәт иткән партияләренең һәм шәхси сәяси карашларын ачып күрсәтәсе урынга, бер-берсен ямьсез сүзләр әйтү, хәтта бер үк тамгалар сугу белән мәшгуль. Язма, сатирадан битәр, шаяру рәвешендә кабул ителә, ул әлеге тарткалашның эчтәлегеннән дә хәбәр бирми, теге яки бу карашларны тәнкыйть тә итми. Әлеге язманың Тукайның «Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мөхаль әндишәси» («Һәркемнең, һичшиксез, үзенчә фикере, төшенчәсе бар») мәкаләсе белән тыгыз бәйләнеше күзәтелә. Үз бәхәсендә Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый һәм фикердәшләре социализмны аңламый, кебек гаепләү ташласа, Тукай бу язмада, халыкны социалистлар арасына, «Карл Маркс мәзһәбенә» кертү өчен, иң элек аң-белемле итү, алар хакында фикерләргә ия булдыру кирәклеге хакында һәм «Фикер» газетасының халыкны «таңчылар»ның карашлары белән коралландыруын яза. Шул ук вакытта ул бөтен мөхәррирләрнең бер үк хыялларга бирелүен дә якламый, чөнки, бар кеше Гаяз Исхакый кебек булса, көрәшчеләрнең корбанга китүе аркасында, татар милләте бөтенләй «гаскәр»сез калыр дип куркуын әйтә.

Тукай, Исхакый кебек, мәктәпләрдә, мәдрәсәләрдә ни укыту, дәреслекләргә, мөһим җыентыкларга нинди әсәрләрне кертергә кирәклек турында да уйлана, һәм аның җавабы шулай укыраткан әдибенекенә охшаш: милли әдәбият җыентыкларында халыкның күзен ачарлык әсәрләр басылырга тиеш. Үзе төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дәреслек-хрестоматиясенә «Мөкаддимә»дә (1911) Тукай болай дип яза:

«…безнең мөхәррирләр вә шагыйрьләремезнең күз яшьләренә манчып язган каләмнәрендин чыкган әсәрләренә “чүп” дип вә язучысына да “эшсез” дип кенә карыйлар иде. Шундый карашлар зарарындадыр ки, без әле Гаяз әфәнденең “Инкыйраз”ы кеби сәтрына сәтыры алтын белән тегелеп язылган гали әсәрнең һаман икенче кәррә табгы ителгәнен, мәгатәссеф, күрә алмыймыз. Вә хәлбуки боларның һәр шәһәр татарының өстәлендә, һәр авыл мужигының пич башында берәр данә булып торулары лязем вә хәтта фарыз иде» [7:12].

Тукай публицистикасында Исхакый әсәрләренең сюжет элементларыннан («Өч баш», «Мәкаләи махсуса»), образларыннан, фикерләреннән, тасвирла-

рыннан («Тиен»), исеменнән («Казанга кайтыш») файдалана. Аларга теге яки бу проблеманы ачканда да ишәрәләп узгалый. Әйтик, Тукайның «Тегендән-шундан» язмасында мондый юллар бар: «Дөрест, Төркия – хаста кеше, ул “авырый”. Ләкин бит Гаяз әфәнденең соңгы “Мулла бабай” романындагы Гали бай хатыны Зөһрә абыстай да авырый, Гали бай **анасы** (? – *Р.Х.*) үлсә, мәдрәсә шәкертләренә симез хосул төшә» [4: 240]. Шәкертләр шуның өчен Зөһрә абыстай үлемен өннәрендә дә, төшләрендә дә күрә. Бу очракта Тукай Төркия үлемен матди баю максатыннан көтүчеләр күплеген искәртә.

Бер дигән әдәбият тәнкыйтьчесе дә булырлык Тукай язмаларында Исхакый әсәрләренең эчтәлегенә бәйле шаян ишарәләр шулай ук очраштыра. Әдип «1912 елның онытылгандан калган гына хисабы»нда: «1912 елда Гаяз әфәнде татарларга бераз “чаршау арты” тормышын да язып күрсәтте», – дип көлеп үтә. Дөрес, моны Тукайның 4 томында бирелгән аңлатмадагыча «Теләнче кызы» әсәре белән бәйләп булмый, чөнки ул, бердән, күпкә алдарак языла, икенчедән, анда гадәти «чаршау арты» эротикасыннан, гаилә эчендәге интим тормыштан битәр, хатын-кызның түбәнгә тәгәрәү тарихы сурәтләнә.

Һәр кемгә, һәр нәрсәгә тәнкыйди карарга гадәтләнгән Тукай авызыннан Исхакыйга карата зур тәнкыйть яңгырамаса да, кайвакыт ул аның язу рәвешенә һәм сөйләм үзенчәлеренә борчылуын сиздермичә булдыра алмый. Әдәби тел бары тик татарның төп халкыныкына – Казан арты сөйләшенә генә нигезләнергә тиеш дип санаган Тукай 1910 елның 9 ноябрендә дусты С. Сүнчәләйгә язган хатында аның, М. Гафуриның, Гаяз Исхакыйның диалекталь сүзләр куллануын сөймәве хакында җиткерә [8: 212].

Гаяз Исхакыйның татар әдәбиятына, шул исәптән Тукай иҗатына тәэсире гаять зур. Ул капитализм җимерелү чорында сүз сәнгате мәйданына ныклы аяк баса һәм прозасында, публицистикасында, драматургиясендә хезмәт кешесенең, татар халкының хис-кичерешләрен, омтылышларын чагылдыра, әлеге омтылышларны иҗтимагый гамәлияташа тормышка ашыру өчен тартыша. Әнә шул сәбәпле Тукайга Исхакый иҗаты белән генә түгел, шәхес буларак та зур тәэсир ясый. Бик күп нәрсәләрдән күңеле кайткан, кайтучан Тукай Исхакыйга булган олы мәхәббәтен гомер ахырынача саклый. Киңкырлы талантка, тирән күзаллауларга ия һәм үтә милләтпәрвәр әдип аның да, яңа әдәбиятка хезмәт иткән башка бик күпләрнең дә күзен ачкан остазга әверелә.

ӘДӘБИЯТ


1. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 14. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 479 б.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 448 б.
3. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.
4. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 496 б.
5. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 384 б.
6. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 415 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Т. 6. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 471 б.
8. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.
9. Г. Тукай шигырьләре // Category: Габдулла Тукай шигырьләре // https://wikisource.org/wiki (дата обращение 24.03.2018).


## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ


***Ә.С. Хәйруллина, Г.Ф. Даутов*** *(Алабуга)*



В статье рассматривается процесс научной реабилитации богатого творческого наследия выдающегося татарского общественного деятеля, писателя и организатора журналистики Гаяза Исхаки. У каждого народа существует свое отношение к миру и свой взгляд на жизнь. Гаяз Исхаки – писатель, который, отражая это, посвятил свое

творчество национальным особенностям жизни татар. Во время глобализации его творчество приобретает еще более резкое звучание.
**Ключевые слова:** жизнь, боец, правда, общечеловеческие проблемы, жизнь татар.

The article considers the process of scientific rehabilitation of rich creative heritage of prominent Tatar public figure, writer and organizer of journalism Gayaz Iskhaki. Every nation has its own attitude to the world and its own view to life. Gayaz Iskhaki is a writer who, reflecting this, devoted his work to the national peculiarities of the Tatars' life.In the time of globalization, his works get more dramatic sound.
**Key words:** life, fighter, true, human problems, life of the Tatars.

Без, татарлар, кызык кына этнопсихологик сыйфатларга ия халык. Аларга мин татарның канына сеңгән эшчәнлек, тырышлык, тыйнаклык, әдәплелек кебек гадәтләрне кертә. Канга сеңгән, чөнки кечкенәдән үк әбиләрнең аркадан сөйгәндә «бәхет-тәүфыйгын белән үс, балакаем», дигән сүзләрен ишетеп үсәбез. Әти-әни дә: «Өлкәннәргә каршы әйтмә, сабыр бул», – дип үгетли. Ләкин артык карусызлык, үз хокукларыңны белмәү, шуның аркасында башкаларның синең хезмәтең аркылы уңышка ирешүләренә юл кую – монысы чаманы бозу була.

«Көрәшчеләр кирәк безгә!» дип яза шагыйрь Р. Фәйзуллин.

Кирәк, һәм халыкның симпатиясе дә күп очракта көрәшчеләр ягында була. К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендәге Булатның гаярь, тәвәккәл булуында түгел микән бу әсәрнең популярлыгының сере? Үлемгә дә бирешмәгән авыру Тукай һәм Т. Миңнуллинның гомеренең ахырына кадәр тормыштан туймаган Әлмәндәре – халык аларны әнә шуның өчен үз итәдер? Т. Галиуллинның «Элмәк» романын егетлеккә сәләтле Сәет Сакмановы халык арасында иң укыла торган китап иткәндер?

Үз хокукың өчен көрәшә белү – безнең халыкка иң кирәкле сыйфат. Бүген дә бар, әлбәттә, безнең көрәшчеләребез. Тик... көрәшеп янганнарның иҗатын, эшчәнлеген өйрәнү җитми.

Татарларның иң олы көрәшчеләреннән берсе – Гаяз Исхакый. «Ничә дистә еллар хаксызга рәнҗетелеп, иҗат мирасы халыктан яшереп торылганнан соң бу әдип 90 нчы еллар башында кире асыл Ватанына кайтты. Бүгенге катлаулы вазгыятьтә Исхакый иҗаты аеруча әһәмияткә ия. Күпчелеге телен һәм гореф-гадәтләрен оныткан татарлар өчен әдип иҗатында күтәрелгән идея һәм проблемалар айныткыч тәэсир ясый торган саф һава кебек кирәк. «Талантлы кешеләр арасында шөһрәткә сусаган, байлыкка кызыккан, шуларга ирешер өчен сәләтен дә, көч-кодрәтен дә кызганмаган затлар юк түгел. Андыйлар да үз милләтен «күтәрергә» мөмкин. Әмма Исхакый, алардан аермалы буларак, газиз милләтен ирекле, бай рухлы, бәхетле итәр өчен матди байлыктан да, шөһрәттән дә аңлы рәвештә ваз кичкән олы җанлы сәнгатькәр, гасырга бер генә тапкыр туа ала торган даһи иҗатчы һәм каһарман көрәшче», – дип яза аның турында Тәүфикъ Әйди [1: 147].

Г. Исхакый көрәшче, милли көрәшче һәм характерының бу үзенчәлеге аның яшәеш рәвеше булып китә. Мәдрәсәдә бергә укыган шәриктәшләре Сәгыйть Рәмиев белән Габдрахман Хөсәенов та аның үзен рәнҗеттермәвен, алай гына да түгел, хәтта башкаларга да яклаучы булып йөрүен язалар [4: 12].

Ләкин хакыйкатьне якларга омтылыш кына Г. Исхакыйны милли каһарман итеп формалаштыра алмас иде. Моның өчен үз халкыңны, аның яшәешен, дөньяга мөнәсәбәтен, фикерләү рәвешен яратырга, чын күңелдән аңлый белергә кирәк. Татарларның күп гасырлар дәвамында формалашкан гореф-гадәтләренең, традицияләренең, әхлак нормаларының асылын, матурлыгын күрә белеп, шуларның барлык гаммасын әсәрләрдә чагылдыру – болар бары Г. Исхакый каләменә генә мөмкин эш. Әдип туган халкының фаҗигале та-

рихын, көчләп руслаштыру сәясәтенә каршы фидакарь каршылык күрсәтүен әдәби эшләнештә күрсәтә алган.

Әдипнең һәр әсәре татарның теге яки бу проблемасына багышланган. Ул татар тормышын үзенең эчке закончалыклары белән яшәүче җәмгыять буларак кабул итә. Анда яшәүчеләр үз тормышларыннан канәгать булырга («Сөннәтче бабай»), икенчеләре, киресенчә, риза булмаска мөмкин («Тормышмы бу?»). Әгәр Сөннәтче бабай әйләнә-тирә мохит белән тулы гармониядә яшәсә, «Тормышмы бу?» повестеның герое үз-үзе белән дә, җәмгыять белән дә уртак тел таба алмаган.

Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?» повесте гомумкешелек проблемаларын, шул проблемаларның татар милли төсмере белән баетылып күтәрелүе белән кызыклы. Повестьның герое – сәләтен, эшчәнлеген иҗтимагый яшәештә тормышка ашыра алмаган кеше. Ул, һичшиксез, акыллы, үз-үзенә бәяне белә, ләкин үзенең эчке тормышында артык казынырга яратучан. Кичерешләренә артык игътибарлы булу аны теге яки бу адымыннан, эш-гамәленнән өзлексез шикләнергә мәҗбүр итә. Үзе күркәм генә кыяфәтле булса да, егет чагында кызлар белән аралашып китә алмавына әнә шул гаепле: «Чыннан да, мин шул хәзер кызлар кызыгырлык егет булганмын, ахры. Кызлар карый башласа, үземнең йөрәгем сикерә башлый. Бик якыннан карасалар, колакларым, битләрем ут кебек яна башлый. Бүлмә ярыгы аркылы “фәлән” кызлар күзе берлә күзем очрашса, никадәр карыйсым килсә дә, ихтыярсыз күзем түбән төшә. Мин аларның күз карауларына каршы, әллә нәрсә эрегән кеби булып, йомшарып-изрәп китәм» [2: 86]. Кызлар тарафыннан аның хәрәкәтләренә теләктәшлек күрсәтелсә дә, ул әле теге, әле бу сәбәп табып, соңыннан үзен-үзе шул җебегәнлеге өчен битәрләп, китеп бара.

Яшь егетнең болай өзгәләнү-бәргәләнүләренең сәбәбе, ахры, аның үзенең йомшак, тәвәккәл булмавында гына түгелдер. XX йөз башы татар иҗтимагый тормышына буржуаз мөнәсәбәтләр тирән үтеп керә, ул һәркемгә, шул исәптән безнең геройга да кагыла. Шәкерт чагында иске тип муллалардан булган этисе – аның өчен әле идеал. Ләкин мәдрәсәдә заманча китаплар укып, дөньяга карашы киңәя башлаган егет, мулла булып, авыл кысаларында гына калу белән килешә алмый башлый. Ул зуррак эшләргә сәләтле икәнен аңлый, ләкин яшь чакта да кызлар белән аралашудан үзен «кеше күрер», «берәрсе белә күрмәсен» дип тыеп килгән герой, үсеп җитеп формалашкач та, билгеле бер кысалардан чыгып китә алмый. Мулла булырга да ул эти-әнисен тыңлап кына ризалаша. Дөньяви китаплардан бераз авыз иткәнгә күрә, ул хәзерге шөгыленең бик вак, кечкенә нәрсә икәнлеген аңлый, ләкин шул халәтен җиңәргә көч тә, чара да таба алмый. Нечкә күңелле, эмоциональ кеше буларак, ул үзенең киләчәген бары кара буяулар белән генә күзаллый: «Әнә минем киләчәк! Зур корсаклы, көненә ун бәлеш төбе ашый торган, күрше хатыннары, асраулар берлә маташа, былчырана торган мин! Әнә мужиклар берлә юк нәрсәләр өчен ялган шаһитлар яллап-яллап хөкемнәргә йөрүче мин! Әнә мужик хатыннары берлә каз бәбкәләре өчен орышучы мин!..» [2: 117].

Әдип өчен милли яшәештә кечкенә мәсьәләләр юк. Аның өчен барысы да: укып азмы-күпме күңел күзе ачылган егетнең эчке кичерешләре дә, ике йөз елдан соң булачак перспективалар да, гади татар авылында игелекле һәм изге эш белән шөгыльләнүче Сөннәтче бабай да – барысы да әһәмиятле.

«Сөннәтче бабай» әсәренең төп герое – гади бер татар авылының табигый, аерылгысыз бер элементы. Г. Исхакый бу повестенда билгеле бер шартларга куелган – милли һәм икътисади яктан хокуксызландырылып, әйдәп баручы катлавы – морзалары юк ителгән, авыл җирлегенә куып кертелгән һәм игенчелек

белән генә шөгыльләнергә мәҗбүр булган татар авылының тыныч, салмак, үзенә генә хас булган яшәешен тасвирлый. Бу тормыш-көнкүреш шулкадәр табигый һәм садә ки, анда яшәүчеләр башкача тереклек итүне күз алдына да китерә алмыйлар. Әгәр чак кына тайпылыш була икән, ул инде фаҗигагә китерә. Әдип Сөннәтче бабайны болай тасвирлый: «Авылның картлары, ир урталары, яшьләре – һәммәсе дә үзләре белә башлаганнан бирле аны Сөннәтче бабай дип таныйлар. Сөннәтче бабай дип йөриләр иде» [3: 77]. Аның өе дә: «Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде. Авыл тарихын белми торган вакытта такта берлән ябылган түбәсе, вакыт үтә-үтә каралып бетеп, анда-монда кәкрәеп торулары берлән Сөннәтче бабайның битенә бөтенләй охшый иде» [3: 155].

Сөннәтче бабай әнә шулай авыл белән, аның кешеләре һәм бу кешеләрнең тереклеге белән кушылып, көйле генә яши. Әгәр хатыны да үзенә яраклашып бетмәсә, мондый бөтенлек тулы булмас иде. Исхакый, бөек сүз остасы буларак, анын карчыгының да нәкъ татар хатын-кызларына гына хас булган сыйфатлары белән искиткеч гүзәл, сөйкемле, җанга якын образын тудыра сыман. Алар яши-яши икесе инде бер кеше булып китә язганнар: «Бонларның төсләрендә, йөзләрендә, кыланышларында, табигатьләрендә дә һичбер аерма юк иде. Дөресе генә, бонлар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде» [3: 78].

Алар әнә шундый гармониядә яшиләр. Тормыш итешләре дә саф татар яшәеш шартларына көйләнгән. Сөннәтче бабайның, исеменнән үк күренеп торганча, бер генә һөнәре бар. Шул шөгыле аңа кыш чыгарга җитәрлек чимал тупларга мөмкинлек бирә. Натураль хуҗалык шартларында яшәгән бу кешеләр өчен ашлык белән тулган келәтләр – исән калуның төп шарты.

Сөннәтче бабай үз яшәешеннән бик канәгать. Ул үз эше, осталыгы белән горурлана, хәтта үзенең бу эшкә хокуклы икәнлеген документлаштыра. Документ – аның нәсел шәҗәрәсе. Үз нәселең белән горурлану, ата-бабаңны җиде буынга кадәр белү – татар халкындагы иң күркәм гадәт-традицияләрнең берсе.

Гомумән алганда, «Сөннәтче бабай» әсәре без укып күнеккән мавыктыргыч вакыйгалы, катлаулы әдәби әсәрдән аерылып тора. Сюжеты бик гади, алай гына да түгел, бу әсәр гадәти тормыш-көнкүреш тасвирламасы кебек тоелырга мөмкин. Ләкин сүз сәнгате остасы Исхакый каләме аны кызыклы, җәлеп итә торган итеп сурәтли, һәр халыкның үзенчәлекле яшәешен, мәдәниятен тәшкил иткән детальләр, күренешләр Исхакый тарафыннан мавыктыргыч итеп тасвирлана. Әдипнең образлы теле картиналарны җанлы, тере итеп гәүдәләндерә. Мондый мисал китерәсе килә. XIX гасырда яшәгән Казан университеты галиме Карл Фуксның «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» дигән китабы Казан татарлары турында иң компетентлы хезмәтләрдән санала. Галим бу китабында Казан татарларын бай фәнни материалга, ышанычлы, үзе күреп белгән һәм өйрәнгән фактларга таянып тасвирлый. Әйтик, мәҗлес һәм андагы аш-суны тасвирлап, күренекле ориенталист ризыкларның гаять күп булуын билгели һәм «...второе блюдо было что-то в роде лапши с бараниной, третье – пельмени, четвертое – пироги с мясом, пятое – ..., шестое – ..., восемнадцатое – ...», дип санап күрсәтә [5: 73]. Бүгенге көн укучысына унсигез төр аш чыккан мәҗлесне күз алдына китерүе шактый кыендыр. Ә XIX–XX йөз башлары татар җәмгатьчелеге өчен кунакка йөрешү, бер-береңнән уздырып сыйлау, үзенә күрә аралашу, үзеңне таныту чарасыбулган, ахрысы. «Сөннәтче бабай» әсәрендә дә нәкъ шундый картина бирелә: «...дүртенче самавырга хәзрәт кенә түгел, абыстай да каршы килә... шуның артыннан табык итеннән пешкән шурпа китерә иде. Ул бетәргә өлгерә алмый...» [3: 158] һ.б., һ.б. китә, аларны санап тору күп урынны алыр иде.

Сөннәтче бабай әнә шундый тормыштан башканы күз алдына китерә алмый. Чөнки болар барысы да аныкы, ул аңа балачагыннан ук сеңгән, ул шәхес буларак шул яшәеш белән формалашкан. Сәламәтлеккә зыян китерә торган гадәтләре юк, ул таза-сау, шуңа күрә тормышка куана, Ходайга шөкер итә. Ләкин карчыгының кинәт үлеп китүе аның көйле тормышын, андагы гармонияне бозып ташлый. Күнегелгән яшәештән тайпылыш фаҗигагә китерә –менә шушы фикер әдипнең татар халкына кисәтү ясавы: башка милләтнең яшәү образын өлге итеп алсаң – бәла булачак.

1938 елда Берлинда чыккан «Яңа милли юл» журналында басылган бер мәкаләсендә дә әдип чиркәүдә музыка уйнап йөрүче бер татар кешесе турында яза һәм аны «бәхетсез» дип атый. Чөнки, ул үзенең асылын югалткан. Аны башка халык барыбер кабул итмәячәк, ул аларга чит һәм шул ук вакытта үзенекеләрдән дә киткән. Кеше нинди мохит, нинди туфракта яралган – шунда калырга тиеш. «Сөннәтче бабай» әсәрендә дә үзе туган тирәлеккә ярашып яшәгән кешенең гармониясе бозылу фаҗигасе бирелгән. Гомер иткән карчыгының кинәт үлеп китүе, аның көйле тормышында китеклек барлыкка китерә һәм, ахыр чиктә, Сөннәтче бабайның тормыштан китүенә сәбәпче була.

Күргәнебезчә, Г. Исхакый үз вакытында күтәргән проблемалар бүгенге көндә тагын да әһәмиятлерәк һәм актуальрәк булып яңгыраш ала икән. Телен, теле белән бергә гореф-гадәтләрен, тормышка үзенчәлекле мөнәсәбәтен югалтып баручы татарларга карата әдип әсәрләренең идея-тематикасы кисәтү булып хезмәт итсен иде.

ӘДӘБИЯТ


1. Әйди Т. Үлемсез исем // Казан утлары, 1994. № 2. 194 б.
2. Исхакый Г. Тормышмы бу? // Мирас, 2002. № 2. 162 б.
3. Исхакый Г. Әсәрләр 15 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 462 б.
4. Рәмиев С., Хөсәенов Г. Мөхәммәтгаяз әфәнде // Казан утлары, 1994. № 2. 194 б.
5. Фукс Карл. Казанские татары. Казань, Фонд ТЯК., 1991. 210 с.


## Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕ ТЕЛЕНЕҢ ДИАЛЕКТАЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (фонетик диалектизмнар мисалында)


***А.Я. Хөсәинова** (Казан)*



В данной статье расматриваются диалектные фонетические особенности языка произведений Г. Исхаки. Анализируются и выявляются те или иные особенности, относящиеся, как среднему диалекту татарского языка, так и к западному. Посредством чего очередной раз доказывается смешанный характер чистопольского говора западного диалекта татарского языка. На примере употребления писателем фонетических диалектизмов прослеживается тенденция развития национального языка начала XX века, которая основывается на особенностях народного разговорного языка.


**Ключевые слова:** язык писателя, фонетические диалектизмы, фонетические варианты, смешанный говор, чередование согласных.



This article discusses the dialect phonetic features of the language of G. Ishaki's works. The author analyzes and reveals certain peculiarities related both to the middle dialect of the Tatar language and to the Western one. By means of which the mixed character of the Chistopol dialect of the Western Tatar language is once again proved. On the example of the use of phonetic dialectics by the writer the tendency of development of national language of the beginning of XX century which is based on features of national conversational language is traced.


**Key words:** a writer's language, phonetic dialect, phonetic variants, mixed dialect, the alternation of consonants.

Җирле сөйләм, гадәттә, персонаж телендә ишетелә, аның кайсы тарафтан булуын, тел культурасын тойдырырга, типиклаштырырга, индивидуальләштерергә булыша.

Җирле сөйләмнең матур әдәбиятта законлы урыны, диалект һәм милли телнең үзара бәйләнеше, йогынтысы белән билгеләнә. Диалектлар – халыкның тел диңгезен тулыландырып торучы чишмәләр алар. Ул чыганаклардан уртак телгә мәшәкатьсез аңлашылырдай сүзләр, гыйбарә, фразалар керә тора. Язучы да, берәр сүз әдәби телдә булмаганда, җирле сөйләмгә мөрәҗәгать итә һәм кайбер сүзләр әдәби сүзгә әйләнә [7: 121].

Диалекталь сүз әдәби телгә түбәндәге очракларда килеп керә: 1) әдәби телдә шушы төшенчәне белдерердәй сүз булмаса; 2) персонажның сөйләм үзенчәлеген сурәтләү өчен; 3) язучының үз хикәяләвендә милли колорит бирү өчен; 4) этнографик лексиканы бирү максаты белән.

Диалекталь сүзләрне куллану әсәрнең темасына, сурәтләү объектына, авторның максатына, аның эстетик идеалына, осталыгына бәйле. Татар язучыларының күпчелеге авылдан чыкканга күрә, һәр язучы үзе яшәгән төбәкнең диалекталь лексикасын куллана. Бу – автор сөйләмендә дә, персонаж сөйләмендә дә күзәтелә, хәтта аерым очракларда публицистикада да урын ала.

Матур әдәбиятта диалектизмнарның мәгънә төрлелеге күзәтелә. Автор аның мәгънәсен юл астына төшерергә мөмкин, сүздән соң җәя эчендә бирергә мөмкин, куштырнаклар эчендә күрсәтергә мөмкин; автор һәм персонаж тарафыннан мәгънәсе тасвирлап күрсәтелергә мөмкин [4: 158].

Г. Исхакый яшәгән һәм иҗат иткән чорда әдәби тел белән диалект-шивәләр арасындагы мөнәсәбәт тә ачыкланып җитә. Бу да шул чордагы милли әдәби телнең мөһим үсеш закончалыкларыннан берсе. Г. Исхакый әсәрләренең теле мисалында без әдәби телнең лексик-семантик, фонетик-орфоэпик һәм грамматик яктан кагыйдәләшә баруын һәм кайсы диалектларга нигезләнгәнлеген ачык күрәбез. Монда да диалектара җирлекнең кинәт кенә үсеп китмәгәнлеге, гасырлар дәвамында әзерләнеп килгәнлеге ачыклана. Әдәби телнең нигезендә татар халкының милли үзәге булган Казан тирәсендәге сөйләшләр ята. Биредә урта диалект белән беррәттән, көнбатыш диалектның да (мишәр сөйләменең) билгеле бер урын тотуын әйтеп үтәргә кирәк.

XIX гасырда һәм XX гасыр башында татар халкының милләт булып оешуы, шул җирлектә милли әдәби телнең үсеп китүе өчен шартлар өлгереп җитә, татарларда уяну чоры башлана. Г. Исхакыйның иҗат эшчәнлеге дә шул катлаулы күтәрелеш елларында чәчәк ата, ул вакыттагы иҗтимагый хәлләр татар көнкүрешендәге үзгәрешләр белән бәйләнешле рәвештә бара. Эш шунда ки, милли әдәби телнең үсешендә аерым кануннар хәрәкәт итә. Г. Исхакый иҗаты шул кануннарга тәңгәл килә, алар белән тыгыз бәйләнештә үсә. Нәкъ шушында Г. Исхакыйның тел эволюциясе ачык чагыла. Милли әдәби телнең төп закончалыкларыннан берсе — аның халык сөйләү теленә нигезләнүендә, Г. Исхакый әсәрләрендә әдәби телнең шушы юнәлештә үсеш тенденциясе ныгытыла [6: 29].

Гаяз Исхакый 1878 елның 23 февралендә Чистай өязенең Яуширмә авылында туа. Бу территориядә Көнбатыш диалектының чистай сөйләше таралган. Әлеге сөйләшкә хас үзенчәлекләр дә Г. Исхакый иҗатында да чагылыш тапкан. Без әлеге мәкаләдә Исхакый әсәрләрендә урын алаган фонетик үзенчәлекләргә игътибарны юнәлтәбез.

Фонетик диалектизмнар дип әдәби телдән аваз төзелешләре белән аерыла торган үзенчәлекләрне атыйлар [1: 79]. Күренекле татар диалектологы профессор Д.Б. Рамазанова билгеләвенчә, фонетик диалектизмнар төрле аваз тәңгәл-

лекләре, авазларның нинди позициядә килүләре, гомумтөрки характердагы фонетик закончалыклар белән бәйләнгән була» [3: 5].

Фонетик диалектизмнарга түбәндәге үзенчәлекләр керә: аваз тәңгәллекләре, аваз чиратлашуы, аваз өстәлү, аваз төшеп калу, саңгыраулашу һ.б. Тартыклар тәңгәллеге, ягъни диалекталь сүздә әдәби телдәге тартык авазга икенче тартык аваз тәңгәл килә.

Мишәр диалектына сүз башында *й*-ләштерү (бу күренеш әдәби телдә *җ* белән башлана торган сүзләрдә дә күзәтелә): «Үземнең күңелемнең *йемешен* сезгә тәкъдим итәм» [2: 50]. «Әбиләр төрле киңәш итеп, «үз тиде бугай дип» дип, *йеде* мунчадан *йеде йеде* таш, *йеде* корыган агачның ботагыннан *йеде* яфрак, *йеде* коедан таңга кадәр *йеде* төрле су, *йеде* кешенең *йеде* төшеннән *йеде* чүпрәк, *йеде* юлның *йеде* чатыннан *йеде* үлән алып, шуларны яндырып, бикәне төсләделәр дә» [2: 114]. «Мәдәният, мәгариф димез, бунларның берсен дә аңламый әйтәмезме, әллә аңласак та, хәзер безнең заманада шул сүзләрне әйтү мода булганга күрә генә әйтәмезме?» [2: 172] һ. б.

**ж~й.** Тексталрга шулай ук *җ*-ләштерү дә характерлы, ягъни күпчелек очракта *җ* авазы *й* авазына тәңгәлләшә. Мәсәлән: «Газизе! Бүген оемезгә Хәлимнән *җаучы* килде, этиләр бирмәкче булалар, зинһар, газизем, шул җаучы өстенә *җаучы* җибәрсәнә, мин адарга барамыйм дип, сиңа барам дип котылыр идем...» [2: 48]. «Кәләпүшче кыз» минем элеккеге әсәрләремдин булдыгындин, әлбәттә, бик күп *йерләрендә* кимчелекләре бардыр» [2: 51].

«Камәр һәман унбиш яшенә *йетәр-йетмәс* һәр кешегә бик кадерле, бәһасыз яшьлек заманнары *йеткән* вакытта атасыз калып ятимә исемен алган иде» [2: 51].

Һәм Кәриманең уңганлык, матурлык берлә исеме китүе, иргә бару хәбәре чыкса, чибәррәк *йерләрдән җаучылар* килүенә дә ышандырган иде» [2: 52].

«Без, биш-алты иптәш белән төрлемез-төрле якка таралырга вакыт *йетә* башлаганга, Казанның бер бакчасына чәй эчәргә җыелган идек» [2: 79].

«Минем туган *йерем* өч-дүрт көн *парахут*, берәр тәүлек тимер юл берлән барырлык озын юл иде» [2: 81] һ.б.

Бу ике төрле күренешнең бер текст кыссаларында туры килүенең сәбәбен Чистай төбәгендә куп милләт вәкилләре, төрле яклардан килеп урнашкан мишәрләр һәм урта диалект вәкилләре яшәеү белән аңлатып була. Алар исә җирле татар халкы һәм Казан ягыннан күчкән урта диалект вәкилләре белән мәдәни-икътисади бәйләнешкә керәләр, тормыш-көнкүреш һәм телләре ягыннан бер-берсенә үзара тәэсир итешеп яши башлыйлар. Шулай итеп, чистай сөйләше, нигездә, *ц*-лаштыра торганнардан саналса да, катнаш сөйләш булып формалашкан [5: 222].

Аерым сүзләрдә күзәтелә торган тәңгәллекләр: **г ~ к.** Бу тәңгәллек урта диалектның кайбер сөйләшләрендә, мәсәлән, керәшен татарлары сөйләшләрендә: «...никадәр җәфалар *чикеп* аерылган икән дип хөкемме идәрсең?» [2: 50]; **х ~ һ** тәңгәллеге төрле дәрәҗәдә татар теленең барлык сөйләшләрендә дә таралган, ләкин керәшен сөйләшләрендә, кама тамагы, пермь сөйләшләрендә һәм себер диалектларында системалы рәвештә күзәтелә. «Билгакес, гаебене күрсәтеп, шуннан котылыр өчен юл күрсәтү хәер *хаһлыктыр*» [2: 113]; **д ~ е.** Бу үзенчәлек билгеле бер сүзләрдә генә очрый: «Мәдрәсәгә тел *тиермә*, атам, мәдрәсә гыйлем казаны, ..., аларга тел *тиерү*дингә тел *тиерү* була, дингә һәрвакыт шөкранәдә булырга кирәк» [2: 32]; **м ~ б.** Аерым сүзләрдәсүз башындагы ирен-ирен *м* тартыгына *б* тартыгы тәңгәл килә. «Бикнең бу хәлене хәбәр алгач, *бунда* калган зур приказчик Мәкәрҗәгә ... телеграм да бирде» [2: 115].

Шулай ук Г. Исхакый үз әсәрләрендә алынма сүзләренең диалекталь фонетик вариантын куллана. Мәсәлән: «Стенадагы китаплар куяр өчен ясалган шүрлекнең өстендә бер *фурашкы*, бер татар бүреге бер *нимес фурашкасы*, бер салам эшләпәсе ята иде» [2: 271]; «Мин чалбарымны рәтләгән булып, стражник алдында тагы бераз торып, *политсәгә* кердем» [2: 275] һ.б.

Шулай итеп, катнаш сөйләшнең торле фонетик вариантларын куллану язучы теленә хас үзенчәлекләренең берсе. Әлеге үзенчәлекләр Исхакыйның туган ягының милли колоритын бөтен тулылыгында күзалларга мөмкинлек бирә. Диалектизмнарны тикшерү, язучының тел-стиль үзенчәлекләрен генә түгел, татар әдәби теленең формалашу тарихын өйрәнү өчен дә зур әһәмияткә ия.

ӘДӘБИЯТ


1. Ахатов Г.Х. Лексика татарского языка. Казань, 1995. 93 с.
2. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 1 т.: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). 399 б.
3. Рамазанова Д.Б. Вопросы татарской диалектологии. Казань: Алма-Лит, 2008. 272 с.
4. Татар теле лексикологиясе: өч томда / проект җитәкчесе М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.
5. Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.
6. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе: татар әдәби теленең үсеш тарихыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.
7. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Раннур, 2002. 352 б.


## «СОВЕТ ИЛЛӘРЕНДӘ НИЛӘР БАР?»
## («Яңа милли юл» журналы материаллары нигезендә)


***Г.А. Хөснетдинова** (Казан)*



В данной статье рассматриваются публицистические статьи татарского классика Г. Исхаки, напечатанные в журнале «Яңа милли юл». В статьях, написанных в 1930 годах XX века, Г. Исхаки анализирует события происходящие в России. Критически относится к политике Советского государства в отношении к национальным меньшинствам, к коллективизации и религии.


**Ключевые слова:** Гаяз Исхакый, публицистика, татарская периодическая печать, эмигрантская периодическая печать, татарская литература, история.



This article discusses the journalistic articles of the Tatar classic G. Ishaki, published in the journal «Yana Milli Yul». In articles written in 1930 of the XX century, Mr. Ishaki analyzes the events taking place in Russia. It is critical to the policy of the Soviet state in relation to national minorities, collectivization and religion.


**Key words:** Gayaz Iskhaky, journalism, Tatar periodicals, emigrant periodicals, Tatar literature, history.


Гаяз Исхакый исемен ишетү белән күз алдына киң колачлы әдип, үткен телле публицист, ялкынлы журналист, курку белмәс милли хәрәкәт юлбашчысының җыелма образы килеп баса.

Гаяз Исхакый 1917 ел Февраль инкыйлабын шатланып кабул итә. Россиядә яшәүче халыкларның язмышындагы бу тарихи вакыйгага зур өметләр баглый, чөнки ул халкының үткәнен, аның самодержавия шартларында күргән җәберҗәфаларын яхшы белә. Шуңа да инкыйлаби, иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрдән файдаланып калырга, милли-азатлык хәрәкәтен ахыргача җиткерергә хыяллана, милли изүдән коткару юлларын эзли. Ул шул вакыйгалар эченә кереп китә.

Кызганыч ки, әмма тарих башкача юнәлеш ала, Октябрь инкыйлабыннан соң татар халкының милли азатлыгы өчен көрәшүче Г. Исхакыйга үз илендә иҗат итәргә, иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнергә мөмкинлек калмый һәм ул мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була.

Мөһаҗирлектә дә ул туган иленә, халкына тугрылыклы булып кала. Чит җирләрдә яшәүче милләттәшләре өчен чын мәгънәсендә «милләт хадименә» әйләнә. Аларны оештыра, милли бердәмлек рухында тәрбияләү өчен барын да эшләргә тырыша.

Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә башкарган иң зур нәтиҗәле эшләреннән берсе – «Милли юл» («Яңа милли юл») журналын чыгару. Аның беренче саны 1928 елның 23 декабрендә, соңгысы – 136 нчы саны – 1939 елның октябрендә дөнья күрә. Гарәп хәрефләре белән басылган татарча бу журнал (1930 елдан «Яңа милли юл» исеме белән басыла башлый), нигездә Берлинда нәшер ителә [7: 13].

Әмма «илемезнең иреге югалганнан бирле беренче мәртәбә Идел буеның истикъляль байрагын күтәргән, большевикларның иң сөйли торган бер мәҗмугасы булып өлгергән» [6: 12] бу журнал, аның мөхәррире хакында совет илендә озак еллар дәвамында ялган сүзләр, ялгыш фикерләрдән гайре сүз сөйләнмәде. Бары үзгәртеп кору чоры гына киң җәмәгатьчелеккә бер гаепсезгә рәнҗетелгән шәхесләр, «кара фикерле» дип мөһер сугылган газет-журналлар белән танышу мөмкинлеге тудырды.

Иҗтимагый фикер, ялкынлы каләм иясе Г. Исхакый өчен «Милли юл» журналы бер трибунага әверелә. Ул журналистик эшчәнлеген тагын да активрак дәвам иттереп, үзенең туган халкы, туган җире азатлыгы, мөстәкыйльлеге өчен көчен аямыйча көрәшен дәвам итә. Әле тәнкыйтьләп, әле яклап, әле киңәш итеп теге яки бу мәсьәлә хакында үз фикерләрен әйтә, илдә барган вакыйгаларга анализ бирә. Әлбәттә, бер мәкалә кыссаларында гына Г. Исхакыйның публицистик эшчәнлегенә бәя бирү, аны иңләп алу мөмкин түгел. Шул сәбәпле бу мәкаләдә аның 1930 елгы «Яңа милли юл» журналында басылган кайбер мәкалә-язмаларына күзәтү ясау максат итеп алынды.

Журналның беренче саны «Бер еллык тәҗрибә вә киләчәккә план» исемле хисап мәкалә белән ачыла. Ул «Милли юл» журналы нәшер ителә башлауга бер ел тулу уңае белән язылган. Мөхәррир үзенең язучылык осталыгын җигеп, журналның берьеллык гомерен бер яшьлек баланың үсүе, дөньяны танып-белүе, төрле авыруларга, җил-давылларга каршы торырга өйрәнүе белән тиңләштереп сурәтләп бирә. Әмма әлегә шундый яшь булуына карамастан, ул» унике ел караңгылыкта торган милләт балаларына бердән күк капагы ачылгандай, бөтен барачак юлларын күрсәткән, аларның күңелләренә ялтыраган милли маяклар кага алды» [1: 2], дип шатлана Г. Исхакый һәм киләчәктә дә журналның шул мәсләкне тотып, көрәш юлын дәвам итәчәгенә ышанычын, өметен белдерә.

Г. Исхакыйның Совет Татарстаны оешуга 10 ел тулу уңае белән язган мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Күләмле һәм шактый күп мәгълүмат туплаган бу мәкаләләр журналның дүрт санында басыла. Аларда автор совет хакимиятен, аның алып барган сәясәтен кискен тәнкыйтьли, үз укучыларын милли азатлык көрәшенә рухи яктан әзерли.

Совет Татарстаны оешуга 10 ел тулган көн, ягъни 1930 елның 25 июне, Г. Исхакый фикеренчә, «милләтләр тормышында зур вакыт аралыгы булмаса да, татар милләте өчен бөтен барлыгын югалткан, шомлы бер көн. Ул 1552 елда Иван Грозный тарафыннан Казан истикъляленең кан дәрьясында буылган 15 октябрь көне кебек икенче бер “милли матәм” көне.

Аларның аермасы бары шунда: Иван Грозный безнең илебезне, суыбызны һәм матди байлыгыбызны таласа, кызыл чикмәнгә бөркәнгән, кызыл рус хулиганы илебез һәм йортыбызның җанын, мәдәниятен җимерде» [4: 1].

Татарстан Совет җөмһүрияттен ясауда Мәскәү ике төрле максатны күздә тотып эш итә. Аның берсе Идел-Урал буендагы көчле бер төрек-татар берлеген

бетерү, икенчесе – кыска күзле татар милләтчеләрен сүздә мохтариат биреп алдау була. Мохтариат төзү беренче чиратта Мәскәү өчен файдалы һәм шул юлда хезмәт иттерү өчен эшләнелә [4: 1].

Яшь республикага илдә дәвам иткән икътисади кризисның бөтен авырлыгын татырга туры килә. Әле дә бетеп җитмәгән Гражданнар сугышы азык-төлекне, көчкә эшли торган санагать продукциясен суырып кына тора. Авылдан икмәкне тартып алу көчәйгәннән-көчәя. Бу үз чиратында 1921 елдагы ачлыкның килеп чыгуына һәм миллионлаган халыкның ачтан үлүенә сәбәп була. Россиянең ул еллардагы халәтен Гаяз Исхакый «фаҗига» дип тасвирлый.

Совет хөкүмәте бу авырлыклардан файдаланып үзенең башка сыймас икътисади һәм сәяси тәҗрибәләрен үткәрүне дәвам итә.

Иң зур икътисади җимерүләр массакүләм колхозлаштыру аркасында килеп чыга. Чөнки ул әһәмияте ягыннан Октябрьгә, ә корбаннар саны ягыннан Гражданнар сугышына тиң вакыйга була. Колхозлаштыру барышында барлык нык крестьян һәм күпчелек урта хәлле крестьян хуҗалыкларының мөлкәте конфискацияләнә, таланып бетә. Ә совет системасына баш иймәгәннәре төрмәләргә утыртыла, сөргеннәргә сөрелә.

«Татарстан тоташтан колхозлаштырыла» исеме белән басылган мәкаләсендә публицист» кумәк хуҗалыкузенең табигый юлыннан барса, табигый үссә, бер дә искитәрлек нәрсә түгел, чөнки ул күптәннән Яурупада билгеле һәм таралган, һәм дә халыкның тормышын җиңеләйтә торган нәрсә» [2: 1] булуын яза. Әмма совет хөкүмәте күмәкләштерүне үз мәнфәгатендә куллана. Аның күзаллавынча күмәкләшкән хуҗалыктан иген җыю, аның күпме иканлеген белеп тору, ашлыкны бирмәсәләр гаскәр көче белән талап алу җиңел һәм табышлырак булачак [2: 3].

Гаяз Исхакыйны илнең, төгәл итеп әйткәндә Совет Татарстанының икътисади хәле генә түгел милли мәдәниятнең тырышы да борчый. Чөнки татар милләтенең милли-мәдәни мирасы борынгы тамырларыннан, чыганакларыннан ясалма рәвештә аерыла башлый. Өстен сыйныф вәкилләренең иҗат мирасы ислам, милләтчелек мәдәнияте мирасы дип күрсәтелә һәм тыела. Рәсми совет сәясәте татар халкын элек артта калган халыклар рәтенә куя.

Ялкынлы публицист хөкүмәтнең мондый сәясәте белән килешми. Ул «Совет Татарстанының 10 еллык бәйрәме» исемле мәкаләсендә совет газет-журналларында мисал итеп китерелгән татар халкы арасындагы укый-яза белүчеләрнең саны дөреслектән ерак булуы хакында яза һәмбу мәсьәләгә карата үз аңлатмасын бирә: «Белемгә омтылу татар кешесендә элек-электән килгән гүзәл гадәтләрнең берсе. Шуңа күрә, рәсми 1896 елның сан алу хисабына караганда Казан губернасындагы татарлар арасында укый-яза белүчеләрнең саны 20% тыр. Ә 1920 елда 18,0% ка төшүе, ә инде 1929 елда 45% менүе мөмкин түгел. Бу большевикларның киләчәктәге үсүләрен күтәреп күрсәтер өчен ясалган, уйланып эшләнгән ялганыдыр». Фикерен дәвам итеп: «әгәр дә инде укый-яза белү дигәндә большевиклар татарның русча укый-яза белүен алалар икән, бу, саннарның дөрес булу ихтималын да» [5: 2] белдерә. Әлбәттә, туган телеңнән тыш башка телләрдә укый-яза белү нур өстенә нур гынадыр, әмма аның көчләп тагылуы фәнни яктан да, гамәли яктан да хаталы булуы ачыкланды. Игътибар үзәгенең татар мәктәпләрендә рус телен өйрәтүгә күчерелүе милли телне өйрәтү проблемаларының онытылуына китерде. Алай гына да түгел, татар милли мәктәпләре челтәре гомумән тарая барды.

Социалистик үзгәрешләр татар халкының тормышына гына түгел, хәтта аның ничәмә-ничә гасырлар кулланышта йөргән алфавитына да кулын суза. Латин әлифбасы иң алдынгы һәм киләчәк бөтендөнья инкыйлабына булышлык итә торган әлифба дип танылa. Ә әлифба алышыну аркасында белемле

булу бик күпләр өчен көч җитмәс нәрсәгә әйләнә, меңнәрчә китаплар, кыйммәтле кульязмалар әрәм була, аларның күбесе юкка чыга. Гаяз Исхакый халык өстендә мондый тәҗрибәләр үткәрүгә, гарәп әлифбасын латин әлифбасы белән алыштыруга каршы чыга. Ул үзенең ризасызлыгын белдереп болай ди: «татар дөньясы рус, латин, әрмән әлифбаларыннан ясалган кырык кырамалы бер әлифбаны кабул итәргә мәҗбүр ителә» [4: 3]. Моның белән Г. Исхакый фикеренчә, Мәскәү Совет Татарстанындагы халыкның үзлеген, минлеген бетерер өчен аның мәдәниятенең тарихи тармагын кисә. Бу татар милли мәдәнияте өлкәсендәге икенче «сыйнфый чистарту» сыманрак бер нәрсә була.

Вакытлы матбугат, матур әдәбият һәм китап бастыру турында сөйләгәндә дә шул ук алдаулар, ялганнар кабатлануын яза Гаяз Исхакый. Ул мәкаләләрендә ялганны ачыкларга, дөреслекне күрсәтергә тырыша, большевизмның мәдәниятебез өчен зур бер һәлакәт булуына борчыла. Аның фикеренчә «ун ел эчендә "әдәби" исемен алырлык әсәрләр йөзгә бер, яисә бөтенләй юк. Алар большевик лыгырдамасыннан гыйбарәтләр. Бу көнгә кадәр 10 ел эчендә татар большевик әдәбиятыннан күзгә ташланырлык, әдәбият тарихына кертерлек әсәрләр язылмаган, һичбер кулга алырлык әдип тумаган. Большевиклык агымы татар әдәбиятын тәмам харап итте һәм харап итүен дәвам итә. Бигрәк тә шигырь бүлеме искиткеч ярлы» [5: 5]. Шул ук сүзләр татар театрының репертуарына карата да әйтелә.

Дингә кагылышлы мәсьәләләр дә Совет Татарстанында чишелми кала. Коммунистлар хөкүмәте татар кешесенең бердән-бер ышанычы булып калган диненә – мөселманлыгына тия башлый. Беренче елларда дини яктан иркенлек бирелгән булса да, тора-бара мәчетләр һәммәсе Мәскәү хөкүмәтенең малы итеп игълан ителә һәм талана. Имамнарга зур салымнар салына, намаз уку урыннарыннан файдаланган өчен фатир хакы түләнү кертелә. Дини китап, Коръән-кәримнәрне бастыру һәм сату эше дә туктатыла. Хөкүмәт мәчетләрне бикли, яисә клубка, кызыл чәйханәләргә әверелдерә. Мулла-мәзиннең дин өйрәтүен, балалар укытуын большевик хөкүмәте контрреволюцион бер эш итеп билгели, аларны төрмәләргә яба, сөргенгә сөрә [3: 11].

Большевик хөкүмәте Алласызлар, динсезләр оешмалары ясап хөкүмәт хезмәтендәге кешеләрне, фабрика һәм заводларда эшләүче эшчеләрне, намаз укыган һәм ураза тоткан, баласына мулладан исем куштырган өчен эш урыннарыннан, паектан мәхрүм итү белән куркыта. Шуның белән аны диненнән ваз кичтерергә омтыла.

«Болар барысы да Совет җөмһүриятенең татар халкына ун елда иткән хезмәтләре, татар коммунистлары дип йөри торган кешеләрнең үзләренең милләтләренә эшләгән хыянәтләренең җимеше» [4: 6], – дип нәтиҗә ясый Гаяз Исхакый.

Чыннан да, инкыйлабтан соң вәгъдә ителгән якты киләчәккә тиз генә юл салу планы үтәлми, ул юл озынрак һәм кыенрак булып чыга.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, Г. Исхакыйның публицистик мәкаләләре идея-проблематик яктан гаять үзенчәлекле. Гасырга якын вакыт үтүгә карамастан, аларда күтәрелгән проблемалар бүгендә актуальлеген, кыйммәтен югалтмыйлар.

## ӘДӘБИЯТ


1. Исхакый Г. Бер еллык тәҗрибә вә киләчәккә план // Яңа милли юл. 1930. № 1. Б. 1–5.
2. Исхакый Г. Татарстан тоташтан колхозлаштырыла // Яңа милли юл. 1930. № 2. Б. 1–6.
3. Исхакый Г. Идел-Уралда ислам диненең хәзерге хәле // Яңа милли юл. 1930. № 5. Б. 4–13.
4. Исхакый Г. Татарстан совет җөмһүриятенең унъеллыгы // Яңа милли юл. 1930. № 6. Б. 1–6.
5. Исхакый Г. Совет Татарстанының 10 еллык бәйрәме // Яңа милли юл. 1930. № 12. Б. 1–7.
6. Исхакый Г. Гәзитәчелек эшендә егерме биш ел // Яңа милли юл. 1931. № 9. Б. 10–13.
7. Миңнегулов Х. Кайда да милләтпәрвәр // Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 10–25.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТОТРЫКЛЫ ТӨЗЕЛМӘЛӘР
## (Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» пьесасына нигезләнеп)

***М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина*** *(Казан)*

Данная статья посвящена исследованию языковых аспектов художественного наследия Гаяза Исхаки. Цель работы – провести анализ лингвистических исследований на материале пьесы Г. Исхаки «Дулкын эчендә». Для анализа собран фактический материал – фразеологизмы в произведении Г. Исхаки. Они распределены по лексическим группам и по определенным группам по их структуре. Также рассматривается синонимия фразеологизмов в указанном произведении.
**Ключевые слова:** Г. Исхаки, фразеологизмы, татарский язык, языковые аспекты, пьеса, синонимические варианты.

This article is devoted to the study of linguistic aspects of the artistic heritage of Gayaz Ishaki. The aim of this work is to analyze linguistic research on the play of G. Ishaki «Dulkyn ascenda». For the analysis of the collected actual material – idioms in the work of G. Ishaki. They are divided into lexical groups and certain groups according to their structure. Synonymy of phraseological units in the specified product is also considered.
**Key words:** G. Ishaki, phraseological units, Tatar language, language aspects, play, synonymous variants.

Телдә таркалмый торган, тотрыклы төзелмәләр – фразеологизмнар әдәби текст эчендә ассоциатив сурәтләү чарасы вазифасын башкаралар. Бу очракта фразеологизм төшенчәсе халык телендәге мәкаль-әйтемнәрне дә, үткен, образлы гыйбарәләрне дә үз эченә ала. Язучының тел-стиль үзенчәлекләрен ачыклау сүзләрнең этимологиясенә, беренчел һәм икенчел мәгънәләренә, синонимик, антонимик, омонимик, фразеологик мөнәсәбәтләргә керү үзенчәлекләренә тукталырга тулы мөмкинлекләр бирә. Болардан тыш, әдәби әсәр белән эш итү башка киңлекләр дә ача: текстның семантик һәм хисси-эмоциональ кырын билгеләү, абзацара бәйләнешне ачыклау, күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен, морфологик, синтаксик һәм пунктуацион үзенчәлекләрне күзәтү, стилистик ялгышларга күзәтү ясау һ.б.

XX йөзнең 1940 елларында фразеологик әйтелмәләрнең төрләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәнү, рәткә, системага салулар башлана. Л. Җәләй, Ш. Рамазанов, Л. Мәхмүтова, Н. Борһанова, В. Хаков, Г. Ахунҗанов, Х. Курбатов, Г. Әхәтов, Н. Исәнбәт, Ф. Сафиуллина һәм башка галимнәребезнең гыйльми хезмәтләре, сүзлекләре дөнья күрә [11: 289]. Шулай ук 1977–1981 елларда өч томда чыккан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә фразеологик әйтемнәргә зур урын бирелә. Телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртүләргә бирешмичә таркалмый торган сүзтезмәләр белән дә белдереләләр: *авыз еру – көлү, авыз сулары килү – кызыгу.* Телдәге мондый сүзтезмәләрне фразеологизмнар (грек. *phrasis* – тәгъбир, сөйләм әйләнмәсе, *logos* – өйрәнү) дип атыйлар. Мондый сүзтезмәләрне өйрәнә торган тармакны фразеология диләр. Г. Алпаров фразеологик берәмлекләрне читләтеп әйтелгән сүзләр (кинаяләр), тапкыр җаваплар, каргышлар һәм алкышлар кебек исем астында биргән [1: 176].

Ф.С. Сафиуллина фикеренчә, фразеологизмнар – таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган тотрыклы сүзтезмәләр [8: 135]. Галимә «Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология» хезмәтендә, тел берәмлекләре буларак, тотрыклы, фразеологик сүзтезмәләрнең түбәндәге дифференциаль билгеләрен аерып чыгара: 1) сүзләрнең аерым булуы (кимендә ике сүз булу); 2) компонентларның мәгънәви кушылуы; 3) мәгънәнең һәм аны белдерүче лексик-грамматик чараларның тотрыклыгы; 4) сөйләмдә әзер килеш кулланылуы [8 : 136].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә дә фразеологизмга карата шуңа охшаш билгеләмә урын алган: Фразеологизм – икенче телгә хәрефкә-хәреф тәрҗемә ителми торган тотрыклы сүз тезмәсе, әйләнмә; идиома [5: 353].

Рус тел белемендә Н.М. Шанский фразеологик тәгъбирләр дигән дүртенче төр турында мәгълүмат бирә. Бу – ирекле мәгънәле сүзләрдән төзелгән, әмма сөйләмгә әзер килеш килеп керә торган әйтелмәләр: *авырлык үзәге, гәҗит сүзе* һ.б. Гомуми мәгънә һәр сүзнең лексик мәгънәсеннән җыела [10: 160].

А.И. Молотков фразеологизмнарны лексик-граматтик яктан тикшерә, түбәндәге төркемчәләрен аерып чыгара: 1) исемле фразеологизмнар; 2) фигыльле фразеологизмнар; 3) рәвешле фразеологизмнар; 4) сыйфатлы фразеологизмнар; 5) фигыльле-пропозициональ фразеологизмнар; 6) ымлыклы фразеологизмнар [7: 280].

Л.А. Введенская, М.Т. Баранов һәм Ю.А. Гвоздарев үзләренең хезмәтләрендә укучыларның фразеология бүлеген өйрәнү барышында түбәндәгеләрне белергә тиешлекне ассызыклыйлар:

1) фразеологиянең гомуми тел системасындагы урынын, төп үзенчәлекләрен, аларга нигезләнеп бүленеп чыккан төркемчәләрен, ясалыш ысулларын, тотрыклы сүзтезмәләрнең сөйләмдәге вазифасын, телнең фразеологик составы үзгәрү сәбәпләрен, төп фразеологик сүзлекләрне һәм белешмә китапларын күз уңында тотарга;

2) текстан фразеологизмнарны аерып ала белергә, аларны җөмләдәге синтаксик ролен билгеләргә, мөмкин булган очракларда фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәсен билгели белергә, сөйләмдә аларны стилистик үзенчәлекләрен исәпкә алып кулланырга тиеш [3: 98].

«Рус теле дәресләрендә лексика һәм фразеологияне укыту методикасы» дигән хезмәтендә М.Т. Баранов укучыларга таләпләрне башкачарак билгели: 1) сүзләрнең һәм фразеологизмнарның лексик мәгънәсен аерырга; 2) таныш сүзләр һәм фразеологизмнарның лексик мәгънәләрен аңлатырга; 3) контекстта сүз яки фразеологик әйтелмәнең кайсы мәгънәдә кулланылганын билгеләргә; 4) текстан өйрәнелгән лексик һәм фразеологик күренешләрне табарга; 5) бирелгән текстан лексик күренешләрне һәм фразеологизмнарны сайлап ала белергә; 6) бирелгән текстан өйрәнелгән таныш лексик күренешләрне һәм тотрыклы сүзтезмәләрне төркемли алырга; 7) укучы төрле аңлатмалы сүзлекләр, шул исәптән фразеологик сүзлекләрне дә, куллана белергә тиеш» [2: 99].

Язучылар, драматурглар әсәрләрендә яңгыраган уй-фикерләрен тирән, үткен, образлы итү; персонажларның характерларын ачу, аларның сөйләм телен үзенчәлекле, бай итүне сурәтләү максатларыннан фразеологик әйтелмәләрдән бик иркен файдалана. Г. Исхакыйның сәхнә әсәрләре фразеологизмнарга шактый бай икәнлеге күренә. Гаяз Исхакый, XX йөз башы драматургиясенә хас булган традицияләргә яңалык кертеп, 1920 елда «Дулкын эчендә» дигән биш пәрдәлек пьеса яза. Төп идея – тол хатын Разыяның баласын яратуы, аны тәрбияләүдәге бурычы. Әлеге бурычы Разыяга гаиләне яңадан корырга ирек бирми, бөтен гомерен кызына багышлый, соңрак бер үзе ялгыз кала. Кызганыч, Разыяның бала каршындагы бурычы Хәйрулланы да бәхетсез итә, ул сугышта үлә, аның балалары ятим кала. Автор гражданнар сугышы фаҗигаләрен, большевикларның кансызлыгын икенче яктан ача: комсызлык, талаш, үтереш, нәфрәт.

Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» дигән биш пәрдәлек пьесасында урын алган фразеологизмнарның күбесе тел, сүз, сөйләмгә, дөнья көтү, илдә барган яңалыкларга кагылышлы. Мисаллар: К ә р и м ә. Дөнья бу, көннең яхшысы бар, яманы бар, бер-бер авырлыкка килгәндә, кемгә үз итеп **тел ачарсың**? Х ә й р у л л а. Мәхфузә белә, бер генә **тәмсез әйткәнне** ишеттегезме? Р а з ы я.

Беләм, Хәйрулла абзый, барысын да беләм, үзеңә каршы да, балаларыңа каршы да әйтер сүзем юк. Ләкин шулай инде, үземә, үземне шул бердәнбер баламны тәрбиягә багышлыйм, дип **сүз биргән** инде. Х ә й р у л л а. Бар бозыклыгым булса, инде шул, үземезнең театрдан калмыйм. Анда бит хәзер **ил-көн йөри** [6: 278].

Кешенең рухи халәтенә бәйле фразеологизмнарның халык телендә еш кулланыла торган **күңел** сүзенең синонимик вариантлары да Г. Исхакый тарафыннан бик оста файдаланылган: *күңел төшү, күңеле калу. күңел сыкрау, күңел курку, күңел тыну, күңел теләү, күңел ашкыну, күңелне кыру, күңелгә керү, күңел төрлеләнү, күңелдә тынычлык бетү, күңеленнән рәнҗеп үлү, күңелгә авыр алу, күңеле шикләнү, нечкә күңел* һ.б.: К ә р и м ә. **Дөнья үткәрү** бик авыр бит, кызым! **Күңел төшү** дигән эш тә бар. **Нәфес теләү** дигән нәрсә дә бар, **эч пошу** дигән уңайсызлык та бар. **Күңелемә дә кереп чыкканы** юк. Х ә й р у л л а. ...алай-болай **күңелең шикләнә** икән, менә тот та нотариус белән бөтен малыңны кызыңа яздыр... [6: 279]. **Разыя**. Балам бар, Кәримә абызтай, балам! Шуны тәрбияләп, шуны үстерим, шуның **күңелен кырмыйм** дим. Кәримә. Дөрест, баланың **күңеле калмый булмый**. Р а з ы я. Тагы **күңелем төрләләнде** [6: 280]. Р а з ы я. Шулай, шулай, ләкин **күңел** бит **сыкрый**, Кәримә абыстай... [6: 291]. Р а з ы я. Ничек чыкмыйсың? Бердәнбер кызым иде, инде ике ай була – бер хәбәр юк, **күңел тынмый** шул! [6: 30]. Р а з ы я (ялгыз). Әллә ни **күңелдә тынычлык бетте!** Бу, дим. Хәйрулла абзый **күңеленнән рәнҗеп үлдеме** икән әллә дим? [6: 308]. Р а з ы я. **Күңелем курка** иде [6: 317]. Биредә *күңел сыкрауның* синонимы буларак автор тарафыннан *күңел төшү, күңел тынмау, күңелдә тынычлык бетү, эч пошу* һ.б. вариантлар кулланылган. Әлеге күчерелмә мәгънәдәге сүзләр телдәге образлылыкны, эмоциональлелекне, мәгънә төсмерләрен бирүдә алыштыргысыз чара хезмәтен үтиләр.

Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» дигән әлеге пьесасында синонимик фразеологизмнар белән бергә компонетлар составы үзгәрәк, әмма мәгънәләре бердәй яки якын булган, **тел, сүз, сөйләмгә** бәйле – антонимик эчтәлекле фразеологик берәмлекләр дә бар. Мәсәлән: *Тәмсез әйтү* (усал итеп әйтү, әче телле, явыз) – *сүзе тәмле* (тәмле телле).

Болардан тыш әсәрдә сөйләм телендә һәм әдәби телдә еш очрый торган **кешедәге уңай сыйфатларны** калку итеп күрсәтүгә хезмәт итә торган тәгъбир-гыйбарәләр, фразеологик әйтелмәләр дә күп. Мәсәлән: *тугры кеше, кече күңелле, ачык йөзле* кебек фразеологизнар. Сүзлекләрдән күренгәнчә, *тугры (туры) кеше* – туры сүзле, намуслы кешегә карата әйтелә; *кече күңелле* – түбәнчелекле, үзен зурга куймаучы, ихлас кеше, *ачык йөзле* – көләч, эчкерсез, ягымлы сүз белән каршы алучы кешеләргә карата әйтелә.

Кешенең тышкы кыяфәтенә, холык-фигыленә бәйле аның тискәре сыйфатларыннан, җитешсезлекләреннән, дөньяның начарлыгыннан **көлүгә, хурлауга, әрләүгә, кимсетүгә, мыскыл итүгә** нисбәтле фразеологизмнардан түбәндәге мисалларны китерергә була: «Бер-бер **азып-тузып кайтканымны** күрдеңезме?» «Дөнья бит **канга баткан**» [6: 278]. «**Нәфес теләү** дигән нәрсә дә бар...» [6: 279]. «Нәрсә **уклау йоткан кебек** каткансың?»; «Шулай, шулай, башыңны күтәрә төш, ни йөзеңне **әвене янган урыс** төсле ясыйсың...» [6: 284]; «Бөтен яшь егетләрне әрәм итеп бетерде, авылда бит **күзгә алырлык кеше калмаган, бөтен кыз утырып кала** инде!» [6: 286–287].

Фразеологик берәмлекләрнең структур ягын исәпкә алсак, шуны әйтергә була: Г. Исхакый әсәрләрендә ике яки өч компоненттан торган фразеологик әйтелмәләрне еш очратырга була. Мондый идиомалар «исем-фигыль» һәм «фигыль-фигыль» калыбында булалар: «**Эч пошу** дигән уңайсызлык та бар» [6: 279]. Эч пошу – шикләнү, шомлану, борчылу хисе кичерү. «Галимә **катып**

**кала**» [6: 327]. Катып калу – 1) хәрәкәтсез калу; 2) туңу; 3) ис китү, гаҗәпләнү, хәйран калу.

Гомумиләштереп әйткәндә, Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» дигән пьесасында фразеологик әйтелмәләрнең ике, өч, дүрт компоненттан торган төрләре күзәтелә. Иң элек ике компоненттан торган фразеологик әйтелмәләрнең түбәндәге модельләрен карап үтик:

А) исем + исем моделе;

Балаларга да **күз-колак** кирәк бит [6: 278].

Б) исем + фигыль моделе:

Сезнең **кулыгызны сорармын** дип торадыр идем... [6: 295].

Өч компоненттан торган фразеологик әйтелмәләрнең модельләре:

А) исем + исем + фигыль моделе:

Мин хәзер **җеп очымны югалттым**... [6: 291].

Б) сыйфат + исем + фигыль моделе:

Хәерле булсын, кызым, **зур адым атладың**, ай-һай, көчең җитәрме икән? [6: 279].

В) исем + фигыль + исем моделе:

Синең **күңелең курыкмаган вакыты** булмады инде [6: 309].

Дүрт компоненттан торган фразеологик әйтелмәләрнең модельләре: исем + сыйфат + исем + фигыль моделе, сыйфат + исем + исем + фигыль моделе: Кызым **тормышның иң зур адымын атлый**, **нечкә сират күпереннән кичә**, насы кебек бәхетсез булмасын... [6: 297].

Пьесада кеше әгъзаларын белдерә торган кайбер атамалардан бик күп фразеологизмнар ясалган: *күңел сыкрау, йөрәк борчылу, кулдан ычкындыру, борын салындыру* һ.б.

Шулай итеп, Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» дигән биш пәрдәлек пьесасында фразеологизмнар сөйләмне җанлы, образлы итәләр. Алар ярдәмендә герой-персонажларның эчке кичерешләрен, психологик моментларын, рухи дөньяларын тирәнтен ачып була. *Әйткәнебезчә,* пьеса*ның теле матур һәм тәэсирле. Моны фразеологик гыйбарәләрнең күплеге белән дә аңлатып буладыр.* Сөйләм телендәге фразеологик әйтелмәләрне киң кулланып, Г. Исхакый аларны әдәби телгә кертә. Алар халыкның бөтен матур хисләрен, җорлыгын, телен тагын да төзек, матур, аңлаешлы итәләр. Әдәби әсәр белән эшләгәндә сөйләмне баетуда, аны үтемлерәк, тәэсирлерәк итүдә, әсәрнең стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда фразеологизмнар мөһим роль уйныйлар.

ӘДӘБИЯТ


1. Алпаров Г. Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе, халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр. Казан: Татарстан халык мәгариф комиссариатының басмасы, 1926. 55 б.

2. Баранов М.Т. Методика лексики и фразеологии на уроках русского языка: пособие для учителя. М.: Просвещение, 1988. 191 с.

3. Введенская Л.А., Баранов М.Т., Гвоздарев Ю.А. Методические указания к факультативному курсу «Лексика и фразеология русского языка». М: Просвещение. 1983. 143 с.

4. Гиниятуллина Л.М., Айдарова С.Х. Фразеологизмнар һәм сөйләм культурасы // Традиционная культура тюркских народов: проблемы и перспективы: материалы международной научной конференции (09.04.15–11.04.15). Канаш, 2015. С. 162–165.

5. Зиляева Р.А., Абдрахманова Г.Г. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 5 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 559 б.

7. Молотков А.И. Основы фразеологии русского языка. Л.: Наука, 1977. 284 с.

8. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

9. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 218 б.

10. Шанский Н.М. Фразеология современного русского языка. М.: Высш. шк., 1985. 231 с.

11. Шакурова М.М. Теоретические основы обучения татарскому языку в условиях двуязычия Республики Татарстан (на материале изучения лексики и фразеологии) //

И.А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика: международ. конф.: VI Бодуэновские чтения (Казан. федер. ун-т, 18-21 окт. 2017г.): тр. и матер.: в 2 т. / под общ. ред. К.Р. Галиуллина, Е.А. Горобец, Д.А. Мартьянова, Г.А. Николаева. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. Т. 1. С. 289–291.

# AYAZ ISHAKİ'YLE BAŞLAYAN SÜREÇTE REJİM MUHALİFİ İÇ SÜRGÜNLER: HESEN TUFAN VE IBRAHİM SALAHOV

***Hatice Şirin*** *(İzmir, Türkiye)*

Гаяз Исхаки, вынужденный покинуть родину после Октябрьской революции 1917 года, был первым из сосланных среди татарской интеллигенции (две ссылки на Север России – в Архангельск в 1907 и 1911 годах). Тоталитарный подход к тюрко-татарской интеллигенции, имевший место в период самодержавия, был продолжен после Октябрьской революции 1917 года со стороны ЧК, ОГПУ и НКВД и нацеливался на тех, кто шел вслед за Гаязом Исхаки. На первом месте среди них находятся поэт Хасан Туфан и писатель Ибрагим Салахов. В докладе, в рамках тех стихов и романов, в которых они отразили татарскую культуру и политическую жизнь XX века, будет рассматриваться драма, которую пережили эти два великих татарских интеллектуала, и формы отражения этого; оцениваться влияние, которое оказал на этих великих интеллигентов Гаяз Исхаки.
**Ключевые слова**: Гаяз Исхаки, Хасан Туфан, Ибрагим Салахов, репрессия.

Ayaz Ishaki, who was forced to leave his country after the October Socialist Revolution, is the the first Tatar intellectual exposed to inner exiles (two exiles to Arhangelsk in Northern Russia in 1907 and in 1911). The totalitarian attitude towards the Turk-Tatar intellectuals during the tsarist period, was maintained by ÇEKA, OGPU and NKVD after the October Socialist Revolution, and the Tatar intellectuals who followed in Ayaz Ishaki's footsteps were re-targeted. The poet Hesen Tufan and author Ibrahim Salahov are the most important names among them. In this paper the tragedy of these two great Tatar intellectuals and the influence of Ayaz Ishaki on these two great intellectuals will be examined based on poems and novels which were reflecting 20th-century Tatar culture and social life.
**Key words:** Ayaz Ishaki, Hesen Tufan, İbrahim Salahov, Repressiya.

Yazarları susturmak için sürgüne göndermek, yazma etkinliklerinin başladığı çağlara uzanacak kadar eski bir yöntemdir. Avrupa literatürü, sözleri ve eylemleri nedeniyle doğduğu ülkeden veya şehirden sürülen yazarlarla tıkabasa doludur. Ovid, Dante, Rousseau, Mann, Joyce, Kundera ve daha bir çok Avrupalı edebiyatçı, yazarlıklarını / şairliklerini sürgünleriyle yeniden biçimlendiren ünlü isimler. Modern Çağ'da ise, özellikle 1800 yılını takip eden devrede Rusya, dünya sürgün edebiyatına hatırı sayılacak ölçüde katkıda bulundu (Bethea-Frank 2011: 195). Puşkin, Lermontov, Turgenyev, Dostoyevski, Pasternak, Nabokov, Soljenitsin, Brodski vd. yazarları kapsayan uzun bir listeyle, sürgün cezasını kitlesel bir imha silahı gibi kullanmayı denedi. Sayısı çok kabarık olan sürgün yazarlar, Rusya Devleti ile yazar arasındaki ilişkinin çok müşkül ve tehlikeli olduğuna tanıklık eder. Vladislav F. Khodasevich, «Rusya dışında hiç bir ülkede mevcut her yöntem ve aracın kullanılmasıyla yazar / şair imha etme çalışması yapılmadı. Bu bizim utanç değil, gurur duymamıza sebep olabilir. Çünkü hiç bir edebiyat, Rus edebiyatı kadar *peygamberane* çizgiye ulaşamadı» der (Bethea-Frank 2011: 196).

Rusya'nın 1800'lü yıllarda canavarlaşan emperyal ihtiraslarının ve topraklarını sürekli olarak genişletme tutkusunun önünde durma, karşı çıkma, hatta bunu ima etme potansiyeli olan yazar / şairi yutmasının en kolay yolu, onları kültür ve siyaset merkezlerinden olabildiği kadar uzağa sürgün etmekti. Bunu, zekası yüksek ve yetenekli çocuğuyla başa çıkamayan despot ebeveynlerin, çocuğu evin karanlık bir odasına veya deposuna kilitleyip «terbiye etmesi»ne benzetebiliriz. Çarlık Rusyası'nın uyguladığı bu yöntem, 1924'ü izleyen günlerde, Sovyet Rusyası'nda daha et-

kin ve daha acımasız yollarla geliştirildi. Devletin empoze ettiği Sosyalist Realizmi görmezden gelen yazarlar çok çeşitli yollarla susturuldu. Egemen kültürlerin hemen hepsinde olduğu gibi, Rus egemenliği de temsil iddiasında bulunduğu milletlerin – bilhassa Türk dillilerin – belleklerini boşaltmayı, «kendi kafalarıyla düşünmelerini, kendi yürekleriyle hissetmelerini, kendi ayaklarıyla yürümelerini engellemeyi» [Galeano 2006: 118] hedefledi.

Kötü günler geçip de yazarlar aklandıktan, iadeleri itibar edildikten sonra, edebiyat tarihçileri, Rusya Devleti ile yazar arasındaki mezkur antagonistik ilişkide azınlık halkların yazar ve şairlerini her zaman görmezden geldi. Oysa Çarlık ve Sovyet dönemlerinde özellikle Kazan, Türk dünyasının en önemli kültür merkezlerinden biri olması hasebiyle bir çok yazar ve şairin yetiştiği bir kentti. Üstelik bu yazar ve şairler sık sık kovuşturmaya uğrayıp sürgün ediliyorlar, yaratıcılık süreçleri bu sürgünlerde körükleniyordu. Sürgünün yaratıcılığı tetikleyen bir olgu olarak, büyük yazarlar ortaya çıkarmasının en önemli örneklerinden biri de Gayaz İshaki idi.

Tatar aydınlanma hareketinin önderi Ayaz İshaki'nin doğumunun 140., ilk sürgünün 111. yıldönümündeyiz. Onun Tatar ve Türk dünyası üzerindeki siyasi ve edebi damgasının derinliği tartışılmaz. Yaşamöyküsü, modern çağ insanı için dayanılması güç acılarla çerçeveli. Oysa, bu çileli yola girmek yerine Yevşérme'de kalıp sıradan bir köylü gibi yaşayabilirdi; ancak o, 1552 tarihiyle başlayan süreçte, öz yurdunda en temel haklardan bile yoksun yaşam sürdürmek zorunda kalan Tatar halkının kaderini değiştirmeyi hedefledi. Böyle bir hedef, yüzyıllardır mağdur, bir o kadar da pasifize edilmiş bir halkın uyanışını sağlayacağından, 1905 İhtilali ile verilmeye başlanan hakların yeniden tahdit edilmesini beraber getirmiş ve Ayaz İshaki, 20. yüzyılın sürgüne gönderilen ilk Tatar fikir adamı olmuştur[1], çünkü İshaki, merkezi otorite ve yönetilen azınlık arasındaki düelloda edilgen bir figüran olmayı reddetmişti. İlk sürgün yeri olan Arhangelsk'e Sosyalist Devrimci Partisi mensubu olmak ve köylüler arasında suç teşkil eden propagandalar yapmak suçlamasıyla 11 Ekim 1907'den geçerli olmak üzere üç yıllığına gönderildiğinde (Alp 2010: 204), 1917'den sonra tam tersi bir suçlama ile (milliyetçilik, Türkçülük) suçlanıp takibata uğrayacağını tahmin edemezdi. Aynı yıl (1907) G. Kamal, Tukay'la beraber *Yeşén* isimli mizah dergisini[2], Fatih Emirhan *Elislah*, Höseyén Yamaşev *Ural* gazetesini çıkarmaya (Nurullin 1966: 23; İbrahimova 1986: 552–592) ve geleceğin Tatar lirizmi üstadı Hesen Tufan, doğduğu köy İské Karmet'te 1905 İhtilali'ni müteakip açılan mektepte Kayyum Nasırı'nin *Fevakihél cölesa fil-edebiyat*'ını okuyarak Tatar cedidciliğini öğrenmeye başlamıştı. 1906 ve 1907'de kapatılan dergi ve gazete sayısı ise, çıkmaya başlayanlardan sayıca daha yüksekti[3].

İshaki, Çıstay hapishanesinde *Zindan* adlı hikayesini, Kazan hapishanesinde *Aldım-birdém* dramını, Arhagelsk-Pinega sürgününde *Soldat* uzun hikayesini,

---

[1] Ayaz İshaki, 1906'da da sürgün edilmişti, ancak sürüldüğü yer kendi köyüydü ve burada Duma'ya milletvekili adayı gösterilmişti. Bu sürgün, onun lehinde gelişmeye başlayınca tutuklanarak Çistay Hapishanesi'ne yatırıldı (Nurillin 1991: 9).

[2] Refail Mostafin – Reis Davutov, *age*, 226. s.

[3] Gazeteler: Seyétgerey Alkin redaktörlüğünde ve Yusuf Akçura'nın sekreterliğinde *Kazan möhbiré* (Aralık 1905 – Ekim 1907), Gabdreşit İbrahimov redaktörlüğünde *Ölfet* (1906 – Haziran 1907), Segıyt Remiyev redaktörlüğünde *Tañ yoldızı* (Mayıs 1906 – Kasım 1906), Galiesgar Kamal redaktörlüğünde *Azat halık* (Haziran 1906-Eylül 1906), K. Motıgıy redaktörlüğünde ve Tukay mürettipliğinde *Fikér* (Aralık 1905 – Eylül 1906), Abdullah Apanayev redaktörlüğünde *Azat* (Şubat 1906 – Mayıs 1906), Höseyén Yamaşev redaktörlüğünde *Ural* (Ocak 1907 – Mart 1907). Dergiler: K. Motıgıy redaktörlüğünde *Elgasrél cedit* (Ocak 1906 – 27 Mayıs 1907) vd. (İbrahim Nurullin, *XX. yöz başı Tatar edebiyatı*, Kazan 1966, 23.s.; F. İbrahimova, *Edebiyat-kultura tormışı yılyazması*, Tatar edebiyatı tarihı, 3. cilt, Kazan 1986, 552–592. s.

Arhagelsk-Mezen sürgününde *Bér torkarnıñ sataşuvı*[1] adlı romanını yazdı (Uslu Bayramlı 2006: 275; İshakıy 2011: 58). Sürgün yılları, eser üretimini durdurmak yerine hız kazandırmıştı. Bu, yöneten sınıfın amaçladığı doğrultuda gitmeyen bir süreçti. Ayaz İshaki, temel haklarının gasp edilmesine karşı çıkıyordu, itaatkarlık ödevini yerine getirmiyordu. Bu sürgünde iki eser yazmış; üstelik cezasını tamamlamadan kaçmıştı. Sistem, dişlisine girmeyi reddeden bu düşünürü, «halk düşmanı» ilan etmeye adım adım yaklaşıyordu.

G. İshaki'nin ikinci sürgünü 1911 yılında gerçekleşti (İshakıy 2011: 86). Daha önceki cezasını tamamlamak üzere yeniden Arhangelsk'e gönderilen yazar, 1913 yılında Romanov Hanedanlığı'nın 300. yıldönümü kutlamaları kapsamındaki genel af ile sürgünden kurtuldu (İshakıy 2011: 74; Kamalieva 2009: 50). İshaki'nin sürgüne gönderildiği yıl, Kazakistan'ın Kökşetav kentinde XX. yüzyıl Tatar edebiyatının efsanevi adlarından İ. Salahov dünyaya gelmişti. İshaki'nin ilk mahkumiyetinden otuzbir yıl sonra (1937), İ. Salahov RSFSR Ceza Kanunu'nun 58. maddesine binaen (Sovyet hükümetini yıkıp Büyük Turan Devleti kurma, yoldaş Stalin ve diğer parti liderlerini yok etmeyi planlama, karşı devrimci propaganda yürütme) on yıl hapis, beş yıl vatandaşlık haklarından mahrumiyet cezasına çarptırıldı. İrtiş boyunda F.M. Dostoyevski'nin de yattığı Tubıl hapishanesinde yattıktan sonra, Sibirya'nın kuzeydoğusu ucunda yer alan Magadan limanından Kolıma'ya sürgün edildi. Onun sürgünde yaşadıklarını konu alan *Kolıma Hikeyeleré* adlı tarihi / dokumental / otobiyografik romanı, 1988'de *Kazan utları*'nda tefrika edildiğinde *Taygak kiçü* adıyla yayımlanmıştı (Salahov 1989: 65). A. Soljenitsin'in *Gulag Takımadaları*'ndan (1973) onbeş yıl sonra yayımlanan bu roman, sürgün edebiyatının şaheserlerinden biri olmakla birlikte, Avrupa edebiyat tarihçilerinin dikkatini hiç çekmemiş ve çekmeyecekti. Çünkü «bazı azınlıkların dünyası» Batılının nezdinde konuşmaya, haber ve araştırma konusu yapılmaya değmeyen üçüncü sınıf insanlara aitti. Galeano'nun sözleriyle onların «sorunları doğaya aittir, tarihe değil. Açlık, hastalık, şiddet doğal işleyişin bir parçasıdır» (2006: 70).

İbrahim Salahov, 1940'ta Kolıma'da Linkoln altın madeni ocaklarında çalışırken galeri çöker. Yazar, Moroz adlı bir mahkumla göçük altında kalır. Moroz ölür; Salahov'un kangren olan sol ayağı, önce topuktan, sonra bilekten kesilir; buna rağmen yayılımını sürdüren hastalık dizinin onbeş santimetre altından kesilmesiyle sonlanır. Ameliyat ve tedaviyi üstlenen cerrah ile iyileşme süreci sonunda İ. Salahov'a koltuk değneği yapan marangozun, sürgündeki diğer mahkumlar olması, yaşanan dramın bir başka boyutudur (Salahov 1989: 141). İlk iki ameliyatın narkozsuz, üçüncüsünün kloroform ile gerçekleştiği esir kampı koşullarında, Salahov'un yazarlığını sürdürebilmek için kalem ve kağıt temin etmesi olası değildi. Bu nedenle sürgün anılarını hafızasına kazımak zorunda kaldı. *Kolıma Hikeyeleré* (*Taygak kiçü*), onu Tatar halkına tanıtıp sevdiren, adını edebiyat tarihine yazdıran kitabıydı. *Kolıma Hikeyeleré* onun sürgünde elde ettiği kazancıydı; ama E. Said'in sözleriyle «sonsuza dek arkada bıraktığı bir şeylerin kaybedilmesiyle sürekli olarak baltalanan» bir kazançtı bu (Said 2017: 4). Halkının omuzlarında yükselmenin onurunu[2], aile bireylerini toprağa vermenin kederiyle bir arada yaşamak zorundaydı. Onun sürgün yılları, *Kolıma Hikeyeleré*'nden başka bir çok eserine yansımıştır; ancak 1960 yılında yazdığı bir şiiri dünya edebiyat antolojisine girmeyi hak edecek derinliktedir:

*Yuk irkelep üstérmedi yazmış / Törlé yakka étté, taşladı / Boz diñézé buylap çana tarttım / Töyep avır avır taşlarnı // Min altınnı anda taptap yördém / Almazlarnı öydém köreklep / Lekin / tik bér kabım ikmek tabalmıyça / Kan sarkıdı miném*

[1] İshaki, tercüme-i halinde bu romanın savaş sırasında Varşova'da yandığı bilgisini verir (2011: 58).

[2] Madalyaları yaz.

*yörekten / İyélgende cilkem çatnap kite / Söyel anda – kayış ézleré / Vagrankalar tarttım min cigélép / Perforator tottım tézlenép / Bér ayagım taş astında kaldı / E bér kulım altın astında / Tik şulay da bireşmedém / Yazmış! / Min tagın da sinéñ karşında / Küzlerémnen ménem yeş ézleme / Yardem kulı miña kirekmiy / Böyék yıllar / Tınmas, şavlı cırlar / Sézge birem kaynar yörekné* (1960).

Salahov'un sürgün cezasını tamamlamasına yedi yıl kala, Ayaz İshaki, İstanbul'a gelir. Aynı yıl (1940), Hesen Tufan tutuklanır. Yedi yıl cezaevinde yattıktan sonra önce toplama kampına (Potma, 1947), ardından da sürgüne (Novosibirsk, 1950) gönderilen Hesen Tufan'ın, devrim karşıtı gizli örgüt kurup yabancı ülke casuslarıyla ilişkiye girerek Sovyet idaresini yıkmaya çalışmakla suçlanması derin bir ironi olarak tarihteki yerini alır. H. Tufan, öylesine naif ruhlu bir şairdir ki, anlattığı masallar ve okuduğu şiirlerle ömürleri boyunca ellerine kitap almamış katil ve eşkıyaların bile yüreğini yumuşatmıştır. Mordva topraklarındaki Potma toplama kampında, yardımseverliğinden ve iyiliklerinden dolayı, *izgé can* «kutsal ruh» diye anılırdı (Mostafin 1989: 62, 79). Cezaevinde, ona olan saygı ve hürmetlerinden ötürü, şiirlerini yazabilsin diye kalem ve kağıt temin eden azılı mahkumlar sayesinde şiir üretimini sürdürür. Sibirya sürgününe eksi otuz derece soğukta, üzerinde tek kat yırtık giysilerle, otuz kişiyle beraber hayvan vagonuna yüklenerek gönderilen, en hafif cezası çiftlik bekçiliği olan, kışları kolhozun sığır sürüsünü güden şair, Sibirya'daki çetin koşullarda yazmayı sürdürür (Gaynetdinov 1989: 171).

H. Tufan, cezaevindeyken II. Dünya Savaşı sürmektedir. Şiirlerinde bireysel ve sosyal bir kötümserliğin yansıması kaçınılmazdı: *Tışta niler bar iken / Yullar zeñger kar miken? / Boz tereze alsulana, / Pojar miken, tañ miken? / Tışta niler bar iken?* (1944). Toplama kampına gönderildiği yıl yazdığı bir şiirinde *Nişletiyk indé siné béz, / Éh, yörek, yörek, yörek?!* derken, duygularıyla başa çıkmaya, onları kontrol etmeye çalıştığını anlamak zor değildir. Hesen Tufan'ın mahkumiyeti ve sürgünü, savaş yıllarına denk geldiği için, ayrılık acısı, memleket hasreti, ölüm düşüncesi, sevgili özlemi gibi duygu ve düşünceleri derin bir lirizmle şiirlerine yansıtır. Hesen Tufan'ın bu şiirleri, söz konusu yıllarda, cephede, hapiste ve sürgünde yaşayanların kaderinin ortaklığını, hatta aynılığını gözler önüne sürer. Tatar insanı, bu yıllarda hem savaşta hem de Stalin'in Temizlik Harekatı'nda ağır kayıplar vermektedir (Şirin 1998: LXXXIII).

Tıpkı Salahov gibi, Tufan da sürgün yıllarından sağ çıkmanın ödülünü alır; ama bedelini de öder[1]. Eşinin ölümünü haber aldıktan sonra yazdığı *Romaşkalar* şiirinde saf bir çocuk gibi papatya falına bakan Tufan, çok ani bir biçimde reel yaşama dönüp ruhundaki derin yarayı ve karanlığı gösterir: *Yuk, ışanmıym romaşkalarga, / Aldaşa iç alar, aldaşa / Anıñ kabéré östénde indé / Rezedalar üse lebasa…* Tatar halk inanışına göre sürekli yaramazlık yaptıkları için annelerinin bedduasına uğrayan ve ormanlarda *sak* ve *sok* diye ötüp sonsuza kadar birbirine kavuşamayacak olan, ancak kıyamette karşılaşacaklarına inanılan bu kuşların başlarına gelen, şairin ve ailesinin de başına gelmiş, akıbetleri de aynı olmuştur. Şairin sürgünden dönmesine bir kaç ay kala eşi Luiza ölmüştür. *Romaşkalar* adlı dramatik şiirin yazılmasına, Hesen Tufan'ın derin acılar çekmesine yol açan bu ölüm sebep olur (Şirin 1998: XC).

* * *

Sonuç olarak G. İshakiy, H. Tufan ve İbrahim Salahov, Tatar edebiyatının sembolleşmiş adlarıdır. «Bir entelektüelin kamusal rolüne en çok gölge düşüren

---

[1] Hesen Tufan, tutuklanmasından iki yıl sonra oğlu, sürgünden dönüşünden bir kaç ay önce deeşi Luiza vefat eder. 1964'te yayımlanan *Saylanma eserler* kitabıyla, 1966 yılında Tataristan'ın edebiyat ve sanat alanındaki en büyük mükafatı Abdullah Tukay ödülünü alır (*Abdullah Tukay premiyesé lavreatları*, Kazan Utları, Haziran 1966, 156. s.).

tavırlar, nabza göre şerbet vermek, konuşulması gereken yerde susmak, şovenist kabadayılıklara, tantanalı döneklik ve günah çıkarma törenlerine rağbet etmek»tir. Üç isim de bunlara rağbet etmedi. Onlar, dilleri ve dinlerini kimliklerinin işareti saymayan, aksine yok sayan bir sistemin dişlisine girmeyi reddettiler. Bu reddiye, bireysel olarak onların aleyhine, ama toplumsal olarak Tatar halkının lehine gelişti. Bu üç isim, hakiki birer aydındı. Sürgün onların yaşamlarında onulmaz travmalar bıraktığı kadar, motivasyon da sağladı. En etkileyici, derin ve lirik eserlerini sürgün yıllarında yazdılar.

Bu bildiri vesilesiyle, Tataristan Cumhuriyeti Eğitim Bakanlığı Tataristan Cumhuriyeti Bilimler Akademisi G. İbragimov Dil, Edebiyat ve Sanat Enstitüsü'nün Türkiye'deki üniversitelerle işbirliği yaparak «Sürgün Tatar Edebiyatı» başlıklı bir projeyeyi hayata geçirmesini teklif ediyorum.

KAYNAKLAR


Abdullah Tukay premiyesé lavreatları, Kazan Utları, Haziran 1966.

Alp, Alper (2010). Kazan Tatarları'nın Siyasî Konum ve Yönelişleri (1905–1916), Gazi Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü Tarih Anabilim Dalı Yakınçağ Tarihi Bilim Dalı. Doktora Tezi.

İbrahim Nurullin (1966). XX. yöz başı Tatar edebiyatı, Kazan 1966.

Bethea, D., & Frank, S. (2011). «Exile and Russian Literature»: The Cambridge Companion to Twentieth-Century Russian Literature, E. Dobrenko & M. Balina (Eds.), Cambridge: Cambridge University Press, 195–214.

Galeano, Eduardo (2006). Biz Hayır Diyoruz, İstanbul: Metis.

Mostafin, Refail (1989). «İñ avır yıllarda»: Ak çeçek atar idé, Kazan.

Mesgut Gaynetdinov, age, 136.s.;

Refail Mostafin, Hesen Tufan: Tatar edebiyatı tarihı, 5. cilt, Kazan 1989, 234.s.

Nurillin, İbrahim (1991). «Gayaz İshakıy (Edipnéŋ tormış yulı hem icat éşçenlégéne kıskaça bér küzetüv)»: Zindan. Saylanma proza hem sehne eserleré. Kzzan: Tatarstan Kitap Neşriyatı.

F. İbrahimova, Edebiyat-kultura tormışı yılyazması, Tatar edebiyatı tarihı, 3. cilt, Kazan 1986.

İshakıy, Gayaz (2011). «Gezitçélék éşénde 25 yıl»: Gayaz İshakıy. Tarihı-Dokumental Cıyıntık. Kazan: Cıyın Neşriyatı.

İshakıy, Gayaz (2011). «Tercemei helém»: Gayaz İshakıy. Tarihı-Dokumental Cıyıntık. Kazan: Cıyın Neşriyatı.

Hesen Tufan, Şigırler, Kazan 1929; Hesen Tufan, Şigırler, Yañalif, Kazan 1932.

Uslu Bayramlı, Ayşen (2006). «Zindan'da Bir Yazar: Ayaz İshaki»: Zindanlar ve Mahkumlar (Ed: Emine Gürsoy-Naskali-Hilal Oytun Altun), İstanbul: Babil, 275–291.

Agay, H., A. S. Akis, and Tahir Cagatay, eds. Muhammed Ayaz Ishaki, Hayati ve faaliyeti: 100. Dogum Yili Dolayisiyla. Ankara, 1979.

Nurullin, Ibrahim. «Gayaz Iskhakiyga yoginti.» Kazan Utlari, no. 2 (1993), 153–157.

Ali Akış, «İ dil-Ural Millî Kurtuluş Hareketinin Büyük Önderi Ayaz İshakî», Muhammed Ayaz. İshakî Hayatı ve Faaliyeti 100. Doğum Yılı Dolayısıyla, Yay. Haz: Tahir Çağ atay, Ali Akış, Saadet.

Çağatay, Hasan Agay, Ankara, Ayyıldız Matbaası, 1979.


## Г. ИСХАКЫЙНЫҢ «МӨГАЛЛИМӘ» ДРАМАСЫ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬТӘ
### (XX йөз башы тәнкыйди материаллары нигезендә)


***Н.М. Юсупова** (Казан)*



В статье анализируется литературно-эстетическая и общественно-философская интерпретация драмы «Учительница» Г. Исхаки татарскими критиками начала XX века. Особое внимание уделяется принципам и приемам анализа прозведения. На материале статей данного периода выявляется, что драма Г. Исхаки в начале XX века интерпретируется на уровне принципов и приемов художественного изображения, жанровой парадигмы и образной структуры текста. В них раскрывается проблематика и национально-общественная ценность произведения в контексте национальной общественно-философской и литературно-эстетической мысли, определяются идеалы татарской интеллигенции, пути служения татарскому народу и нации.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, драма, критика, идея-проблематика, стиль, направление, образ.

The article analyzes the literary-aesthetic and socio-philosophical interpretation of the drama «Teacher» G. Ishaki by Tatar critics of the early 20th century. Particular attention is paid to the principles and methods of analysis of the vocabulary. The material of the articles of this period reveals that the drama of G. Iskhaki at the beginning of the twentieth century is investigated on the level of the principles and techniques of the artistic image, the genre paradigm and the figurative structure of the text. They reveal the problems and national-social value of the work in the context of national socio-philosophical and literary-aesthetic thought, the ideals of the Tatar intelligentsia, the ways of serving the Tatar people and the nation are determined.
**Key words:** G. Iskhaki, drama, criticism, idea-problematics, style, direction, image.

Гаяз Исхакый – үз чорының әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси тормышында төп урынны биләгән фигураларның берсе. XX йөз башы татар прозасын, вакытлы матбугатын, тәнкыйтен үстерү белән янәшәдә, ул татар театры һәм драматургиясенең алга китешенә дә зур өлеш кертә. Әдип иҗат дәверендә «Мөгаллим», «Мөгаллимә», «Зөләйха», «Тартышу», «Алдым-бирдем», «Җәмгыять», «Кыямәт», «Җан Баевич» һ.б. кебек барлыгы унбишләп сәхнә әсәре иҗат итә. Әдәбият белемендә Гаяз Исхакый күбрәк прозаик буларак өйрәнелә һәм бәяләнә. Шулай да замандашлары прозаик Исхакыйга караганда драматург Гаязны өстенрәк куйган булсалар кирәк, аның драма әсәрләре игътибарны күбрәк җәлеп иткән. Хәтта «Исхакый театры» дигән төшенчә дә йөргән һәм аның иҗатына беренче игътибар итүче кеше дә – театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрам [12: 144].

Г. Исхакыйның драмалары арасында иң күренеклесе – матбугатта кызу бәхәсләр уяткан, ялкынлы чыгышлар, күләмле язмалар, проблемалы мәкаләләр дөньяга чыгуга сәбәпче булган «Мөгаллимә» драмасы. Чыганаклар аның 1913 елда Петербург – Финляндиядә язылуын һәм 1914 елда Петербургта басылып чыгуын [5: 34] хәбәр итә. «Мөгаллимә» драмасы сәхнәдә дә зур уңыш белән бара. Беренче тапкыр ул 1914 елның 16 нчы августында «Сәйяр» Нижний Новгородта гастрольдә чагында тамашачы хөкеменә чыгарыла» [14: 166]. 1916 елда «Тормыш» газетасының мөхәррире Закири татар театрының ун еллыгына багышланган кичәдә сөйләгән нотыгында [11] инде «Мөгаллимә»-не театр сәхнәсендә күп уйнала торган мәшһүр әсәрләр рәтенә кертә. Әсәр язылып, дөнья күргәч, сәхнәгә куелганнан соң да, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Ә. Мөхетдиния, Г. Кәрам кебек, үз чорының абруйлы зыялыларыннан алып, исемнәре бик үк билгеле булмаган авторларга кадәр аның әлеге драмасына карата тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр бастыра.

«Җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән нәрсә – пьесаның Г. Исхакыйның моңа кадәр язган әсәрләренә охшамавы. Биредә элеккеге әсәрләрдәге кебек иске тормыш белән яңа тормышның тартышуы да, иске фикер белән яңа фикер каршылыгы да юк. Халыкка фидакарьләрчә хезмәт итү теләге һәм илаһи мәхәббәт – шул ике тема геройларның рухи кичерешләрендә үрелеп бирелә. Мөгаллимә образы ул – әдипнең татарның киләчәге турындагы бөек хыялы җимеше» [4: 108], – дип яза Л. Гайнанова. XX йөз башында дөнья күргән мәкаләләрдә үк әлеге әсәрнең Г. Исхакый иҗатына яңарыш алып килүе турында хәбәр ителә. Мәсәлән, Ш. Әхмәдиев: «Моңа кадәр Гаяз әфәнденең үткен каләме татарның кара тормышында гына йөзеп йөри иде... Галәме өнсада үзенең хыялханәсендә шундый көчле, гали табигатьле кызлар тудырырга тырышып, мөхәррир әллә ничә баскычка күчеп беткән» [1], – дип, әлеге әсәр белән Г. Исхакый иҗатында гына түгел, татар драматургиясе тарихында да яңа чор башлануын ассызыклап үтә.

XX йөз башында язылган тәнкыйть мәкаләләрендә драма, нигездә, өч позициядән бәяләнә: идея-эчтәлеге, төп герой яңалыгы һәм әсәрнең иҗат принциплары мәсьәләсе. Драманың эчтәлегенә мөнәсәбәттә тәнкыйтьчеләрнең карашлары ике төркемгә аерыла: аерым авторлар әсәрдә яктыртылган төп теманы халыкка хезмәт итү, халыкчылык идеясе белән бәйли; икенчеләре исә мәхәббәт тарихын үзәккә куя. Язмаларда халыкчылык һәм миллилек төшенчәләре бәяләнә, аерып куела һәм нәзари нигезләнә.

Билгеле булганча, XX йөз башы нәзари фикерендә җәмгыятьчеләр һәм рухиятчеләр кебек ике мәктәп аерылып чыга. Җәмгыятьчеләр мәктәбе белән рухиятчеләр бәхәсе әдәби тәнкыйть белән янәшә, дөресрәге, тәнкыйть мәкаләләре эчендә дә әйтелә. Бу очракта әдәбият үзе зур сөйләшү өчен азык, сәбәп ролен башкара [7: 219]. Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы шундый сөйләшүләргә этәргеч биргән, кайнар бәхәсләргә юл биргән әсәрләрнең берсе була. Әлеге ике мәктәп тарафдарларының фикер каршылыгы бу әсәр аша сызылып үтә, бәхәс, нигездә, әдәби әсәрне бәяләү принципларының аермасыннан килеп туа.

Драманы нәзари яктан иң беренче бәяләүчеләрдән булган Ә. Мөхетдиниянең «Кем ул мөгаллимә Фатыйма?» дип аталган мәкаләсе фәлсәфилеге, беркадәр лирик булуы белән аерылып тора. Ул драманы, нигездә, хисси планда, кешенең рухи тормышы яссылыгында тикшерә, ягъни романтизм иҗат принциплары яктылыгында бәяли. «Мөгаллимә»нең идеясе татар әдәбиятында моңарчы күрелмәгән яңа икәнлегенә басым ясап, ул: «мондый әсәр татар әдәбиятында яңа. Моңа кадәрле безнең мөхәррирләремез үзләренең драма һәм комедияләрендә тормышның әһәмиятсез вак-төяк якларын гына күрсәтеп, рухани матур кәдыйкаләрне вә бөек хисләрне оныталар иде, гомумә общеловеческий типлар бирә алмыйлар иде» [15: 415], – дип бәян кыла. Шушы ноктадан ул әсәрнең Исхакый иҗатында гына түгел, гомумән, татар әдәбиятындагы борылышны тәэмин итүен, сүз сәнгатенең тарихы һәм киләчәге арасында чик ролен үтәвен ассызыклый. Әдәбиятның иҗтимагый мәсьәләләрне генә яктыртудан рухи яссылыкка борылырга тиешлеген анык нигезли. Тәнкыйтьче драманың эчтәлеге мәсьәләсендә фикерен йомгаклап, шундый ахыр нәтиҗәгә килә: «бу мәүзүг түгел, татар милләтенә генә, бәлки рухани тәрбия алган һәрбер халыкның күңеленә якын» [15: 416].

Ләпәйскийнең «Мәкәрҗә хәбәрләре» [13] мәкаләсендә дә шушы позиция ачык күренә. Г. Гыйсмәтинең дә «Мөгаллимә» мәкаләсендә әсәрнең әдәби кыйммәте, идея-эчтәлегенә мөнәсәбәттә фикерләре аваздаш. Әсәрнең татар тормышыннан алынуына тукталып, тәнкыйтьче: «...аның мөндәриҗәсе, аның рухы, максат әгъласе безнеке» [6], – дип язып үтә. Ул әсәрне Грибоедовның «Акыллык бәласе» шигъри комедиясе белән янәшә куеп тикшерә. Гыйсмәти билгеләп үткәнчә, әсәр өч көндә язылып беткән, әмма «аның мөндәриҗәсе ничә еллар буенча җыелган, андагы рух, андагы әмәлләр, андагы моңлар, теләкләр бик күп елларның арасында төрле тармак буенча ачып килгән мәгънәви, милли дулкындан гыйбарәт» [6].

Җ. Вәлиди драмага төпле бәя бирергә омтылган «Мөгаллимә» исемле мәкалендә: «...бунда гашыйк белән халыкка хезмәт көрәшә» [3], – дип яза. Шушы ноктада ул Г. Исхакый әсәрендә нигилистлык, народниклык күренешләренең булуы хакында сүз башлый. Тәнкыйтьче «Мөгаллимә»дә инсанда булган ике нух иҗабы куәтенең тартышын тасвир итү»не Г. Исхакый иҗатындагы яңалык буларак бәяли. Җ. Вәлиди драманың төзелешенә дә киң туктала, сәнгатьчә эшләнешенә игътибар итә, өлешләргә бүлеп дәлилле тикшерә.

Шуның белән янәшәдә драмага кискен тәнкыйть белдереп язылган мәкаләләр дә дөнья күрә. Мәсәлән, Г. Кәрам «Шәрыкъ» клубы сәхнәсендә

«Мөгаллимә» исемле мәкаләсендә драманы кире кагып, «анда башлыча бер идея дә юк»лыгын [12: 352] исбатлап чыга. Г. Кәрам драманың телен тәнкыйть утына тотып, Габдулланың сөйләмендә ул «безнең өчен шактый гарип, ифадә, калимәләр дә» барлыгын искәртә, «табан астыңны үбәрмен кебек хис, нәфасәткә куна торган» кирәксез, урынсыз, мәгънәсез җөмләләр барлыгын күрсәтә. Руста бик гади сүзләрдән саналып та, татарда кабул ителә алмаган мондый кәлимәләрнең Мәкәрҗәдә нинди вакыйга китереп чыгаруын да искә ала.

1915 елда Г. Ибраһимовның да драманы кискен тәнкыйтьләгән «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Г. Ибраһимов, әсәрнең идеясенә бәйләп, «әдипнең бөтен язганнары бер идеягә хезмәт итәргә тиеш» [8] дигән принципны үзмаксат итеп билгеләгән хәлдә, Г. Исхакыйны рус, Европа әдәбияты вәкилләре Толстой, Арцибашев, Байрон, татарлардан публицистлар Риза Казый, Рәшид Казый, И. Гаспринскийлар белән чагыштырып, «Гаяз әфәндедә бер мәсләк – идея юк» [8] дигән ялгыш нәтиҗәгә килә. Идеягә бәйле Г. Ибраһимов әдипнең иҗатын дүрт чорга бүлә: җәдит вә кадимчелек дәвере («Тәгаллемдә сәгадәт», «Бай угълы», «Кәләпүшче кыз», «Ике гыйшыйк», «Өч хатын берләң тормыш»...); байлар һәм ярлылар көрәше («Теләнче кызы»); порнографик әсәрләре язылган чор («Шәкерт абый», «Тормышмы бу?», «Мәдрәсә җимеше»); иске тормышны сүрәтләгән әсәрләре («Сөннәтче бабай», «Кияү», «Мулла бабай»). «Мөгаллимә» исә бөтенләй бытописательгә әйләнде, дип саный [8].

Тәнкыйтьче драманың исеменнән чыгып, «әсәрдә мөгаллимләрнең типик тормышы сүрәтләнергә, татар мөгаллимәсенең авыр язмышы» проблемасы күтәрелергә тиеш, дигән фикерне алга сөрә. Үз карашын мисаллар белән раслап, Г. Ибраһимов аларның юклыгына инана һәм: «Мөгаллимә» уку өчен күңелле бер әсәр. Әмма әдәби һәм иҗтимагый кыйммәте хәятнең көзгесе була алмаганга якын» [8], – дигән нәтиҗәгә килә.

Бераз соңрак вакытлы матбугатта Г. Ибраһимовның әлеге фикерләрен нигезле кире каккан зур язма да дөнья күрә – «Кояш» газетасында А. Бикташев җавап мәкаләсен бастыра. Ул Г. Ибраһимов карашларын тәнкыйть утына тота, аның Исхакыйны Толстой, Арцибашев, Байрон, Риза, Рәшид Казыйлар, И. Гаспринский белән чагыштыруын нигезсез дип таба. Тәнкыйтьче Ибраһимовның әдипне мәсләксезлектә, идеясезлектә гаепләвен кискен кире кагып, «...бу ялгышлар барысы да Гаяз әфәндедә идея кая, ул юк» казыясын исбатлавына ясалганлар; ләкин бу шундый исбат кылынмаслык казыя, аларга үз тарафыңдан исемләр тагу гына бик аз, Гаяз әфәнденең әдәби кыйммәтен белер өчен битараф, чын тәнкыйтьчеләр кирәк» [2], – дип язып чыга. Бикташев Г. Исхакыйның тормышны шулай оста язып чыгара белүен «әдиптәге булган бер камилият, аның әдәби тарихына бик зур плюс» буларак кабул итә.

Г. Исхакый Г. Ибраһимовка җавап мәкаләсен язуны кирәк дип санамый, шулай да мондый эчтәлекле язмалардан ул үз әсәрен яклый. Шушы уңайдан «Татарча театр вә концерт» китерү кулай булыр. «Мин «Мөгаллимә»не язсам, – дип бәян итә ул үзенең язмасында, – аны мәгълүм бер типларны эшләргә тырышып язганмын» [10].

Шуның белән янәшәдә тәнкыйть мәкаләләрендә әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше дә игътибар үзәгенә алына: тәнкыйтьчеләрнең күбесе драманың композициясе төзек, пропорциональ булмавын, пәрдәләрнең артын озынлыгын искәртә. Беренчеләрдән булып, без бу фикер белән Г. Кәрам мәкаләсендә очрашабыз. Аның фикеренчә, «Мөгаллимә» өч пәрдәдән генә гыйбарәт булса да, ләкин пәрдәләр шактый озындыр...Өченче пәрдәнең башы шактый күңелсез, эч пошыргычтыр» [12: 353]. Пәрдәләрнең артык озынлыгын С. Рәмиев тә

«Татарча театр» мәкаләсендә драманың җитешсезлеге буларак кабул ителә. «Болар шулхатле озын ки, дип яза ул, – карап торучы җәмәгать ул сценаларны тиешенчә карап торып үткәререгә җитешә алмыйча, алар пьесаның иң трагедияле урыннарында прых-прых көлешеп утыралар» [17].

Г. Гыйсмәти исә драманы бер-бер артлы тезелгән мәрҗәннәргә тиңләп, түбәндәге бәяне бирә: «Мөгаллимә»дәге тойгының төрле-төрле булуы, яңа фикерләрнең бере артыннан бере килеп, энҗе кебек тезелеп алып торалар, «Мөгаллимә»не җәүһәр тезмәсенә үргән иде» [6]. Шул рәвешле, тәнкыйтьче драманың сәнгатьчә эшләнешенә югары бәя бирә, әсәрдәге «кәлимәләр, шигъри тасвирларның... матур, дөрес нәтиҗәләрне чыгаруда юлбашчылык итеп баруын» күрсәтә.

«Мөгаллимә» драмасының иҗат методы мәсьәләсе дә тикшеренүләр һәм кызу бәхәсләр үзәгенә әверелә. Иҗат принципларына мөнәсәбәттә нәзари нигезле тәүге фикерләр Ә. Мөхетдиния мәкаләсендә аваз сала. Автор «Кем ул мөгаллимә Фатыйма» исемле мәкаләсендә романтик принципларны алга чыгара, драманы шул яссылыкта тикшерә. Аның фикеренчә, «сәхнәнең максаты түгел тормыш көзгесе, бәлки йөрәк, күңел көзгесе булудыр» [15: 415]. Мәкалә авторы Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы шул максатка якынлаша, дип исәпли. Гомумән, Ә. Мөхетдиния – шагыйрь буларак, хис кешесе, хис кол, мәкаләсендә дә күбрәк шул якны алга чыгара. Кайбер тәнкыйтьчеләрнең «драманы тирән мәгънәле дип булмый, аның мөндәриҗәсе дә хәзерге татар тормышындан ерак» дигән фикерләре белән килешә алмый. Ә. Мөхетдиния шул чор әдәби тәнкыйте алдына «соң әдипләр үз халкының киләчәк тормышын алдан күреп, шуны безгә тасвир итәргә хаклы түгелмени» кебек романтизм рухы белән сугарылган сораулар куя, тәнкыйть мәйданында шул хакта фикер алышырга чакыра.

Бу җәһәттән Җ. Вәлидинең «Мөгаллимә» мәкаләсе нәзари нигезле. Тәнкыйтьче шактый күләмле мәкаләсендә «Мөгаллимә» уңае белән бөтен татар әдәбиятының торышына, язучы иҗатына анализ ясый, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовны «яңа тасвирый әдәбиятның өч терәге» дип атап, пьесага киң туктала. Мәкалә авторы драмага бәйле рәвештә әдипнең иҗат методын билгеләү юнәлешендә омтылыш ясап, «Мөгаллимә»гә, нигездә, романтизм иҗат принциплары ноктасыннан якын килә. «Гаяз әфәнденең бу ел «Мөгаллимә» исемле яңа бер драмасы нәшер ителде, – дип яза ул, аның бу әсәрендә без народниклыкның яңарак бер шәкелен, романтизм буявына буялган хәлен күрәмез» [3]. Җамал Вәлиди мондагы тасвирларны «тормышның гади хәлләрендән бигрәк, мөхәррирнең хыялында ялтыраган өмет вә әмәлләре», – дип саный. Тәнкыйтьченең әлеге фикерен Ф. Ибраһимова түбәндәгечә шәрехли: «... монда ул драмадагы Фатыйма образын күздә тота булыр, чөнки пьеса язылган 1913 елларда Фатыйма кебек иҗтимагый мәнфәгатьләр белән янып, салкын Себергә балалар укытырга китүче татар кызлары безнең мохиттә сирәк була әле, алар күбрәк хыялда гына яши» [9: 145].

Җамал Вәлиди реализм һәм романтизм принципларыннан чыгып, Исхакый әсәрләрен ике якка аерырга тәкъдим итә: «кайда тыныч, иске тормыш тасвир ителсә, анда Гаяз әфәнде чын реалист, кайда көрәш тасвир ителсә, анда Гаяз әфәнде һәм реалист, һәм идеалист» [3]. «Мөгаллимә»дә исә ул беренче мәртәбә Гаяз Исхакыйда чын идеалист күрә, чөнки «бунда сәлиби тараф, иске тормыш юк». Шул рәвешле, Җ. Вәлиди әсәрне реалистик һәм романтик иҗат принципларының синтезы сыйфатында күзаллый башлый. Фатыйма образын да ул шушы ноктада бәяли: аның мөһим сыйфаты – «дөньяда кеше өчен торуы, җәмгыять өчен, халык өчен яшәве»ндә.

Тәнкыйтьче татар әдәбиятында реализм һәм романтизм иҗат юнәлешләренең бер-берсенә кушылып китүе, үзенчәлекле үсеш алуы турындагы нәзари

фикерне алга чыгара. Җ. Вәлиди, драмага бәйле рәвештә, романтизм иҗат методының асыл хасиятен дә ачыкларга тырыша. Ул «әдәбият үткәндән, хәзердән файдаланган кебек киләчәктән дә файдалана аламы, тормышның алдындан җырып, аңа юл билгеләп барырга, тиздән булачагы, булырга тиешлеге күренеп торганларны булды иттереп тә күрсәтергә хакы бармы?» кебек урынлы сораулар куя һәм «бездә бунсыз мөмкин түгел»легенә басым ясап, болай дип җавап бирә: «...безнең әдәбиятымыз хәзерге хәлдә бер яктан тәнкыйди булса, икенче яктан тәрбияви булырга тиеш. Шуның өчен тормышның сәлиби якларын гына күрсәтү җитми. Иҗаби иделларны да күрсәтергә ихтыяҗ бар. Тормышымның бу көнге хәле андый бербөтен идеал ясап бетерә алмый, шуның өчен безнең әдәбиятымыз бу ягы илә тормышның азмы-күпме алдына чыгарга, аның «иртәгә»сен тасвир итәргә мәҗбүр була» [3]. Тәнкыйтьче әдәбиятның материалны «иске, таушалган тормыштан түгел, бәлки үсеп килә торган яшь, яңа вә таза тормыштан» алырга тиешлеген билгели.

Әдәби әсәрләрендә романтизмга хас иҗат принциплары өстенлек иткән язучы, шагыйрьләре иҗатын югары бәяләгән Г. Ибраһимов «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» мәкаләсендә Ә. Мөхетдиния фикеренә дә кушылмый, Җ. Вәлиди бәясен дә уртаклашмый. Иҗат методы мәсьәләсенә якын килеп, ул «Мөгаллимә»нең әдәби кыйммәтен ике яктан бәяләргә тәкъдим итә: романтик принципларны алга куйган хәлдә, «матур вә мәгънәле хыял тудырмак». Г. Ибраһимов фикеренчә, «бу карашны Фатыйма беренче пәрдәдәге кымыз мәҗлесендә сөйләгән нотыгы белән җимереп ташлый»; «мөхәррир үзенең тугъры тәэсире белән тормышның авыр җәрәһәтләрен бердәм вакыйга алдына ачып салып, шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга – һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен» [8].

Автор иҗат юнәлешләренең бурыч-максатларын берьяклырак аңлый, аларның үзара керешеп китүен, синтез күренешен кире кага. Аның фикеренчә, реалистик әдәбиятта романтик элементларның яки киресенчә кулланылуы максатка ярашлы түгел, ике иҗат методы арасында чикләр төгәл билгеләнгән булырга тиеш. Һәм «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәтле вә и бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора. Бу мөхтәрәм зат татар әдәбиятына башлап реализмны кертүче» [16: 85], – дип язып чыккан галим «Мөгаллимә» драмасы бу таләпләргә җавап бирми, дигән караштa тора. Шушы фонда Г. Ибраһимов Фатыйма образының типиклыгы мәсьәләсен дә кузгата. Типиклыкның асыл хасиятен тәфсилләп аңлатканнан соң, тәнкыйтьче ахырда «пьесада күп нәрсә, күп нотыклар, хаталар бардыр, ләкин күпчелегенең язмышы шул югарыдагыча булган татар мөгаллимәсе тибы юктыр» [8] дигән нәтиҗәгә килә.

Шул рәвешле, «Мөгаллимә» үз чорында ук тәнкыйтьчеләрнең игътибарын яулый, мәкалә авторлары аның Г. Исхакый иҗатына, татар әдәби барышына бәйле әдәби кыйммәтен билгеләү белән генә чикләнеп калмыйча, әлеге әсәр аша күп нәзари проблемаларны калкытып куя, нәзари төшенчәләрне нигезли. Бүген әдәбият белеме өчен әсәр шул ягы белән дә кыйммәтле.

## ӘДӘБИЯТ


1. Әхмәдиев Ш. Мөгаллимә // Йолдыз. 1914. 3 октябрь.
2. Бикташев А. Тәнкыйть тирәсендә // Кояш. 1915. 13–14 август.
3. Вәлиди Җ. Мөгаллимә // Вакыт. 1915. 10 гыйнвар.
4. Гайнанова Л. «Мөгаллимә» пьесасы // Мирас. 1998. № 1. Б. 108–109.
5. Гаяз Исхакый бәйнең әдәби әсәрләре // Татарстан. 1993. № 8. Б. 34–35.
6. Гыйсмәти Г. Мөгаллимә // Йолдыз. 1914. 12 гыйнвар.
7. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

8. Ибраһимов Г. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән // Тормыш. 1915. 25–27 февраль.
9. Ибраһимова Ф. Исхакый турында замандашлары // Казан утлары. 1995. № 3. Б. 142–146.
10. Исхакый Г. Татарча театр вә концерт // Сүз. 1916. 13 март.
11. Кадыйри З. Театрда сөйләнгән нотыткан // Тормыш. 1916. 1 октябрь.
12. Кәрам Г. Казанда «Шәрекъ» клубы сәхнәсендә «Мөгаллимә» // Аң. 1914. № 19. Б. 352–354.
13. Ләпәйский. Мәкәрҗә хәбәрләре // Йолдыз. 1914. 21 август.
14. Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 399 б.
15. Мөхетдиния Ә. Кем ул мөгаллимә Фатыйма? // Аң. 1914. № 23. Б. 415–420.
16. Нуруллин И. Кайту // Казан утлары. 1990. № 1. Б. 85–88.
17. Рәмиев С. Татарча театр // Тормыш. 1915. 19 февраль.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ «ӨЙГӘ ТАБА» ПОВЕСТЕНДА МИЛЛИ КЫЙММӘТЛӘР

***Р.Ә. Яруллина Йылдырым*** *(Адыяман, Төркия)*

Повесть Гаяза Исхаки «Өйгә таба» («Домой»), написанная по следам исторических событий, основана на раскрытие причин пробуждения национальных чувств главного героя произведения, который утратил свою национальную личность. События, которые привели к пробуждению, развитию и кульминации национального самосознания героя, направлены на разъяснение понятий национальность и национальное чувство. Исходя из труда Садри Максуди, изучавшего социологические принципы национальных чувств, проанализированы элементы, которые пробуждают национальные чувства и основополагающие элементы национальности. Национально-культурные компоненты такие, как национальная история, общая земля (родина), общий язык, религия, обычаи, национальный характер, объясняются на примере судьбы и раздумий главного героя Тимергалиева. Также подчеркивается, что возвращение Тимергалиева к своему «я» поможет освобождению и других тюркских солдат от настроений рабства, освобождению чувства национальной независимости и достижению священному идеалу под общим турецким знаменем.
**Ключевые слова:** Гаяз Исхаки, история, национальное чувство, национальное единство.

Towards home is a story, which was written by Ayaz Ishaki based on historical events, and it explained the reasons why an individual lost his / her identity and his/her national emotions move into action. The work had been diretected to explain the events that was contributed to the national heritage of the hero's awakening, development and summit, as well as explain the nation and nationality concepts deeply. Inspired by Sadri Maksudi's study of sociological aspects of national sentiments, the elements that awaken the national feelings and make the nation a nation will be examined in the work «Towards Home». National civilian components such as national history, common motherland, common language, religion, traditions, customs and national character will be revealed in the case of the main hero Timergaliyev's thoughts and destiny. Timetgaliyev, who returned to his own self, will be reminded of the liberation of other Turkish soldiers from the feeling of slavery, the liberation of the national sense of independence and the attainment of the sacred ideals under the common Turkish flag.
**Key words:** Ayaz Ishaki, history, national sentiment, national solidarity.

Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектә иҗат ителгән «Өйгә таба» (1922) повестенең нигезен егерме сигез ел патша армиясендә хезмәт итү чорында һәр милләт өчен ватан бер дип уйлаган Тимергалиевның, бөтен хезмәтләренең руслык сәясәтен урнаштыру юлында төрки халыкларны изү һәм кол итү өчен киткәнен аңлау һәм соңында үз асылына кайту хисләрен тасвирлау тәшкил итә. Беренче дөнья сугышы елларында Кавказ фронтында барган хәлләрне яңача кабул итә һәм башка күзлектән бәяли башлаган татар полковнигының үз-үзен тану

процессы кире чигенеш, үткәнгә һәм киләчәккә мөрәҗәгать итү алымнары ярдәмендә ачыла бара. Аның милли үзаңының уянуына, үсүенә һәм иң югары ноктага җитүенә сәбәп булган вакыйгалар бер ноктага – милләт һәм миллият (милли хис) төшенчәсен ачыклауга юнәлгән.

Нәрсә соң ул милләт һәм миллият? Садри Максуди, миллият төшенчәсен социологик яктан ачыклауга багышланган хезмәтендә, ерак тарихта мөстәкыйль бер дәүләт булып яшәгән һәм шул дәүләт эчендә уртак хис, уртак тел һәм гореф-гадәтләр белән бәйләнгән кешеләр төркемен милләт дип атый. «Нәселләре бер, тарихлары бәйләнгән, телләре якын халыклар бер милләт тәшкил итәләр. Шул халыклардагы бер-беренең якынлык тойгысы, бер-беренә бәйләнгәнлекләрен хис итүләре “миллият” дип атала» [8: 75].

Садри Максуди милләтне тәшкил итүче төп шартлар итеп, дәүләтчелек, халык, географик урыны (ил, йорт, Ватан) берлеге; бәйсезлек, тел берлеге, гореф-гадәтләр, дин, милли холык һәм бер ырык (токым), этник тамыр кебек тугыз әһәмиятле компонентны билгели. Садри Максудиның барлык хезмәтләре арасыннан иң кыйммәтлесе саналган соңгы хезмәте – «Миллият тойгысының социологик әсаслары» исемле китабы төрек телендә 1954 елында дөнья күрә. Төрек миллиятчесе идеясе тарафдары булган Садри Максудиның милләт һәм миллият төшенчәләрен фәнни яктан дәлилләгән әлеге фикерләре Гаяз Исхакыйның 1922 елда дөнья күргән «Өйгә таба» повестенда да төп баганалардан санала. Бу әсәрдә дә төрек миллиятчелеге идеясе күтәрелә.

Җәмгыятьтә миллият тойгысы уянуда иң әһәмиятле фактор буларак, Садри Максуди ул милләт кешеләренең үз милләтенең үткәнен, милли тарихын яхшы белүләре кирәклеген саный. Галим бу турыда «Милләт тойгысы. Беренче чиратта, теге яки бу милләткә караган кешеләрнең үзләренең милли тарихларына, милләтләренең үткәндәге уңышларына яки бәхетсезлекләренә изге бер нәрсә итеп караулары рәвешендә сиземләнә. Милләтче инсан милләтенең тарихта шанлы булган дәверләрен, тәрәккыйлеккә илткән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алыр. Караңгылык чорлары, бәхетсезлекләре вә газап китергән заманнар исә аңарда кайгы хисе уятыр» [8: 80], дип яза. Чыннан да, милли идеянең көчәюендә, үткәнгә, ерак тарихкамөрәҗәгать итү, чын тарихи дөреслекне уртага чыгару аша яшь буында үз тарихы һәммилләте белән горурлану хисе уяту зур әһәмияткә ия. Бу, үз чиратында, милли азатлыкка омтылыш, милли бәйсезлек өчен көрәш хисен тәрбияләүдә хәлиткеч фактор булып тора.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәреннән (1902) башлап, татар тарихын дөрес яктыртуны төп максат иткән Гаяз Исхакый, «Өйгә таба» повестенда да милли тойгыларны уяту өчен төркиләрнең шанлы тарихи үткәнен һәм тарихи шәхесләренсюжеттагы вакыйга агышына туры китереп хәтерләтеп бара. Мәсәлән, катлаулы вазгыятьтән чыгу юллары турында уйланганда, Тимергалиевның акылына туктаусыз төркиләрнең куәтле чорлары килә, күз алдыннан Чыңгыз гаскәрләре уза башлый. «Чыңгызча иттереп бер хәрәкәт ясап, шимали Иран, Хәзәр диңгезе аша үтеп, Төркестанга барып керер идем. Идел буйлап Казанга кадәр менеп, Алтын Урданың нигезен корып, урыс ягыннан Иделгә ага торган елгаларның коюларына сакчылар куеп, бөтен Идел буена, Хәзәр диңгезенә хуҗа булыр идем» [1: 45], дип хыяллана. Баш героеның уйлары аша, язучы укучысына төркиләр яшәгән дәүләтнең географик чикләренкабат хәтерләтә, Русия туфракларының күп өлеше кайчандыр татар җирләре булуын, бер яктан горурлык, икенче яктан, өзелү хисе белән телгә китерә. Төрекләрнең үткәне һәм төрек гаскәренең уңышлары белән горурлану хисе Тимергалиевка көч бирә, аны яңа адымнарга этәрә. «Балкан сугышында Әнвәр паша атлы гаскәр берлә көненә җитмеш биш километр йөрде, ике тәүлектә Әдернәгә барып

керде. Үзем япон сугышында алтмыш километр йөрдем. Минем гаскәрем – төрек гаскәре, төрек гаскәрен Аурупа гаскәре берлә үлчәргә ярамый. Аның тамагы тук, өсте бөтен булса, аның алдында һичбер манигъ юк» [1: 49], ди.

Язучы тарихи шәхесләрдән Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә исемен икенче тапкыр бу повестенда куллана. Сөембикә ханбикә 1552 елда Казан ханлыгын руслардан саклап калу өчен көрәшкән булса, «Өйгә таба» повестенда тасвирланган Тимергалиевның кызы Сөембикә исә бердәнбер бәйсез төрек дәүләтен руслардан саклап калу өчен фидакарьлек күрсәткән образ булып күңелдә кала.

Узган тарих белән горурлану тойгылары Тимергалиевка көч-куәт бирсә, үткәндәге шанлы дәүләтнең төркиләр кулы белән җимерелү фикере аны тирән газапларга сала. Төрки халыкларның ул еллардагы аянычлы халәтенә борчылган Гаяз Исхакый, кайчандыр киң туфракларны биләгән Алтын Урда дәүләтенең Аксак Тимер тарафыннан җимерелүен кабат телгә ала: «Аксак Тимер маршы» уйнаганда аның күз алдына Аксак Тимернең гаскәре килеп баса. «Ул шул кыска музыка уйналганда Тимернең бөтен тарихын Тимер берлә бергә үткән кебек булды. Тимернең шул зур хәрәкәтендәге гаясен, фикерен эзләде. Аның хәзерге ишеткән Идел буе музыкасының егълавы, ыңгырашуы, сыкрануы астында эзләде. Каһарман Тимер Идел буена барып Алтын Урданы җимермәгән булса, бәлки бу моңлы «Ашказар» көе, егълый, сыкрый торган «Тәфкилеф» көе тумаган булыр иде. Бәлки Идел буеның углы, полковник Тимергалиев төрле төрек кабиләсеннән җыелган атлы гаскәр белән берлә, ике башлы каракош байрагы астында икенче төрекләргә каршы сугышмаган булыр иде. Бәлки ике башлы кара кошның канатлары да бу кадәрозынга, Кавказ тауларына кадәр, Тимернең үзенең кабере яткан алтын Сәмәркантка – Төркестанга кадәр сузылмаган булыр иде. Бәлки ул хәзерге кебек Дәҗлә, Форат буйларына таба тешләрен ыржайтмаган булыр иде. Истанбулга, бугазларга кадәр ерткыч теше арасында күтәргән тәресен китерергә көчләнмәгән булыр иде...» [1: 30–31]. Гаяз Исхакый, үткән тарихта хаксызлыкка очраган милләт балаларының бу хаксызлыкны аңлау дәрәҗәсенә килүен аларда милләтенең киләчәге өчен көрәшкә омтылу хисләрен көчәйтүгә сәбәп булуын ассызыклый.

Һәр милләтнең милләт булып яшәвендә аның милли бәйсезлеге әһәмиятле принциплардан бере булганлыктан, Исхакыйның герое өчен ул елларда барган сугышта Төркиянең бөтенлеген һәм мөстәкыйльлеген саклап калуын зарури күренеш дип саный. Бу сәбәпле татар полковнигы гаскәрләре белән төрекләр ягына чыгуны милли хисләре көчле булган һәр кешенең милли бурычы дип кабул итә: «Без дә сезнең кебек төрек балалары. Төркиянең шул авыр көннәрендә, дошманнар берлә бөтен тарафыннан камалган көннәрендә, сезнең берлә бергә булып, ана йорт өчен үземезнең канымызны фида итәргә булып, рус сафын ташлап чыктык! Һәммәмезне кабул итеп, төреклек вазыйфамызны үтәргә әмер боеруыгызны көтәмез!-диде, кулындагы рус байрагын забитларын аягы астына ташлады. «Яшәсен Төркия!» дип кычкырды» [1: 85].

Миллият хисенең нигезендә иң әһәмиятле башка бер фактор – тел факторы. Тел безгә борынгы әби-бабаларыбыздан калган мирас, аңыбызга сеңгән рухи байлык. Ана сөте белән кергән туган тел шәхестә ата-анасына, туган туфрагына, туганнарына, табигатькә мәхәббәт һәм аларга омтылу хисе тәрбияли. Публицистик мәкаләләрендә төрки халыкларның милли бердәмлеге өчен уртак тел мәсьәләсенең әһәмиятен еш телгә алган Гаяз Исхакый «Өйгә таба» повестенда да бу мәсьәләнең хәлиткеч йогынтысын ассызыклый. Руслаштыру сәясәте астында калган бик күп милләт вәкилләре кебек, Тимергалиев та үзенең ана теленә әһәмият бирмәвен, манкортлаша баруын аңлый. Кызы Сөембикәнең хаты-

на иске гадәт буенча русча язарга тотынгач, «Ник соң ул әле кызына русча яза? Ул бит бик һәйбәт төрекчә яза белә, кызын да махсус мөгаллим алып укытты, ник соң ата берлә бала арасындагы мөнәсәбәтне рус сүзләре белән йөретә?... Ул яңа фикер ачты кебек булды, сөенде, шатланды. Кызына татарчалатып язарга тотынды» [1: 22]. Телнең гаилә әгъзаларын гына түгел, бөтен төрки халыкларны берләштерүче үтемле чара икәнен язучы татар Тимергалиевның биюче төрек кызлары, полкында хезмәт итүче Кырым татары, кыргыз, үзбәк, азәрбайҗан сугышчылар белән иркен аңлашуы вакыйгалары аша да җиткерә.

Милләтләрне бер арада торучы милли мәдәни компонентлардан диннең аерым бер вазыйфасы бар. Кешелек яшәешенең әхлак кануннарын билгеләүче дин җәмгыятьне тотрыклы һәм көчле итә. Дини кануннар буенча яшәүнең аерым шәхес һәм милләт өчен файдалы булачагын искәртә. Төрки халыкларның күпчелегендә милли үзаңның аерылгысыз компоненты булып ислам дине санала. Гаяз Исхакый баш героеның уяну процессын нәкъ менә аның дини тойгыларын кузгатудан башлый. «Айның нурына коенган мәчет», «йөзләрчә еллар моңлы азан тавышын тирә-юньгә тараткан манара», «ничә йөз еллар кешеләргә күңел тынычлыгы, җан рәхәте биргән михраб» кебек Ислам дине белән бөтенләшкән манзара әсәр героеның сугышларда алҗыган рухына көчле тәэсир итә. Повестьнең беренче битләрендә полковник Тимергалиевны «Чын, без кем? Дошман кем? Мин, полковник Тимергалиев, кем?!!» дип үз үзенә сорау бирергә мәҗбүр иткән күренеш – туп белән тишелгән мәчетне, аның яртылай өзелеп төшкән манарасын күрү тетрәтә. Тетрәтеп кенә калмый, «аның өзелеп төшкән манарасы кулы киселгән кешенең кулсыз җиңе кебек селкенә, саллана кебек, моңар йодрык күрсәтә кебек булды» [1: 20], ди язучы. Бу вакыйга аның гаиләсенең фаҗигасен дә кабат хәтерләтә: сугыш мәйданында каһарманча үлгән бердәнбер улы һәм бер кулы киселгән хатыны Нәфисәнең сыңар кул белән дога итү күренешләре белән төне буе саташып чыга.

Миллиятче мулла белән мөселманнарның хәле турында сөйләшкәндә, Тимергалиев төрки дәүләтләрне тәсбихтәге аерым-аерым төймәләргә охшата. Боларның баш төймәсе – бисмилласы Төркия, дип саный. «Менә хәзер тәсбихне дошманнар сүтеп җибәрү өчен аның бисмилласын югалтмакчы булалар, аның бәйләгән җебен өзеп-өзеп ыргытмакчы, астындагы төймәләрне аерым-аерым берәр төймә көенчә генә калдырмакчы булалар. Шул йипни кисүдә, бисмилланы бетереп ыргытудагы иң авыр йөкне безгә йөклиләр. ... Менә мин шуны, Мирхәйдәр Батыргәрәй угылы Тимергали, үземне-үзем төрек-татар дип уйлаган, үземне-үзем мөселман дип уйлаган Мирхәйдәр, шуны эшлимме? Дин ягыннан минем шул эшемә ничек дип каралачак? Милләтчелек ягыннан мин Шәехгалилек итимме?» [1: 69], ди ул ачынып. Ул моннан соң да руслар ягында калуны 350 ел буенча руслашу сәясәтеннән саклаган эти-бабаларның рухына хыянәт, диненә, милләтенә хыянәт, дип саный, «Илемезә, көнемезә, тарихымыза каршы хыянәт» [1: 69], дип уйлый. Язучы милләт белән динне, төрек-татарлык белән мөселманлыкны бер-береннән аерылмас төшенчәләр буларак тәкъдим итеlә.

Белгәнебезчә, тел һәм дин белән бергә, һәр милләтне милләт итеп яшәтүдә һәм башка милләтләрдән аерып торуда милли рухи кыйммәтләр, ул милләтнең рухи мәдәнияте әһәмиятле роль уйный. Ышанычлар, гореф-гадәтләр һәм йолалар теге яки бу халыкның мәдәни йөзен чагылдыра. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен һәм йолаларын сакларга омтылган. Татар халкының мең елларга сузылган бай тормыш тәҗрибәсе, матур гадәтләре, кешене шәхес итеп тәрбияли торган рухи хәзинәсе бар. «Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык – тарихсыз», дип әйтелә халыкта.

Билгеле берй олаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне тотырыклы итә, милләтне югалудан саклый һәм милли характер формалашуга җирлек булып тора. Мәсәлән, борынгы заманнан сакланган мәҗлес үткәрү тәртибе – аш-суның муллыгыннан бигрәк, кунакларның күңелен күрә белүгә һәм бер арада булуга корылган. «Өйгә таба» повестенда Гаяз Исхакый кунак чакыру һәм сый-хөрмәт күрсәтү кебек милли традицияне сурәтләүгә мөһим вазыйфа йөкли. Тимергалиевның азербайҗанлы адвокат Арыслан Үлмәс угылы белән татар Әсма ханымнарда кунакта булу эпизодында хуҗаларның юматрлыгы, кунакның күңелен күрә белү кебек сыйфатлар күзгә чалына. Гаилә башлыкларының кунакчыллыгы, балаларының килгән кунакка яхшы тәэсир калдыру өчен тырышулары кебек матур күренешләр – барлык төрки халыкларга хас уртак милли характер сыйфаты итеп бирелә.

Икенче яктан, Үлмәс угылы гаиләсендәге җылы мохит Тимергалиевның милли тойгыларын, үзенең татарлыгын уята: гаилә тормышын, Оренбургта вакытта хатыны, әбисе белән бергә булган бәхетле мизгелләрен, ямьле Дим буйларын хәтерләтә. Мөһаҗирлектә яшәгән Исхакый, туган җирен сагыну хисләрен, әйтерсең, баш герое кичерешләре аша бирә. Тудырган ана һәм туган тел образлары туган җир һәм ватан образлары белән аерылгысыз бәйләнгән. Олылау, илаһи дәрәҗәдә соклану хисләре уята торган бу газиз образлар, тормышның төрле яклары, шартлары белән бәйле булып, мәңгелек сагыш, үкенеч хисләре белән дә сугарылган.

Үлмәс угылы гаиләсе мисалында Исхакый милли мәдәни компонентлардан милли ризыклар (Казанча пешерелгән пилмән, шурпалы Казан бәлеше, төрек каһвәсе һ.б.) белән бергә милли музыкага да аерым вазифа йөкли. Ягъни милли хисләрне уятуда, милли тарихны, халыкның үткәнен искә төшерүдә халык җырларының көчле тәэсирен янә Тимергалиев кичерешләре аша аңлата. «Менә бердән музыка башланды. Тимергали әйтә торган сүзен онытып, музыка тыңларга тотынды. Нәфисәнең сөеп уйный торган “Ашказар”ын Фәридә моң иттереп уйнап җибәрде. Аның юл алуын көтеп торган Зәйнәп тамак тавышы берлә, җыр берлә кушылды. Аның хәтфә кебек йомшак тавышының каймак кебек ягымлы агышы Тимергалине тәмам исертте. Ул үзенең яшь вакыттагы хатыны берлә Дим буенда кунакта йөрүләрен, шундагы матур, ямьле чакларны яңадан хәтерләде, шундагы дөньяда гизде. Фәридәнең кулында пианино егълаганнан егълады. Ул иске “Ашказар”ның кайгы-хәсрәтенә бу көнге аһны, бу көнге моңны, бу көнге юксыллыкны, бу көнге мыскыллануны кушты...

“Ашказар”ны “Сакмар суы” алыштырды. Аның артыннан “Галиябану” килде, аның артыннан “Тәфкиләү”е, аның артында полковник ишетмәгән “Ләйлә-Мәҗнүн”, “Аршын-мал-алан” операларының парчалары, азербайҗан, комык йырлары уйналды, йырланды. Фәридә һичбер арымады, һаман уйнады. Полковник Тимергалиев һаман тыңлады, туймады, тыңлады» [1: 30]. Сугышта ятим калган балалар файдасына Җәмгыяте Хәйрия тарафыннан уздырылган кичәдә дә Гаяз Исхакый татар полковнигында милли хисләрне ныклап урнаштыру һәм төрки халыклар мәдәнияте, әдәбияты белән таныштыру максатын куя. Кичәдә «Ләйлә-Мәҗнүн» операсыннан парчалар, Кырым татарлары кайтармасы, лезгин биюе, аеруча С. Рәмиевнең «Татар йоклый» шигыре һәм Г. Тукайның «Соңгы азан» җыры кичәгә катнашучылар күңелендә берлек һәм үз кавемен саклау өчен көрәшкә күтәрелүдә яңа дәрт-көч уята. Тимергалиев полкы Төркия чикләре ягына чыккач, Тимер маршы, төрек музыкасы һәм Урда маршының дәртле яңгыравы ярдәмендә, язучы төрки халыкларның бердәмлеге хисен тагын да көчәйтә төшә. Гомумән, XX гасыр башы татар язучылары кебек, Гаяз Исхакый бу әсәрендә дә театр, матур әдәбият, уен кораллары һәм

жыр-бию кебек сәнгать чараларының милли тойгыларны уяту һәм саклау өчен үтемле чара икәненә басым ясый.

Белгәнебезчә, төрки халыклар төп йортлары саналган Алтай тауларыннан көнбатышка таба күчү нәтиҗәсендә, бу этнос евразиянең төрле җирләренә таралып урнаша, төрле дәүләтләр кора, төрле табыш-югалтуларга очрый. Һәр төрки халыкта электән уртак булган милли мәдәни кыйммәтләрне дәвам иттерү белән бергә, яңа географик җирлектә башка халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә үзгә гадәтләр дә үтеп керә һәм бу табигый процесс буларак кабул ителә. Мәсәлән, татарлар, барлык төрки халыкларга хас уртак кыйммәтләрне саклау белән берлектә, руслар, чувашлар һ.б. милләтләр белән күрше яшәү сәбәпле, аларга хас кайбер йолаларның да тәэсирендә кала. Шулай да, Исхакый мирасын өйрәнүче күренекле галимнәрдән Хатип Миңнегулов та билгеләп үткән кебек, «Шәҗәрәи туганлык, тел, гореф-гадәт, рухи мирас якынлыгы төрле төбәкләргә сибелгән төрки кавемнәрен үзара тартып тора, аларда чагыштырмача рухи бердәмлек тудыра, кардәшлек тойгысын саклый» [3: 35]. Электән килүче кыйммәтләр бөтен төрки халыкларның уртак әдәби ядкарьләре саналган дастаннарда, мәкаль-әйтемнәрдә, халык җырларында сакланып калган. Халык авыз иҗаты ул – халкыбызның шанлы һәм аянычлы тарихын, яшәү тәҗрибәсен, тормыш фәлсәфәсен һәм хыял-омтылышларын чагылдыручы иң бай хәзинә. Халык әдәбиятыннан тәэсирләнгән Исхакый, Тимергалиевне вакыт-вакыт каһраманлык дастаннардагы куркусыз каһарман сыйфатында күз алдына бастыра. Язучы рус генералы авызыннан татар полковнигының сугышка һәрзаман хәзер булуына, армыйча, һаман алга баруына соклануын белдерә. Тимергалиев, бәйсез төрек дәүләте мәйданга китереп, бүленгән, башка милләтләр басымы астында калган төрки халыкларны тупларга хыяллана.

Үз милләтенең үткән тарихын яхшы белгән һәм горурлык тойгылары булган халыклар киләчәккә якты өметләрен югалтмый, һәртөрле авырлыкларны җиңеп чыгарга көч таба. Үткән тарихыннан һәм милләтенең казанышларыннан көч аларак, үз асылына кайткан Тимергалиев, полкында үзе кебек милли коллык хисеннән арына башлаган сугышчыларның да милли бәйсезлек хисләренең иреккә чыкмасына мөмкинлек ярата. Уртак тарих, уртак тел һәм дин бердәмлеге фикере астында кулга кул тотынышкан бер кавем балалары Тимергалиев җитәкчелегендә уртак төрки байрак астында милли идеалга туры юлга чыга. «Гаяз Исхакыйның үзе алып барган көрәшнең эзләре тасвирланган “Өйгә таба” повесте – Төркилек, Хөррият, Ватан, Байрак кебек төшенчәләр тирәсендә уйланганда бер туу, барлыкка килү хикәясе, – дип яза Самед Азап. – МиралайТимергалиев – рус армиясендә хезмәт итәргә мәҗбүр булган төрек гаскәрләренең тавышы» [4: 312].

Гомумән алганда, «милли азатлык идеясе белән сугарылган бу әсәрдә» [6: 63] татар полковнигы төрекмән, кара кыргыз, казак, татар, нугайлардан оешкан полкы белән «милләтебезнең бердәнбер мөстәкыйль мәмләкәте» саналган Төркияне һәлакәттән коткаруны милли һәм хәрби вазифа итеп күрә. Бары тик бердәмлек булганда гына төрки халыклар үзләрен коткарып кала алачакларын [2: 100] үткәндәге һәм ул еллардагы конкрет вакыйгалар үрнәгендә җиткерергә омтыла.

Беренче дөнья сугышы бетеп, Төркия Республикасы корылуын Гаяз Исхакый төрки бердәмлек фикерен тормышка ашыру өчен уңайлы мөмкинлек туды дип саный. Язмаларында Төркиянең башка төрки халыкларга юлкүрсәтүче вазифасын башкаруын, аеруча мәгариф идарәләре аша Төркестан, Азәрбайҗан, Кавказ, Идел буе һәм Себер якларында эшчәнлек алып барырга тиешлеге фикерен алга куя. Төркия дәүләтенең яңа милли үзаң оештыру өчен милли максат һәм хис бердәмлегенә, уртак тел, тарих һәм милли тәрбиягә әһәмият бирергә

тиешлегенә басым ясый. Төрек дөньясы белем һәм мәгариф мәркәзе, төрек әдәбияты да бу юлда байракны алдан алып баручы булырга тиеш дип саный [5: 8].

«Төрек сәясәтчеләрен һәм зыялыларын юньләндерергә тырышулары һәм Төркиянең башка төрки халыкларга игътибарсыз калмаска тиешлеге хакындагы киңәш-нәсыйхәтләре уңай кабул ителмәгән. Киресенчә, бу теманы яктырткан мәкаләләре тәнкыйтькә очраган, совет һәм төрек сәяси мохитен борчыган. Бу исә аның читкә этәрелүенә сәбәп булган. Ләкин төрек дөньясы белән мөнәсәбәтләр яңадан тергезелә башлаган соңгы егерме елда аның фикерләре кабат актуальлек казанды» [7: 124], дип яза төрек галиме Әхмәт Канлыдәрә.

Йомгаклап әйткәндә, Гаяз Исхакый «Өйгә таба» повестенда милләтне милләт итүче һәм милли тойгыларны уяндыручы сәбәпләрне, төрки халыкларның үткәнен һәм бүгенге сәяси торышын бер герой уйланулары һәм язмышы мисалында җыйнак композициядә бирә алган. Төп героеның кичерешләре һәм күзаллауларында халкыбызның милли тарихны дөрес күрә белергә, милләтнең үткәнен, бөеклеген аңлый белергә һәм ата-бабаларыбызга лаек буын җитештерергә кирәклеге фикере аңлашыла. Әсәрдә уздырылган идея – телне, динне, гореф-гадәтләрне, милли кыйммәтләрне саклау нәтиҗәсендә милләтнең бәйсезлегенә ирешә алу мөмкинлеге фикере бүген дә көнүзәк мәсьәләләрдән санала.

ӘДӘБИЯТ

1. Исхакый Г. Өйгә таба //Әсәрләр: 15 томда. 5 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 559 б.
2. Зарипова Четин Ч. Гаяз Исхакый әсәрләрендә милләт язмышы // Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 2008. Б. 93–101.
3. Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 367 б.
4. Azap S. (2015), Ayaz İshaki’nin Üyge Taba (Eve Doğru) Romanında Milli ve Dini Uyanış, Selçuk Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Dergisi. Sayı 34. S. 303–312.
5. İshaki A. Hariçteki Türklerin dileği, Yeni Kafkasya, I/8, 1 Kanunısani, 1339/1 Ocak, 1923, 8.
6. Kamalieva A. (2009), Romantik Milliyetçi Ayaz İshaki, Grafiker Yayınları, Ankara, 248 s.
7. Kanlıdere A. Ayaz İshaki (1878-1954) ve Türkiye’de Türkçülük Fikrinin Evrimi. Türk Kültürü İncelemeleri Dergisi 27, 2012, İstanbul, S. 77–124.
8. Maksudi S. (1975), Milliyet Duygusunun Sosyolojik Esasları, Ötüken Yayınevi, İstanbul, 196 s.

# Г. ИСХАКЫЙНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ИҖАТЫ ХАКЫНДА Г. СӘГЪДИ

***Ф.З. Яхин*** *(Казан)*

Статья посвящена первому периоду творческого пути Г. Исхаки, раскрытию его особенностей. На основе научных фактов и анализов, автор делит его на две основные части, подчеркивая, что они имеют общие признаки, но значительно отличаются по своим характеристикам. Г. Исхаки принадлежал к числу нового поколения, которые начали писать свои произведения на «новом» татарском литературном языке, разработанном в научном и практическом уровнях Каюмом Насыйри. Но писатель в далее начал переход в так называемый «путь И. Гаспринского», а все же вскоре отказался от данной затеи. Основываясь на результаты исследований ученых, оставляя в центре внимания труды Г. Сагди, автор статьи делиться своими литературоведческими наблюдениями, характеризует первый этап творческого пути Г. Исхаки. Отмечается, что в эти годы писателя интересовали вопросы личного счастья людей, но от произведения к произведению он больше начал интересоваться национальными, общественными и политическими проблемами, находя решения в идейно-художественном уровне.

**Ключевые слова:** Революционное крыло татарской буржуазии, европоцентрист, представитель национального возрождения, творческий потрет Г. Исхаки, первый этап творческого пути Г. Исхаки, вопросы личного счастья, общественно-политический уровень.

The article is devoted to the first period of creative way of G. Ishaki and disclosure of his features. On the basis of scientific facts and analyses, the author divides it into two main parts, emphasizing that they have common features, but differ significantly in their characteristics. G. Ishaki was among the new generation who began to write their works in the «new» Tatar literary language, developed at the scientific and practical levels by Kayum Nasyri. But the writer then began the transition to the so called «the path of I. Gasprinsky», but soon abandoned this venture. Based on the results of research scientists, leaving the focus of the works of G. Sagadi, the author of the article to share his literary observations, characterizes the first stage of the creative path of G. Ishaki. It is noted that in these years, the writer was interested in the personal happiness of people, but from work to work, he began to be more interested in national, social and political problems, finding solutions in the ideological and artistic level.
**Key words:** Revolution wing of the Tatar bourgeoisie, eurocentrism, the representative of the national revival and creative portrait of G. Ishaki, the first stage of the creative path of G. Ishaki, questions of personal happiness, social-political level.

Г. Исхакый әдәбият мәйданына килгән чорда татарда әдәби тел ике юнәлештә үсеш алырга өлгергән була. Бу мәсьәләне аерым өйрәнеп, 1926 елда басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы»нда галим Г. Сәгъди XX йөзгә кергәндә әдәби телебезнең үсешенә бәйле күзәтүләрен бирә, бу ике юнәлешне И. Гаспринский куәтләгән төрекчелек һәм К. Насыйри нигезләгән татарчылык хәрәкәтләре буларак аңлата [3: 104]. XVIII гасыр ахырында, беренче тапкыр мөфти сайлау мәсьәләләре килеп тугач, татар милли буржуазиясе шактый активлашып ала. Шул чорда аның милли-мәдәни карашлары формалаша. Дини китапларның татарга аңлаешсыз булулары, аларны аңлау өчен озак еллар буена гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнү таләп ителүе, алга таба болай барырга ярамау, татар милли мәгарифен булдыру кирәклеге хакында Казан байлары еш әйтә башлыйлар. Тел мәсьәләсе актуальләшеп китә. XIX йөзнең икенче яртысында гарәп-фарсы телендәге китапларны милли телгә тәрҗемә итеп бастыру эше милли капиталистлар ярдәме белән алга китә. Шәригать гыйлемнәрен халыкка үз телендә җиткерүгә аеруча зур игътибар бирелә. Шул чорда иҗат иткән әдипләребезнең, галимнәребезнең хезмәтләренә игътибар итсәк, аларның никадәр бу хәрәкәткә берегеп китүләрен ачык күзалларга була. Бу хәрәкәтнең иң актив эшлеклесе И. Гаспринский уку-укыту эшен милли юнәлешкә кору концепциясен эшли. Аның нигезенә «җәдит методы»н (әлбәттә шартлы рәвештә хәзерге фәнни әдәбиятта ул шулай атала, әмма чынлыкта «ысулы сөбүтия», ягъни «аваз методы»исеме белән мәшһүр укырга-язарга өйрәнү-өйрәтү методикасын) куя.

И. Гаспринскийның төрекчелек хәрәкәтен матур әдәбиятта пропагандалап алып баручы әдипләр итеп Г. Сәгъди М. Акъегетне, З. Бигиевне, Р. Фәхретдиновны атый, бу исемлекнең шактый киң булуын да искәртә [3: 104]. Ә К. Насыйри юлын алып тотучы әдипләр исемлегендә Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камал, Ф. Кәрими, С. Максуди, Г. Исхакый, Я. Вәли, Ш. Шәһидуллин, Ш. Рәхмәтуллин атала [3: 104].

Шушы хәбәрләргә нигезләнеп, Г. Исхакыйның әдип буларак беренче адымнарыннан татарчалыкка өстенлек бирүен ачык билгели алабыз. «XX йөзгә кергәндә бу юлда шушы төркемнең эше күзгә күренерлек бер хәл иде» дип ассызыклый Г. Сәгъди һәм бу әдәби телнең «гавәм теле» нигезендә үсә башлавын аңлата [3: 104]. Монда, «гавәм теле» дигәнендә, гади сөйләм телеме, әллә гади халыкка аңлаешлы татар милли әдәби телеме күздә тотыла – галим боларга ачыклык кертми. Шулай да аңлашыла: сүз гади сөйләм теле хакында бара алмый, чөнки әдәби әсәрнең төп үзенчәлегенең берсе – аның әдәби телдә язылуы. Гади сөйләм телендә публицистик әсәрләр иҗат ителә, журналистика аның нигезендә үсә.

Шул ук вакытта, «гади сөйләм теле» дигәндә, теге яки бу диалект, җирле сөйләм теле дип тә аңларга ярамый. Гади сөйләм теле текстларныәдәби сурәтсез, гади сүзләр, тасвирлар урынына хәбәрлекләр белән төзүгә хезмәт итә. Алар икесе дә, әдәби тел һәм гади сөйләм теле, язма телгә карыйлар. Шулай итеп, «гади сөйләм теле» дип аталуы гадәти, туры җөмләләрдән булуыннан килә.

1906 елда татар әдәбиятының үсешенә бәйле мәкаләләрендә Й. Акчура «Милләттәшләрем арасында ике чын әдип җитеште: берсе – хәссас, адәшле [артыгы белән хисле, утлы] милләтпәрвәр идеалист вә романтик Гаяз; икенчесе – гасаби [борчулы], тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих» [3: 122]. Бу сүзләргә таянып, Г. Сәгъди аларга мондый уртак характеристика төзи: «Болар икесе дә мөгаллим, икесе дә җәдитчеләр булып, татар буржуазиясенең сулрак, радикальрәк булган яңа, яшь гыйльми-әдәби терәкләре – чын «европеист» юлбашчылары иде. Икесе ике яктан торып, буржуазиянең матди ярдәменә таянган хәлдә эшне кызулата башладылар» [3: 122].

Болардан аңлашылганча, галим тарафыннан Г. Исхакый милли буржуазиянең революцион канаты вәкиле, европачыл фикер иясе, милли яңарыш вәкиле, мәгърифәтче-мөгаллим һәм юлбашчы буларак бәяләнә. Й. Акчураның фикерләренә килгәндә, Г. Исхакыйның иҗат портретын ул тулы һәм конкрет детальләрдә ача, аның иҗатына хас үзенчәлекләреннән хисчәнлекне һәм ялкынлы милләт сөючәнләкне төгәл күрсәтә. Аның бу бәяләмәсе белән килешми мөмкин түгел. Шул ук вакытта ул, Г. Исхакыйның идеалист һәм романтик булуын да билгели. Димәк, Г. Исхакый әдәби геройларын күңел дөньялары үзгәрешләре белән бәйле сурәтли, вакыйгаларны да геройларының эчке дөньялары аша, күңел күзләре күргәнчә тасвирлаучы әдип буларак бәяләнә.

Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатын Г. Сәгъди 1900 елда басылып чыккан «Теләнче кыз» хикәясенә бәйләп икегә бүлә. Аның беренчесен «зәгыйфь, өйрәнчек һәм телендә мишәр вә госман йогынтысы көчле» әсәрләр тәшкил итүен күрсәтә. Аларга «җәдитчә, яңа мәктәпләрдә укытуга кызыктыру», «ризалар [Р. Фәхретдинов кебек әдипләр] юлынча әдәбиятта рационализм агымының бер тамчысы» буларак бәя бирә [3: 123], арадан «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем өйрәнүдә рәхәт гомер» хикәясен Гани бай Хөсәеневнең мактавын искәртә. Җәдитче, Оренбургта «Хөсәиния» җәдит мәдрәсәсен оештыручы һәм аны югары уку йорты дәрәҗәсенә җиткерү өчен байлыгын да кызганмаган Гани Хөсәенев кебек кешенең Г. Исхакыйга беренче әсәреннән башлап фатиха бирүе олы иҗтимагый резонанс тудырган, билгеле.

Беренче әсәрләреннән әдип төп игътибарны шәхсият мәсьәләләренә юнәлтә. Аны бәхетнең нидән гыйбәрәт булуы кызыксындыра. Әдәби герой омтылышларын иҗтимагый яссылыкта әдәби тасвир аша бирүшә алына алмый, иҗтимагый әһәмияткә ия фикерләрне турыдан-туры, нотык сүзе буларак әйттерү белән чикләнә. Бу аның әлегә әсәрләрне схематик планда коруыннан да килә. Беренче әсәренең басылу тарихчасын соңыннан исенә алып, аны бер-ике көн эчендә язып бетерүен, аннары, укып та тормастан, китапчы бертуган Кәримовларга илтүен, аларда сатып калдыруын, бу гамәле белән ничә көннәр очынып йөрүләрен яза [4: 5–55].

Г. Исхакый, язучы буларак, укучының мәхәббәтен «Кәләпүшче кыз» хикәясе белән яулый. «Әдәби агым ягыннан әсәр сентиментализмның татар әдәбиятында беренче ачык үрнәге, – дип билгеләп уза әсәрне Г. Сәгъди. – Ләкин фикерчелек-рационализмнан аерылып бетмәгән бер рәвештәгесе», – дип тә аңлата [3: 125]. Бусы сүзләре дә «Кәләпүшче кыз»ны Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗатына нисбәтле бәяләргә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта Г. Сәгъдинең бу сүзләрен әдипнең фикерчелектән сентиментализмга таба авышуы,

ягъни публицистик формалардан матур әдәбиятка күчеш башлавы буларак та бәяләү дип аңларга кирәк. Димәк, фикер бирү – публицистик әсәрләргә хас булса, хисси тасвирлар әдәби әсәрнең тууында төп рольне башкаралар. Әдәбиятта фикер бирүгә мәгънәви тасвирлар бирү ярдәмендә ирешелә. Г. Исхакый да нәкъ шуны эшли. «Кәләпүшче кыз» белән ул башлангыч иҗат чорының икенче баскычына күчә. Әмма әлегә фикер бирүдән котылып җитә алмый. Г. Сәгъдинең: «Гаязның соңыннан басылган бөтен хикәя-романнары, пьесалары аның киң шашкын котырык хыяллы һәм тасвирының күренешле (картиналы), җиңел алымлы булуын күрсәтәләр» [3: 124], – дигәннәре, аерым бер иҗат дәверенә генә түгел, бәлки «Кәләпүшче кыз»га һәм аннан соң язылган һәммә әсәрләренә карый, анализ ягыннан да тулы, дөрес бәя булып тора, дияргә кирәк.

Бу хикәя Р. Фәхретдиновның «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәрен хәтерләтә. Татар кибетче-приказчикларының кызлар белән уйнарга яратулары, аларның булышчылары буларак карчыкларның арадашчылык итүләре хис-кичерешләр стихиясе эчендә тасвир ителә. Хикәягә сүз башында Г. Исхакый Камәр кебек юлдан язган кызларның язмышлары нәрсә белән бетәчәген күрсәтергә теләвен аңлатып язып уза [2: 51]. Хикәянең ахыры, Р. Фәхретдиновныкыннан аермалы буларак, герой һәлакәте белән тәмамлана. Шәхси язмыш һәм бәхет турында мәгънәви яктан уйлану бу чорда Г. Исхакый иҗатының төп көченә әверелә.

Әдипнең «Өч хатын белән тормыш» драмасы да шундый әсәрләреннән берсе. Ул 1900 елда дөнья күрә, ахырдан да татар театры тарафыннан уйнала, репертуарында төп спектакльләреннән санала. Г. Сәгъди бу драманы толстойчылыкның татар әдәбиятында чагылышы буларак бәяли, надан Кәрим байның энесе Ризаны шул идеяләрне әсәрдә турыдан-туры сөйләүче персонаж буларак бәяли [3: 127]. Бу драма яңа татар зыялылары катламын барлыкка китерү һәм аңа үсеш юнәлешен ачыклап бирү теләге белән язылган.

Г. Исхакыйның башлангыч иҗат чорына Г. Сәгъди «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен һәм «Теләнче кыз» роман-трилогиясен дә (өченче кисәгенең 1914 елда гына басылуын да исәпкә алып, әлбәттә) кертә [3: 130–133]. Әдип бу әсәрләре белән шәхси әдәп һәм бөек әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый проблемаларга кадәр үсеш кичерә, гомумкешелеккә һәм милли язмышка бәйле әдәби-мәгънәви эзләнүләрен башлый. Бу аның язучы-мөгаллим булудан әдиплеккә таба кыю адымы буларак бәяләнергә тиешле.

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен тикшереп, аның жанры табигатен билгеләү юлында эзләнүләр алып барып, Ә. Сәхапов аны, И. Нуруллин кебек үк, «фантастик-публицистик повесть» дип атый [5: 50–54]. Галимә Ч.М. Гыйләҗева «“Инкыйраз” турында Габдрахман Сәгъди» мәкаләсендә кызыклы күзәтүләр уздыра һәм Г. Баттал кебек үк Г. Сәгъдинең дә әсәрне «хитаби тәэлиф» буларак атавына тукталa, шуның нигезендә мондый фикерне алга сөрә: «Структурасы ягыннан караганда, әсәрнең төзелеше чыннан да хотбә рамкаларына туры килүе күзәтелә» [1: 109].

Хотбә мәсьләсенә килгәндә, ул публицистик жанр, әлбәттә. Аның эмоциональ характерда булуын, моның өчен әдәби стильгә мөрәҗәгатә итүен, әдәбият үсешенә йогынты ясавын У.А. Гафарова 1989 елда кандидатлык диссертациясе буларак яклаган «Арабское ораторское искусство (хутба) VI – середины VII в.» хезмәтендә махсус тикшергән, аның киң таралыш алган сөйләм чәчмә жанр буларак формалашуын, матур әдәбиятта да файдалана башлавын ачыклаган [6]. Әмма хотбәнең аерым, матур әдәбият жанры буларак түгел, бәлки публицистик әдәбият жанры булуын ачык аңларга тиешбез. Әдәбиятыбыз галимнәренең фикерләренә таянсак, Г. Исхакый аны әдәби жанрга әверелдерүен ассызыкларга тиешбез. Г. Сәгъдинең «хитабы тәэлиф» дигән, Г. Батталдан алынган

терминына килсәк, аны «нотык тупланмасы» буларак тәрҗемә итәргә туры килә. Димәк, әсәрнең жанр табигате күз алдына тулырак килә, публицистик формада язылганлыгы да раслана.

Киләчәктә булачак вакыйгаларны тасвир итүе белән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый күзаллауга корылганлыгын, ягъни фантастика булуын күрсәтә. Автор үзе әсәрен «хыялый роман» дип атый [1: 109], Г. Сәгъди аның, күләменә бәйле – роман, формасына карап– хикәя, стиле белән – әдәби хотбә икәнен ачыклый [3: 128]. Бу фикерләре «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның фантастик-публицистик повесть булуын тагын бер кат раслыйларга ярдәм итә. Димәк, бу әсәрнең жанрын билгеләгәндә И. Нуруллин да, Ә. Сәхапов та дөрес нәтиҗәләргә килгәннәр. Әмма әсәр авторының ихтыярын да исәпкә алырга, ягъни «хыялый роман» булуын истә тотарга мәҗбүрбез.

Әдәбиятлар үсешен тикшергәндә, ихтыярсыз шундый күзәтүгә килергә мәҗбүрбез: беренчедән, ничек кенә булмасын, әмма рус-европа мәдәниятен үзләштерүгә таба борылганда, милләтебезнең шул чор зыялылары лубок әдәбияты саналган китапларга тартылганнар, әдипләрнең үз әсәрләрен укудан бигрәк, «халык китаплары» буларак басылып чыккан, эчтәлек сөйләп чыгуга корылган вариантларын укыганнар, икенчедән, дөньякүләм танылган рус-европа әдипләренең әсәрләрен шул форматта гына булганнар дип күз алларына китергәннәр, өченчедән, менә шулар сәбәпле алар йөз сәхифәдән арткан әдәби әсәрләрне роман итеп күзаллаганнар. XIX йөз ахырында, алга таба XX гасыр башларында язылган «милли роман»нарның күләм ягыннан кечкенә булулары сәбәбен башкача аңлап булмый. Аннары, бу фикерне ул чордагы тәрҗемәләр дә раслыйлар. Алар чыннан да «халык китабы» форматында эшләнелгәннәр һәм зур-зур чәчмә әсәрләрнең эчтәлекләрен кыскача сөйләп чыгуга корылганнар. «Халык китаплары»нда романнарның бер сюжет линиясе генә алынып сөйләп чыгыла. Ә роман булу өчен әсәр кимендә ике сюжет сызыгына корылырга тиеш. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның, берничә вакыйгалы булуыннан чыгып, повесть икәнлеген таныргa тиешбез.

Г. Сәгъди «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә Г. Исхакый иҗатының башлагыч чорына бәя биргәндә чын мәгънәсендә фәнни-тикшеренү эше алып бара, үзен яхшы теоретик әзерлекле, киң белемле галим буларак күрсәтә. Аның фикерләре белән килешеп, әдипнең иҗатта катлаулы үсеш юлын кичерүен, шәхси бәхет мәсьәләләрен ачыклаудан иҗтимагый проблемаларны сурәтләүгә һәм аларны чишү юлын табуга кадәр күтәрелә баруын, XX йөзгә җитлеккән, әдәби-иҗтимагый аңы формалашып өлгергән сыйфатында килеп керүен аерым билгеләргә тиешбез.

## ӘДӘБИЯТ

1. Гыйләҗева Ч.М. «Инкыйраз» турында Габдрахман Сәгъди // Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш: Гаяз Исхакый тууна 130 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (11 декабрь, 2008). Казан, 2008. Б. 108–113.

2. Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. Т. I: Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 399 б.

3. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926.

4. Сәхапов Ә. Г. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты: монография. Казан: Мирас, 1997. 528 б.

5. Сәхапов М.Җ. Татарны инкыйраздан саклап калу өчен көрәштә // Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: Әдипнең 120-еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: Фикер, 2000. Б. 50–66.

6. [Электрон ресурс]. URL: http://cheloveknauka.com/arabckoe-oratorckoe-iskusstvo-hutba-yi-serediny-yiii-vv (мөрәҗәгать итү датасы: 28.03.2018.).

## СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРАХ

**Абзалина Рамзия Асраровна,** старший научный сотрудник Национального музея Республики Татарстана. *Казань, Россия.*

**Айшегюль Сойсал Акъёз,** преподаватель Босфорского университета. *Стамбул, Турция.*

**Алишина Ханиса Чавдатовна,** доктор филологических наук, профессор, директор центра тюркологии Тюменского государственного университета. *Тюмень, Россия.*

**Аминева Венера Рудалевна,** доктор филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Арзу Кылынч,** кандидат наук, преподаватель Университета искусств им. Мимара Синана. *Стамбул, Турция.*

**Ахмет Канлыдэрэ,** доктор наук, профессор Университета Мармара. *Стамбул, Турция.*

**Ахметова Миляуша Ансаровна,** ведущий библиотекарь Научной библиотеки Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Ахтямова Алсу Вазиховна,** кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Бадиков Канафи Габделбарович,** кандидат филологических наук, доцент, член Правления союза Писателей Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Байрамова Фаузия Аухадиевна,** кандидат исторических наук, писатель. *Набережные Челны, Россия.*

**Баширова Илида Басыровна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Баязитова Флера Саидовна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Болгарова Рамзия Марсовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Булатова Миннира Рахимовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Габдрахманова Фануза Хайдаровна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Габидуллина Фарида Имамутдиновна,** кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Гайнанова Лена Рашитовна,** в 1963–2001 годы работала старшим научным сотрудником Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Гайнанова Миляуша Рамилевна,** кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Гайнутдинов Айдар Марсилевич,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Гали Булат Талгатович,** доктор исторических наук, доцент Казанского государственного аграрного университета. *Казань, Россия.*

**Галимзянова Эльмера Махмутовна**, кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Галимова Гульшат Наилевна,** аспирант Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Галимова Эльмира Мунировна,** кандидат искусствоведения, зав. отделом театра и музыки Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Галимуллин Фоат Галимуллович,** доктор филологических наук, профессор Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Галиуллин Радик Рамилевич,** кандидат филологических наук, доцент, зав. кафедрой татарского языка и литературы, методик их преподавания Набережночелнинского государственного педагогического университета. *Набережные Челны, Россия.*

**Галиуллин Талгат Набиевич,** доктор филологических наук, профессор, старший научный сотрудник Республиканского центра развития традиционной культуры. *Казань, Россия.*

**Галиуллина Диляра Магзумовна,** кандидат исторических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Галлямов Филус Гатипович,** доктор филологических наук, профессор Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Гарипова Лейля Шамилевна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Гарифуллин Васил Загитович,** доктор филологических наук, профессор, зав. кафедрой татарской журналистики Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Гёздэ Гюнгёр,** кандидат наук, лектор Синопского университета. *Синоп, Турция.*

**Гилазов Тагир Шамсегалиевич,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Гилязова Алия Фанавилевна**, преподаватель татарского языка и литературы ГАПОУ «Арский педагогический колледж им. Г. Тукая». *Арск, Россия.*

**Гиниятуллина Лилия Миннулловна,** кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Гумметова Хураман Бахман,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Азербайджанской Национальной Академии наук. *Баку, Азербайджан.*

**Даутов Гумар Фильгизович,** кандидат филологических наук, доцент Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Денмухаметова Эльвира Николаевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Загидуллин Ильдус Котдусович,** доктор исторических наук, доцент, зав. отделом новой истории Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Загидуллина Дания Фатиховна,** доктор филологических наук, профессор, вице-президент Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Зайнуллина Гульшат Ильфатовна,** кандидат филологических наук, доцент Университета Управления ТИСБИ. *Казань, Россия.*

**Закиев Мирфатых Закиевич,** доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Закирова Ильсеяр Гамиловна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Зарипова-Четин Чулпан Афраимовна,** кандидат филологических наук, доцент, зав. кафедрой русского языка и литературы Кавказского университета. *Карс, Турция.*

**Ибрагимов Марсель Ильдарович,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Ибрахим Гюмюш,** кандидат наук, ассистент Бартынского университета. *Бартын, Турция.*

**Идрисов Рауф Рифгатович,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного университета. *Уфа, Россия.*

**Ильяс Кемальоглу (Камалов),** доктор наук, профессор Университета искусств им. Мимара Синана. *Стамбул, Турция.*

**Исламова Эльвира Альбертовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Кадирова Дина Марсиловна,** старший преподаватель Казанского национального исследовательского технологического университета. *Казань, Россия.*

**Кадирова Энзе Ханафиевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Камалиева Алсу Миннахметовна,** доктор наук, зав. кафедрой тюркских языков и литератур Бартынского университета. *Бартын, Турция.*

**Каюмова Гелюса Фаридовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Кириллова Зоя Николаевна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Кириллова Роза Владимировна,** кандидат филологических наук Удмуртского государственного университета, отв. редактор научного журнала «Ежегодник финно-угорских исследований». *Ижевск, Россия.*

**Мингазова Ляйля Ихсановна,** доктор филологических наук, доцент, профессор Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Мингазова Резиля Абузаровна,** кандидат филологических наук, преподаватель Набережночелнинского педагогического колледжа. *Набережные Челны, Россия.*

**Миннегулов Хатип Юсупович,** доктор филологических наук, профессор Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Миннуллин Ким Мугаллимович,** доктор филологических наук, профессор, член-корреспондент АН РТ, директор Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Миннуллина Фатыма Халиулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Мотигуллина Альфия Рухулловна,** кандидат филологических наук, доцент Поволжской государственной академии физической культуры, спорта и туризма. *Казань, Россия.*

**Муртазина Ляля Раисовна,** кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Мухаметшин Зуфар Гумерович,** кандидат филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Мухарлямова Гульназ Нурфатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Набиуллина Гузель Амировна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Насибуллина Нурида Шайдулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Насибуллова Гузель Ришатовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Нигматуллина Алсу Мансуровна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Нурмухаметова Раушания Сагдатзяновна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Рамеев Зуфар Зайниевич,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Родионов Виталий Григорьевич,** доктор филологических наук, профессор, ведущий научный сотрудник Чувашского государственного института гуманитарных наук. *Чебоксары, Россия.*

**Сабитова Ильгамия Исламутдиновна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Сагдеева Фаузия Кабировна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Сагдиева Рамиля Камиловна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Садекова Айсылу Хусяиновна,** доктор филологических наук, главный научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Сайфулина Флера Сагитовна,** доктор филологических наук, профессор, зав. кафедрой татарской литературы Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Салихова Айгуль Рустэмовна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Самитова Савия Гималтыновна,** кандидат филологических наук, доцент Института социальных и гуманитарных знаний. *Казань, Россия.*

**Саттарова Мадина Рашидовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Сафина Эльвира Ирфатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Сибгаева Фируза Рамзеловна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Тагирова Фяридя Инсановна,** кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Фаезова Ландыш Робертовна,** аспирант Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Фазлутдинов Ильдус Камилович**, кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного университета. *Уфа, Россия.*

**Файзуллина Фания Галимулловна,** старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Фардеева Динара Радиевна,** кандидат филологических наук, научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Фаттахов Ильгам Фаилевич,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Фатхуллова Кадрия Сунгатовна,** кандидат педагогических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Хабутдинова Милеуша Мухаметзяновна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Хазиева-Демирбаш Гузалия Сайфулловна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Хайруллина Альфира Салихзяновна,** кандидат филологических наук, старший преподаватель Елабужского института Казанского (Приволжского) федерального университета. *Елабуга, Россия.*

**Хайруллина Дина Мунировна,** кандидат филологических наук, доцент Башкирского государственного университета. *Бирск, Россия.*

**Хакимова Василя Харисовна,** старший преподаватель Удмуртского республиканского социально-педагогического колледжа. *Ижевск, Россия.*

**Ханнанова Гульчира Махмутовна,** научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Харрасова Рифа Фатхрахмановна,** кандидат филологических наук, доцент, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Хатиджэ Ширин**, доктор наук, профессор Эгейского университета. *Измир, Турция.*

**Хусаинова Алина Ямилевна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Хуснутдинов Дамир Хайдарович,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Хуснутдинова Гульназ Азатовна,** кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Шакурова Муслима Магесумовна,** кандидат филологических наук, доцент, ведущий научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Юсупова Альфия Шавкетовна,** доктор филологических наук, профессор, директор Высшей школы татаристики и тюркологии им. Габдуллы Тукая Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Юсупова Нурфия Марсовна,** кандидат филологических наук, доцент Казанского (Приволжского) федерального университета. *Казань, Россия.*

**Яруллина Йылдырым Рамиля Асхадулловна**, доктор филологических наук, профессор Адыяманского университета. *Адыяман, Турция.*

**Яхин Фарит Закизянович,** доктор филологических наук, профессор, зав. отделом текстологии Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

**Яхшисарова Гульнара Рашитовна,** научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. *Казань, Россия.*

СОДЕРЖАНИЕ

Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Х. Саләховның сәламләү сүзе . 3
*К.М. Миңнуллин (Казан).* Гаяз Исхакый: халыкка кайту юлы . . . . . . . . . . . . 4
*Д.Ф. Заһидуллина (Казан).* Г. Исхакыйның әдәби иҗаты: милләтне үстерү-үзгәртү юлын эзләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
*Ahmet Kanlıdere (İstanbul, Türkiye).* Ayaz İshaki'nin *Milli Yul* Dergisindeki Yazıları . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
*X.V. Hümmətova (Bakı, Azərbaycan).* Ayaz İsaki və XX əsr Azərbaycan ədəbiyyatında milli özünüdərk düşüncəsi . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
*Р.А. Абзалина (Казань).* Труды в пользу общества будут поводом навечно в радость его души… (Коллекция личных вещей и документов Г. Исхаки в Национальном музее Республики Татарстан) . . . . . . . . . . . 33
*Х.Ч. Алишина (Тюмень).* Татарская диаспора Турции: общественный деятель Менгер Ахмедвали Бин Ибрагим . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
*В.Р. Аминева (Казань).* Аналитический психологизм Г. Исхаки и «диалектика души» Л.Н. Толстого . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
*М.А. Ахметова (Казань).* Реакция Гаяза Исхаки на голод в Поволжье . . . . . . 48
*А.В. Ахтямова (Казань).* Гаяз Исхаки и печатные органы татарских социалистов-революционеров . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
*К.Г. Бадиков (Казан).* Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» повестеның тел-стиль үзенчәлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
*Ф.С. Баязитова (Казань).* Языковые особенности художественных произведений Гаяза Исхаки . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
*Ф.Ә. Бәйрәмова (Яр Чаллы).* Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы һәм Зөләйха образының прототибы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
*И.Б. Бәширова (Казан).* Татар әдипләренең академик басмасы әзерләнгәндә, төп текстның үзенчәлеген саклау мәсьәләсенә карата . . . . . . 76
*Р.М. Болгарова, Э.А. Исламова (Казань).* Сравнения в рассказе Г. Исхаки «Татар гакылы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
*М.Р. Булатова (Казан).* Гаяз Исхакый әсәрләренең морфологик һәм башка тел үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
*Ф.И. Габидуллина (Алабуга).* Г. Исхакый романнарында романтик хыял һәм кырыс чынбарлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
*Л.Р. Гайнанова (Казан).* Мөһаҗирлек сәхифәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
*М.Р. Гайнанова (Казан).* «Гаяз Исхакый даһи бер әдәбиятчы, сәләтле бер мөхәррир, ялкынлы бер инкыйлабчы иде» . . . . . . . . . . . . . . . . 101
*А.М. Гайнетдинов (Казан).* «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендәге голямалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
*Б.Т. Гали (Казань).* Общественно-политическая и историческая деятельность Г. Исхаки в годы революций и эмиграции . . . . . . . . . . . 112

*Э.М. Галимҗанова (Казан).* Гаяз Исхакыйның 1917 елгы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге һәм «Ил» газетасы . . . . . . . . . . 118
*Э.М. Галимова (Казан).* Г. Исхакый әсәрләренең Г. Камал театры куелышында музыкаль бизәлеш үзенчәлеге . . . . . . . . . . 121
*Ф.Г. Галимуллин (Казан).* Яңа әдәбиятыбыз Гаяз Исхакый карашы яктылыгында . . . . . . . . . . 125
*Р.Р. Галиуллин (Яр Чаллы).* Утопические и антиутопические мотивы в творчестве Г. Исхаки, Ф. Амирхана и Г. Губайдуллина . . . . . . . . . . 129
*Т.Н. Галиуллин (Казан).* Без һаман аңа бурычлы (Татар шигъриятендә Гаяз Исхакый) . . . . . . . . . . 133
*Д.М. Галиуллина (Казан).* Г. Гобәйдуллин Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре турында . . . . . . . . . . 140
*Ф.Г. Галләмов (Алабуга).* Г. Исхакый әсәрләренең тел үзенчәлекләре . . . . . . 145
*Л.Ш. Гарипова (Казан).* Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Исхакый көндәлекләре . . . . . . . . . . 151
*В.З. Гарифуллин (Казан).* Гаяз Исхакыйның журналистик эшчәнлеге . . . . . . 155
*İbrahim Gümüş (Bartın, Türkiye).* Kahramanın erginlenmesi bağlamında «Üyge taba» . . . . . . . . . . 162
*Gözde Güngör (Bartın, Türkiye).* Ayaz İshaki'nin «Tormış mı Bu?» adlı eserinde cedidizm algısı ve aydın tipi . . . . . . . . . . 166
*Т.Ш. Гыйлаҗев (Казан).* Гаяз Исхакыйның 1905–1910 еллар публицистикасында проблематика . . . . . . . . . . 173
*Гыйләҗева А.Ф. (Арча).* Г. Исхакый әсәрләрен анализлауда картограмма төзү алымын файдалану . . . . . . . . . . 178
*Э.Н. Денмөхәммәтова (Казан).* Г. Исхакый әсәрләрендә фразеологик синонимия . . . . . . . . . . 181
*И.К. Загидуллин (Казан).* Гаяз Исхаки в петиционной кампании мусульман 1905 года . . . . . . . . . . 186
*Г.И. Зайнуллина (Казань).* Проза Гаяза Исхаки эмиграционного периода . . . 193
*И.Г. Закирова, Г.Р. Яхшисарова (Казан).* Г. Исхакый иҗатында гаилә-көнкүреш йолалары һәм гаилә моделе . . . . . . . . . . 195
*Ч.А. Зарипова-Четин (Карс, Турция).* Монография японского тюрколога Акиры Матсунага «Аяз Исхаки и тюрко-татары на Дальнем Востоке» . . . . 199
*М.З. Зәкиев.* Танылган тюрколог Гаяз Исхакыйны аклау һәм хезмәтләр җыентыгын әзерләп чыгару . . . . . . . . . . 204
*М.И. Ибраһимов (Казан).* Әдәби рецепциянең ике төре: XIX йөз рус язучылары Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге тәнкыйть хезмәтләрендә . . . . 208
*Р.Р. Идрисов (Уфа).*Әмирхан Еники һәм Гаяз Исхакый . . . . . . . . . . 210
*Д.М. Кадирова, Э.Х. Кадирова (Казан).* Г. Исхакый иҗатында каралты-кура атамаларының семантикасы . . . . . . . . . . 214
*A.M. Kamalieva (Bartın, Türkiye).* Ayaz İshakî piyeslerinde milliyetçilik . . . . . . 217
*Г.Ф. Каюмова (Казан).* Гаяз Исхакый иҗатында милли һәм сәяси мәсьәләләрнең чагылышы . . . . . . . . . . 222
*İlyas Kemaloğlu (İstanbul, Türkiye).* İdil-Urallı bilim adamlarının Türkiye'de tarihçiliğin gelişimine katkısı . . . . . . . . . . 226
*З.Н. Кириллова (Казан).* Гаяз Исхакый әсәрләренең тел үзенчәлеге: ияртүче теркәгечле җөмләләр . . . . . . . . . . 230

*Р.В. Кириллова, В.Х. Хакимова (Ижевск).* Автобиографический дискурс в творчестве татарского писателя Гаяза Исхаки и удмуртского классика Кедра Митрея . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
*Arzu Kılınç (İstanbul, Türkiye).* Ayaz İshakî'nin tiyatrosu'nda milli bilinç ve eğitim misyonu . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
*Х.Ю. Миннегулов (Казань).* Гаяз Исхаки и татарская литература зарубежья советского периода . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
*Л.И. Минһаҗева (Казан).* XX гасыр башы татар балалар прозасы: Г. Исхакый иҗаты мисалында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
*Р.А. Минһаҗева (Яр Чаллы).* Хәзерге татар поэзиясендә Гаяз Исхакый образы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
*Ф.Х. Миңнуллина (Казан).* Г. Исхакый драматургиясендә фаҗигалелек («Зөләйха», «Дулкын эчендә», «Олуг Мөхәммәд» әсәрләре мисалында) . . . 260
*Л.Р. Мортазина (Казан).* «Милли байрак» газетасында мәгариф мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 263
*Ә.Р. Мотыйгуллина (Казан).* Г. Исхакыйның 1910–1920 еллар иҗатында «гаилә бөтенлеге» мәсьәләләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
*З.Г. Мөхәммәтшин (Казан).* Милләт мәҗлесе эшчәнлегенә Гаяз Исхакый карашы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
*Г.Н. Мөхәрләмова (Казан).* Г. Исхакыйның «Өйгә таба» повестенда хронотоп бирелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
*Н.Ш. Насибуллина (Казан).* Япониядә татар мөһаҗирләре эшчәнлеге һәм Гаяз Исхакый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
*Г.Р. Насибуллова (Казан).* Г. Исхакый һәм Рифә Рахман әсәрләре арасында интертекстуаль диалог . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
*Г.Ә. Нәбиуллина, Ә.Ш. Юсупова, Г.Н. Галимова (Казан).* Г. Исхакый әсәрләрендә гендер үзенчәлеген чагылдырган стереотиплар . . . . . . . . . 288
*А.М. Нигматуллина (Казань).* Просветительская роль театра и драматургии через призму творчества Ахмета Мидхата и Гаяза Исхаки . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293
*Р.С. Нурмөхәммәтова (Казан).* XX гасыр башы татар телендә милли ризык лексикасы (Г. Исхакый әсәрләре материалында) . . . . . . . . 298
*З.З. Рәмиев (Казан).* Гаяз Исхакый һәм Фатих Әмирхан . . . . . . . . . . . 303
*В.Г. Родионов (Чебоксары).* Эволюция этнического сознания чувашской творческой интеллигенции в начале XX века . . . . . . . . . . . 309
*Ф.К. Сагдеева (Казан).* Ассоциативно-смысловое содержание морально-этических категорий в индивидуально-авторской картине мира Г. Исхаки (на примере прозаического произведения «Теләнче кызы») . . . . 316
*А.Х. Садыйкова (Казан).* Гаяз Исхакыйның «Сөннәтче бабай» әсәрендә милли һәм дини гореф-гадәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
*Ф.С. Сайфулина (Казан).* XX йөз башы милли яңарыш хәрәкәтендә Гаяз Исхакый замандашы Ибраһим Бикколов . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
*А.Р. Салихова (Казань).* «Зулейха» Г. Исхаки на сцене театра им. Г. Камала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
*М.Р. Саттарова, Ф.Х. Габдрахманова (Казан).* Гаяз Исхакый иҗатында дини лексика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
*Э.И. Сафина (Казан).* Гаяз Исхакый әсәрләрендә чагыштырулар . . . . . . . 333

*Р.К. Сәгъдиева, Д.Х. Хөснетдинов (Казан).* Г. Исхакый әсәрләрендә *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчаларының кулланылышы . . . . . . . . . . . 337
*С.Г. Сәмитова (Казан).* Г. Исхакый иҗатында кешенең эчке конфликты . . . . 340
*Ф.Р. Сибгаева (Казан).* Затны тасвирлый торган лексик берәмлекләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре (Г. Исхакыйның «Теләнче кызы» һәм «Нищенка» әсәрләре материалында) . . . 345
*Ayşegün Soysal Akyos (İstanbul, Türkiye).* Martin Hartmann'a göre Ayaz İshakî . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
*Ф.И. Тагирова, И.И. Сабитова (Казань).* Названия одежды в произведениях Г. Исхаки как объект лексикологических изысканий . . . . 354
*И.К. Фазлетдинов (Уфа).* Гаяз Исхакыйның башлангыч чор прозасында герой эволюциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 359
*Д.Р. Фардеева (Казан).* Постановки произведений Г. Исхаки в дореволюционном татарском театре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 364
*И.Ф. Фаттахов (Казан).* Гаяз Исхакый – публицист . . . . . . . . . . . . 366
*К.С. Фатхуллова (Казань).* Языковые трансформации в русском . . . . . . . . 371
*Л.Р. Фәезова (Казан).* М. Юныс публицистикасында милләт проблемаларының үстерелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 375
*Ф.Г. Фәйзуллина (Казан).* Гаяз Исхакый хатларында яктыртылган кайбер әдәби проблемалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 377
*М.М. Хабутдинова (Казань).* Аяз Гилязов и Гаяз Исхаки . . . . . . . . . . . 380
*Д.М. Хайруллина (Бирск).* Отражение системы культурных ценностей в рассказе Г. Исхаки «Күк капусы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 387
*Г.С. Хаҗиева-Демирбаш (Казан).* Гаяз Исхакый әсәрләренең поэтик антропонимикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 391
*Г.М. Ханнанова (Казан).* Камил Мотыйгый белән Гаяз Исхакыйның «Әлгасрелҗәдид» журналы хакында язышкан хатлары . . . . . . . . . . . 395
*Р.Ф. Харрасова (Казан).* Г. Тукайның идея-фәлсәфи эзләнүләре контекстында Г. Исхакый шәхесе һәм иҗаты . . . . . . . . . . . . . . . 397
*Ә.С. Хәйруллина, Г.Ф. Даутов (Алабуга).* Гаяз Исхакый һәм татар әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 405
*А.Я. Хөсәинова (Казан).* Г. Исхакый әсәрләре теленең диалекталь үзенчәлекләре (фонетик диалектизмнар мисалында) . . . . . . . . . . . . . 409
*Г.А. Хөснетдинова (Казан).* «Совет илләрендәниләр бар?» («Яңа милли юл» журналы материаллары нигезендә) . . . . . . . . . . . 412
*М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина (Казан).* Татар телендә тотрыклы төзелмәләр (Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» пьесасына нигезләнеп) . . . . 416
*Hatice Şirin (İzmir, Türkiye).* Ayaz Ishaki'yle başlayan süreçte rejim muhalifi iç sürgünler: Hesen Tufan ve Ibrahim Salahov . . . . . . . . . . . . . . 420
*Н.М. Юсупова (Казан).* Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы әдәби тәнкыйтьтә (XX йөз башы тәнкыйди материаллары нигезендә) . . . . 424
*Р.Ә. Яруллина Йылдырым (Адыяман, Төркия).* Гаяз Исхакыйның «Өйгә таба» повестенда милли кыйммәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . 430
*Ф.З. Яхин (Казан).* Г. Исхакыйның башлангыч чор иҗаты хакында Г. Сәгъди . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 436

Сведения об авторах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 441

**ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ҺӘМ XX ГАСЫР БАШЫНДА**
**ТАТАР МИЛЛИ ЯҢАРЫШЫ**

**Халыкара конференция материаллары**
**2018 елның 6–7 сентябре, Казан шәһәре**

**ГАЯЗ ИСХАКИ И НАЦИОНАЛЬНОЕ ВОЗРОЖДЕНИЕ ТАТАР**
**В НАЧАЛЕ XX ВЕКА**

**Материалы международной конференции**
**6–7 сентября 2018 года, город Казань**

**GHAYAZ ISHAKI AND NATIONAL RENAISSANCE OF THE TATARS**
**AT THE BEGINNING OF THE 20th CENTURY**

**Proceedings of the International scientific conference**
**6–7 September, 2018, Kazan**

Материалы публикуются в авторской редакции

Дизайн обложки *А.В. Булатова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать: 30.07.2018 г.
Формат 70×108 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 39,4. Уч-изд. л. 36. Тираж 500

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12